# Аяз Гилязов

# ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

в пяти томах

2 том

*Пьесы*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Аяз Гыйләҗев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

биш томда

2 том

*Пьесалар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-6
Г92

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, М.Б.Галиев, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

Төзүчесе *Нәкыя Гыйләҗева*

**Гыйләҗев Аяз**

Г92 Сайланма әсәрләр. 5 томда. 2 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 527 б.

ISBN 5–298–01210–8 © Татарстан китап нәшрияты, 2002



# *Киек Каз Юлы*

*Драма ике кисәктә, унике күренештә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Хәлиулла Бадамшин — завод директоры.
Гөлфия — аның хатыны, балалар бакчасы мөдире.
Зөфәр — уллары, химия-технология институты студенты.
Әмин — кече уллары, унынчы класс укучысы.
Нәзилә — карьер цехында мастер.
Ләбиб — директор урынбасары.
Нәҗип — баш инженер, соңыннан директор.
Чая хатын.
Мыеклы кеше.
Күрше карчык.
Кардинал — цех начальнигы.
Халидә — аның кызы.
Алмаз — шофер.
Бәллүр — кранчы кыз.
Кассир карт.
Урам себерүче.
Врач.
I эшче.
II эшче.
III эшче.
IV эшче.
Эшчеләр, кызлар, үтеп баручылар һ.б.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Завод идарәсе янындагы бакчада тыз-быз килеп Алмаз чабып йөри. Вакыт-вакыт ул тәрәзәдән төшкән ут яктысына килеп керә дә ярканат кебек тиз генә югала. Кулындагы сәгатен ут яктысына куеп карый. Якыннан гына уфылдап поезд үтеп китә. Алмаз өметсезләнеп кулын селкә. Бераздан ут яктысы төшкән эскәмиягә килеп утыра. Башын түбән ия. Тынлык. Кайдадыр еракта кызлар чыркылдыйлар, музыка тавышы ишетелеп китә. Тормыш кайный. Алмаз аны да ишетә. Шуңа күрә аңа бигрәк тә күңелсез. Бәллүр керә. Алмазны эзләп таба, башта ачуланып яныннан үтеп китә. Туктап карап тора. Борылып килә.

Б ә л л ү р. Әй, гражданин! Монда йокларга ярамый!

А л м а з. Бәллүр! (*Сикереп тора. Ул гаҗәпләнгән дә, шатланган да.*) Син ничек мине эзләп таптың?

Б ә л л ү р. Эзләп? Фи-и! Алмаз булгач та, сине һәрвакыт эзләп азапланалар иде ди! Аннары караңгы төшкәч, сине эзләп йөрисе дә юк. Директор ишеген саклаудан башка эшең бармы әллә синең?

А л м а з. Ачуланма инде, Бәллүр!

Б ә л л ү р. Аннан ни файда? Ачуланып карадым бит инде! Ә бүген, бүген... Таш яуса да килә торган көн бит бүген!.. Син килә алмагансың икән, менә мин килдем. Соңгы сүзләремне әйтеп калдырырга килдем.

А л м а з (*коты чыгып*). Соңгы?

Б ә л л ү р. Бүлдермә! Бер сәгать буе көтеп торганда күңелемә җыелганнарны әйтеп бетерим... Бер сәгать! Ниләр генә уйлап бетермәдем мин. Ишетәсеңме? Ә сине... бакча каравылчысы итеп куйганнар икән. (*Китә башлый.*)

А л м а з. Бәллүр, Бәллүр! Тыңла әле... Кая барасың?

Б ә л л ү р. Сине каравыллап торыйммы әллә? Берәүләрнең кадерлесе... Урламасыннар тагын!

А л м а з. Хәллә абый һаман чыкмый бит. Китәргә дә ярамый. Янына керсәң дә уңайсыз... Тресттан бик хәтәр җыелыштан кайтты. Бик борчылган.

Б ә л л ү р. Ә-ә! Директорның борчылуын күрәсең икән син! Минем януларымны, машинасы белән берәр чокырга аумадымы икән, дип кайгыруларымны...

А л м а з (*аны бүлдереп*). Нишлим соң?

Б ә л л ү р. Шуны да белмисеңме?

А л м а з (*өметсез*). Җибәрмиләр бит! Завгаражга ни ялындым, директор машинасыннан туйдым, бер кабар җирем калмады дип карадым. Бер коньяк куеп җайларга тырыштым. Директор үзе җибәрми дип риза булмады.

Б ә л л ү р. Әйе, Бадамшин синең кебек уҗым бозауларын җибәрәме соң! Киләм дип сөйгән кызыңа вәгъдә бир, үзең загска бару турында сөйләш һәм китәргә куркып утыр. Андый куян йөрәкләрне кем яратмасын? Җибәрәме соң?

А л м а з. Ипидер, быелдан калмыйм! Йөк машинасына күчәм, алай да булмый икән, заводны ташлыйм!

Б ә л л ү р. Сорый белеп сорамагансыңдыр әле?

А л м а з. Күрешер вакыт җиткәч тәмам акылдан язам дип торам.

Б ә л л ү р. Нәрсә булган соң бу Бадамшинга? (*Тәрәзәгә карап.*) Горкомга чакырып кыздырсалар гына шулай җилләнә торган иде бит ул. Әллә трестта да күрсәтеп, әлпиен укытып кайтарганнармы үзенә? Бирсен Ходай!

А л м а з. Бик кычкырма инде, ишетә күрмәсен.

Б ә л л ү р. Ишетсен! Ишетсен иде әле! Әйткәнем бар инде аңа. Үткән атнада гына мин бу сүзләрне бөтен кеше алдында чыгып сөйләдем.

А л м а з. Шулай да килешми... Җыелыш җыелыш инде ул. Монда тәрәз төбендә... урыны түгел, яхшы түгел...

Б ә л л ү р. Кычкырыйммы?

А л м а з. Куй инде, җүләр...

Б ә л л ү р. Җүләргә нәрсә булсын, кычкыра да бетә...

А л м а з. Ачуландырасың киләме?

Б ә л л ү р. Кемне, синеме?

А л м а з. Юк ла, Хәллә абыйны.

Б ә л л ү р. Менә, менә! Үз күңелендәген ачыктан-ачык директорга әйтергә куркасыңмы, куркасың! Ә нигә алай? Эш сәгатең беткән. Сине монда тотарга хакы юк бит аның. Гомумән, кемнәрнеңдер кәефе өчен нигә үз тормышыңда шулкадәр зыян күрергә! Син хаклы, синең якта дөреслек. Директор да буржуй түгел, коммунист.

А л м а з. Анысы шулай да шулаен, әллә ничек инде... Өйрәнелмәгән.

Б ә л л ү р. Әйе, куркып өйрәнелгән, өркеп өйрәнелгән. Шуңа күрә Бадамшин сине сәгатьләр буе ишек төбе саклата. Уйламый да ул синең хакта. Чөнки син аның шоферы. Ул бүген кыл да кыймылдатмаган, көне буе җыелышта утырган. Син анда да көткәнсең! Юк, болай ярамый. Телисеңме, Бадамшин янына үзем кереп сөйләшәм.

А л м а з (*телсез, өнсез кала*). Син?

Б ә л л ү р. Әйе. Нигә куркып торыйм мин? «Сез Алмазны минем янга җибәрәсезме, юкмы» дип якасыннан алам.

А л м а з (*тәмам аптырап*). Бәллүр, кара әле, бүген Зөфәр әйткән була, сез Алмаз да Бәллүр, өйләнешсәгез балаларыгыз нинди асылташ булыр икән, ди.

Б ә л л ү р. Аһа, Зөфәрме? Директор малае... Шул гына җитмәгән иде. Инде син аны да ташый башладыңмы?

А л м а з. Кычкырма, зинһар, кеше ишетер! Ләбиб абый да монда гына чуала иде...

Б ә л л ү р. Бетте! Син тилене кызганып йөри идем әле мин! Болай булгач кызганмыйм да, уйламыйм да. Киттем-бардым, хуш!

А л м а з (*китә башлаган Бәллүрне туктатып*). Бәллүр, син минем хәлгә дә кер әле...

Б ә л л ү р (*колакларын тота*). Ишетмим.

А л м а з. Әйдә, бакчага керәбез дә иркенләп сөйләшәбез.

Б ә л л ү р. Куркасың бит син анда керергә!

А л м а з. Бакчаданмы?

Б ә л л ү р. Юк, Бадамшиннан.

Алмаз. Ипидер курыкмыйм. Әйдә, кирәк булса, эзләп тә табар. Керәбез дә утырабыз.

Бәллүр. Соңгы мәртәбә, Алмаз! Үз саныңны үзең тотарга вакыт. Яле, курыкмаганда син ничегрәк атлыйсың икән? Раз-два! Раз-два! Шулай, шулай! Тормыш нык булганны ярата. Раз-два, раз-два!

Чыгып китәләр. Сәхнә караңгылана. Югарыдан директор бүлмәсе яктыра.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бүлмә. Бүлмәдә телефон. Графин белән су куелган өстәл. Хәлиулла Бадамшин. Таза гәүдәле ир уртасы кеше. Бертуктаусыз тәмәке тарта. Йөренә. Телефон шалтырый.

Хәллә. Әйе, директор... Бадамшин тыңлый, дим ич!.. Нәрсә?.. Экскаваторчы эшкә чыкмаган? Кинәт авырып киткән? Кем рөхсәт биргән аңа? Ай ахырында гына... Хәзер үк... Язып ал... Беренче... (*Исенә төшә.*) Ә-ә?.. Директор юк монда. Юк, дим, монда беркем дә юк... (*Трубканы куя.*) Әйе, беркем дә юк. Егерме ел завод директоры булып эшләгән Хәлиулла Сөнгатович Бадамшин чәнчелеп төште... Бүгеннән... Бетте Бадамшин! (*Тагын телефон шалтырый.*) Юк, юк! Директор юк! Кайда булсын, өендәдер... Бу... бер үтеп баручы гына! Чит кеше! (*Трубканы куя.*) Ничек шулай булды соң әле? Ничек абайламый калдым мин моны? Комиссиянең отчетында бер дә куркырлык әйбер юк иде ич. Әллә теге җыелышта лыгырдаган җыен кызыл авызларга колак салдылармы? Үзем узындырдым, үзем! Күптән куып бетерергә иде... (*Пауза.*) Әйе, үз бәхетемне ташлап, әллә кая хурлык базына мәтәлеп төштем. Түбәнлеккә... Кая барам мин? Егерме ел директор... Почет, хөрмәт, дан... машина... бар да бетте! Җир селкетеп яшәгән Бадамшин урынына адәм көлкесе бер шәүлә генә калды. Таныш-белешләр нәрсә диярләр? Дошманнар... (*Халыкка карап.*) Сөенәсезме? Көттегезме Бадамшинның егылганын?.. (*Өметсезләнеп.*) Их, күренми торган берәр машина уйлап чыгарасы иде дә бер әйләнеп чыгасы иде үзләрен! Ни сөйлиләр икән? Беләсе иде... (*Өстәлгә каплана.*)

Бүлмә ярым караңгылана. Бадамшинның күз алдына килә башлый. Менә ишекне шакып та тормыйча Мыеклы кеше килеп керә. Хәллә аңа гаҗәпләнеп карап тора.

Мыеклы кеше. Нигә мин кергәндә аягүрә басмадың? Директор вакытыңда да шактый җәелеп утырдың инде. Җитәр.

Х ә л л ә. Нигә аңа шатланасың?

М ы е к л ы к е ш е. Шатланам. Нигә шатланмаска? Үзеңне таш кыяга санап, безне чүпкә чыгарып йөри идең бит син.

Х ә л л ә. Дөнья булгач төрлесе булыр инде.

М ы е к л ы к е ш е. Дөньяны беләсеңме соң син? Шушы кетәктән чыкканың, телефон трубкасыннан башка нәрсә тотканың бармы әллә? Яле, минем кулны тотып кара! (*Хәлләнең кулын кыса.*)

Х ә л л ә (*кычкыра*). Ай!

М ы е к л ы к е ш е. Унике ел электрик булып эшләгән кешенең кулы диләр аны. Майлымы? Унике ел бер заводта эшлибез бит. Шактый гомер, ә? Шул елларда син кабинетыңны гына да алты мәртәбә алыштырдың. Җайлырак, тынычрак, кешеләрдән ераграк урын сайладың. Сиңа кулай булсын, саф һава кереп торсын дип вентиляторлар куйдым мин. Синең күзләрең талмасын дип, бүлмәләреңә көн яктылыгы үткәрдем.

Х ә л л ә. Алты ук булдымыни?..

М ы е к л ы к е ш е. Ә безнең эш урыннарында булганың бармы соң синең?

Х ә л л ә. Булгалыйм ич...

М ы е к л ы к е ш е. Киптерү цехындагы газны иснәгәнең бармы? Аварга торган электр линияләренә күз төшерденме берәр? Чыкканың юк бит синең!

Х ә л л ә. Газ... Газ дисең инде...

М ы е к л ы к е ш е. Өстәл астыңны ач әле. (*Хәллә ача.*) Сиңа хатка салып бер рәсем җибәрделәрме? Шул рәсем инде, шул!.. Завод идарәсеннән бер төркем кешеләр синең табутыңны күтәреп чыгып киләләр. Аста язу «Ниһаять, безнең директор да халык янына чыкты!» Ха-ха-ха! Усал әйтелгән бит, усал! Мин төшердем бит ул рәсемне! Ике көн утырсам утырдым, әмма ясадым. Мин җибәрдем аны сиңа! Нигә имзамны куймадыммы? Ярамый иде бит... Заманы шундый иде! Менә хәзер ачыктан-ачык әйтәм! Ишеттеңме? (*Югала.*)

Ч а я х а т ы н пәйда була.

Ч а я х а т ы н. Ну.

Х ә л л ә. Нәрсә ну?

Ч а я х а т ы н. Мине күрәсеңме?

Х ә л л ә. Күрәм.

Ч а я х а т ы н. Күзең ачылдымы?

Х ә л л ә (*күзен уып*). Ачылды.

Ч а я х а т ы н. Җиде ел мин шушы заводта эшлим. Җиде ел син мине күрмәмешкә салынып йөрдең. Фати-

рым начар, кысан дип сиңа барган идем. Үзеңә күп бүлмәле квартира алган көнне иде ул. Син мине бик озак кабул итми тордың.

Х ә л л ә. Хәтерләмим.

Ч а я  х а т ы н. Ә мин хәтерлим. Яныңа барып кергән идем. Безгә килеп карамасаң, өеңә барам, ятагыннан тартып төшерәм дигән идем.

Х ә л л ә. Монысы да онытылган.

Ч а я  х а т ы н. Озак көттереп булса да килдең син. Машинаңны капка төбендә туктаттың да киң пальто итәкләреңне җилфердәтеп безгә килеп кердең. Кердең, борыныңны җыерып карап тордың да: «Квартира мәсьәләсен урынбасар хәл итә»,— дип, чыгып киттең.

Х ә л л ә. Ул шөгыльләнә шул.

Ч а я  х а т ы н. Үзеңә квартира эшләткәндә буяуларына кадәр сайлап йөргәнсең ич!.. Тагын бер балам булгач: «Күп балалы хатыннар заводка бөлдергеч кенә, эшләвен эшләмиләр, декрет акчасы гына ашап яталар. Алардан котылырга кирәк!» — дип, цех начальнигын син котырттыңмы?

Х ә л л ә. Булгандыр, бәлки...

Ч а я  х а т ы н. Заводны ташлап китсен дип син мине төнге сменага күчерттең.

Х ә л л ә. Төнге сменага кешеләр җитми бит.

Ч а я  х а т ы н. Булганнарының кадерен беләсеңме соң син? Минем кебекләр чыннан да түзмәделәр, ташлап киттеләр. Ә мин түздем. Синең чәнчелеп төшүеңне көттем мин... Ха-ха-ха! Хәзер мин сине теләсә нишләтә алам. Телисеңме, шәп квартирыңнан куып чыгарам? Түшәк-ястыкларыңны тәрәзәдән ыргытам, үзеңне лырк итеп икенче каттан беренче катка... Тәгәрәр идең бер!..

Хатын югала. У р а м  с е б е р ү ч е килеп керә.

У р а м  с е б е р ү ч е. Кәҗә маеңны чыгардылармы?

Х ә л л ә. Ничек кәҗә маеңны?

У р а м  с е б е р ү ч е. Үз борыныңнан башканы күрми башлаган кайберәүләрне урынына утырталар аны шулай. Партиягә рәхмәт, синдәйләргә дә чарасын таба ул! Беләбез бит, ничә мәртәбә чакырдылар, ничә мәртәбә кисәттеләр үзеңне! Ниһаять, көне килеп җитте, күк күкрәгәндә сагаймаган идең, яшен яшьнәтеп очырттылар үзеңне! (*Чыга.*)

К е ш е л ә р берәм-берәм керәләр дә үз сүзләрен әйтеп чыгалар. Хәллә бер сүз дә дәшми.

К а р д и н а л. Кардинал дигән кушаматны син тактың миңа. Имеш мин цехта үз артымнан мастерларны, ялагайларны ияртеп йөрергә яратам. Син бит үзең чит

ил кунагын каршы алган кебек каршы алуны, өер белән озатып калуны таләп итә идең. Әйе. Менә шуңа күрә дә цехны автоматлаштыру хакында синең белән чын-чынлап көрәшергә, сугышырга туры килде. Син мине ничә кат эшемнән куарга теләдең. Эш горкомнарга барып җитте. Шуннан бирле син мине яратмадың. Чөнки син заводта кунак кына идең. Кунакларны заводта түзеп тора алмадым шул. Менә очтың урыныңнан. Үзеңә дә берәр кушамат тагар инде халык. Кем диярләр икән сине?

Кассир. Акчаңны башкалар белән рәттән кассага төшеп алсаң, ярамый идеме әллә? Юк бит... Карт башым белән сөйрәлеп өченче катка менеп йөрим. Өч кат санаганыңны көтеп басып торам. Утыр дияр идең ичмасам! Әнә күрше заводта акчаны кассирсыз гына бирә башлаганнар.

Кешеләр бар да югалалар. Ут көлтәсе тәмам югалып калган Бадамшинны гына яктырта.

Хәллә. Йа Ходай! Бу буталчык дөньяда бер генә якын дустым да, яклаучым да, киңәшчем дә калмадымыни? Кайгымны кем белән уртаклашыйм?.. Тукта... Моңарчы берәр кеше белән ачыктан-ачык, эчкерсез, дустанә сөйләшеп йөрдемме мин? Кем белән? Сизенәм, бөтенесе дә минем борыным канауны көтеп тордылар! Үлмәс борын кабер казыдылар алар миңа! Мә ашагыз, мә! Бәлки менә Ләбиб кенә инде... Ул әйбәт кеше. Кече күңелле. Аннары улым Зөфәр... Анысы үземә охшаган. Тапкыр, кырыс, нык! Эшлекле... Ул аңлар. Ул аңларга тиеш. Ул ата җанлы бала... (*Өстәлгә каплана.*)

Әллә каян караңгылыктан Зөфәр чыга.

Зөфәр. Әти, җаным... беләм... ишеттем. Кайгырма! Син бу заводтан китсәң, монда мин калам әле... Мине икенче курста гына димә син! Әле дә ярый, практикага синең заводны сайлаганмын. Өч елдан инженер булып үзем шушында кайтырмын. Дошманнарыңа үч итеп кайтырмын. Бадамшин, иптәш Бадамшин дип бәбәкләренә кереп торырмын. Минем даным синеке дә булыр. Без аны уртаклашырбыз. Кайгыңны да бүлешеп алырбыз. Әти, хәсрәтләнмә, әти, мин сине ташламам! (*Югала.*)

Бадамшин сикереп тора. Аның йөзендә өмет нуры, эчке горурлык нуры кабынган.

Хәллә. Улым... Балам! Бөтен өметем синдә! Югыйсә мине көнче, вак кешеләр урап алганнар! Шулар дәгъвасы белән мине горкомнарга чакырып тинтерәттеләр, трестта гаепләп чыктылар. Артта калгансың, үсмисең, за-

водның үсешен тоткарлап торасың, диләр. Күрсәт әле, улым, Бадамшиннарның кемлеген! Күрсәт, улым, шуларга!.. Егылганда таянычың булу нинди рәхәт, сөенеч, күңелле икән ул! Шундый дәү, олы җанлы балаң булу нинди зур шатлык! Таланган күңелдә ярма бөртеге кадәр генә булса да өмет бар! Ә бер бөртектән келәт-келәт иген үстергән кешеләр хакында кайда укыган идем соң әле мин? Ә-ә, теге утрауга эләккән бәхетсез сәяхәтчеләр турындагы китапта бит... Менә үзем дә дулкыннар, өермәләр уртасында адашып калган утрауга килеп эләктем. Улым... (*Пауза. Хәллә озак кына итеп су эчә, китәргә әзерләнә.*)

Ишек шакыйлар. Җавап көтеп тә тормастан Л ә б и б килеп керә.

Л ә б и б. Хәлиулла Сөнгатович, кайда югалдыгыз сез?

Х ә л л ә. Мин монда, монда...

Л ә б и б. Өегезгә кагылдым, анда юк... Гөлфия ханым бик борчылып көтә сезне. Онытмыйча аңа шалтыратыгыз...

Х ә л л ә. Кайтып җитә алганым юк... Менә уйлап утырдым да, күз алдыма әллә ниләр килеп китте. Күңелсез хәлләр, Ләбиб. Бу бүлмәдән тизрәк ычкынырга иде. Әллә ниләр уйлап шомланып, тәмам саташып беттем! Өйгә кайтырга!.. Өйгә, өйгә! Гөлфия көтә дисеңме?

Л ә б и б. Нишләмәкче буласыз хәзер?

Х ә л л ә (*Ләбиб каршысына килеп баса*). Ләбиб, син әйт әле. Әйтегез әле... Сез мине яратасызмы?

Л ә б и б. Монда ике сүзнең булуы мөмкин түгел.

Х ә л л ә. Кайчандыр сез миңа: «Без икәү шундый якынайдык, әгәр сез берәр бәхетсезлеккә дучар булсагыз, хуҗасы артыннан калмаган турылыклы бурзай кебек артыгыздан калмам»,— дигән идегез.

Л ә б и б. Ә мин сезне ни өчен эзләп чабам соң? Аяк табаннарым көйдерерлек булды.

Х ә л л ә (*таң калып*). Сез дә заводтан китәргә уйлыйсызмы?

Л ә б и б. Китәргә дә, сезне җибәрергә дә уйламыйм. Сезнең кебек талант иясен, оста җитәкчене шундый вак интригалар корбаны ясарга ярамый...

Х ә л л ә. Кирәкми, Ләбиб... Гәрчә мин сездән нәкъ шушы сүзләрне көттем. Яшермим, шуларны ишетергә теләдем дә. Тик сез әйткәнчә үк куркыныч түгел минем хәлем.

Л ә б и б. Сез бер-бер чарасын күрдегезме инде?

Х ә л л ә. Нинди чарасын?.. Кирәкми... Арыдым мин. Ял итәсем генә килә... Ялгышмасам, сезнең хатын, балачагаларыгыз юк шикелле?

Л ә б и б (*көлеп*). Ялгышмадыгыз.

Х ә л л ә. Кызганыч.

Л ә б и б. Гаилә минем өчен артык зур мәшәкать. Булган бар көчемне, энергиямне җәмәгать файдасына, дусларга сарыф итәм. Кеше кайгысын кайгыртып яшәү миңа аерата бер ләззәт бирә. Бергәләп тотынсак сезнең хәлне бик тиз рәтлибез без!

Х ә л л ә. Кирәкми, Ләбиб. Бәла-казага очраганда үз семьяң, балаларың булу нинди рәхәт икән!.. Сине анда баш булудан, хөрмәтле урыныңнан берәү дә төшерә алмый! Әле генә күз алдымнан күп кешеләр үтеп киттеләр. Берәүләре янады, икенчеләре куркытты, ә өйдәгеләр? Алар юаталар. Анда тынычлык... Кешенең җан тынычлыгы крепосте ул семья!

Л ә б и б. Сезгә өйгә кайтырга ярамый хәзер. Гөлфия ханымга шалтыратыгыз да эшкә керешергә кирәк. Сезнең директор булуыгыз минем өчен дә мөһим!.. Хәзер дусларга шалтыратып, кирәген кисәтеп, җаваплысыннан үтенеп, зуррагыннан ялынып калырга кирәк. Тимер суынмасын, Хәлиулла Сөнгатович!

Х ә л л ә. Өйгә, Ләбиб, өйгә! Туры өйгә генә... Кешеләр аяусыз алар. Синең кебекләр сирәк бит, Ләбиб! Өйгә, туры өйгә генә! (*Чыга.*)

Л ә б и б (*аны ишеккә кадәр озата*). Хәлиулла Сөнгатович, өйгә ашыгып ялгышасыз! Берүк катгый карар кабул итәргә ашыкмагыз! Сезнең өчен үзем тырышып карыйм! Димәк, Бадамшин бетте!.. Аңа өметләнергә ярамый! (*Телефонга бара.*) Галиевлар квартирасын бирегез! Нәҗип Солтанович? Мин әле бу, Ләбиб. Сезне директор булуыгыз белән котларга рөхсәт итегез. Мин бик шатмын. Заводка килеп чыгарга уйлап торасыз? Ял итегез, арыгансыздыр. Монда мин үзем карармын... Йомыш дип, шатлыгымны уртаклашасым килде. Бу көнне күптән көтә идем инде. Бадамшин кебек иске карашлы, тар кеше белән эшләү миңа да бик уңайсыз иде. Эшкә комачаулый иде ул... Ярый, ярый, сезгә уңыш телим!

Бүлмә караңгылана.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакчада бер агач төбендә А л м а з белән Б ә л л ү р утыралар. Бәллүр акрын гына җырлый.

Б ә л л ү р.

Тын бакчада үскән төнге гөлләр
Керфекләрен ачып миңа карый...
Гөл керфеген иркәләгән җылы җилләр
Минем йомшак чәчләремне тарый.

Алмаз. Ә чәчләрең йомшак синең, Бәллүр... Ефәк кебек...

Хәллә керә.

Хәллә. Күңел ачасызмы?

Бәллүр. Ачып ук бетерә алмыйбыз шул. Кайбер кешеләр безнең күңелне бик нык ябалар.

Алмаз. Тс-с... Хәллә абый, озак эзләдегезме?

Хәллә. Юк, бөтенләй эзләмәдем.

Алмаз. Бәллүр, син аз гына көтеп тор. Мин хәзер. Монда уңайсыз була...

Хәллә (*аны бүлдереп*). Көтеп тормасын. Миңа машина бөтенләй кирәкми.

Алмаз. Кайтмыйсызмыни әле?

Хәллә. Җәяү генә кайтасым килә.

Бәллүр. Җәяү йөрү рәхәт кенә бит ул, Хәллә абый. Төне дә бик матур бүген. Җылы, рәхәт... Ул күккә күз салыгыз әле! Әнә Киек Каз Юлы, ука читле келәм төсле булып күкне иңләп яткан. Киек казлар шушы юл буйлап үзләренең туган-үскән җирләрен эзләп табалар, ди. Дөресме икән ул, Алмаз?

Алмаз (*күктән күзен алмый*). Киек Каз Юлы...

Хәллә. Киек Каз Юлы... Таптың кызыгыр нәрсә! Син әнә теге офык өстендә балкыган йолдызга кара. Бөтенесеннән дә нурлырак, яктырак яна ул... Бөтен кеше аны күреп тора... Яшь чагында без шундый йолдызларга карап хыяллана идек... Ниндидер томанлы, төссез Киек Каз Юлына күз салганыбыз да булмады.

Пауза.

Алмаз. Машинаны гаражга илтергә туры килә инде.

Хәллә. Ихтыярың. Теләсәң иртәнгә кадәр чибәр туташыңны йөртә аласың.

Алмаз. Чынлапмы? Путевкага кул куярсызмы?

Хәллә. Кара таңга кадәр мине йөртте диярмен.

Алмаз. Рәхмәт, Хәллә абый!

Бәллүр. Ә хәзер шундый сихри таңнар, Хәллә абый!

Хәллә. Мин, Алмаз, бер нәрсәне ачыкладым әле. Тормышның нигезендә, аның тотанагы булып гаилә ята икән. Шуның өчен сиңа да киңәш: өйләнә тизрәк! Балаларың үссен... Куаныч та алар, юаныч та! Өйгә, Алмаз, өйгә! (*Чыга.*)

Бәллүр. Ни булган аңа бүген?

Алмаз. Дәшмә, май кап. Ни булганын кем белсен дә...

Бәллүр. Путевка хакында сорарга ничек йөрәгең җитте? Синдә дә бармыни ул йөрәк дигән нәрсә?

Алмаз. Таң атканчы үзеңне иң матур урыннарда гына йөртим әле бер. Белгән кебек бензинны да мул алган

идем. Күрсәтим әле үзеңә Алмазда нинди корыч йөрәк барлыгын!

Бәллүр. Ишетмәсәң ишет! Бадамшин белән икегезгә трестта яңа йөрәк куеп җибәрделәрме әллә?

Алмаз. Киттек! (*Чыга башлыйлар.*)

Караңгылыктан Мыеклы кешенең тавышы килә.

Мыеклы кеше. Алмаз, Алмаз!

Алмаз (*Бәллүргә*). Кач тизрәк... Күрмәсеннәр!

Куак артына яшеренәләр. Мыеклы кеше керә. Алмазны күреп ала.

Мыеклы кеше. Әһә, менә син кайда икәнсең. Әйт әле, тегендә синең драндулет торамы?

Алмаз. Драндулет? Тавык күзе булгандыр сиңа.

Мыеклы кеше. Син кая барырга җыенасың хәзер?

Алмаз. Минме? Эш белән йөрим, курыкма. Тресттан бик кәттә бер иптәш килгән, шуны кайтарып куярга кирәк.

Мыеклы кеше. Әй, алай икән лә!.. Беләсеңме, Алмаз, өченче сменага чыгарга тиешле экскаваторчы чирләгән бит, малай.

Алмаз. «Скорая помощь» чакырыгыз. Телефоны ноль три. Момент килеп җитәр.

Мыеклы кеше. Авыруны карарлар! Менә аның урынына эшләргә кеше юк. Тиз генә барып Бадамшинның теге практикант малаен алып кил әле син. Сыкрап булса да таңга сменага чыгарга ризалашмасмы?

Алмаз. Килми ул. Килми. Беләм ич мин аны! Әле көндез: «Фәлән җиргә барасым бар, шулкадәр эшем күп»,— дип торды.

Мыеклы кеше. Иренмә инде, гөжт иттереп кенә барып кайтасы бит.

Алмаз. Бик гөжләми әле. Тресттан килгән кеше көтеп тора. Ярый, сыздым мин... Бик кәттә иптәш ди! Бадамшин үзе җәяү китте, ә моны озатырга кушты! Машинасыз бер адым да атламыйм, ди. Хәтәр кеше! Бик хәтәр...

Мыеклы кеше. Бозыла адәм баласы! Бабалары нинди машинага утырып йөрде икән аның? Кая, күрсәт әле, тресттан килгән шул кошыңны! Үзем сөйләшеп карыйм, булмаса!

Алмаз. Әнә тегендә көтә ул! (*Билгесез якка күрсәтә.*)

Мыеклы кеше. Алып бар янына дим!

Бәллүр (*көлә-көлә куак артыннан чыга*). Ярамый, Алмаз. Бадамшиннарга барырга кирәк.

Алмаз. Кем чакырган әле сине? Урыныңда гына торсаң ни булган?

Б ә л л ү р. Ярамый, Алмаз.

М ы е к л ы  к е ш е. Син дә, малай, Алмаз, килде-китте халык арасында уралып тәмам бозылгансың. Күрә торып тере саескан очырасың.

А л м а з. Сезнең белән үлесен очырырсың! Гомер эченә бер туры килде дигәндә... (*Бәллүргә.*) Күрдеңме? Син мине орышасың да орышасың... Ә монда? Тәгәрмәч эчендәге тиен кебек...

М ы е к л ы  к е ш е. Туры килер әле, башың яшь!.. (*Бәллүргә карап.*) Мин нинди кош икән дип аптырап торам, үзебезнең кранчы кыз икән ләбаса!.. Ярый инде, талагыгыз бик ташый икән, икәүләп барып кайтыгыз!

А л м а з. Тукта әле, кем булдың соң син, миңа боерык биреп маташасың?

М ы е к л ы  к е ш е (*аны ишетмәгән дә кебек*). Караңгырак урамнарга да керергә рөхсәт итәм, тик Бадамшин малаен гына китереп җиткерегез.

Б ә л л ү р. Киттек, Алмаз! Үзе бер кызык булачак!

М ы е к л ы  к е ш е. Аңла, эш бик җитди, урыны бик кыен. Экскаваторга теләсә кемне утыртып булмый... Бадамшин малае иркә булса да, бер тотынгач эшли ул!..

А л м а з. Барырга туры килә инде... (*Мыеклы кешегә.*) Исеңә төшерермен әле мин сиңа моны! (*Чыгып китәләр.*)

М ы е к л ы  к е ш е. Җәһәтрәк йөрегез! Үбешкәндә руленне ныграк тот!

Ашыгып Л ә б и б керә.

Л ә б и б. Син машинаны кая җибәрдең?

М ы е к л ы  к е ш е. Бадамшиннарга.

Л ә б и б. Нәрсәгә анда җибәрәсең син аны?! Хәзер Нәҗип Солтанович килеп җитә. Машина кирәк дисә?

М ы е к л ы  к е ш е. Бадамшин малаен алып килергә кирәк.

Л ә б и б. Ә Нәҗип Солтанович нәрсә әйтер?

М ы е к л ы  к е ш е. Нәрсә әйтсен? Мактарга тиеш. Эшне туктатмагансыз, чарасын тапкансыз дияр.

Л ә б и б. Таптың!.. Ул кичә инженер иде, бүген директор. Аның кайсы якка карап төкерәсен, кайсы почмакка баш орасын кем белсен! Бәлки, ул Бадамшиннар токымының заводта эзе дә булмасын дип куяр!.. Зөфәр кем аркасында практикага безгә килде? Әтисе аркасында. Әтисен очырттылар, бәлки, улын да выжгыртырга кирәктер?..

М ы е к л ы  к е ш е. Килсен генә иде әле... Килсен!.. Килмәсә кая барырбыз? Кайсы почмакка баш иярбез? Шул шул менә!..

Сәхнә караңгылана.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бадамшиннар квартирасы. Бүлмәдә Зөфәр белән Нәзилә.

Нәзилә. Юк, Зөфәр! Син артыгын кыланырга яратасың. Җитди эшең күренми. Менә гитара. Уйнаганың да юк ич синең аны. Ә сатып алгансың.

Зөфәр. Уйнаганым юкмы? Рәхим итеп тыңла әле, кадерле туташкай! Иванов-Крамской ук булмасам да... Гомумән, нигә миңа Крамской булырга? Бездән соң киләчәк буыннар «Зөфәр Бадамшин кебек булырга иде!» дип йөрсеннәр. (*Уйнап күрсәтә.*)

Нәзилә. Һи-и! Моны уен дип атасаң!..

Зөфәр. Ә син аңла, балакай, мин кеше өчен уйнамыйм, үзем өчен генә чиртәм. Ялгыз гына калган чакларымда гитарамны кулыма алам да, кылларын чыңлатып, колагыма куеп торам. Кыллар мине әллә кайларга, сихри дөньяларга чакыралар кебек. Зур эшләргә, батырлыкларга өндиләр.

Нәзилә. Чынмы, Зөфәр?

Зөфәр. Ә син уйный белмисең дисең...

Нәзилә. Димим бит инде... Тик син бар нәрсәне дә үзеңә җыярга яратасың. Бусы миңа ошамый... Иптәш егетең алдырганчы гитара дип авыз да ачканың юк иде... Менә кешеләр белән дә шулай бит син. Аларны үз яныңа җыясың, мактанасың, макталасың килә...

Зөфәр. Бу сиңа ошамыймы, балакай?

Нәзилә. Белмим.

Зөфәр. Әле алда зур гомер юлы бар бит, Нәзилә. Кешеләрне белә, өйрәнә торырга кирәк. Шушы безнең буын кешеләреннән әллә кемнәр чыгар әле... Алар белән... Аннары юкка борчыласың, мин бит сине генә сөям.

Шул вакыт ишек ачыла, нидер шапылдап төшкәне ишетелә. Эзләнеп Әмин керә.

Нәзилә. Әмин, син куян аягы ашаган кеше сыман, баядан бирле бер керәсең, бер чыгасың. Нигә безнең янда утырмыйсың?

Әмин. Вакытым юк. (*Чыга.*)

Зөфәр. Әллә минем яратуым да ошамый инде син балакайга?

Нәзилә. Ә?.. Синең яратмавың борчый мине.

Зөфәр. Кемне, ничек?

Нәзилә. Бик күпләрне! Зөфәр, менә үзең уйлап кара. Синең яныңа бик күп егетләр, кызлар килеп йөри. Нинди төрле-төрле кешеләр алар. Берәүләре хәйләкәр, икен-

челәре гадел. Болары саран, тегеләре аумакай, эчкерле. Ә син аларның барын да бертигез күрәсең. Елмаясың, матур сүзләр әйтәсең... Чәй белән сыйлыйсың. Яратмаган бер генә кешең дә юкмыни синең?.. Бу минем өчен бик мөһим. Ярата белгән кеше нәфрәтләнә дә белергә тиеш.

Зөфәр. Буш теорияләр, мираж борчый сине! Тилекәй, мин сине генә яратам!

Ишек ачыла. Әмин керә. Уңайсыз тынлык.

Кара әле, малай! Син нәрсә һаман минем бүлмәдә буталасың? Мәрхәмәтле атакай сиңа да үз өлешеңне чыгарган: ике тәрәзәле, унике квадрат метрлы бүлмәң бар. Утыр шунда гына алгебраңа атланып.

Әмин. Кемнәрнеңдер үзләренә тигән өлештән артыграгын әләктереп куюларыннан куркам. (*Чыга.*)

Нәзилә. Нәрсә булган бу егеткә?

Зөфәр. Борынына кызлар исе керә башлаган.

Нәзилә. Әйе... Әмингә дә унҗиде яшь бит... Унҗиде яшь... Мин унҗиде яшемдә техникумның өченче курсында идем.

Зөфәр. Син хәзер дә бала-чага бит әле, Нәзилә... Бала булмасаң шундый матурлыгың, төпсез күзләрең белән кирпеч заводында эшләп азапланыр идеңме?

Нәзилә. Син үзең дә кирпеч заводында эшлисең ич.

Зөфәр. Мин практикада...

Нәзилә. Укып бетергәч заводны ташлыйсыңмы?

Зөфәр. Анысы билгесез... Мин ераграк карап, тирәнрәк уйлап яшәргә яратам. Менә шуңа күрә дә син яратмаган кайбер кешеләргә елмаеп карарга да, теләмәгәндә дә аларны чәй белән сыйларга туры килә.

Нәзилә. Бу бит... әшәкелек, Зөфәр.

Зөфәр. Юк, бу — яши белү, балакай! (*Үбәргә тели.*)

Акрын гына атлап Әмин керә.

Әмин. Бик кирәкле бер нәрсәмне тапмыйм.

Зөфәр. Бу бүлмәдә минем әйберләр генә!..

Әмин. Кем белсен? Нигәдер шушындадыр кебек. Күңелем сизә...

Зөфәр. Нәрсә, синең күңелең компасмы әллә? Йә, бар, комачаулап йөрмә әле.

Әмин. Мин комачауламыйм, эзлим генә... Сиңа кирәк нәрсә түгел ул... Син аны белмичә таптап китәргә дә... Йә чыгарып ташларсың... Синең андыйлар күп бит, Зөфәр!..

Нәзилә. Үзем эзләшимме?

Әмин. Юк, юк... Хәзер... Менә шушында гына ул...

Г ө л ф и я белән А л м а з керәләр.

Г ө л ф и я. Улым, Зөфәр, монда сине сорап килгәннәр.

З ө ф ә р. Каян, милициядән түгелме? Ә-ә, бу син икәнсең! Йә, ни йомыш?

А л м а з. Сине алырга килдем.

З ө ф ә р. Мине?

Г ө л ф и я. Атагыз кайтты дип торам. Баядан бирле йөрәгем сызлап тора. Яңгыр яварга дисәм, күге аяз... Машиналар безнең якка борылган саен йөгереп чыгам. Менә машинасы килде, әтиегез юк...

А л м а з. Күптән кайтып китте инде ул... Мәснәви авырган да, менә Зөфәр янына җибәрделәр... Өченче сменага кеше юк. Вилданны калдырыгыз ди теге Ләбиб. Вилдан көне буе ремонтта булган. Җитмәсә хатыны да яңа гына бәбәй алып кайткан икән.

Н ә з и л ә. Уллары булганмы, Алмаз, кызларымы?

А л м а з. Икесе дә.

Н ә з и л ә. Ничек икесе дә?

А л м а з. Берсе малай, берсе кыз. Игезәкләр.

Г ө л ф и я. Менә шәп булган! Вилдан бала бик көтә иде. Җиде ел бәбәйләре булмаган бит!

Н ә з и л ә. Быел малайлар елы дигән булалар тагын...

Ә м и н. Быел, беләсең килсә, сыер елы. Бабайларча әйтсәк.

З ө ф ә р. Аңламыйм, кемнәрдер ул, кыз табалар. Кемнәрдер авырып китәләр. Монда минем ни катнашым бар? Ясле, бакча кирәк булса, менә сезгә Гөлфия ханым: балалар бакчасы мөдире. Инде врач кирәк икән, менә минем кыйммәтле энем Амин Харитонович! Унынчыны уңышлы гына тәмамласам, медиклар мәктәбенә китәм, ди!

Г ө л ф и я. Маймылланма, Зөфәр.

З ө ф ә р. Ах, әни! Тормышның төрле вак-төягенә кагылмасаң иде син!

Н ә з и л ә. Зөфәр, бар, син эшли беләсең! Шәп эшлисең бит син, Зөфәр! Мәснәви абый, хәле булса, үрмәләп тә килә торган кеше.

А л м а з. Ягез, тизрәк уйлагыз! Генеральный ассамблеягә охшый башладыгыз.

З ө ф ә р. Син тик тор. Машинаң тик торса да, синең зарплатаң барамы, бара!

А л м а з. Күптән шулай диләр аны. Әллә кайчан икенең берен әйткән булсаң... (*Чыгарга бара.*)

Г ө л ф и я. Ашыкма, Алмаз. Улым, нигә бармыйсың? Әтиең дә мактамас бу эшең өчен!

З ө ф ә р. Әтиме? Бик әйбәт иткәнсең дияр. Мин бүген

көне буе лекциядә булдым, арып беттем. Миңа ял да кирәк бит! Әти сезнең кебек түгел ул, үз бәясен белә...

Гөлфия. Ә кешеләр нәрсә диярләр? Син иртәгә алар янына барасың бит. Шул ук Вилдан, Мәснәви... Алар бит сине чүкеч тотарга, машина исен иснәргә өйрәттеләр...

Зөфәр. Әллә арган-талган бер студентны көчләп эшләтәсегез килә инде?

Гөлфия. Көчләп эшләтәсем килә.

Зөфәр. Ах, әни, әни! Йөрәгең начар бит синең. Сиңа дулкынлану ярамый. Эш дисең син. Син ул сүзнең русчасын беләсеңме? Ра-бо-та. Раб сүзеннән, кол сүзеннән алынган бит ул. Физик эш машиналар ярдәмендә башкарганда да кешене кол итә...

Гөлфия. Зөфәр, кылануның бер чиге була!

Әмин. Тимә, әни, кыланып калсын!

Зөфәр. Әй син, малай... Кызма, әни. Барам. Синең өчен генә барам! Ә йокым килә, йокым! Кайда минем теге киемнәрем, чыннан да, маймыл итә торган киемнәр! (*Күрше бүлмәгә чыга.*)

Алмаз. Күпме кадерле вакытны әрәм итте. Минем йокым килми менә, иртәнге алтыдан бирле машинада.

Нәзилә. Гөлфия апа, сез ял итегез. Соң бит инде. Болай булгач, Зөфәр бара инде! Мин дә барам.

Гөлфия. Әмин, син капка тирәләрен әйләнеп кер әле. Әтиең күренмәсме?

Әмин. Әни, мин дә заводка барам.

Эш киемнәреннән Зөфәр керә.

Зөфәр. Кая, кая барасың?

Әмин. Заводка.

Зөфәр. Тиләләр, валлаһи, тиләләр! Карагыз әле! (*Тәрәзәне ачып җибәрә.*) Күрмәгән булсагыз, күрегез! Һава нинди, төн нинди! Һәр почмактан мәхәббәт пышылдап тора. Беләм, барырга кирәклеген дә, кеше юклыгын да беләм! Ләкин шушындый төндә менә шушы майлы, салкын киемнәргә төренеп, җиде сәгать буена җансыз балчык дөньясында эшлисе килми шул!

Гөлфия. Ни сөйлисең син, Зөфәр?

Нәзилә. Ул шаярта гына...

Әмин. Юк, ул шаяртмый. Усал кеше шаярта белми.

Зөфәр. Усал кеше төннең матурлыгы белән сокланып торганчы, синең ипи шүрлегеңә менеп төшәр иде инде, малай!

Гөлфия. Балалар, тату гына йөрегез!

Зөфәр. Ах, әни, әни!

Алмаз (*бик нык кына кызып*). Китәбезме, юкмы,

наконец! Машинада тресттан килгән бик кәттә иптәш тә бар әле!

Нәзилә. Киттек. Мин дә барам.

Гөлфия. Атагыз шунда күренмәсме? Зөфәр, сак бул, төнлә эшләп күнекмәгәнсең.

Зөфәр. Курыкма, әни, берни булмас! Барыбер мин теләгәнчә булмады, эшләп кинәним әле бер! Нәзилә, алдан!

Яшьләр саубуллашып шау-шу белән чыгып китәләр. Гөлфия утларны сүндереп йөри. Телефоннан шалтыратып карый. Җавап булмагач, акрын гына кереп китә. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Завод ишегалдында бер калку урын. Еракта машиналар эшләгән тавышлар килеп китә. Мыеклы кеше бик борчылып Зөфәрне көтә. Кардинал керә.

Кардинал. Килмәдеме?

Мыеклы кеше. Директор иркәсен алай тиз генә кузгата алмассың.

Кардинал. Ат урлаткач кына сарай бигенә тотынгач шулай булмый ни. Теге вакытта ни әйттем, оештырыйк курс, механика цехындагы һәр кеше экскаватор йөртә белергә тиеш, дидем.

Мыеклы кеше. Директор кирәкми диде бит.

Кардинал. Кеше фикере белән бер дә санашмый шул. Ярар, теге малай килеп тә куандырмас инде... Мин түбәндә булырмын. Сменаны кабул итәргә кирәк. Килеп җитсәләр, ашыктыр. (*Чыга.*)

Пауза. Бераздан Зөфәр, Нәзилә, Алмаз, Әмин керәләр.

Алмаз. Кем бу? Мыек, синме? Менә алып килдем.

Мыеклы кеше. Болары кемнәр?

Зөфәр. Почет каравылы.

Алмаз. Конвой диген!

Зөфәр. Син, шома егет, мине алып килмәдең, мин үзем килдем. Аңыштыкмы? Икенчедән, иртән смена бетүгә, капка янында бул.

Мыеклы кеше. Килмисез дип кот чыккан иде. Яхшы булган. Алмаз, син тагын кирәк әле миңа.

Алмаз. Юк инде, мыекбай! Җитәр! Муеныма менеп атланасың гына калды, болай да!

Мыеклы кеше. Вилданны озатып куй инде, малай. Ул каланың иң читендә тора. Трамвайларга ышанып юлга чыксаң, үзе кайтып җиткәнче, балалары үсеп бетәр.

А л м а з. Кәтигәрически булмый.

М ы е к л ы  к е ш е. Әй, балаларын күрсәң иде! Игез булсалар да шундый дәүләр, икесе дә түп-түгәрәк!

А л м а з. Бәлки, минем хатынның да игез бала китерәсе килә торгандыр. Сезнең аркада ике ел инде өйләнә алмый йөрим. Иртәдән бирле юньле-башлы ашаган юк.

М ы е к л ы  к е ш е. Күптән әйтәләр аны. Тамак ялгарсың дип, апаң күкәй пәрәмәче тыккан иде. Аша. (*Куенынннан төргәк алып бирә.*)

А л м а з. Кем булдым соң әле мин? Тегендә йөгертәләр, монда чаптыралар. Миңа директор башмы, әллә сезме?

Н ә з и л ә. Эш кыенга киткән синең, Алмаз!

М ы е к л ы  к е ш е. Син кемме? Кеше. Шул җитмиме сиңа? Кешедән дә өстенрәк чин юк ул, җанкисәгем. Аннары машиналарны директорлардан алалар дигән хәбәр дә бар әле.

З ө ф ә р. Башкасы белән килешергә була, әмма соңгысын арттырдың, мыекбай иптәш.

М ы е к л ы  к е ш е. Синең әтиең урынында булсам, мин машинада йөрергә оялыр идем.

З ө ф ә р. Нигә, дәүләт үзе биргән ич.

М ы е к л ы  к е ш е. Төнге уникедә сменадан кайтучыларны гына кара син, автобус көтеп зар җылыйлар. Әтиең урынында булсам, шушы драндулетны тапшырып, бер шәп автобус алып җибәрер идем.

З ө ф ә р. Булсаң шул ул... Әлегә әти директор. Хәлиулла Бадамшин. Ишеттеңме? Ул директор, ә син кем?.. Сезнең икегезне ике камырдан әвәләгән.

М ы е к л ы  к е ш е. Алайса, аның камырына чүпрәне артыграк салганнар. Артыграк кабарган да ачыган.

Гудок тавышы.

З ө ф ә р. Әнә күктән изге чакыру инде. Йә, чибәр туташ, озатып куюыгыз өчен мең-мең рәхмәт. Хәзер кайтсагыз да була. Ә мин чумдым.

Н ә з и л ә. Зөфәр, син бар, төш! Мин аз гына монда булам әле.

З ө ф ә р. Көч биреп торырга уйлыйсыңмы? Кирәкми, без үзебез дә... Тик төшәсем килми... Килми! Һоп! (*Чыгып китә.*)

А л м а з. Йә, тагын кая барырга кушасың инде?

М ы е к л ы  к е ш е. Бар, капка янында Вилданны көт. Хәзер җибәрәм мин аны. Хуш, Нәзилә. (*Чыга.*)

А л м а з (*кычкырып кала*). Пәрәмәче өчен апага рәхмәт әйт! Бәллүр көтә бит мине анда!.. Бетә инде минем башкайларым, әлегә инде бүген миңа! (*Чыгып чаба.*)

Ә м и н (*паузадан соң*). Кем бу мыеклы абый? Берәр начальникмы?

Н ә з и л ә. Түгел. Электрик. (*Пауза.*) Йә, нигә килдең инде монда?

Ә м и н. Электрик... Ә син?

Н ә з и л ә. Мин Зөфәр килгәнгә.

Ә м и н. Ияреп кенә йөргән кешеләрне яратмыйм мин.

Н ә з и л ә. Син яратмасаң, Зөфәр ярата.

Ә м и н. Ул буйсынганны, кол булганны ярата. Кеше кеше булып күренми аңа. Ул бу яктан этигә охшаган.

Н ә з и л ә. Абыең хакында мондый сүзләр сөйләп йөрү әйбәт түгел.

Ә м и н. Беләсеңме, безгә килеп йөрмә син.

Н ә з и л ә. Нигә?

Ә м и н. Мин сине ялгыз гына Зөфәр янында калдырырга куркам.

Н ә з и л ә. Тешләшәме әллә?

Ә м и н. Үз бүлмәсенә килгән кызларның барысына да бер үк сүзләрне сөйли ул.

Н ә з и л ә. Син!.. Малай актыгы! Бервакытта да кеше хакындагы начар хәбәрләрне сөйләмә! Ишеттеңме?

Ә м и н. Ә мин яратканга сөйләсәм?

Н ә з и л ә Ул чагында бигрәк тә сөйләмә.

Ә м и н. Мин бит сине яратам, сине!

Н ә з и л ә. Мин моны күптән беләм, Әмин.

Ә м и н. Беләсең? Кем әйтте? Зөфәрме?.. Ул миннән гел көлә... Сиңа язган хатымны табып укыган.

Н ә з и л ә. Юк, ул әйтмәде. Үзең әйттең...

Ә м и н. Кайчан?

Н ә з и л ә. Мин Зөфәр янына килгән беренче кичне.

Ә м и н. Шул заманнан бирле эчтән генә көлеп йөрдеңме?..

Н ә з и л ә. Бала гына бит әле син, Әмин.

Ә м и н. Баладa да арыслан йөрәге булырга мөмкин.

Н ә з и л ә. Арысланның йөрәге кешенекеннән күп кечкенә диләр.

Ә м и н. Телисеңме, мин син ни телисең шуны үтим?

Н ә з и л ә. Алайса, бик әйбәтләп кайт та алгебраңны укы. Иртәгә имтиханың.

Ә м и н. Ә син?

Н ә з и л ә. Утырам әле.

Ә м и н. Зөфәрне көтәсеңме?

Н ә з и л ә. Көтәм. (*Пауза.*) Сәер кеше синең абыең. Мине шундый серле, сәер кешеләр ныграк тарта.

К а р д и н а л керә.

К а р д и н а л. Яшьләр нишли? Хыялланамы? Сәлам мастерга! Смена вакытында түбәндә, смена беткәч югарыда каравылда икән син...

Н ә з и л ә. Кирәкми... Артыгын бер сүз дә сөйләмәгез.

К а р д и н а л. Ә нигә ят кеше төнлә завод ишегалдында йөри?

Н ә з и л ә. Ул ят кеше түгел, директор малае.

Ә м и н. Минем директор малае булуымны яңадан беркемгә дә әйтмәгез. Начар кушамат ул.

К а р д и н а л. Дөрес! Кушамат белән йөрмәскә кирәк!

Ә м и н (*көлеп*). Кайчагында йөрергә туры килсә дәме?

К а р д и н а л. Булгалый. (*Әмингә.*) Карьерга карап торасың. Кызыгасыңмы?

Ә м и н. Белмим. Әмма бүген анда булырга теләр идем. Бигрәк тә бүген.

К а р д и н а л. Экскаваторда синең абыең инде, алайса. Йоклап йөри торган гына егет иде ул, бүген ничектер ут өертә!

Н ә з и л ә. О-о! Күрсәтер әле ул сезгә үзенең кемлеген!

К а р д и н а л. Шулай да әйбәт! Студент халкын заводта эшләтеп бик шәп итәләр хәзер. Кул куям мин моңа. Абыең да инженер булып чыга калса, заводка эшченең бәясен белеп киләчәк. Ә менә әтиең,— яман сүз сөйләүдән түгел, мисалга гына алуым,— парта арасыннан гына безгә баш булып килде. Бүгенгедәй хәтеремдә, берзаман безгә яңа директор килгән, диделәр. Мин механика цехында слесарь булып эшли идем. Килгән бу. Шундый кукрайган, яшь әтәч кебек. Эшләпәләр киеп җибәргән. Дәшми. Кешеләрне түгел, машиналарны карый. Китаптан шуларны гына укыган бит. Станокларга чиертеп-чиертеп торды да, чыгып барганда гына безгә таба борылды. Теш арасыннан гына сызгырына: фю-фю. Үзе чиртә, үзе миңа карамыйча гына: «Шәмсетдин Суфьянович сез буласызмы?»— дигән була, үзе һаман: фю-фю!

Ә м и н. Моны миңа түгел, әтинең үзенә сөйләгез.

К а р д и н а л. Сиңа да ярап куяр... Яши генә башлагансың. Белсәң ярап куяр... Әнә абыең... Йә, ярар... Мастерның кәефе кырыла. (*Чыга.*)

Н ә з и л ә. Ярата да инде сөйләргә! (*Пауза.*) Әмин, нигә кайтмыйсың?

Ә м и н. Калдырып китәргә куркам...

Н ә з и л ә. Алайса, үзең белән алып кит.

Ә м и н. Синеме, Нәзилә?

Н ә з и л ә. Юк, мәхәббәтеңне. (*Пауза.*) Бүлгәләмә син аны, Әмин. Шул зур килеш, ялкынлы килеш сакла. Сафлык зур нәрсә бит ул. Гадәттә аны кызлардан гына таләп итеп ялгыш эшлиләр.

Ә м и н. Ялкынлы килеш... Әнә ай да калка... Ул меңнәрчә еллар буена гашыйкларның күзләренә карап тора. Бәлки шуңа да матурдыр ул?.. Кайтасыңмы?

Н ә з и л ә. Утырам әле... Рәхәт монда. Мин ялгыз гына яшим бит. Өйдә күңелсез. Кул сәгатенең пружинасы сүтелгәненә кадәр ишетелеп тора. Бәхетле кеше аны ишетмәскә тиеш. Сәгать йөргәнен тыңлап ятасың да гомер үтүен уйлап хафаланасың.

Ә м и н. Чыннан да рәхәт монда. Башым сафланып китте. Җылы. Су коенасы килә.

Н ә з и л ә. Менә карьерның бу почмагыннан балчык алып бетерәбез дә су җибәрәбез. Бик әйбәт, тирән күл булачак.

Ә м и н. Күп балчык чыгаргансыз инде сез.

Н ә з и л ә. Кара, бер район төзеп тә куйдык бит.

Ә м и н. Бик күп.

Н ә з и л ә. Зөфәр умырта. Ишетәсеңме, машинасы ничек улап куя?

Ә м и н. Ишетмим. Мин синең йөрәк тибүеңне тыңлыйм.

Н ә з и л ә. Син Кардиналга үпкәләмә, ягымлы кеше ул.

Ә м и н. Үзең үпкәләмә.

Н ә з и л ә. Кара, бу Зөфәр нигә ул якка борылды әле? Аннан балчык алырга ярамый бит. Кырыйда гына электр баганалары.

Ә м и н. Үзе дә беләдер инде...

Н ә з и л ә. Аннан балчыкны алу ансатрак. Баганаларны күчерергә йөриләр...

Ә м и н. Эш күп сезнең монда...

Н ә з и л ә. Тагын да күбрәк булачак.

Ә м и н. Син нигәдер борчылгансың. Йөзең ап-ак булган.

Н ә з и л ә. Ай нуры төшкәнгәдер.

Ә м и н. Әйдә, йөреп киләбез!

Н ә з и л ә. Кая барабыз? Соң бит инде...

Ә м и н. Телисеңме, мин сине озатып куям!

Н ә з и л ә. Булмаса булган икән, озат, Әмин!

Чыга башлыйлар. Кинәт бөтен җирдә ут сүнә. Тоныкы кына булып ай яктысы кала. Тавышлар тына. Еракта нидер ишелә. Кемдер ачы тавыш белән кычкырып җибәрә.

Ә м и н. Ни булды?

Н ә з и л ә. Кем кычкырды? Зөфәрме?

Ә м и н. Белмим. Юк бугай...

Н ә з и л ә. Утлар сүнде...

Ә м и н. Әллә...

Н ә з и л ә. Әйдә карьерга, әйдә, Әмин!

Ә м и н. Көтик бераз!

Н ә з и л ә Юк, юк! Бу Зөфәр! Аңа ни булды икән? Әйдә, әйдә. Мин юлны беләм. Егылма, монда ташлар бар.

Чыгалар. Бераздан куркынган, күзе тонган З ө ф ә р чабып керә.

З ө ф ә р. Ни булды бу? Кемне үтердем мин? Нишләргә? Качаргамы? Нишләдем мин? Нишләдем? Кая барырга? Кая? Кем коткарыр мине. Кем аралап алыр? А-а-а! Өйгә, өйгә, эти янына! Өйгә, өйгә!..

П ә р д ә т ө ш ә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бадамшиннар өе. Зал. Г ө л ф и я ялгыз гына китаплар караштырып утыра. К ү р ш е к а р ч ы к керә.

К ү р ш е к а р ч ы к. Һаман ятмагансың икән...

Г ө л ф и я. Үзең дә, Зарифа апа...

К ү р ш е к а р ч ы к. Йокы алмый. Урамнан йөреп керим дисәм, тәрәзәгездә ут бар. Ишекләрегез ачык. Хәллә кайтканда болай озак утырмый торган иде, мин әйтәм... Кердем...

Г ө л ф и я. Ул барында да кер.

К ү р ш е к а р ч ы к. Зур кеше бит. Уңайсыз. Күзенә чалынасым да килми. Урамда-мазарда очраганда да тезләрем калтырый.

Г ө л ф и я. И-и син бигрәк тагын!

К ү р ш е к а р ч ы к. Әллә картлык галәмәте, әллә өйрәнелмәгән, белеп булмый... Йә, ярый, чыгыйм әле! Йокы алмый, йокы...

Г ө л ф и я. Зарифа апа, утыр әле. Болай коры гына чыгып китү уңайсыз ич. Кайнаган чәем бар. Берүземә генә күңелсез дә...

К ү р ш е к а р ч ы к. Рәхмәт, кая ул!.. Буыннар каткан, йокы да качкан... Кара әле, синең янга нигә кергәнемне онытып чыгып барам икән... Исемә төште... Фәгыйләнең кызын бакчага урнаштыра алмассыңмы? Көндез аларга кергән идем, ялгызын бикләп калдырып эшкә йөри икән.

Г ө л ф и я. И, Зарифа апакаем, урыннары юк бит аның! Тагын бер бина булмаса, ул балалар белән кая барырбыз инде?

К ү р ш е к а р ч ы к. Үзең беләсең инде, үзең... Бала бит... Шундый матур кыз. Барган идем, алма ашап йөри.

Алмаңны миңа да бир әле, тәтием, дигән идем, бу алма түгел бит, суган, шундый а-ачы-ы! дигән була. Менә хәйләкәр! (*Кеткелди.*)

Г ө л ф и я. Суган диме?

К ү р ш е  к а р ч ы к. Фәгыйләнең үзен төнге сменага йөртәләр икән. Ире кичке институтта укый. Анысы анда йөгерә, монысы монда. Бала берүзе төн саклый. Үзенә әйтеп карамассыңмы?

Г ө л ф и я. Хәлиулла эш турында сөйләшкәнне яратмый яратмавын да, шулай да уйлашырбыз әле...

К ү р ш е  к а р ч ы к. Шул гына иде. Ярый, ачуланма... Йокы алмый. Өченче фатирдагы хатынның ире командировкага киткән. Берүзе болай да шүрләп тора, җитмәсә, ике бушбугаз моның тәрәзәсе төбенә килеп куркытып бетергәннәр бичараны... Куып җибәрдем үзләрен... Замановларның малае велосипедын югалткан... Менә йөрим шунда... Йокы алмый...

Г ө л ф и я. Фәгыйләгә әйт, вакыт табып бакчага кереп чыксын. Бәлки, берәр җаен табарбыз...

К ү р ш е  к а р ч ы к. Менә рәхмәт!.. Кызы бик матур шул. Күзләре зәп-зәңгәр. Нәкъ җитен чәчәге төсле инде менә. Яшь чагында җитен йолкырга бик ярата идем мин. Андый зәңгәр күзле кызлар безнең заманда гына була торганнар иде... (*Чыга.*)

Гөлфия борчылып телефонга бара. Шалтыратып карый. Пауза. Ишекне ачык калдырып күрше бүлмәгә чыга. Акрын гына атлап Х ә л л ә керә. Урындыкка утыра. Телефон шалтырый.

Х ә л л ә. Әйе... Зират?.. Юк, юк! Нинди зират булсын!

Г ө л ф и я керә.

Г ө л ф и я. Бик озак тордың, әтисе Хәллә. Нигә ишекләрне ачык калдырдыгыз? Малайлар өйдәме? Мин кергәндә генә кемдер баскыч күләгәсенә качып калган кебек булды.

Г ө л ф и я. Зарифа апа гына ул.

Х ә л л ә. Нинди Зарифа?

Г ө л ф и я. Күрше карчыгы.

Х ә л л ә. Нәрсә ул, картаеп беткәч өрәк шикелле төне буе йөри? Бер-бер хәсрәте булса ярар иде... Изелеп, ишелеп ятасы урынга. Менә җүләр!..

Г ө л ф и я. Йоклый алмыйм, ди.

Х ә л л ә. Шул шул, көне буе йокы бүсәләр дә, төне буе убыр шикелле йөриләр...

Г ө л ф и я. Бик озак тордың, әтисе...

Х ә л л ә. Озак... Озаграк шул... Зөфәрне чакырып керт әле.

Г ө л ф и я. Өйдә юк. Эшкә китте.

Х ә л л ә. Ничек эшкә? Төнләме?

Г ө л ф и я. Килеп алдылар.

Х ә л л ә. Ах, хәерсезне... Киңәшәсе сүз бар иде!

Г ө л ф и я. Берәр нәрсә капкалыйсыңмы?

Х ә л л ә. Нәрсә бар?

Г ө л ф и я. Бар да бар. Эремчек, каймак, салкын ит. Чәй.

Х ә л л ә. Калын итеп кара икмәк кис тә тоз сибеп бир әле.

Г ө л ф и я. Нәрсәгә ул?

Х ә л л ә. Кара икмәкнең тәмен беләсем килеп китте.

Г ө л ф и я. Кара икмәгем юк шул.

Х ә л л ә. Күршеләрдән алып тор.

Г ө л ф и я. Вакыт бик соң инде. Зарифа апаларга керсәм генә...

Х ә л л ә. Аларга кермә. (*Телефон шалтырый.*) Алло!.. Нинди зират булсын бу! Квартир, дим ич... Квартир!

Г ө л ф и я. Кайчагында малай-шалай шаярткалый.

Х ә л л ә. Өлкән кеше тавышы.

Г ө л ф и я. Салкын ит китерим булмаса?

Х ә л л ә. Җәяү кайттым әле. Урамнар тарайган кебек... йортлар тәбәнәк. Юаш безнең шәһәр! Шулай сыман тоела. Башын игән... Мәкерле дә сыман. Караңгы урамнардан үткәндә кемдер артымнан килеп өстемә сикерер төсле... Әле дә ярый кешенең кайтып егыла торган өе, кыен вакытларда кайтып сыена торган хатыны, уллары бар!.. Безнең урам якты... Ишегалдына гына кайсы тилесе шундый зур лампочка элгәндер!

Г ө л ф и я. Үзең куйдырган идең ич.

Х ә л л ә. Йоклап булмый... Тәрәзәдән яктысы төшә... Аннары нинди эш инде ул, урамга аяк басарлык түгел. Бөтен кеше синең кая баруыңны, ни эшләвеңне күреп тора!

Г ө л ф и я. Кызлар янына йөрергә чамалыйсыңмы әллә, этисе?

Х ә л л ә. Кем белсен... (*Кинәт.*) Зөфәр кайда соң әле? Ә-ә, эштә дидең бугай...

Г ө л ф и я. Онытканчы әйтим әле, теге Фәгыйлә бар ич әле?

Х ә л л ә. Кайсы Фәгыйлә?

Г ө л ф и я. Алдынгы эшче дип бүләк тә биргән идегез, Саматова.

Х ә л л ә. Йә?

Г ө л ф и я. Шуның кызын бакчага урнаштырып булмасмы икән?

Х ә л л ә. Саматова... Хәтерләмим. Кешеләрне оныта башладым инде хәзер. Усаллык эшләгәннәрен күңелдә асрыйсы килми, яхшылык эшләгәннәрен саклар идең, андыйлары юк... (*Тагын телефон шалтырый.*) Әйе... Квартир... Карагыз әле, бирермен мин сиңа зиратны! Ә-ә, көләсеңме, хулиган! Мә, көл! (*Телефон трубкасын өзеп ала.*)

Г ө л ф и я. Ай, этисе, өзеп үк чыгардың бит.

Х ә л л ә. Кирәге дә шулкадәр генә...

Г ө л ф и я. Син нигә чишенмисең?

Х ә л л ә. Каядыр китәрмен кебек... Юлга, билгесез, озын юлга чыгар алдыннан күңелдә шундый авыр сагыш була... Кая, бир булмаса салкын итеңне! (*Чишенә.*)

Г ө л ф и я. Фәгыйлә хакында әйтмәдең?..

Х ә л л ә. Нәрсә әйтим? Минем аңа бер катнашым да юк.

Г ө л ф и я. Нигә булмасын? Син бит директор. (*Пауза.*)

Х ә л л ә. Юк, әнисе, ялгышасың. Мин директор түгел инде.

Г ө л ф и я. Ни булды, Хәлиулла? Берәр әшәке эшме?

Х ә л л ә. Ни булды, ни булды? Ә мин каян белим? Горкомнан килеп казындылар, казындылар да трестка чакырып приказ тоттырдылар. Менә шул. Ә син сорау алырга керешәсең...

Г ө л ф и я. Мин, Хәлиулла, белергә генә телим. Соңгы вакытларда синең ватылып, борчылып йөрүеңне сизә идем... Сөйләсәң икебезгә дә җиңелрәк булыр.

Х ә л л ә. Кирәкми, сорама. Үзем өчен дә җавап таба алмыйм. Җир тишеге булса, кереп дөмегер идем дә шуннан чыкмас идем. Болай исә үземә атап казыганны котәргә калды инде. Башкача яшәүнең мәгънәсе калмады... Җәяү кайттым! Шуңа күрә озак тордым. Трамвайга утырырга базмадым. Танышы-фәләне очрый башлар... Әнә берсе телефоннан үчекли бит. Белми шалтырата дисеңме син аны? Ишеткән ул хулиган! Менә шуңа куана! Беләм, анда бар да миңа теш кайрыйлар...

Г ө л ф и я. Адәм башыннан төрле хәлләр кичә...

Х ә л л ә. Кешеләрнең явыз икәнлеген белә идем, әмма бу кадәр үк шөкранасыз, рәхимсез булырлар дип уйламый идем...

Г ө л ф и я. Тынычлан, этисе!

Х ә л л ә. Тынычланмый нишлисең? Минем кулда хәзер тылсымлы пичәт юк... Шушы кулларым белән сейфта бикләп калдырдым мин аны...

Г ө л ф и я. Өр-яңадан яши башларга кирәк, Хәлиулла. Яңарып, сафланып...

Х ә л л ә. Минем яңадан шул заводка баруымны, гомерем буе директор булып эшләгәннән соң балчык арасына төшүемне телисеңме? Юк! Монысы булмас! Туйдым мин ул явыз кешеләрдән, туйдым! Улларым, Зөфәрем булмаса бер минут яшәмәс идем!

Ашыгып З ө ф ә р кайтып керә.

З ө ф ә р. Әни, такси көтеп тора, ике сум гына бир әле.

Г ө л ф и я. Улым, син нигә эштә түгел?

З ө ф ә р. Соңыннан, әни бәгырем, соңыннан! Түгел, эштә түгел! Тизрәк бул. Акчаң кайда? Кесәмдә бер тиен дә юк икән...

Г ө л ф и я. Ике сум бик күп бит ул...

З ө ф ә р. Мин аргы урамнардан урап кайттым.

Г ө л ф и я. Мә, чыгарып бир. (*Акча бирә.*)

З ө ф ә р. Әнием, кадерлем, чыгарып та бир инде. Әти белән сөйләшеп аласы сүз бар иде.

Х ә л л ә (*нечкәргән күңел, җылы хис белән*). Улым... ишеттең дәме?

Г ө л ф и я. Ярар, алайса... (*Чыга.*)

Х ә л л ә (*тора. Зөфәрне кочаклап ала*). Зөфәр, мин синнән башканы көтмәгән дә идем...

З ө ф ә р. Әти...

Х ә л л ә. Мин, улым... Минем улым!

З ө ф ә р. Әти... Миңа синең зур ярдәмең кирәк...

Х ә л л ә. Шулай, улым... Без бер-беребезгә ярдәм итәрбез. Таянычым, тотнагым инде син минем. Күңелемә килгән иде, юк, Зөфәр ишетсә, түзмәс, кайтыр дигән идем...

З ө ф ә р. Әти... Синең ашыгыч ярдәмең кирәк миңа!

Х ә л л ә. Тукта, ярдәмем дисеңме?

З ө ф ә р. Синең исемең, танышларың, якыннарың, дәрәҗәң кирәк! Синең кодрәтең генә ярдәм итә ала миңа. Син генә мине бу бәладән йолкып ала аласың!

Х ә л л ә. Исемем, дусларым, кадерем, дәрәҗәм...

З ө ф ә р (*түземсезләнеп*). Әти... Мин ялгыш кына кеше үтердем...

Х ә л л ә. Мине дә үтерделәр...

З ө ф ә р (*аяк тибеп*). Кеше үтердем, кеше! Ишетәсеңме?

Х ә л л ә. Ә? Тукта! Ни сөйлисең син, юньсез!

З ө ф ә р. Мин сизми дә калдым. Водокачка ягыннан балчык төйи башлаган идем, һич алдырып булмый. Шуннан азлап-азлап завод ягына каерылганмын. Мин ерак дип торам әле... Яр ишелде, электр баганалары авып берәүнең өстенә чыбык төшкән...

Х ә л л ә. Булмас! Үзең күрдеңме?

Зөфәр. Юк, мин монда ашыктым, әти. Прокурордан алданрак өлгерергә кирәк. Юкса соң булыр. Син мине коткарып кала аласың, әти. Сине тыңлыйлар, яраталар анда. Минем төрмәгә эләгәсем килми. Килми! Өчәр смена балчык төяргә риза, тик синең заводыңда калдырсыннар гына. Җир себерергә риза, институттан кумасыннар гына. Синең бер сүзең, бер сүзең җитә бит анда.

Хәллә. А-а! Юк, юк!.. А-а! Мин директор түгел инде... Мин уйлаган идем...

Зөфәр. Син?

Хәллә (*таркау*). Әйе. Бүген приказ булды.

Зөфәр. Син?! Нишләрмен инде хәзер?

Хәллә. Мин нишләрмен, мин диген син!

Зөфәр. Сиңа нәрсә булсын?! Нәрсә, әйт әле!

Хәллә. Зөфәр улым, өметем, таянычым!..

Зөфәр. Нишлиләр бит, нишлиләр! Әти җаным, бер генә ай директор булып кала алмадыңмы? Эшне үзгәртеп корам, үзем дә нигездә үзгәрәм дияргә иде. Андый урыннарда вәгъдә биргәнне яраталар бит! (*Пауза.*) Кемне куйдылар? Нәҗипнедер әле? Шайтан алгыры! Кешесе дә табылып тора бит аның... Институттан куалар, төрмәгә утырталар инде болай булгач!

Хәллә. Теге кешенең хәле ничек икән?

Зөфәр. Ах, әти! Шуны сорап торыр чакмы соң? Аныкы нәрсә, үлгән дә беткән. Монда терeләрнең хәле яман!

Хәллә. Алай димә, улым...

Зөфәр. Мин каян белим? Бик беләсең килсә барып кайт!

Хәллә. Син нәрсә? Син нәрсә?

Зөфәр. Белмим, нишләгәнемне дә белмим! Әтием, кадерлем, утырма. Бар киен, прокурорны күр, дусларыңны җайла! Коткар мине.

Хәллә. Булмый. Алай ашыгып ярамый... Зөфәр! Булмый...

Зөфәр. Булмыймы? Халык синең хакта дөресен сөйли икән. Кабинетта кычкырынырга сине куш, йөрәкләнеп берәр эш башкарырга синнән булмый, булачагы да юк! Улыңны бәладән коткарып та кала алмагач...

Хәллә. Зөфәр! Тукта!

Зөфәр. Таянычым, таянычым, имеш! Син ул минем таянычым! Һәм ул менә шундый икән... Чыннан да Бадамшин түгел, Мадамшин икән син...

Хәллә. Зөфәр, син акылыңдамы? Ни сөйлисең син?

Гөлфия керә.

Гөлфия. Нигә шулкадәр кычкырышасыз?

З ө ф ә р. Сохари әзерлә, анакай, төрмәгә утырырга барам.

Х ә л л ә. Тиле малай, әниеңә шулай диләрме?

Г ө л ф и я. Тавышыгыз урамга ишетелә. Утырышыгыз. Менә шулай. Йә, ни бар?

З ө ф ә р. Йә, әйт, әти! Йолып аласыңмы мине?

Х ә л л ә. Ни әйтим соң сиңа?

З ө ф ә р. Алайса, тыңла, әни, менә шушы Мадамшин аркасында төрмәгә китәргә туры килә.

Х ә л л ә. Дурак! Син ачыгавыз булып кеше үтереп йөр дә, мин синең өчен муенымны кисәргә биримме?

Г ө л ф и я. Кеше? Нигә шундый коточкыч сүзләр сөйлисез? (*Йөрәген тота.*)

Х ә л л ә. Бар, әнисе. Монда син тыңларлык сүзләр юк әле.

Г ө л ф и я. Ай... (*Йөрәген тота.*)

Х ә л л ә. Әнисе, әнисе! Нәрсә катып торасың. Шалтырат тизрәк...

З ө ф ә р. Алло! Алло! Телефон эшләми бит!

Х ә л л ә. Төзәт, кулын чергән нәрсә!

З ө ф ә р. Әмин кайда соң? Коралы да юк бит кирәктә...

Г ө л ф и я. Кирәкми... Йөрмәгез... Теге бүлмәдәге караватка гына салыгыз... Үтә ул... Безнең гаиләдә нидер булырга тиеш дип күңелем сизә иде...

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бадамшиннар өе. Иртә. Баштa бер яктан кереп Х ә л л ә үтеп китә. Ул картайган, йончыган. Икенче яктан кереп З ө ф ә р үтә. Алар сөйләшмиләр. Ә м и н керә.

Ә м и н. Мин иртәрәк китим әле.

З ө ф ә р. Кая ашыгасың?

Ә м и н. Иртәрәк барып, иртәрәк биреп чыгасы иде.

З ө ф ә р. Син югында өйдәге эшләрне кем карар?

Ә м и н. Әнигә чәй кайнатып керттем.

З ө ф ә р. Миңа да калдырдыңмы?

Ә м и н. Шунда, кухня өстәлендә.

З ө ф ә р. Табармын.

Ә м и н. Мин озак тормам.

З ө ф ә р. Үзең чамала инде... Әй, тукта әле...

Ә м и н. Йомышың бармы?

З ө ф ә р. Син тегендә заводта булгансың икән...

Ә м и н. Йә. Булса? (*Пауза.*)

З ө ф ә р. Теге... Ну, беләсең бит инде... Ничегрәк икән? Үләрлекме, юкмы?

Ә м и н. Үзең барып карарга иде.

З ө ф ә р. Йә, йә! Акыл өйрәтмә!

Ә м и н. Хәле авыр. Үләр диләр...

З ө ф ә р. Үләр диләр? Ах, шайтан алгыры! Шул вактөяккә дә үләрлек булгач ник туган ул?!

Ә м и н. Анысын сорарга оныткаңмын. Аннары ул җавап та бирә алмас иде... (*Чыга.*)

З ө ф ә р. Нишләргә? Нишләргә?

Х ә л л ә керә.

Х ә л л ә. Төннең озынлыгына синең бераз ачуың килмәме?

З ө ф ә р. Килми. Төн гадәттәгечә.

Х ә л л ә. Нигә әниең янына бер дә кереп чыкмадың?

З ө ф ә р. Авыру кешене карарга яратмыйм.

Х ә л л ә. Минем бүлмәгә кереп хәлен сорашыр идең.

З ө ф ә р. Врачлар килеп карады бит инде, куркыныч булса, алып китәрләр иде.

Х ә л л ә. Шулай да...

З ө ф ә р. Минем бүлмәгә дисең син... Кызык кына яңгырый. Кичә болай сөйләшүеңә ис китми иде. Минем завод, минем малайлар, минем бүлмә, минем машина... Син миңа гаять зур бер кеше кебек күренә идең. Баксаң, син дә гап-гади, күз төпләре җыерчыкланган гадәти бер адәм икәнсең.

Х ә л л ә. Зөфәр... Кичә мин түздем... Әниең хакына түздем. Бүген җанымны кыздырма...

З ө ф ә р. Кызып нишли алырсың икән?

Х ә л л ә. Күрмәгәнеңне күрсәтермен.

З ө ф ә р. Анысын син булдырырсың! Син менә, кулыңнан килсә, мин күргәнне күрсәт. Бар да элеккечә калсын. Без синең белән тагын якын дус булырбыз...

Х ә л л ә. Әйе... Шактый шомаргансың син... Мин күрми дә калганмын... Бурычларыңны түләргә әниеңнән яшереп акчалар алганда, институтка кергәндә булышканда син башкачарак идең. Алдыма тезләнмәгән генә идең...

З ө ф ә р. Вакытында барын да эшли белергә кирәк дип син өйрәттең түгелме? Ә синең сүзең минем өчен закон иде. Хәтереңдәме: «Кирәк икән, тезләнә дә, ялына да бел. Тормыш үзе шуны куша». Ләкин мин сине шундыйдыр, бәләкәй генә җилдән дә бөкрәеп төшә торган кешедер дип уйламый идем. Күрәсең, власть кешеләргә көч бирә, аларны кеше күзе алдында танымаслык батыр ясый...

Х ә л л ә. Ахмак малай, власть кына түгел, син дә мине көчле итә идең.

З ө ф ә р. Мин? Ха-ха-ха! Ничек?

Х ә л л ә. Син көләсеңме? Көлә аласыңмы? Зөфәр, Зөфәр! Әтиең шундый хәлдә, әниең... Тукта! Аптекага барырга кирәк бит. Мә әле. Йөгереп кенә аптекага барып кил. Әниеңә дару кирәк...

З ө ф ә р. Бармыйм, андый вак-төяк йомышларга Әминне йөгерт.

Х ә л л ә. Үз күз алдыңда чыгып китте бит.

З ө ф ә р. Китсә, кайтыр. Имтиханнарын алдан бирә ул. Җүләр... Икмәктер җүләр! Иң арттан керергә кирәк. Имтихан алучының күзләре арып, әлҗе-мәлҗе килә башлагач кына керергә. Үзенең эче чурласын, үзе тыңлап утырган булсын. Белсәң дә, белмәсәң дә бишле куеп чыгарачак. (*Хәлләгә хәйләкәр карап.*) Әмин синең вәгазьләргә аз колак сала бит, сизәсеңме?

Х ә л л ә (*басынкы, төшенке тавыш белән*). Әниең чәй эчкәч тынычлап йоклап китте.

З ө ф ә р. Шулаймыни?

Х ә л л ә. Уянганчы дару алып кайтырга кирәк. Ишетәсеңме, хәзер үк бар!

З ө ф ә р. Бүген булмый...

Х ә л л ә. Нигә булмый?

З ө ф ә р. Үзең бар. Бер гимнастика булыр. Зиһенең ачылып китәр. Сиңа файдалы ул... Аптека ерак түгел: ике квартал тәпиләсәң, берне тыракласаң барып та җитәрсең...

Х ә л л ә. Бармыйсың, алайса?

З ө ф ә р. Исәп шулай. Ә син?

Х ә л л ә. Минме? (*Кара-каршы басалар. Икесенең дә урамга чыгарга куркуларын аңлыйлар. Хәллә телефонга тотына, ул ватык.*) Ах, черт!

З ө ф ә р. Зарланма. Эчәгесен үзең чыгаргансың.

Х ә л л ә. Телефонны гына төзәтеп бир инде, хәсрәт-студент!

З ө ф ә р. Аның миңа кирәге юк. Мин бөтен дөнья белән дипломатияне өзгән. Вакытлыча, әлбәттә!

Х ә л л ә. Тфү!

З ө ф ә р. Менә бусы антигигиенично! Идәнгә төкерергә ярамый. Анакай хезмәтче тотуга каршы. Үзе авыру. Идәнне мин юып йөри алмам.

Х ә л л ә. Барып кил инде...

З ө ф ә р. Оһо! Син ялына да башладың? Тиз үзгәрәсең син! Уйла башың белән, кая җибәрәсең син мине? Аждаһа авызынамы? Кая бара алам мин? Юк, син бу бәладән мине коткармыйча торып, мин беркая да бармыйм...

Х ә л л ә. Әйе... Коткарырга... Ләкин ничек? Бу бит әниеңнән качырып акча түләү түгел... Кемгә барып егылыйм?

З ө ф ә р. Их, мин синең кебек егерме ел совет хөкүмәтенә тир түккән булсам!.. Белер идем!.. Әти җаным, ачуланма миңа, минем кичәдән бирле башым буталды... Гафу ит мине... Бердәнберем дип сөя идең син мине бәләкәй чакта... Шулай сөй, ярат мине...

Х ә л л ә. Кирәкми... Үткәннәрне искә төшермә!

З ө ф ә р (*ялагай, төче тавыш белән*). Китик без моннан, әти, Урта Азиягә, Себергә, Казахстанга... Пичәтең үзеңдә бит әле. Документлар ясыйк та ычкыныйк... Акчаң да бар бит синең. Әни белми торган акчаң.

Х ә л л ә. Малай! Ахмак малай! Әтиеңне сукбай булырга кыстыйсыңмы?

З ө ф ә р. Алайса, мине йолып аласың...

Х ә л л ә. Булдыра алмыйм... Әле кичә уйлап караган булыр идем... Бүген булдыра алмыйм! Үземнең дә кеше күзенә күренер хәлем юк. Битем кара, өстем-башым керле кебек... Күрмәс идем сине, беркемне, борылып карамас идем сиңа, кап-кара урман уртасына кереп ятар идем дә бүре булып улар идем...

Ишектә звонок.

З ө ф ә р. Бар әле, белеш, кем икән?

Х ә л л ә. Аягың-кулың исән, бар да ач.

З ө ф ә р. Миңа килер кеше юк, килсә сиңа килгәннәрдер.

Х ә л л ә чыгып әйләнеп керә.

Кемгә, нәрсә кирәк?

Х ә л л ә. Әминнең иптәшләре.

З ө ф ә р. Яңа баралармы? (*Пауза.*)

Х ә л л ә. Аптека кайда дисең әле?

З ө ф ә р. Милиция идарәсе янында. Барасыңмы? Күптән шулай кирәк иде. Кара, эш турында да уйла.

Х ә л л ә. Белмим. Ни әйтергә дә белмим. (*Пауза.*) Әйе, яланаяк чыккач кына урамда күпме пыяла ватыклары аунаганын күрәсең...

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам чаты. Бер якта аптека ишеге. Ч а я  х а т ы н басып тора. Х ә л л ә керә. Ул хатынны танымый. Чая хатын аның белән кыюсыз гына исәнләшә.

Ч а я  х а т ы н. Исәнмесез, Хәлиулла абый.

Хәллә. Ә, исәнмесез, исәнмесез. Аптека биклемени?

Чая хатын. Бикле шул әле. Баядан бирле көтәм инде. Һаман ачылмый.

Хәллә. Җидедә үк ачыла дигән бит.

Чая хатын. Кая инде җидедә! Сигезгә килеп җитсә дә куанырсың. Үзәктәге аптекаларда гына инде ул рәт. Монда теләгәндә ачып, теләгәндә ябып йөриләр.

Хәллә. Нигә алай? Болай ярамый. Чарасын күрергә кирәк.

Чая хатын. Бик кирәк тә, чарасын күрергә тиешле кешеләр иртән җидедә торып аптекаларга чапмыйлар. Менә мин якшәмбе көн саен ялымны мунча чиратында уздырам. Барган саен зарланып кайтам. Безнең кадерле вакытларыбызның чиратларда тилмереп үткәнен бер дә күрмиләр микәнни, дип офтанам. Картым әйтә, күрергә тиешле кешеләр үзләре әллә кайчан ванналы квартираларга күчеп беттеләр инде, ди.

Хәллә. Шулайрак бугай шул!..

Чая хатын. Шулайрак түгел, бик шулай! Элек вакытның чамасы юк чагында чиратларга ис китми иде. Хәзер эш көннәре кыска, ялны да шәбрәк уздырасы, вакытның кадерен беләсе килә.

Хәллә. Әйе, әйе... Вакыт бик кадерле, гомер бик санаулы шул.

Чая хатын. Төнге сменадан кайттым гына әле. Балам өйдә ялгыз гына. Зуррагын авылга җибәрдек. Кичәсе менә авырып китте.

Хәллә. Яслегә бирмәдегезмени?

Чая хатын. Чират җитми. Туганчы ук язылып куясы калган. Акыллы кешеләр әнә шулай итәләр ди. Анысын уйлаган да юк инде, көндезге сменага күчерсәләр дә бик куаныр идем...

Хәллә. Нигә, мөмкиндер ич ул?

Чая хатын. Мөмкинен мөмкиндер дә... (*Уңайсызлана.*)

Хәллә. Әйе, әйе... (*Пауза.*)

Чая хатын. Төне дә әллә нинди булды бүген. Эшләмәдек, энергия булмады.

Хәллә. Шулай булган икән шул.

Чая хатын. Әллә сез заводта булмадыгыз? Чирләпфәлән яткансыздыр инде... Алайса, Шәмсетдин абзыйны да күрмәгәнсездер әле?

Хәллә. Күреп үк өлгермәдем.

Чая хатын. Хәле бик-бик авыр, ди, мескеннең. Авызы чалшайган, бер кулын бөтенләй кымшата да алмый икән. Үкчәсе кара көеп имән кисәве төсле булган. Те-

релсә дә, аксак, кыек авызлы булып калыр дигәннәр врачлар...

Хәллә. Аксак?.. Нигә бу аптекачы килми инде?!

Чая хатын. Нинди дару кирәк иде соң сезгә?

Хәллә. Менә йөрәк даруы.

Чая хатын (*рецептны карап*). Һи-и! Сезгә кирәкле дару монда юк та әле. Кичә генә күршедәге бер абый шундыйны сораткан иде. Тимер юл аптекасында гына бар ул.

Хәллә. Бәлки, бүген тапканнардыр?

Чая хатын. Булмас. Жалоба кенәгәләренә әле кичә генә язып чыктым... Беләсезме, бирегез миңа язуыгызны. Үзем алып өегезгә кертермен. Бик ипле хатын бит ул Гөлфия апа... Сезнең заводка барасыгыз да бардыр. Директор башыгыз белән монда тормассыз инде.

Хәллә. Сирәк-мирәк директорларга да комачауламый... Аннары директор түгел инде мин.

Чая хатын. Ишеттек. Директор булмасагыз Нәҗип абыйга ярдәмләшерсез. Таң алдыннан гына күргән идем үзен. Бик йончыган иде, бичара.

Хәллә. Бар да буталып бетте шул... Ә безнең өйне беләсезме?

Чая хатын. Сезнең өйнеме? Белмәскә, беләм, әлбәттә.

Хәллә. Ә менә мин сезнекен белмим... Барганым да бар шикелле... Тик белмим... (*Чыга.*)

Чая хатын. Үз гомеремдә беренче тапкыр чиратта рәхәтләнеп тордым... Директорлар белән дә сөйләшәсе килә кайчакта. (*Көлә.*)

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бадамшиннар өе. Зал. Ашыгып кайтып кергән Хәллә Күрше карчык белән очраша.

Хәллә. Син?.. Сез монда нишлисез?

Күрше карчык. Менә кибеткә барган идем. Син ярата торган кефир бар икән. Снежок. Алдым әле... Шуны керттем.

Хәллә. Минем нәрсә яратканны кайдан белдегез?

Күрше карчык. Аллага шөкер, нәрсә яратмаганыңны да беләбез. Күршеләр ич без!

Хәллә. Рәхмәт. Рәхмәт, алайса.

Күрше карчык. Гөлфиягә торып йөрергә ярамый. Синең вакытың да юктыр... Заводта да эшләр чуалып тора икән.

Хәллә. Шулай сөйлиләрме?

Күрше карчык. Ишетелә шунда...

Хәллә. Әйе... Хәлләр бик үк шәптән түгел.

Күрше карчык. Гөлфия өчен борчылма син... Әле кайнар шулпа керттем. Кирәгем булса, шушында өй арасында гына чуалам. Зарифа атлы булам мин.

Хәллә. Дәшәрмен, Зарифа апа.

Күрше карчык чыга, Хәллә озата бара. Пауза. Нәзилә керә. Ул Хәллә белән очрашуны көтмәгән, уңайсызлана.

Нәзилә. Исәнмесез...

Хәллә. Ярый...

Нәзилә. Мин... Мин Зөфәр янына килгән идем.

Хәллә. Килсәң, әнә сөйләш... Үз бүлмәсендә...

Нәзилә (*ишекне шакып*). Зөфәр, Зөфәр! Бу мин... Ач әле... Әйе... Әйе. Бу мин, Зөфәр! Нигә киттең син төнлә? Нигә ташлап киттең?.. Ач әле...

Зөфәр. Ачмыйм.

Нәзилә. Нигә?

Зөфәр. Ачмыйм. Кирәкми. Килмә син монда яңадан.

Хәллә. Чыннан да, нигә килдең әле син монда? Җомга көннәрне тимер капка янына передачалар ташыйсың киләме?

Нәзилә. Әйтегез әле, нигә минем белән сөйләшми ул?

Хәллә. Аңа син кирәкмисең хәзер. Юкка килгәнсең. Ярдәм итәрлек көчең юк. Нишләтә аласың? Юк, хәзер син аңа кирәкмисең! Буяма исемеңне... Бар кайт.

Нәзилә. Нигә алай? Нигә?

Хәллә. Аңа син дә, мин дә кирәкми хәзер...

Нәзилә. Нигә алай?

Хәллә. Сорама... Заводта ниләр бар?

Нәзилә. Үзегез шуннан кайттыгыз ич...

Хәллә. Барып җитә алганым юк әле. Ерагайдым.

Нәзилә. Электр линиясен вакытлыча җибәрделәр. Линияне карьер яныннан бөтенләй күчерәләр.

Хәллә. Кардинал... Шәмсетдин ни хәлдә?

Нәзилә. Хәле бик авыр ди... Нәҗип абый да больницага китеп калды...

Хәллә. Нәҗип абый, Нәҗип абый!.. Ә син нигә бармадың?

Нәзилә. Ничек барыйм инде, Хәллә абыкаем? Монда киләсе иттем. Нишлим соң? Ниләр булып бетәр инде, Хәллә абый?

Хәллә. Тагын ниләр башланыр диген син!

Нәзилә. Шәмсетдин абый үлсә, Зөфәргә нәрсә булыр?

Х ә л л ә. Менә шул шул! Йөрмә син монда! Бар кайт!

Н ә з и л ә. Кайтырлык булсам, килмәс тә идем. Күрсен әле ул мине, сөйләшсен! Нигә качты икән ул төнне? Нигә бүген кача? Инде сез дә мине куасыз... Икесе дә миңа бик якын кешеләр бит... Бик якын... Әгәр Шәмсетдин абый үлсә... Мин китә алмыйм. Ни булыр аңа?

Х ә л л ә. Белмим, ышан менә, белмим. Мин бүген бернәрсә дә аңламыйм. Бүгенге көн минем моңарчы булган гомеремә бер тамчы да охшамаган. (*Пауза.*) Былтырдан бирле кигән ботинкаларым. Хәтта бүген алар да кыса башладылар! Күлмәгем муенымны буа!

Ишектә звонок. Хәллә телефонга тотына.

Алло, алло! Ах шайтан, эшләми бит! Хәтер чуалып беткән. (*Тагын звонок.*) Ачык ишеккә сыймый башлады берсе!..

М ы е к л ы к е ш е килеп керә.

М ы е к л ы к е ш е. Менә мин килеп тә җиттем. Көттегезме?

Х ә л л ә (*шикләнеп*). Килгәнсең шул. Утырып җибәр.

М ы е к л ы к е ш е. Утырып тормыйм. Йокы килә. Утырдым исә йоклап китәм... Килгәндә трамвайга утырган идем. Бара-бара оеп киткәнмен. Сезнең тукталыш әллә кайда калган. Берзаман төрткәләп уяталар. Ике-өч квартал җәяү сыпырттым. Урамда җил... Рәхәт... Кешеләргә бәрелеп узам... Кайсыберләре сүгенә. Мине бераз салган дип уйлыйлар, ахры... Ә мин көләм! Салулар эләкмәде бүген! Тю-тю! Төне буе баш күтәрмичә эшләдем бит... Заводны туктатырга ярамый иде, иеме, Хәллә абый?

Х ә л л ә. Завод? Әйе, завод эшләргә тиеш. Аны туктатырга ярамый иде...

М ы е к л ы к е ш е. Туктатмадык! Бүген туктатырга ярый идеме соң. Безнең яндагы тыкрыкта гына балалар бакчасы сала башладылар. (*Көлә.*) Безнең кирпечтән!

Н ә з и л ә. Ә син... Нишләп монда килеп чыктың әле.

М ы е к л ы к е ш е. Син нигә килсәң, мин дә шуңа...

Н ә з и л ә. Син дә?

М ы е к л ы к е ш е. Мине Нәҗип абый җибәрде... Дөресрәге, кайтышлый сугылып чык, диде. Телефоннары да эшләми, рәтлә әле шуны, диде. Карыйммы, Хәллә абый?

Х ә л л ә. Ремонт бюросыннан чакырткан булыр идек...

М ы е к л ы к е ш е. И-и, аннан килгәнче аны!..

Х ә л л ә. Менә өзелгән.

М ы е к л ы к е ш е. Шушы гынамы? Безгә нәрсә бу?

Без Дунайны да кичкән кеше. Сугышта связьдә булдым мин. Малай гына идем әле үзем. Анда менә дүртәр тәүлек йокламаган чаклар да булды... (*Төзәтә башлый.*) Юк, бүген заводны туктатырга һич тә ярамый иде. Яңа директор килгән иде, завод туктап калды димәсеннәр. Шәмсетдин абый да рәнҗеп ятмасын... (*Төзәтә-төзәтә җырлый.*)

Чылтыр-чылтыр ни чылтырый?
Ат өстендә ыңгырчак.
Без җырламый, кем җырласын,
Безнең самый җырлар чак...

Нәзилә елап җибәрә.

Нәзилә. Әйе... Җырлар чак...

Мыеклы кеше. Ә син, үскәнем, җылама. Бәлки, безнең барыбызга да шулай ук авырдыр... Иптәшебез бәлагә тарыган икән, без барыбыз да бераз гаепле...

Хәллә. Сез сөйләшмичә генә эшли аласызмы?

Мыеклы кеше. Сөйләшмәскә дә була, ләкин аңа карап кына хәл үзгәрми бит... (*Пауза.*) Менә булды да. (*Номер җыя.*) Булды да... Завод! Галия! Синме бу? Ну тавышың! Көмеш кебек чылтырый. Яңагым чылтырамасын дисеңме? Шаян, директор квартирыннан мин, Галия... Син мине ишетәсеңме? Төзәттем!.. (*Чүгәләгән җиреннән йоклап китә.*)

Хәллә. Чү, егылды бит бу малай!

Нәзилә. Йоклый. Арыгандыр.

Хәллә. Йоклый йоклавын. Нишләтергә соң аны?

Нәзилә. Бите кап-кара. Елмая-елмая йоклый... Төш күрәдер. Машина чакыртыйк та озатыйк булмаса. Монда комачаулар гына.

Хәллә. Тимә, йокласын... Бигрәк тәмле итеп мышный... Бала кебек...

Нәзилә. Пычратыр бит. Өсте-башы бик каралган.

Хәллә. Каралтмас. Каралтса да зыян юк. (*Мыеклы кешене күтәреп салалар.*) Йокла әйдә! Менә монда йокла! Шулай. Аякларыңны сузып җибәр...

Нәзилә. Мендәр дә булса...

Хәллә. Хәзер. (*Бүлмәдән мендәр алып чыга. Кыстырып куялар.*)

Әмин керә.

Әмин. Әти, мин алгебраны бишкә бирдем... Нәзилә дә мондамы?

Хәллә. Ә? Алгебраны? Шәп булган.

Әмин. Тик син нигәдер сөенмисең, әти. Әни ни хәлдә?

Х ә л л ә. Әниең әйбәт... Әйбәт!

Ә м и н. Ишек төбендә бер апа басып тора. Дару китердем, ди. Керергә уңайсызлана. Менә миңа гына бирде. (*Шешә белән дару бирә.*)

Х ә л л ә. Нигә үзе кермәде икән?.. Рәхмәт әйтәсе иде бит... Тукта әле, китмәдеме ул?

Ә м и н. Очты гына. Үзем дә рәтләп күрми калдым.

Х ә л л ә. Өйгә керегез дип әйтсәң телең калыр идеме? Алгебраны бишлегә өйрәнәсез. Ә кешегә... Җайсыз булган, җайсыз. Өемдә балам ялгыз дигән иде! Чыгып карыйм әле! (*Чыга башлый. Каршысына кассир карт очрый.*)

К а с с и р. Уф, көчкә эзләп таптым. Исәнмесезләр!

Х ә л л ә. Сез? Сез нигә килеп чыктыгыз?

К а с с и р. Килдем. Акча. Миңа бит бүген ведомостьларны тапшырырга кирәк, Хәлиулла Сөнгатович! Бик әйбәтләп кенә кулыгызны куегыз да акчагызны алыгыз.

Х ә л л ә. Бүген зарплата көнемени әле?

К а с с и р. Бездә бирәү акча алган саен, зарплатаны зерәплата дип әйтә-әйтә ала. Әмма сезгә зерәплата китермәдем, Хәлиулла Сөнгатович, хәләл акча. Менә санап алыгыз. (*Ведомость күрсәтеп.*) Бадамшин — директор...

Х ә л л ә. Директор... Юк, юк, санамыйм. Мин сезгә ышанам.

К а с с и р. Юк, сез санагыз. Ашыкмагыз. Мин сезне эзләп тапканчы гына ашыктым. Килергә, дим. Карчыгыгыз да сырхаулап тора икән. Өйдә авыру булган көнне акча су кебек ага инде ул. Заводта кылбырдак киләләр... Акча бирергә кешеләрне табып булмый. Көндезге сменалар, төнгеләр дә бар да шунда... Экскаваторны казып чыгарганнар... Көчкә эшемне бетердем. Шәмсетдиннең кызы килгән. Закон буенча ышаныч язуыннан башка акча бирергә ярамый... Бирдем. И-хи-хи! Бик авыр ята, ди. Авыр... Япь-яшь кеше!

Х ә л л ә. Рәхмәт сезгә, булды менә.

К а с с и р. Тагын менә шушы ведомостька гына кул куеп җибәрегез дә...

Х ә л л ә. Анысы нәрсә?

К а с с и р. Бусы премиальныйлар. Планны үтәдек бит. Күпме премиальный гына аласыз. Әйбәт ич? Бик күпләр алдылар. Рәхим итеп кулыгызны...

Х ә л л ә. Юк, бусына кул куймыйм.

К а с с и р. Ничек куймыйсыз?

Х ә л л ә. Акчагызны кире алып китегез.

К а с с и р. Булмый, Хәлиулла Сөнгатович! Бухгалтериядә андый статья юк. Мин ул акчаны кая куйыйм?

Х ә л л ә. Теләсә нишләтегез... Әмма мин... Бүген... Ул акчаларны алырга хакым юк...

К а с с и р. Как так юк? Баш бухгалтерның имзасы бар, инженер да кул куйган.

Х ә л л ә. Теләсә нәрсә уйлагыз! Булмый! Һәм яңадан бу хакта, зинһар, сүз кузгатмагыз! Берчагында да!

К а с с и р. Мин карт җүләрне дә тыңлагыз әле... Артыгын борчыласыз... Бар да җайланыр. Тормыш шундый бит ул. Анда абынып, сөрлегеп куйган чаклар да була. Ләкин тирә-ягыгызга күз салыгыз әле. Бар җирдә дә үз кешеләр, якыннар. Алар янында моңаерга ярамый! Кайгы да, шатлык та өйгә генә, бер кеше күкрәгенә генә сыймыйлар алар. Безнең халык кайгысын да, шатлыгын да уртак итәргә күнеккән... Шулай җиңелрәк була... Ярар, алайса, боларын соңрак алырсыз... Мин көтәрмен... Бухгалтериядә булмаса да, тормышта андый статья да бар ич! Ярый, хушыгыз! (*Чыга.*)

Х ә л л ә. Хушыгыз. (*Нәзиләгә.*) Исемен әйтәсем килә, оныткамнын бит. Фамилиясен беләм, исемен белмим. Әйтә алмадым... Әллә элек тә белми идемме?

Ә м и н. Әти, синең урында булсам, мин дә алмас идем ул акчаларны!

Х ә л л ә. Тик тор, малай! Синең акыл җитә торган эшме бу?.. (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Ә м и н. Тагын ачуланды... Мин берәр сүз әйттемме, кыза.

Н ә з и л ә. Ә син әйтмә. Түз... (*Зөфәр ишегенә бара.*) Зөфәр, Зөфәр! Син мине ишетәсеңме?

З ө ф ә р т а в ы ш ы. Юк, ишетмим!

Ә м и н. Түзә алмыйм, Нәзилә! Синең монда булуың да ошамый миңа.

Н ә з и л ә. Үзем дә күрәм. Минем монда булуым беркемгә дә ошамый, Зөфәргә дә, сиңа да... Ә синеңчә, мин кайда булырга тиеш? Зөфәр кебек бикләнеп ятаргамы? Ошамый, ошамый! Туйдым шул сүздән! Яхшылыгың, якынлыгыз, хәтта мәхәббәтең дә кешеләргә ошамасын инде! (*Елый. Чыгып китә.*)

Ә м и н. Нәзилә, Нәзилә!

З ө ф ә р чыгып аны туктата.

З ө ф ә р. Кая чабасың, кеше көлдереп. Китсен! Нәрсәгә кирәк ул? Монда аннан башка да эт баш, сыер аяк.

Ә м и н. Елады... Беләсеңме, синең өчен елады!

З ө ф ә р. Еласа, күзе кара булыр. Төкер син аңа... Хәзер үк теге тиле картны куып җит тә этинең премиальный акчаларын алып кайт.

Ә м и н. Нәрсәгә алар миңа? Кирәк булса, эти үзе дә алган булыр иде.

З ө ф ә р. Бар, диләр синә!

Ә м и н. Барам, ләкин син куган якка түгел.

З ө ф ә р. Дурак, миңа бик күп акча кирәк, аңлыйсыңмы? Акча! Акчасыз берни дә эшли алмыйм мин. Абыеңа шул яхшылыгыңны да кызганасыңмы? Бар, йөгер, ул хәл җыя-җыя гына бара. Азрак бара да утыра. Чыпчыклар белән сөйләшә. Мин тәрәзәдән карап тордым.

Ә м и н. Бармыйм. Ул акчаларның безгә кирәге юк...

З ө ф ә р. Бар инде... Барсаң, үз файдаңа Нәзиләдән баш тартам!

Ә м и н. Син, син... Беләсеңме син кем?

З ө ф ә р. Җүләр син, менә кем!

Ә м и н. Әйтмим инде. Тормыш сиңа барыбер кемлегеңне күрсәтер! Гомереңбуе эти җилкәсенә ышыкланып, яшеренеп йөри алмассың! (*Чыга.*)

З ө ф ә р. Дурак! Философ, имеш, җүләр! Теге карт шайтаны килер вакыт тапкан бит... Үзем генә булсам... Юллык акча кесәдә дигән сүз иде. Үзеннән сорасам. Бирмәс... Эти, эти!

Бүлмәдән Х ә л л ә чыга.

Х ә л л ә. Кычкырма, кешене уятасың.

З ө ф ә р. Әти, минем хәлемне...

Х ә л л ә. Үзең баш ват... Үзең! Балигъ булгансың, башың йомры, гыйлемлегең җитәрлек, үзең уйла! Бүген сиңа киңәш бирергә куркам... Әгәр ялгышсам, миңа тагын да үкенечлерәк булачак. Үкенергә соңрак шул. Гомер күп үткән, син үсеп җиткәнсең... Мин күрми дә калганмын. Менә нинди егет булгансың!.. Куркам мин синең өчен...

З ө ф ә р. Әти... Гафу ит минем дуамаллыгымны! Әти!

Х ә л л ә. Кешене уятасың, кычкырма! Төне буе эшләгән бит ул. Кычкырма... Син башыңны эшкә җик. Уйларга ирек бир. Куркам мин синең өчен... Ә мин сине кеше булдың дип йөри идем... Кычкырма! (*Чыга.*)

З ө ф ә р. Әллә исереп йоклаган инде? (*Барып карый.*) Әй, тор әле! Кеше!.. Белмим, сүгенү сүземе бу, әйбәт сүзме? Кеше, карыйм әле, син нинди буласың икән? Сине кеше, диләр, мине түгел, диләр! Кеше! Әйт әле, нишләргә инде миңа? Синең кебек ваемсыз, шулай эреп, тәмле төшләр күреп изелеп йоклар өчен миңа нишләргә?

Акрын гына ут сүнә. Еракта музыка тавышы ишетелә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Больница. Тәрәзә янында **Халидә** елый. Шактый күп халык палата ишеге төбендә өелешеп тора. Бу — карьер цехы **эшчеләре**. Алар турыдан-туры эштән монда килгәннәр. Халат астыннан эш киемнәре күренеп тора. Арадан берсе сүз кыстыра, башкалар аны тыңламаган да кебек, һәркем үз дөньясына чумган...

IV эшче. Бу врач хәзер чыгармын дигән иде...

II эшче. Әйттем мин сезгә, ашыкмыйк, кибетләр ачылганны көтик, берәр нәрсә алып килербез, дидем.

III эшче. Анысы качмас, терелсен генә. (*Пауза.*)

I эшче. Халидә җылый...

II эшче. Җыламый ни, үкчәсе кара күмергә әйләнгән бит. Җыларсың да... Төнәгеп генә тап-таза йөргән кеше бүген үле-мәле ятсын әле. Уен эшмени?

I эшче. Үкчә нәрсә?..

II эшче. Аксак булып калсаң да рәхәт түгел инде ул. Яшь бит әле ул Шәмсетдин. Әти-әнисе дә исән ич аның. Әтисе сиксән биштә, әнисе сиксән дүрттә. Икесе дә яшен ташы кебек йөриләр. Шәмсетдин илле яшенә чыккач: «Инде гомернең уртасына да җиттек»,— дип көлеп йөргән иде...

I эшче. Нык иде әле ул...

III эшче. Шул кеше кемнеңдер гаебе, җебегәнлеге аркасында үлем түшәгенә егылсын әле.

IV эшче. Хак, хак! Бадамшин малаена ни әйтте Шәмсетдин абый! Абай бул, ул якка каерыла күрмә, диде. Авызы балның кайда икәнлеген белә шул, ансатрак якка борылган да... Шәмсетдин абый аның янына йөгерә башлады. Тик менә...

I эшче. Халидә җылый. (*Пауза.*) Җылама, Халидә...

Халидә. Мин җыламыйм. Җыласам башым гына авырта. Башым авырткач, җыламыйча түзә алмыйм.

II эшче. Һавага чык булмаса, Халидә. Монда бөркү дә, дару исе дә килеп тора. (*Тәрәзәне ача.*)

Халидә. Врач һаман чыкмый. Сез кайтыгыз инде. Эштән генә бит. Өйдәгеләрегез көтәләрдер.

III эшче. Өйдәгеләр саулар.

Халидә чыгып китә.

I эшче. Халидә җылый. (*Пауза.*) Тыңлыйсызмы, бер мишәр корбан чала икән. Бисмилласын әйтеп пычагына тотынган да кәҗәнең колагына: «Слышь, кәҗә, сират күпере аркылы иң элек мине, аннан соң Миңкамал апаңны алып чыгарсың!» — дип пышылдый икән. (*Пауза.*) Йә, нигә көлмисез?

III эшче. Көләсе килми.

I э ш ч е. Көлеп булмый... Шәмсетдин абый мине кеше итте. ФЗУны бетереп заводка килдем шулай. Акча юк, эш авыр, торыр урын юк. Директорга — Бадамшинга бардым. Юк, ди. Торыр урын да, аванс та юк, ди. Сызарга чамаладым. Шунда ул минем янга килеп хәлемне белешкән иде. Өенә алып кайтты, чәй эчертте... Менә шул кеше үләргә ята... Ә аны кабер якасына аталы-уллы Бадамшиннар бастырды...

III э ш ч е. Әйбәт кеше иде...

IV э ш ч е. Яшен суккан кешегә кара сыер сөте эчертеп, кара тавык итен ашаталар иде безнең авылда. Электр да яшен түгелме соң? (*Пауза.*) Тик аның кара тавыгын каян аласың?

Н ә җ и п керә.

Н ә җ и п. Сез китмәдегезмени әле?

II э ш ч е. Көтәбез менә. Врач анда. Ул ни әйтер бит. Кайтыгыз, тынычланыгыз дисә, кайтабыз...

Н ә җ и п. Хәле ничек?

I э ш ч е. Әнә Халидә җылый. Ул бездән алданрак килгән... Сораган идек тә, эндәшмәде. Врач сөйләшми...

Н ә җ и п. Сөйләшми дисез?

I э ш ч е. Бадамшинның көяз малаен нишләтмәкче буласыз, иптәш директор.

IV э ш ч е. Аталы-уллы төрмәгә утыртырга кирәк аларны. Лаеш шулпасын авыз итсеннәр әле. Югыйсә майларына чыдаша алмыйлар иде. Ул Зөфәре үзен икенче директор дип санап йөри иде бит!

III э ш ч е. Ата Бадамшинын да, бала Бадамшинын да калдырмаска кирәк. Икесе дә нәкъ бер чыбыктан сөрелгән!

Карана-карана Х ә л л ә килеп керә. Ул III эшченең сүзләрен ишетеп сискәнеп туктый.

Н ә җ и п. Аңлыйм мин сезне, аңлыйм...

Х ә л л ә. Туктагыз әле. Монда мин дә бар бит.

Н ә җ и п. Хәлиулла Сөнгатович?

Х ә л л ә. Әйе, бу мин... һәм ялгыш кына сезнең сөйләгәннәрне ишетеп калдым. Алай дип әйтергә ярамый. Минем улым минем белән бер чыбыктан сөрелмәгән... Юк, юк! Әле гади бер ялгыштан аны чуттан чыгарып ташларга ярамый.

II э ш ч е. Гади ялгыштанмы? Директор малае дип без аны азындырдык. Тагын гади ялгыш дип башыннан сыйпап калыйкмы?

Н ә җ и п. Зөфәрнең гаебе зур, бик зур...

Х ә л л ә. Кем аның гаебе кечкенә ди? Кем?

Ул арада ишектән **в р а ч** чыга. Хәлләнең соңгы сүзләренә беркем дә игътибар итми. Дәшми-тынмый гына врачны урап алалар. Ул арыган, талган, тирләгән. Дәшми, тәрәзә янына килеп тәмәке кабыза.

В р а ч. Сәгать ничә?

Н ә җ и п. Уннар тирәсе...

В р а ч. Кем җылый анда?

Н ә җ и п. Халидә ул, Шәмсетдин абзыйның кызы.

В р а ч. Һаман җылый икән... Күз яшенең файдасы юк инде...

Х ә л л ә. Ничек? Әллә хәле бик өметсезме?

I э ш ч е. Их, Шәмсетдин абый, Шәмсетдин абый!..

В р а ч. Күз яше кирәкми монда, монда кан кирәк, кан!

IV э ш ч е. Каныгыз юкмыни?

В р а ч (*борылып, текәлеп карап*). Шәмсетдин абыйга кайчандыр үзе янган кеше каны кирәк. Бер мәртәбә шундый авыр сынауны үткән, организмы көрәштә чыныккан кеше каны кирәк.

II э ш ч е. Безнең Мәснәви шахтада котельныйда янган түгелме? Тик ул үзе дә авырып тора.

Н ә җ и п. Янган кеше каны дисезме? Әйтегез әле, танкта янган кеше каны ярармы?

В р а ч. Әгәр ул кеше сәламәт икән...

Н ә җ и п. Алайса, мине тикшереп карагыз әле.

В р а ч. Сезне?

Н ә җ и п. Әйе...

В р а ч. Әйдәгез әле. (*Кереп китәләр.*)

II э ш ч е. Ничек булды соң әле бу? Без килдек, бер файдасызга җыелып утырдык. Янган кешене үзебезгә табарга иде.

I э ш ч е. Янганын да, яндырганын да таба алмадык шул! Нигә алай?

IV э ш ч е. Вәт кеше! Күзен дә йоммады!

III э ш ч е. Йомды инде йомуын...

IV э ш ч е. Кайчан?

III э ш ч е. Врач янган кеше хакында әйтә башлагач, синең чыраең ап-ак булды. Син дә авылда чагында мич башында ятып, аркаңны пешергәнсең түгелме соң? Шул чыраеңны күрмәс өчен ул күзен йомды.

IV э ш ч е. Китсәнә, бәйләнмәсәнә!

Х ә л л ә. Сез уйламагыз тагын... Мин улым өчен ниндидер җиңеллек, аерым бер закон сорарга килгән дип уйламагыз. Юк, юк! Мин... Шәмсетдиннең хәлен белергә дип килдем...

II э ш ч е. Безгә барыбер. Тегеләй килсәгез дә, болай да...

Х ә л л ә. Хәле авыр икән. Авыр... (*Беркем дә аңа игътибар итми. Хәллә авыр гына атлап чыгып китә.*)

I э ш ч е. Халидә җылый... Җылама, җүләр! Болай булгач, этиең котыла инде!..

II эшче. Котыла, кәнишне. Син әйткәндәй, нәрсә ул үкчә! Баш сау булсын, баш. Мин бер шигырь китабында укыган идем. Анда «Дустым, аягым юк дип хәсрәтеңне җибәрмә тирәнгә, юньләбрәк карасаң, башсызлар да шактый йөри тирәндә!» диелгән иде.

I эшче. Башсызлар да дигәнме?

Бар да елмаялар. Көләләр. Халидә керә.

Халидә. Нәрсәдән көләсез?

II эшче. Кайгырма, Халидә! Әтиең терелә!

Халидә. Врач шулай дидеме?

I эшче. Юк, моны Нәҗип абый әйтте. Ул белә инде аның серен. Үзе дә танкта янган кеше!

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Завод идарәсе яны. Күрсәткечләр тактасы. Быел яз гына утыртылган агачлар. Урам себерүче белән Ләбиб.

Ләбиб. Бадамшинның фамилиясе булган бөтен кәгазьләрне кубарып ал. Эзе калмасын.

Урам себерүче (*кәгазьләр кубара-кубара*). Миңа нәрсә, ал дигәч алам. (*Пауза.*) Ул Бадамшиннар малаен нишләтәсез инде?

Ләбиб. Закон ни кушса, шуны эшләрбез.

Урам себерүче. Закон ни куша соң?

Ләбиб. Законның сүзе кыска аның: ун ел, ди.

Урам себерүче. Күбрәк икән шул. Анда яхшылыкка өйрәтмәсләр лә аны...

Ләбиб. Юньле кеше бала-чага үстереп азапланамы соң? Монда үз башыңны ватмый-чәчми саклап алып бара алсаң да әйбәт әле! Менә Бадамшин. Коточкыч бит: үзе бетте, малае нишләде! Ай-яй!

Урам себерүче. Бик хәтәр икән алайса, хәтәр! Улын әллә ни белмим, әмма үзе кызганыч!

Ләбиб. Тапкансың кызганыр кеше! Үз гаиләсендә тәртип урнаштыра алмаган кешедән ни көтәсең? Әле дә ярый эшне бик тирәнгә җибәргәнче чарасын күрдек... Монда эшеңне бетергәч гараж тирәләрен чистартып куй! Нәҗип Солтанович килгәнче бар да ялт итеп торсын! (*Чыга.*)

Урам себерүче. Ай-яй, хәтәр икән, бик хәтәр икән! (*Кәгазьләрне кубарып бетерә, үз-үзенә мыгырданып чыгып китә.*)

Карана-карана Зөфәр килеп керә. Кемнеңдер килүен күреп, күрсәткечләр тактасы артына кача. Нәзилә килә.

Зөфәр. Нәзилә?

Н ә з и л ә. Зөфәр!

З ө ф ә р. Кичер мине, Нәзилә.

Н ә з и л ә. Син монда нишлисең, Зөфәр?

З ө ф ә р. Синең янга килдем.

Н ә з и л ә. Алайса, нигә монда постың?

З ө ф ә р. Башка кеше килә дип торам...

Н ә з и л ә. Башкаларга күренергә ярамыймыни?

З ө ф ә р. Нәзилә... Үзең уйлап кара, Нәзилә... Ничек күреним мин хәзер? Син акыллы кыз бит, аңла! Миңа бик кыен бит хәзер! Бөтен җирдә, бар урыннарда минем әшәке гайбәтемне генә саталар! Карьердагы эш өчен генә түгел, эти дә шундый булып киткәч...

Н ә з и л ә. Әтиеңә нәрсә булган тагын?

З ө ф ә р. Аңла, тормыш хыялларым, уй-фикерләрем бар да челпәрәмә килделәр.

Н ә з и л ә. Андый ук өметсезлеккә сәбәп юк, Зөфәр!

З ө ф ә р. Әй, хәзер ни сөйләсәң дә барыбер. Кайтмас инде минем бәхетле вакытларым! Кемнәрдер миннән сорау алырга тотынырлар, кемнәрдер кызганган булып маташыр, кемнәрдер сүгәр, ачуланыр... Ә минем улваклыклардан өстен буласым килә!.. Бүген төнлә балчык яр белән бергә минем Зөфәр Бадамшинлыгым җимерелеп төште. Мин үземне зур эшләргә, батырлыкларга әвәс, лаек кеше дип йөри идем. Бар да бетте...

Н ә з и л ә. Алайса, нигә минем янга килдең син?

З ө ф ә р. Төшен, Нәзилә! Мин монда кала алмыйм... Элеккеге Зөфәрне белгән, күргән кешеләр янында мескен Зөфәр, гаепле Зөфәр булып кала алмыйм. Минем китәсем килә...

Н ә з и л ә. Зөфәр... Мин сине тотмыйм.

З ө ф ә р. Акча биреп тор син миңа, Нәзилә! Олагыйм кая да булса китеп! Азрак баш-күз алгач, мин акчаңны кире җибәрермен...

Н ә з и л ә. Шуның өчен генә син мине эзләдеңме?

З ө ф ә р. Шуның өчен генә дип...

Машина туктаган тавыш ишетелә, йөгереп А л м а з керә.

А л м а з. Нәзилә! Әһә! Зөфәр дә монда!

З ө ф ә р. Тукта әле, комачаулама!

А л м а з. Берәрегезнең кая да булса барасы юкмы, машинага утыртырга кеше юк.

Н ә з и л ә. Хәзер, Алмаз, минем больницага барасым бар. Сменага кадәр әйләнеп кайтабыз бит?

А л м а з. Була гына ул! Җилдәй очыртам үзеңне! Их, җайлы чагында Бәллүре囗 эштә бит аның!

Н ә з и л ә. Зөфәр, бүген иртән син миңа бүлмә ишегеңне ачмаган идең. Мине дә бүлмәмдә дип уйла, мин дә

сиңа ишегемне ачмадым. Башка кешеләргә күренергә оялмый, курыкмый башлагач, бәлки, ул ишекне шакып карарсың... (*Алмазны җитәкләп чыгып китә.*)

Зөфәр. Ах син, бытбылдык! Ни кылана бит! Кая барырга инде? Кемгә сугылырга?

Хәллә керә.

Хәллә. Син монда нишләп йөрисең?

Зөфәр. Сине эзлим, эти.

Хәллә. Мин югалмадым. Өйдә дә сөйләшкән булыр идек.

Зөфәр. Өйдә куркыныч, эти... Күңелсез... Анда чыдап, түзеп булмый... Син мине тыңлыйсыңмы?

Хәллә. Бар кайт. Ишетәсеңме?

Зөфәр. Кайта алмыйм... Әти, килешик без! Моңарчы аңлаша идек бит, син мине ярата идең бит...

Хәллә. Нишләргә кушасың инде? Яратыргамы? Аңлашыргамы? Әйдә, аңлашыйк. Нигә монда килдең дип ник сорамыйсың?

Зөфәр. Нигә, эти?

Хәллә. Сине эзләп түгел, курыкма. Үземне-үзем эзләп. Гомеремне эзләп...

Зөфәр. Әти, соңгы мәртәбә әйтәм, ычкыныйк без моннан! Монда сине терелә́й тотып ашаячаклар. Ул Нәҗипләр, ул башкалары! Чүл бүреләре бит алар! Китик, акыллы бит син, көчле бит син! Шуңа күрә сине күрә дә алмыйлар... Китик! Берзаман, үз вакытыбызны белеп кенә, кайтырбыз.

Хәллә. Дөрес! Кит син. Дүрт ягың кыйбла!

Зөфәр. Китмисең икән, миңа юлга акча бирәсең!

Хәллә. Акча? Шуны иснәнеп килдеңме? Бер генә тиен дә бирмим. Хәтта сукыр бер тиен дә! Үзең эшләп тап! Менә шунда синең кемлегең күренер! Ә мин сине кеше булгансыңдыр дип йөри идем...

Зөфәр. Ну, ярый! Хуш! Ишетерсең әле минем хакта! Үкенерсең! Үткәннәре өчен үкенеп бетә алмыйм. Ике үкенеч булмас!

Зөфәр чыга. Хәллә акрын гына йөренә, Ләбиб керә.

Ләбиб. О-о! Хәлиулла Сөнгатович! Сагынып беттек үзегезне! Әле бая теге карт белән, урам себерүче белән дә телгә алдык.

Хәллә. Яманлагансыздыр инде...

Ләбиб. Каян белдегез! Валлаһи, зирәк кеше сез! Сездән нинди начарлык күргәне бар инде аның? Хәлиулласын да, малаен да төрмәгә утыртырга кирәк дип сөйләнеп ята.

Х ә л л ә. Сөйләр инде, нишлисең?!

Л ә б и б. Тора-тора кешеләргә тәмам гаҗәпкә калам мин! Аяк эзегез суынып бетмәгән, тоталар да сезне яманларга тырышалар! (*Якынрак килеп.*) Теге төнлә булган вакыйганы да оештырмадылар микән, дим?

Х ә л л ә. Булмас.

Л ә б и б. Сезнең малайны чакырырга каршы чыктым бит мин. Башкалар, чакырабыз да чакырабыз, диләр. Менә үз башларына чакырдылар...

Х ә л л ә. Әйе, Шәмсетдиннең хәле бик начар...

Л ә б и б. Әллә анда да барып җиттегез? Юкка, юкка, Хәлиулла Сөнгатович! Кеше күзен кыздырып юкка анда барасыз, монда киләсез.

Х ә л л ә. Шулай да бит... Менә завод. Күңел урынында түгел... Үз-үземне кая куярга белмим. Анда сугылдым, монда...

Л ә б и б. Өйдә ятуларга ни җитә. Крепость эчендә! Тәрәзә капкачларын бикләп тә җибәрсәң, син дөньяның патшасы! Төкер барына да...

Х ә л л ә. Берни белми яту да кыен бит, Ләбиб. Хата эшләнгән булса да, монда егерме ел гомер үткән. Егерме ел, Ләбиб... Бу бит бер гомер дигән сүз...

Л ә б и б. Бик аңлыйм... Ләкин кешеләрнең ачуын кабартып, каннарын кыздырып йөрү кирәкми, дим. Нәҗип Солтанович күрсә дә, әллә ни уйлар... Эшегезне көйләрбез, кайгырмагыз...

Х ә л л ә. Әйе... Китим булмаса! Чыннан да, башың ярылса да, кулың сынса да, йөрәгең авыртса да өйдә тынычрактыр, ахры...

Л ә б и б. Әнә Нәҗип Солтанович килә. Бергәләп аның гайбәтен саталар дип уйлар...

Хәллә китә башлый, Н ә җ и п аны кычкырып туктата.

Н ә җ и п. Хәллә абый!

Л ә б и б. Мин дә монда.

Н ә җ и п. Хәллә абый, бая да сөйләшеп булмады. Нигә китәсез?

Х ә л л ә. Өйдә эшләр... Кайтыйм дигән идем...

Н ә җ и п. Әле менә юлда уйлап килгән идем. Исегездәме, мин техникумның соңгы курсыннан сезгә практикага килгән идем. Шунда бик шәп яңгырлар явып карьерны су баскан иде... Экскаваторлар күмелеп калган иде.

Х ә л л ә. Исемдә, исемдә!

Н ә җ и п. Шул чагында сез ничек оста итеп эшне көйләп җибәргән идегез!

Л ә б и б. Ә-ә! Менә монысы минем дә исемдә!

Х ә л л ә. Сез юк әле ул вакытта, Ләбиб. Сез килгәләгәнче дә булгалады бит әле монда хәлләр.

Л ә б и б. Мин килгәч, алар бетте диярга кирәк, алайса.

Н ә җ и п. Әйе... Тик ул вакытта беркемгә дә зыян килмәгән иде. Ә бүген... Шәмсетдин абыйның хәле бик мөшкел... Терелер диләр терелүен... Тик тиз булмас!

Л ә б и б. Терелергә тиеш!

Х ә л л ә. Кайтыйм булмаса мин... Тик... Беләсе килә, теге вакыйгаларны нигә искә алдың икән син, Нәҗип?

Н ә җ и п. Болай гына... Шәмсетдин абый сезне сораштыы...

Х ә л л ә. Мине? Онытмаган икән... Рәхмәт инде... Минем дә аны бик күрәсем килгән иде. Тик нигәдер уңайсыз. Менә... Бәлки, карьерга... мин барырмын?

Л ә б и б. Булмас, Хәлиулла Сөнгатович! Булмас! Кешеләр нәрсә диярләр? Сезнең белән эшләргә кем риза булсын. Тагын гауга кубар.

Х ә л л ә. Шулай шул. Ярый, китим. Апагыз да...

Н ә җ и п. Хәллә абый!

Х ә л л ә. Әйе.

Н ә җ и п. Әйдәгез әле. Минем башка бер фикер килде! Бәлки, чыннан да!.. Нигә тавыштан куркырга! Бар да булыр. Тавышы да... Эш шуңа барып җиткән икән... Әйдәгез әле!

Л ә б и б. Бәлки, мин? Мин дә гомуми җитәкчелекне булдыра алам бит!

Н ә җ и п. Кайгырмагыз, сезгә дә эш табып куйдым инде мин! Әйдәгез әле, Хәллә абый. Бер минут кичегергә ярамый. Эш муеннан! Барыйк әле. (*Чыгып китәләр.*)

Л ә б и б. Сөйли бу... Эш табам, ди. Ни кыланырга уйлый икән? Нинди начальниклар заманы килде соң бу? Директор итеп билгеләгәннәр, банкет юк, котлау юк. Эш, карьер!.. Әй, миңа калса, ике дөнья бер, уртасы камыр!

## УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Нәкъ беренче күренештәге кебек төн. Бакча. Арлы-бирле чабып А л м а з йөри. Завод идарәсенең барлык бүлмәләрендә ут янганга сәхнәдә яктылык бик мул. Йөгерә-йөгерә диярлек Б ә л л ү р керә.

А л м а з. Бәллүр?! Син ничек мине эзләп таптың?

Б ә л л ү р. Их Алмаз, Алмаз! Караңгы төшкәч, сине эзләп йөрисе дә юк бит!

А л м а з. Ачуланма инде, Бәллүр! Нәҗип абыйны көтәм...

Б ә л л ү р. Ачуланмыйм, көләсем генә килә! Инде бүген дә...

Алмаз. Соңгы мәртәбә, җаным! Менә машинаны тапшырам да, иртәгә таксига... дөресрәге, шул машина таксига әйләнә!

Бәллүр. Әллә иртәгә үк? Анысы шулай, тик безне бүген әниеңнәр көтә бит!

Алмаз. Нигә әниеңнәр? Әни диген! Әни көтә диген! Безнең вакытыбыз хәзер беләсеңме күпме? Өч көн ял! Кара әле, өйләнешкән кешеләргә өч көн ял бирүне кайсы миһербанлы бәндә уйлап чыгарды икән? Рәттән өч көн! Менә шул яңа хәбәрне Нәҗип абыйга әйтергә кирәк бит! Ялны да ул бирә, бәлки, машинаны да биреп торыр! Күктән төшкән бәхет бит бу! Аннары мин такси йөртүче булып китәм. Сменамны эшлим дә кайтам... Син мине пәрәмәчләр пешереп көтеп торасың...

Бәллүр. Ә син театрга билет алып кайткан буласың...

Алмаз. Син мине кайту белән пәп итеп аласың...

Бәллүр. Ә син миңа сөеклем дип эндәшәсең...

Алмаз. Өй җыештырылган, юылган... Чиста... Түрдә...

Бәллүр. Йомшак кәнәфидә...

Алмаз. Син мине көтеп утырасың!

Бәллүр. Мин сменада чагында аш пешерелгән, су китерелгән, йөземле батон алып кайтылган — мин йөземле күмәчләрне бик яратам, чәй кайнатылган...

Алмаз. Ур-ра! Мондый куанычлы хәбәрләрне Нәҗип абыйга әйтми китәләрме соң?

Бәллүр. Соң бар, әйт!

Алмаз. Уңайсыз ла, Бәллүр! Кеше беренче көнен директор булып утыра.

Бәллүр. Ни эшләргә инде синең белән? Өйләнешкән көнне үк ачуланыша башласак яхшы түгел...

Алмаз. Әйе, әйе, көтик бераз! Нәҗип абыйны, дим...

Бәллүр. Әйдә бакчага! Кичәге урынга!

Алмаз. Киттек, Бәллүрем! (*Чыгалар.*)

Бераз тынлык. Акрын гына Гөлфия керә. Тәрәзәдән төшкән яктылык турына килеп баса.

Гөлфия. Кайда икән ул? Монда булмас... Буламы соң? Юкка гына килдем, ахры. Әйе... Өйдә беркем дә юк... Үзе дә, Зөфәр дә... Аның китүен ишеткәч ничек түзәр ул? Анага кара хәсрәт булып туган бала булды ул... Зөфәр...

Нәзилә үтеп бара. Ул эш киемнәреннән.

Нәзилә. Гөлфия апа?.. Карыйм да аера алмыйм, сезме, түгелме...

Гөлфия. Мин бу, Нәзилә. Килеп чыктым әле... Эш киемнәре сиңа бик килешә икән... Беләсеңме, Зөфәр дә таныш кызлары арасыннан сине бик якын итә иде...

Н ә з и л ә. Гөлфия апа!

Г ө л ф и я. Нәрсә, Нәзилә?

Н ә з и л ә. Болай гына... Зөфәр нишләп калды дип сорамакчы булган идем дә, сорамаска булдым инде.

Г ө л ф и я. Зөфәр... китте ул.

Н ә з и л ә. Кая китте?

Г ө л ф и я. Безне ташлап... Чемоданын алган, киемнәрен, тагын... Китте... Мин өйдә идем, саубуллашырга да кермәде...

Н ә з и л ә. Кая, нигә киткән инде ул!

Г ө л ф и я. Кызым, Нәзилә кызым! Син бик әйбәт, ягымлы кыз. Дуслар табарсың әле син...

Н ә з и л ә. Мин гаепле бит аның китүенә, мин!

Г ө л ф и я. Юк, кызым, нишләп син гаепле буласың ди!

Н ә з и л ә. Киткән икән, киткән...

Г ө л ф и я. Абыеңны күрмәдеңме?

Н ә з и л ә. Кемне?.. Киткән икән... Хәллә абыйнымы? Хәзер килә...

Г ө л ф и я. Кызым минем, кызым... Гомерем буе шушындый бер кыз хакында хыялланып яшәдем мин!

Х ә л л ә керә.

Х ә л л ә. Әнисе? Сиңа урыннан торырга кушмаганнар иде бит?

Г ө л ф и я. Ята-ята да бик ялыктырды. Акрын булса да йөрисе килә...

Х ә л л ә. Мин дә бик арыдым, әнисе. Арыдым... Ә син, Нәзилә, нигә кайтмыйсың?

Н ә з и л ә. Хәзер кайтам, Хәллә абый.

Г ө л ф и я. Көне буе югалып тордың бит, әтисе...

Х ә л л ә. Шулайрак булды шул...

Г ө л ф и я. Кайтыйк инде. Аш та куйган идем, чәй дә. Ашар кеше дә юк, эчәр кеше дә.

Х ә л л ә. Малайлар өйдәдер бит? (*Нәзиләгә карый.*)

Н ә з и л ә. Хәзер кайтам, хәзер...

Еракта поезд үтә.

Г ө л ф и я. Чү, поезд үтә түгелме?

Х ә л л ә. Поезд... Безнең заводның кирпечләрен төяп барадыр ул.

Г ө л ф и я. Бәлки, безнең улыбызны, Зөфәрне алып киткәндер ул поезд, әтисе...

Х ә л л ә. Ничек? Нәрсә булды? Нигә аңлатып кына сөйләмисез?

Н ә з и л ә. Зөфәр киткән, Хәллә абый.

Х ә л л ә. Нигә миңа хәбәр иттермәдегез?

Г ө л ф и я. Үзем дә белми калдым... Әтисе, соң булса

да берәр чарасына керергә кирәк. Кая бара ала ул болай? Җибәрмәскә кирәк аны!

Хәллә. Әнисе, күңелеңә авыр алма, бәлки, китүе хәерлегә генә булыр әле.

Нәзилә. Юк, Хәллә абый. Алай китәргә тиеш түгел ул! Әйдәгез, тиз генә вокзалга барыйк. Бәлки, куып җитәрбез әле! Әйдәгез. Әнә машина тора. Алмаз, Алмаз!

Агачлыктан Алмаз, Бәллүр чыгалар.

Алмаз. Нәрсә бар?

Нәзилә. Машинаң төзекме?

Алмаз. Төзек булмыйча! Әйеме, Бәллүр?

Нәзилә. Әйдә тизрәк вокзалга. Зөфәр киткән...

Алмаз. Ничек инде вокзалга? Әйеме, Бәллүр? Без бүген өйләнештек.

Нәзилә. Котлыйм... Әйдә инде! Хәллә абый, нигә бер сүз дә дәшмисең?

Хәллә. Бәхетле булырга бөтен мөмкинлекләре булган кешенең ничек бәхетсез булуын күреп йөрәгем яна.

Гөлфия. Әтисе!

Хәллә. Дәшмә, әнисе! Котлыйм, Алмаз, Бәллүр. Ә хәзер өйгә! Өйгә! Арыдым. Җеп өзәр хәлем юк!

Алмаз. Озатып куябызмы, Бәллүр?

Бәллүр. Киттек, Алмаз! Бик күңелле булачак.

Чыгалар. Нәзилә ялгыз кала. Ул кая барып бәрелергә белмичә сәхнә буйлап йөри.

## УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә бераз гына караңгы тора. Бик моңлы скрипка тавышы килә. Кайдадыр бер почмакта кайгылы Халидәнең йөзе чагылып китә. Марляларга уралып беткән Кардинал күренеп кала. Поезд тәгәрмәчләренең тавышы астында Зөфәр тәмәке тартып бара. Көлешә-көлешә бер төркем яшьләр үтеп китәләр. Сәхнәдә ут көлтәсе. Ул җиргә иелеп нидер чүпләүче Күрше карчыкны яктырта. Акрын гына атлап урам яктан Хәллә керә. Өй ягыннан Гөлфия чыга. Арттан Әмин күренә.

Хәллә. Кем бу? Зарифа апа? Нишлисез монда?

Күрше карчык. Пыяла ватыкларын җыештырып куйыйм әле, дим, йокларга яткан идем, йокы алмый. Юньсез балалар тәрбияләгән юньсез ата-аналарга ачуым чыгып ятты... Зөфәрегез бая таш бәреп шушы лампочканы ватты бит. Бала-чага уянып чыккалаганчы җыештырып алырга булдым.

Хәллә. Әйе... Йокы алмый. Йокы... Олы сүз икән бу...

Күрше карчык. Халидә дә йоклый алмый икән, бичара. Иртәгә скрипкадан имтиханы бит югыйсә...

Х ә л л ә. Әле генә шалтыратып белештек, Шәмсетдиннең хәле бик авыр ди.

Г ө л ф и я. Әтисе, тагын кая барасың инде?

Х ә л л ә. Йөрим әле...

Г ө л ф и я. Ә син, Әмин, кая җыендың?

Ә м и н. Мин дә йөрим әле. Нәзирәләргә барып кайтыйм әле, дим. Ялгыз бит ул... Сәгать пружинасының кыштырдавын тыңлап интегеп ятадыр...

Г ө л ф и я. Йөрмә инде, иртәгә барырсың...

Х ә л л ә. Барсын. Үзенә ошый икән, барсын.

Әмин чыга.

Г ө л ф и я. Монда шундый шыксыз, караңгы...

Х ә л л ә. Дәшмә, энисе!.. Караңгыда да күңелле. Беләсеңме, мин бүген күкне күрдем... Менә берничә ел инде күкне дә, җирне дә күрмичә тыңланып кына яши идем. Телефон шалтыраса да, ишекне шакысалар да, берәрсе кычкырыбрак сөйләшсә дә мин ниндидер хәвефле хәбәр көтә идем... Тормышта тыңланып кына, куркынып кына түгел, бәлки, күреп тә, сокланып та яшәргә кирәк. Менә мин бүген шуны белдем. Эшчеләр белән юл күчерештем мин бүген, забойларны рәтләдек. Мәж килдек... Менә бер- заман гудок... Гап-гади бер тавыш. Ә шуннан соң күпме хәрәкәт, сөенеч. Берәүләр килә, берәүләр китә...

Г ө л ф и я. Мин көне буе синең өчен борчылдым. Үз-үземә урын тапмадым...

Х ә л л ә. Ишетәсеңме, шәһәр тонык кына гөрли. Ә безнең өй түбәсендә нинди матур күк!

Г ө л ф и я. Киек Каз Юлы! Бигрәк матур инде! Ука читле келәм төсле күкне иңләп яткан. Дөресме икән, киек казлар шул йолдызларга карап үзләренең туган якларына кайталар, ди...

Х ә л л ә. Киек Каз Юлы!.. Ерактан гына шулай томанлы бер тасма кебек күренә ул. Үзендә исә әллә никадәр эреле-ваклы йолдызлар, йолдызчыклар... Томаннар да бар... Менә кешеләр дә шулай... Син алардан никадәрле ерагайсаң, алар бар да бертөсле соры, төссез булып тоелалар. Аларга якынайганда гына, алар белән бер һаваны сулап, бер икмәкне бүлешкәндә генә син кешеләрнең нинди олы җанлы, гадел, киң күңелле һәм төрле-төрле икәнлеген күрәсең. Адашмас өчен Киек Каз Юлына карарга кирәк икән, әнисе... Тик менә шуны бик соң аңлау гына аяныч...

П ә р д ә.

*Казан—Бигеш*
*Август, 1960 — май, 1961*

# *Көзге ачы җилләрдә*

*Драма өч пәрдәдә, тугыз күренештә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гандәлиф.
Хәнҗәр.
Ибраһим.
Ясыйр.
Ак түти.
Сәхи.
Рәҗәп.
Рафаил.
Нури.
Мәймүнә.
Мәкәрим.
Дибәҗә.

Егетләр, кызлар, юлчылар, озатучылар, гармунчы егет, хор һәм башкалар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Яңа салынган тимер юлда соңгы станция. Моннан ары әле поездлар йөрмиләр. Әллә шуңа, әллә станция яңа булганга, поезд озату монда бер бәйрәм төсен алган. Гәрчә поезд төнге унбердә генә китсә дә, вокзал яны бер тамаша урыны. Бәлки, пассажир поезды тәүлегенә бер генә мәртәбә килгәнгәдер ул? Менә хәзер дә халык шау-гөр килеп поезд озата. Арада Ясыйр, Сәхи, Рафаил, Нури, Дибәҗә күренеп китә. Станциянең нәни генә вокзалы бар. Вокзалның бер башында дежурный бүлмәсе. Тышта кечкенә генә лампочка янганга, вокзал тирәсе ярым караңгы. Вокзал эчендә Гандәлиф ялгызы. Тышта тавышлар көчәйгән саен, ул үзе эченә кереп бикләнә сыман. Сәхнә әйләнә, вокзалның бер кыры һәм Гандәлиф күренеп кала. Алдыбызда станция.

Тавышлар:

— И-и, станцаның якынлыгы рәхәт тә инде!

— Зәй буйларына да тимер юллар килеп җитте диген, агай.

— Ике-өч сәгатьтән Бөгелмәдә диген! Син шуны әйт!

— Сөйләмә дә инде, исәпләсәң исең китәр!

1 т а в ы ш. Исән йөреп, сау кайтыгыз!

2 т а в ы ш. Бозау алып кайтыгыз дисеңме?

3 т а в ы ш. Кысылма! Кысылырсың, үләрсең, биш тиен акча түләрсең!

2 т а в ы ш. Яңа акча beләнме?

Я с ы й р т а в ы ш ы. Читкәрәк китегез! Тимер юлга якын йөрергә ярамый!

Төркемнәр аерылып, Дибәҗә ялгызы гына караңгыда басып кала. Рафаил белән Нури икесе ике яктан аның янына киләләр.

Р а ф а и л. Нури! Колакларыңны торгыз!

Н у р и. Нәрсә бар, Рафаил?

Р а ф а и л. Чибәр кыз! Борыным сизә! Тәгәрәп китим, чибәр кыз! (*Кызга якынаеп.*) Чибәркәй! Җаннарын кая куярга белми йөргән ике егетне бер бәладән йолып ал, зинһар. Өзеп кенә әйт тә бир: үзең кебек сылу, тал чыбыктай сыгылып торган, су кашыгыдай елгыр апаң яки сеңлең юкмы синең?

Н у р и. Ай, булса!

Р а ф а и л. Май кап, Нури, чиртә!

Д и б ә җ ә (*кычкырып көлеп җибәрә*). Сеңлем дә юк, апам да юк, сезгә бирергә иске катам да юк!

Н у р и. Дибәҗә ич бу!

Р а ф а и л. Төртмә әле, үзем дә күрәм. (*Кызны яктыга алып чыга.*) Дибәҗә... Әле генә кайтып киткән идең бит, очып килдеңме әллә?

Д и б ә җ ә. Очып килдем шул! Сезнең баҗалар булырга теләп апалы-сеңелле кызлар эзләп интегүегезне белдем дә килергә булдым. Йә, кайсыгыз миңа өйләнә?

Р а ф а и л (*өметсез*). Сиңа булмый...

Н у р и. Әткәңне дә әйтер идем, менә дигән кеше үзе, пар кыз да үстерә алмагач...

Д и б ә җ ә. Әй, агылый белән тагылый, сез монда, өченчегез кайда?

Н у р и. Дибәҗә кайда, ул да шунда.

Р а ф а и л. Чакыр Сәхиеңне!

Д и б ә җ ә. Сәхиеңне? Нишләп минеке булсын ул.

Р а ф а и л. Чакыр әле, Дибәҗә, бер кызык ясыйбыз. Ул килгәндә мин сине кочаклаган булып торыйм...

Д и б ә җ ә. Ярый... Бик якын килеп кочаклама.

Р а ф а и л. Читтән генә... Менә болай. (*Күрсәтә.*)

Д и б ә җ ә (*җырлый*).

Очып киткән аккошларның
Санадым канатларын.
Йөрәгемне алып киттең,
Нигә килми хатларың?

Р а ф а и л (*шаяртып*). Җаным...

Д и б ә җ ә (*кыланып*). Бәгырем...

Р а ф а и л (*шыпырт*). Тагын берне җырла, ишетмәде...

Н у р и (*кулларын уып*). Тагын берне, Дибәҗә! Дибәҗә (*җырлый*).

Очып үткән аккошларны
Санамадым, ун икән.
Бу дөньяда мәхәббәттән
Авыр нәрсә юк икән.

Н у р и. Килә, килә!

Р а ф а и л. Синең өчен күккә менеп йолдызлар чүпләр идем, диңгез төпләренә чумып энҗе-мәрҗәннәр күрәр идем...

Д и б ә җ ә. Тасма тел!

Йөгереп С ә х и керә, Нури аны туктата.

Н у р и. Сәхи, күрәсеңме?

С ә х и. Кем белән ул?

Н у р и. Танымадым. Баядан бирле чут-чут үбешәләр.

С ә х и. Үбешәләр?! Син авызыңны ачып карап торасыңмы? Иптәш, имеш... (*Бара башлый. Рафаил Дибәҗә артына кача.*) Дибәҗә!

Д и б ә җ ә. Ах, җаным, хур булдык!

С ә х и. Янында кем ул?

Д и б ә җ ә. Ул... ни... теге инде... килде дә бәйләнде... кем инде...

Н у р и (*үртәп*). Хәзер кемме, әле генә сары былбылым дип үбә идең ич!

С ә х и. Әй, сары былбыл! Кызлар итәге артына качтыңмы? Чык монда! (*Танып ала.*) Рафаил?! (*Бар да кычкырып көлеп җибәрәләр.*) Их Дибәҗә, мыскыл итәргә үк тотындыңмы?

Д и б ә җ ә. Әллә чынлап турсая инде.

Н у р и. Кызык иттек әле үзеңне бер. Карт буйдаклар дип бездән көлеп йөрмәссең!

С ә х и. Исегезгә төшерермен әле мин моны.

Д и б ә җ ә. Серкәң су күтәрми икән, егет.

С ә х и. Хисләреңнән шулай көлсеннәр дә...

Д и б ә җ ә. Китте инде, хисләр, мәхәббәт... Мәхәббәтне тел белән әйтмиләр. Аннары гыйшык алай туры гына, шау-шусыз гына булмый ул. Андый гыйшык булганчы, булмаганы мең өлеш артык!

С ә х и. Син нигә монда соң әле?

Д и б ә җ ә. Әтине озаттым, көнче күбәләк! Районга китте.

Р а ф а и л. Дибәҗә, аның үзеннән сорау ал: нишләп монда килгән ул?

С ә х и. Эштән кайтып килә идем, Хәнҗәр абый очрады...

Д и б ә җ ә. Хәнҗәр абыймы?

С ә х и. Әйе. Урман юлына борылганда ялгыз карама бар бит, шуның янына баскан да моңаеп тора.

Д и б ә җ ә. Хәнҗәр абый моңаямы? (*Сиздерми генә чыгып китә.*)

С ә х и. Әйе, әйе...

Н у р и. Дибәҗә кайда?

Р а ф а и л. Сызган! Тәгәрәп китим.

Н у р и. Шаяртам ди торгач агач атка атландыра бит бу кыз сине!

С ә х и. Атландырмый торсын. Әйдәгез, егетләр!

Чыгалар. Я с ы й р белән Х ә н җ ә р керәләр.

Я с ы й р. Яшь чагында мин дә шул ялгыз карама төбен урарга ярата идем... Ләкин, Хәнҗәр, шуны да аңлап кит: безнең яшьлек заманасы белән сезнеке арасында зур аерма бар.

Х ә н җ ә р. Заманалар үзгәрә. Тик ялгыз карама һаман ялгыз...

Я с ы й р. Тимер юл буйларында урман үстергәч ялгыз булмас әле.

Х ә н җ ә р. Агачлар озак үсә шул, Ясыйр абый...

Д и б ә җ ә керә.

Д и б ә җ ә. Хәнҗәр абый!

Х ә н җ ә р. Әү, Дибәҗә.

Д и б ә җ ә. Мин Ясыйр абый димәкче идем...

Я с ы й р. Әле кайтып китмәдеңмени, Мәкәрим Зиннуровичның кызы?

Д и б ә җ ә. Безнең егетләр сине эзлиләр, Ясыйр абый.

Я с ы й р. Кайда алар?

Д и б ә җ ә. Әнә тегендә, кибет янында.

Я с ы й р. Тагын ни кирәк булды икән. (*Чыга.*)

Х ә н җ ә р. Нигә ялганладың?

Д и б ә җ ә. Минем алдашканны каян белдең?

Х ә н җ ә р. Аңа зур гыйлемлек кирәкми.

Д и б ә җ ә. Шаярдым гына, Хәнҗәр абый.

Х ә н җ ә р. Олы кеше белән алай әдәпсез шаярмыйлар.

Д и б ә җ ә. Минем синең янда ялгыз гына каласым килде.

Х ә н җ ә р (*гаҗәпләнеп*). Нигә?

Д и б ә җ ә (*хәйләкәр*). Сорасы сүзем бар.

Х ә н җ ә р. Әйт алайса.

Д и б ә җ ә (*балаларча беркатлылык белән*). Хәнҗәр абый, нигә моңаеп тордың син бая?

Х ә н җ ә р. Моңаеп, кайда?

Д и б ә җ ә. Үзем күрдем, үзем күрдем!

Х ә н җ ә р. Ни дип моңайыйм мин?

Д и б ә җ ә. Инде син дә шулай дигәч...

Х ә н җ ә р. Мин нәрсә?

Д и б ә җ ә. Үзең беләсең инде.

Х ә н җ ә р. Син, кызый, белер-белмәс башың белән әллә ниләр бутап йөрмә. Хатын-кыз өчен моңая башласаң, башың себер китәр. Менә шул. Сәхиең белән әйбәт кенә йөр дә, шул җиткән сиңа. (*Чыга.*)

И б р а һ и м керә.

И б р а һ и м (*үзалдына*). Поезд киткән, ул да киткән булырга тиеш.

Д и б ә җ ә. Хәнҗәр абый, Хәнҗәр абый!

И б р а һ и м. Нигә шулкадәр өзгәләнәсең, Дибәҗә?

Д и б ә җ ә. Өзгәләнәсе килә дә, сәбәбе юк.

И б р а һ и м. Дибәҗә...

Д и б ә җ ә. Мин туганнан бирле Дибәҗә.

И б р а һ и м. Сине монда очратуыма шатланам.

Д и б ә җ ә. Ә минем сезне бу тирәләрдә бер дә күргәнем юк иде.

И б р а һ и м. Моннан соң һәр көн килермен инде.

Д и б ә җ ә. Бик әйбәт булыр... Саф һава суларсыз.

И б р а һ и м. Мин шаярмыйча гына әйткән идем, Дибәжә.

Д и б ә җ ә. Мин дә шаярмыйм бит, Ибраһим абый! Участок начальнигы, инженер, егет кеше икән, аңа да вокзал тирәләрендә йөрергә ярыйдыр! Шулаймы, Ибраһим абый? Әллә участок начальнигы башкачарак уйлыймы?

И б р а һ и м. Юк, ул нәкъ шулай уйлый.

Д и б ә җ ә (*җырлый*).

Йөгереп төштем су буена,
Суларда сусар гына...

С ә х и, Н у р и, Р а ф а и л керәләр.

Р а ф а и л. Менә алар!

Н у р и. Тагын егет белән!

С ә х и. Ибраһим абый гына ич бу.

Ибраһим. Нигә, Ибраһим абыегыз егет түгелмени?

Сәхи. Егетнең асылы... Тик сезгә, Ибраһим абый, безнең тирәләрдә үскән кыз гына ярамас.

Нури. Валлаһи шулай! Үткән ел мин Казанга барган идем. Андагы кызларны күреп йөрәгем чак ярылмады. Җитмәсә, кайтканда шундый бер кыз белән урын туры килде. Ашарга-эчәргә куркып кайттым.

Рафаил. Ибраһим абый, кызлар янында ничегрәк ашарга, ничегрәк сөйләшергә кирәклеген бер өйрәтерсез әле!

Ибраһим. Нигә өйрәтмәскә, берәр буш вакыт табабыз да...

Сәхи. Шәп булыр иде, ә, Дибәҗә!

Ибраһим. Сәхи, теге мәсьәләне хәл иттем. Иртәгә егетләреңне дежур бүлмәгә күчерә аласың.

Сәхи. Менә рәхмәт, Ибраһим абый.

Ибраһим. Урнашсыннар, машина бирермен. Авылдан әйберләрен алып килсеннәр.

Рафаил. Үзебез ташышабыз!

Сәхи (*Дибәҗәгә*). Безнең бригададан өч егетнең торыр урыны юк иде. Ибраһим абый аларны дежуркада урнаштырырга булды.

Хәнҗәр керә.

Дибәҗә. Хәнҗәр абый, Хәнҗәр абый!

Ибраһим. Хәнҗәр, син минем участокка күчәргә йөрисең икән бит.

Хәнҗәр. Ремонт базасында эшләгән эш күзгә күренми. Төп корпуска күчәсе иде.

Ибраһим. Тик чамала, эш монда авыррак булачак. Акча да азрак төшәр. Торба салучы белгечләр юк. Аларны читтән чакырырга уйлаганнар иде, үзем монда өйрәтергә булдым. Күңелле эш ул. Көн саен югарырак менә барасың.

Хәнҗәр. Ә егылып төшсәң?

Ибраһим. Үзе егылган үзенә үпкәли.

Хәнҗәр. Авыр эш кирәк миңа. Онытылып эшләрлек булсын. Беләкләр талып, тән авыртып-сызланып торсын!

Ибраһим. Теләгеңне үти аласың. Иртәгедән эшкә чык.

Хәнҗәр. Чыгам. ГРЭС торбасын миннән башка салып бетерәсез икән дип курыккан идем.

Сәхи. Менә аны салып бетергәч эшең күренәчәк инде. Бөтен тирә-яктан.

Рафаил. Сез монда кайтканнан бирле вакытның үткәнен сизмибез дә, Ибраһим абый.

И б р а һ и м. Үзем дә туган якларыма кайтуыма бик канәгать.

Д и б ә җ ә. Ибраһим абый, сизәсезме, бу малайлар тәмам сезгә гашыйк булып беткәннәр бит.

И б р а һ и м. Бик табигый. Мин үзем дә күптән аларга гашыйк.

Д и б ә җ ә. Гашыйк... Кем уйлап чыгарган диген шушы матур сүзне?

С ә х и (*Дибәҗәгә*). Синең күңелдә гашыйк кына инде...

Д и б ә җ ә (*жырлый*).

Ай-һай, гыйшык, кесә тишек...
Бир кызларга, ямасын.

С ә х и. Хәнҗәр абый, әйдә, сөйләшә-сөйләшә кайтыйк бер!

Х ә н җ ә р. Йөрим әле. (*Китә.*)

И б р а һ и м. Дибәҗә, син минем белән кайтасыңмы? Бу якларга бер дә чыкканым юк иде, караңгыда адашырмын дип куркам.

С ә х и. Сез болын ягыннан кайтыгыз, Ибраһим абый, аннан корырак та, якынрак та.

И б р а һ и м. Болын якларыннан сез йөрегез инде, егетләр.

Р а ф а и л. Бергә кайтабыз, бергә.

Д и б ә җ ә. Чыннан да, берүземә өч егет. Сез дүртенчесе була аласыз, Ибраһим абый.

И б р а һ и м Рәхмәт, беренче булырга күнеккәнмен (*Көлә.*)

Вальс.

Д и б ә җ ә. Туйдырды пыскып янулар,
Янып көясем килә,
Янып көясем килә дә
Шашып сөясем килә.

Н у р и. Сөеп-сөелеп үзеннән
Күз алалмаслык булсын.
Ияреп кителсен артыннан,
Һич кадалмаслык булсын.

С ә х и. Сагынылсын, саргаелсын,
Ашау үтмәслек булсын,
Мәхәббәтем аңлатырга
Сүзләр җитмәслек булсын.

Р а ф а и л. Төннәр буе йоклый алмый,
Керфек ормаслык булсын*.

* Шәүкәт Галиев шигыре.

Чыгып китәләр. Ибраһим ялгыз.

Ибраһим. Юктан да кызык табып йөри торган чаклар... Ибраһим абыең тотынса, өзгәләнгәнеңне сизми дә калырсың.

Вокзал янына бара башлый. Вокзалда Гандәлиф, ул акрын гына җырлый.

Гандәлиф. Кыр казы...
Суларда уйный...
Ялгыз башым гел сине уйлый.

Ибраһим. Бу нихәл? Китмәгән? Ул монда! Авыз күтәреп җырлап утыра. Инде дә аңламагач! Тиле...

Ясыйр керә. Кулында фонарь. Аны күрүгә Ибраһим чыгып китә.

Ясыйр. Сәхи, Нури! Кайда сез? Шул инде, бу заман яшьләре бер кыз-кыркын күрсәләр, күзләре тоз була. Китеп тә барганнар. Сөякләр сызлап тора. Әллә явымга, әллә картаелды.

Гандәлиф. Кыр казы...
Суларда уйный...

Ясыйр. Картаерга иртә бит әле, бик иртә. (*Вокзалга керә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вокзал эче. Гандәлиф ялгыз. Ясыйр керә.

Ясыйр. Бу нинди әкәмәт?

Гандәлиф. Нинди әкәмәт, абый?

Ясыйр. Син нишләп китмәдең?

Гандәлиф. Поездның миңа дигәне килмәгән шул әле.

Ясыйр (*бүлмәсенә кереп фонарен куя. Себерке алып чыга*). Алайса, вокзалның да үзеңә дип атап салынганын көт.

Гандәлиф. Әллә ачуландыгыз, абый? Бирегез, үзем себереп алыйм.

Ясыйр. Шулай да нигә китмәдең син?

Гандәлиф. Китмәдем шул әле, абый... Килдем генә ич...

Ясыйр. Вокзалда кунаргамы?

Гандәлиф. Юк, кунмыйм. Тиздән мине алырга ки-

леп җитәргә тиешләр. Без поезд белән китәргә теләгән идек тә... Абый, сезнең монда җиңел машиналар йөрерлекме? Юлларыгыз бик начар күренә.

Ясыйр. Көндез йөреп килдең бит, күргәнсеңдер.

Гандәлиф. Күземә ак-кара күренмәде лә көндез.

Ясыйр. Җиңел машиналар белән килеп алырлык кешене тәүлек буе көттермиләр...

Гандәлиф. Мин көтәргә риза! Көтәм, үпкәләмим.

Ясыйр. Үзең тәрәзәдән күзеңне алмыйсың.

Гандәлиф. Читтән кайтып киләм мин, абый. Ул монда эшли... Менә аны алырга кердем. Ул килергә тиеш.

Ясыйр. Ә-ә...

Гандәлиф. Бигрәк кечкенә сезнең вокзалыгыз. Тәрәзәсе дә бер генә.

Ясыйр. Безгә шул да җиткән.

Гандәлиф. Ямансудыр сезнең монда!.. (*Ясыйр дәшми. Пауза.*) Караңгы сезнең яклар. Әнә кайда гына бер ут җемелди... Монда адашып кереп китсәң, чыга алмассың!

Ясыйр. Бар, чык!

Гандәлиф. Нәрсә дисез, абый?

Ясыйр. Әйберләреңне ал да чыгып кит.

Гандәлиф. Нигә, абый?

Ясыйр. Юллары начар, вокзалы әшәке, караңгы... Туган җирен хурлаган кешене яратмыйм мин.

Гандәлиф. Мин ул җирләрне сагынып кайттым, абый. Шулай булгач, монда калырга рөхсәт итәсезме?

Ясыйр. Кем килергә тиеш соң синең арттан?

Гандәлиф. Килгәч күрерсез.

Ясыйр. Ай-һай...

Гандәлиф. Улмы? Ул... аның кебек кеше дөньяда юк. Ул бер генә... Ул матур... ягымлы, киң күңелле, гадел, кечелекле... Их абый! Ташла әле эшеңне, елмай әле бер. Йә, бер көлегез инде!

Ясыйр. Алдыңда биеп торырга кушар идеңме әллә?

Гандәлиф. Биерсез дә, әйдәгез безнең белән. Барасызмы? Өй туена кайтам бит мин. Дөнья кадәр күчтәнәч алып кайтам. Сыйланырсыз! Сез аны яратырсыз. Бик әйбәт кеше ул... Аны яратмаган бер генә кеше дә юк. Их абый! Матур икән сезнең бу яклар! Вокзалыгыз да нинди нәни, җыйнак! Ә ул ни дип яза бит... Безнең якта торыр рәт юк, караңгы як, сиңа бер дә ошамас, ди. Кайтарасы килмәде.

Ясыйр. Бу диванны кем пычратты?

Гандәлиф. Кайда?

Ясыйр. Язып тутырганнар. (*Укый.*) Кы-ыр ка-азы,

суларда уйный, ялгыз башым гел сине уйлый... Моны кем язды?

Г а н д ә л и ф (*аның елыйсы килә, әмма ул эчке кичерешләрен көчкә тыеп сөйләшә*). Мин язганмындыр шул... Абый җаным, кайнар су белән юсаң, бетә ул, чүпрәк, су бирегез әле.

Я с ы й р. Ярар инде, үзем юармын. Кулың бик ак күренә.

Г а н д ә л и ф. Чынмы, абый җаным? Штукатур кулы дип кем әйтерме?

Я с ы й р. Штукатур дисеңме?

Г а н д ә л и ф. Әйе, абый җаным! Сәгать ничә икән?

Я с ы й р. Унике тула. Үзеңнеке йөрмимени?

Г а н д ә л и ф. Әллә нишләгән.

Я с ы й р. Яле карап карыйк...

Г а н д ә л и ф. Юк, мин борырга гына онытканмын, ахры.

Я с ы й р. Ялганлый да беләсең икән.

Г а н д ә л и ф. Көтеп торганда сәгатькә караулар авыр шул. (*Пауза.*) Ничек шулай ялгыз гына яшисез сез? Поезд көнгә бер генә килә икән...

Я с ы й р. Кем ялгыз? Минме? Һе, кызым, ялгыз вакытлар бар иде минем. Бик озак вакытлар ялгыз булдым мин.

Г а н д ә л и ф. Ә ничек түздегез?

Я с ы й р. Түзәсең аны... Бер нәрсә күрсәтим әле үзеңә. Шуннан аңларсың.

Р а ф а и л белән Н у р и керәләр.

Н у р и. Ясыйр абый, Хәнҗәр абый монда кермәдеме?

Я с ы й р. Күренмәде.

Р а ф а и л. Болай таба китте дигәннәр иде.

Я с ы й р. Китсә дә кермәс, талаштык әле үзе белән. Кайтканына бер ай тулмаган, артык зирәкләнеп китә башлады.

Р а ф а и л. Нури, тәртәләрне борабыз, барып чыкмады...

Я с ы й р. Нигә кирәк булды әле ул? Кендек әбисен генә ярты төндә эзлиләр.

Р а ф а и л. Армиягә китәбез. Өйгә кайтсак, өчебезгә дә чакыру кәгазе килгән, Сәхигә, миңа, Нурига. Берсекөнгә каралырга барабыз.

Я с ы й р. Хуш.

Н у р и. Менә хәзер Хәнҗәр абый кирәк, үзе кирәк, гармуны кирәк. Тар урамнарны киң итеп үтәсе иде, айкасы иде бер! Их!

Р а ф а и л. Күркә күк кабарынма, бии белсәң ярар иде!

Н у р и. Бүген биим. Чәчрәп китим. Бир музыкаңны, их-ма! (*Кыланып биеп ала. Гандәлиф көлеп җибәрә. Ясыйр бүлмәгә керә.*)

Р а ф а и л (*Гандәлифне күреп*). Тс-с!

Н у р и. Чибәр кыз! Менә моны чибәр дисәң дә ярый.

Р а ф а и л. Канатларыңны җилпемә! Үзем сөйләшәм!

Н у р и. Эш чыгара алсаң ярый ла!

Г а н д ә л и ф. Ни пышылдашасыз анда?

Р а ф а и л. Пышылдашмыйбыз, карыйбыз гына. Әйтегез әле, сезнең апагыз, йә булмаса сеңлегез бармы?

Г а н д ә л и ф. Апам да, сеңлем дә бар.

Н у р и. Тәгәрәп китим!

Р а ф а и л. Нури, мондарак кил әле. Сүз бер булсын, апасы сиңа, кыз минеке!

Н у р и. Ничек синеке?

Р а ф а и л. Кыз миңа ошады.

Н у р и. Миңа да ошады.

Р а ф а и л. Бәхәсләшмә, апасыннан колак кагарсың.

Н у р и. Апасы дигәне саңгырау, кәкре аяклы, сакау булса?

Г а н д ә л и ф. Серләрегез берегәме?

Р а ф а и л. Сер дип...

Н у р и. Тотлыкма, яр да сал.

Р а ф а и л. Менә Нури белән дуслар без. Әйбәт егет ул. Ташчы. Мин дә аның белән бергә эшлим. Безнең дуслар гына түгел, туганнар да буласыбыз килә. Аның бердәнбер юлы: баҗалар булу. Шуңа күрә менә... ни... апалы-сеңелле кызлар белән танышырга телибез.

Н у р и. Апагыз да чибәрме?

Г а н д ә л и ф (*көлеп*). Искиткеч чибәр.

Н у р и. Сезгә охшаганмы?

Г а н д ә л и ф. Тик бераз соңгарак калдыгыз бит, егетләр.

Н у р и. Чәчрәп китим!

Г а н д ә л и ф. Апам кияүдә.

Н у р и. Ә сеңлегез, сеңлегез?

Г а н д ә л и ф. Сеңлем җидене генә бетерде әле.

Р а ф а и л. Нури! (*Читкә дәшеп.*) Сеңлесе үсеп җиткәнен көтәсеңме?

Н у р и. Өч-дүрт ел?! Син өйләнәсе, ә мин көтәсеме?

Р а ф а и л. Ә үзегез? Сез, сез...

Г а н д ә л и ф. Ә үзем... Үзем менә сезнең күз алдыгызда!..

Р а ф а и л. Сез монда килдегезме? Кунаккамы? Кемгә?

Г а н д ә л и ф. Барын да белергә телисез! Бик тиз!..

Рафаил. Әйберләрегезне илтешәбез, әйдәгез, безнең клубта бүген уен була.

Гандәлиф. Кызларыгыз көнләшер бит.

Рафаил. Көнләшсеннәр иде әле. Әйдәгез, нигә монда вакыт әрәм итәбез?

Нури (*шыпырт*). Уен әллә кайчан таралгандыр инде.

Гандәлиф. Рәхмәт, егетләр, тик минем иптәшем бар инде, ирем бар.

Нури. Рафаил! (*Читкә дәшә.*) Кил бире, бу кыз синеке булсын, мин сеңлесен күтәргә булдым.

Рафаил. Әй, ташла әле!

Ясыйр керә.

Нури. Алайса, киттек.

Ясыйр. Утырыгыз әле, менә җыр тыңларсыз.

Нури. Гармун кирәк безгә, гармун. Шагыйрь ничек дигән әле:

Җырласы килеп китте бер
Шаярып, юри генә.
Рояльләр өйдән чыга алмый,
Гармуннар йөри менә.

Рафаил (*шыпырт*). Ясыйр абый, бу нинди кыз? Нишли ул монда?

Ясыйр. Кемнедер көтәм, ди.

Рафаил. Көтә? Бүген күрмәдем микән мин аны. Төзелештә йөрмәдеме икән ул.

Ясыйр. Булгандыр, булгандыр. Көндез чыгып йөрде. Үткән төнне поезд белән килеп төшкән иде. Икенче төнен куна инде.

Рафаил. Кемне көтә икән?

Ясыйр. Менә анысын белмим инде.

Рафаил. Гаҗәп... Хушыгыз. Әй, чибәр кыз! Сеңлеңә сәлам әйт! Без армиядән кайтуга сылу кыз булып үсеп торсын!

Чыгалар.

Ясыйр. Күрдеңме? Безнең егетләр. Минем энем аларның башлыклары. Уһу, минем энемне белсәң син! Үзем укытып чыгардым. Кеше иттем. Кәттә егет. Ә син ялгыз дисең? Тыңлыйсыңмы? (*Патефон һәм пластинка күрсәтә.*)

Гандәлиф. Уйнатыгыз булмаса.

Ясыйр «Көзге ачы җилләрдә» көен уйната. Үзе дә җырга кушыла, ахры, иреннәрен кыймылдатып тора.

Ясыйр. Йә, әйт әле, шәпме?

Г а н д ә л и ф. Моңлы җыр, җыласыны китерә.

Я с ы й р. Җыласыны китерми, яшәсене китерә. Яшәртеп җибәрә бу көй. Гомер юлымда күп тапкырлар тыңладым мин аны.

Г а н д ә л и ф. Нигә? Башка юанычыгыз булмадымыни сезнең?

Я с ы й р. Бу көйдә юаныч та, куаныч та, өмет тә — бар да бар!

Г а н д ә л и ф. Бәгыреrезгә үтеп кергән икән.

Я с ы й р. Гражданнар сугышы вакытында чыккан көй бу... Җимерек окоплар арасында, көзге ачы җилләрдә, иске ертык шинельләргә төренеп утырган ач, ябык татар солдатлары туган илләрен сагынып шушы көйне чыгарганнар. Җиргә сыенып, җирне сагынып, җирнең кадерен, ирекнең кадерен белгән кешеләр генә шулай моңлы җырлый алганнар... Тик бу пластинкада начар яңгырый ул. Әйбәт җырламыйлар, ашыгалар, кабаланалар. Күз алдыңа китер әле: көзге төн, ачы, зәһәр җилләр...

Сәхнә артында көзге төн күренә. Ачы җилләр исәләр һәм көчле хор «Көзге ачы җилләрдә»не башкара.

Х о р.

Без утырган паровозның
Тоткалары җиз генә,
Бер илләрдән чыгып киткәч,
Кайтып булмый тиз генә.

Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам,
Көзге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә.

Чәчәк идем илләремдә,
Чәчелдем чит җирләрдә.
Тагы да чәчәк булыр идем,
Кайтсам туган илләргә.

Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам,
Көзге ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә...

Ишеттеңме? Дөньяда шундый көйләр барында, шундый моң булганда, шундый сагынырлык җирең барында, син аның белән бергә булганда ялгыз буласыңмы соң? Ялгыз дисең син... Ул заманнар үтте инде. Иң матур, иң рәхәт көннәремне кичерәм мин хәзер.

Г а н д ә л и ф. Тагы да чәчәк булыр идем, кайтсам туган илләргә... (*Пауза.*) Көегез белән җил чакыргансыз, ахры. Әллә нигә тәрәзәләр зыңлап тора.

Я с ы й р. Тиздән явымнар башланыр. Яусын. Җир тугаеп, сугарылып калсын...

Г а н д ә л и ф. Чыннан да җил күтәрелә... Ишетәсезме? Агачлар шаулый... (*Тәрәзәгә таба бара да куркып кире чигенә.*) Абый, монда кемдер бар!

Я с ы й р. Булса ни.

Г а н д ә л и ф. Ул монда карап тора иде, мине күргәч качты.

Я с ы й р. Күзеңә күренгәндер.

Г а н д ә л и ф. Юк, ул чын кеше иде...

Я с ы й р. Берәр узгынчыдыр. Усал ниятле кешеләр юк хәзер.

Г а н д ә л и ф. Усал ниятле... булмагач, нигә бу кружканы аркан юанлыгы чылбыр белән бәйләп куйдыгыз?

Я с ы й р. Җүләрлек. Инструкция кушканга бәйләнгән.

Г а н д ә л и ф. Тышта караңгы да соң! (*Пауза.*) Чыннан да күземә генә күренде микән әллә? Борчыдыгыз сез ул җырыгыз белән мине. Мин дә ерактан кайтып киләм бит. Туган илемә, кадерле кешем янына... һәм икенче төнемне монда үткәрәм! (*Пауза.*) Ай!

Я с ы й р. Ни бар тагын?

Г а н д ә л и ф. Барыгыз, чыгыгыз әле, абый, карагыз әле, әгәр ул булса, керсен, Гандәлиф көтә диген, шаяртып йөриме әллә? Ул килергә тиеш бит.

Я с ы й р. Менә тиле кыз, кем, кем ул?

Г а н д ә л и ф. Барыгыз инде, бар! Бәлки, соңарган юлчыдыр.

Я с ы й р. Ә-ә... Чыннан да... Юллар пычрак, төннәр караңгы, поездга дип чыккандыр да адашкандыр. Чыгыйм әле, адашкан кеше булмасын.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә әйләнә. Вокзал алды. Караңгы. Яңгыр сибәли. Көзге зәһәр җилләр чыелдап куялар. Җил арасыннан гармун тавышы да ишетелә. Фонарен тотып Я с ы й р чыга. Тирә-якны күзәтеп тора.

Я с ы й р. Әй, кем бар монда? Әй! Берәү дә юк... Менә тиле кыз. Арыган да күзләре әлҗе-мәлҗе килә башлаган.

Акрын гына атлап бара башлый, шул чагында караңгыдан бер күләгә чыгып аңа каршы юнәлә. Бу — И б р а һ и м.

Ибраһим. Һәй!

Ясыйр. Чү, чү, иплəп...

Ибраһим. Ясыйр абый, курыкма.

Ясыйр. Ибраһим? Нишләп йөрисең монда болай?

Ибраһим. Менә синең янга килеп чыктым.

Ясыйр. Кит аннан!

Ибраһим. Мондарак кил. Бер чакрымнан торып сөйләшәсең.

Ясыйр. Рәхмәт сиңа, туганкай! Рәхмәт. Онытмагансың икән. Кереп чыгармын дигән идең. Сүзеңдә тордың. Егет икәнсең. Беләм, беләм, акланып маташма! Вакытыңның алтын бәясенә торганын да беләм! Үпкәләмимим! Мин картның күңелен тапкан өчен рәхмәт сиңа. Эшең күп шул. Уен эшмени? Европада иң зур ГРЭСны Чаптар Минхәер малае Ибраһимнар төзеп ятсын әле. Әйе, кемгә ярдәм итәргә кирәклеген сизгәнмен мин. Апага — әниең мәрхүмәгә хат саен яза идем. Ибраһимны укытыйк, безнең нәселдән дә бер кеше чыксын әле дия идем.

Ибраһим. Рәхмәт, абый, син ярдәм итеп тормасаң, укып чыга алмаган булыр идем.

Ясыйр. Әйдә, әйдә! Өйгә уз, кунак булырсың. Алып куйган яртым бар.

Ибраһим. Керә үк торырмын микән.

Ясыйр. Керәбез, керәбез! Бусага алдыннан борылып китмәссең. Мин төнлә йокламаска күнеккән.

Ибраһим. Ашыкма. Саф һавада берне көйрәтик.

Ясыйр. Куанычымнан онытып торам, син ничек болай бик соң йөрисең?

Ибраһим. Эшең төшкәч йөрисең аны, абый.

Ясыйр. Пычранып беткәнсең. Әллә җәяү килдеңме?

Ибраһим. Болын ягыннан урадым.

Ясыйр. Болыннардан урадың? (*Пауза.*) Син тәгаен минем янга дип килдеңме?

Ибраһим. Әйе.

Ясыйр. Тормыйк әле, алайса, монда кагаеп.

Ибраһим. Тартып бетерик... Ашыкканны яратмыйм мин... Вакыт кадерле кадерлесен... эш муеннан!

Гандәлиф (*ишекне ачып кычкыра*). Абый, кайда син? Мин берүзем куркам.

Ясыйр. Әй, әттә генәсе, син бар бит әле анда! Хәзер керәм, хәзер! Башка кырмавык булды.

Ибраһим. Бу нинди кыз?

Ясыйр. Юлаучы.

Ибраһим. Нишли ул монда?

Ясыйр. Бер кешене көтә. Чемоданнарын тезеп куйган, стеналарга язып тутырган. Ялгыз башым гел сине уйлый, дигән.

И б р а һ и м. Тагынниләр эшли, берәр җиргә бардымы?

Я с ы й р. Көндез каядыр барып килде.

И б р а һ и м. Кешеләр белән сөйләшәме? Ни сөйләшә?

Я с ы й р. Анысын күрмәдем. Ибраһим, керик, аякка таракан үтә башлады.

И б р а һ и м. Ашыкма, абый, мин әйткәч ашыкма, тыңла. Минем болай соң йөрүемә гаҗәпләнденме бераз?

Я с ы й р. Сәер, Ибраһим, бик сәер.

И б р а һ и м. Китәм, синең белән саубуллашырга килдем.

Я с ы й р. Ничек? Ни диден?

И б р а һ и м. Моннан китәргә туры килә.

Я с ы й р. Ничек алай? Ничек? Бик дәртләнеп кайткан идең бит.

И б р а һ и м. Нишлисең.

Я с ы й р. Бер-бер хаталык эшләдеңме?

И б р а һ и м. Хаталык күзгә күренгәнче китәргә кирәк.

Я с ы й р. Юк, Ибраһим, юк, мин карт инде, син киткәч, мин ничек яшәрмен? Ялгыз башың ничек яшисең дип кешеләр гаҗәпләнәләр. Ялгыз яшиммени мин, синең белән яшим! Ибраһим, син мине гомеремнән, шатлыгымнан мәхрүм итмә.

И б р а һ и м. Абый, күп сөйләүдән файда юк.

Я с ы й р. Әйт, кем сиңа аяк чала? Кем ул синең дошманың?

И б р а һ и м. Вокзалдагы кыз.

Я с ы й р. Кыз? Шушы кызмы? Аның синдә ни эше бар?

И б р а һ и м. Төпченмә анысын!.. Шул кыздан котылырга ярдәм ит.

Я с ы й р. Ни гаебең бар ул кыз алдында?

И б р а һ и м. Гаебем юк, нинди гаебем булсын, абый...

Я с ы й р. Соң шулай булгач?

И б р а һ и м. Әшәке кыз ул... бозык кыз...

Я с ы й р. Син шундый кызга бәйләндеңме?

И б р а һ и м. Кем белгән аның шундый икәнен! Каян килеп чыккан диген! Стройкада йөрим, муеныма берәү килеп асылынды, һуштан язам дип торам... Алты айга алты хат та язмадым үзенә. Аңлаган кешегә аңларлык! Юк!

Я с ы й р (*таркау*). Үткән төнне килеп төште шул.

И б р а һ и м. Әле дә ярый, кешеләр күрмәде. Көч-хәл белән вокзалга озаттым үзен. Киләм, дидем, килмәдем. Аңлаган кешегә тагын аңларлык. Әйберләрен җыясы да китеп кенә барасы бит!

Я с ы й р. Китми ул. Поезд белән китмәгәч, машина белән кереп алалар дип көтеп тора.

И б р а һ и м. Күз белән әйткәнне аңлыймы соң ул? Тел белән әйтергә кирәктер шул. Абый... син монда минем якын кешем. Мин сиңа ышанам, ярдәм ит, озат син аны!

Я с ы й р. Ничек озатыйм? Кеше бит, өмет белән кайткан кеше...

И б р а һ и м. Уйлап тап шунда, һич югында болай диген, Ибраһим телефоннан шалтыратты, аны тиз генә трестка чакырып алганнар, этиләренә кайтырга кушты диген. Ике көннән синең янга барып җитә диген.

Я с ы й р. Ике адымда гына үзе утыра. Янына кер дә ачыктан-ачык сөйләш.

И б р а һ и м. Тавыш-гауга күтәрсә! Авыз күтәреп җырлап утырганны, бугазын киереп стройкага бармас дисеңме син аны? Кошмар! Мин киткәч алты ай читтә себерелеп йөрегән урам кызы минем җилкәмә кайтып төшә.

Я с ы й р. Бер дә андый кызга охшамаган бит ул...

И б р а һ и м. Син, абый, кемгә ышанасың? Миңамы, әллә үз күзеңәме?

Я с ы й р. Әгәр бозык кыз икән, бәйләнмәскә генә кирәк булган.

И б р а һ и м. Егыласы җиремне белгән булсам, түшәк җәеп куяр идем, дип әйтте бер агай. Әгәр монда берәрсенә телен ачса...

Баядан бирле гармун тавышы ишетелә, ул якыная.

Бусы ни тагын?

Я с ы й р. Хәнҗәрдер ул.

И б р а һ и м. Нишләп йөри ул монда?

Я с ы й р. Төн авышкач, вокзал тирәләрен бер урый. Моңая.

И б р а һ и м. Саташкандыр ул.

Я с ы й р. Саташырсың да... Армиядән кайтуыңа бер атна калганда сөйгән кызың сине ташлап кияүгә чыксын әле. Шундый егетне! Моряк!

И б р а һ и м. Моңаеп ни файда?

Я с ы й р. Тимә, монда мәхәббәт... Кайдадыр җиде юл чатында гына танышмаган. Яшьли сөйгән яр диләр аны. Атлыгып кайтып керәсең, ә ул юк... Китеп барган...

Гармун тавышы якыная. Х ә н җ ә р җырлый. Ясыйр белән Ибраһим җырны тыңлап торалар.

Х ә н җ ә р (*җырлый*).

Бәгырькәем, туңар булсаң,
Ки кара бишмәтеңне;
Синең утларыңда янам,
Теләсәң нишләт инде.

Я с ы й р. Чылангансың, моряк.

Х ә н җ ә р. Яңгыр астында йөрергә яратам мин.

Я с ы й р. Кем яратмый? Җәйге баллы яңгырларда болыннарда йөрисең.

И б р а һ и м (*аны бүлдереп*). Абый, син туңгансың, ахры. Кер булмаса, салкын тимәсен.

Я с ы й р. Хәзер керәм... Их, яшь чагында булган бер гыйбрәтне сөйләрмен дигән идем үзеңә... Тыңламадың.

И б р а һ и м. Башка вакытта, башка... Без синең белән сөйләштек, абый... Кара, мин сиңа ышанып торам.

Я с ы й р. Керәм, керәм, уф, дөньялар! (*Кереп китә.*)

Х ә н җ ә р. Сөйләсен иде, дөнья күргән кеше, бер-бер акыллы сүз әйтеп куяр иде.

И б р а һ и м. Бер әйләнә башласа туктатырсың аның тегермәнен! (*Пауза.*) Төн уртасында монда мине очраткач гаҗәпләндеңме?

Х ә н җ ә р. Ә сез?

И б р а һ и м. Юк, синең сәбәбең бар. Моңаясың икән.

Х ә н җ ә р. Кем әйтә?

И б р а һ и м. Аны кешедән әйттермиләр. Үзең сизәләр.

Х ә н җ ә р. Рәхмәт.

И б р а һ и м (*көлеп*). Бала.

Х ә н җ ә р. Нигә, кеше гомере буе азрак бала булып каладыр инде.

И б р а һ и м. Син артыгы белән бала. Уенга алма, чыны шулай. Ниндидер бер кыз ташлап киткән өчен, янып-көеп яңгырга чыланып йөр инде.

Х ә н җ ә р. Ачуыгыз килмәсен, әмма кешенең беркемгә дә күрсәтми торган күңел почмаклары була.

И б р а һ и м (*ярым мыскыллап*). Әллә?

Х ә н җ ә р. Мин ул хакта беркем белән дә сөйләшмим.

И б р а һ и м. Үзем дә егет кеше, аңлыйм. Хатын-кызга ышанырга ярыймы соң? Бүген синең белән, иртәгә җиде ятның муенына ташлана ул. Күңел почмагы дисең син. Шул күңел почмагында хатын-кыз асраган кешедән дә юләррәк бәндә бармы? Тәмлерәк, ягымлырак бер сүз әйтсәң, теләсә нинди кызны ияртәсең. Яңа туган бозау белән бер алар. Аларга ышанып булмый.

Х ә н җ ә р. Ә сезнең яраткан кешегез бармы?

И б р а һ и м. Егет күңеле буш буламы?

Х ә н җ ә р. Ярый, сез аны яратасыз ди, бик нык яратасыз ди. Әгәр дә сездән дә шәбрәк бер егет килеп чыгып, сезнең сөйгәнегезне тартып алса?

И б р а һ и м. Андый егет мич артында күмер ашый.

Х ә н җ ә р. Юк, сез алса дип уйлап карагыз әле.

И б р а һ и м. Әгәр дә бу дөньяда шундый могҗиза булса,

төкереп кенә китәр идем. Беткәнмени дөньяда чибәрләр?

Хәнҗәр. Әгәр анысы да сезне ташласа?

Ибраһим. Минем күршедә бер агай тора. Шул: хәзерге заманда егетләр талон белән, хатын-кыз шалон белән дип кенә җибәрә.

Хәнҗәр. Әйе... Хатын-кыз сөя белми, ахры. Әгәр чын мәхәббәт белән сөйсә... Шундый бер кызны очратсам, фуражкамны салып башымны ияр идем. Болай яшәү бик кыен бит. Ышанасы килә, сөясе килә.

Ибраһим. Дөрес, мин үзем дә нәкъ синеңчә уйлыйм, тик тормыш аяусыз... Аның үз законнары бар. Ул без теләгәнчә генә, кешеләр теләгәнчә генә бармый.

Хәнҗәр. Бардырырга кирәк иде...

Ибраһим. Кулыңнан килсә бардыр. Яңгырга шәбәреп, гармун кычкыртып йөрүдән башка ни кыра аласың? Сине ташлап киткән кыз җәзаланамы шуңа карап? Мамык түшәгендә изелеп йоклый ул.

Хәнҗәр. Ибраһим!

Ибраһим. Кычкырма, зинһар!

Хәнҗәр. Шәхси эшләргә кагылмыйк без.

Ибраһим. Кызганып әйтәм үзеңне, Хәнҗәр! Ташла син алай борчылып йөрүләреңне.

Хәнҗәр. Җиңел түгел шул... Онытылып булмый.

Ибраһим. Аның өчен ир йөрәкле булырга кирәк. Туктале, синең сынап карасың киләме?

Хәнҗәр. Ничек?

Ибраһим. Вокзалда бер кыз утыра. Чибәр! Яхшы мал! Искиткеч! Кап та йот!

Хәнҗәр. Чибәрләрдән куркам мин.

Ибраһим. Тот та хәзер шуның янына кер.

Хәнҗәр. Кереп нишлим мин анда?

Ибраһим. Минем сүзгә ышанмасаң, үз күзеңә ышанырсың. Бер дәлил булыр үзеңә. Кер дә тәмле телеңне кызганма. Боргалан, сыргалан, сез миңа бик ошадыгыз диген. Сөям диген, кем булуын сорашма, тормышын төпченеп торма, кызлар андый сүзләрне яратмыйлар, алар җиңел акыллы, ут күзле, нык куллы, кыю егетләрне яраталар.

Хәнҗәр. Шулай инде, андый егетләр аларга ошый.

Ибраһим. Шикләнмә. Шикләнсәң дә, аны кызларга белдермә.

Хәнҗәр. Ярый, кердем, ди. Яңагыма кундырып чыгарса?

Ибраһим. Кундырмый. Күзендә ат тоягы эзе бар аның. Кыю бул, моряк бит син! Морякларның законын беләсең инде. Ике тапкыр каш сикертә, бер тапкыр күз

кыса да палундра!

Хәнҗәр. Ни булса булган!

Ибраһим. Менә шулай! Гармуның кулында. Уйнап җибәргән бул. Ваемсыз, егет малай икәнлегеңне күрсәт. Мәхәббәт дигән нәрсәнең буш сүз икәнлеген менә шунда күрерсең.

Хәнҗәр. Карап карыйк. (*Керә башлый, туктап.*) Ә Ясыйр абый?

Ибраһим. Ул күптән йоклый.

Хәнҗәр кереп китә.

Шундый буй-сын, гармунчы, моряк! Кыр да бар кызларны! Гомерен бушка уздыра.

Чыгып китә. Җилләр исә. Яңгыр сибәли. Калын яулыкларга төренгән Мәймүнә белән Ак түти керәләр.

Мәймүнә. Тавыш-тын юк.

Ак түти. Вокзалга кергәндер. Тәрәзәгә генә күз сал әле.

Мәймүнә (*тәрәзә янына барып килә*). Адәм шәүләләре күренә. Шулардыр...

Ак түти. Әҗәлем исемдә иде, курка-поса тәрәзә төпләре сакларммын дип уйламый идем.

Мәймүнә. Син сөйләгәч исем-акылым китте, әй!

Ак түти. Яман хәбәр тишек авыз эзли ди. Дөньяга чыгара күрмә инде, күршекәем.

Мәймүнә. Чыгып йөрмә, өйдә генә утыр дип караганың юкмы соң?

Ак түти. Ничек әйтәсең, Мәймүнәкәем? Бер ай эчендә бала саргаеп катты бит инде. Шушы вокзал тирәләреннән кайтмый. Төн җитеп, кеше аяк эзе басылгач, гармунын күтәреп чыгып китә дә таң алларыннан гына кайтып керә. Башта мин аны клубта-мазарда, кызлар янында йөри дип юрадым. Сораштырам, анда булмаган, уенга төшмәгән. Эчемә пошаман инде... Яман юлларга тап булмасын... Үзем генә чыгарга куркып йөрдем...

Мәймүнә. Чыгарлыкмы соң? Күзеңә албасты күренсә!

Ак түти. Поезд кычкырганын ишетсә, чабышкы ат төсле ярсый башлый. Кызың гаепле, Мәймүнә... Эльвираң! Асыл егетнең башын ашады.

Мәймүнә. Кыз кешене тыеп буламы? Кызлар җилкенер, хатын булгач, үкенер диләр бит. Хәнҗәрең дә ни шайтаныма, кайтам, шунда электрда эшләрбез дип хат язып ята! Шул хатны укыгач, кыз бөтенләй исәрләнде. Китәм. Монда аю базында калып бурсып үләр хәлем юк, ди.

А к т ү т и. Үзең гаепле. Туган җирне яраттыра алмагансың.

М ә й м ү н ә. Инде, күршекәем, тәкъдирдә язгандыр. Чәчләре чәчкә бәйләнмәгән булса... Үзеңне генә хәтерлә дә тын инде. Тын инде, күршекәем.

А к т ү т и. Безнең анын заманы башка иде. Кая барып бәрелерлек түгел иде.

М ә й м ү н ә. Ул чагында да кавышканнар кавышты. Син шул тиле-миле Ясыйрга гашыйк булдың да...

А к т ү т и. Мәймүнә, син юкны кузгатма. Син бернәрсә дә белмисең.

М ә й м ү н ә. Һе, бөтен авыл авызына кергәнне мин белми калам ди. Саңгыраумы мин, сукырмы? Әй, Ясыйр чыгып сызгач тыз-быз чаба! Безнең турдан әллә ничә кат юргалап үттең...

А к т ү т и. Йомышым булгандыр. Хәтерләмим инде.

М ә й м ү н ә. Йон очырасың. Хәтерләмим дигән булып Мәймүнәнең башын тинтерәтмә. Әгәр дә мәгәр шушы вокзалда Ясыйр утырмаса, син керми китәр идеңме? Хәнҗәреңнең артыннан барып җилтерәтеп алып чыгар идең.

А к т ү т и. Нигә кирәргә? Монда да рәхәт ич.

М ә й м ү н ә. Рәхәт. Аяклар шыкранлап катты. Әйдә керәбез.

А к т ү т и. Кермик инде.

М ә й м ү н ә. Алайса, йөреп киләбез. Әйдә!

А к т ү т и. Ул чыгар да күрми калырбыз.

М ә й м ү н ә. Тор инде алайса, төн саклап. (*Тыңлап.*) Тукта, Хәнҗәр тавышы бит бу.

А к т ү т и. Хатын-кыз да бар түгелме? Кем булыр икән ул?

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук вокзал. Диванда аякларын бөкләп Г а н д ә л и ф йокымсырый. Ул вакыт-вакыт башын күтәреп тыңлана да тагын ия. Еракта скрипкада «Көзге ачы жилләрдә»не уйныйлар. Тышта көзге җилләр исә. Алар пәрәвездәй нечкә куллары белән вокзал тәрәзәләрен капшыйлар. Стеналарны ялыйлар. Гандәлифкә үреләләр. Ул туңа, ахры, вакыт-вакыт иңбашлары калтыранып китә. Х ә н җ ә р керә.

Х ә н җ ә р. Сәлам!

Г а н д ә л и ф (*йокы аралаш*). Килде!

Х ә н җ ә р. Килдем шул, көткән идеңме?

Г а н д ә л и ф (*йокы аралаш*). Уфф! Көнме, төнме хәзер?

Х ә н җ ә р. Төн.

Г а н д ә л и ф. Яңгыр явамы?
Х ә н җ ә р. Синең өчен барыбыр түгелмени?

Гандәлиф сикереп тора. Хәнҗәрне күрә.

Менә синең янга килдем.

Г а н д ә л и ф. Нигә авызыңны йомып торасың алай булгач?

Х ә н җ ә р. Нишлим?

Г а н д ә л и ф (*ярсып*). Сөйлә!

Х ә н җ ә р (*ярым аптырашта*). Нәрсә сөйлим?

Г а н д ә л и ф (*ачуланып ук*). Менә шашкан! Сине ул җибәрдеме? Нишләп үзе килмәде? Чирлиме әллә? Нәрсә дияргә кушты? Йә, торма инде. Юлда килгәндә телеңне йотып җибәрдеңме әллә?

Х ә н җ ә р. Кем җибәрсен мине, үтеп бара идем, тәрәзәдә шәүләң уйный. Күрдем дә кердем.

Г а н д ә л и ф. Күптән шулай диләр аны... (*Менеп утыра.*)

Х ә н җ ә р. Матур гына икәнсең үзең. Әйтәм аны тәрәзәдә нурлар уйный.

Г а н д ә л и ф (*мыскыллап*). Сүзең шул булса, мин аны күптән беләм.

Х ә н җ ә р. Ямьсез дисәм, ачулансаң да ярар иде, матур дигән өчен турсайма инде.

Г а н д ә л и ф. Бар, чыгып кит.

Х ә н җ ә р. Бусы бөтенләй киртәгә кермәде, нигә куасың?

Г а н д ә л и ф. Йомышыңны йомышладың, мин арыдым, йокым килә.

Х ә н җ ә р. Гармун уйнап күрсәтимме?

Г а н д ә л и ф. Монда клуб түгел, вокзал.

Х ә н җ ә р. Мин акрын гына (*Уйный һәм җырлый*).

Алып бирим алтын тарак
Маңгай чәчең тарарга,
Күзләреңдә нурлар уйный,
Кыймыйм туры карарга.

Г а н д ә л и ф. Нинди көй бу?

Х ә н җ ә р. Матурмы? Сиңа ошадымы?

Г а н д ә л и ф. Матур көй.

Х ә н җ ә р. Чынмы? Бик яратам мин шушы көйне. (*Ул бер минутка монда ни өчен керүен дә оныта. Көйнең Гандәлифкә ошавы аны юашландырып җибәрә.*) Клуб түгел дисең, элек монда безнең авылның болын башы иде. Яшьләр уенга гел шушында җыелалар иде. Минем абыйлар... Малай чакта ук ишеткән идем мин бу көйне.

Г а н д ә л и ф. Болыныңны кызганасыңмы?

Х ә н җ ә р (*хәтере калып*). Кызганмыйм. Чибәр кызлар белән болында утырсаң ни дә, вокзалда утырсаң ни. Синең янга утырыйммы?

Г а н д ә л и ф. Ярамый.

Х ә н җ ә р. Ярамаса да утырсам?

Г а н д ә л и ф (*янап*). Утырып кара!

Х ә н җ ә р. Кәҗәләнмә инде, үскәнсең бит. Бүрек белән генә бәреп егарлык түгел.

Г а н д ә л и ф (*тыныч кына*). Күгәргән күрекле гармуныңнан нинди матур көй чыгарасың. Япь-яшь, бозыларга өлгермәгән күңелеңдә нинди әшәке уй асрыйсың. Оялыр идең!

Х ә н җ ә р. Кемнән? Монда берәү дә юк. Без икәү генә... Чәүчәләкләнмә инде.

Г а н д ә л и ф. Үзеңнән оял, үзеңне-үзең күреп торасың ич. Баксаң, сөйгән кызыңны озатып кайтып киләсеңдер әле.

Х ә н җ ә р (*кинәт кызып*). Сөйгән кызым юк минем. Юк! Ишетәсеңме һәм кирәге дә юк.

Г а н д ә л и ф. Мондый чуар йөрәкле егетнең сөйгәне булмау да гаҗәп түгел. Кайсы кыз ышанып язмышын сиңа бәйләсен?

Х ә н җ ә р. Үземнең бәйлисем килми.

Г а н д ә л и ф. Әле кергәнсең бит.

Х ә н җ ә р. Хатын-кыз шуннан башкага ярыймы соң ул? Сөюне аңлый дип beləсеңме әллә син аны. Турылыкны, гаделлекне бәяли белә дисеңме?

Г а н д ә л и ф. Әйе, хатын-кыз сөя белә. Ул турылыклы була белә. Ул гаделлекнең кадерен белә.

Х ә н җ ә р. Белә! Тик теләми генә. Боларның барсын да үтәү өчен кешенең башында мие булырга кирәк. Хатын-кызның ми тартмасында җил уйный. Йә, ташлыйк әле шушы суган сатуны.

Г а н д ә л и ф. Телең кычытып үзең кердең ич.

Х ә н җ ә р. Телем түгел, кулым кычытып. Кочаклыйсым килә бер үзеңне. (*Кулларын җәеп бара башлый.*)

Г а н д ә л и ф. Якын килеп кара.

Х ә н җ ә р. Артыгын кыланма инде, йә, йә! (*Кочаклап үбә.*)

Нәкъ шул вакытта А к т ү т и белән М ә й м ү н ә керәләр. Гандәлифнең тавышына Я с ы й р чыга.

Г а н д ә л и ф. Ах, менә кайсы төшең кычыткан икән синең. (*Уңлы-суллы яңаклый.*) Менә, менә!

А к т ү т и. Улым!

Мәймүнә. Хәзерге заман баласына ышансаң.

Хәнҗәр телсез кала, ул нишләргә белми.

Ясыйр. Ни бар монда, ни булды? (*Ак түтигә.*) Шәмсерур?!

Ак түти. Кайтуыңа күпме вакыт булып күрешә алмаган идек. Исәнме, Ясыйр...

Ясыйр. Шәмсерур... Исәнме, ни булды монда?

Хәнҗәр. Берни дә юк, Ясыйр абый, ну кызый...

Ак түти. Улым!..

Хәнҗәр. Буталып беттем мин, әнкәй...

Чыгып китә, вокзалдан чыгу белән гармун тартып җибәрә. Ачулы җыр тавышы ишетелә.

Ак түти. Улым, Хәнҗәр! (*Чыга. Мәймүнә аңа иярә.*)

Ясыйр. Шәмсерур... Китте... Бер генә дә үзгәрмәгән... Таныды бит, таныды, онытмаган. (*Гандәлифне күреп.*) Ни булды монда?

Гандәлиф. Бер гаебем дә юк, абый җаным.

Ясыйр. Хәнҗәр кебек егет тиктомалга килеп бәйләнмәс.

Гандәлиф. Нахакка рәнҗетәсез, абый җаным. Ни булды? Бая да минем белән сөйләшмәдегез. Ни гаебем бар? Үз теләгем белән утырмыйм бит... Килә алмагандыр шул.

Ясыйр. Белмим, ни әйтергә дә аптырадым...

Гандәлиф. Сәгать ничә икән, абый?

Ясыйр. Соң инде, сорама. (*Кереп китә.*)

Гандәлиф (*тәрәзә янына барып, пыялага нидер яза*).

Чәчәк идем илләремдә,
Чәчелдем чит җирләрдә,
Тагы да чәчәк булыр идем... (*Туктый, пауза.*)
Тагы да чәчәк булыр идем...

Җырның соңгы юлларын җырламый, өзеп-өзеп кенә әйтә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук вокзал. Көн яктырган. Гандәлиф тә, Ясыйр да бу төнне йокысыз үткәргәннәр. Ясыйр Ибраһимның боерыгын хәтердән чыгара алмый. Әнә ул кырын күзе белән карап вокзал аша үтеп бара. Гандәлиф кечкенә генә колак мендәре тотып тора.

Г а н д ә л и ф. Абый, бу мендәр каян килгән монда?

Я с ы й р. Мин салдым. Карыйм, йоклап киткәнсең, башың бер якка авышкан.

Г а н д ә л и ф. Йокым да йокы булмады, дерт-мерт итеп саташып яттым. Ай-һай, җилләр котырынды. Җил дә исә, кайдадыр «Күзгә ачы җилләрдә»не җырлыйлар кебек...

Я с ы й р. Ә? Әһә... Урыны җайсыз шул.

Г а н д ә л и ф. И-и абый, йокы килгәндә урын талымлап торылмый. Эшләгәндә бик арыган чаклар була. Әбәт вакытында коры тактага башыңны куеп биш-ун минут черем итеп алсаң, җаннар рәхәтләнеп китә.

Я с ы й р. Син кем булып эшлим дигән идең әле?

Г а н д ә л и ф. Штукатур булып эшлим.

Я с ы й р. Штукатур? Алай икән... алай!..

Г а н д ә л и ф. Бик күңелле эш ул, абый. Кытыршы, ямьсез стеналар син эшләп киткәннән соң көлеп торалар. Буяп та җибәрсәң, курчак шикелле була инде менә. Ул кәрниз сызулар... Минем эшемне ул да бик мактый иде.

Я с ы й р. Кем?

Г а н д ә л и ф. Ибраһим. Аның исеме Ибраһим бит. Без бит шунда таныштык. Ул укып бетереп прораб булып безгә эшкә килде. Якташлар икәүдән-икәү генә идек. Ял саен безгә килә. Казан концертларын тыңлыйбыз. Мин аңа пәрәмәчләр пешерәм. Кухнябыз кечкенә генә... Безнең кызлар егыла-егыла миннән көләләр, ник интегеп маташасың, диләр. Мин пешерәм, ә ул мактый-мактый ашый. Икебез дә Казанны сагынабыз. Җырлап алабыз.

Я с ы й р (*бик кызыксынып*). Шуннан, шуннан?

Г а н д ә л и ф. Әй абый, барын да сөйләп буламыни? Искиткеч кызык иде анда. Ул әллә никадәр китаплар укыган, мин дә аннан күрмәкче укырга тотындым. Тугызынчыны бетердем мин быел. Абый, минем дә аның кебек инженер буласым килә.

Я с ы й р. Нигә булмаска? Мөмкин. Теләгәч булдырырга кирәк.

Г а н д ә л и ф. Сезнең монда кичке мәктәпләр бармы?

Я с ы й р. Алары да бар, бар да бар.

Г а н д ә л и ф. Ә ул мәктәпләр ачылмаган әле дип язган иде.

Я с ы й р. Белми калгандыр, белмәгәндер.

Г а н д ә л и ф. Безнең авыл моннан якын гына. Тимер юл безнең авыл аша да үтә. (*Көлеп.*) Кызык булды, мин поездда үзебезнең өй янының үтеп киттем. Ап-ак морҗадан күгелҗем төтен чыгып тора. Өй түрендә пар каен...

Төтен чыга. Коймак пешә. Әти-әниләр кияү көтәләр.

Ясыйр. Кияү? Кияү диденме син?

Гандәлиф. Кияү шул, без өйләнешкәнгә елдан артты инде. Аннары... аннары ул шушы Зәй буйларына кайтып китте. Мин калып тордым... Хәзер менә безгә кайтабыз. Өй туена. Әтиләр кияү көтәләр. (*Хыялланып.*) Икенче кызлары — Гандәлиф кияү белән кайта. Өйдә тагын өч бала — сеңелләрем бар әле... Әти комбайнчы минем. Айяй шәп өй салганнар. Киләсе елга автомашина алам дип язды әти. Нигә, алыр да! Без дә азрак ярдәм итәрбез. Эх, әтинең машинасы булса, килеп кенә китәр иде...

Ясыйр. Балакай, ул синең монда утыруыңны белми дә бит.

Гандәлиф. Тагын яварга тора инде әллә. Юлларны бетерә. Йөрерлек жир калмый бит.

Ясыйр. Көз бит, явар инде. Син туңасыңмы? Туңсаң мичкә ягып җибәрербез.

Гандәлиф. Туңмыйм.

Ясыйр. Монда якында гына буфет бар. Ул иртә ачыла, кайнар аш та була анда. Бар, ашап кил, эчең җылыныр.

Гандәлиф. Бармыйм, ул килер дә, аймылыш булырбыз.

Ясыйр (*ачуланып*). Килсә көтеп торыр! Син көтәсең бит әле.

Гандәлиф. Килә алмавына үзе дә өзгәләнә торгандыр әле. Эше күп шул аның. Үлеп тырыша бит ул. Бик авырлык белән генә укып чыккан. Укыганда абыйларына, әниләренә ярдәм итеп торган, хәзер эшенә кимчелек китерәсе килми.

Ясыйр. Абыйларына, әниләренә диденме син?

Гандәлиф. Әйе. Әй абый, ачуланмыйм мин аңа. Китте дә уңмады ул. Бер әбинең почмагында гына торам дип язды. Шушы вокзалларда яткырыр идеме Әллә ул мине. Ояла ул. Тегендә без бик әйбәт бүлмәдә тордык. Шуңа мондагы хәлен күрсәтәсе килми. Мине күргәч шундый читенсенде, югалып калды. Кызгандым да соң үзен. Ябыгып беткән, арыган. Шул инде. Керен кем юа да ашын-суын кем әзерли. Кайтуым шәп булды әле. Бөтен әйберне үзем белән алып кайтам. Савыт-сабасын, бар да бар... Яңадан аякка бастырам мин аны. Караңгы төнле Зәй буйларына утны тизрәк яндырсын.

Ясыйр. Теләкләрең әйбәт, изге. Кешене аякка бастыру яхшы эш. Менә мин дә үз гомеремдә бер кешене аякка бастырдым. Кеше иттем, үзем ашамадым, киенмәдем, бар да аңа булды. Укыттым.

Гандәлиф. Ул кеше булып чыкмадымы?

Ясыйр. Кеше кешесен. Кешенең ниндие юк. Тик заман шундый бит. Бик яхшы кешеләр кирәк безгә...

Гандәлиф. Кешенең күңеле син уйлаганча булып чыкмаса аянычтыр ул, абый?

Ясыйр. Аяныч, аяныч була. Син яшь, хыялларың матур. Менә мин дә хыяллана торган, бар нәрсә белән кызыксынучы бер малай идем. Күршебезнең улы авырып китте. Бөтерелеп йөрим бит шул бала янында. Терелтәсем килә сабыйны. Үлде ул... Сыным катты. Шуннан хыялга бирелеп киттем... Явыз чирләрне бетерәсем килә. Абага чәчәк атканын көтеп җиде төн уртасында карурман урталарында утырдым. Терәк суы ташый торган куяннар очрамасмы дип, әрәмәләрдә йөрдем. Авыл халкы моны күреп, миннән көлә, мыскыл итә башлады. Хыялый ул, исәр, айлы төннәрдә мәчет манарасына менеп, тирән коеларга төшеп йөри, дип сүз чыгардылар. Түздем... инде килеп, сихер белән шөгыльләнә, җеннәр белән сүзгә кергән дип, авылыбызның мулласы урәтникне котыртып, каравыл өенә бикләп чыбык белән суктыртты. Шуннан көзге ачы җилләр дулап торган бер төнне авылны ташлап чыгып киттем. Барын ташладым. Нигеземне дә, туган туфрагымны да, сөйгән ярымны да... Шул китүдән озак еллар кешеләргә якынаерга куркып, ялгыз каңгырап йөрдем...

Рәҗәп (*керεп*). Ясыйр абый!

Ясыйр. Әү, малай.

Рәҗәп. Исәнмесез. Мәймүнә малае мин. Рәҗәп. Әни әйтә, сәгатьне төзәтте микән, ди.

Ясыйр. Сәхинең энесе буласың инде, алайса?

Рәҗәп. Үзе. Ясыйр абый, аннары сине бер абый сорады.

Ясыйр. Ә? Нинди абый, кайда ул?

Рәҗәп. Ибраһим абый, ул теге куаклык артында тора. Тиз генә килеп китсен әле, ди.

Ясыйр. Ул шундамы? Хәзер... Гандәлиф, кызым, мин хәзер әйләнеп киләм... Шунда барын да сөйләшеп бетербез инде.

Гандәлиф (*ул Ясыйрның Рәҗәп белән сөйләшүен ишетмичә читтә тора иде. Менә моңланып кына Ясыйр янына килә*). Ясыйр абый... Сез югында китеп барсам, сау булыгыз. Юл төшеп безнең якларга барып чыксагыз, кагылмый үтмәгез. Дәвек кызы мин. Гандәлифләр дип сорасагыз, теләсә кем безнең өйне күрсәтер. Сезгә яхшылык эшлисем килә. Кыен вакытларда мине юаттыгыз, рәхмәт сезгә.

Ясыйр (*бик нык уңайсызланып*). Ни өчен рәхмәт? Кирәкми, алай димә...

Р ә җ ә п. Ә сәгать? Сәхи абыйның сәгате? Ул армиягә китә.

Я с ы й р. Хәзер, хәзер. Мин хәзер киләм. (*Чыга.*)

Р ә җ ә п. Мәктәпкә барасым бар. Әни тиз кайт дигән иде.

Г а н д ә л и ф. Көт инде бераз.

Р ә җ ә п. Исемең ничек синең, апа?

Г а н д ә л и ф. Гандәлиф, үскәнем.

Р ә җ ә п. Кит әле, шундый исем буламыни?

Г а н д ә л и ф. Әнием мине Гандәлиф, сандугачым, дип дәшә иде. Печенье биримме үзеңә?

Р ә җ ә п. Үзеңә каламы соң? (*Пауза.*) Син, апа, кая кайтасың?

Г а н д ә л и ф. Дәвеккә. Әлмәт ягына.

Р ә җ ә п. Минем дә Әлмәтне күргәнем бар. Печеньең печатьле икән синең. (*Пауза.*) Бу Ибраһим абыйны да инде... Үзе генә килсә ярамаганмы? Хәзер көтеп утыр инде менә.

Г а н д ә л и ф. Кем, кем дидең син?

Р ә җ ә п. Ибраһим абый ла... Безнең Сәхи абыйларның начальнигы.

Г а н д ә л и ф. Кайда күрдең син Ибраһим абыеңны?

Р ә җ ә п. Әнә тегендә. ГРЭС юлындагы әрәмәдә. Ясыйр абыйны шул чакырды бит инде.

Г а н д ә л и ф. Үскәнем, син барыбер Ясыйр абыйны көтәсең бит.

Р ә җ ә п. Көтми кая барасың?

Г а н д ә л и ф. Мин җәһәт кенә бер җиргә барып килим.

Р ә җ ә п. Озак торырсың син анда?

Г а н д ә л и ф. Бик тиз... Мә, печенье ашый тор.

Р ә җ ә п. Ашаганы өчен дә эшләгән юк әле.

Г а н д ә л и ф. Йа Аллам, Ибраһим. (*Чыгып китә.*)

Рәҗәп ялгыз. Беренче эш итеп Ясыйр бүлмәсенең йозагын капшап карый. Нидер эзли.

Х ә н җ ә р керә.

Х ә н җ ә р. Рәҗәп, син монда нишлисең?

Р ә җ ә п. Эшләр хутта, Хәнҗәр абый. Абзаң хәзер иң зур начальник. Теләсәм поездларны туктатам, теләсәм җибәрәм...

Х ә н җ ә р (*җитди*). Шаяртма әле.

Р ә җ ә п. Шаяртмыйм.

Х ә н җ ә р. Ясыйр абыең мондамы?

Р ә җ ә п. Юк шул.

Х ә н җ ә р. Чыннан да монда беркем дә юкмы?

Р ә җ ә п. Берәү дә юк. Хәнҗәр абый, син авылдан китәсеңмени?

Х ә н җ ә р. Китмим.

Р ә җ ә п. Алайса нигә вокзал тирәсеннән кайтмыйсың?

Х ә н җ ә р. Эшкә барышым.

Р ә җ ә п. Син бу якта эшләмисең лә.

Х ә н җ ә р. Яңа урынга күчтем.

Р ә җ ә п. Ә-ә. (*Пауза.*) Хәнҗәр абый, мин бу пәкене сиңа кире бирергә булдым.

Х ә н җ ә р. Нигә, Рәҗәп?

Р ә җ ә п. Каениш булмаган кешегә пәке бүләк итмиләр.

Х ә н җ ә р. Мин сиңа дус итеп, күрше итеп бүләк иттем.

Р ә җ ә п. Әни белән Ак түти сөйләшәләр, син бер-бер эш кылып ташламасын, диләр.

Х ә н җ ә р. Алар сөйләшер.

Р ә җ ә п. Син бер-бер эш кылып ташлама, яме, Хәнҗәр абый. Китмә дә. Абый армиягә китә. Эльвира китте. Әти көне-төне буровойда. Атнага бер кайта да югала. Әни билем авырта дип гел зарлана. Үзе врачка да күренми. Без синең белән утыннар кисәрбез. Олы малай булып мин калам бит хәзер. Яз көне син безнең бакчаны сукаларсың, минем сыерчыкларым синең арттан ияреп йөрерләр. Мин киләсе язга өч оя куям. Берсен сезнең ишегалдына каратып. Тимер юлдан олы поездлар йөри башлагач, мин машинист булам. Ясыйр абыйныкы төсле фуражка киеп җибәрәм. Сине диңгез буйларына, тагын әллә кайларга алып барам.

Х ә н җ ә р. Планнар шәп синең, малай.

Р ә җ ә п. Диңгез олы буламы, Хәнҗәр абый?

Х ә н җ ә р. Бик олы.

Р ә җ ә п. Тирәнме?

Х ә н җ ә р. Бик тирән.

Р ә җ ә п. Безнең ГРЭС торбасыннан да тирәнрәкме?

Х ә н җ ә р (*уйлап тора*). Тирәнрәк булыр.

Р ә җ ә п. Хәнҗәр абый, торбаны салып бетергәч айга менсәләр, айдан күренер микән ул?

Х ә н җ ә р. Күренмәс, малай, ай бик ерак бит.

Р ә җ ә п. Син шул торбаны сала торган җиргә эшкә күчтеңме?

Х ә н җ ә р. Әйе.

Р ә җ ә п. Мин синең янга барып йөрермен. Теге Карамалы егетен барыбер җизни дип әйтмим мин.

Х ә н җ ә р. Нигә? Әйт, Рәҗәп, җизни диген. Ул сине яратмас бит.

Р ә җ ә п. Яратмасын. Эльвираны да апа димим. Мин аларны поездларга да утыртмыйм. Сәхи абыемны да сине генә утыртам. Сине генә җизни дип йөрим. Курыкма, кеше югында гына шулай дип әйтермен. Әй, Хәнҗәр абый, вакыт күпме әле? (*Беләген селкегән була.*) Минеке туктаган.

Х ә н җ ә р. Сигез тула.

Р ә җ ә п. Соңга калам. Син, Хәнҗәр абый, бу әйберләрне саклап тор, бер апаныкы. Кызык апа! Мине бөтенләй белми, әйберләрен калдырды да йөгерде.

Х ә н җ ә р. Кая йөгерде?

Р ә җ ә п. Ибраһим абый янына.

Х ә н җ ә р. Кайсы Ибраһим?

Р ә җ ә п. Теге... Сәхи абыйларның начальнигы... Хәнҗәр абый, монда тәртип сакла, иң олы начальник булып син каласың.

Чыгып йөгерә, Хәнҗәр ялгызы. Кабаланып Г а н д ә л и ф кайтып керә.

Г а н д ә л и ф. Син? Тагын син?

Х ә н җ ә р. Күргәнеңчә.

Г а н д ә л и ф. Малай кайда?

Х ә н җ ә р. Кайтып китте. Дәрескә соңга кала.

Г а н д ә л и ф. Берәр сүз әйтмәдеме?

Х ә н җ ә р. Әйберләреңне миңа ышанып калдырды.

Г а н д ә л и ф. Мине сораучы булмадымы икән?

Х ә н җ ә р. Әйтмәде. Мин барында сораучы күренмәде. (*Пауза.*)

Г а н д ә л и ф. Ясыйр абый мондамы?

Х ә н җ ә р. Күрмәдем.

Г а н д ә л и ф. Тагын нигә кердең инде монда?

Х ә н җ ә р. Хан кызын көн яктысында күрәсем килде.

Г а н д ә л и ф. Нинди хан кызы?

Х ә н җ ә р. Ханы нинди булгандыр. Әйтә алмыйм, ә кызы күз алдында басып тора.

Г а н д ә л и ф. Кара алайса, бик күрәсең килгәч... Тик сора: минем сине күрәсем килә микән?

Х ә н җ ә р. Килмәсә, чакырып китерербез.

Г а н д ә л и ф (*әрнеп*). Күрәсем килми, килми... Берегезне дә күрәсем килми... Ишетәсеңме?

Х ә н җ ә р. Күрәсен килмәгәч, нигә Ибраһим янына йөгердең?

Г а н д ә л и ф (*бик нык ачуланып*). Анда синең ни эшең бар?

Х ә н җ ә р. Шулай да...

Г а н д ә л и ф. Кирәк иде, шуңа йөгердем.

Х ә н җ ә р. Туктале, сине белә бит ул, әллә берәр та-

нышыңмы? Әйе, кичә сөйләп торды... Бер дә мактамады ул сине. Кем-кем, әмма Ибраһим кызларның бәясен белә инде. Дөнья күргән егет!

Гандәлиф. Кайда күрдең син Ибраһимны кичә?

Хәнҗәр. Шушында. Вокзал янында.

Гандәлиф. Кайчан?

Хәнҗәр. Күрдем инде. Поезд киткәндә монда иде. Төнлә дә...

Гандәлиф. Ялганлыйсың син, ялганлыйсың. Әгәр Ибраһим монда булган булса, син минем янга керергә кыймас идең. Мин ялгыз, яклаучысыз булганга батырайдың син кичә.

Хәнҗәр. Менә кеше, тезә адәм ышанмаслык сүзләрне.

Гандәлиф. Әгәр ул сине күргән булса, кирәгеңне биргән булыр иде. Синең күк елтыр күзле малайларны чәнчә бармагы белән генә чөя.

Хәнҗәр. Яле, яле, тагын сиптер.

Гандәлиф. Мактамады, имеш. Очраган бер азгантузган малайга мактап, хурлап йөрер инде. Ул андый ачык авыз түгел.

Хәнҗәр. Каян беләсең син Ибраһимны?

Гандәлиф. Үз иремнеме?

Хәнҗәр. Ха-ха-ха-ха...

Гандәлиф (*кимсенеп*). Авыз ерасы юк.

Хәнҗәр. Соң мин синең ирең хакында сөйләмим бит, мин әйткән Ибраһим бөтенләй башка кеше. Безнең төзелештә начальник.

Гандәлиф. Бик олы начальниктыр инде, минем Ибраһимым аннан биш битәр начальник.

Хәнҗәр. Безнең начальник өйләнмәгән егет.

Гандәлиф. Өйләнмәсә өйләнер.

Хәнҗәр. Монда Ибраһим исемле начальник бер генә. Ибраһим Минхәерович. Белдеңме? Ирем, ирем! Тәтегән сиңа!

Гандәлиф. Шул Ибраһим Минхәерович бит инде минем ирем...

Хәнҗәр. Ирең? Синең иреңме?

Гандәлиф. Ирем инде, ирем! Мин шуның янына кайттым бит.

Хәнҗәр. Ә нигә монда утырасың?

Гандәлиф. Син сорамас микән дип...

Хәнҗәр (*ул чын-чынлап кызыксына башлады*). Шаярмыйча, нигә монда утырасың син?

Гандәлиф. Аны көтәм. Ул килергә тиеш. Аннары безнең авылга китәбез.

Хәнҗәр. Нигә килми соң ул?

Гандәлиф. Эше күптер.

Хәнҗәр. Беләсезме...

Гандәлиф. Нигә телеңне тешләдең? Әйтер сүзләрең тамагыңа утырдымы? Ирем шул! Сөйгән кешем, турылык белән исемен йөрәгемдә йөрткән кешем.

Хәнҗәр. Сөйгән кешең?

Гандәлиф. Әйе, яшәргә дәрт, көч, бәхет биргән кешем... Әй, нигә боларны сиңа сөйләп торам соң. Син андый кешеләрнең, андый гаиләнең булуына ышанмыйсың да инде. Бәхетсез кеше син, ялганчы!

Хәнҗәр. Шулай да нигә килми ул?

Гандәлиф. Килер. Мөмкинлеге булса көттермәс иде. Әллә кайчан килер иде. Синең кебек әрсез алабайлардан күптән аралар иде... Юатыр иде...

Хәнҗәр. Гафу итегез, мин аны кичә монда күрдем.

Гандәлиф. Би-ик! Бик ышандым ди мин сиңа. Берәр әшәке уй ниятлисеңме?

Хәнҗәр. Минем беркемне дә алдаганым юк.

Гандәлиф. Һа, юк, имеш.

Хәнҗәр. Юк, алдаганым юк... Ләкин алдаучыларны күргәнем бар.

Гандәлиф. Ибраһимның исемен ишеткәч тә калтырап төштеңме? Шул кирәк сиңа.

Хәнҗәр. Әйе... калтырадым мин... Калтырадым. (*Чыгып йөгерә.*)

Гандәлиф. Кулымдагы йөзегемә
Ибраһим дип уелган.
Гаҗәп икән бер яраткач,
Һич чыкмыйсың уемнан.

Пәрдә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Төзелеш мәйданы. Күтәрү краны. Якында гына төп корпусның нигезе салынган. Дәү-дәү арматура чытырманлыклары. Ул якта сварщиклар эшли, ахры, утлы күбәләкләр атылган төсле шәүләләр уйный. Иртә булса да бар җирдә дә эш кайный. Үтеп-сүтеп эшчеләр йөри. Автомашиналар гөрли. Шау-шу. Дибәҗә керә. Кемнедер эзли.
Ибраһимны күрә.

Дибәҗә. Ибраһим абый!

Ибраһим. Әү, матурым!

Дибәҗә. Матурым дип эндәшмәгез миңа.

Ибраһим. Һәрнәрсәне үз исеме белән атау яхшы.

Дибәҗә. Мин нәрсә түгел, кеше. Бу бер. Икенчедән, кичә Хәнҗәр абыйны минем күңелне табар өчен генә безнең участокка чакырдыгызмы сез?

И б р а һ и м. Юк, матурым. Әй, юк, матурым түгел.

Д и б ә җ ә. Ул эшкә чыкмаган.

И б р а һ и м. Элекке урынына киткәндер.

Д и б ә җ ә. Белештем, анда да юк.

И б р а һ и м. Соңга калгандыр.

Д и б ә җ ә. Моряк кеше соңга калмый.

И б р а һ и м. Белешмәләрне шактый җыйгансың син.

Д и б ә җ ә. Сорарга ярамыймы әллә?

И б р а һ и м. Син сорамыйсың, борчыласың.

Д и б ә җ ә. Борчылам, чирләп-фәлән ятмасын, дим. Кичәге сөйләшүгә ышанып мин аны табельгә дә язып куйдым.

И б р а һ и м. Дөрес иткәнсең. Мин чакыргач килмиме соң ул? Моряклар да соңга калгалыйлар кайчак.

Д и б ә җ ә. Ә сез бүген нигәдер бик иртәләгәнсез. (*Мутланып.*) Вокзал янындагы әрәмәдә кемне көтә идегез, Ибраһим абый?

И б р а һ и м. Сине, Дибәҗә.

Д и б ә җ ә. Алайса, нигә мине күргәч тә качарга маташтыгыз? Юлда килгәндә дә әле артыгызга, әле як-ягыгызга борыласыз?

И б р а һ и м. Син миңа карата шундый игътибарлы дип уйламый идем мин, Дибәҗә...

Д и б ә җ ә. Шулай да... Нигә як-ягыгызга каранып, сагаеп бардыгыз сез?

И б р а һ и м. Сагаеп түгел, масаеп... Синдәй чибәр кыз белән рәттән баруымны күрәләр микән дип карандым мин...

Д и б ә җ ә. Бик чибәрмени мин?

И б р а һ и м. Минем өчен синнән дә чибәррәк беркем дә юк.

Д и б ә җ ә. Бик, бик чибәр, алайса.

И б р а һ и м. Искиткеч! Хисләрне актарып чыгара торган, күңелне тезгененнән ычкындыра торган чибәр...

Д и б ә җ ә. Тик минем дустым бар бит инде.

И б р а һ и м. Кем?

Д и б ә җ ә. Үзегез беләсез бит.

И б р а һ и м. Сәхиме? Йа Аллам! Кыз беткәнме аңа? Табар әле үз ишен.

Д и б ә җ ә. Әгәр ул мине сөйсә?

И б р а һ и м. Шундый ук зур теләк белән башкаларны да сөя алыр дип ышанам.

Д и б ә җ ә. Менә бусы яңалык! Хис белән түгел, теләк белән. Димәк, сезнең берәүне сөеп икенчегә күчкәнегез дә бар.

И б р а һ и м. Миңа бәхет бирерлек бөтен сыйфатларны туплаган кызлар күптер дип уйламыйм мин, Дибәҗә.

Моңа кадәр андый кыз очрамады, йөрәгемә хуҗа булырлык беренче кеше син...

Д и б ә җ ә. О-о!

С ә х и керә.

О! Сәхи, яхшылабрак кара әле, алдыңда кем басып тора.

С ә х и. Син, Дибәҗә!

Д и б ә җ ә. Белдең! Дөньяда иң чибәр кыз басып тора синең алдыңда.

С ә х и. Кем әйтә?

Д и б ә җ ә. Карагызчы моны, кем әйтә дип тора бит.

И б р а һ и м. Сәхи яшь әле, аңлап бетерми торгандыр.

С ә х и. Мин, Дибәҗә, кызларның матурлык дәрәҗәсен билгеләп, бусы чибәр, тегесе сылу дип сортларга аерып йөрмим.

Д и б ә җ ә. Кайчагында йөрергә дә кирәк икән. Иеме, Ибраһим абый?

И б р а һ и м. Дибәҗә, этиең күренмәдеме?

Д и б ә җ ә. Районнан кайткан, күзгә күренгәне юк.

И б р а һ и м. Күренсә, мин аны эзли диярсең. (*Чыга.*)

Д и б ә җ ә. Йә, нәрсә дип килдең инде, кичкә кадәр өйдә утырам дигән идең бит?

С ә х и. Санаулы көннәр калды ич... Күңел тыныч түгел...

Д и б ә җ ә. Нигә тыныч түгел ул, Сәхи?

С ә х и. Күз алдында булып узган хәлләр тынычсызлый. Беләсең бит Хәнҗәр абыйларны... Эльвира...

Д и б ә җ ә. Син миңа ышанмыйсыңмы?

С ә х и. Ышанам. Тик менә... кичә дә Ибраһим абый белән. Бүген дә. Элек тә ничә карасаң син аның янында бөтереләсең.

Д и б ә җ ә. Шулаймыни?!

С ә х и. Менә шуларны уйлап утырдым да түзмәдем, килдем.

Д и б ә җ ә. Эти килә.

С ә х и. Бәлки, Мәкәрим абый белән сөйләшеп карарга кирәктер.

Д и б ә җ ә. Ул хакта авызыңны да ачасы булма.

М ә к ә р и м күренә, Дибәҗә аңа каршы китә.

Монда кил, эти!

С ә х и. Исәнмесез, Мәкәрим абый.

М ә к ә р и м. Сәхи, исәнме, нишләп сез берегез дә эш урынында түгел? Ибраһим үзе дә күренми.

С ә х и. Без армиягә китәбез.

М ә к ә р и м. Котлыйм, мә тот бишне, ир кеше булып, дөнья күреп кайтырсыз.

Д и б ә җ ә. Әти, кайчаннан бирле яныңда басып торам. Теләгән әйберләреңне алып кайттым дип сөендерер идең.

М ә к ә р и м. Алып кайттым, кызым, алып кайттым.

Д и б ә җ ә (*үбеп ала*). Әйбәт әти, тәти әти!

М ә к ә р и м (*көлеп*). Эшчеләр арасында интим мөнәсәбәтләрне күрсәтмәскә дип сүз куешкан идекме?

Д и б ә җ ә. Сәхи эшче түгел инде, ул солдат.

С ә х и. Мин сезне күрергә дип тә килгән идем, Мәкәрим абый.

Д и б ә җ ә. Сәхи! (*Аңа ымлап.*) Сөйлисе булма.

С ә х и. Алай димә әле син!

Д и б ә җ ә. Сәхи, син бүгеннән солдат, мин сиңа сугышчан боерык бирәм. Смирно! Кругом марш!

С ә х и. Буйсынырга туры килә бит, Мәкәрим абый! Тыңлыйм, иптәш лейтенант!

Д и б ә җ ә. Фи-и, лейтенант кынамыни?

С ә х и. Иптәш генерал-лейтенант! (*Чыга.*)

Д и б ә җ ә. Менә шулай.

М ә к ә р и м. Бу генерал кулына эләксәң, күрсәтә икән күрешеңне!

Д и б ә җ ә. Кызыңны хурлама, кияүгә алмаслар!

М ә к ә р и м. Алмасалар, үз сөягебез үзебезгә. Артык кызыбыз юк. (*Китә башлый.*)

Д и б ә җ ә. Әти, ә китаплар?

М ә к ә р и м. Мин аларны өйгә кертеп калдырдым, кызым. Әниең шаккатты... Мин дә аптырап киттем. Син биргән исемлекне карасам, бар да югары мәктәп дәреслекләре. Нигә кирәк булды алар?

Д и б ә җ ә. Әти, минем генерал буласым килә.

М ә к ә р и м. Генерал укмыни?

Д и б ә җ ә. Төзелеш генералы. Башка эшкә күчәсем килә. Укырга керәсем килә.

М ә к ә р и м. Мин әйткәндә тыңламаган идең. Фикереңүзгәрүе миңа бик ошый. Тик сәбәбе генә...

И б р а һ и м күренә.

Д и б ә җ ә. Әнә мең яшәр әле сезнең кадерле Ибраһимыгыз. Үзе килә.

М ә к ә р и м. Нишли ул җүләр? Балка аша чыкмакчы буламы?

Д и б ә җ ә. Менә батыр! (*Кул чаба.*)

Ибраһим, юл туры булсын дип, төп корпусның нигезе аша салынган балка аша гына чыкмакчы була. Ярты юлда башы әйләнеп күзен каплап туктап кала.

М ә к ә р и м. Аска карама! Аска карама! Кыюрак!
Д и б ә җ ә. Менә бу егетләрчә!
М ә к ә р и м. Егыла инде!
Д и б ә җ ә. Ай!
М ә к ә р и м. Үрмәләп чык булмаса!

Ибраһим, үрмәләп, ап-ак агарынып килеп чыга.

И б р а һ и м. Эшчеләр карап тормадымы?
Д и б ә җ ә. Бу кәмитне карамыйча! Егет икәнсең, Ибраһим абый! Ха-ха-ха! (*Чыгып китә.*)
И б р а һ и м. Башка вакытта рәхәтләнеп чыгып йөри идем. Бүген аягым калтырый, йөрәгем дөп-дөп тибә... Бер-ике көн ял итеп аласы иде!
М ә к ә р и м. Артыгын чабасың син.
И б р а һ и м. Шунсыз булмый бит, Мәкәрим абый.
М ә к ә р и м. Азрак кешеләргә дә ышанырга кирәк.
И б р а һ и м. Ышанырсың! Хәтерегездә бит, Гөлҗиһан Мәликова бригадасын бетонга куеп китеп, иртән килүгә нишләгәннәр иде.
М ә к ә р и м. Хәзер алар эшкә өйрәнделәр.
И б р а һ и м. Күзәтүче булмаганда барыбер, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче дип эшлиләр инде.
М ә к ә р и м. Торба салучылар бригадасын башка эшкә күчердеңме әллә?
И б р а һ и м. Шулар артыннан чабам. Дүрт егетемне армиягә алалар. Бригада оешып килә дигәндә генә.
М ә к ә р и м. Мәликова бригадасын шунда күчер.
И б р а һ и м. Якын да китермим! Менә дигән егетләр таптым.
М ә к ә р и м. Мәликова нигә ярамый?
И б р а һ и м. Хатын-кыз белән эшли алмыйм мин, Мәкәрим абый!
М ә к ә р и м. Нигә?
И б р а һ и м. Ирләр белән эшләүгә ни җитә.
М ә к ә р и м. Хәзер иң мөһиме торба салуны җайга салырга кирәк. Мәликова бригадасы хакында уйла. Әйбәт ташчылар анда хәзер. Үз каланчаңнан карап кына фикер йөртмә. Яхшы эшчеләрне җаваплырак урынга куй.
И б р а һ и м. Яхшы, барсын да башкарып чыгармын. (*Чыга.*)

Алар сөйләшкән арада Я с ы й р керә. Ибраһимның Мәкәрим белән сөйләшүен күреп якынаерга кыймый. Кулын изәп Ибраһимны чакыра. Ибраһим аңа читкә китәргә ымлый. Мәкәрим күздән югалгач кына аны чакыра.

И б р а һ и м. Кил монда! Йә, тизрәк бул.

Я с ы й р. Тиз булмый, ашыктырма син, Ибраһим, сулышым капты.

И б р а һ и м. Сөйләштеңме, китәме?

Я с ы й р. Китми.

И б р а һ и м. Нишли?

Я с ы й р. Утыра.

И б р а һ и м. Берәр сүз әйтәме?

Я с ы й р. Ул килергә тиеш, ди.

И б р а һ и м. Сөйләшмәдең бит син, кичә тәрәзәдән күреп тордым. Бүлмәңә кердең дә бикләндең!

Я с ы й р. Бүген сөйләштем... Иртән.

И б р а һ и м. Гомер эчендә бер йомыш куштым, шуны да үти алмадың.

Я с ы й р. Җанлы кеше бит!

И б р а һ и м. Ә мин җанлы түгелме? Бер салган камытны муенга кияргә.

Я с ы й р. Сөя бит ул сине, Ибраһим, сөя! Җаны-тәне белән сөя!

И б р а һ и м. Сөя? Ха-ха-ха! Син шул сүзне әйтәсеңме? Син?!

Я с ы й р. Нигә әйтмәскә?

И б р а һ и м (*ярсып*). Сазаган карт буйдак! Син дә шул сүзне әйткәч...

Я с ы й р. Минем кай җирем кешедән ким?

И б р а һ и м. Акылың ким, акылың! Әгәр акыл дигән нәрсәң булса, син гомереңне патефон гыжлатучы карт исәр булып үткәрмәс идең.

Я с ы й р. Ибраһим!

И б р а һ и м. Син хатын-кызны аңларлык кеше булсаң, вокзал идәнен себерүче дивана булып калмас идең.

Я с ы й р. Ибраһим... Син үтер мине, тик бу сүзләрне әйтмә...

И б р а һ и м. Сөя... Ярты ел тик кенә йөргәндер дисеңме аны. Ай-һай, Ибраһимым бар дип, сагынып торгандыр дисеңме?

Я с ы й р. Сөйгәч сагыныр да, көтәр дә...

И б р а һ и м. Малай-шалайлар мин барында ук аңа күз аталар иде инде! Ә мин киткәч... Ялгызы бер бүлмәдә. Күпме юллар ялгызы кайткан.

Я с ы й р. Андый бала түгел ул!

И б р а һ и м. Андый түгелме? Ә кичә, кичә... берни дә булмадымы анда?

Я с ы й р. Берни дә булмады. (*Пауза.*)

И б р а һ и м (*өметсез*). Нишләргә?

Я с ы й р. Берәр кызга күзең төштеме әллә?

И б р а һ и м. Күзем, күзем... Монда шундый автори-

тет казанганда гына... Алты айда иң җаваплы участокка инженер итеп куйдылар. Югарырак күтәрелергә мөмкинлекләр бар, юл ачык. Шунда минем өстемә бәла кайтып төшә. Җитмәсә кем әле? Йомыкый гына бер штукатур... Урам кызы....

Ясыйр. Шигемне генә әйттем. Син аны яхшырак беләсең...

Ибраһим. Сукыр килеш күзлене җитәкләмәкче буласың син, абый. Булмады синнән. Гомереңдә бер эшне ахырынача очлап чыга алмадың. Пешмәгән син, абый.

Ясыйр. Мин шулай, мин шулай...

Ибраһим. Башыңны исәрлеккә салма! Ичмасам, син миңа комачаулама. Үзем озатам мин аны. Ишетсен колагың! (*Чыгып китә.*)

Ясыйр. Ишетсен колагың... Ишетмәсә иде ул бу сүзләрне! Күзләрем күрмәсә иде шушы хәлләрне! Нигә мин саңгырау, сукыр булып тумадым икән?

Мәкәрим керә.

Мәкәрим. Ясыйр, исәнме, кордаш! Нинди җилләр сине монда ташлады?

Ясыйр. Ә-ә? Әшәке җилләр? Көзге ачы җилләр... Ишетәсеңме, әллә кая кран башына кунып нечкә генә бер җил җылый...

Мәкәрим. Көзге ачы җилләр... Кайчандыр шул җилләрдә адашып син авылны ташлап киткән идең... Тик ул җилләр сине бәхетле дә иттеләр түгелме? Ялгышмасам шул җилләр сине туган илеңә алып кайттылар. Туганнарың, кадерле энең белән кавыштырдылар...

Ясыйр. Кичә шулай иде... Бүген шул җилләр күкрәгемнән җегәремне, беләгемнән көчемне, күңелемнән бәхетне урлап киттеләр...

Мәкәрим. Нәрсә булды, кордаш, ни булды?

Ясыйр. Ә? Берни дә юк, булырга тиешлесе генә...

Мәкәрим. Сөйлисең килми инде, алайса?

Ясыйр. Сөйләрлек сүз юк.

Мәкәрим. Адашып йөреп туймадыңмыни әле син, кордаш? Нигә бездән читләшәсең син? Үз итмисең?..

Ясыйр. Сез әнә кемнәр булып киттегез... Син, Мәкәрим, шушы зур төзелештә баш инженерның урынбасары...

Мәкәрим. Ә син, син?

Ясыйр. Мин һаман шул инде... Исәр, дивана, хыялый.

Мәкәрим. Шул түгел! Син дә, мин дә — барыбыз да бер зур эш эшлибез. Тиңнәр без, тиңдәшләр без. Шулай булгач, нигә синә безнең арада ачык күңел белән

йөрмәскә? Читләшәсең... Өемә ничә чакырдым... Бертуганнар кебек чөкердәшеп чәй эчәр, сөйләшер идек.

Ясыйр. Рәхмәт, кордаш, яхшы сүзеңә. Бәлки, килеп тә чыгармын әле... (*Чыга.*)

Мәкәрим бераз ялгыз. Дибәҗә керә.

Дибәҗә. Әти, эш кирегә китте бит.

Мәкәрим. Шуңа борының салындымы?

Дибәҗә. Мине төп корпуска күчерү хакында Ибраһим абый белән син дә сөйләшеп кара әле.

Мәкәрим. Әтиеңә аркаланма.

Дибәҗә. Ул мине тыңламый.

Мәкәрим. Сөйләштеңме соң?

Дибәҗә. Әһә!

Мәкәрим. Нәрсә ди?

Дибәҗә. Балчык, таш арасында йөрү синең эш түгел, ди.

Мәкәрим. Син ничегрәк җавап бирдең инде аңа?

Дибәҗә. Киттем дә бардым!

Мәкәрим. Шәп иткәнсең.

Дибәҗә. Кешемени ул Ибраһим абый.

Мәкәрим. Тукта, тукта, нигә алай дисең әле син? Бая да сүзеңне әйтеп бетермәдең. Нигә болай фикерләрең үзгәрде әле?

Дибәҗә. Әти, без синең белән дуслар бит, әйеме?

Мәкәрим. Әйе, кызым.

Дибәҗә. Син миңа мәхәббәткә начар караган кешенең яхшы кеше булуына ышанма дигән идең.

Мәкәрим. Әйткән идем, ләкин бүгенге көнгә боларның ни катнашы бар соң?

Дибәҗә. Шундый кешенең берсен мин бүген үзем очраттым кебек.

Мәкәрим. Кем ул?

Дибәҗә. Менә бүген Ибраһим абый белән мәхәббәт турында сөйләштек тә миңа куркыныч булып китте.

Мәкәрим. Куркыныч булып китте дә син этиеңнең аркасына ышыкланырга булдыңмы?

Дибәҗә. Нишлим соң?

Мәкәрим. Куркыныч күрсәң чигенмә, күзенә туры карап, туп-туры каршысына атла. Шикне ачыкла.

Дибәҗә. Туп-туры карап бар дисең, алайса?

Мәкәрим. Әйе, генерал булу өчен барын да үзең ерып бар.

Дибәҗә. Есть, үзем ерып барам, әти.

Мәкәрим уйланып кына икенче якка бара башлый. Сәхи кычкырып аны туктата.

Сәхи. Мәкәрим абый!

Мәкәрим. Нәрсә, Сәхи?

Сәхи. Мәкәрим абый, без тиздән китәбез.

Мәкәрим. Шуңа пошынасыңмы әллә?

Сәхи. Юк, Мәкәрим абый.

Мәкәрим. Солдат шулпасы ашамаган ир ир түгел ул, Сәхи.

Сәхи. Мәкәрим абый, безгә Дибәҗә белән язылышырга рөхсәт бирегез инде.

Мәкәрим. Тукта, тукта, ничек дидең?

Сәхи. Язылышырга...

Мәкәрим. Соң, туганкай, бездә ике ел эшлисең, моңарчы авызыңа су кабып йөрдең дә бүген батыраеп киттең! Ни булды?

Сәхи. Дибәҗә әйткәндәй, әле генә эшче идек бит... Бүген солдат.

Мәкәрим. Һәм син барган шәпкә һөҗүмгә кучмәкче булдыңмы?

Сәхи. Разведка ясау гына...

Мәкәрим. Разведка алдыннан максатын аңлаталар иде.

Сәхи. Болай гына калдырып китә алмыйм, күңел тыныч түгел.

Мәкәрим. Нигә әле син япь-яшь башыңнан күңел тынычлыгы эзлисең?

Сәхи. Күз алдында төрле хәлләр булып алды бит, Мәкәрим абый.

Мәкәрим. Инде, туганкай, мәхәббәтеңне төрле хәлләр белән үлчәргә калгач, язылышырга йөрмә син.

Сәхи. Яратам бит мин аны, Мәкәрим абый.

Мәкәрим. Шәп егет, кызын яратуы хакында этисенә килеп сөйли.

Сәхи. Дибәҗә күптән белә.

Мәкәрим. Ә ул нәрсә ди?

Сәхи. Дәшми... Көлә, шаяра, уенга ала...

Мәкәрим. Шулай булгач, син шатлан гына инде, Сәхи энекәем.

Сәхи. Димәк, сез...

Мәкәрим. Җылап, саклап йөргән кешеләрне яратмыйм мин! Дибәҗә дә яратыр дип уйламыйм. Шикләнүләр, ышанмаулар яхшыга алып бармыйлар.

Рафаил белән Нури керәләр. Мәкәримне күреп ерактан ук кычкыралар.

Нури. Мәкәрим абый, китәбез!

Рафаил. Саубуллашырга кердек.

М ә к ә р и м. Сынатмагыз, безне шәп саклагыз. Иң мөһиме күңелегез көр булсын. Олы юлга, җаваплы юлга чыкканда күңел көр дә, керсез дә булсын ул. Алдыгызда дошман, як-ягыгызда дошман булса да, без барын, ил барын, дусларыгыз барын онытмагыз. (*Чыга.*)

С ә х и. Ишеттегезме, миңа төрттерде.

Р а ф а и л. Риза түгелме?

С ә х и. Риза! Шундый бөтереп алды, чыдап кына тор! Сез дә шул... Вакытсыз килеп комачаулап йөрисез.

Р а ф а и л. Тәгәрәп китим, сиңа да ярап булмый башлады.

Н у р и. Чәчрәп китим, алай ошамасак китәбез.

Р а ф а и л. Тәгәрәдек, Нури! (*Чыгалар.*)

Х ә н җ ә р керә.

Х ә н җ ә р. Нури, Рафаил, килегез әле!

Е г е т л ә р керәләр.

Беләсезме, мин нәрсә күрдем.

Р а ф а и л. Нәрсә, Хәнҗәр абый?

Х ә н җ ә р. Мин, егетләр, мәхәббәт күрдем. Дибәҗә! (*Кулын изи.*) Таптым мин аны... Адашып кына барып кергән идем... Чәчәк атып утыра. Көзге җилләр аны безнең якларга китергән. Аңа салкын, ялгыз ул, тик һаман да чәчәктә.

С ә х и. Ни сөйлисең син, Хәнҗәр абый?

Х ә н җ ә р. Күңелемә шик килә башлаган иде бит, егетләр! Бар микән ул мәхәббәт дип уйлап куя идем. Авыр бит андый шик белән яшәү. Көннәрне төнгә ялгавы авыр... Мәхәббәт булганда гына тормыш бөтен, түгәрәк бит.

Р а ф а и л. Син бераз нитмәгәнсеңдер бит, Хәнҗәр абый?

Х ә н җ ә р. Һәм шул мәхәббәтне адаштырырга җыеналар.

С ә х и. Ачыклабрак сөйлә әле, Хәнҗәр абый, табышмакның җавабы табылса гына кызык бит ул.

Х ә н җ ә р. Әйе, адаштырырга маташалар.

Д и б ә җ ә керә.

Д и б ә җ ә. Хәнҗәр абый, син нигә эшкә соңга калдың?

Н у р и. Авызы белән кош тоткан ла ул.

Х ә н җ ә р. Ачуланма, Дибәҗә, мин эшне эшләрмен. Бирегез генә хәзер миңа эшне. Мин, Дибәҗә, мәхәббәтне таптым.

Д и б ә җ ә. Кайда таптың?

Х ә н җ ә р. Вокзалда.

Н у р и (*көлеп*). Нишләгән була ул анда?

Х ә н җ ә р. Мәхәббәт нишләсен? Көтә, дулкынлана, сагына, кайгыра, дөрләп яна.

С ә х и. Ә кем аны адаштырырга маташа?

Х ә н җ ә р. Ибраһим.

Н у р и. Безнең Ибраһим абыймы?

Х ә н җ ә р. Әйе. Безнең Ибраһим өйләнгән кеше икән.

Н у р и. Юк сүз, чыбыксыз телефон тарата, гайбәт.

Х ә н җ ә р. Үзем күрдем.

С ә х и. Вокзалда күрдеңме?

Д и б ә җ ә. Шуннан, Хәнҗәр абый?

Х ә н җ ә р. Шуннан, сез кирәк миңа, егетләр!.. Әйбәт, турылыклы кыз булырга тиеш. Сөя белә торган кыз. Ә ул аннан... мәхәббәттән көләргә маташа. Мин дә чак кына аның кармагына эләкмәдем.

Н у р и. Шушы бетон балканы тешең белән кимереп бетерсәң дә, Ибраһим абыйның өйләнгән булуына ышанмыйм. Белмибезме әллә, егет кеше. Мәхәббәт хакында ул шундый сөйли иде...

Р а ф а и л. Хатыны булса нигә вокзалда утыртсын, Ибраһим абыйның менә дигән квартирасы бар.

Д и б ә җ ә. Ашыкмагыз әле, малайлар, Хәнҗәр абый сөйләсен.

С ә х и. Әгәр чыннан да өйләнгән булса...

Х ә н җ ә р. Мәхәббәттән көләргә, аны таптарга ирек бирмәскә кирәк. Адаштырмасын ул аны.

Н у р и. Юк, мин бу сүзгә ышанмыйм да, бу эшкә катышмыйм да!

Х ә н җ ә р. Катышмыйсың?

Н у р и. Катышмыйм.

Х ә н җ ә р. Бүген, иртәгә солдат буласы кеше! Терсәкне терсәккә куеп давыллар җиңәсе, диңгезләр кичәсе егет!

Р а ф а и л. Әйдәгез, Ибраһим абыйны эзләп табабыз.

Х ә н җ ә р. Ибраһимны тапсак та, тапмасак та вокзалга барыйк! Бәлагә юлыккан кешене ялгыз калдырырга ярамый. Мәхәббәттә бәлагә юлыккан кешене бигрәк тә! (*Чыгалар.*)

П ә р д ә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вокзал. Болытлы сүрән төн. Г а н д ә л и ф тәрәзә янында. Ул моңлы, озын көйгә җырлый. Кинәт җырны өзеп туктап кала. Әйе, әйе, ул килә! И б р а һ и м керә.

Г а н д ә л и ф. Кулымдагы йөзегемә
Ибраһим дип уелган...

И б р а һ и м. Гандәлиф!

Г а н д ә л и ф. Ибраһим!.. Килеп җиттеңме?.. Ибраһим...

И б р а һ и м. Кичә килә алмадым... Өлгереп булмады... Төнлә икенче сменада... Салкыннар башланганчы нулевой отметканы тәмамларга кирәк.

Г а н д ә л и ф. Салкыннар? Әйе шул, көн суык... Салкын җилләр исә...

И б р а һ и м. Әйдә, әйберләреңне ал да киттек, машина көтеп тора.

Г а н д ә л и ф. Хәзер. (*Әйберләрен җыештыра.*)

И б р а һ и м. Тизрәк бул инде.

Г а н д ә л и ф. Кая барабыз алай ашыгып.

И б р а һ и м. Юлда сөйләшербез.

Г а н д ә л и ф. Монда да сөйләшергә була ич. Күнегелгән, кадерле урын. Түшәмдәге әнә теге тапларга карап та мин сине сагындым.

И б р а һ и м (*ачуы чыгып, мыскылланып*). Гандәлиф, ташла инде шул тозсыз сүзләреңне!

Г а н д ә л и ф. Кызма, нигә кызасың? Мин кызасы урында син кызасың?! Син мине алырга килдеңме?

И б р а һ и м. Мин сине аэропортка илтәм.

Г а н д ә л и ф (*ярсып, хис белән*). Нигә?!

И б р а һ и м. Самолетка өлгерергә кирәк.

Г а н д ә л и ф. Нигә ул самолет? Безне өй туена чакырдылар бит. Безне анда көтәләр, Ибраһим.

И б р а һ и м. Сиңа моннан китәргә кирәк.

Г а н д ә л и ф. Ә син?

И б р а һ и м. Мин биредә калам.

Г а н д ә л и ф. Шаяртма инде, Ибраһим. Елмай инде бер.

И б р а һ и м. Безгә бергә торырга ярамый, Гандәлиф.

Г а н д ә л и ф. Нигә, нигә?

И б р а һ и м. Безнең юллар башка икән, бөтенләй башка. Мин сине сөймим икән, Гандәлиф.

Г а н д ә л и ф. Нигә син боларны хатта язмадың? Нигә син боларны мин килеп төшкәч тә әйтмәдең?

И б р а һ и м. Ялганлыйсың. Мин яздым, Гандәлиф.

Г а н д ә л и ф. Язмадың.

И б р а һ и м. Кичә дә аңлаттым мин сиңа, Гандәлиф.

Г а н д ә л и ф. Кайчан?

И б р а һ и м. Менә үзең дә күрәсең... Бер-беребезне бөтенләй аңламыйбыз без... Син бик гади, артык гади... Тирән хисләрнең нечкәлеген бөтенләй аңламыйсың. Әгәр аңласаң, уйланыр идең. Гадел дөреслекне үзең үк тапкан булыр идең. Сиңа язган хатымда сөям, сагынам дидемме? Димәдем. Димәк... Ә кичә... ничек күрештек без! Күз карашымның корылыгыннан иң кирәген аңларлык иде бит...

Аннан, киләм, дидем, килмәдем. Киләм дип килмәгәч тә үзенең монда беркадәр артык кеше икәнен аңламаган кеше белән яшәү бик авыр ич. Минем хисләрем катлаулы, омтылышым зур... син барыбер аңламассың аларны.

Гандәлиф. Син... ни сөйлисең син? Син — минем гомеремне кап урталайга бүлгән кеше.

Ак түти керә.

Ак түти. Монда икәнсең әле... Бусы кемең тагы?

Гандәлиф. Сез миңа эндәшәсезме?

Ак түти. Сиңа инде, сиңа!

Гандәлиф. Апа, безнең сөйләшәсе сүзебез бар, аны кичектерергә ярамый.

Ибраһим. Сөйләшәсен сөйләштек бугай.

Гандәлиф. Юк әле.

Ибраһим. Аңлаштык шикелле. Калганнарына барыбер тешең үтеп кермәс.

Гандәлиф. Әйе... зиһенем чуалды. Ничек шулай булырга мөмкин?

Ибраһим. Менә бит! Сөйләп торасы да юк! Кыскасы, мин машинада көтеп торам. Апаны көттермә, сөйләш. Озаклама, Гандәлиф. (*Чыга.*)

Гандәлиф. Озаклама!..

Ак түти. Гандәлиф икәнсең син... Сандугач.

Гандәлиф. Әйе, апа, сандугач...

Ак түти. Әйт әле, чибәр кыз, минем улымны каян беләсең син?

Гандәлиф. Улыгыз? Белмим, апа.

Ак түти. Ничек белмисең?

Гандәлиф. Мин сезне дә белмим.

Ак түти. Белмәгән кешенең яңагына ничек суктың?

Гандәлиф. Сез кичәге апамыни?

Ак түти. Төпчегем ул. Хәнҗәр... Сугыш аның дүрт абыйсын алды. Әтиләре Берлин капкасы төбенә барып җитеп башын салды.

Гандәлиф. Апа, болар бар да миңа нигә кирәк?

Ак түти. Нишләп ятасың син монда? Нигә кунасың? Нигә суктың син минем улыма? Нигә төн буе йокламады ул. Таң белән тагын синең яныңа китте.

Гандәлиф. Нигә минем янга китсен ул?

Ак түти. Синең янга! Синең! Мин барын да сизәм.

Гандәлиф. Апа җаным, калдырыгыз әле мине ялгызымны...

Ак түти. Ә син минем улымны калдыр.

Гандәлиф. Хулиган малаегызның бик хаҗәте бар иде.

Ак тути. Хулиган түгел ул. Анда минем дүрт улымның, иремнең төсе бар. Күзләре олы улым күзләренә охшаган, Рәфкатем төсле көлә, Мидхәтем төсле җырлый, бии ул. Салихымның чалымы, йөреше бар аңарда. Барыннан да бигрәк ул мәрхүм Әнәсемә охшаган. Шул кешегә син ничек суга алдың?

Гандәлиф. Ул мине рәнҗетте, бик рәнҗетте!

Ак тути. Кайда? Кайчан? Ни өчен?

Ясыйр керә.

Гандәлиф. Ясыйр абый, бу апага аңлатыгыз әле, минем бер гаебем дә юк.

Ясыйр. Мин күңелле генә, матур гына яши идем, өметләрем, юанычларым җилдә тузгып, таралып бетте.

Гандәлиф. Абый, минем ни гаебем бар?

Ак тути. Нинди явыз! Улымны, Хәнҗәремне буташтыра башлады.

Гандәлиф. Мин?! Апакаем, абый җаным! Минем үз хәлләрем хәл бит.

Ясыйр. Сезнең кайсыгызга ышанырга?

Хәнҗәр, Сәхи, Дибәҗә, Нури, Рафаил керәләр.

Хәнҗәр. Менә ул! (*Күрсәтә.*) Менә үзе... Карагыз...

Ак тути. Улым, син нишләп йөрисең болай?

Хәнҗәр. Әнкәй? Кирәк булганга йөрим, әнкәй! Егетләр, танышыгыз, Гандәлиф бу...

Гандәлиф. Миннән сезгә нәрсә кирәк? Монда килеп инде сезгә дә зыяным тидеме?

Рафаил. Исәнмесез, Гандәлиф... Сез ипле генә тыңлагыз әле.

Нури. Әйе, тыңлагыз.

Сәхи. Менә Хәнҗәр абый әйткәч ышанмый торабыз.

Гандәлиф. Миннән сезгә ни кирәк?

Хәнҗәр. Белергә кирәк. Ачыкламыйча ярамый, Гандәлиф!

Гандәлиф. Гаилә арасына катышырга сезгә кем кушкан?

Сәхи. Гаилә? Димәк, сез аның хатыны?

Хәнҗәр. Катышырга кирәк, Гандәлиф. Болай гына калдырырга ярамый. Без катышмыйча, аңа кем катышсын.

Нури. Хәнҗәр абый, борчымыйк инде. Күрәсең бит, үзләре генә аңлашырлар әле.

Дибәҗә. Син, Нури, алай димә.

Хәнҗәр. Дөрес, Дибәҗә.

Гандәлиф. Дөресләми генә тор, сезнең эшегез юк монда!

Ак түти. Ясыйр, әйт әле, зинһар, син берәр нәрсә аңлыйсыңмы, юкмы?

Ясыйр. Аңлыйм да, аңламыйм да!

Сәхи. Нәрсәсен аңлыйсың инде, бар да ачык. Менә нинди кеше икән ул!

Ак түти. Кем?

Ибраһим керә.

Ибраһим. Гандәлиф! (*Кешеләрне күреп.*) Уһу, монда мин генә юк икән, саулармысыз!

Хәнҗәр. Кемнең кем икәнен ачыклыйбыз инде менә хәзер.

Рафаил. Үзе әйтеп бирсен, чыннан да.

Нури. Әйтсен, әйтсен.

Ибраһим. Сез нәрсә, бәбкә саклаучы ата казлар кебек...

Хәнҗәр. Әйт әле, каршыңда басып торган кем ул?

Ибраһим. Беләсең киләме?

Хәнҗәр. Килә.

Рафаил. Әйтегез инде, Ибраһим абый!

Нури. Әйе, кем ул?

Гандәлиф. Нигә эндәшмисең, Ибраһим? Нигә әйтмисең?

Ибраһим. Бу кыз... Гандәлиф. Без бергә читтә булдык. Бергә эшләдек... Дуслаштык та шикелле, якташлар бит. Һәм... башкасы кызык та түгел инде аның. Сезнең өчен кирәге дә юк!

Хәнҗәр. Юк, Ибраһим, бу дөньяда безгә кирәк булмаган бер генә эш тә юк. Синең каршыңда кеше басып тора! Без дә кешеләр, безгә барына да катнашырга кирәк. Шулаймы, егетләр?

Сәхи. Шулай, Хәнҗәр абый!

Гандәлиф. Нигә туктадың, Ибраһим?

Ибраһим. Ну, без бераз гына бергә тордык, алты айлар чамасы шикелле....

Гандәлиф. Алты ай да унике көн.

Ибраһим. Ул анда калды, мин монда кайттым... Ул ни сәбәптәндер монда кайтып гауга күтәрә. Күрәсез бит, сезне кузгаткан, абыйны җибәргән... Үзара гына хәл итә алмас идекме?

Гандәлиф. Рәхмәт, Ибраһим... Бая син аңлашып бетердек дип әйткән идең. Күрәсең, иң кирәге калган ич әле... Исеңдәме, ничек дуслашкан идек? «Миңа бәхет бирерлек бөтен сыйфатларны туплаган кызлар күптер дип

уйламыйм мин, Гандәлиф! Моңа кадәр андый кыз очрамады...»

Дибәҗә (*дәвам итә*). «Йөрәгемә хуҗа булырлык беренче кеше син».

Гандәлиф. Әйе, әйе... Ә сез аны каян беләсез?

Дибәҗә. Таныш сүзләр.

Сәхи. Ничек, ничек таныш, Дибәҗә?

Ибраһим. Дибәҗә, шаярып әйткән сүзләрне мәйданга чыгып кычкырмыйлар.

Дибәҗә. Шаярып...

Сәхи. Менә ничек!

Хәнҗәр. Димәк, шулай? Пәрәвезеңне яңа почмакларга суза башладым диген?! Үрмәкүч кебек?!

Ибраһим. Әллә аны тегендә тик кенә йөргәндер дисезме?

Гандәлиф. Ибраһим, баскан урыныңда җир убар! Телең тартышыр. Ничек шулай дип әйтә аласың?

Ибраһим. Хатын-кызны беләбез лә инде анысы!

Ак түти. Тик тор, адәм мәсхәрәсе!

Поезд тавышы ишетелә.

Ясыйр. Поезд килә! Йөк поезды! (*Флажокларын тотып чыгып йөгерә.*)

Хәнҗәр (*Нурига*). Ә син катышмыйк дисең, Нури...

Поезд тавышы көчәя. Гандәлиф чыгып китә.

Сәхи. Поезд килә...

Дибәҗә. Үрне менә...

Хәнҗәр (*Ибраһимга*). Кичә син миңа нинди сүзләр әйттең? Кем янына кертеп җибәрдең син мине?.. (*Тәрәзәгә карап тора да кинәт кычкырып җибәрә.*) Гандәлиф!

Сәхи. Гандәлиф поездга каршы йөгерә!

Бар да чыгып чабалар.

Ибраһим. Нишли ул! Бетә бит, бетерә... Җүләр хатын!

Сәхнә әйләнеп тора. Поезд тавышы көчәйгәннән-көчәя. Чәчләре тузган Гандәлиф поездга таба чаба. Менә вагоннар дөбердәп уза башлыйлар. Гандәлиф егыла. Егетләр аның янына килеп җитәләр.

Ак түти. Аллага шөкер, егылды! Дөбердәп поезд узып китә.

Ибраһим. Гандәлиф, нишлисең син, җүләр!

Хәнҗәр. Тотынма пычрак кулларың белән! (*Гандәлифне күтәреп ала.*)

Ак түти. Улым, син аны кая алып барасың?

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәнҗәрләр өе. Ишегалдына һәм эчке якка чыга торган ишекләр. Гөлләр. Җыйнак һәм матур өй. Бу йортта тәртипнең һәм чисталыкның гадәти бер хәл икәнлеге күренеп тора. Мондый пычрак көндә дә шундый чиста өй тоткан хуҗаны юкка гына Ак түти дип атамаганнар шул. Менә шул өйгә хәзер бер төркем кеше килеп керә. Алдан Ак түти, аның артыннан Гандәлифне күтәргән Хәнҗәр, төеннәр, чемоданнар күтәреп Сәхи, Дибәҗә, Рафаил, Нури керәләр. Хәнҗәр Гандәлифне олы яктагы диванга китереп яткыра. Ак түти аның баш астына мендәр-көпчек китереп сала. Бар да бераз тын

торалар. Аннан акрын гына сөйләшәләр.

Дибәҗә (*шыпырт*). Хәнҗәр абый, нишләргә инде хәзер?

Сәхи. Кая барыр ул, нишләр?

Рафаил. Юл буе күзләрен дә ачмады...

Хәнҗәр. Белмим, егетләр.

Дибәҗә. Әллә врач чакырыйкмы?

Сәхи. Күңел ярасын врач төзәтә аламы соң?

Дибәҗә. Бер әшәке адәм никадәр кешегә хәсрәт ясый ала икән.

Сәхи. Берәр нәрсә эшләргә кирәк бит инде.

Дибәжә. Таптым! Әти янына барам. Сез дә монда өелешеп тормагыз! Әйдәгез, Хәнҗәр абый, без килербез әле!

Яшьләр аяк очларына гына басып чыгып китәләр.

Ак түти. Мунча ягарга кирәк. Парлы мунча, мәтрүшкәле себерке хәл кертеп җибәрер. (*Чиләкләргә барып тотына.*)

Хәнҗәр ашыгып аның янына килә.

Хәнҗәр. Әнкәй, үзем...

Ак түти. Юк, юк, улым, болай да күршеләрдән оят.

Хәнҗәр. Оят икән, карап торсыннар. Суын да үзем китерәм. Мунчасына да ягам. (*Чыга.*)

Бераздан Гандәлиф исенә килә.

Ак түти. Көзнең көне ялкау хатын саплаган җеп кебек шул. Бетә дә китә. Уяндыңмы, балакай?

Гандәлиф. Мин кайда?

Ак түти. Бездә, балакай, бездә.

Гандәлиф. Ничек килеп кердем мин монда? (*Тәрәзәгә карап.*) Бу кичәге малай бит! Хулиган малай! Хәзер үк чыгып китәм.

Ак түти. Бу килеш кая бармакчы буласың?

Г а н д ә л и ф. Бу килеш, бу килеш... Әйтерсең лә кеше хәлен аңлый торган җаннар.

А к  т ү т и. Аңламаганын аңларга тырышам.

Г а н д ә л и ф. Би-ик! Улыгыз кичә, үзегез бүген... Кадерле, якын кешене югалтуның нәрсә икәнлеген аңлыйсызмыни сез!

А к  т ү т и. Үткәннәр кайтмый. Онытып тор аларны. Әле синең гомерең алда. Алма үзең белән үткәннәрнең барын да... Авыр булыр...

Г а н д ә л и ф. Йөрәккә сарган кайгы киемгә кунган тузан түгел шул ул. Аны кагып кына төшереп калдырып булмас.

А к  т ү т и. Бәхетең алда әле синең! Яшь бит әле син! Яшь!

Г а н д ә л и ф. Бәхет, яшьлек... Сөйләү җиңел, башка төшкәч сөйрәү авыр...

А к  т ү т и. Кайгы мең килер, шатлык бер килер. Килер дә оныттырыр.

Г а н д ә л и ф. Тизрәк моннан китәргә кирәк!..

А к  т ү т и. Бу хәлдә чыгарып җибәрмим.

Г а н д ә л и ф (*нык гаҗәпләнеп*). Ничек җибәрмисез?

А к  т ү т и. Җибәрмим, утыр, тыңла.

Г а н д ә л и ф. Тыңламыйм.

А к  т ү т и. Тыңларсың. Язмыш безнең юлларны очраштырган икән инде, аз гына безнеңчә бул. Әнә тегендә кереп, өс-башларыңны алышып чык.

Гандәлиф икенче бүлмәгә кереп китә. Я с ы й р керә.

Я с ы й р. Керимме?

А к  т ү т и. Ясыйр? Синме бу?

Я с ы й р. Мин бугай, Шәмсерур...

А к  т ү т и. Ай Аллам, әйдә, әйдә, рәхим ит, түрдән уз.

Я с ы й р. Узмыйм. Аякларым да бик пычрак. Шактый еракта торасыз икән.

А к  т ү т и. Еракта шул. Тимер юлның бер тармагын безгә борып җибәрсәң иде....

Я с ы й р. Башта Кама аръягына чыгыйк инде.

А к  т ү т и. Син тагын чегәннәр күк күчеп китәсеңме?

Я с ы й р. Кая ул, шушы тимер юлны олы юлга чыгарып җиткереп, көмеш кадаклар какканны күрә алсам...

А к  т ү т и. Көмеш кадаклар?

Я с ы й р. Яңа тармакны олы юл белән тоташтырганда соңгы шпалга рельсларны көмеш кадаклар белән беркетәләр.

А к  т ү т и. Җәлләмиләр икән көмешне.

Я с ы й р. Алтынын кагарсың, зур эш бит ул... Менә

зур поездлар китәр... Теләгән кеше теләгән җиренә барып йөрер!

Ак түти. Самолетка утырып хәзер дә барып була, рәхим ит.

Ясыйр. Тимер юлга җитми, Шәмсерур. Тәрәзәдән карап кына, аны-моны сөйләшкәләп, чәй эчеп барулар... Ә кырыйда урманнар, әрәмәләр, чиксез дөнья кала торган иде. Кәҗә сукмагы да, әкияттәге кебек, серле күренә иде. Әй! (*Сөйләнә-сөйләнә түргә уза.*) Кай арада түргә уздым әле, пычратканмын.

Ак түти. Төшеп бие, анда да сүзем юк. Кайтканыңа күпме булды, йортымны күргәнең юк.

Ясыйр. Шатлык йөртмәгән иде, менә кайгы китерде.

Ак түти. Кайгыга рәхмәт укыргамы?

Ясыйр. Олы кайгы кинәт искән җил кебек ул, яшьләрне бөгә, картларны сындыра.

Ак түти. Бу Ибраһим дигәннәре Галимә апаңның улымы?

Ясыйр. Үзе... Шатланган идем ул кайткач. Берүземә генә ямансу иде, менә тагын ялгыз калдым. Бүген киләм, карыйм, чит-ят кебек бу җирләр.

Ак түти (*яратмыйча*). Каның салкыная башлагандыр синең. Үз җирен кем ятсынсын.

Ясыйр. Синең ул җирдән куылганың юк.

Ак түти. Сине дә кумадылар.

Ясыйр. Кара язмыш куды.

Ак түти. Кумадылар, качтың син, Ясыйр. Әнә шул кара язмыштан өркеп качтың. Юып киртәгә элгән җирдән минем яулыгымны урлап китәргә генә җитте синең батырлыгың! Ни уйладың син минем хакта? Нигә ул вакытта берни дә әйтмәдең? Гомерем буе күңел түремдә шул газап торды. Әйбәт кеше белән яшәдем. Матур уллар үстердем... Нигә качтың син?

Ясыйр. Мин гомерем буе сиңа турылыклы булып калдым.

Ак түти. Кысыр турылыктан ни файда?

Ясыйр. Кичер син мине, Шәмсерур, кичер...

Ак түти. Нинди кешеләр сез! Инде менә энең! Нигә бу баланы рәнҗетә ул.

Ясыйр. Аптырагач Мәкәрим кордаш янына барган идем. Нигә башыңны иеп торасың, нәселегезнең өлкәне син, барсының да уртасында бул, ди.

Ак түти. Әйе, нәселегезнең өлкәне син.

Ясыйр. Яулыгыңны саклыйм мин, менә ул... (*Куеныннан яулык чыгара.*)

Ак түти. Минем яулык! Ише бар иде, сугыш вакы-

тынача сакладым... Авыр елларда малайларга посылкалар салганда чикләвек, бавырсаклар тутырып бетердем соңыннан...

Ясыйр. Син һаман шушы яулыгыңны чөеп бәйләп тыкрыктан суга төшәсең кебек...

Ак түти. Аннан соң күпме гомер үткән.

Ясыйр. Теге бала кайда?

Ак түти. Бездә...

Ясыйр. Үзем сезгә киләм, үзем шул баланың күзләренә ничек күренермен икән дип хафаланам.

Чабып Хәнҗәр керә.

Хәнҗәр. Әнкәй, су ташыдым. Миче дулый-дулый яна.

Ак түти. Кунак белән күреш, улым!

Хәнҗәр. Ясыйр абый, төнәгеп без кич очраштык бит, хәтерлисеңме?

Ясыйр. Очраштык, Хәнҗәр.

Хәнҗәр. Ибраһим нигә килгән иде синең янга? Гандәлиф хакында берәр нәрсә беләидеңме син ул вакытта?

Ясыйр. Беләидем, барын да белә идем.

Хәнҗәр. Кызык кеше син, Ясыйр абый! Шунда миңа берәр сүз әйтсәң булмаганмы? Сәер кеше! Барын да күрәсең, ә кул кушырып тик торасың? Ишеткәч тә изүне чишәргә, йодрыкны йомарларга иде. Әгәр шунда әйткән булсаң, эш моңа кадәр килеп тә җитмәс иде. (*Тузынып чыгып китә.*)

Ак түти. Ясыйр... Теге вакытта урлаган идең, бүген үзем бүләк итәм. Төсем итеп сакла бу яулыкны!

Ясыйр. Рәхмәт, Шәмсерур! Китим инде, китим...

Ак түти. Ашыкма, чәй эчәрсең.

Ясыйр. Китим.

Ак түти. Алай адашып кына түгел, атап та кил.

Ясыйр. Атап та килермен.

Ак түти. Теге бала өчен борчылма.

Ясыйр. Үзем өчен дә борчылып килгән идем, хушыгыз. (*Китә.*)

Ак түти озата чыга.

Гандәлиф. Әгәр гомер буе күңел түреннән китми шулай газаплап торса, ничекләр түзәрсең! (*Җылый.*)

Рәҗәп керә.

Рәҗәп. Апа, нигә җылыйсың?

Гандәлиф. Мин җыламыйм бит, үскәнем.

Рәҗәп. Җылыйсың, җылыйсың.

Г а н д ә л и ф. Юк, үскәнем, малайлар гына җылый ул, олы кешеләр җыламыйлар.

Р ә җ ә п. Һе, күргәнем бар инде, олы кешеләр дә җылый. Хәнҗәр абый моряк, ике потлы герне сыңар кулы белән элдереп өй түбәсенә ыргыта: эһ тә итми. Аның да җылаганын күргәнем бар.

Г а н д ә л и ф. Хәнҗәр абыең кайда җылады соң?

Р ә җ ә п. Безнең ындырда. Солдаттан кайткан көнне кич белән без икәү генә ындырга төшкән идек. Безнең ындыр түрендә куш каен үсә.

Г а н д ә л и ф. Куш каен?

Р ә җ ә п. Шуны кочаклады да җылый да җылый. Үзе миңа дәшкән була: «Шушы каенны аударып булыр микән?» — ди. Көчәнгән була, күзеннән яшь ага. «Ай-һай, нык утыра икән бу каен, күздән яшь чыгарды»,— дигән була. Янәсе, мин гыйшыкның нәрсә икәнен белмим.

Г а н д ә л и ф. Нигә җылады соң Хәнҗәр абыең?

Р ә җ ә п. Эльвира Карамалы тинтәге белән киткәнгә.

Г а н д ә л и ф. Нинди Эльвира?

Р ә җ ә п. Минем апа.

Г а н д ә л и ф. Син апаңны бер дә яратмыйсың, ахры?

Р ә җ ә п. Алдашкан кешене яратмыйм мин. Син, апа, кияүгә чыгасы булсаң, егетеңне ташлап китмә, яме?!

Г а н д ә л и ф. Юк, үскәнем, юк, балакаем, алай итмәм.

Р ә җ ә п. Апа, син берәүгә дә, берәүгә дә сөйләмә моны, яме?

Г а н д ә л и ф. Сөйләмәм, үскәнем, сөйләмәм, балакаем...

Р ә җ ә п. Ипидер сөйләмәм, сөйләсәм, ипинең чыраен күрмим диген.

Г а н д ә л и ф. Ипидер сөйләмәм.

Р ә җ ә п. Чыгыйм әле, әни биләмгә йөргәнне яратмый. Ә син бер нәрсәне белмисең...

Г а н д ә л и ф. Нәрсәне, үскәнем.

Р ә җ ә п. Мин олы малай булып калам. Әни әйтә, миңа хром итек тектерәбез, ди.

Г а н д ә л и ф. Итексез булмас, малай, урамнарыгыз шактый пычрак.

Р ә җ ә п. Ә Хәнҗәр абыйның пычракка да исе китми. Әле бүген дә сине күтәреп кайтып килә. Выжлап кына бара.

Г а н д ә л и ф. Мине?

Р ә җ ә п. Әйе инде. Ул күтәреп кайтты бит сине. Син чирләп егылгансың да... Әни әйтә, чирләмәгән ул, хәйләләп кенә яткандыр, ди. Кайсы төшең авыртты синең, апа?

Гандәлиф. Башым.

Рәҗәп. Ә-ә... Апа, терелгәч тә безгә кер. Әнигә карама. Сиңа маркаларымны күрсәтермен. Мич арасында керпем дә бар әле минем, тере!

Гандәлиф. Керермен, үскәнем, керермен.

Рәҗәп. Кара, вәгъдәңдә тор! (*Чыга.*)

Гандәлиф ялгыз. Ул тәрәзә янына килә. Стенадагы Хәнҗәр рәсеме алдына тукталып озак кына уйланып тора.

Гандәлиф. Менә кем икән син, Хәнҗәр...

Бераздан яшәреп, кызарып киткән Ак түти керә.

Ак түти. Балам, нигә өс-башыңны карамадың? Хәзер үк кер!

Гандәлиф. Өлгерермен әле. Апа, нигә сезне Ак түти дип йөртәләр?

Ак түти. Белмим шул. Нигә әйткәннәрдер инде.

Гандәлиф. Мин дә Ак түти дип йөримме сезне?

Ак түти. Әйт, кызым, әйт. Күрше апаң кереп килә. Бу килеш аның күзенә күренеп йөрмә инде син... Бар теге якка ук чыгып тор.

Гандәлифне кече якка чыгара. Ишек бераз ачык кала. Мәймүнә керә.

Мәймүнә. Исән-саулар гына торасыңмы?

Ак түти. Әйбәт, уз әйдә.

Мәймүнә. Кунагың кайда?

Ак түти. Теге якта, ял итә.

Мәймүнә. Ял? Ясыйр абыймы?

Ак түти. Ул китте. Каян күреп алдың әле аны?

Мәймүнә. Тәрәзәне ник уйганнар соң? (*Утырып.*) Ярты гомерен зимагурлыкта йөргәч, ник кайтты икән безнең якларга?

Ак түти. Күпләр кайтты. Туган җире тарткандыр.

Мәймүнә. Җир нишләп тартсын ул, хи-хи-хи... Өйләнгәнме?

Ак түти. Анысын сорарга оныткандмын.

Мәймүнә. Үзе дә әйткәндер әле.

Ак түти. Син сорасын белгән булса, әйтеп калдырыр иде.

Мәймүнә. Миңа нигә ул? Әстәгъфирулла, тәүбә! Тилемиле... Тимер юлда бала-чаганы таптатып бетерер әле.

Ак түти. Туган җир — туган җир ул, Мәймүнә...

Мәймүнә. Җир кая барсаң да бертөсле. Бөгелмәгә кадәр барганым бар. Гыймран әйтә, Бөгелмә Рәсәйнең яртысы, ди. Барыбер бер җир. Тузан, туфрак, пычрак. Фу...

Ак түти. Аера белергә дә кирәк, Мәймүнә. Менә тимер юлчылар безнең колхоздан күпме генә җир алдылар. Басуның бер читен кыеп кына тимер юл үтте. Беләсеңме, күпме акча түләделәр алар?

Мәймүнә. Күптер инде син әйткәч.

Ак түти. Кырык мең сум.

Мәймүнә. Син миңа иске акча белән әйт, мин яңача чутлый белмим.

Ак түти. Дүрт йөз мең сум.

Мәймүнә. Озын куак үре өченме?

Ак түти. Менә сиңа җир. Шуны ишеткәннән бирле бакчадагы һәр карыш җиргә башкача карый башладым.

Мәймүнә. Бакча дигәннән, кәбестәләрегез шәп икән! Тудыкайларга кунакка барышлый бакчагыз кырыеннан үттек.

Ак түти. Шәп. Чык безгә эшкә. Үз бригадама алам.

Мәймүнә. Чыкмыйм. Нефтәннек хатыны ла мин. Менә Сәхиемне генә алалар. Кысынкыракка калабыз.

Ак түти. Безнекеләр кебек үләргә китми әле.

Мәймүнә. Белмәссең, теге герман каһәрләр һаман тынмый, ди.

Ак түти. Үз башларына булыр. Аларны тындырырлык кына бар инде бездә.

Мәймүнә. Каян беләсең?

Ак түти. Германнарның патшасы белән хат алышам. Шул язды!

Мәймүнә. Ишетмәсәң ишет, әстәгъфирулла, тәүбә!

Хәнҗәр керә.

Нигә эндәшмисең, Хәнҗәр?

Хәнҗәр. Ни эндәшим?

Мәймүнә. Кәләш алып кайткансың икән, хи-хи-хи...

Хәнҗәр. Кызыкмы?

Мәймүнә. Кызык дип, юкка башыңны бәйли күрмә, апаем... әллә нинди олы юлларда йөргән нәмәстәдер. Гыймран әйтә...

Хәнҗәр. Мин Гыймран информацияләре белән кызыксынмыйм.

Ак түти. Мәймүнә, булашма бала белән.

Мәймүнә. Бала белән? Хи-хи-хи...

Ак түти. Әйдә, сыер саварга чыгам, шунда сөйләшеп бетерербез.

Мәймүнә. Юк, күршекәем, вакытым бер дә юк, сыерыңны үзең генә сау инде. Үзебезнекен дә Сабира апага яллап саудырам. Сыер исеннән башым әйләнә, фу! (*Чыгып китә.*)

Х ә н җ ә р. Ник кергән?

А к т ү т и. Бик ашыга иде, йомышын әйтергә өлгермәде. (*Чиләк алып чыгып китә.*)

**Хәнҗәр гармунын ала да акрын гына уйный-уйный ишеккә бара башлый. Кече як ишек төбендә Гандәлиф аны карап тора.**

Г а н д ә л и ф. Хәнҗәр, бу нинди көй?

Х ә н җ ә р. Исемен белмим. Поездда кайтканда бер старшина уйнаган иде. Шунда оттым. Сагыну, юксыну хисләре бар бу көйдә.

Г а н д ә л и ф. Аларның икесе дә бер түгелмени?

Х ә н җ ә р. Бер түгел... Сагынасың сагыныр кешең булганда, сагыныр кешең юк икән, күңел юксына...

Г а н д ә л и ф. Син флотта булдыңмы?

Х ә н җ ә р. Әһе.

Г а н д ә л и ф. Нигә әһе генә дисең?

Х ә н җ ә р. Әйе, мин флотта булдым.

Г а н д ә л и ф. Бу ел миңа да кара диңгезгә путевка биргәннәр иде, ялгыз барасы килмәде.

Х ә н җ ә р. Диңгез ялгыз итми ул. Ул дәү, ягымлы дус кебек, аңа сыенырга, иркәләнергә була.

Г а н д ә л и ф. Син кичә миңа бик нык ачуландыңмы?

Х ә н җ ә р. Ә син?

Г а н д ә л и ф. Ачуланма, яме. Син кичә әллә нинди идең. Тупас. Үзең гармунчы егет, куш каеннарны кочаклап җылый алган егет.

Х ә н җ ә р. Җыламадым мин, җыламадым...

Г а н д ә л и ф. Җыласаң ни ояты бар? Кешенең нинди вакыты булмый да, күңелнең нинди чагы булмый.

Х ә н җ ә р. Шулай да тормыштан туярга ярыймы соң?

Г а н д ә л и ф. Син үзеңә ышанган кебек ышанган, аның өчен җаныңны бирергә әзер торган кеше сине алдаса...

Х ә н җ ә р. Куш каеннарны беләсең икән инде, яшереп булмый, кыен вакытлар, бик рәнҗегән чаклар да була. Тик кешенең үз язмышыннан тыш туган җире, халкы бар бит. Үләргә ашыкма син. Сине тудырган, үстергән җирең алдында олы бурычларың бар.

Д и б ә җ ә керә.

Д и б ә җ ә. Керергә ярый идеме?

Х ә н җ ә р. Кер, кер әйдә, Дибәҗә. Гандәлиф, таныш, Дибәҗә, безнең начальникның кызы.

Д и б ә җ ә (*кулын биреп*). Олы начальникныкы диген. Ак түти өйдәме?

Х ә н җ ә р. Ак түтидәмени йомышың?

Д и б ә җ ә. Йомышсыз килергә ярамыймыни? Бик беләсең килсә, синең янга килмәдем, Гандәлиф янына килдем.

Г а н д ә л и ф. Рәхмәт.

Д и б ә җ ә. Кадерле сүзне алай ашыгып әйтмә. Нигә килгәнне белгәч әйтерсең. Әти белән, дөресрәге, олы начальник белән сөйләштем... Иртәгедән эшкә килә аласың.

Г а н д ә л и ф. Нинди эшкә?

Д и б ә җ ә. ГРЭС салабыз. Сине дә шунда эшкә чакырырга килдем.

Г а н д ә л и ф. Минеме?

Х ә н җ ә р. Ял итсен әле.

Д и б ә җ ә. Яхшы эш үзе ял ул. Ә хәзер әйберләреңне җый да безгә киттек.

Х ә н җ ә р. Ничек сезгә?

Д и б ә җ ә. Минем бүлмәдә буш карават бар. Күпме теләсәң, шулкадәр бездә торырсың. Бергә-бергә эшләрбез.

Г а н д ә л и ф. Рәхмәт сиңа, Дибәҗә.

И б р а һ и м керә.

Ибраһим!

И б р а һ и м. Гандәлиф, мин сине алырга килдем.

Г а н д ә л и ф. Ибраһим!

И б р а һ и м (*тиз-тиз*). Алырга килдем. Әйе, алырга... Гафу ит син мине, кичер. Мең кат кичер. Кайтып кердем, бүлмәгә керергә аягым тартмый... Өстәлемдә синең белән бергә алган, синең кулың тигән әйберләр. Кайсы почмакка гына карасам да, синең истәлегең. Әйберләр бар, син юк. Үзем өчен гаять кадерле бер кешене югалта язуымны мин шунда гына аңладым. Яши алмыйм мин синнән башка!

Г а н д ә л и ф. Ибраһим, ни булды сиңа?

И б р а һ и м. Ялгыштым мин, ялгыштым. Ләкин әле соң түгел! Мин ни әйтсәң дә риза, бүген үк бабайларга китәбез. Көтәләр бит анда безне.

Г а н д ә л и ф. Булып узганнардан соң!

И б р а һ и м. Үзем киләм, үзем уйлыйм. Юк, гафу итмәс ул мине! Күңелдә икенче уй калка. Гандәлиф олы җанлы кыз, ул аңлар... мине бәхетсез итеп, ялгыз калдырмас дип өметләнәм.

А к т ү т и керә.

А к т ү т и. Син нишләп монда әле?

И б р а һ и м. Исәнмесез, апа... Сезне дә күреп рәхмәт

әйтәсем бар иде. Кыен вакытта Гандәлифкә ярдәм иттегез, миннән күрмәгәнне ул сездән тапты.

Ак түти. Нигә андый төче сүзләр?

Дибәҗә. Ак түти, Ибраһим Гандәлифне алырга килгән, гафу үтенә.

Ак түти. Нияте изге, теләге нык микән?..

Ибраһим. Хәзер монда сүзләргә урын калмады. Ак түти, аларның кадере бетте.

Гандәлиф. Ак түти, ышанасы килә...

Ак түти. Гандәлиф балам, мондый чакта кеше киңәшенә колак сал, әмма ләкин үзең уйла. Күңелеңдә ни бар?

Хәнҗәр. Гандәлиф!

Ак түти. Ә син хәзер тик тор.

Ибраһим. Әйтсен, апа, әйтсен, Хәнҗәр акыллы егет.

Гандәлиф. Ни уйларга белмим, башым чуалды.

Ибраһим. Әйдә, Гандәлиф, әйдә!

Ак түти. Менә нәрсә, Ибраһим, бу күңелсез эш безне дә бик борчыды. Мин кыз баланы бу хәлендә урамга чыгарып җибәрә алмыйм. Безгә килгән икән, бездән китсен. Мунча әзер, юынып чыксын. Чәй кайнаган, сыемнан авыз итсен. Син бар, кайт, әзерлән. Кич белән вокзалга килерсең.

Ибраһим. Олы кешедән олы сүз чыга шул. Риза. Очтым. Гандәлиф, мин түземсезлек белән көтәрмен. (*Чыга.*)

Гандәлиф. Әгәр кичә шулай килгән булса, килгән булса... Нинди зур куаныч була иде бит.

Хәнҗәр. Зур куаныч...

Ак түти. Бәхет артык соңга калмаганда әйбәт әле ул.

Дибәҗә (*ачулы*). Шушы буламы инде мәхәббәт?

Пәрдә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Вокзал алды. Хәнҗәр ялгыз. Ярсып гармун уйный, җырлый.

Хәнҗәр. Ват, җимер коймасын,
Сүз әйтергә кыймасын,
Таш атып ишеп төшердек
Галәү агай морҗасын.

Дибәҗә керә.

Дибәҗә. Җырың шәп синең.

Хәнҗәр. Малай чакта җырлаган җыр... Диңгездә давыллар вакытында гел шул хәтергә төшә торган иде.

Д и б ә җ ә. Нигә тузгыдың?

Х ә н җ ә р. Ничек түзәсең? Син ут, ялкын дип уйлыйсың, ә ул тычкан уты булып чыга... Син мәхәббәт дип уйлыйсың, ул балаларча бер кылану икән.

Д и б ә җ ә. Синең тәрәзә ватасы, нәрсәдер җимерәсе, ишәсе килгән вакытларың буламы?

Х ә н җ ә р. Булгалый.

Д и б ә җ ә. Миндә андый теләк еш кына була. Бөтенесен онытасы, җимерәсе, кырасы килеп китә.

Х ә н җ ә р. Әйдә киттек.

Д и б ә җ ә. Кая?

Х ә н җ ә р. Син безнең тәрәзәне ватарсың, мин сезнекен.

Д и б ә җ ә. Ул гына күңелне басар микән соң?

Х ә н җ ә р. Тәрәзә генә җитмәсә, капканы аударырсың, ачуланмыйм.

Д и б ә җ ә. Сәхи килермен дигән иде. Килмәде. Аңа бер ачуым чыкты. Бары бергә җыелды... Әллә нинди көн!

Х ә н җ ә р. Сәхи дигәннән, мин дә аларны эзлим. Безне озатырга төш дигәннәр иде.

Д и б ә җ ә. Әйдә киттек.

Х ә н җ ә р. Кая барабыз?

Д и б ә җ ә. Башта уңга, аннан тагын уңга, тагын уңга... Шулай итеп тагын шушында килеп чыгабыз. Анда да Сәхи булмаса, армиядә бәрәңге әрчергә генә ярарлык итәм мин аны.

Чыгып китәләр, алар китүгә е г е т л ә р күренәләр.

Р а ф а и л. Эләгә, Сәхи, сиңа.

Н у р и. Бар, куып җит.

Р а ф а и л. Чыннан да, монда үзебез дә башкарып чыгарбыз.

С ә х и. Юк, минем үз бурычым бар, ул аны минем кулдан алырга тиеш.

Н у р и. Килмәс ул, юкка гына көтәбез.

С ә х и. Килер, мин аны күрдем. Каядыр китәргә җыена. Чемоданын тоткан да кибеттән кибеткә йөри. Тәмам эт икән. Һаман авызы ерык. Көлә, шаяра, әйтерсең берни булмаган.

Р а ф а и л (*уйланып*). Кичкырын вокзал ягына ике кыз үтеп китте. Пар күлмәкләр кигәннәр. Мөгаен, апалысеңелле булганнардыр әле.

Н у р и. Ачу китереп маташма. Тәки бер сүз әйттерерсең.

Р а ф а и л. Нигә?

Н у р и. Сиңа ышанып йөргән мин юләр. Үзем тотын-

ган булсам, әллә кайчан өйләнгән идек инде. Әгәр дә мәгәр апалы-сеңелле кызлар күрсәң, тел ачасы булма! Абзаң артыннан йөгер!

Р а ф а и л. Килә, килә!

Егетләр посалар. Җиңел көйгә сызгыра-сызгыра чемодан тоткан И б р а һ и м керә. Егетләр өчесе өч яктан аңа ташланалар.

С ә х и. Менә ул!

Н у р и. Эләкте.

И б р а һ и м. Туктагыз, танымыйсызмы әллә, бу мин!

Р а ф а и л. Таныйбыз, син кирәк тә безгә.

С ә х и. Син безне алдадың. Безнең яшьлектән файдаландың. Без сиңа ышана идек. Серләребезне, сөйгән ярларга сөйләргә базмаган серләребезне сөйли идек. Киңәшә идек. Ярата идек. Ярата идек без сине. Ә син ялганчы, мәкерле бер җан икәнсең! (*Суга.*) Мә, ал!

И б р а һ и м. Ну, малайлар, күрсәтәм мин сезгә хәзер.

С ә х и. Күргәне җитәрлек булды. Инде күрсәтә алмассың. Син безнең ышанычны урладың, безгә сагаю, шикләнү, дусларга, якыннарга ышанмау чире йоктырдың.

И б р а һ и м. Бозау кебек күбенгәнсең.

С ә х и. Юк, авызга да алганым юк минем аны. Куркытма, курка торган күлмәкләр тузды инде безнең хәзер. Ил чигенә сакка китәбез, алда дошман, як-якта дошман, артта да дошман калмасын инде. (*Кыйныйлар.*)

Х ә н җ ә р белән Д и б ә җ ә йөгереп керәләр.

Х ә н җ ә р. Туктагыз, егетләр, нишлисез?

С ә х и. Хәнҗәр абый, җибәр!

И б р а һ и м. Җибәрмә, Хәнҗәр!

Х ә н җ ә р. Сугышырга ярамый, егетләр!

Р а ф а и л. Ни сөйләшеп торасыз, мә, бусы Гандәлиф өчен!

И б р а һ и м. Шаштыгызмы әллә, без Гандәлиф белән килештек бит инде.

С ә х и. Тагын ялганларга тотындыңмы?

И б р а һ и м. Менә Дибәҗә әйтсен, Хәнҗәрдән сорагыз, ул мине гафу итте.

С ә х и. Гафу итте, синеме?

Д и б ә җ ә. Әйе, Сәхи.

Егетләр аптырап бер Дибәҗәгә, бер Ибраһимга карап торалар.

С ә х и. Ул гафу итсә дә, без гафу итмибез сине. (*Суга.*)

Х ә н җ ә р. Сәхи, пычратма кулыңны!

Ибраһим чыга.

Сәхи. Нишләргә, нишләтергә соң бу Ибраһимны.

Хәнҗәр. Нишләтәсең, судка биреп булмый, кеше бәхетен урлаган өчен хөкем итәргә статья да юк, шулай да халыктан, җирдән качып китә алмас, җәзасын алыр әле.

Сәхи. Ә мин гафу итмәс идем, гомердә дә гафу итмәс идем!

Дибәҗә. Сәхи... Синең мине бер дә үпкәнең юк, Сәхи! (*Кочаклап үбә, моны егетләр күреп чыгып китәләр.*)

Сәхи. Каян килде әле бу көтелмәгән бәхет.

Дибәҗә. Көн бүген озын, олы булды. Без барыбыз да бераз гына олыгайдык.

Ясыйр керә.

Ясыйр. Нигә иптәшләрегез янында түгел?

Дибәҗә. Читтән карап торучылар да кирәк бит, Ясыйр абый, ә?

Ясыйр. Ә? Читтән дисеңме? Андыйлар кирәкми. (*Пауза.*)

Дибәҗә. Ишеттегезме, Ибраһим белән Гандәлиф килешкәннәр бит.

Ясыйр. Ишеттем.

Сәхи. Ничегрәк соң, Ясыйр абый, куанасызмы?

Ясыйр. Куана алмыйм, Ибраһим белән бәхет таба алмас ул бала.

Сәхи. Сез моны аларның үзләренә әйтегез, Ясыйр абый. Күрсәтегез бер егетлек!

Ясыйр чыга. Яшьләр гармун, җыр белән вокзалга якынаялар. Арада Ак түти, Гандәлиф, Рәҗәп һәм башкалар.

Дибәҗә. Хәнҗәр абый, Хәнҗәр абый, мин яраткан көйне уйна әле.

Сәхи. Зәй буйларын бер селкет әле, Дибәҗә.

Бию башлана.
Дибәҗә бии. Бии-бии Гандәлифне чакыра. Ул кыстатып кына чыга.
Ул чыгуга Хәнҗәр уйнаудан туктый.

Гандәлиф. Ник туктадың, Хәнҗәр?

Хәнҗәр. Чыннан да биисең килгән идеме синең?

Гандәлиф. Күптәннән биегәнем юк иде, шашып биисем килә.

Хәнҗәр. Синең өчен зур көн бит бүген. Бәйрәм! Туйга кайтасың! Өй туена! Нигә ул туйны монда башлап җибәрмәскә. Сиңа ак юл теләп, синең туеңда беренче булып үзем биим. Уйна, егет!

Бию. Ибраһим керә.

Гандәлиф. Җитте, булды.

Ибраһим. Арыдыңмы, Гандәлиф?

Гандәлиф. Арыдым, бик ардым.

Ибраһим. Утырып ял итеп тор, мин билетлар алам.

Гандәлиф. Ә син кая барасың?

Ибраһим. Ничек кая? Бабайларга.

Гандәлиф. Мин намусы саф бер кыз идем. Беркөнне син килдең дә: «Мин сине сөям»,— дидең. Беләсеңме шул чагында кыз баланың күңеле нишләгәнен?! Сине сөяләр, сине! Син кемгәдер бик кирәк, ул сине ярата, көтә, сагына... Ул синсез яши алмый. Кыз бала шул кешегә бөтен барлыгын, яшьлеген, сафлыгын, намусын тапшыра. Минем өчен ул кеше син идең, Ибраһим! Син туган җирләреңне, туганнарыңны сагындым дип кайтып киттең. Шундый кеше янына кайтмый ничек түзәсең?

Ибраһим. Болар барсы кемгә кирәк?

Гандәлиф. Миңа кирәк. Менә бу бәхетле яшьләргә кирәк. Менә син безнең алдыбызда басып торасың. Синең өчен кадерле изге берәр нәрсә бармы бу дөньяда? Туганнарың изгеме? Син аларның йөзләренә төкердең. Дусларыңмы? Син аларның һәммәсенә хыянәт иттең! Мәхәббәтме? Син аны аяк астына салып таптадың! Миңа әле генә ак юл теләделәр. Мин ул юлга синең белән чыга алмыйм. Юк, мәңге юк.

Ясыйр. Кичер, кызым, безнең нәселне кичер! Ул рәнҗеткән дә бик җиткән.

Гандәлиф. Ясыйр абый, мин бирегә килеп төшкәч, күзгә ачы җилләр башланды. Караңгы бу якларда әллә кайда гына бер ут җемелди. Монда кереп китсәң адашканыңны сизми дә калырсың, дип уйлаган идем.

Ясыйр. Кызым, балам, хәзер дөнья башка, яхшы кешеләр күп. Ә син яшь, ата-анаң тигез, хыялларың матур, күңелеңне төшермә.

Гандәлиф. Рәхмәт, Ясыйр абый. Ә хәзер поездны җибәр, Ясыйр абый, вакыт җитте! (*Җыелганнарга.*) Рәхмәтләр яусын сезгә.

Дибәҗә. Гандәлиф, кая барасың инде хәзер, өегезгәме?

Гандәлиф. Өйгә? Юк, Дибәҗә. Ата-анама, туган җиремә кайгы алып кайтасым килми, онытылсын бераз. Хушыгыз!..

Поезд гудок бирә. Саубуллашалар. Алгы планда Ак түти белән Хәнҗәр кала.

Хәнҗәр. Әнкәй... Әгәр мин шушы тимер юлдан кайтырга чыгып, синең янга керми үтсәм, авыр булыр идеме?

Ак туги. Ана кеше түзә инде, чыдый.

Хәнҗәр. Ә бала... Әнкәй, китим әле мин Гандәлиф белән.

Ак туги. Кая?

Хәнҗәр. Аларга. Әнкәй, бик ошады ул миңа. Аңлыйсыңмы, минем аны югалтасым килми.

Ак туги. Ни әйтим соң сиңа? Үзеңә кара, улым...

Хәнҗәр. Борчылма, әнкәй, без бик тиз әйләнеп кайтырбыз. (*Китә.*)

Ибраһим. Ясыйр абый, кадерлем, ашыкма, җибәрми тор.

Ясыйр. Кая барасың?

Ибраһим. Китәм моннан.

Ясыйр. Кая бара аласың син? Синең өчен бөтен җирдә юллар ябык.

Ибраһим. Теле ачылган! Кеше бусагасында кәкрәеп үлгәндә туганнарыңны искә алырсың әле. Авызыңа кашыклы су салучы булмас.

Ясыйр. Куркытма, күбәүләр без. Күрәсеңме, бик күбәүләр, һәм без бу җирдә, үз җиребездә, мәңге торырга уйлыйбыз. Кит юлдан!

Поезд кузгала. Кешеләр кул болгап, шаулап озатып калалар.

— Бәхетле юл!
— Хәерле юлга!
— Исән йөреп, сау кайтыгыз!
— Юллар уң булсын! — дигән озату сүзләре яңгырый.

Пәрдә. Пәрдәнең бу ягында ялгыз Ибраһим гына кала. Көзге җилләр исәләр. Яңгыр шыбырдый.

*Бигеш—Ялта—Казан—Мәскәү*
*1961*

# Җиргә тапшырылган серләр

*Драма өч пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Кәрим Хәернасов.
Илшат.
Зәнә.
Рәдиф.
Шәрифҗан.
Самат Гаязович.
Гөлсем.
Марат Кәримович.
Гаян апа.
Шофер.

Кара киемле укытучы, беренче класс укучылары.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урам буйлап рәт-рәт тезелешеп бер төркем бала — беренче класс укучылары үтеп баралар. Малайлар артык зур фуражкалар, озын чалбарлар, кызлар шактый килбәтсез күлмәклар кигән. Балалар шактый тәртипсез атлый. Кайберләре сөрлегеп янга чыккан, икенчеләре авыз күтәреп артта калганнар. Иң алдагы баланы җитәкләп кап-карадан киенгән укытучы ханым бара. Менә бер малай чалбар балагына абынып егыла. Рәтләр тәмам чәбәләнеп туктыйлар, барысыда куркынып укытучыга карыйлар.

Укытучы (*калын тавыш белән*). Балалар, сафларның тәртибен саклагыз.

Укучылар (*өч-дүрт тавыш хор белән*). Без сафта йөри белмибез.

Укытучы (*шундый ук тавыш белән*). Бер-берегездән калмагыз.

Укучылар (*хор белән*). Без тигез бара алмыйбыз.

Укытучы (*кырыс*). Узып та китмәгез.

Укучылар (*хор белән*). Малайлар ашыгалар.

Укытучы (*һаман тезә бирә*). Як-ягыгызга каранмагыз. Әнә безнең мәктәп бакчасы.

Укучылар (*хор белән*). Мәктәп тегендә калды, ә нигә бакчасы монда?

Укытучы. Безнең яңа мәктәп шунда булачак.

Укучылар (*хор белән*). Без ун ел шунда укырбызмы?

Укытучы (*аларга җавап бирми*). Бакчада сезне унынчы класста укучы абыйларыгыз, апагыз көтә.

Укучы (*шатланып*). Безнең Шәрифҗан абый, Шәрифҗан абый!

Укучы (*куанып*). Минем Илшат абый!

Укучы (*күңелсез*). Ә безнең Тәлгать абый анда юк.

Укучы (*моңлы*). Сәрвиназ апа да китте.

Укучылар (*шаулашалар*). Безнең дә!.. Минем дә!..

Укытучы. Гөжләмәгез әле.

Укучылар (*хор белән*). Без сөйләшәбез генә.

Укучы (*бик белдекле төс белән*). Унынчылар анда дүртәү.

Укучы. Белдең! (*Төртешәләр.*)

Укытучы (*үтә җитди төс чыгарып*). Беренче класста аларны да мин укыттым. Хәзер алар тәртипле, акыллы, сүз тыңлаучан турылыклы егетләр һәм кызлар. Хәзер сез дә укучылар. Тәртип бозарга да, каты кычкырырга да, рөхсәтсез сөйләшергә дә, ялгыш атларга да ярамый сезгә.

Пауза. Укучылар, башларын иеп, мескен генә басып торалар.

Укучы. Ул үзе, ул үзе!

Укытучы. Әләкләшергә дә ярамый.

Укучы (*җилкенеп*). Ул түгел, син башладың ич.

Укытучы. Яклашырга да ярамый.

Укучы (*еламсырап*). Ул үзе, ул үзе...

Укытучы. Еларга да ярамый.

Укучылар (*хор белән*). Нәрсә генә ярый соң?

Укытучы (*шундый ук таштай йөз белән*). Җырларга ярый. Әйдәгез, кулга-кул тотынышып алга атладык! Җырлагыз!

Укучылар (*хор белән*). Без җырлый белмибез.

Укытучы. Белмәсәгез — өйрәнерсез.

Укучылар (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез.

Тигезсез сафлар булып кыптыр-кыптыр чыгып китәләр. Акрын гына пәрдә күтәрелә. Бакча ачыла. Көз. Бер якта яфраклары саргайган карт агачлар. Алгы планда бушлык. Яңа казылган чокырлар. Төпләре әйбәтләп чыптага төрелгән агач үсентеләре. Көрәкләр, мунчалалар, казыклар. Барысы да агач утыртырга әзерлекне күрсәтә. Илшат белән Шәрифҗан тирләп-пешеп чокыр казыйлар.

Илшат. Тизрәк, тизрәк, Шәрифҗан.

Шәрифҗан. Җеп өзәр хәлем юк, карыным ачты.

Илшат (*казый*). Тизрәк бул, Шәрифҗан, тизрәк.

Шәрифҗан. Ашыктырма шулкадәр, яндырып үтерәсең. (*Карanып.*) Беренче чебешләре барыбер күренмиләр.

Илшат. Бер көндә үзем теләмәгән ике эшне үк үти алмыйм. Сырт йоным кабара. Җаным теләмәгән килеш бакчасына килдем, кулым бармаса да, чокырлар казып ятам. Инде күңелем тартмаган хәлдә беренчеләр белән әңгәмәгә кала алмыйм. Сабырым шартлады! Тиз-тиз генә эпә-чәпә китерик тә алар килгәнче ычкыныйк.

Шәрифҗан (*киң итеп елмаеп*). Ә чокыр инглизчә «пи-ит» була.

Илшат. Берәрне сыпыртып җибәрсәм...

Шәрифҗан. Бүген иртәдән бирле кыланышың кагыйдәләргә сыймый!

Илшат. Кыланышым да, уйларым да кагыйдәгә сыярга тиеш түгел минем. Мин ирекле кеше.

Шәрифҗан. Анысы шулай да... (*Пауза.*)

Илшат (*тукталып тирен сөртә*). Иң элек теге Кәрим булыр-булмас сочинениесе белән ачуны чыгарды.

Шәрифҗан. Ну инде, шуңа да ачуың килеп торса...

Илшат. Бу бит аның башы гына! Бүген «Минем әни» дигән сочинение язып килергә кушар, иртәгә «Минем әти», берсекөнгә «Үзем турында үзем»!.. Сизәсеңме, каршысына утырта да күңел җепләреңне берәм-берәм тарткалый. «Исем-фамилияң ничек, туган елың, әти-әниеңнәр кем булган, ни эшләгән, чит илдә туганнарың бармы?..» Минем ата-анамның кем булуы, ничек яшәвем, ни уйлавым Кәримгә нәрсәгә?.. Серләремне берәү белән дә уртаклашасым килми. Сереңне уртак иттеңме, син колга әйләндең дигән сүз.

Шәрифҗан. Сочинение беребез дә язмадык дигәч, үзе дә биш минут телсез торды, малай... Шулай да кызгандым мин аны, Илшат.

Илшат. Таман гына булды! Килгән икән, кеше төсле генә үз фәнен укытсын, безнең күңелләрдә актарынмасын!

Шәрифҗан. Шулай да кызганыч... Мескен... «Бәлки, Рәдиф язгандыр, үзе күренми, авырып ятмыйдыр ич?» дигән була. Абайладыңмы, киндер кебек агарынды, лып иттереп урындыкка утырды.

Илшат. Бик шәп. Дәресне унынчы класста алып баруын онытмасын. Килер-килмәстә мәктәп гадәтләрен бозарга тотынды. Бездә унынчылар — ирекле кошлар. Кирәк икән, дәресен дә калдыралар, җәмәгать эшләрен

әйткән дә юк. Алар инде кирәген алган, укыйсын укыган. Хәзер әйбәт кенә экзаменнарын тапшырсыннар да, очты китте.

Ш ә р и ф җ а н. Чыннан да, ни җитми икән Кәрим абыйга? Директорга әйтеп безне монда җибәртте. Бакча утыртып йөрергә биология укытучысы беткәнме?

И л ш а т (*казый*). Их, тизрәк килсен иде яз. Мәктәбеннән дә, Кәрименнән дә котылыр идек.

Ш ә р и ф җ а н. Ә яз инглизчә «спринг» була.

И л ш а т. Тизрәк, Шәрифҗан, тизрәк!

Ашыгып-ашыгып казыйлар. Менә Р ә д и ф керә. Тәмәке кабызып, тегеләрнең казыганын эре генә карап тора.

Р ә д и ф. Әй сез, штрейкбрехерлар! Шушы хурлыкка төштегезмени? Бала-чагалар өчен мәктәп бакчасында рекорд куасызмы?

И л ш а т (*аңа карамыйча*). Тизрәк, Шәрифҗан, тизрәк.

Р ә д и ф. Борынгы китапларда язылган ди. Кешеләр тора-тора вакланачак, бәләкәйләнеп мич төбендә ашлык сугачаклар, имеш... Элекке елларда директор унынчы класслар белән кул биреп күрешә иде...

И л ш а т (*ачу белән*). Ну, син, арттырма! Без монда булганга гына койрыгыңны сыртка сала аласың.

Ш ә р и ф җ а н. Без булмасак, качар идең бит дәрестән... Болай да өч партага бер кеше. Уф, арыдым. Карын ачты. (*Утыра, сумкасыннан ипи чыгарып ашый башлый.*)

Р ә д и ф. Синең дә аркалар дымланган, Илшат. Кил, берне көйрәтеп җибәр. «Честерфильд». Америка сигаретлары. Иң атаклы фирма. Абый җибәргән.

И л ш а т. Безнең корсакка сары май килешерме соң?

Тарталар. З ә н ә керә, чокырлар тирәли йөри.

З ә н ә. Нәрсә була инде монда?

Ш ә р и ф җ а н. Яңа Гайд-парк. Шуннан ким түгел.

И л ш а т. Нәрсә ул Гайд-парк?

Ш ә р и ф җ а н. О! Гайд-парк Англия ул! Демократия. Кем ни тели, шуны сөйли. Уртага чыгып басасың да: «Безнең премьер-министр җүләр!» — дип кычкырасың. Әлбәттә, әгәр сине тыңлаучылар булса.

И л ш а т. Әгәр бу Гайд-парк булса, бер-ике сүз мин дә әйтер идем бүген...

Р ә д и ф. Кызык илләр, сәер гадәтләр бар инде...

И л ш а т (*үсентеләргә күзе төшеп*). Каян мондый агачларны тапканнар? Тамырлары нинди нык, сабакка шәп, бөреләре ядрә кебек.

З ә н ә (*Рәдифкә*). Син тагын дәрестә булмадың. (*Пауза.*) Беренче класста утыз бала. Кызыктыр ул?

Р ә д и ф (*сикергәләп Зәнә янына барып җитә*). Ха! Аның егерме тугызы малай булып, арада бердәнбер кыз булсаң, сиңа кызык.

З ә н ә (*кычкырып көлә*). Карагызчы моны... Нахал!

И л ш а т (*Шәрифҗан янына эскәмиягә барып утыра*). Укый башлаганда без дә егерме бер идек.

Ш ә р и ф җ а н (*ипи сындырып аңа суза*). Болар да берәм-берәм коелырлар әле.

Р ә д и ф (*чокыр янына чүгәләп балчык ата*). Тизрәк җитсен иде ул яз. Яз, весна, Шәрифҗан бытылдагандай «спринг»!

З ә н ә. Шәрифҗан!

Ш ә р и ф җ а н. Тыңлыйм, ханым-солтаным.

З ә н ә. Минем сумкада майлы ипи бар. Алып аша.

Ш ә р и ф җ а н (*сикереп төшә*). Рәхмәт. (*Мәчедәй үрмәләп сумка янына бара. Ача. Иң элек кәгазьләрне караштыра. Хат табып ала. Яшерергә уйлый, аннары тантана белән кычкыра.*) Хат! Егетләр хаты!

З ә н ә (*урыныннан купмыйча гына*). Куй.

Ш ә р и ф җ а н. Хәзер шәпләп укыйбыз.

Р ә д и ф (*сикергәләп*). Миңа бир, Шәрифҗан, миңа бир.

З ә н ә (*нәфрәт белән*). Оялыгыз, күсәкләр.

И л ш а т (*тегеләр көтмәгәндә хатны тартып алып Зәнәгә бирә*). Ярамый.

З ә н ә (*сумкасын барып ала*). Кемнәр белән яшьлегемне уздырам бит, кемнәр белән!..

Ш ә р и ф җ а н (*әче тавыш белән Илшатка*). Ә нигә ул безгә хыянәт итә?

З ә н ә (*ачу белән сумкасын җыештыра*). Хыянәт... Син ул сүзнең чын мәгънәсен аңламыйсың да әле... йә, әйт, инглизчә хыянәт ничек була?

Ш ә р и ф җ а н (*кызарынып*). Белмим.

Р ә д и ф. Ачыгавыз син, Шәрифҗан.

И л ш а т. Кузгалыйк, өйдә эшләр дә бар.

Р ә д и ф. Киттек, малайлар.

З ә н ә. Малайлар, малайлар... Рәдиф, инде унынчы класста укыйсың, мыек үстерә башладың. Шулай да минем малай түгеллегемне аера алмыйсың, ахры.

Р ә д и ф. Гафу ит, Зәнә.

З ә н ә (*үчекләп*). Кая инде, безнең татар егетләре кызлар артыннан ухаживать итә беләләрме соң!

Ш ә р и ф җ а н. Синең кебек Одессага барып өйрәнеп кайтмаган!

Р ә д и ф. Зәнә, мин сине беренче класста ук күргән идем.

Илшат (*Рәдиф янына барып баса*). Мин дә, Зәнә.

Шәрифҗан (*сикергәләп*). Мин дә, Зәнә, мин дә!

Зәнә (*хәйләкәр генә елмаеп*). Син, Шәрифҗан...

Шәрифҗан (*ялварып*). Зинһар, бу крокодилларга сөйләмә, якты дөнья йөзен күрсәтмәсләр.

Зәнә (*исе китмичә генә*). Бишенче класста укыганда...

Шәрифҗан (*ялварып*). Кызган, Зәнә.

Зәнә (*аның саен тәм табып*). Көн саен хат яза идең. Чүп шигырьләр белән тутыра да тәнәфестә төртеп китә. Алтынчыда, алтынчыда...

Шәрифҗан. Эх, сер сөйләрлек кешеләрме болар?!

Зәнә. Апаңнан урлап пудра бүләк иткән идең.

Илшат белән Рәдиф егылып көләләр.

Зәнә. Нигә шул хатларның берәрсен сакламадым икән.

Рәдиф. Менә хәзер шәпләп укыр идек.

Шәрифҗан (*башта шашып тора да сабырлана*). Саттың мине, Зәнә. (*Тыныч.*) Тагын саттың. Хәтереңдәме, бишенчедә тәрәзә ваткач, укытучыга саткан идең. Яшелчәдә кишер урлагач, бригадирга саттың. Хәзер тагын.

Рәдиф (*кыюсыз*). Минем хатларны да сакламадыңмы, Зәнә?

Илшат (*көчен җыеп*). Минекеләрне дә?

Зәнә (*горур*). Анысы сер, малайлар.

Шәрифҗан (*ярсып*). Сер? Минем хатлар сер түгел, аларныкы серме? (*Рәдиф белән Илшатка.*) Буегыз шәп дип тормам, тукмармын да ташлармын... Боздык без сине, Зәнә. Ата-анаңның бердәнбер иркәсе. Класста да берүзең. Тәмам бозылдың. Күзгә карап кешене мыскыллый аласың. Одессадан кем яза? Морякмы? Купшыдыр, ахры, хатыннан хушбуй исе аңкый.

Зәнә (*кычкырып көлә*). Бусы да сер!..

Илшат. Казынма кеше күңелендә! Кузгалдыкмы? (*Китә башлыйлар. Илшат чокырлар янында туктала, яратмыйча карап тора.*) Әйдәгез, беренчедәге аксак песнәкләргә, ядкарь итеп, чокырларга тәмәке төпчеге тутырып китик. Барыбер чия үсәчәк түгел! (*Аяк очы белән төпчекләрне төшерә башлый. Рәдиф аңа булыша.*)

Рәдиф. Чия урынына сигарет үсеп чыксын. Бездән соң укыган малайлар тәмәке сатып алырга әниләренең күкәйләрен урлап интекмәсеннәр.

Җыйнаулашып бакчада төпчек эзләп йөриләр. Шәрифҗан баягы эскәмиягә менеп утыра.

Ш ә р и ф җ а н. Фригия патшасы Мидасны бервакыт Аполлон Алла үзенә дәшеп китергән.

З ә н ә. Юньсез булса сөйләмә.

Ш ә р и ф җ а н (*мут кына аңа карап ала*). Аполлон белән елгалар Алласы Марсий флейтада ярышмакчылар икән. Мидасны судья иткәннәр.

З ә н ә (*кызыксынып*). Аполлон җиңгәндер әле?

Ш ә р и ф җ а н. Шәбрәк уйнаган. Әмма Мидас елгалар алласы шәбрәк уйный дип хөкем чыгарган.

Р ә д и ф (*купшыланып*). Судьялар гомер-гомергә ялгышканнар.

Ш ә р и ф җ а н. Ачуы килгән Аполлонның. Мидас патшаның колакларын эләктереп алган да тарта-тарта ишәк колагына әйләндергән.

З ә н ә (*кулларын чәбәкләп*). Менә ичмасам җәза!

И л ш а т. Шәрифҗанда әкият бетмәс.

З ә н ә. Тик тор. Синең колакларыңа ишарә итми.

Ш ә р и ф җ а н. Мидасның серен чәч алучысыннан башка берәү дә белмәгән. Патша аңа кисәтеп куйган: «Ни-ни... югыйсә!» (*Муенын ышкып күрсәтә.*) Әмма сер тик ятарга ялратамы соң!

И л ш а т. Телен тыймас чәчтараш башсыз калганмы?

Ш ә р и ф җ а н. Бичара бәндә, чыдары тәмам беткәч, көннәрдән бер көнне аулак үзәндә чокыр казыган. Чокырга иелгән дә «Мидас патшаның колагы — ишәк колагы» дип пышылдаган. Серен чокырга күмгәч кенә азрак тынычланган, мескен.

З ә н ә. Шуннан, шуннан, Шәрифҗан?

Ш ә р и ф җ а н (*маймылланып*). Чокыр өстенә курай үскән. Көтүче шул курайны кисеп алган да уйнап җибәргән. Курай «Мидас патшаның колагы — ишәк колагы!» дип, серне бөтен дөньяга фаш иткән.

И л ш а т (*аларга якын килеп*). Мораль?.. Сереңне берәү белсә, ул сер булудан туктый.

З ә н ә. Әлләниләр беләсең син, Шәрифҗан.

Р ә д и ф (*көнләшеп*). Юри ятлый ич ул аларны.

З ә н ә (*аны үчекләп*). Тырышканы үзе өчен.

Ш ә р и ф җ а н (*серле*). Малайлар! Әй, Зәнә, син дә. Әйдәгез, бүген кара төн уртасында Гайд-паркка киләбез дә беркемгә дә әйтә алмаган серләребезне җир куенына тапшырабыз. Чокырлар әзер. (*Күрсәтә.*)

З ә н ә. Ә курай үсеп чыкса?

Ш ә р и ф җ а н. Колагың матур ла синең, Зәнә.

Р ә д и ф. Нәрсәгә кирәк инде?

И л ш а т. Мин килмим. Ташлагыз әле, бала-чага уены...

З ә н ә. Ну, Илшат. Ифрат кызык булачак. Кеше аяк

эзе басылгач... Кап-кара төн уртасында... Караңгы чокырга! Ух-х!

Илшат. Серләремне кешенең дә, җирнең дә белүен теләмим.

Шәрифҗан. Илшат, кил инде. Бу бакча — безнең Гайд-парк. Ни телисең, шуны сөйлисең.

Рәдиф. Кызыгын кызык бит, Илшат.

Зәнә. Барыбыз да киләбез. Чокырларны бүлешик. Иң кырыйдагы — минеке. Аннары, Рәдиф, сиңа. Бусы Шәрифҗанга.

Кәрим керә, аларның шау-шуын тыңлап тора. Аннары якынлаша.

Илшат. Тс-с, Кәрим килә!

Рәдиф. Мин ычкындым.

Шәрифҗан. Тукта, сүзе бардыр. Бергә китәрбез.

Кәрим. Туктагыз!

Укучылар тукталалар.

Сез китәсезмени?

Илшат. Өстән бурыч төште. (*Чокырларны күрсәтә.*)

Кәрим. Хәзер беренче класслар килеп җитә.

Рәдиф. Бик әйбәт! Килсеннәр дә агачларны шәпләп утыртсыннар, карасыннар, су сипсеннәр. Күр дә тор, алардан җәмгыять өчен файдалы кешеләр чыгар.

Кәрим. Рәдиф, син нигә минем дәресләрдән качасың?

Рәдиф. Йә бер эш килеп чыга, йә бер эш.

Кәрим. Нигә ул эш гел минем дәресләр вакытында табыла?

Рәдиф. Нәрсәгә ул миңа татар теле?

Кәрим. Ана теленнән мин сиңа икеле чыгарачакмын.

Рәдиф. Хакыгыз юк. Педсовет рөхсәт итмәс. Унынчы класслар аз-маз дәрес калдырганнар икән, йа Алла, җир җимерелеп төшкәнме әллә? Имтихан бирәсе фән түгел әле.

Кәрим. Мин сине класста утыртып калдырачакмын.

Рәдиф. Әгәр алай дип куйсагыз, карап карарбыз. Кем кемне җиңәр.

Кәрим. Син гаделлек белән көрәшергә уйлыйсыңмы?

Илшат. Нигә ул гына? Әгәр гаделлек дип деспотизм тәкъдим итәләр икән, монда әле без дә бар.

Шәрифҗан. Ягез инде, малайлар, җитәр. Куегызсана.

Рәдиф. Чыннан да, нигә талашып ятабыз әле. Киттек.

Кәрим. Сез миңа сүз бирдегез.

Илшат (*чокырларны күрсәтеп*). Кушканны үтәдек. (*Китәргә җыеналар.*)

Кәрим. Туктагыз, тукта! Сез нишлисез? Бу нинди тупаслык, кирелек?.. Сезнең янга дип нәниләр килә! Мин сезгә кетәргә кушам.

Рәдиф. Безнең мәктәптә унынчы классларны көчләмиләр!

Чыгалар. Иң ахырдан, артына карый-карый, Шәрифҗан бара. Кәрим башта катып кала, аннары сугылып арлы-бирле карана. Сүзсез генә җыр сузып Самат Гаязович керә.

Самат. Кыймылдасаң алга барасың. Байтак эш башкарганнар болар. Чокырлар әзер, көрәкләр, агачлар, су...

Кәрим. Алар киттеләр, аңлыйсызмы, йөземә сүз белән бәреп таралдылар!

Самат. Ничек? Хәзер беренче класслар килеп җитә.

Кәрим. Юк, нидер эшләргә иде, хәзердән үк чарасына керешергә иде!.. Алар мине бөтенләй аңламыйлар, ишетәсезме, Самат Гаязович, бөтенләй аңламыйлар.

Самат. Гафу итегез, директор буларак мин сезне баштарак искәртергә тиеш идем. Сез, Кәрим, бирєдә яңа кеше.

Кәрим. Ләкин эштә, тормышта мин яңа түгел ич!

Самат. Былтыр безнең мәктәпнең чирек гасырлык юбилее узды. Аның үзенә күрә традицияләре бар, гореф-гадәтләре...

Кәрим. Юк, юк, бу бит коточкыч! Күзләремә ышанмыйм, колакларыма. Йә, әйтегез әле, нәрсә бу? Нигә шулкадәр дошманлык?

Самат. Сез дилбегәне артык каты тартып җибәрдегез. Алай ук эшләмәгез... Соңгы еллары, алар бүген монда, иртәгә...

Кәрим. Ярый, бүгеннән башлыйк. Беренче классларга ничек аңлатабыз? Алар бит качып китте.

Самат. Бала-чагага берәр хәйлә табарбыз анысы...

Кәрим. Иң куркынычы: алар яхшы белән яманны аермыйлар!

Самат. Кайгырмагыз, мин сезне килештерү ягын үзем карармын.

Кәрим. Укучылар өстеннән жалоба белән йөри дип уйлый күрмәгез!.. Тик алар мине бөтенләй аңламыйлар!..

Чыгалар. Көлешә-көлешә Зәнә, Рәдиф, Илшат, Шәрифҗан килеп керәләр.

Рәдиф. Каян казып чыгарганнар бу Кәримне?

Илшат. Гомер узып бара, Верховный Советка сайламаганнар, орден бирмәгәннәр, менә шуңа бездән үч ала.

Зәнә. Сындырыйк дисәк, безгә бердәм булырга кирәк.

Шәрифҗан. Кая кереп качар тишек тапмасын!

Илшат. Яшәсәк, ireklerәк яшәп калабыз. Югары мәктәпкә эләгәсеңме, юкмы... Аннары армиягә...

Рәдиф. Раз-два!.. Раз-два!..

Илшат. Аннан тормыш камыты әзер тора.

Зәнә. Димәк, яшәп калыйк!

Хушлашалар. Рәдиф белән Зәнә бер якка китәләр. Шәрифҗан юлга кузгалган Илшатны дәшеп туктата.

Шәрифҗан. Илшат!.. Шулай да кызганыч.

Илшат. Хәзер һәммәсе майлагандай булачак. Күрерсең.

Шәрифҗан. Мин сине аның өчен туктатмадым.

Илшат. Нәрсә бар?

Шәрифҗан. Сатмаска сүз бирәсеңме?

Илшат. Әйтмәм.

Шәрифҗан (*Илшатны җитәкләп чокыр янына алып килә*). Бу Зәнә чокыры. Бүген төнге уникедә ул шуңа серләрен әйтәчәк.

Илшат. Таптың җүләрне.

Шәрифҗан. Әйтәчәк. Зәнәне белмисеңме әллә? Хәзер чокырны тирәнәйтеп куям. Икәү алданрак килик тә син мине шушы чокырга күмәрсең.

Илшат (*текәлеп аңа карап тора*). Яратасыңмы?

Шәрифҗан. Анысын мин сиңа үлгәндә дә әйтмәм. Тик мин Зәнәнең серләрен алырга тиеш. Күм мине, Илшат!

Илшат. Тере кешене җиргә күммиләр.

Шәрифҗан. Ә син мине күм. Күм мине, Илшат!

Илшат (*уйланып*). Син булмасаң, ул шикләнәчәк.

Шәрифҗан. Ә син киләсеңме?

Илшат. Болай булгач килермен инде. Тик син башка берәр хәйлә эзлә, Ромео!

Шәрифҗан. Эзләрмен. Табармын. Тик син кил, яме.

Чыгалар. Пәрдә төшә. Урам яктыра. Бакча ягыннан баягы балалар кайтып киләләр. Алар арыганнар, кайберләре фуражкаларын салып кулларына тоткан.

Укытучы (*һаман таштай йөз белән*). Тигез атлагыз, укучылар.

Укучылар (*хор белән*). Без арыдык, апа.

Укытучы. Балалар, без мәктәпкә кайтып күренергә тиеш.

Укучылар (*хор белән*). Без ачыктык, апа.

Укытучы (*көйләбрәк*). Анда сезне директор абыегыз көтә.

Укучылар (*хор белән*). Яңадан бакчага бармыйк, апа.

Укытучы. Олылар сүзен тыңларга кирәк.

Укучылар (*хор белән*). Нигә унынчылар тыңламаган?

Укытучы. Сафларның тигезлеген саклагыз!

Укучылар (*хор белән*). Без тигез бара алмыйбыз.

Укытучы. Ничә кат әйтергә мөмкин инде?

Укучылар (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез.

Чыгып китәләр. Кәрим аларны күз белән озатып бара. Караңгы урам. Кәрим бара да бара. Менә сул кырыйдагы йортта ут кабына. Кәрим аңа якын килә, тәрәзә шакый. Эчтән Гаян тәрәзә ача.

Гаян. Ходаем, боз явамы әллә? Ни тыкырдый? Хараплар булабыз бит. (*Кәримне абайлап.*) Син ник боз яудырып йөрисең? Кем син?

Кәрим. Боз яумый. Карагызчы, күк йөзе чалт аяз.

Гаян. Кем син?

Кәрим. Бу мин.

Гаян. Кунарга кертмибез. Үзебез ишле. Юлчылар да кайтып бетмәгән. Күрәсең ич, тәрәзәдә ут яна. Көтәбез.

Кәрим. Илшат өйдәме? Мин аларның яңа укытучылары Кәрим.

Гаян. Сиңа ни кирәк соң? (*Урамга чыга. Чиста киенгән, кечкенә генә, матур гына хатын. Бик җентекләп Кәримгә карап тора.*)

Кәрим. Менә танышырга килдем. Исәнмесез.

Гаян. Бакчада җирнең авызын син ачтырып куйдыңмы?

Кәрим. Мин.

Гаян. Алай боз яудырып кеше куркытып йөрмә. Әйбәтме әллә? Җирне сакла, җирне. Әнә укытучы дисең бит. Кәрим атлымы әле? Син чыннан да минем улымны сагынып килдеңме?

Кәрим. Әйе.

Гаян. Чын сөйлисеңдер, әнә бит көлеп торасың.

Кулына сөтле чиләк тоткан Илшат күренә.

Илшат. Әни!.. (*Тукталып.*) Кемнәр бар монда?

Кәрим. Бу без, Илшат. Менә әниең белән сөйләшәбез...

Илшат (*югалып калып, җәберсенеп*). Кәрим абый?.. Әни, бар, өйгә кер, әни. (*Йомшак кына сөеп, иркәләп әнисен озата.*)

Гаян. Сыерны саудыңмы, улым?

Илшат. Саудым, әни, саудым.

Гаян. Керәм, улым, керәм. Син булмасаң нишләр идем? Колакларым шаулап тора. Һавалар бозылырга булмасын. (*Кереп китә.*)

Кәрим. Бозылмас, һавалар бик матур тора.

Илшат. Мин сезне тыңлыйм.

Кәрим. Нигә өегезгә чакырмыйсың, Илшат?

Илшат (*кырыс*). Өйгә? (*Барып тәрәзәне ябып килә.*) Монда да сөйләшергә була ич. Урын бар. (*Кәрим капка янындагы утыргычка барып утыра.*)

Кәрим. Әниең сине бик ярата, ахры?

Илшат. Әнигә тимәгез!.. Начарлыгым бар икән, үзем җавап бирәм. Үзем. Әти... Әнә кашлакта, зиратта... фашист снаряды ярчыгын күкрәгендә егерме бер ел йөртте. Сочинение өчен ачуланырга килдегезме?.. Мин язмадым. Башкаларга да язмаска мин куштым. Әнинең монда ни катнашы бар? Әгәр үз иптәшләремне бакчадан алып киткәнмен икән, моңа әни гаепleme?

Кәрим. Бетердеңме?

Илшат. Нәрсәгә барын да әйтеп торырга? Без бала-чагалар түгел. Без бүген монда, иртәгә...

Кәрим. Иртәгә кайда?

Илшат. Анысын күз күрер.

Кәрим. Шул куркыта да мине! (*Тавышын бераз күтәрә төшеп.*) Сез бүген генә монда. Иртәгә кайда сез, минем укучыларым... Тик хәзер нәкъ шуның өчен килгән дип уйлама. Син миңа сөйләргә дә ирек бирмисең. Бая бакчада да...

Илшат. Нигә килдегез соң?

Кәрим. Утыр син, утыр. Чиләгеңне дә куй... Тын гына утыр. Минем синең янда тын гына утырасым килә. Мин синең ни уйлавыңны беләм. Кыланганыңны карап торырга монда тамашачылар юк. Дәшми тор, түз. Чынлап барыбер сөйләшмәссең, ялганыңны ишетәсем килми. (*Пауза.*)

Илшат. Сочинение язмадык шул... Кырык җиденче елны, мин күкрәк баласы чакта, авылда ачлык булган. Язын бик күп кешеләр кырылганнар. Яңа иген өлгерүен җан атып көтеп торганнар. Башаклар пешкән. Әниләр урак тотып тау өстенә менгәннәр. Шунда беренче учмаларны ура башлагач та давыл чыгып яңгыр килгән. Боз сугып бөтен басуларны харап итеп бетергән. Шуннан бирле безнең әни...

Тәрәзә ачыла. Анда чәчләре сибелеп киткән Гаян күренә.

Гаян. Һавалар ничек, улым? Болытлар кабармыймы?

Илшат. Юк, әни, күк йөзе чалт аяз. Йокла, әни, ял ит... Син арыгансыңдыр... (*Барып тәрәзәне яба.*)

Кәрим. Синең әниең изге кеше, Илшат.

Илшат (*кычкырып диярлек*). Тик күңелеңдәгене

бөтен кешегә дә сөйләп йөреп булмый бит!.. Башкалар өчен ул нибарысы... Гомумән, кешеләр бер-берсеннән көләргә яраталар.

Кәрим. Аның изгелеген үзең белгән дә бик җиткән. Кешеләрнең яхшылыгын белү минем үземә җан рәхәте китерә.

Илшат. Җылы сөт эчәсезме? (*Сөт салып бирә.*)

Кәрим. Рәхмәт.

Илшат. Сөзелгән сөт, курыкмыйча эчегез.

Кәрим. Кулыңа куан, Илшат. Сөтегез бик тәмле.

Илшат (*басып тора*). Сез миннән көлмисезме?

Кәрим. Нигә көлим, Илшат!

Илшат. Өй җыештырырга өлгермәдем бүген... Безнең бит кечкенәләр дә бар...

Кәрим. Мин сиңа карап сокланам.

Илшат. Тагын эчәсезме? Сөтне бик яратам мин. Савып кергәч тә ике чокыр тутырып эчәм.

Кәрим. Рәхмәт... Йә, хуш... Хуш. Сөтегез бик тәмле булды, Илшат. (*Чыгып китә.*)

Тәрәзәдә Гаян күренә.

Гаян. Кайда теге ямьсезкәй?

Илшат. Кайсы?

Гаян. Тәрәзәгә боз яудыра торган. Ул чыннан да сине эзләп килгәнме?

Илшат. Белмим.

Гаян. Сүзем бар иде аңа, бер сүзем...

Илшат (*тәрәзәне барып яба*). Әни, бар, ял ит. Ял ит.

Ут сүнә. Кәрим урам буйлап бара да бара. Икенче йортта ут кабына. Капка алдындагы урындыкта Рәдиф гитара уйный. Кәримне күреп сискәнеп китә.

Рәдиф. Кәрим абый?

Кәрим. Мин сезгә килә идем.

Рәдиф. Менә ул безнең өй.

Кәрим. Күргәнем бар. Кызыгып үткәнем бар. Бизәкле кәрнизләр. Тәрәзә нәличникләрендә арысланнар. Болдыр баганаларында калканлы сугышчылар.

Рәдиф. Әти шунда, эш юктан эш таба. Сугыштан кайтканнан бирле әллә ниләр ясый да ясый.

Кәрим. Солдатмы?

Рәдиф. Солдат.

Кәрим. Кайда сугышкан?

Рәдиф. Тәгаен генә белмим. Беренче Украинскийда дидеме...

Кәрим. Без бер фронтта булганбыз. Өйдәме үзе?

Р ә д и ф. Юк. Түбән очта бер тол карчыкка өй күтәрәләр... Сез әләкләргә уйлыйсызмы? Кәрим абый, әтигә бер сүз дә әйтмәгез. Ул бик борчылучан. Хәер, әйтегез! Әйтегез!

К ә р и м (*гитарага күрсәтеп*). Уйныйсыңмы?

Р ә д и ф. Чиртәм.

К ә р и м. Яле, уйнап күрсәт.

Р ә д и ф. Читенсенәм. Өйрәнчек кенә бит мин. Татар көйләрен белмим дә.

К ә р и м. Солдат... Днепр кичәргә мин сине түгел, ә этиеңне юлдаш итеп сайлар идем. Болдыр баганаларын калканлы сугышчылар белән бизәгән солдатны. Төннәрен дә өмәләрдә йөри торган солдатны. Польша, Германия кырларында разведкага йөргәндә дә мин аны иптәш итәр идем. Юк, сине алмас идем... Ә кайчан исә бер кемгәдер сине иптәш итәргә туры килер. Турылык сыналганда, халык авырлык кичергәндә син дә кемнеңдер юлдашы булырсың... Шунда синең иптәшең безне, безнең халыкны, сине укытып чыгарган кешеләрне нинди сүзләр белән телгә алмас?!

Р ә д и ф. Мин олы юл басарга җыенмыйм.

К ә р и м. Үз телен сөймәгән ир үз илен сөймәс. Үз илен сөймәгән ир кем була?.. Мин сораганда җавап бирми дә кала аласың. Качарга да осталыгың җитә. Бервакыт шуны синнән ил сорар. Шул вакытка әзер бул! (*Чыгып китә.*)

**Ярсып уйнаган гитара тавышы. К ә р и м урам буйлап бара да бара. Өченче йортта ут кабына. Тәрәзә каршысында Ш ә р и ф җ а н ашыгып-ашыгып магнитофон ремонтлый.**

К ә р и м (*якын ук килеп карап тора*). Эшлисеңме?

Ш ә р и ф җ а н (*сискәнеп*). Үзегез кушканга гына, Кәрим абый. Әллә кайчан әйткән идегез...

К ә р и м. Бүленмә, бүленмә. Эшлә. Әле Рәдифләрдән килешем. Илшатларга да кагылдым.

Ш ә р и ф җ а н (*бик шикләнеп*). Илшат берәр сүз әйттеме әллә?

К ә р и м. Илшат тынмый, эшли...

Ш ә р и ф җ а н (*кабынып*). Рәдиф берәр нәрсә чаккандыр әле. Беренче класстан атаклы әләкче. Гитара тагып кызлар кызыктырып йөри. Кызлар тәкәсе!

К ә р и м (*таң калып*). Мин синең бу сүзләреңне ишетмәдем.

Ш ә р и ф җ а н (*аптырап*). Ник?.. Алайса, нигә киләсе иттегез соң? Бездә укытучылар өйгә килеп йөрмиләр. Авыл ич бу!

К ә р и м. Бүгенгедән соң мин тыныч кына өйгә кайтып китә аламмы, ә?.. Көндез дә, кич тә, төнлә дә мин сезне күрергә, сезнең белән булырга телим. Шул ич инде минем яшәешемнең мәгънәсе, черт возьми!.. Ә син эшлә, эшлә! (*Чыгып китә.*)

Ярсып уйнаган гитара тавышы. Шәрифҗан тиз-тиз магнитофонын җыештыра. Р ә д и ф керә. Кулында гитара.

Р ә д и ф. Нишләп йөри ул?

Ш ә р и ф җ а н. Кем белгән аны. Шпион кебек караңгыдан килеп чыккан да чекерәеп тора. Әйтерсең лә мин берәр яшерен эш белән маташам.

Р ә д и ф (*гитарасын чиртә*). Мине җене сөйми. Илшаттан көлә. Егет башы белән сыер савып, аш пешереп ята, ди. Сине «җебегән» диде.

Ш ә р и ф җ а н. Аңладым: безне ызгыштырмакчы була! Аннары берәм-берәм иярләү җиңел булачак дип уйлый.

Р ә д и ф. Сөенеп кенә укып ятканда, яшәү күңелсез булып китте.

Ш ә р и ф җ а н. Әйттем, китик Бөрлегән мәктәбенә, дидем. Ичмасам, бокска өйрәнер идек. Район чемпионы аларда.

Р ә д и ф. Оста! Мине котыртып җибәреп, үзең монда калыргамы?

Ш ә р и ф җ а н. Бик кирәгең бар иде. Беләсең килсә, Кәрим сине кызлар тәкәсе, диде. Гитара күтәреп кызлар кызыктырып йөри, ди.

Ут сүнә. Уң кырыйдагы йортта ут кабына. Верандада, иңенә йомшак шәл ябынып, кәнәфидә З ә н ә китап укый. Бүлмәдән Г ө л с е м чыга.

Г ө л с е м. Кызым, синең дәресләрең ничек? Унынчыда укуыңны онытма.

З ә н ә. Әти директор бит әле. Һәм минем белүемчә, үз постыннан китәргә дә җыенмый. (*Киерелеп ята.*)

Г ө л с е м. Әдәпсез кыланма!.. Кәрим сезнең класстан бик борчылып чыкты. Сочинение язмадыгызмы?

З ә н ә. О, күрсәң иде анда ниләр булганын...

Г ө л с е м. Укытучыдан, өлкән кешедән көләсеңме?

З ә н ә. Нәрсә дип языйм? Алдап утырырга иренәм, ә дөресе Кәримгә нәрсәгә?

Г ө л с е м. Ни бар, шуны яз идең.

З ә н ә. Бернәрсә дә юк! Безнең мәктәптә дә, өйдә дә тып-тын. Ничего не происходит! Ичмасам, әти белән пыр тузышып бер ызгышсагыз икән. Мин белә-белгәннән бирле кеше төсле бер талашканыгыз да юк.

Г ө л с е м. Талашыр сәбәп юк, шуңа күрә тын яшибез... Син кешеләрдә гел яманлык кына эзлисең.

З ә н ә. Яратмаганың бер мин булдым инде, әни.

Г ө л с е м. Киресенчә түгелме икән?.. Бала үсә-үсә бөтен авырлыкларны күтәрергә өйрәнә, тик ата-ананың артык мәхәббәтен генә күтәрә алмый, диләр.

З ә н ә. Бөтенесе ялган!.. Барыгыз да әкәм-төкәм кебек качып-посып яшәргә җайлашкансыз. Син дә, Кәрим дә... Кыланчык. Мин булдыра алсам циркта эшләр идем. Һава гимнасты булып. Менә анда бөтенесе чып-чын. Мең кеше күз алдында.

Г ө л с е м. Тагын кәефемне җибәрдең.

З ә н ә. Әни, ызгышмыйк әле шул Кәрим өчен.

Гөлсемне үбә, Гөлсем башын чайкап кереп китә. Зәнә китап укырга утыра. Ишек шакыйлар. К ә р и м керә.

К ә р и м. Хәерле кич, Зәнә.

З ә н ә. Әти кайтмады әле.

К ә р и м. Хәерле кич.

З ә н ә. Хәерле кич. Өйгә узыгыз. Әни өйдә.

К ә р и м. Синең янда утырыйм әле. (*Утыра.*) Һаман укыйсың үзең.

З ә н ә. Монда, авылда, шул китап укысаң гына инде.

К ә р и м (*китапка карый*). Пастернакмы? Ошыймы?

З ә н ә. Ошый. (*Пауза.*) Сез мондый җавап көтмәгән идегезме?

К ә р и м. Бу җавап артык кыска.

З ә н ә. Пастернакны шагыйрьләр шагыйре, диләр. Осталарның остазы. Ә мин укыйм да аңламыйм. Кат-кат укыйм, барыбер аңламыйм. Шуңа күрә ошый. Анда сер бар кебек, яшерен сер. Белмәгән сүзләре дә юк, ә мәгънәсе читтә кала. Туктыйм да үз-үземне табалыйм.

К ә р и м. Нигә?

З ә н ә. Без монда «Кәҗә белән Сарык» әкиятен ятлап йөргән арада, Пастернакларны аңлый торган кешеләр туган. Яңа буын. Яңа кешеләр. Алар барын да беләләрдер, барын аңлыйлардыр. Аларга яшәү дә җиңелдер. Ничек табаламассың...

К ә р и м. Шулай анысы...

З ә н ә (*үтә гаҗәпләнеп*). Сез минем белән килешәсезме?

К ә р и м. Әлбәттә! Синең кызыксынуың, үзеңнән ризасызлыгың, үзенчә уйлавың миңа гаҗәп ошый... Синең кайбер иптәшләрең кыланырга, уйнарга яраталар...

Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Бу этиең озаклады түгелме? Кунак бар икән. Кәрим, менә рәхмәт. Хәзер аш өлгертәм.

К ә р и м. Рәхмәт, рәхмәт. Озакка кермәдем.

Г ө л с е м. Рәхмәте соңыннан. Сез ялгыз кеше. Болай да аптырап йөрим, нигәдер безнең өйне чит итәсез. (*Караңгылыктан кемдер сызгыра.*) Кем йөри ул анда?

З ә н ә. Курыкма, мине урларга йөрмиләрдер.

Г ө л с е м. Мин сезнең сүзне бүлмәдемме?

К ә р и м. Мине юк... Сездән яшерен серем юк, Гөлсем ханым. (*Зәнәгә карый.*)

З ә н ә. Без тормыш турында сөйләштек.

Г ө л с е м. Ничек? Син ул турыда сөйләшергә яратмыйсың бит.

З ә н ә. Бүген сөйләштек инде.

К ә р и м. Тормышта уйланып эшләү, аңлы рәвештә яшәү мактаулырак. Шулаймы, Зәнә?.. Ярар, мин китим инде.

Г ө л с е м. Аш янында...

К ә р и м. Башка вакытта керермен әле, Гөлсем ханым. Бүген түгел. Рәхмәт. Хушыгыз. (*Чыга.*)

Гөлсем ханым аны озата. Зәнә китабын атып бәрә дә сузылып ята.

З ә н ә. Сөйләшербез, ди. Әгәр көн саен килеп, нәрсә укыганга кадәр тикшереп, вакчылланып йөри башласа...

Г ө л с е м. Ул сезнең белән дуслашырга тели.

З ә н ә. Минем аз гына горурлыгым, мин-минлегем булса, аның урынында бу мәктәпне ташлап качар идем! Нәрсә генә әйтмәдек без аңа бүген!

Тагын ярып сызгыралар.

Г ө л с е м. Бәлки, аны мин-минлегеннән олырак, көчлерәк хис тотадыр? Кызым, олы кешегә ничек телегез барды?

З ә н ә. Һәр олы кеше — акыл капчыгы дигән сүз түгел... Йә, бар, минем укып бетерәсем килә.

Г ө л с е м. Тупас син, кызым! (*Кереп китә.*)

Зәнә тора. Ишеккә бара.

З ә н ә. Монда килегез!

Р ә д и ф белән Ш ә р и ф җ а н керәләр.

Р ә д и ф. Хәерле кич, Зәнә.

З ә н ә (*каршыларына барып бөеренә таяна*). Төчеләнмә. Тапканнар әмәл. Эт чакыралармыни?!

Шәрифҗан (*иснәнеп*). Тавык шулпасы. Тагын пәрәмәч... Тозлы гөмбә. Ух-х... Ә без иртәгә каз суябыз.

Рәдиф (*Шәрифҗанга төртә*). Гитара белән килмәкче идек.

Зәнә (*кәнәфигә барып утыра*). Мужиклыгыгыз берәр чыгармы инде, юкмы.

Шәрифҗан (*юаш кына утыра*). Графлар да сызгыра белгәннәр.

Зәнә (*китабыннан аерылып*). Нигә болай иртә килдегез?

Рәдиф (*шундук аның янына барып җитә*). Кәрим килеп кәефне кырып китте.

Шәрифҗан. Яхшымы-яманмы, мәктәп тыныч кына яши иде. Безнең башны бутаучы да юк иде.

Рәдиф. Зәнә, әтиең директор бит. Азрак шуны файдаланып булмыймы?

Зәнә. О, юк. Әти белән без хәзер тегенди-мондый вак-төякне генә сөйләшәбез.

Рәдиф. Өйдә гел бергә буласыз. Бер җаен тап инде.

Зәнә. Шымчы да, димче дә була алмыйм. Пакь яшисем килә.

Шәрифҗан (*сикереп тора*). Мин өйгә кайтам!

Рәдиф. Ничек? Син безгә икәү генә йөрергә рөхсәт итәсеңме?

Шәрифҗан (*блокнотыннан бер бит ертып бирә*). Төнге уникегә кадәр пропуск.

Зәнә (*чөйдән плащын алып кия*). Үкенерсең, малай.

Шәрифҗан (*хәйләкәр генә елмая*). Нишлисең инде!.. Тик бакчага соңга калмагыз.

Рәдиф. Үкенсен, тәгәрәп җыласын.

Зәнә. Эндәшмә аңа. (*Ишекне ачып кычкыра.*) Әни, мин йөреп киләм. (*Чыгалар.*)

Гөлсем верандада күренә. Төрлесе-төрле җирдә аунап яткан әйберләрне җыештыра, Зәнәнең китабын алып куя. Бераздан, сүзсез генә җыр көйләп, Самат керә.

Гөлсем. Их, шул җырыңның сүзе дә булса кана!

Самат. Сүзсез җыр синең өчен яңалык түгел. Унтугыз ел ишетәсең.

Гөлсем. Бүгенге кебек соңга калып кайтканда, синең җырыңның сүзләре җитми!.. Мин синең кәефеңнең ничеклеген белер идем. Сагынып кайтасыңмы, әллә болай...

Самат. Кәефне белгән юк әле. Өең җыештырганмы?

Гөлсем. Районнан тагын берсе килгән!

Самат. Көтмәгәндә инспектор килеп төште.

Гөлсем. Колхозның менә дигән кунак йорты бар. Нигә шулкадәр түбәнсенәсең?

Самат. Эшләп ашый торган замана бит, әнисе. Йә, йә, табынныңның хәстәрен күр.

Гөлсем бүлмәгә кереп китә. Марат Кәримович керә. Самат аны каршы ала, чишенергә ярдәмләшә.

Марат. Бу верандагыз элекке килүемдә юк иде шикелле.

Самат. Җәй өчен бик уңай дип әле генә эшләтеп алдым.

Марат. Яши беләсез, Самат Гаязович. Тәмләп яшисез!

Самат. Яхшы сүзегезгә рәхмәт.

Марат. Бая укытучылар алдында сорарга базмадым. Безнең Кәрим абый ничегрәк?

Самат. Ничек дип, сез бит аны миннән яхшырак беләсез.

Марат. Безнең районга килеп төшкәч тә минем янга керде бу. Яшерен-батырын түгел, каушап калдым. Сизенәм, кая гына җибәрсәм дә мәктәпнең дә, безнең дә башны бутаячак.

Самат. Электән үк шулай идеме?

Марат. Безне укытканда ук бөтен җиргә тыгылып, тыкшынып йөргәнен сизенә идек. Ә күбесен соңыннан акыл, тәҗрибә белән аңладым.

Самат. Унынчылар белән ничектер йогышып бетмиләр...

Марат. Унынчылар дигәннән, сезгә килүемнең төп максатын әйтеп өлгермәдем.

Самат. Буш кул белән йөрмисездер дип уйлыйм.

Марат. Без сездә унынчы классны бетерергә булдык. (*Пауза. Самат дәшми.*) Дүрт бала өчен класс тоту, үзегез уйлап карагыз, кадерле Самат Гаязович, экономик яктан һич тә акланмый.

Самат. Моны көтәргә була иде. (*Пауза.*) Укучылар кызганыч.

Марат. Аларны Бөрлегән мәктәбенә күчерәбез. Формаль якларны хәл итүгә, туп-туры шунда китәм.

Самат. Утыз чакрым. Җитмәсә, юллар нинди.

Марат (*тегенең хафасын аңлады*). Анда менә дигән интернат бар.

Самат (*өметләнеп*). Укытучыларның хезмәт хакына нык сугачак.

Марат. Каешларны кысыбрак буарга туры килер.

Самат (*иң соңгы дәлиленә тотынды*). Ә Кәрим? Ул аларның класс җитәкчесе.

Марат. Унынчылар белән килешә алмады дидегез түгелме?

Самат. Хәер, алардан котылуына Кәрим шатланачак кына. Әйтмәм дигән идем... Ничектер үзара йогышмадылар алар, Марат Кәримович!

Гөлсем керә.

Гөлсем. Исәнмесез, Марат Кәримович. (*Күрешәләр.*) Безнең якларны онытып бетермисез тагын.

Марат. Яхшы кешеләрне очраштырырга дөнья үзе сәбәпләрен табып тора, Гөлсем ханым.

Гөлсем. Рәхим итегез, аш әзер.

Самат. Әйдәгез, Марат Кәримович. Баш казанын нык эшләттек, ашказанына сүз бирик. (*Көләләр. Кереп китәләр.*)

Пәрдә. Авансцена яктыра. Рәдиф белән Зәнә керәләр. Рәдифнең кулында гитара. Ул уйный-уйный бераз арттанрак килә.

Зәнә. Җырлый белмим. Биер урын юк.

Рәдиф. Мин аны яңа гына өйрәндем. Радиодан тапшырдылар.

Зәнә (*көлеп җибәрә*). Нәрсә? Якынрак кил. Ашамыйм. Куян ите яратмыйм.

Рәдиф. Тинтәклегемне үзем дә сизәм. Әлләниләр әйтердәй булам, шул чакта гына артымнан Шәрифҗан килеп чыгар төсле.

Икесе дә борылып карыйлар. Артта чыннан да Шәрифҗан тора.

Зәнә. Ул! Молодец, Шәрифҗан!

Рәдиф. Менә! Әйтмәдемме? Тыңланып килә.

Шәрифҗан. Нәрсәңне тыңлыйсың? Гитарада уйный белмисең, сүзеңнең рәте-башы юк, шигырьләреңне район газетасы да басмый.

Зәнә. Синнән башка күңелсез икән, Шәрифҗан. Көлдер мине. Уйлап тап бирер нәрсә.

Рәдиф (*гитарасын чиртә*). Ут белән уйныйсың, Зәнә.

Зәнә. Миңа уналты яшь тулган инде... Көлдер мине, Шәрифҗан!

Шәрифҗан. Үзем дә көләргә яратам. Тик иң актыктан.

Рәдиф. Зәнә, атаклы цирк артисткасы булып китсәң, клоун итеп Шәрифҗанны алырсың.

Шәрифҗан. Син циркка килсәң, маймылны котыртып синең мыегыңны йолкытам!

Зәнә кычкырып көлә. Рәдиф гитарасын чиртә. Пәрдә күтәрелә. Бакча. Төн. Этләр өрә.

Р ә д и ф. Зәнә, сак бул, көлдереп җылатмасын.

Ш ә р и ф җ а н (*караныт*). Илшат киләме соң?!

З ә н ә. Мужик.

Р ә д и ф. Кайтыйк булмаса, йокы килә.

Ш ә р и ф җ а н. Бер генә көй уйна инде. Син шактый остардың бит, малай.

З ә н ә. Көтик.

Р ә д и ф. Үз тирәңдә бер взвод егет тотарга яратасың.

З ә н ә (*көлә*). Нахал.

Ш ә р и ф җ а н. Синең чокыр иң тирәне икән, Зәнә. Серләрең күп булганга инде ул. Сыярмы?

З ә н ә. Хәзер монда тып-тын гына утырырга кирәк.

Р ә д и ф. Йокы килә.

Ш ә р и ф җ а н. Коткы таратма әле! (*Төртеп җибәрә.*)

Р ә д и ф. Гитараны ватсаң, бишләтә түләтермен.

З ә н ә. Тыныгыз, дим!

Менә йөгереп диярлек И л ш а т керә.

И л ш а т. Егетләр!

З ә н ә. Тавышы...

И л ш а т. Мин куркам. Кинәт җир убылып төшеп китәр төсле.

Ш ә р и ф җ а н. Убылса, аста нефтьтән башка бернәрсә дә юк.

Р ә д и ф. Тотышабыз. (*Җирдән бер таяк табып ала.*) Кем очка чыга, шул беренче.

Тотышалар.

Ш ә р и ф җ а н. Гомергә бәхетем булмады. Буй теләдем, Ходай буй бирмәде. Акыл сорадым, анысын да мыскаллап кына тамызды.

И л ш а т. Чокырга сөйләргә серең каламы синең?

Р ә д и ф. Мин икенче.

З ә н ә. Илшат иң актыкка. Чиратларны алышмыйбызмы?

Ш ә р и ф җ а н. Юк инде, юк.

Р ә д и ф. Башла алайса. Сәгать нәкъ унике.

И л ш а т. Әфәнделәр, Гайд-парк ачык. Телеңә ни килә, җаның ни тели, күңелеңдә нәрсә бар!

Ш ә р и ф җ а н. Тыңлап тормагыз.

З ә н ә. Исебез китә. Кеше сере кешегә нәрсәгә?

И л ш а т. Шулай да мин куркам... Күңелне нидер тырный...

Ш ә р и ф җ а н. Ераккарак, ераккарак! (*Тегеләр күренмәс булалар. Шәрифҗан иң элек Зәнә чокыры янына*

*барып нидер эшләп килә. Аннары үз чокыры өстенә иелә.*) Серләр, уйлар, теләкләр... Ах, минем кодрәтем булса! Мең ысулын, миллион хәйләсен табар идем — Зәнәне үземә каратыр идем!.. Нишлим, ниләр кылыйм... Илшат белән Рәдиф шаккатып тәгәрәп егылсыннар иде!.. Нигә ул шулкадәр горур, чибәр, иркә?! Ә мин ник шулхәтле гади... Нигә аның тәсле була алмыйм мин? Нигә яратмый ул мине... Мең кодрәтем булсын иде! Ул чагында матур Зәнә, сылу Зәнә... (*Пышылдый. Күтәрелә. Карап тора.*) Бетте.

Илшат. Җир упмадымы?

Зәнә. Шулай тизме?

Рәдиф. Финита?

Шәрифҗан. Рәдиф, хәзер синең чират. Чокырыңны буташтырма. Югыйсә безнең серләр сөзешеп ятырлар.

Рәдиф (*усал*). Өйрәтмә. Читкәрәк таегыз. (*Башкалар югалуга нык кына җиргә тибеп ала.*) Җир, әй, җир! Кәримне олактыр моннан, җир!.. Тугыз ел көтеп торган матур вакытымның ямен җибәрә... Үзем дә моннан китсәм иде. Шушы якларга әйләнеп кайтмасам иде. Атаклы, зур кеше булу җаен табасы иде. Инде ул чагында миңа Зәнә дә кирәкми. Чамасыз назлы, иркә авыл кызы ич ул! (*Нилэрдер мыгырдап чокыр тирәли йөгереп йөри, иптәшләренә кычкыра.*) Килегез!

Зәнә. Ну, кызык. (*Дулкынланып.*) Хәзер минем чират.

Рәдиф. Минем сүзләр ишетелмәдеме?

Шәрифҗан. Зәнә, менә синең чокыр.

Зәнә. Якын йөрмәгез. Шәрифҗан, син кая барасың?

**Агач төбендә нидер эшләп маташкан Шәрифҗан торып китә.**

Шәрифҗан. Ярамыймы? Киттем. (*Югалалар.*)

Зәнә (*чокыр янына утыра. Этләр өрә. Тынлык*). Кызык һәм куркыныч. (*Пауза.*) Нигә бу дөнья шулай буталчык яратылган? Нигә кешеләр бер-берсенә бөтенләй охшамыйлар. Шәрифҗан — аңгыра, Илшат — мужик, Рәдиф — мактанчык... Әти яшертен генә акча җыя. Нигә? Җүләр! Мин җыймас идем, әллә кайларда йөреп туздырыр идем. Дөнья матурлыгын карап кына, ваемсыз гына... О, беркөн уянам да тәрәзәдән карыйм: яңа тормыш башланган... Кешеләр буталышып бер-берләрен борчымыйлар. Иртәгә кара көн килер дип куркып тормыйлар... Кәрим җүләр... Безнең мәктәптә берәр нәрсә үзгәртеп булыр дип уйлый, ахры. Надан укытучылар, аңгыра укучылар. Сөймим мин аларны, сөймим, сөймим!.. Кәрим буталып йөрмәсә, мәктәпне алтын медаль белән тәмам-

лыйм. Нигә мин җырлый белмим икән? Кешеләрне акылыннан шаштырыр идем, котыртыр идем.

Рәдиф үрмәләп кенә аңа якынлаша, Зәнә аны күреп сикереп тора.

Әшәке малай, бүлдердең ич!

Рәдиф. Чакырып кул изәдең дип торам.

Зәнә. Йодрык күрсәттем.

Рәдиф. Илшат, кыскарак тот.

Шәрифҗан. Тизрәк, Илшат, тизрәк!

Илшат. Ярый. (*Тегеләр югалалар.*) Менә без дә үсеп егет булдык... Күз алдыбыздан күпме укытучылар үтте! Без дә бик күпләрнең күз алдыннан уздык... Берәүләре безнең директор Самат Гаязович төсле. Икенчеләре Кәрим кебек... Фу, шайтан, кайсысының безнең өчен файдалырак икәнен аера да алмассың. Кәрим кебекләр булдылар да югалдылар, ә Самат Гаязович һаман директор. Яшим дисәң, ертлач булма!.. Ә нигә без ертлачландык әле? Нигә безнең Кәримне җиңәсебез килә?.. Әллә безне бозганнар, әллә үзебез бозылганбыз... Яшәү ничектер кыенрак булып китте!.. Уйлап яшәү авыррак. (*Тора, шыпырт кына.*) Җиттеме, малайлар?

Зәнә. Әйдәгез, хәзер тотаклашабыз да чокырлар тирәли шыпырт кына әйләнәбез.

Шәрифҗан. Ярар инде, җиткән.

Рәдиф. Юк инде, әйләник.

Илшат. Баткан аяк чыланган!

Кулга-кул тотынышып, кыргыйлар кебек сикергәли-сикергәли әйләнәләр. Зәнә нәрсәгәдер абынып чуалып егыла. Рәдиф аны торгыза.

Рәдиф. Авырттымы?

Зәнә. Нәрсә бу, малайлар?

Илшат (*капшап бара*). Тимерчыбык.

Рәдиф. Электр чыбыгы булмасын.

Зәнә. Минем чокырга төшеп китә.

Рәдиф. Кая әле. (*Чокырны караштыра.*) Зәнә, синең чокырда микрофон!

Шәрифҗан. Юктыр ла!

Рәдиф (*чокырдан чыбык буйлап бара*). Монда магнитофон куйганнар!

Илшат (*Рәдиф янына бара*). Эшләп утыра.

Шәрифҗан (*үкереп җибәрә*). Кагылмагыз, шартлый!

Зәнә. Шәрифҗан куйган! Рәдиф, тот үзен, эләктер.

Шәрифҗан. Тотмый торсын әле. (*Магнитофон лентасын йолкып алып уктай атылып чыгып китә.*)

Рәдиф. Лентаны эләктерде!

Зәнә. Тот!

Рәдиф Шәрифҗанны куып китә. Зәнә чүгәләп елый.

Илшат. Тукта! Әгәр анда минем сүзләр дә язылган булса?..

Зәнә. Сезнең белән... Сезнең белән... Хайваннар. Нәфрәтләнәм. Күралмыйм... Сөймим, берегезне дә яратмыйм. (*Инәлеп.*) Рәдиф, Рәдиф, тот шуны, кыйна бер, каны чыксын, җаны. Ух, хайваннар!..

Ярсып-ярсып этләр өрә. Илшат, исе китеп, Зәнәгә карап тора. Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче көн. Беренче класс укучылары, рәт-рәт тезелешеп, бакчага баралар. Сафларда һаман тәртип юк. Иң алдагы баланы җитәкләп тагын да кырыслана төшкән кап-карадан киенгән укытучы ханым бара. Укучылар күңелсез.

Укытучы. Балалар, сафларның тәртибен саклагыз.

Укучылар (*хор белән*). Көн дә, көн дә бакчага барабыз.

Укытучы. Сезне анда унынчы класс укучылары көтә.

Укучы (*күңелсез*). Безнең Рәдиф абый...

Укучы (*бик күңелсез*). Ә безнең Шәрифҗан абый анда юк.

Укучылар (*шаулашалар*). Безнең Сәрвиназ апа да! Минем дә!

Укытучы (*ярсып*). Гөжләмәгез, шауламагыз! Тыныгыз чыкмасын!

Укучылар (*хор белән*). Аларны алдашырга кем өйрәткән?

Укытучы. Алдашкан өчен аларга бик каты чара күреләчәк.

Укучылар (*хор белән*). Нәрсә ул чара?

Укытучы. Кыскасы, аларга сизелерлек җәза биреләчәк.

Укучылар (*хор белән*). Нәрсә ул җәза?

Укытучы. Чарасын да, җәзасын да үсә төшкәч татырсыз.

Укучылар (*хор белән*). Алайса, нигә үсеп торырга?

Укытучы (*борылып*). Җәзаны да белмисезме?

Укучылар (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез.

Рәт-рәт булып, буталышып чыгып китәләр. Пәрдә ачыла. Бакча. Шул ук урын. Көн бераз сүрән. Шул ук әйберләр. Рәдиф белән Илшат икесе ике якка карап тәмәке тарталар. Машина туктаган тавыш. Ялт борылып карыйлар, тормыйлар. Кабаланып, борчылып шофер керә.

Ш о ф е р. Ул-бу юкмы?

И л ш а т. Күргәнеңчә.

Ш о ф е р. Утырасызмы?

Р ә д и ф (*мыскыллап Илшатка карый*). Оядагы каз кебек.

Ш о ф е р (*кычкырып*). Нишләп утырасың? Ничек җаныгыз түзә? (*Тегеләр эндәшмиләр.*) Бәләкәй чагында үпкәләп-нитеп куйса, Мәңгәрдәге ерак туталарына кача торган иде. Карлы-бозлы яңгыр дип тә тормый, зәһәр суыкларга да чыдый, ун чакрымны сыпыртыпмы-сыпырта. Эзләп бардым, бу юлы анда да юк.

Р ә д и ф. Ай-яй каты йөгерә икән, туп кебек тәгәри.

Ш о ф е р. Нәрсә булды соң? Ник үпкәләттегез Шәрифҗанны? Инде алты-җиде ел Мәңгәргә качканы юк иде... Бу юлы аннан да ераккарак китәрлек иткәнсез, ахры!..

Р ә д и ф. Бернәрсә дә булмады.

Ш о ф е р. Юк, булган... Алай икән нигә үз-үзегезгә исегез китеп монда утырасыз, нигә Шәрифҗанны эзләшмисез?!

Р ә д и ф. Әнә Илшат җибәрми. Әллә кайчан сыпырыр идем.

И л ш а т. Ярамый. Директор кушмады. Кемдер дөнья тәгәрмәчен әйләндереп җибәргән инде. Аны Шәрифҗан югалып кына, син, Шайхразый агай, кычкырып кына, Рәдиф кәпрәеп кенә туктата алмый. Кеше үз-үзенә хуҗамы соң?! Менә нәни генә мисал: кемнеңдер тинтәк башына, беренчеләр чия утыртканда унынчылар да катнашсын, дигән җүләр уй килгән. Шул директорга барып ишетелгән. Хуплаган. Ул, үз чиратында, инспекторга мактанган... Юк кына хәбәр таудан төшкән кар кебек зурая, дәвәя. Мең Шәрифҗан югалсын хет, без монда утырырга тиеш.

Ш о ф е р. Әнкәсе бүген каз суйды. Каз бүтәкәсен бик ярата иде. (*Чыгып китә. Машина тавышы.*)

Р ә д и ф. Үпкәләде.

И л ш а т. Күрәм.

Р ә д и ф. Нигә күрә торып кеше үпкәләтәсең?

И л ш а т. Син дә минем төсле бит.

Р ә д и ф. Мин кешесен белеп кенә.

И л ш а т. Үз-үземне белеп кенә диген... Үзеңә җайлы икән, үпкәләтмисең.

Р ә д и ф. Китик без моннан. Халыктан оят.

И л ш а т. Самат Гаязович Кәрим түгел. Аның безне бер дә ачуланганы юк. Тик сизәм, әгәр үчкә калса, җырлый-җырлый биш кат тиреңне тунар.

Р ә д и ф. Бүген иртәдән бирле син куркакка әйләндең.

И л ш а т. Юк, кичәге төнге уникедән бирле. Шәриф-

җан юк. Аның кулында пленка... Әгәр ул берәрсенең кулына төшсә?!

Рәдиф. Директор килә!

Тиз-тиз тәмәкеләрен ташлыйлар. Самат керә. Укучыларны гүя күрми, як-ягына карап барлап чыга. Сүзсез генә җыр суза.

Самат. Чокырлар, көрәк, су, агачлар... һәммәсе әзер. Элеккечә.

Рәдиф. Шәрифҗан табылмадымы, Самат абый?

Самат. Нигә табылмасын? (*Пауза.*) Табылыр.

Илшат. Сез монда кирәгрәк. Озакламый беренче класс килеп җитәргә тиеш.

Илшат. Безнең иптәшебез югалганда бу бакчаны күрәсебез дә килми!

Самат. Яшьтән үк чебеннән дөя ясарга өйрәнмәгез. (*Тегеләр шып туктыйлар.*) Нәрсә булды сезнең арада? Берәр нәрсә яшермисезме?

Рәдиф. Бернәрсә дә булмады. Элеккечә матур гына утырып дәрес әзерләдек. Әйбәт кенә урамда йөрдек. Күңелле генә дусларча таралыштык.

Самат. Бусы яхшы. Шушы сүзләрегезне хәтерегезгә сеңдерегез, әгәр берәрсе кызыксынса, чатнатып торыгыз... Беренче класслар килгәндә монда булыгыз! (*Чыга.*)

Егетләр шундук тәмәкеләрен кабызалар. Рәдиф Илшатка карамыйча гына шигырь ятларга тотына.

Рәдиф. Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр... (*Илшатка.*) Ничек әле?

Илшат (*тәмәкесен чөеп*). Ташла!

Рәдиф. Тукайны белмисеңме?

Илшат. Ну...

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Рәдиф. Түрләре, почмаклары... Нәрсә күз алдыңа килә?

Илшат (*тәнен язып чүгәли, турая*). Кәрим шактый өркеткән икән үзеңне.

Рәдиф (*ботакны сындырып төшерә*). Төкерәм Кәримеңә. Шуны әйт син: без шул җирнең кайсы почмагында яшибез?

Илшат (*ярсып*). Нигә сындырдың?

Рәдиф. Түрендәме? Почмагындамы? Һәм кем булып көн күрәбез?

Илшат (*ботакны сынган урынына куеп карый*). Тараканнар булып ярыкларында яшибез.

Р ә д и ф (*тезенә суга-суга такмаклап йөри*). Хурлары, оҗмахлары... хурлары, оҗмахлары... гитарада көйгә салып булырмы?

И л ш а т (*Рәдифне тотып ала, муенына кулын сала*). Маташтырма, төкермисең бер дә. Гитарага-митарага да борма. Өркеттеме сине Кәрим? Боргаланма-сыргаланма. Без барыбыз да аннан куркабыз. И, вообще без куркаклар. Беренчедә егерме укый башладыкмы? Дөнья белән очрашудан шүрләмәгәннәр бу мәктәпне күптән ташлап чыктылар. Төкермисең, агайне, борчакны эредән чирттермә... Шәрифҗан белән бу мәктәпкә ник ябышып ятуыгызны беләм: Зәнә сагыз ычкындырмый. Өзәргә йөрәгегез тю-тю... Куян койрыгы төсле... Куркаклар без!

Р ә д и ф. Син үзең дә, син үзең дә!

И л ш а т. Танаммы әллә? Әйе, куркак икәнлегемне бүген төнлә белдем. Тормышымда нәни генә, бәләкәй генә үзгәреш булды... һәм мин...

Р ә д и ф (*башын ат кебек чайкап йөри*). Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары... Монда... (*Туктап.*) Без ярыкта. Түрдә кемнәр соң?

И л ш а т. Әнә Кәримнәр... Яки Самат Гаязовичлар.

Р ә д и ф. Кәримнәр түрдә?

И л ш а т (*эскәмиягә барып күккә карап ята*). Югарыда зәңгәр күк, аста сары җир... Уртада мин — адәм угылы. Чыннан да, бәлки, мин мин түгелдер? Ялгыш кына, бөтенләй башка кеше урынын алып яшимдер? Табигатьнең шундый хата могҗизасы булмасмыни? Әгәр мин шул хатаны бик соң аңласам?..

Р ә д и ф. Күк белән җир арасына сине кыстырганнар, кыстыбый!

И л ш а т. Менә әле генә директор алдында бертөсле сөйләштек. Үзебез генә калгач гел икенче сүзләр, үзгә уйлар, башка фикерләр... Директор да шуны белеп, аңлап хуплаган сыман. Кайда соң минем чыным?

Р ә д и ф. Төнлә убырлы карчык, көндез сылу кыз. Әкиятләрдә бар бит. Начар түгел.

И л ш а т. Минем шулай булуым кемгәдер кирәк алайса?

Р ә д и ф. Майламасаң — тәгәрмәч әйләнми, җайламасаң — дөнья алга бармый, ди безнең Гайнел бабай.

И л ш а т. Классикмы ул синең Гайнел бабаң?

Р ә д и ф. Уйнама, сиксәнне яшәгән.

И л ш а т. Һәм фәлән тонна тоз ашаган. Бәхетлеме ул синең Гайнел бабаң?

Р ә д и ф. Зарланганы юк. Шөкрана итә. Үз тормышыннан үзе канәгать булып яшәгәч, бәхет шул түгелмени? Һәркемнең үз бизмәне. (*Төпчеген чокырга ташлый.*)

И л ш а т. Хәзер үк үрелеп ал.

Р ә д и ф. Каравылчы булып яллandыңмы?

И л ш а т. Бу чокыр минеке. Анда минем чыным. Мөгаен, чынымдыр. Таптама. Чокырымда тәмәке төпчеге үсүен теләмим.

Р ә д и ф (*төпчекне алып үз чокырына ташлый*). Миңа димәгәе... Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары...

И л ш а т. Җитәр сиңа! (*Пауза.*)

Р ә д и ф. Зәнә дә дәрескә килмәде... Без белмәгән шикле сере бар, ахры.

И л ш а т. Белмим.

Р ә д и ф. Шәрифҗан белә... Тыңлый алдымы икән, юкмы?

И л ш а т. Авылда бер генә кешедә магнитофон бар. Рабига апаларда. Ул аларга керергә кыймас... Әйдә, Зәнәләргә!

Р ә д и ф. Барыйк. Эт итеп куып чыгарыр.

Чыгып китәләр. С а м а т белән З ә н ә керәләр.

С а м а т. Болары кая югалган әле тагын?

З ә н ә. Әти, минем аларны күрәсем килми.

С а м а т. Аларга таба карама. Әмма шушында бул.

З ә н ә. Әти, алар янында калдырып китмә.

С а м а т. Башка вакытта, кызым, башка вакытта.

З ә н ә. Барыбер йәр-йәр-йәр дип шыңшып йөрүдән башка эшең юк ич инде. Әти, нигә синең җырларыңның бер дә сүзе юк?

С а м а т. Башка вакытта, иркәм, башка вакытта.

З ә н ә. Бәләкәй чакта минем сиңа ияреп мәктәпкә барасым килә иде. «Барыйм инде, әти, синең бәләкәй китабыңнан мин укытырмын» дия торган идем.

С а м а т (*түземсезләнеп*). Мин сине ияртми идем. Син елап кала идең. Булдымы? Ә хәзер мине җибәр. Инспектор абыең көтәдер.

З ә н ә. Көтсә, күңелен күрергә синең холуйларың бетмәгән. Әй аны мактаган булырлар, елмаерлар. «Сезнең килүегез ифрат файдалы булды» диярләр. Эчтән генә «Кайчан китәрсең икән, жәфа!» дип уйларлар.

С а м а т (*Зәнәнең маңгаен тотып карый*). Төнлә йокламаган идең, кызый... Кара, шушында урал. Иптәшләрең белән аерата дус, ягымлы бул!

З ә н ә. Әти, җибәрегез мине башка мәктәпкә!

С а м а т. Инде бу чир сиңа да йоктымыни?

З ә н ә. Укый алмас дисеңме? Хур булыр дип уйлыйсыңмы? Күзләрем атылып чыгар, китаптан күтәрелмәм! Җибәрегез!

С а м а т. Болай да китәргә туры килер әле сиңа... (*Чыгып китә.*)

Зәнә үз чокыры тирәсендә йөри. Р ә д и ф белән И л ш а т әйләнеп керәләр. Карап торалар. Зәнә чокыр ягасында торган чиләкне тибеп җибәрә.

Р ә д и ф. Зәнә! (*Зәнә ачу белән борылып карый.*) Сезгә барырга чыккан идек. Тыкрыктан үзегезне күреп калдык.

З ә н ә. Эндәшмә миңа.

И л ш а т (*Рәдифне кагып җибәреп, Зәнә янына үзе бара*). Дүртәү дус кына уку бик рәхәт икән, Зәнә, кояштыр, әй.

З ә н ә (*Илшатка*). Кит янымнан.

И л ш а т (*сабырлыгын җыеп*). Укытучылар да безнең хәлне аңлый, ахры. Берсе дә дәрес сорамады. Тик гәп сугып утырдык.

З ә н ә (*йөзе белән аларга борылып*). Сез сүз берләшкәнсез. Берегез дә мине дус итми. Хәйләләп эч серемне алдыгыз. Алдалап, талап. Бандитлар, шпионнар кебек. Мәкерле җаннар. Анда язылган сүзләрне бәбәгегезгә терәп әйтә алам. Кирәкме, йә?

И л ш а т (*чокырдан бая Зәнә тибеп төшергән чиләкне ала*). Яньчелгән. (*Таш белән аны кага.*) Тавышы. Сугыш барабаны дип белерсең. (*Ташын ыргыта.*) Миңа кирәкми, Зәнә.

Р ә д и ф. Миңа да, Зәнә.

З ә н ә. Бер ишеткәч, кабатлап тору кирәкме соң? Барыбер мин сезнең белән укымыйм. Барыбер китәм.

Р ә д и ф (*курка-курка гына*). Ераккамы, Зәнә?

З ә н ә. Белгәннәрең дә хәттән ашкан.

И л ш а т. Бернәрсә дә белмәдем дип әйтә алмыйм.

З ә н ә. Астыртын.

И л ш а т. Шәрифҗан миңа, «Зәнә чокырына күм мине» диде.

Р ә д и ф. Магнитофон төзәтеп утырганын мин дә күрдем. Ул чагында кем уйлаган бит.

З ә н ә. Берегез күргән, икенчегез ишеткән. Өчәүләшеп пленка тыңлап яталар бугай.

Р ә д и ф. Ничек тыңлыйк ди без аны?

И л ш а т. Ялгышма, Зәнә. Тыңлау түгел, күргәнебез дә юк. Без барганда Шәрифҗан өйдә юк иде. Көттек, көттек, кайтмады... Магнитофон мәктәптә, бикле шкафта.

З ә н ә. Алдамыйсызмы?

И л ш а т. Алдап ни файда?

З ә н ә (*уңайсызланып кына*). Илшат, Рәдифкә бер сүзем бар.

Илшат. Теләсәң — мең сүз. Тик чамала — җирнең дә колагы бар.

Зәнә. Колагы булса да, авызы юк.

Илшат чыгып китә.

(*Зәнә чокыр тирәли йөри. Тибеп-тибеп карый.*) Пленкага яза алдымы икән?

Рәдиф. Кыек эшкә этлеге җитәр. Нәрсә әйткән идең?

Зәнә. Анысы синең эш түгел. Син миңа шул пленканы кайтар.

Рәдиф. Ансат, иң элек Шәрифҗанны табарга кирәк!

Зәнә. Беркем эшли алмаганны син булдырырга тиеш.

Самат керә. Икесенең арасына баса. Рәдиф оялып читкәрәк китә.

Самат. Рәдиф, барчы, бер генә минутка китеп тор. Тик ерак йөрмә!

Рәдиф чыга.

Буядыгыз исемегезне!

Зәнә. Нәрсә бар, эти?

Самат. Теге малай төнлә Рабига ханымны уятып кергән дә икәүләп пленканы тыңлаганнар.

Зәнә. Ничек?

Самат. Ничек ничек, авызы тишек! Гомереңә телеңне тыя алмадың... Хәзер сез йомарланган йодрык кебек бер булыгыз!.. Үпкәләр онытылсын, хәзер сез аерым-аерым кеше булудан туктыйсыз. Сез — класс, җәмгыять! Мин Рабига ханымны ничек тә җайлармын. Инде аннан ары китсә...

Зәнә. Әти!

Самат чыга. Йөгереп Рәдиф керә.

Рәдиф. Нәрсә бар? Ни булды?

Зәнә (*тиз-тиз*). Нихәтле хат яздың... Шигырь укыдың... Күпме сүзләр әйттең... Болар барысы да коры шапырыну гына идеме? Тап Шәрифҗанны!

Рәдиф (*беркадәр оятсызланып*). Тапсам?

Зәнә. Ни телисең?

Рәдиф (*шыпырт*). Ә теге егет? Одессадагы?

Гаян керә.

Гаян. Безнеке кайда әле?

Рәдиф. Шушында гына йөри.

Гаян. Чокырлары һаман буш тора... Шайхра малае югалган бит. Шушы чокырлардан сорагыз, аның аяк та-

вышын ишетмәдеме икән? Җиркәй барын да белә, барын да саклый...

З ә н ә (*Рәдифкә шыпырт кына*). Китик.

Г а я н. Теге ямьсезкәегез кайда?

Р ә д и ф. Кем ул ямьсезкәй, Гаян апа?

Г а я н. Тәрәзәгә боз яудыра торган яңа укытучыгыз. Кәрим атлымы шунда...

З ә н ә. Мәктәптәдер.

Г а я н. Сүзем бар иде аңа, бер сүзем... (*Чыга.*)

З ә н ә. Одессаны оныт син! Бар, кыйммәтле вакытны югалтасың.

Р ә д и ф (*Гаян артыннан бик җентекләп карап кала*).

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары...

Зәнә, нинди заманалар булган: электр юк, кинолар юк. Радио-телевизорларны әйтәсе дә түгел. Клублар-мәктәпләр истә-оста булмаган. Тоташтан милли изелү. Халык фәкыйрь, моңлы. Ничек итеп шушы җирләрне оҗмахка охшата алды икән Тукай? Кыр, өй эшеннән башы чыкмаган надан, кытыршы куллы апаларны сылу хур кызларына ничек тиңли алды икән? Каян килгән аңа мондый киң күңеллелек?

З ә н ә (*йодрыкларын йомарлап*). Сез барыгыз да ялагайлар. Кәрим җырын җырлыйсыз. Сез барыгыз ялагайлар!

Р ә д и ф. Вәгъдәңдә торырсыңмы?

З ә н ә. Иң элек егетлегеңне күрсәт.

Р ә д и ф. Илшат, Илшат!

И л ш а т керә.

Салкын кан белән генә уйлашыйк әле.

З ә н ә. Нинди салкын кан? Сез беләсезме, җүләркәйләр, Шәрифҗан пленканы Рабига апага тыңлаткан.

И л ш а т. Бер абынсаң, егылганыңны, борының канаганны көт тә тор.

З ә н ә. Рабига апаны беләсез, чабып директорга жалоба белән килгән.

Р ә д и ф. Бердәнбер мөмкинлекне бозган икән, җебегән салма!.. Их! Әле дә ярый Самат абый үзебезнеке. Кыен чакта тукмарга ирек бирмәс.

И л ш а т (*Зәнәгә*). Хәзер көт тә тор: Шәрифҗан — җүләр баш, барыбызны себер җибәрер!

З ә н ә. Соң нишләп монда катып торасыз? Әгәр пленка Кәрим кулына төшсә?

Р ә д и ф. Авылны, кырны квадратларга бүлеп чыгам да кармалап-кармалап бетерәм. (*Чыга башлыйлар.*)

И л ш а т Тарак. Шәрифҗанның тарагы төшеп калган.

З ә н ә. Фу, җирәнгеч.

Чыгып китәләр, ш о ф е р белән К ә р и м керәләр.

Ш о ф е р. Өч яшендә кызамык белән чирләде. Бик каты уздырды, балакаем. Төнлә уянып сикереп торган. Ятмый гына бит. «Әти, бәләкәй чакта синең исемең ничек иде?» — ди. Сугыштан соң авылда фельдшер юк, җигәргә аты юк, телефон эшләми, җәяүләп районга чаптым.

К ә р и м. Читтә, якын-тирә авылларда серләрен бүлешерлек берәр кешесе юк идеме аның?

Ш о ф е р. Иптәшләре монда инде... Читтә юк... Чыгып-нитеп йөргән, дөнья күргән малай түгел.

К ә р и м. Яхшы юлны яманнан аера алса, ярый ла.

Ш о ф е р. Син бик каты кысма инде аны, Туганай. Болай да синнән шүрләбрәк йөри иде.

К ә р и м. Аңа куркырга кирәкми. Олы кеше. Үз яшәгәне өчен үзе җавап бирә алырлык... Юк, юк, мин аннан җавап таләп итәргә җыенмыйм. Укучының яшәешен шулай оештырырга кирәк, ул сорауларны үз-үзенә күбрәк куйсын!

Пауза. Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Кәрим, сезгә пакет бар. Мәскәүдәге бик куркыныч медицина оешмалары белән хат алышасыз икән.

К ә р и м. Сагыналар бит, Гөлсем ханым! Үзем бик юксынмаска тырышам. (*Пакетны ала.*) Рәхмәт.

Г ө л с е м. Шәрифҗаннан хәбәр-хәтер юкмы?

Ш о ф е р. Кош теле кадәр генә хат язып калдырган булса кана!

К ә р и м. Хат язып калдырмавы әйбәтрәк тә әле аның. (*Пакетны ача-ача чыга, шофер аңа иярә.*)

Гөлсем китә башлый, сүзсез генә җыр көйләп С а м а т керә.

Г ө л с е м. Унынчыны ябасызмы?

С а м а т. Шулай диләр.

Г ө л с е м. Үзләренә кайчан аңлатасыз?

С а м а т. Хәзер диләр... Бакчада эшләре генә бетсен дә.

Г ө л с е м. Ә Зәнә?

С а м а т (*чак кына кызып*). Нәрсә Зәнә?.. Азрак нужа күрсен. Без үскәндә барын да татыдык. Беләсеңме синең кызың нишләгән?

Г ө л с е м. Кыз минеке генә булгач, мактарлыгы юктыр инде.

Самат. Җүләр кыз икән!.. Бу заманда ни уйлаганыңны әйтергә ярыймы соң?! Ярый, мин ишетмәмешкә дә салынырмын ди. Унынчы класс белән бәхәскә кереп тормам. Алар бүген монда, иртәгә... үзләре тиешле җавабын бирерләр. Ә инспекторга барып ишетелсә?

Кабаланып Марат Кәримович бакчага килеп керә.

Марат. Самат Гаязович, мин әле генә Рабига ханымны күрдем. Ул миңа менә шушы гаризаны тапшырды.

Самат. Таудан түбәнгә чаба башлаган чыгымчы бияне туктатырмын димә.

Гөлсем. Нинди гариза ул? Рабига ханым тагын берәрсен чагамы?

Марат. Дөресен яза. Дөреслек чакканда хәл тагын да яманрак.

Самат. Беләм, Марат Кәримович. Ишеттем.

Марат. Ишеткәнегезне колагыгызда гына калдырмый торган идегез моңарчы.

Самат. Гаеплемен. Бу юлы калдырырмын дигән идем.

Марат. Тизрәк-тизрәк бу унынчы классны таратырга кирәк. Котылырга. Мин сезне яратам. Шуңа күрә барын да аңлыйм. Бу кәгазьне күрмәдем дә, ишетмәдем дә... Сездә унынчы класс кичәдән бирле юк. (*Гаризаны ертып ташлый.*)

Кәрим керә.

Кәрим. Әйтегез әле, унынчы классны ябалармы?

Самат. Яман хәбәр ярык эзли, шайтан алгыры!

Марат. Кәрим абый, мин сезгә әйтергә, аңлатырга өлгермәдем.

Кәрим. Аңладым... Дүрт бала өчен класс тоту, бәлки, нindidер законнарга туры да килмидер. Тик ул дүрт бала: Илшат... Рәдиф... Шәрифҗан... Зәнә! Юк, безне җир йотар!

Марат. Бу мәсьәлә хәл кылынган дип санагыз, Кәрим абый.

Кәрим. Бу мәсьәләне бездән башка кем хәл кыла алсын?

Самат. Сезнең берәр тәкъдимегез бармы?

Кәрим. Аңа китсә, унынчы классны түләүсез укытабыз.

Самат. Ничек? Акча алмыйчамы?

Кәрим. Үз укучыларымны бу хәлдә мәктәптән җибәрә алмыйм.

Гөлсем. Балаларга бик-бик кыен булачак. Уку кызып барганда гына классны таратсыннар әле.

Марат. Сезнең корбан булуыгыз кемгә кирәк? Ни өчен тагын укытучылар интегергә тиеш? Болай да итәкләренә ут капкан. Утырып ашарга да вакытлары юк.

Кәрим. Ни өчен кирәген белмим, әмма бу хәлдә укучыларымны җибәрергә намусым кушмый.

Самат. Сез аларны яратмыйсыз, Кәрим.

Гөлсем. Яратмаса, ул алардан котылырга теләр иде.

Самат. Бушлай эшләргә кем риза булсын? Әле бит елның башы гына.

Кәрим. Укытучылар без ич инде. Сез, мин, Гөлсем ханым.

Гөлсем. Мин риза.

Кәрим. Ә сез, Самат Гаязович?

Самат. Уйларга кирәк. (*Маратка карый.*)

Марат. Юк, юк, мондый җаваплылыкны өстемә алырга теләмим.

Кәрим. Тик бер шарты бар: бу турыда укучылар берсе дә белергә тиеш түгел. Бездә һәммәсе дә искечә калсын.

Самат. Шулай булсын иде дә бит.

Марат. Элеккечә кала алмый, Кәрим абый. Сез аларның кичә нәрсә эшләгәнен белмисез!.. Ниндидер шикле уеннар, төнге уникедә җыелулар. Йә чарасын күрергә, йә җәзаларга кирәк аларны. Икенең берсе!

Кәрим. Беләм. Ул гаризаны мин иртүк укыдым.

Самат. Миңа кадәр үк?

Марат. Менә бит!

Кәрим. Хәзер ризалашасызмы инде?

Гөлсем. Ә мин барын да иң соңыннан гына ишетәм.

Марат. Болай урамда торып сүз арасында гына хәл кылына торган мәсьәлә түгел. Әйдәгез барыйк, утырыйк, уйлашыйк. Тик кисәтеп куям: мин баш-аягым белән унынчыны ябу ягында.

Гөлсем. Бер Рабига ханымның телен генә җиңәрбез әле.

Самат. Тел бик еракларга үрелә ала шул ул.

Марат. Сез бармыйсызмыни, Кәрим абый?

Кәрим. Үз сүземне әйттем. Мин сезгә ышанып калам.

Самат. Ихтыярыгыз.

Чыгып китәләр. Шундук Гаян керә.

Гаян. Җирнең авызы һаман ачык тора. Укучылар сине тыңламыйлармы?

Кәрим. Тыңламыйлар.

Гаян. Шайхра малаен өермә күтәреп киткәндер. Әйт әле, җил каян чыга?

Кәрим. Җил — күзгә күренми торган һава хәрәкәте.

Гаян. Ә уй? Ул да күренмичә йөри бит. Тик кешеләр ничектер аны беләләр... Бер сүзем бар әле сиңа, бер сүзем...

Кәрим. Мин сезне тыңлыйм, Гаян апа.

Гаян чыгып китә. Кәрим туктап кала. Менә аның каршысына акрын гына Шәрифҗан килә. Аның өсте-башы йомарланып беткән, киемнә салам кисәкләре ябышкан, йокысызлыктан йөзе ямьсезләнгән.

Шәрифҗан (*текәлеп карап торган Кәримнән уңайсызланып*). Тарагымны югалттым... Тарак. Чәч тарый торган. Шушында төшеп калмадымы икән?

Кәрим. Ә нигә аны моннан эзлисең?

Шәрифҗан. Рәдифләр ялганлыйлар!

Кәрим. Сөйләргә ашыкма, минем сиңа сүзсез генә карап торасым килә.

Шәрифҗан. Мин беркая да китмәдем. Лапас түбәсенә мендем дә шунда салам арасында күмелеп яттым.

Кәрим (*көлә*). Җылы урын сайлагансың син.

Шәрифҗан. Башта курыктым. Күземне шытырдатып йомдым да үлем көтә башладым. Чакырдым үлемне! Үләсем килде... Дөнья шулкадәр ямьсез, әшәке иде. Бөтен җир пычрак, шакшы, үзем дә, битем дә, кулларым да... Аннары сезне хәтергә төшердем.

Кәрим. Рәхмәт.

Шәрифҗан. Лапас түбәсен тиштем дә сезне сагалап яттым. Урамнан әллә ничә үттегез, тик ялгыз түгел идегез. Сезне ялгыз калдырмыйлар икән.

Кәрим. Ялгыз калырга куркам мин, Шәрифҗан.

Шәрифҗан. Ә мин ялгыз чагыгызны барыбер таптым.

Кәрим. Кайчан?

Шәрифҗан. Менә хәзер.

Кәрим. Ялгышма, без монда икәү, Шәрифҗан.

Шәрифҗан. Менә. (*Куеныннан пленка чыгара.*) Кичәдән бирле куенымда саклыйм.

Кәрим. Нәрсә бу?

Шәрифҗан. Мәктәпкә керегез дә тыңлагыз. Магнитофон төзек. Илшатлар аны алып киттеләр.

Кәрим. Үз телең белән генә әйт, Шәрифҗан.

Шәрифҗан. Кабатлый алмыйм. Бу аның сүзләре. (*Кыенлык белән генә.*) Зәнә сүзләре. Кичә төн уртасында ул мондагы сүзләрне менә шушы чокыр авызына тапшырды.

Кәрим. Шуннан?

Шәрифҗан. Без шундый уен оештырдык... Дөресе,

мин уйлап чыгардым. Серләрне, уйларны чокырга тапшыру уены. Мин аның чокырына магнитофон тоташтырдым.

К ә р и м. Шыпырт кына яшеренеп алдан килдең дә?..

Ш ә р и ф җ а н. Әйе.

К ә р и м. Алар соңыннан барын да сизенделәр. Ә син пленканы әләктердең дә качтың?

Ш ә р и ф җ а н. Пленканы түгел, мин аның сүзен урладым! Аның серен! Анда сезнең хакта да әйтелгән!..

К ә р и м. Ә ул сер сиңа нигә кирәк? Авыл буйлап теләсә кемгә чәчеп йөрергәме?

Ш ә р и ф җ а н. Магнитофон Рабига апаларда гына бар.

К ә р и м. Булса? Тагын башкаларга да керер идеңме?

Ш ә р и ф җ а н. Монда бит аның сүзләре! Зәнә сүзләре!

К ә р и м. Син көчсез, зәгыйфь бер малай икәнсең! Бар, пленканы Зәнәнең үзенә кайтар. Гафу үтен.

Ш ә р и ф җ а н. Юк! Әгәр сез чарасына керешмисез икән, барам да колхозның радиосын яулап алам. Аның сүзләрен бөтен авылга яңгыратам.

К ә р и м. Син кичә генә ирек, демократия турында сөйләдең түгелме?

Ш ә р и ф җ а н. Зәнә җәзасын алмый калсынмы?

К ә р и м. Пленканы кайтар. Җәзаң шул булыр.

Ш ә р и ф җ а н. Көне буе салам астында мин сезне көттем бит!..

К ә р и м. Ә мин көне буе син акылсыз малайны эзләдем! Мин барын да белә идем. Рабига ханым иртүк миңа керде. Буталдың син, Шәрифҗан... Минем сине күреп тизрәк кул сузасым килде. Ярамый, кешеләрнең хисләрен көчләргә ярамый. Егет бул!

Г ө л с е м керә.

Г ө л с е м. Шәрифҗан табылган, Шәрифҗан табылган.

Ш ә р и ф җ а н. Югалмадым да...

Г ө л с е м. Кая җибәрәсез Шәрифҗанны?.. Исән-сау... һай, балакай, кузгаттың монда кайгы елгасын...

К ә р и м. Егет булса, Шәрифҗан кая барырга кирәклеген үзе белер.

Ш ә р и ф җ а н. Хәзер беләм. (*Чыга.*)

Г ө л с е м. Ни булды бу балаларга? Зәнә әллә нишләде. Төне буе йокламады. Дәрескә бармады. Әтисенең папиросларын алып тарткан.

К ә р и м. Ә нигә ул һәр төнне тыныч кына йоклап уздырырга тиеш? Йокламасын, уйласын!..

Г ө л с е м. Бик борчылам...

К ә р и м. Бергәләп борчылыйк. Шулай итсәк, дөреслекне табарбыз.

Гөлсем. Сез мине юатасыз гынамы? Әллә чыннан да шулай уйлыйсызмы?

Кәрим. Юату — ялган сөйләү ул. Ә мин каушап калганда да үз җиребезнең, илебезнең, халкыбызның кодрәтенә ышанам.

Гөлсем. Сез хәзер Марат Кәримовичлар белән кермичә бик яхшы иттегез.

Кәрим. Мин керсәм, алар ярсып бәхәскә тотынырлар иде. Болай, әйдә, үзара уйлансыннар.

Гөлсем. Самат ризалашты, Марат Кәримович икеләнде.

Кәрим. Димәк, эш безнеңчә барып чыга дигән сүз.

**Чыгып китәләр. Бакчага Рәдиф килеп керә. Кулындагы таягы белән җиргә нидер сыза. Икенче яктан эзләнеп Шәрифҗан керә, Рәдифне күреп туктала. Рәдиф башын күтәрә, аны күреп куркынып артка чигенә.**

Шәрифҗан (*кыргый хәрәкәтләр ясый*). Бр-р-р!

Рәдиф. Кыланмасана.

Шәрифҗан. Шыр җибәрмә, мин өрәк түгел.

Рәдиф (*Шәрифҗанның кулыннан тота*). Мин сине таптым.

Шәрифҗан. Мин синең үзеңне таптым. (*Якасыннан эләктереп ала.*) Нигә таш ыргытып калдың? Җилкә чокырына килеп тиде. Әле дә сызлый.

Рәдиф. Кызулык белән булгандыр инде.

Шәрифҗан. Кызулык белән башны ярган булсаң? (*Ярсып.*) Капризный бер кызның боерыгын үтәп бит!.. Үтертер ул. Таптый-таптый күмдерер.

Рәдиф. Караңгыда кем чамалап торган? Тоттым да ыргыттым.

Шәрифҗан. Бар, берлеккә исән калдырам.

Рәдиф. Кая югалдың син?

Шәрифҗан. Салам арасында яттым.

Рәдиф. Салам торхан патша. Сине эзләп бөтен авыл купты. Әй эзлиләр, әй эзлиләр, салам арасында ятасың дип кем уйлаган?

Шәрифҗан. Шуннан да ары китәрлек эш булмады. Зәнә кайда?

Рәдиф. Ну үзең дә йөгерәсең икән.

Шәрифҗан. Зәнә кирәк миңа.

Рәдиф (*һаман үз сүзен сукалый*). Ташла әле шул иркә кызны. Нәрсәгә ул сиңа? Бер яхшылап, иптәшләрчә генә гәпләшик.

Шәрифҗан. Тапшырасы әйбер бар.

Рәдиф. Әйбер? (*Кинәт аңлап ала.*) Пленкамы?

Шәрифҗан. Әйе.

Рәдиф. Син арыгансың, талчыккансың. Бир үземә генә. (*Каккалап.*) Өс-башыңны кара. Валлаһи, салам эскертендә аунагансың син. (*Шәрифҗанны чистарта. Куен турын капшап карый.*) Шушымы? Бир әле.

Шәрифҗан. «Алтынчәч» сабыныгыз бармы?

Рәдиф. Тагын кылана башлады.

Шәрифҗан. Кайтып кулыңны шул сабын белән өч тапкыр юып кил. (*Чыгарга таба атлый, Рәдиф аның юлына төшә.*)

Рәдиф. Сер итеп кенә әйт:ниләр сөйләгән?

Шәрифҗан. Рәдифне өзелеп яратам дигән.

Рәдиф. Дус итеп сорыйм: бир пленканы.

Шәрифҗан. Дус итеп әйтәм: көтмә.

Рәдиф. Барыбер сиңа кирәкми ич, тыңлагансың. Бир.

Шәрифҗан. Кәрим кушмады. Үзем дә сиңа бирмәс идем.

Рәдиф. Кем ул Кәрим? Арага ятлар кертмик.

Шәрифҗан. Бирмим.

Рәдиф. Ни сорасаң, шуны эшлим. Гитарамны ал, тик пленканы бир.

Шәрифҗан. Андый кодрәтең булгач, барын да үзең бел. Күп лыгырдап торырга вакыт юк, карын ачты.

Рәдиф. Телләшеп торган була бит, Салам торхан! (*Әтәчләнеп барыпябыша, Шәрифҗан аны сугып ега.*)

Шәрифҗан. Җитәр! Арттан таш атып калу түгел бу. Монда, туганай, җегәр кирәк.

Рәдиф тора да тагын Шәрифҗанга барыпябыша, нык сугышалар. Илшат белән Зәнә керәләр. Илшат икесен ике якка очырып җибәрә.

Илшат. Тапканнар урын. Тапканнар вакыт!

Зәнә. Шәрифҗан?

Шәрифҗан (*канлы иренен сөртә-сөртә, туп-туры Зәнә каршысына бара*). Зәнә, инглизчә хыянәт «тризн» була. Русчасы «измена». Татарчасын беләсең... Астан чагып, арттан килеп пычак кадау... «три-зн». Китаптан карамадым. Юк. Кайчандыр укыган идем. Тормышымда мәхәббәт, дуслык сүзләре генә кирәк булыр дип мин аңа игътибар да итмәгәнмен. Тик хәтер үзенекен эшләгән. Караңгы бер почмагына «тризн» дигән сүзне дә кыстырып куйган. Нинди әшәке сүз!

Зәнә. Син ни сөйлисең? Кемгә?

Шәрифҗан. Үз-үземә.

Илшат. Тешең канаган, Шәрифҗан.

Шәрифҗан (*иренен сөртеп, Илшатка карый*). Бетteme?

Илшат, кулъяулыгы чыгарып, аның иреннәрен сөртә.

Беттеме? (*Шәрифҗан рәтләнә, төзәтенә һәм Зәнә каршысына барып баса.*) Мә. Үзең хуҗа. Теләсәң нишләт. (*Пленканы суза.*)

Зәнә (*алып*). Бу шулмы? Бу шулмы?

Шәрифҗан. Тикшереп кара.

Зәнә (*өзгәләп, ерткалап пленканы атып бәрә*). Шулмы? Шулмы?

Илшат. Әрәм иттең.

Зәнә (*аяклары белән таптап*). Менә сезнең хәйләгез. Мин аны җиргә күмәм.

Шәрифҗан. Таптама. Ул хәтле үк таптама. Ике урынга сүзләреңне күмәсең. Кем белә, кайчан исә бу җирдә курай үсеп чыгар. Көтүче малай ул курайны кисеп алыр...

Зәнә. Куркытма. Үстермәм мин монда курай. Таптый-таптый йөрермен. Нык-нык басып.

Шәрифҗан. Картаерсың, аягыңның җегәре бетәр.

Зәнә. О! Ул чагында мин еракта булам инде. Синең ишеләрнең генә кулы җитмәс!

Шәрифҗан. Дөньядагы иң зур циркларның гөмбәсе астындамы? Иң-иң куркыныч номерны башкарганда оркестрда курай тавышы ишетсәң...

Зәнә. Янама!

Илшат. Әле ярый без класста егерме түгел.

Зәнә. Ә үзегез? Җиргә нинди серләр тапшырдыгыз. Тел төбегезне белмимме әллә?

Шәрифҗан. Без барыбыз да пычрак куллы җүләрләр.

Зәнә. Кем котыртты? Кем башлады? Мидас патшамы?

Шәрифҗан. Без барыбыз да җүләрләр.

Зәнә. Рәдиф, безнең договор шушы минутта көчен югалтты.

Рәдиф (*таң калып*). Син мине сатып алырга гына теләдеңме?

Шәрифҗан. Сатылырга әзер кешеләр барда алучылар табылыр. Ходай Адәм белән бергә җиргә Иблисне дә иңдергән.

Зәнә. Син безнең сүзгә катнашма.

Илшат. Кәрим безне кысып дөрес итә икән.

Рәдиф. Син башладың, син!

Илшат. Эш кем башлауда түгел. Эш безнең ялтырап күренеп китүебездә... Тәрәзә пәрдәсен кем тартса да, барыбер түгелмени? Барыбер җыелмаган чүпле өй эче күренде.

Шәрифҗан. Карыным ачты. Бүген иртәдән бирле унбер күкәй генә эчтем. Минем бәхеткә, бүрекле чуар тавык күкәен качып сала икән.

Илшат. Әле ярый без егерме түгел!

Ш ә р и ф җ а н. Ә «дуслык» инглизчә... оныттым! (*Чыга.*)

И л ш а т. Бу чокырларга тыныч кына карый алмыйм. Нидер ымлыйлар төсле. (*Чыга.*)

З ә н ә (*өзгәләнеп*). Нинди әшәкеләр, нинди әшәкеләр!

Р ә д и ф. Син мине сатып алырга гына теләдеңме?

З ә н ә. Кит!.. Без ел буе ничек бер һаваны суларбыз? (*Үтеп китә.*)

Рәдиф шаккатып карап кала. Аннары ул да чыга. К ә р и м белән М а р а т киләләр.

М а р а т. Яшәү мәгънәсен сезгә аңлатып торасы юк, Кәрим абый. Тик нигә барына да сез катнашырга тиеш? Саулыгыгыз начар...

К ә р и м. Булсын, телгә алып тормаганда да була.

М а р а т. Монда да тынычлыкка каршы сугыш ачмакчы буласызмы?

К ә р и м. Ваемсызлыкка каршы, Марат, ваемсызлыкка!.. Менә без синең белән күп нәрсәләрне бик соңга калып кына аңлашабыз. Хәзерге укучыларым белән мин бу хатаны җибәрмәскә тырышам... Гомер юлларыбыз кисешсәләр, алар өчен оялырлык булмасын!

М а р а т. Ярар. Сез минем укытучым. Тыңламый булдыра алмыйм. Сезнең белән ризалашырга туры килер.

К ә р и м. Ризалашырга һәм мине якларга!

Үтеп китәләр. Пәрдә төшә. Авансценага арыган-талган б е р е н ч е к л а с с у к у ч ы л а р ы килеп керә. Алдагы рәттәге баланы җитәкләп капкарадан киенгән у к ы т у ч ы  х а н ы м бара.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Рабига апа, су эчәсебез килә.

У к ы т у ч ы. Өйләрегезгә кайткач эчәрсез.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Ашыйсыбыз килә.

У к ы т у ч ы. Түзегез, хәзер сез укучылар.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Безгә бакча кирәкми, апа.

У к ы т у ч ы. Зурлар ни әйтсә, шуны үтәгез.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Чия ачы була бит ул, апа.

У к ы т у ч ы. Эш чиядәмени? Алга куелган бурычны үтәргә кирәк.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Таралышыйк инде, Рабига апа.

У к ы т у ч ы. Эчке тәртип кагыйдәләрен беләсезме?

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез.

Кыптыр-кыптыр чыгып китәләр. Пәрдә күтәрелә. Эңгер-меңгер иңә. Караңгылана. Кайдадыр җайдаклы чабып уза. Хатын-кыз тавышы: «Кәҗ, кәҗ, кая олактың тагын, мур кыргыры!». Бакчадагы нәрсәләр чак кына шәйләнәләр. Акрын гына Ш ә р и ф җ а н керә. Чокырлар тирәсендә йөри.

Шәрифҗан. Апрель ахырларында курай борын төртеп чыкса... Июльдә аны көтүче кисеп алса... Бөтен кыр-урманнарны яңгыратып уйнап җибәрсә... Курай инглизчә ничек була соң әле?.. Хәер, тәкәббер альбион уллары курай уйнамыйлардыр.

Илшат керә. Шәрифҗанга карап тукталып озак кына карап тора.

Илшат. Бу мин йөрим әле.

Шәрифҗан. Тарак югалган, тарак... Сирәк-мирәк тарап, башым барлыгын тикшереп торыр идем.

Илшат. Тарагың миндә. Мә, югалтып йөрмә.

Шәрифҗан. Рәхмәт.

Илшат. Үкенәсеңме?

Шәрифҗан. Әле үкенеч килеп җитмәде. Әле тамак төбендә бер ачы су гына утыра... Илшат, мин синең сүзләрне тыңламадым!

Илшат. Нигә?

Шәрифҗан. Курыктым.

Илшат. Мин үзем дә ул сүзләрдән куркам...

Шәрифҗан. Ә минем чокырда кыска гомерле ал чәчәк үсеп чыгар... Анда минем кыска гомерле мәхәббәтем...

Илшат. Онытырга тырышып карыйм, булмый.

Шәрифҗан. Унынчы классны ябалар диме?

Илшат. Япсалар укып булмый инде. Ташларга туры килә. Шул гына.

Шәрифҗан. Болай гына хәбәр тараталар булыр.

Кәрим керә. Йөткерә.

Кәрим. Бу сезме?

Илшат. Без.

Кәрим. Нигә икәү генә? Рәдиф белән Зәнә кайда?

Шәрифҗан. Алар юк.

Кәрим. Барыгыз да мондадыр дип уйлаган идем.

Илшат. Нигә монда булыйк, Кәрим абый?

Кәрим. Килер бер көн, менә син басып торган җир, шушы бакча кайларга гына китсәгез дә, сезнең күңелләрне бәйли торган урын булып калыр.

Шәрифҗан. Шушы бакча?

Илшат. Сез шуны теләдегезме, Кәрим абый?

Кәрим. Юк, тормыш үзе шуны теләде. Монда булып узган вакыйгалар, монда очраган кешеләр гомергомергә онытылмаслар.

Шәрифҗан. Шушы чокырлар... Анда күмелгән серләр...

Илшат. Үзем дә аптырыйм, аякларым шушы бакчага таба тартты...

Шәрифҗан. Кәрим абый! Ә сезнең күңелне бәйләгән урыннар кайда?

Кәрим. Алар күп. Күңелдә мәңге калган иптәшләр дә аз түгел. Иң элек Кама ярында, авылда... Аннан Казан, Урал, Магнитогорск... Сталинград урамнары. Днепр ярында полкташларым йоклый... Аннан Польша, Берлин... Сугыштан соң партия эшендә... Аннары, аннары, менә шушы авыл... Шушы бакча.

Илшат. Безнең авылмы? Шушы бакчамы?

Шәрифҗан. Бакча әлегә юк...

Кәрим. Менә яз җитсен әле. Апрель ахырларында җыелышып без монда килербез.

Илшат. Җыелыша алырбызмы икән инде без?

Шәрифҗан. Апрель ахырларында курай баш төртә... Юк, мин болай гына! Җыелыша алмабыз без, Кәрим абый!

Кәрим. Апрель ахырларында, ай туганда безнең бакча өстеннән каңгылдашып кыр казлары узарлар.

Шәрифҗан. Кыр казлары? Безнең якка килмиләр алар.

Илшат. Минем дә ишеткәнем юк.

Кәрим. Колак салып тыңлаганыгыз юктыр. Айлы кичләрдә күңелләрне җилкендереп кычкыралар...

Еракта гитара тавышы.

Илшат. Рәдиф йөри.

Шәрифҗан. Рәдиф йөри.

Кәрим. Чакырыгыз аны.

Шәрифҗан. Килмәс.

Илшат. Килмәсен, кирәкми.

Кәрим. Чакырыгыз!.. Зәнә дә безнең белән булса икән!

Шәрифҗан. Зәнә киләме соң?

Илшат. Гаҗәп. Рәдиф тә бу тирәдә йөри.

Шәрифҗан. Рәдиф, Рәдиф! Монда кил.

Рәдиф (*күренә*). Хәзер. Гитараны гына куям.

Илшат. Нигә?

Рәдиф. Сез мине кыйнамыйсызмыни?

Кәрим, Илшат, Шәрифҗан тонык кына көләләр.

Илшат. Кыр казлары тавышы ишеткәнең бармы, Рәдиф?

Рәдиф. Юк, нигә?

Кәрим. Борчылмагыз, ишетерсез. Язлар гына җитсен...

Шәрифҗан. Ә яз инглизчә «спринг» була.

К ә р и м. Күп тапкырлар ишетерсез... Ел саен киләләр алар... Кыр казлары... Апрель ахырларында... Айлы төннәрдә... Тыныч җирләргә, матур илләргә кайталар алар... Кешеләрнең күңелләрендә матур тойгылар уятып... Шул чакларда мин үземнең шушы җирдә яшәвем белән, кеше булуым белән чиксез горурланам!

Р ә д и ф. Мин китәм... Мин монда утыра алмыйм!

К ә р и м. Рәдиф, Рәдиф! (*Кычкырып кала.*)

Акрын гына пәрдә төшә. Гитара тавышы.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кулларына умырзаялар тоткан б е р е н ч е к л а с с у к у ч ы л а р ы авансценага килеп керәләр. Иң алдагы баланы җитәкләп, кап-карадан киенгән у к ы т у ч ы бара. Сәхнә аркылы үткәнче арттагы рәттәге малайлар берәм-берәм таялар. Балалар күзгә күренеп шукланалар.

У к ы т у ч ы (*борылмыйча гына*). Балалар, шауламагыз.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Без көләбез генә.

У к ы т у ч ы. Көләргә ярамавын беләсез.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Әнә безнең бакча.

У к ы т у ч ы (*кырыс*). Сафта тип-тигез генә барыгыз.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Анда без утырткан чияләр үсә.

У к ы т у ч ы. Вакыты җиткәч, бакчага да килербез.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Рабига апа, нигә кыш узгач яз килә?

У к ы т у ч ы. Сафта барганда сорау бирергә рөхсәт ителми.

У к у ч ы. Ә язын агачлар нигә яшәрәләр?

У к ы т у ч ы. Хәзер файдалы микроблар турында җыр җырлыйбыз.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Бу чәчәк нигә умырзая дип атала?

У к ы т у ч ы (*борылып, кырыс кына*). Шуны да белмисезме?

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез. (*Умырзаяларны җиргә ташлап чыгып китәләр.*)

Пәрдә ачыла. Бакча. Тик аның икенче ягы. Киртә тоткан зур гына бушлык. Агачлар артта, еракта гына шәйләнәләр. Урам. Урам яктан С а м а т белән ш о ф е р керәләр. Самат сүзсез генә җыр суза. Эчкә үтә. Иелеп туфрак ала, җирне таптап карый.

С а м а т. Җир шылтырап кипкән, Шайхра агай. Җиң сызганып эшкә керешергә була.

Ш о ф е р. Әй-һәй-һәй оста икәнсең, соң бу җир кашлак урын лабаса. Тау. Авылның маңгае. Районнан кайтканда борылыштан чыгуга шушы төш иң әүвәл күренә.

С а м а т (*атлап-атлап карый*). Ташны менә монда эчкә кертеп, тәртип белән генә бушатырсыз. Өлкән класс укучыларын ярдәмгә җибәрербез.

Ш о ф е р. Кайтып җитә алсак, анысы читенлек түгел. Тик нигә шулай ашыгасыз әле сез? Көзгә кадәр мәктәп түгел, пулат салырлык вакыт бар.

С а м а т. Беренче майга ташып куясы иде, Шайхра агай. Колхоз белән килешенгән. Машиналарыгыз хутта. Таш карьерда. Әзер. Акча күчерелгән.

Ш о ф е р. Әтә-тә, майлы ботка казанда, тәти кашык базарда. Түргә менеп утыр да ялана-ялана аша. Әзергә бәзер.

С а м а т. Өзеп әйт, Шайхра агай. Иртәгә-берсекөнгә районга барам.

Ш о ф е р. Күптән шунысын әйтсәңче. Районга барып аз-маз мактанып кайтырга исәп диген. Бәйрәм алды ярышы, фәлән-фәсхет... Бар, бар, Самат агай, мактанып кайт.

С а м а т. Ялганлый алмыйм, миңа өзеп кенә бер сүзең кирәк.

Ш о ф е р. Һай, эттәгенәсе, мич башында энкәсе. Сабагына эт эчәгесе уралган икән әле. Биисе дә килә, итәк тә тар. Куркак тагын үзең!

С а м а т (*уенга алып*). Куянны аяклары коткара.

Ш о ф е р. Керпене чәнечкеләре. Куян — атаклы куркак, керпе — егет.

К ә р и м керә.

Юк, вәгъдә бирә алмыйм. Юллар начар, бәләкәй генә яңгыр сибәләсә дә, бетте баш, калды муен сераеп.

К ә р и м. Сак та соң бу кеше дигәнең! Баш та исән булсын, муен да сынмасын. Тыныч яшәргә яратасыз, агай.

Ш о ф е р. Башны салырлык ук сәбәп күрмим мин. Әллә аңлап җиткермәдемме, Самат агай?

С а м а т. Менә материаллар өчен җаваплы иптәш үзе килде. Сөйләшегез, Кәрим. (*Чыга.*)

Ш о ф е р. Әле җиңгәң дә әйтеп торды. Кыш буе өзмикуймый көн аралаш кереп йөрде, нигәдер бу арада бер дә күренми, ди. Баксаң, мәктәп нигезен түшәргә әзерләнеп ятасыз икән.

К ә р и м. Вакыт, вакыт. Карагыз, көннәр нинди?..

Ш о ф е р. Сиңа йөкләгәннәр, без ташын ташыйсы. Самат районга барып мактанасы? Ничегрәк була соң инде бу?

К ә р и м. Саматны белмим, минем үземә кирәк ул яңа мәктәп. Бик кирәк.

Ш о ф е р. Куша да боера, ник авызыннан бер өметле

сүз чыксын. Бер ярты куярмын, шәпләп сыйлармын дип тә ычкындырмый.

Кәрим. Яртыны мин дә куймыйм.

Шофер. Син, туганай, бөтенләй башка чут. Син үз ишебез. Әйт әле син миңа шуны. Яңа мәктәп дип, син тыкырдатасың икән. Гыйлемлекне аны яңасында алсаң ни дә, искесендә ни. Әллә син дә теге, ярыш-фәлән дип кенә шыттырасыңмы?

Кәрим. Сүзегез хак. Тик миңа мәктәпнең үзеннән бигрәк шуны төзү процессы, шау-шуы, хезмәте, ыгы-зыгысы кирәк... Кайбер читләшебрәк йөргән укучыларымны берләштерә торган уртак эш кирәк. Бу минем соңгы чарам!

Шофер. Берләштерә торган дисеңме?

Кәрим. Шуңа өметләнәм. Шуңа ашыгам да...

Шофер. Карыйм-карыйм да гаҗәпләнәм. Ашыгып яшисең, туганай. Минем менә машинамны дүртенче тизлеккә дә куйганым юк.

Кәрим. Кешенең гомере чиксез түгел бит. Ул санаулы. Мөмкинлеге дә санаулы. Шул рәхимсез законга буйсынасым килми... Хәрәкәттә — бәрәкәт!..

Шофер. Тәки машинаны дүртенче тизлектә йөртергә кушасың инде?

Кәрим. Кушмыйм, үзең шундый теләк әйтеп торасың бит, агай! Әйдә, көз утырткан агачларны күрсәтәм. Чәчәккә бөреләнәләр!

Шофер. Үсәрләр дип ышанмаган идем, туганай.

Чыгалар, Самат керә, алар артыннан карап кала. Сүзсез генә җыр суза. Борчылып Гөлсем керә.

Самат. Бакча үсә башлар. Мәктәп төзелер. Бу Кәрим тагын нәрсә уйлап чыгарыр икән?

Гөлсем. Нәрсә кирәген тормыш үзе күрсәтер. Андыйлар гомергә тынмыйлар, янып үләләр. Бәйгеләрдә чапкан ат кебек.

Самат. Тубал тотып чия сатарга чыгармы?

Гөлсем. Чия сату өлеше сиңа калмасын.

Самат. Нигә шундый рәхимсезлек? (*Сүзсез генә җыр суза.*)

Гөлсем. Синең җырыңның берәр вакыт сүзе булырмы?

Самат (*елмаеп*). Көт. Түземлегең җитсә булыр. (*Пауза.*) Нигәдер бу сорауны еш бирә башладың.

Гөлсем. Элек мин синең дә, үземнең дә җитешмәгән якларыма игътибар итми идем. Барамы тормыш — бара, көннәр үтәме — үтә...

Самат. Мине яратмый башладыңмы?

Г ө л с е м. Йа Ходай! Син ул сүзне онытмадыңмыни әле?.. Мәгънәсен әшәкеләсәң дә, тагын бер кат кабатла әле.

С а м а т. Яратмый башлагансың, дидем.

Г ө л с е м. Бу сине бер тамчы да куркытмыймы?

Сумкасын селкеп З ә н ә керә, эти-әнисен күреп туктый. Акрын-акрын һаман якынрак килә.

С а м а т. Тагын нәрсә үпкәләдең икән? (*Сүзсез җыр суза.*) Белмим.

Г ө л с е м. Унынчы класстагы дәресләреннән баш тарттың. Оятымнан җир тишегенә керердәй булсам да, түздем.

С а м а т. Монда минем гаебем юк. Язга директорның эше күбәюен беләсең.

Г ө л с е м. Акча түләүле дәрес булса, син, мөгаен, аны ычкындырмас идең... Дәресләреңне Кәрим алды! Ул бит тарихчы да түгел әле, әдәбиятчы!

С а м а т. Кырык гаепнең кырыгын да тактың миңа.

Г ө л с е м. Санаганнары утыз тугыз гына. Кырыгынчысын син бүген ясагансың.

С а м а т. Төгәллек яратам. Булгач булгач кырыкка тулсын, дидем.

Г ө л с е м. Материаллар артыннан йөрүне дә Кәримгә йөкләгәнсең икән ич.

С а м а т. Кәрим, эшсез тора алмыйм, диде. Кешеләрнең теләгенә аркылы төшә алмыйм. (*Сүзсез генә җыр суза.*)

Г ө л с е м. Җырының сүзе дә булган кеше белән гомер итү ничек рәхәттер!

С а м а т (*ниһаять, кызып*). Җырлатып карап сайларга иде!

З ә н ә (*якын ук килеп*). Менә бу сюрприз! Тезләрем калтырый. Авыл уртасына чыгып мужиклар төсле ызгышып яталар.

С а м а т. Әниең гаепле.

З ә н ә. Кәрим түгелме?.. Ул хәйләкәр песи тырнакларын күрсәтер әле! Хәзер бездә ике фәннән экзамен алачак. Утыртып калдырачак ул мине.

Г ө л с е м. Бөтен авылда, бөтен мәктәптә Кәримне яратмаган ике генә кеше калды. Аның берсе минем ирем, икенчесе кызым. Туктала белегез, ичмасам!

З ә н ә. Ялагайлана белмим! Теләмим дә.

С а м а т. Сүзләреңнән озак торган балык исе килә башлады. (*Чыга.*)

Г ө л с е м. Менә сөйләш син аның белән... Кеше төсле генә аңлаш... (*Зәнәгә.*) Син кайтмыйсыңмыни?

З ә н ә. Юк әле. Син бар, кайт. Монда торма. Берәрсе жылаганыңны күрер.

Гөлсем яшьләрен сөртә, тиз-тиз чыгып китә. Фуражкасын алдын артына кигән Шәрифҗан керә.

Шәрифҗан. Күрегезче, Зәнә дә эшләшергә килгән. Өмәгә!

Зәнә. Ялагай номер бер. Менә син кем.

Шәрифҗан (*шундук җитдиләнә*). Ялагай? (*Фуражкасын рәтләп кия.*) Инглизчә ничек була әле? Онытылган. Татарчасының мәгънәсе ачык. Элек, борын-борында, мактанчык болгар биләре үз яннарында махсус тәлинкә ялаучылар тотканнар.

Зәнә. Фу, җирәнгеч...

Шәрифҗан. Тарихка борыныңны җыерып карама.

Зәнә. Һәм мактанчык.

Шәрифҗан (*муенын кашып*). Инглизчәсе?.. Белмим. Сүзлекне аласы калган. Өйгә эшне күбәйтмә әле. Тагын ничә сүзең бар? (*Язарга әзерләнгәндәй итә.*)

Зәнә. Калганнары сиңа түгел.

Шәрифҗан (*мыскыллап*). Одессагамы? Зәңгәр диңгез, ак пароход. Әйдә, матур сүзләреңне миңа әйтеп бетермәгән булсаң, магнитофонда язабыз да җан дустыңа салабыз.

Зәнә. Нахал.

Шәрифҗан (*кинәт моңаеп*). Шәрифҗан. Менә таныштык та, иптәш Нахал. (*Бакча ягына караштырып.*) Курай үсеп чыкмаганмы? (*Зәнә кызара.*) О, Зәнә, колакларың, колакларың...

Зәнә (*еламсырап*). Син кыш буе мине үчекләдең! Кыш буе! Җитмәдемени әле?.. Мин дә синнән үчемне алырмын! Бер килеп эләгерсең әле!..

Шәрифҗан. Гафу ит... Кичер, Зәнә... Җылама инде.

Зәнә. Җылаганнар ди берәүләр. Бер тамчы яшемне күрсәтмәм.

Шәрифҗан. Уйга килгәннәр телгә килми... Тел — биктә. (*Бакчага карап.*) Әллә минем эти йөри инде? Кәрим дә шунда бит! (*Урамда Рәдифне күреп.*) Әй, Рәдиф!

Рәдиф (*кереп*). Кайтып, өс-башны алыштырып килик инде.

Шәрифҗан. Нинди кайту ул. Йәт-йәт кенә бетерәбез дә ташлыйбыз.

Зәнә. Рәдиф, син дә өмәләргә йөри башладың бит.

Шәрифҗан (*фуражкасы белән җирне каплап*). Кәлтә елан!

Рәдиф. Яшелме? Тотма, йөрсен.

Шәрифҗан. Ялганладым. Еланнар әле бәй-бәй итәләр. Әнә Зәнәдән сора. Әнә — Зәнә! Әнә — Зәнә! Рифма. (*Рәдифкә.*) Сатам.

Р ә д и ф. Алам.

З ә н ә. Рәдиф, мин синең белән сөйләшәм.

Р ә д и ф. Күрәсең бит, эшләп алырга дип килдек.

Бакчага керен китәләр. Зәнә нәүмизләнеп йөри. И л ш а т керә.

И л ш а т. Малайлар, малайлар!

З ә н ә. Малайлар, малайлар...

И л ш а т. Кайтмадыңмыни, Зәнә?

З ә н ә. Илшат-шат!.. Илшат-шат! Рифма. Сатам! Алasыңмы?

И л ш а т. Рәхмәт. Җирнең туңы бетте микән?

З ә н ә. Җирнең туңы бетәр, аның кояшы бар...

И л ш а т. Озакламый таш китерә башлыйлар. Бүген без киртәләрне күчереп куябыз. Безнең бакчага кәҗә кермәсен.

З ә н ә. Озакламый анда курай үсәр... Ул курайны көтүче кисеп алыр... Юк, керсен кәҗәләр!.. Кәҗәләр — минем бердәнбер союзникларым. Чикне ачыгыз аларга!

И л ш а т. Онытмадыңмыни әле син ул әкиятне?

З ә н ә. Ә син?

И л ш а т. Онытмадым... Онытырга теләмим дә... Барабызмы?

З ә н ә. Зур эш тапшырганнар сезгә. Мактаулы, почетлы эш.

И л ш а т. Эшнең зурысы, кечесе буламыни?

З ә н ә. Лозунгларны Кәримнән ятлыйсыңмы? Шәп лидер таптыгыз сез. Дөньягызны оныттыгыз.

И л ш а т. Дөнья абстракт төшенчә түгел бит, Зәнә. Менә шушы авыл, кырлар, дүрт якта да офык. Офык артындагы шәһәрләр. Идел, Кама, Казан, Тукай — шулар ич инде минем бишегем, минем дөньям.

З ә н ә. Мондадыр безнең бабайлар... Мондадыр оҗмах, хурлар! Ялган... Кәрим сүзләре.

И л ш а т. Тукай сүзләре, Тукай.

З ә н ә. Кеше җиргә бәхет, ләззәт, наз өчен туа. Бәхет өчен бернинди чикләр дә, офыклар да юк. Кара, сукыр, ач күзеңне: яз җитте бит, яз. Весна, Шәрифҗан бытылдагандай, «спринг»!.. Кая китте синең хыялларың?

И л ш а т. Хыяллар үз төсмерләрен алдылар.

З ә н ә. Во имя чего?

И л ш а т. Шулай булырга тиеш түгелмени?.. Кешене үзеннән бигрәк башкаларның аңа булган мөнәсәбәте, тирәяк үзгәртә. Минем кешеләрчә яшисем килә.

З ә н ә. Кешеләрчә, кешеләрчә... Мин сине һәр көн көтеп алам. Яңгырда, карда... Ә син һаман шул Кәримнең иярчене. Көн дә, кич тә, төн дә аның белән. Үзең балалар кебек беркатлы. Әрәм итәрсең, Илшат, син башларыңны!

И л ш а т. Син явыз, Зәнә, явыз... Шуңа күрә юашны эзлисең...

Бакча эчендә кычкырып көләләр. Гомумән, бакча эчендә хәрәкәт, шаушу ишетелеп тора. Илшат ул якка тартылып-тартылып ала. Егетләр ара-тирә: «Илшат, Илшат»,— дип кычкыралар.

З ә н ә. Син кайчандыр юаш идең... Ә хәзер...

И л ш а т. Чакыралар.

З ә н ә (*аны тотып кала*). Әйдә, экзаменнарга бергә әзерләнәбез. Гел-гел бергә йөрибез.

И л ш а т. Риза. Хәзерләнүк бергә.

З ә н ә. Алайса ташла эшеңне, оныт иптәшләреңне.

И л ш а т. Син нигә шулхәтле усал?

З ә н ә. Бөтенләй усал түгел. Түгел! Одессадан миңа егет яза дип уйлыйсыңмы? Апаның кызы ул. Унынчыны бетерә. Без юри, малайларны көнләштерер өчен, конвертларга егетләр исеме куеп язышабыз.

И л ш а т. Тормышның ямен буш кызыклардан эзлисең.

З ә н ә (*сумкасыннан хатлар ала*). Ышанмасаң, укы.

И л ш а т. Укымыйча да ышанам.

З ә н ә. Гел-гел бергә булыйк... Тик йөрмә шул аңгыра Шәрифҗаннар, мактанчык Рәдифләр белән. Китик моннан! Сахалинга!.. Менә кайда эшлиләр икән акчаны!

И л ш а т. Юк, Зәнә. Әнә безнең Сәгыйть абыйлар Сахалинга киттеләр дә югалдылар. Биш елга бер сабан туена кайтып кына, үз җиреңне күрмичә, үз суыңны эчмичә ничек яшәмәк кирәк? Акчаны көрәп бирсәләр дә, менә шушы инешне, язгы кичләрдә аръякта яңгыраган җырларны нинди акчага сатып алырсың? Бәхетне акчага сатып аласым килми... Бәләкәй чактан ук укытучы булам дип йөри идем. Үсә төшкәч бу фикерем ничектер чатнады... Хәзер кабат үз уема төштем: укытучы булам.

З ә н ә (*шыпырт диярлек*). Син мине яратмыйсыңмы?

И л ш а т. Бу — син мине яратмыйсың, Зәнә.

З ә н ә. Минем синең белән буласым килә.

И л ш а т. Зәнә...

З ә н ә. Сине чакыралар.

И л ш а т. Алар сине дә чакыралар.

З ә н ә. Юк, үз язмышын үз кулында тоткан буйсынмас кеше булып каласым килә.

И л ш а т. Ихтыярың. (*Чыга.*)

Зәнә текәлеп аны озата. Г а я н керә.

Г а я н. Безнеке кайтып җитмәде.

З ә н ә (*күрсәтеп*). Әнә алар...

Г а я н. Теге ямьсезкәй дә шундамы?

З ә н ә. Кайларга китсен ул?

Г а я н. Сүзем бар иде аңа, бер сүзем...

З ә н ә. Нинди сүз ул, Гаян апа? Нигә аны миңа әйтмисең?

Г а я н. Сиңа ярамый... Әле синең күпне яшисең, сынасың, сыналасың бар. Көнең-сәгатең җитмәгән... (*Чыга.*)

Зәнә китәргә дә, китмәскә дә икеләнеп тора, аның янына К ә р и м килә.

К ә р и м. Киртәләр җимерелде, атла, кыюрак бул, Зәнә.

З ә н ә. Кыю да итәсегез килә мине, яхшы да. Ә мин теләмәсәм?

К ә р и м. Малайлар тагын сине рәнҗеткәннәр.

З ә н ә. Үрелгәннәр иде, буйлары җитмәде.

К ә р и м. Син китәсеңме?

З ә н ә. Рәхимле йөзегезне күреп нәфрәтләнәм. Яхшылык — хәйләнең юлдашы...

К ә р и м. Алар барысы да сине яраталар.

З ә н ә. Юмартланганнар сезнең шәкертләр! (*Чыгып китә.*)

Бакчада көлгән тавышлар. Ш о ф е р керә.

Ш о ф е р. Мине дә укырга алчы, туганай!.. Ни булды сиңа?

К ә р и м. Килегез, кил, агай. Бер өй эченнән мәктәптә бишәү булырсыз.

Ш о ф е р. Заманалар авыр булды шул, юньле-башлы укый алмадым. Шулай да беренче хәреф таныткан Гомәр абзыйны һич тә онытасым юк.

К ә р и м. Хәзер кайда ул?

Ш о ф е р. Сугышта үлде. Беркөнне бергә фронтка киттек. Мәскәүне сакладык. Шунда, буранлы декабрь көнендә ятып калды Гомер абзый. Синдә дә шуның чалымнары бар менә, туганай!

И л ш а т керә.

И л ш а т. Тотындыкмы, Кәрим абый?

К ә р и м. Башлагыз!

Чыгалар. Шатыр-шотыр эшләгән тавышлар килә. С а м а т кереп карап тора, сүзсез генә җырын суза. З ә н ә керә, кулында плащ.

З ә н ә. Әти, әти!

С а м а т. Ни әйтәсең, кызым?

З ә н ә. Мине районга илтеп кайтар әле. Машина бир.

С а м а т. Сине чакырганнарын ишетми калдым, ахры.

З ә н ә. Үзем барам. Чыдый алмыйм, үзем барып сөйләшәм.

С а м а т. Төнгә каршы нинди юл ди ул?

З ә н ә. Машина бирмәсәң, җәяү китәм.

С а м а т. Барыгыз да миңа баш бирмәскә уйлыйсызмы?

З ә н ә. Үрмәләп булса да барам.

С а м а т. Зәнә, Зәнә, кызым, кайт! Йөрмә. Шушы арада инспектор үзе килә.

Зәнә китә.

Кулымнан килсә, кулымнан килсә, тормыш бутап йөрүчеләрнең барысын да... (*Чыгып китә.*)

Бакча ягында көлгән тавышлар. Егетләр шатыр-шотыр киртә аударалар. К ә р и м белән ш о ф е р керә.

Ш о ф е р. Искенең шул инде аның, биш торыгы бергә чукынып төште!

К ә р и м. Тик ул гына юк... Ул гына юк... (*Утыра, ничектер үзгәрә. Шофер аны килеп тота.*)

Ш о ф е р. Туганай, ни булды сиңа?.. Балалар, укытучыгыз үлә!

Пәрдә төшә, кемдер ачы итеп кычкыра. Сәхнә алдына чәчләре тузган Г а я н йөгереп керә.

Г а я н. Сүзем бар иде аңа, бер генә сүзем... Давыл килде, боз сукты, игеннәрне урып ала алмадык!.. (*Чыга.*)

Авансценага кулларына венок тоткан б е р е н ч е к л а с с у к у ч ы л а р ы килеп керәләр. Ачык-якты күлмәк кигән у к ы т у ч ы х а н ы м бер кырыйдан бара.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Апа, нигә кеше туа?

У к ы т у ч ы (*кырыс*). Нигә дип... Яшәр өчен...

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Кеше ничек яши, апа?

У к ы т у ч ы. Ничек дип... Укый, эшли, яши шунда...

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Ә нигә кеше үлә, апа?

У к ы т у ч ы. Анысын үсә төшкәч аңларсыз.

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Нигә кешене җиргә күмәләр?

У к ы т у ч ы. Шуны да белмисезме?

У к у ч ы л а р (*хор белән*). Без әле бернәрсә дә белмибез. (*Чыгып китәләр.*)

Караңгылана. Пәрдә күтәрелә. Төн. Тәрәзә. Өстәл лампасы яна. Өстәл янында плащ кигән, таушалган М а р а т утыра. Урам яктан З ә н ә килә. Нык кына шакый. Марат ишек ача. Зәнә керә.

З ә н ә. Менә... мин килдем.

М а р а т. Сез кем?

З ә н ә. Зәнә. Самат Гаязовичның кызы.

М а р а т. Мине ничек эзләп таптыгыз?

З ә н ә. Каравылчы өйрәтте. (*Утыра.*) Мин төн буе җәяү килдем.

Марат. Беләм. Мин барысын да ишеттем.

Зәнә. Әти сөйләдеме? Тик ул барын да белми.

Марат. Хәзер барын да...

Зәнә. Су бирегез әле. (*Марат су китерә.*) Бу су кайнаганмы? (*Эчә.*) Ул һәрвакыт сезгә каршы котырта. Сезне яратмый. Мәктәпләрдә кайвакыт былбыл балаларын каргага әйләндереп чыгаралар, ди. Каргаларның берсе...

Марат (*Зәнәгә карап тора*). Син кем?

Зәнә (*куркынып*). Зәнә... Унынчы класс...

Марат. Сезнең мәктәптә унынчы класс юк.

Зәнә. Ә без? Мин?

Марат. Син дә юк. Ул сезне юктан бар итте. Саклап калды. Ул!

Зәнә. Барыбер аны бездә берәү дә яратмый. Күчерегез аны!

Марат. Күчерергә, күчерергә... Тик кая? Кайларда гына эшләмәгән ул. Аның якын туганнары юк. Хатыны бәбәйдән үлгән.

Зәнә. Төне буе җәяү килдем. Авылларда этләр улый. Куркыныч...

Марат. Күчерергә, күчерергә... Тик кая? Үзеннән сорар идең, үзе юк. (*Зәнә каршысына басып.*) Син — бар, ә ул — юк.

Зәнә. Ничек юк?

Марат. Авыру иде ул. Яман иде аның чире. Злокачественное малокровие дип атала ул зәһәр чир. Дәва юк аңа! Күп эшләгән, үзен-үзе аямаган кешеләрнең гомерен кыя торган чир. Тик ул үзенең чирен беркемгә дә әйттермәде.

Зәнә. Ой! (*Елый.*)

Марат. Җыла, җыла... Мине яратмый иде дисең... Бәлки аннан да ныграк яраткан кеше булмагандыр мине. Кем ярата мине? Синме? Әтиеңме?

Зәнә. Ялгышты бит башларым...

Марат. Җыла, җыла.

Зәнә. Бу якты дөньяларда ничек яшәрмен?

Марат. Синең кебекләр озак яшиләр. Әйдә, киттек.

Зәнә. Кая?

Марат. Укытучыбыз янына.

Зәнә. Мин сезнең белән бармыйм. Юк, юк. (*Чыгып йөгерә.*)

Марат иягең учлап идән уртасында басып тора. Ут сүнә. Зәнә авансценага йөгереп чыга. Пәрдә төшә. Пәрдәдә ут көлтәсе. Машина тавышы. Шофер керә.

Шофер. Монда нишлисең, туганай?

Зәнә. Белмим.

Шофер. Кайда йөрдең?

Зәнә. Аны тел беләән әйтеп булмый, Шайхразый агай.
Шофер. Болай аңгырайган дүдәк кебек йөрмә, әйдә.

Чыгып китәләр. Машина тавышы. Пәрдә күтәрелә. Барысы да тына. Күк биек-биек. Айлы апрель төне. Киек Каз Юлы ялтырап ята. Бакчада, яшь агачлар арасында, өчесе өч җирдә Илшат, Шәрифҗан, Рәдиф басып торалар.

Рәдиф. Берне көйрәтәсе килеп китте.
Илшат. Ярамый. Ул рәнҗер. Без сүз бирдек.
Шәрифҗан. Сәгать ун.
Рәдиф. Өченче төн монда утырабыз.
Илшат. Ә ул өченче төн анда, җир куенында...
Шәрифҗан. Ул әйтте бит: апрель ахырларында, айлы төннәрдә, диде. Ел саен киләләр, диде.
Рәдиф. Башка елларны килделәрме икән?
Илшат. Берәү дә белми. Быел килерләр.
Шәрифҗан. Быел җирдә безнең бакчабыз үсә.
Илшат. Быел бу җирдә ул ята.
Рәдиф. Көтик. (*Пауза.*)
Илшат. Казанга баргач Академия театрында «Киек Каз Юлы» дигән спектакль караган идем. Театрдан чыккач бик күп тамашачыларның «Киек Каз Юлы»н белмәүләрен аңладым.
Рәдиф. Белмиләрме?
Илшат. Белмиләр. Димәк, ул кешеләр бервакытта да күккә күтәрелеп карамаганнар.
Шәрифҗан. Кемдер аларның башларын аска таба игән...
Рәдиф. Ул бәхетсезләр зәп-зәңгәр күккә, фирүзә йолдызларга гашыйк булып апрель төннәрендә өй нигезләрендә берчакта да утырмаганнар.
Илшат. Аларның тормыш юлларында Кәрим Хәернасов кебек кеше очрамаган.
Шәрифҗан. Әнә ул... Киек Каз Юлы...
Рәдиф. Зәнә кайда икән?
Илшат. Өченче төн күренми.

Гөлсем керә.

Гөлсем. Бөтен җирдә яңару, тереклек, яз исе...
Шәрифҗан. Ишетелми әле, Гөлсем апа.
Гөлсем. Килерләр, килерләр...

Гаян керә.

Гаян. Без тәрәзәдә ут сүндермибез. Ямьсезкәй кайтмадымы?
Илшат. Әни!

Р ә д и ф (*пышылдап кына*). Өегезгә илтеп куйыйк.

И л ш а т. Тимә! Айлы төннәрдә тыныч ул.

Г а я н. Сүзем бар иде ямьсезкәйгә, бер сүзем.

Г ө л с е м. Ямьсезкәй... Дөньяда аннан да матур кешене белмим мин, Гаян апа.

Гаян белән Гөлсем чыгалар.

Р ә д и ф. Туктагыз!

Ш ә р и ф җ а н. Юк, бу тишелеп килгән үлән кыяклары үзара сөйләшәләр.

И л ш а т. Ишетәсезме? Кыр казлары килә!

Ш ә р и ф җ а н. Нәкъ безнең авыл өстеннән.

Өчесе дә хәрәкәткә киләләр. Ай нурына коенган биек-биек күк өстеннән көмешсыман кыр казлары тавышы коела.

И л ш а т. Нәкъ безнең бакча өстеннән.

Р ә д и ф. Ничек, ә?

Ш ә р и ф җ а н. Телләрен аңларга...

Р ә д и ф (*сокланып*). Ничек, ә?

Ш ә р и ф җ а н. Гомер-гомергә, ел саен, мәңгегә очсыннар алар безнең ил өстеннән.

И л ш а т. Рәхим итегез, илаһи кунаклар, кыр казлары!

З ә н ә керә. Ул бер читтә кара күләгә булып басып тора.

Зәнә, Зәнә, ишетәсеңме, кыр казлары уза.

Р ә д и ф. Безнең авыл өстеннән, Зәнә.

Ш ә р и ф җ а н. Безнең бакча өстеннән, Зәнә.

З ә н ә. Сезнең янга килергә ярыймы?

И л ш а т. Кил, Зәнә. Сиңа салкын түгелме?

Р ә д и ф. Кил. Минем пиджакны ки.

И л ш а т. Кыр казлары, ә?

Ш ә р и ф җ а н. Нәкъ безнең чокырлар өстеннән...

И л ш а т. Аның кабере өстеннән.

З ә н ә. Апрель ахырларында курай борын төртсә... Ул курайны көтүче кисеп алса... Сез мине кумыйсызмы?

И л ш а т. Апрель ахырларында кыр казлары килә... Тату илләргә, тыныч илләргә... Менә без тагын дүртебез... Кыр казлары да безнең белән... Очыгыз, кыр казлары, очыгыз!

Кыр казлары кычкыралар, Зәнә яулык болгый. Дүртесе дүрт җиргә басалар.

П ә р д ә.

*Казан — Хуҗайлан — Ялта — Казан*
*1966—1967*

# *Шомырт чәчәк атканда*

*Өч пәрдәдә*
*Аз гына көлке пьеса*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Фәридә.
Наилә.
Галия.
Җамал карчык.
Сәрвиназ.
Әндәрҗан.
Марат бабай.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман авызы. Шомыртлар ап-ак чәчәктә. Язгы иртә. Өздереп-өздереп кошлар сайрый. Күке кычкыра. Бер-берсеннән шактый еракта ике палатка. Палаткаларның берсе зуррак, икенчесе кечкенә. Озын бишмәт, колакчын бүрек кигән Марат бабай керә. Ул мылтыгын кочаклап сак кына йөри. Палаткалар ишеге төбендә таптанып тора да китәргә кузгала.

Марат. Йоклыйлар. Их, елның алтын вакытын йоклап үткәрәләр. Аңламассың хәзерге заманның яшьләрен... Их, их, чак кына карарак булса бу сакал!.. Атка менеп бер җилдереп кайтыр идем. Тирә-яктагы кызларның йокысы качар иде. Ә хәзер өчесе тиң меслəп яталар. Бармы дөньяда Марат, юкмы, аларга барыбер... Их, яшәүнең, гомернең ямен белмиләр... (*Чыга.*)

Менә олы палатканың ишек япмасы күтәрелә. Наилә чыга. Көннең матурлыгына сокланып әйләнгәли.

Наилә (*җырлый*).

Йөгерә-йөгерә кудым җилне,
Тоттырмады җитез җил.
Ялгызлыктан газаплансаң,
Минем янга үзең кил.
Кил, кил, кил, гүзәлем,

Өзелмәсен үзәгем.
Ак дулкыннарны учыма
Сыйдырырга теләдем.
Алар качты, белми китте
Үзәгем өзелгәнен.
Кояш нурын кочагыма
Төясем килә бүген!
Җирне, күкне, җилне, нурны
Сөясем килә бүген.

(*Туктый. Шомырт тирәли әйләнгәли.*)

Нигә? Белмим.
Таңнан торып җилне куам
Нигә, нигә?
Шаян дулкын миңа туган
Нигә, нигә?
Кемнән сорыйм? Кемгә сөйлим?
Кемгә, кемгә?

(*Шомырт агачы янында туктый.*) Сиңа сөйлимме, шомыртым? Исәнме. Хәерле иртә... Ишетәсеңме мине? Күрәсеңме мине? Бу мин — Наилә. На-илә!.. Наиләнең сөйләшәсе килә... Без менә шушы палаткада өч кыз торабыз. Хәер, син аларны беләсең ич. Белмим дисеңме?.. А, әле кичә генә синең күзләрең йомык иде шул. Югыйсә шундый сылу кызларны күрми калыр идеңме? Алайса, үзем таныштырам. (*Палатканы күрсәтеп.*) Бусында без өчәү... Ә тегесендә безнең өлкән техник Әндәрҗан йоклый. Чү, ишетәсеңме? Тигез генә сулый... Без — мелиораторлар. Сазлыклар киптерәбез, болыннарны әшәке куаклардан арчыйбыз, коелар, сулыклар казыйбыз, чишмәләр чыгарабыз. Бер ай монда, унбиш көн тегендә, чегәннәр кебек тик күченеп йөрибез. Безнең вагон шушы ук палаткалар ияреп йөри. Берсендә өч сылу кыз, ә берсендә... Әндәрҗан. Чибәр егет, шомырткаем, ышан миңа! Каравылчыбыз гына күченгән саен яңа була. Якын-тирә авыллардан алабыз. Мондагысы Марат бабай. (*Шыпырт кына көлә.*) Кызыкмы? Исеме кызыкмы, дим. Аның әтисеме, бабасымы «Потемкин» броненосецындагы атаклы восстаниедә катнашкан. Дөнья гизгән, улына да шундый атаклы исем биргән... Без монда унбиш көн торабыз инде. Агачлар яфрак ярды, син чәчәк — күзләреңне ачтың... Көн саен үзгәреш, адым саен яңарыш, ә без һаман шул ук кешеләр яшәп ятабыз. Тормыш бертөсле ага. Бер-беребезне, гадәт-холыкны күптән белеп бетердек. Хәтта азрак ямансурак та була башлады. Иң элек мин йокыдан торам. Һәр көн шулай була. Шул ук чират кабатлана.

Сәгать... Сәгать... Ой, хәзер Әндәрҗан торып чыгачак. Чыга да бернәрсәгә дә карамыйча чүгәләп, тураеп ала. Аннары мине күрә. Елмаймый, шәбәеп кенә: «Почта кагылмадымы, документлар килмәдеме?» — дип сорый. Ой, ул кеше көн яктысында гына шундый эре, хәтәр... Былтыр ул да безнең кебек гади кеше иде, быел аны өлкән техник итеп җибәрделәр. Үзгәрде дә куйды малаең!.. Хәер, ялгыз калган чакларда ул һаман элекке кебек... Ой, шомыртым, кичә безнең ялгыз йөргәнне үзең дә күрдең ич!

Кечкенә палаткадан Әндәрҗан чыга. Чүгәли, турая. Наилә көлеп карап тора.

Әндәрҗан. Почта кагылмадымы? Документлар килмәдеме?

Наилә (*шомыртка*). Әйтмәдемме?

Әндәрҗан. Нәрсә әйткән идең, Наилә?

Наилә. Бу — сер.

Әндәрҗан. Куркак кешенең генә сере була.

Наилә. Алайса, почта кагылмады, документлар кайтып җитмәде. Без тагын эшсез утырачакбыз, бусы беркемгә дә сер түгел.

Әндәрҗан. Телең... (*Сөлгесен иңбашына салып коеныrга төшеп китә.*)

Наилә. Күрдеңме, шомыртым, техник исеме егетне ничек хәтәр итә? Хәзер, аның уянганын күреп, Марат бабай килеп җитәчәк... Начальствога уяулыкны күрсәтеп калырга кирәк! Аннары Марат бабай Әндәрҗанны сәер бер мәхәббәт белән ярата, карт булса да аңар ошарга тырыша... Әнә килә. Аның да сүзләре мәгълүм. Үзе юлдан Әндәрҗанны сагалар, үзе миңа: «Ничек соң, кызым, черкиләр ашап бетермәдеме? Алар бит тәмлене яраталар», — диер... Килде!

Марат керә.

Марат. Ничек соң, кызым, черкиләр ашап бетермәдеме? Алар бит тәмлене яраталар.

Наилә. Алайса, алар сиңа охшаганнар икән, Марат бабай.

Марат. Кая ул, картайгач авызның тәме бетә икән, тәмле-тәмсезне дә аерып булмый.

Наилә. Без бит өчәү, Марат бабай. Фәридә, Галия, мин. Алар миңа караганда тәмлерәкләр. Черкиләр гел аларга куна! (*Шомыртка.*) Карап тор, хәзер Марат бабай көлә.

Марат (*көлә*). Хи-хи-хи, кызым, арада иң-иң татлысы, балдай ширбәтлесе син. Әндәрҗан, очлы күз, сине эләктереп алган бит!

Н а и л ә. Шушы турыда тукта инде, Марат бабай. Калганнарын үзем дә беләм. (*Шомыртка.*) Күрдеңме?

М а р а т. Кемне? Җамал карчык белән Сәрвиназ-каракаш килгәннәрме әллә?

Н а и л ә. Безнең көннең ныклы бер режимы бар, Марат бабай. Син генә аны боздырма! Алар килергә чак кына иртәрәк. Аңа кадәр әле...

М а р а т. Тамак төбе кычытып торганга әйтүем...

Н а и л ә. Үзеңнең йокылар тәмле булдымы соң?

М а р а т. Тол кешенең йокысын әйтерең бармы, кызым. Бер күзеңне көч-хәл белән тырышып-тырышып йомасың, каһәр суккыры, икенчесе барыбер ачык кала! (*Чыга.*)

Н а и л ә. Көн тәртибе буенча хәзер Фәридә уяна. Палаткадан чыга да бөеренә таянып минем алда зыр-зыр әйләнә. Чырык-чырык көлә. «Матурмы мин?» дип сорый. Минем җавапны да көтеп тормый, «Матур шул, матур!» дип, бөтен урманны яңгыратып кычкыра. Тавышы да матур, үзе дә сылу. Үзе уйчан да, акыллы да, күп укыган, әйбәт кыз. Аның белән яшәү рәхәт... Аннары Фәридә белән икәү Галияне уята башлыйбыз. Озак маташабыз, үгетлибез, ялынабыз. Бик озак азаплангач кына Галия көнгә чыга. «Тагын иртә уятканнар, кояш бит әле әнә кайда гына!» дип, тәмләп безне әрли... Барыбыз да уянып беткәч көндәлек эшләр, мәшәкатьләр үз чиратында тезелешәләр, һәр көн шушы үзгәрмәс тәртип... Тормыш үзгәрешсез. Авыллар читтә, без сазлыкта. Зирек әрәмәләре... Гомер уза да уза... Кайчан салкыннар башланыр да без район үзәгенә кайтып китәрбез. Ой, Фәридә уяныр чак җитте. Күр, шомыртым, нинди шат, нинди көләч ул безнең Фәридәбез

Палатка япмасы ачыла. Чәчләре тузган, ап-ак җәймәгә уралган Г а л и я башын бер якка кыегайтып килеп чыга. Абынып егылам дигәндә, Наилә аны тотып кала.

Н а и л ә. Чү, бу ни хәл?

Г а л и я. Йокладыммы бүген, йокламадыммы, белмим.

Н а и л ә. Галия, сиңа ни булды? Ничек үзең торасы иттең, йокы чүлмәге?

Г а л и я. Фәридә анда... (*Йоклап китә.*)

Н а и л ә. Фәридәгә нәрсә булган? Уян әле, уян...

Г а л и я. Белмим, җылыймы, җыламыйммы шунда...

Н а и л ә. Син бүген иртә таңнан шаярасың! Фәридә җылый белә диме?

Г а л и я. Йокладыммы бүген, юкмы, белмим.

Н а и л ә. Мөгаен, авырып киткәндер. (*Барып палатка япмасын ике якка каерып куя. Анда Фәридә утыра.*)

Галия. Кеше гомереңнең өчтән бер өлешен йоклап уздырырга тиеш. Моны галимнәр исбатлаган.

Наилә. Фәридә җаным, авырыйсыңмы әллә?

Фәридә (*күз яшьләрен сөртеп*). Авырмыйм.

Наилә. Берәрсе кимсеттеме әллә, хәтерең калдымы?

Фәридә. Әйе.

Наилә. Кем?

Фәридә. Тәкәрлек белән чөлди.

Наилә. Мөгаен, Әндәрҗан берәр авыр сүз әйткәндер әле.

Фәридә. Юк дидем ич инде.

Наилә. Фәридә, Фәридә, әшәке төш күреп саташтыңмы әллә? Уян, монда чык: элекке кебек көл ичмасам.

Фәридә. Юк, юк... Көлмим. Чыкмыйм. Берни дә эшләмим.

Наилә (*шомыртка*). Акылым ирешми. Ни булган бу кызга?

Фәридә. Өченче языбызны тәкәрлекләр, черкиләр белән бергә уздырабыз. Палатка булып, палатка чыдамый, әнә тишелгән... Ә черкиләре дошман самолетлары кебек безелдиләр. У-у! (*Селтәнә.*)

Наилә. Бер акыллы кеше әйткән. Яңгырдан соң ике кеше түбәнгә карап торалар. Берсе җыелып торган пычрак су күрә, икенчесе шул суда йөзгән йолдызларны.

Галия. Ә? Суда йолдыз йөзә димени?..

Фәридә. Акыллы сүзләрне яшь чагында биш блокнот җыйдым. Йолдызлар өйрәнергә мин астроном түгел.

Галия. Юньле кеше йокламыйча йолдыз карап йөриме? Көндез күренсеннәр иде алар.

Наилә. Чын бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә... Без ишеткән рәхмәт сүзләре!.. Карлыда бәреп чыккан Фәридә чишмәсе?.. Болары онытылдымы?

Фәридә. Хәл кадәренчә эшләдек... Тырыштык... Рәхмәт белән генә тун тегеп булмый. Районда да эш бетмәгән. Ташлыйм да кайтып китәм. Чәнчелсен сазлыгы, у-у, ничек безелдиләр!

Наилә. Көн тәртибе бозылды...

Фәридә (*җырлый*).

Йөзәсе иде аксыл дулкыннарда,
Очасы иде зәңгәр һавада.
Тик язмышым минем яшьлегемне
Алып китте әллә кайларга.
Менәсе иде биек-биек тауга,
Төшәсе иде яшел болынга.
Тик язмышым минем яшьлегемне
Китергән бит шушы урынга.

(*Туктый, шигырь итеп укый.*)

Йөрәгемнең шатлык-бәхетләре
Акрын гына эреп бетә.
Беләм, офыклар артында
Бәхет-шатлык мине көтә.

Н а и л ә. Сүзең белән аңлатмаган идең, җырың белән төшендердең. Аңладым!

Ф ә р и д ә. Үзем аңламаганны ул аңлаган!

Г а л и я. Аңладыммы, юкмы, белмим.

Н а и л ә. Тукта, тукта... Кичә, төштән соң, сез Галия белән кая бардыгыз?

Ф ә р и д ә. Сез Әндәрҗан белән шомырт төбендә рәхәтләнеп утырсыннар дип моннан киттек.

Н а и л ә. Усалланма, сиңа монысы килешми.

Г а л и я. Мондый әшәке озынборыннарны күргәнем бар идеме, юкмы, белмим.

Н а и л ә. Сез үзегездән мине аерасызмыни инде? (*Елый.*)

Ф ә р и д ә. Синең хәлең башка бит, Наилә. (*Елый.*)

Г а л и я. Фәридә җаным, кызганаммы сине, юкмы, белмим. (*Елый.*)

Ә н д ә р җ а н керә.

Ә н д ә р җ а н. Иртәнге серенада башландымы?

Н а и л ә. Җыелыш.

Ә н д ә р җ а н. Мин шаярта белмим.

Ф ә р и д ә. Күренеп тора.

Н а и л ә. Сөйләшә торган җыелышлар туйдырды. Барыбер файдасы юк. Җылаша торган җыелыш җыелды. Әйдә, түргә уз, шул җыелышның президиумына рәхим ит.

Г а л и я. Фәридәкәй, без бик бәхетсез бугай.

Ә н д ә р җ а н. Эше юк кеше бәхет, яшәү турында сөйләшә. Ярар, берничә грамм артык сыеклыгыгызны сыгып чыгардыгыз. Булды. Шаярыр көн түгел.

Ф ә р и д ә. Ә кем шаяра соң әле биредә?

Ә н д ә р җ а н. Өчегез дә.

Ф ә р и д ә. Башкаларның үз телләре бар, мин, Әндәрҗан, моннан китәргә булдым.

Ә н д ә р җ а н. Кая?

Г а л и я. Кала алмабыз, ахры...

Ә н д ә р җ а н. Ну, дуслар, болай булмый ич инде. Дөрес, анализларны җибәргәнгә атна узды. Документлар тоткарлана. Эшсез тору күңелсез. Тормыш шартлары да җайсыз. Ләкин бит болар барысы да медальнең бер ягы.

Ф ә р и д ә. Икенче ягында да шул ук. Тиктомалдан әйтмим, тәмле телеңне әрәм итмә.

Г а л и я. Безгә медальне бирмиләр лә аны.

Ф ә р и д ә. Кирәкми диген, Галия.

Ә н д ә р җ а н. Аңа калса, сезгә ни кирәклеген бик яхшы беләбез.

Ф ә р и д ә. Белмисең, Әндәрҗан, һай, белмисең! Мин шәһәрдә әтиемнең газлы, ванналы менә дигән квартирасын ташлап киттем. Казанда ун урында кала ала идем.

Г а л и я. Ни кирәген беләмме, белмимме, әйтә алмыйм.

Ә н д ә р җ а н. Мин беләм!

Н а и л ә. Әндәрҗан, кеше күңелен алай чикләмә.

Ә н д ә р җ а н. Тигез урынга мөгез чыгарган булып, кычытмаган җирне кашып йөрмәсеннәр.

Ф ә р и д ә. Әйт алайса, нәрсә кирәк безгә?

Ә н д ә р җ а н. Егет кирәк сиңа. Менә шул!

Ф ә р и д ә. Кирәк. Анысы да бик кирәк. Безнең хәлне бик төпле аңлыйсыз икән, техник Әндәрҗан иптәш. Шуңа күрә бәхәсләшми-нитми генә чүлмәкне чүлмәккә шалт та, аерылышыйк.

Г а л и я. Мин дә синең белән китәмме?

Ф ә р и д ә. Сине үземнән калдыра алмыйм, Галия. Әниең миңа тапшырып җибәрде.

Н а и л ә. Машинасы да ремонтта бит аның!

Ф ә р и д ә. Ах, машина да юкмыни?

Ә н д ә р җ а н. Үзең беләсең, Фәридә, запчастьлар бирмиләр. Колхоз председателенең сүзенә ышанып аларның гаражына кайтарып ташлаган идек. Күрәсез бит, аяксыз-кулсыз утырабыз.

Ф ә р и д ә. Һәм телсез.

Н а и л ә. Кызлар китсә, башсыз-гәүдәсез дә калабыз әле.

Г а л и я. Баш кала түгелме соң?

Ф ә р и д ә. Аяксыз-кулсыз баш нәрсә эшли алыр?

Г а л и я. Запчастьлар бирмиләр, ә черкиләре күп... Быел черкиләр былтыргыга караганда биш тапкыр артыграк үрчеде. Бу Таулы районында черкиләр Бельгия, Голландия черкиләрен бергә кушып санаганда Европада... Уф, уяндыммы мин, юкмы, белмим.

Ә н д ә р җ а н. Болай сөйләшү иптәшлек түгел. Дуслык түгел.

Н а и л ә. Үз бизмәнең белән генә үлчәмә. Кызларны аңларга тырыш.

Ф ә р и д ә. Ничек булса да безне озат, Әндәрҗан. Югыйсә, адәм көлкесе ясап, әйберләр күтәреп җәяү чыгып китәрбез.

Г а л и я. Мин дә китәм икән, бер генә минут та көтеп тора алмыйм бугай... (*Чыгалар.*)

Н а и л ә (*Әндәрҗанның кулын тота*). Әндәр!

Ә н д ә р җ а н. Наилә, көпә-көндез...

Н а и л ә. Юк ла... Кызларны бик нык кимсеттең.

Ә н д ә р җ а н. Тиле кешегә сүз дәва түгел.

Н а и л ә. Кичә алар алтынчы участокка бардылар. Участок янына кемнәр күчеп килүен беләсеңме?

Ә н д ә р җ а н. Кем килсә дә, барыбер түгелмени аларга?

Н а и л ә. Барыбер түгел шул менә. Кызлар сазлыкта казынып маташалар. Аякларында дәү-дәү резин итекләр, битләрен зур-зур яулыклар белән каплаганнар... Ә анда чибәр-чибәр яшь егетләр килеп туктаган. Нефтьчеләр. Кызлар чыгарга оялып ике сәгать куак арасында утырганнар.

Ә н д ә р җ а н. Кемнән оялганнар? Нигә?

Н а и л ә. Әй, сиңа сөйләсәң дә...

Ә н д ә р җ а н. Нефтьчеләр ак яка куеп, үтүкләнгән чалбарлардан эшлиләр, ди.

Н а и л ә. Болар бит кызлар, Әндәр! Кызлар! Кыз күңеле — пыяла, кагылдыңмы — уала.

Ә н д ә р җ а н. Оялсалар, киенеп-ясанып йөрсеннәр. Биек үкчәле туфлиләрегез чемоданда ята.

Н а и л ә. Ун километрны тәпиләп кара әле! Сазлыкта йөрергә машинабыз да юк бит.

Ә н д ә р җ а н. Юк. Анысы юк, монысы юк. Булыр. Мелиорация яңа эш. Юк, юк, юк! Мең нәрсә юк. Тик алар ташлап китәргә тиеш түгел. Махсус белем алган мелиораторлар. Һәм китмәсләр дә.

Н а и л ә. Ялгышмыйсыңмы, Әндәр? Күз үткенлегең бетеп китмәдеме быел?

Ә н д ә р җ а н. Закон дигән нәрсә дә бар ич әле!

Г а л и я керә.

Г а л и я. Фәридә җылый да җылый...

Н а и л ә. Галия, кичә сез нефтьче егетләрне күрдегезме?

Г а л и я. Әйе.

Н а и л ә. Оялып торма инде, сөйлә.

Г а л и я. Берсе шундый чибәр. Кара мыеклы.

Ә н д ә р җ а н. Кара мыеклы? Мин дә күрдем аны. Сөйләшеп тә тордым. Искитәрлек нәрсәсе бар?

Г а л и я. Фәридә шуңа гашыйк булды да куйды.

Ә н д ә р җ а н. Менә, әйттем бит! Бакыр акча биш тиен андый кызның бәясе!

Н а и л ә. Алар сезне күрделәрме соң?

Г а л и я. Аннары, аннары без качтык...

Ә н д ә р җ а н. Эх бу кызларны, акыл дип, сабырлык дип тормыйлар, мыек булсын аларга, егет булсын!..

Н а и л ә. Әндәрҗан, фикереңнең уңае, сүзеңнең җае юк бүген. Хәер, бер бүген генә түгел инде!

Галия. Гашыйк кеше шулай кызганыч буламыни ул, Наилә?

Чыгалар.

Әндәрҗан. Гашыйклыгын шуннан белдем, башында җилләр уйный!

Марат керә.

Марат. Тынмыйсың да инде, Әндәрҗан, ничә карасаң аяк өстендә, гел кыймылдыйсың, тырышасың.

Әндәрҗан. Марат бабай, сиңа мондагы эш ошыймы?

Марат. Аллага шөкер дип әйтимме?..

Әндәрҗан. Урын да әйбәтме?

Марат. Зарланырлык түгел, сандугачы да бар, баласы да, икесе дә сайрыйлар.

Әндәрҗан. Без синең белән теләктәшләр, алайса, Марат бабай.

Марат. Тиле кеше әйткәндәй, нәмәрсәкәй булды соң әле?

Әндәрҗан. Эшнең дилбегәсе чуалды.

Марат. Чуалып бия койрыгы астына керсә, эш харап.

Әндәрҗан. Дилбегәсен чуалткан кеше кем була инде ул?

Марат. Бабай мәрхүм «җебегән!» дип кычкыра иде миңа.

Әндәрҗан. Фу, татар телендә шуннан да матур сүгенү сүзе тапмаган икән.

Марат. Чуалса да, әмәле табыла аның. Әмәлен генә табарга кирәк, аннары үз рәвешен ала ул.

Әндәрҗан. Әмәле, әмәле... Юк, Марат бабай, монда бер генә әмәл җитмәс, икәү кирәк монда! (*Чыга.*)

Марат бишмәтен сала, сакалын тарый, ясана. Җамал карчык белән Сәрвиназ керәләр.

Сәрвиназ. Сау йөрисеңме, Марат.

Җамал. Тыныч кына йоклап тордыңмы, Марат.

Марат. Ярыйсы болай. Тик тол кешенең йокысы, Ходай күрсәтмәсен. Куянныкы белән бер. Каравылда да рәхәтләнеп йоклап булмый. Шулай берзаман, корабльдә чакта...

Җамал. Бичара...

Сәрвиназ. Бу арада тартылып, ябыгып киттең. Юкка түгел икән.

Җамал. Таң алдыннан суытып та җибәрә. Монда дымык, күл дә рәттән генә.

Сәрвиназ. Мин сиңа бик әйбәт ак оннан кабартма пешереп алып килдем. Әйдә, тамак ялгап ал.

Җ а м а л. Тозлы каз итеннән шулпа. Яратырсыңмы икән?

М а р а т. Мин тозлы ит шулпасын кабартма белән ашарга яратам.

Җ а м а л. Аша алайса.

М а р а т. Яз көне тозлы ит бик әйбәт була ул.

С ә р в и н а з. Наһар ахирәт тә шулай дия иде.

Җ а м а л. Хәтерлисеңдер, без Наһар ахирәт белән бергә, бер урамда уйнап үстек.

С ә р в и н а з. Бер-беребездән азга да аерыла алмый идек, и-и...

Җ а м а л. Наһар ахирәт үлгәндә без сине караштырып, кайгыртып торырга дип ант иттек.

М а р а т (*утыра, ашый башлый*). Шулпага бер нәрсә җитми икән.

Җ а м а л. Яшел суган турадым, укроп орлыгы йөздердем, кара борыч сиптем.

М а р а т. Майламыйча шулпа да шумый.

С ә р в и н а з. Анысын да әйтеп үлде Наһар ахирәт. (*Кечкенә шешә белән аракы чыгара.*)

М а р а т. Бусын әйткәндә чак кына ялгышкан мәрхүмә. Үзе бер чакта да кечкенәне алмый иде.

Җ а м а л. Кечкенәсенә шөкрана кыл инде, Марат.

С ә р в и н а з. Әле болай да күзләрең бик елтырый.

М а р а т. Тол кешенең күзе күз яшеннән елтырый ла аның, Сәрвиназ-каракаш.

Җ а м а л. Сөйләмә дә инде, Марат... Сугышка бер сәгатьтә өчәү чыгып киттегез. Минем Ибраһимым...

С ә р в и н а з. Минем Гали мәрхүм...

Җ а м а л. Өчәүдән нибары син исән кайттың. Толлыкны белмибезме әллә?

С ә р в и н а з. Син сигез яра белән кайттың, Марат. Берсе дә җилкә ягында түгел, күкрәк ягында.

Җ а м а л. Кабартмасы уңганмы?

М а р а т. Уналты яшьлек кызлар кулы төсле йоп-йомшак.

С ә р в и н а з. Телең, Марат, телең, билләһи дип әйтәм, телеңне тыя белмәдең.

Җ а м а л. Кыз, кыз дип гыжылдавык картка әйләнеп барасыңмы инде?

М а р а т. Безгә шул сагынып сөйләргә генә калды инде. Менә безнең техник яши ичмасам! Берүзенә Идел камышы кебек өч кыз.

Җ а м а л. Син начар яшим дип зарланасыңмы, авызыңнан җил алгыры?

С ә р в и н а з. Авылның менә дигән ике карчыгы сине олылап килеп йөри! Кара әле... (*Бөтерелә.*)

Ж а м а л. Син, Марат, авылда чакта сирәк киләләр дип үпкәләмә. Кешенең теше бар, теш артында кеше чагар эше бар. Әллә ни уйларлар.

М а р а т. Аның берүзенә өч кыз, сез икәү генә.

С ә р в и н а з. Наһар мәрхүмә дусларны сайлый белә иде.

М а р а т. Нигә тагын берәр каракашны сайламаган инде?

С ә р в и н а з. Теге агуның зәһәре авыздан үтте, йөрәккә төште.

М а р а т. Төшеп җитмәде йөрәккә, шешәсе бигрәк нәни иде.

С ә р в и н а з. Шомыртлар да чәчәк атты, и агай.

Ж а м а л. Әле ярый каравылга сине җибәрделәр. Өй арасында уралып ел алмашканын да белми кала идек.

М а р а т. Ярады бу эш, бик кулай булып чыкты. Тик бетәргә маташамы шунда?

С ә р в и н а з. Исләренә исең китәр, и агай... Кузгалабызмы, Җамал ахирәт.

М а р а т. Китәргә миннән рөхсәт сорамыйсызмы?

Ж а м а л. Ни дигән сүзең булды инде бусы тагын?

М а р а т. Теге кечкенә җен эчкә керде дә авыздан сүз булып чыгарга ашкына. Сез китсәгез кем белән сөйләшим?

С ә р в и н а з. Өй арасында да мәшәкать җитәрлек. Бакча эшләре дә күбәйде, шулай да кичкә таба бер урарбыз әле.

Ж а м а л. Ни пешереп алып килик? Өс-башыңны алыштырырга да бик вакыт.

М а р а т. Күлмәк-ыштанны күл суында үзем дә юармын. Китми торыгыз инде чак кына.

Ж а м а л. Болай кылансаң, бу нәмәрсәне моннан ары кандала даруыннан бушаган имән әкәләсе хәтле шешәгә салып кына алып килербез.

С ә р в и н а з. Исән булып тор, Марат.

М а р а т. Вәт ашыктылар, итәкләренә ут капты.

Ж а м а л. Егет булсаң, әйдә, юлга хәтле генә озат безне.

М а р а т. Икегез дә килгәнне тегеләр күреп калсын иде.

С ә р в и н а з. Каравылда торып хыялыйга әйләнә башлагансың син, ахры. Шулаймы, Җамал ахирәт?

М а р а т. Аның берүзен өч кыз ярата.

Ж а м а л. Ә сине ике карчык. Шул җитмиме?

С ә р в и н а з. Берәүне кимсеткәннәр икән. (*Җамал белән Сәрвиназ икәү җырлыйлар.*)

Үтте еллар, исте җилләр,
Учакта бетте күмерләр.
Чәчләргә төште усал чал,
Һай гомерләр, һай гомерләр!
Чәчәкле язларны хәзер

Безнең оныклар күрерләр...
Картаясы килми бер дә,
Һай гомерләр, һай гомерләр.
Безнең яшьлектәге сыман,
Алар дус булып йөриләр.
Үтте еллар, исте җилләр,
Һай гомерләр, һай гомерләр!

Марат. Менә бусын булдырдыгыз!

Фәридә белән Галия үтеп китәләр.

Фәридә. Авыл якын дисең син, Галия. Төшеп карадык бит инде. Ике-өч кызга бер бөртек егетләре бар.

Галия. Син дөрес сөйлисең бугай, Фәридә. (*Чыгалар.*)

Җамал. Бу кызлар башка көннәрдә «әби, әби» дип өтәләнеп торалар иде.

Марат. Шомырт чәчәк аткан, кыз күңеленә ут яккан.

Җамал. Әнә начальнигың да килә. Күңелең булдымы инде, Марат?

Марат. Ярар инде. Вак-вак атлап, шәп кенә китегез әле.

Җамал. Яман күздән Алла сакласын, Марат.

Сәрвиназ. Хуш булып тор. (*Хәтәр генә чыгып китәләр.*)

Әндәрҗан (*кереп карчыкларны озатып кала*). Эредән чирттерәсең, Марат бабай. Борчакның эресен ярасың!

Марат. Ә кәк же! Яшь чагында моряк идек!..

Әндәрҗан. Урман һавасы морякларга да зыянсыз сыман?

Марат. Курортларың бер якта торсын... Сабан туенда йөгерешкә барырлык... Шулай да бер биш тәңкә өстәсәң иде син, улым Әндәрҗан.

Әндәрҗан. Анысы нәрсә өчен тагын?

Марат. Вредное производство. Озынборын бик азынды. Кем белә, төнлә, бәлки, мин аларга бер литр канымны бирә торганмындыр?

Әндәрҗан. Черкиләрдән тиз арада котыласың.

Марат. Һай, шул афәтләрнең бер даруын табарлар әле дип йөри идем. Премиянең иң шәбен бирергә кирәк аңа.

Әндәрҗан. Эшне көйли алмадым, Марат бабай. Районнан да ярдәм итмәделәр. Машиналар аз, булганы ватык. Анализлар кайтып җитми. Кызлар урынында булсам, мин үзем дә ташлап китәр идем.

Марат. Сиңа бер генә кыз каламыни? (*Тегенең курткасын тоткалап.*) Ай-яй курткаң, миңа да шундыйны аласы иде.

Әндәрҗан. Авылда уттай эш өсте башлана. Эшчеләрне каян алыйм? Белмиләр мелиораторларның кадерләрен, белмиләр, Марат бабай.

Марат. Өч кызны да үз янында тота алмагач, әйтер идем инде егетлегеңне!.. Бир миңа яшьлегеңне, бир киемнәреңне, иртәгәдән егерме кызны тездән шушы сазлыкка кертәм.

Әндәрҗан. Арттырма инде, Марат бабай.

Марат. Мин арттыраммы? Гомеремдә бер ялган сүз әйтсәм, телем корышып катсын. Шулай яшь чагында...

Әндәрҗан. Сөйләдең ич инде...

Марат. Һе, сөйләдеммени? Кай арада өлгердем икән? Шомырт исе җенләндерә кызларны. Тап бер әмәлен!

Әндәрҗан. Әйтүгә әмәле табыла ди сиңа.

Марат. Кызлар башын әйләндерә белмисеңме? (*Пауза.*)

Әндәрҗан. Таптым.

Марат. Тапсаң уртак.

Әндәрҗан (*кесәсеннән блокнот чыгара*). Марат бабакаем, хәзер син мине яхшылап сакла! Бу тирәгә берәү дә килмәсен.

Марат. Миңа нәрсә? Эшнең иге-чиге юк.

Әндәрҗан (*яза*). Хәзер иплә кенә тыңла. Тыңла да мыегыңа чолга: бәләкәй генә ялгыш җибәрсәң дә, син дә беттең, мин дә беттем.

Марат. Алайса, ун тәңкә өстәрсең.

Әндәрҗан. Акча турында уйлый торган вакытмы соң хәзер?

Марат. Хәтәр эш башлавыңны сизеп торам, андый эшне ничек бушка гына тәвәккәлләп өстемә алыйм?

Әндәрҗан. Хәзер әбиләрне озатып киткән бул. Бераздан ашыгып кына әйләнеп кайт. Фәридәне эзләп тап. Болай диген: «Нефтьчеләр үтеп бара иде, кара мыеклы бер егет шушы хатны тапшырырга кушты»,— диген.

Марат. Ул егетнең миңа хат тапшырырга кушканы юк.

Әндәрҗан. Хатны шул егет булып мин яздым.

Марат. Башны бетермәсме соң ул?

Әндәрҗан. Сайлыйсың инде, бабакаем: йә хат тапшырасың, йә иртәгәдән расчет. Сиңа да, миңа да.

Марат. Нәрсә язылган соң анда?

Әндәрҗан. Кызларга нәрсә язалар, шуны сырладым. Яратам, дидем. Бер күрүдә гашыйк булдым, дидем.

Марат. Хатны алуга Фәридә чыгып чабачак, теге егетне эзләп табачак.

Әндәрҗан. Чапмый.

Марат. Ә кем белгән аны?.. Вредное производство,

шуның өстенә опасное производство. Тузынып теге егет килеп җитсә? Аның иптәшләре генә дә биш-алты егет, ай-яй... Берәмләп берәрне сөртсәләр дә, җилкәдән камыт бавы теләрлек ясыйлар.

Әндәрҗан. Куркыныч ягы бар икән.

Марат. Ә син әйт, көрешергә кил диген.

Әндәрҗан. Бусы чынлап торып алдау була ич.

Марат. Кыз баланы алдарга ярамый. Көрешергә үзең барырсың.

Әндәрҗан. Мин?

Марат. Үзем бик барыр идем дә... Мыек ябыштырып куясың да, мә сиңа!

Әндәрҗан. Мыек ябыштырып?.. Мин ул егетне беләм, буйга без бер чама. Төскә дә. Киемнәрне үзгәртсәң... Хәзер ай яңа туды. Төн караңгы... Фәридә белән очрашып бер сөйләшсәк, ул атна-ун көнгә тып-тыныч булып калачак. Ул арада шомырт чәчәген коя, документлар кайта, машина ремонттан чыга... Юкны-барны уйларга вакыт та калмый.

Марат. Биш тәңкә?

Әндәрҗан. Барып чыкса, унны өстим. Үземнән.

Марат. Очтым.

Әндәрҗан. Кая?

Марат. Мыеклы чибәр егеттән гыйшык хаты алырга.

Әндәрҗан. Туктап тор, очрашу урынын язмаган бит әле. Хәзер, хәзер... Мә, булды!

Наилә керә.

Наилә. Кыяфәтләрегез бик серле, яшерен эш оештырып ятмыйсызмы?

Марат. Җамал карчык белән Сәрвиназ-каракашны озатырга ашыгам! (*Чыга.*)

Наилә. Фәридәләр китәргә әзерләнәләр.

Әндәрҗан. Китмәсләр. Кая барсыннар алар? Хәер, китсәләр, ак юл.

Наилә. Бер ел эчендә, дөресрәге, бер яз эчендә син ничек үзгәрдең.

Әндәрҗан. Үзгәрмәдем ич инде.

Наилә. Төнлә ару гына кеше көндез үзгәрәсең дә куясың. Синең белән дус булыр өчен төньякка китәргә кирәк. Анда ичмасам алты ай төн.

Әндәрҗан. Борчылуымның сәбәпләрен күреп торасың, Наилә.

Наилә. Гади кеше булып кал. Барысы да уртак булсын. Шул чагында кыен күрсәк тә рәхәт булыр, бер тамчы ялганга, шик-шөбһәләргә урын калмас.

Әндәрҗан. Дөньяның бөтен җепләре минем кулым-

да булса икән, Наилә! Мин сезне өрмәгән җиргә дә утыртмас идем.

Наилә. Син гади кеше чагында ничек рәхәт иде. Матур гына сөйләшә идек... Син җырлап та ала идең. Быел тавышыңны да ишеткән юк. Берәүдән дә курыкмый, качмый идек.

Әндәрҗан. Үзең барын да аңлыйсың дип йөрим мин тагын.

Наилә. Барын да аңлаганга кыйналам да шул.

Әндәрҗан. Күз яшеңне чыгара күрмә, әнә кызлар килә. Тагын әллә ни уйларлар.

Наилә. Уйласалар ни дә, уйламасалар ни. Син мине яратасыңмы, юкмы? Ачык кына итеп әйтеп бир!

Әндәрҗан. Наилә, матурым, тын инде, тын!

Фәридә белән Галия керәләр. Бергәләп җырлыйлар.

Фәридә, Галия.

Карлыгачның, мескенкәйнең,
Канаты каерылган.
Алар да бит безнең кебек
Өеннән аерылган.
Сандугачның балалары
Җим сорыйлар ояда.
Яшәр дусларың булмагач,
Кыен икән дөньяда.
Суда сусар булмый диләр,
Су өсте сусар гына.
Тормыш яме, яшәү тәме —
Кадерле дуслар гына.

Әндәрҗан. Үләр идем, әнкәм бәгырем генә ерак. Бигрәк моңлы җырладыгыз.

Фәридә. Галия!

Галия. Әү, Фәридәкәем.

Фәридә. Бу сүзләрдән туңам, әллә учак тергезеп җибәрәбезме?

Галия. Марат бабайның учагы сүнмәгән, ахры.

Фәридә. Марат бабай учагында җылынырга гына калды инде безгә.

Наилә. Кызлар, мин сезнең белән!

Әндәрҗан. Ничек?

Фәридә. Син дә китәсеңме?

Наилә. Әгәр Әндәрҗан эш шартлары турында уйламый икән, мин дә сезнең белән китәм!

Әндәрҗан. Рәхмәт, Наилә, рәхмәт. Кыен вакытта миңа ярдәмең зур булды.

Г а л и я. Мин дә китәмме, кызлар?
Ф ә р и д ә. Наилә, син уйла, соңыннан үкенерлек булма.

Кычкырып М а р а т керә.

М а р а т. Кызлар, кызлар!
Н а и л ә. Тагын җылан очраттыңмы, Марат бабай?
М а р а т. Сөенче, сөенче!
Ә н д ә р җ а н. Үз колагың үзеңә.
М а р а т. Почта, почта!
Ә н д ә р җ а н. Документлар кайтып җиттеме?
М а р а т. Түгел.
Г а л и я. Минем әнкәйдән хат бармы әллә?
М а р а т. Әндәрҗан энекәем, мин хәзер кызларны терелтәм. Ташлыяр күрәзәсе кулыннан килмәгәнне эшлим. Фәридә, бие.
Ф ә р и д ә. Минме?
М а р а т. Сиңа хат.
Ф ә р и д ә. Хат? Миңа? Бир, Марат бабай.
М а р а т. Ашыкма. Җамал карчык белән Сәрвиназ-каракаш килгәннәр иде. Күрдегезме сез аларны?
Н а и л ә. Күрдек, күрдек.
М а р а т. Шуларны озатып олы юлга чыктым. Карасам, өр-яңа бер машина үтеп бара. Ялтырап тора машинасы. (*Әндәрҗанга карый.*) Оча гына.
Ә н д ә р җ а н. Машина турында соңыннан.
Н а и л ә. Йә, йә, Марат бабай?
М а р а т. Машинада егетләр. Гөрс-мәрс килеп торучы тап-таза нефтьчеләр.
Ә н д ә р җ а н. Гөрс-мәрсләр турында да соңыннан...
Г а л и я. Нефтьче егетләр?
М а р а т. Мине күреп машиналарын туктаттылар болар. Шунда берсе, арада иң кәттәсе, туп-туры миңа карады да: «Син теге черкиләр патшалыгында хезмәт итәсеңме?» — ди. Шунда, дим, каһәр суккан сазлыкта, дим.
Ф ә р и д ә. Каян беләләр алар сине, Марат бабай?
М а р а т. Бабаңны бөтен тирә-як белә. Яшь чагында ук...
Ә н д ә р җ а н. Сөйләгән идең ич инде...
М а р а т. Кайчан өлгердем әле мин?
Н а и л ә. Шуннан, шуннан, Марат бабай?
М а р а т. «Күч син безгә», диләр теге егетләр. «Нәрсә анда сазлыкта бака саклап ятасың».
Ф ә р и д ә. Ә хат?
М а р а т. Хатны әйтәсеңме... Хәзер, хәзер... Шуннан бу егет сорап куймасынмы: «Сездә Фәридә исемле матур эшлиме?» — ди.
Н а и л ә. Күптән шуннан башлаган булсаң соң...

Марат. Башта уйлап тордым, әйтергәме, юкмы. Егетнең күзләренә карыйм, мин бит сынап карарга бик яратам. Яшь чагымда ук...

Әндәрҗан. Уф...

Марат. Хәер, сөйләгән идем шикелле... Егетнең күзләре шундый чиста, түзмәдем, бар, мин әйтәм, бездә аның Фәридәсе дә, Галиясе дә, Наиләсе дә бар, дим. Әндәрҗан, сине әйтмәдем.

Галия. Мине дә сорадылармы?

Марат. Галиясе бик матур матурын, тик анысы кирәкми, ди. Наиләне белмибез, диделәр. Әмма Фәридәсе үзәгемне өзде, ди бу.

Әндәрҗан. Уф...

Марат. Шул чибәр Фәридәгә менә шушы хатны тапшыра алмассың микән, ди. Әманәт — изге ат, мә, кызым, җылы кулың белән алып җибәр.

Фәридә. Күрмәгән-белмәгән кешенең нинди йомышы төште икән? (*Хатны ала.*)

Наилә. Шаяртканнардыр инде. Егет-җиләнчәккә уен гына булсын.

Марат. Уенын-чынын белмим, иллә мәгәр бик ялынып сорады.

Фәридә. Нинди егет соң ул?

Марат. Нефтьче инде. Шулар машинасы. Дөпелдәп тора. Егет. Буйга, буйга... Менә безнең Әндәрҗан кебегрәк, кап кара мыеклы.

Галия. Шул! Үзе! Күңелемә килгән иде...

Наилә. Үзләре утырганнар иде дисең, Марат бабай. Буен ничек чамаладың?

Марат. Әдәпле егет хатны утырып тапшырамы? Бабаңны олылап аягүрә басты. Буйга шәп! Мыек очлары болытка тиеп китте. Машиналары да әйбәт шул.

Фәридә. Шаяртасың, ахры, син, Марат бабай.

Галия. Шул егет ич инде, үзе.

Әндәрҗан. Алдың икән, тот та укы инде.

Наилә. Нигә шаяртасың икән?

Галия. Шул мыеклы егет янында тәбәнәк кенә, юан муенлы бакыр чәчлесе юк идеме?

Марат. Менә анысын карарга онытканмын, кызым.

Әндәрҗан. Ярар, хәзер ашап-эчеп алыгыз да җыелып сөйләшербез. (*Чыгып китә.*)

Марат. Тамак янды, үзем дә чаптым шул. (*Чыга.*)

Галия. Укы инде тизрәк... Ниләр язган...

Фәридә. Куркам.

Наилә. Йә инде, син тагын бигрәк.

Галия. Миңа язсалар, мин ачар идемме, юкмы, белмим.

Фәридә. Ни булса булган! (*Ача, укый.*)
Наилә. Йә, әйт инде.
Фәридә. Телем әйләнми...
Наилә. Бир әле, үзебез укыйбыз...
Фәридә. Туктагыз, үзем.
Галия. Гашыйк булганмы?
Фәридә. Әйе...
Наилә. Свиданиегә чакырамы?
Фәридә. Әйе...
Галия. Бар, дустым, бар.
Фәридә. Әгәр бу бер усал шаяру гына булса?
Галия. Ә миңа берәү дә гашыйк булмый...
Наилә. Их Галия, кайчагында ялгыз башларыңа ни җитә!
Фәридә. Уйладым: барам!
Галия. Алайса, без бүген китмибез?
Фәридә. Калабыз... Теләсә нәрсә уйлагыз, мин аның белән күрешергә барам!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Кич. Якында гына күл. Әндәрҗан белән Марат бабай агач арасында. Марат көзге тотып тора, Әндәрҗан көзгегә карап мыек ябыштырып азаплана.

Әндәрҗан. Өскәрәк. Аскарак. Турырак. Мыекны борынга ябыштыртасың, турырак тот әле, Марат бабай.
Марат. Сәрвиназ-каракаш килмиме дип карыйм.
Әндәрҗан. Көненә ике кат килмәсләр инде.
Марат. Анысын карарбыз әле...
Әндәрҗан. Тагын кыегайттың.
Марат. Тудырган анаң килсә дә, танымас сине хәзер.
Әндәрҗан. Әни танымас, ә бу кыз шундук белеп алыр.
Марат. Ничек белсен ди ул, әкәмәт. Төн караңгы, ай урак кебек кенә.
Әндәрҗан. Чын микән дип, мыегыңны йолкып карар. Син аның әрсезлеген беләсең.
Марат. Читтән генә карап торам: хатны укыгач бер агара, бер кызара. Дәртле нәмәстәкәй икән!
Әндәрҗан. Хатын-кызның шашканы инде, шашканы.
Марат. Шулай да күрешү урынын күлнең бу ягына гына билгеләп хата кылмадыңмы икән син.

Ә н д ә р җ а н. Синнән сер юк, Марат бабай, минем бит әле Наилә янына да кайтып җитәсе бар. Фәридәне күлнең бу ягыннан кайтарып җибәрәм дә үзем Наилә янына чабам.

М а р а т. Әкияттәге теге Шомбай кебек бүрегеңне әйләндереп киясең дә... Хакың күпме? Биш алтын... Алтын дигәннән, син теге вәгъдәңне онытмадыңмы?

Ә н д ә р җ а н. Нинди вәгъдә?

М а р а т. Ун тәңкә дигән сүз авызыңнан чыкты түгелме?

Ә н д ә р җ а н. Булыр. Тик син ерак йөрмә. Мин тиз-тиз киемнәрне алыштырырга тиеш. Бу маскарадны тиз-тиз генә бетерәм дә Фәридәне аткарам, киемнәрне алышам да очам.

М а р а т. Ни кылансаң, шул килешә сиңа хәзер. Менә мин генә йөрим байгыш булып...

Ә н д ә р җ а н. Күз-колак бул, Наилә килеп чыга күрмәсен.

М а р а т. Әндәрҗан, ә теге мыек үзе очрап куйса?

Ә н д ә р җ а н. Икеләндермә, очраса күз күрер. Әйдә, кайда очрашу турында сүз беркетик. Өч тапкыр күке булып кычкыргач та минем янга атыл.

М а р а т. Ярар ла... Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчык килеп җитмиләрмени?

Ә н д ә р җ а н. Алар белән дә озак юанма. Тиз-тиз генә озат. Әкиятеңне башка вакытта сөйләрсең.

Чыгып китәләр. Бераздан Ф ә р и д ә белән Г а л и я керәләр.

Г а л и я. Әгәр миңа шундый хат килсә, барыр идемме, юкмы, белмим.

Ф ә р и д ә. Мөгаен, барыр идең.

Г а л и я. Әгәр ул шаярткан гына булса?

Ф ә р и д ә. Ә мин шаярып кына килсәм?

Г а л и я. Әгәр ул килмәсә?

Ф ә р и д ә. Килмәсәме? Килмәсә...

Г а л и я. Юлда очратып мыегын йолкып бетерәсеңме?

Ф ә р и д ә. Килмәсә, килмәсә...

Г а л и я. Күлгә ташланасыңмы?

Ф ә р и д ә. Шушы карама төбенә утырып чын күңелдән рәхәтләнеп бер көләм. Үземнән-үзем... Тик мин аңа ышанам. Менә нигәдер ышанам.

Г а л и я. Тәгаен шушында очрашырга дигәнме?

Ф ә р и д ә. Шушында.

Г а л и я. Сәгать тугызда дигәнме?

Ф ә р и д ә. Әйе. Мин бая күлне бер әйләнеп чыктым инде.

Г а л и я. Әйтәм аны чәй дә эчмәдең.

Ф ә р и д ә. Күл янында башка карама юк.

Г а л и я. Мин китимме инде?

Ф ә р и д ә. Ашыкма. Әле иртә. Әле алар эштәдер. Төштән соң ул яктан шартлау тавышлары ишетелеп торды.

Н а и л ә керә.

Н а и л ә. Көтәсезме? Әндәрҗан күренмәдеме?

Ф ә р и д ә. Юк.

Н а и л ә. Бая катырак әйтеп хәтерен калдырдым, ахры.

Ф ә р и д ә. Инде йөрәксенеп чын күңелдән бер усал сүз әйткәнсең икән, май кап, үкенеп йөрмә.

Н а и л ә. Күренсә, мин аны эзли дип әйтмәгез. (*Чыга.*)

Ф ә р и д ә белән Г а л и я җырлыйлар.

Ф ә р и д ә, Г а л и я.

Сагышларым ак чәчәкләр белән
Җилләр уйнаганда коелсын.
Гомеремнең алсу таңы яшьлек,
Сихерле җыр булып тоелсын.
Күл буена чыксам, кошлар сайрый
Йөрәк тибешемне арттырып.
Кәккүк кычкыра, мине үзе белән
Ерак-еракларга чакырып.

Г а л и я. Ярата Наилә Әндәрне!

Ф ә р и д ә. Әндәрҗаны аны ярата микән?

Чыгып китәләр. Җ а м а л  к а р ч ы к белән С ә р в и н а з керәләр.

Җ а м а л. Авыл арасында ни сөйлиләр икән, ахирәт. Колагыңа чалынганы юкмы?

С ә р в и н а з. Телчәңнең авызы тишек, теле тегермән. Әйләнә дә тора. Безнең Наһар ахирәткә биргән вәгъдәбез бар.

Җ а м а л. Япа-ялгыз карт янына ихлас күңелдән йөриләр дип әйтәләр микән, әллә гайбәт чәйниләрме?

С ә р в и н а з. Дөнья булгач, төрлесе булыр.

Җ а м а л. Марат әле япь-яшь...

С ә р в и н а з. Марат бабагыз унсигез яшьлек егетләр кебек дип йөри иде Наһар ахирәт тә.

Җ а м а л. Нәселләре нык шул, тазалыгы борынгыдан килә.

С ә р в и н а з. Озын гомерле булсын, әнә үзе дә монда ашыга.

Җ а м а л. Кулында төенчеге бар. Әллә юасы керләрен дә алган инде?

Марат керә.

Марат. Килмичә мине көлкегә калдырасыз икән дип торам.

Җамал. Килдек...

Сәрвиназ. Өйдә дә оныклар...

Марат. Адәм баласы йөрергә ярата. Әле газетада укыдым. Алтмыш биш яшьлек бер карт, япа-ялгызы көймәгә утырып, дөнья тирәли сәяхәткә чыгып киткән.

Сәрвиназ. Бар икән үзендә йөрәк тә!

Җамал. Җәмәгате юктыр аның, шундый хәвефле юлга ничек чыгарып җибәрер иде?

Марат. Бар ди шул. Радиодан сөйләшеп кенә яталар ди.

Сәрвиназ. Минем Галием ялгыз йөрүне бер дә сөйми иде.

Җамал. И-и, Ибраһимым исән-аман кайтса, Әтнә базарына да берьялгызын җибәрмәм, кая ул, түргә утыртып гел-гел карап кына торырмын.

Сәрвиназ. Хәере белән йөреп кайтсын синең тәвәккәл картың. Әйдә, Марат, көн бик кичекте. Күкәй пешердем. Әле кайнар, тастымалга төреп алып килдем.

Җамал. Минеке җимеш суы.

Марат. Ярарлык булган бу.

Сәрвиназ. Кулыңда нинди төенчек ул, Марат?

Марат. Ә, болай гына. Сер төенчеге.

Җамал. Ничек синең кулга килеп керде әле ул?

Марат. Төшә маллар егет кулына.

Сәрвиназ. Шушында гына ашап алабызмы?

Марат. Юк, юк, бу зона куркынычлы зона. Монда ашарга ярамый.

Әндәрҗан керә.

Әндәрҗан. Марат бабай, тизрәк тарттыр моннан!

Марат. Корткалар, тайыйк, әйдә, китик.

Җамал. Пәрәмәч, бу син бит, улым.

Әндәрҗан. Мин, мин!

Сәрвиназ. Безне машинага утыртып син алып килдең ич!

Әндәрҗан. Мин инде, мин! Тизрәк китегез моннан! (*Чыга.*)

Марат. Әйдәгез инде!

Җамал. Ничек чөкердәшеп кенә утырган идек...

Сәрвиназ. Кай арада килеп җиткән ул монда?

Җамал. Машина заманы шул, машина заманы.

Марат. Сер заманы, Җамал карчык, сер заманы.

Чыгып китәләр. Галия белән Фәридә керә.

Фәридә. Вакыт җитте!

Галия. Кара аны, үзеңне кимсеттермә.

Фәридә. Борчылма.

Галия. Борчыламмы, борчылмыйммы, анык кына әйтә дә алмыйм.

Фәридә. Рәхмәт сиңа, дустым.

Галия. Миңа еракка китү ярамас. Шушы тирәдә генә утырып торыйммы?

Фәридә. Рәнҗемәссеңме соң?

Галия. Кирәгем чыгар да куяр.

Фәридә. Мә алайса, минем кофтаны ки.

Галия. Үзең туңарсың бит.

Фәридә. Туңмаска тырышырмын. Кирәк-мазар булсаң, мин ике тапкыр күке булып кычкырырмын. Ялт итеп килеп чык.

Галия. Менә моны күрәсеңме? (*Кечкенә генә пәке күрсәтә.*) Сиңа әйтмичә генә алдым.

Фәридә. Аның кирәге булмас. Йә, бар, утырып тор. Ял ит.

Галия. Килмәсә яхшырак булмасмы икән? (*Чыгып китә.*)

Фәридә ялгыз. Менә кулындагы чыбыгын селки-селки сызгырынып Әндәрҗан килеп керә.

Әндәрҗан. Сәлам сезләргә безләрдән.

Фәридә. Исәнмесез.

Әндәрҗан. Төн нинди матур.

Фәридә. Без танышмадык шикелле.

Әндәрҗан. Танышыйк. Минем исемем... Кәли булыр.

Фәридә. Ни өчен булыр? Сез Ватикандагы папа урынын алырга җыенмыйсыздыр ич? Папа булып сайланган кеше яңа исем ала.

Әндәрҗан. Алайса, Сәли.

Фәридә. Сезнең тагын ничә исемегез бар? Әтиегез испан бае идеме әллә, Кәли-Сәли-Әлләкем.

Әндәрҗан. Ошамыймы?

Фәридә. Минем исемем бик гади. Фәридә.

Әндәрҗан. Ничек инде — Фәридә?

Фәридә. Ошамыймы?

Әндәрҗан. Бик таныш исем... Ләкин ничектер яңача яңгырады.

Фәридә. Сез исемегезне әйтмәдегез әле.

Әндәрҗан. Минем исемем Госман.

Фәридә. Бусы дөрескә якын.

Әндәрҗан. Бусы дөрес. Ике тапкырдан артык ялганлау гөнаһ. Утырабызмы?

Фәридә. Сез арыдыгызмы?.. Утырып нишләрбез икән?

Әндәрҗан. Кешеләр нишләсә, шуны эшләрбез. (*Утыралар.*)

Фәридә. Кешеләр бу очракта ни эшлиләр?

Әндәрҗан. Һәй, монысын мең кат китапларда язып калдырганнар инде. Уникенче йөздә үк. Шуннан соңгы гасыр кешеләре язылганны гына кабатлыйлар.

Фәридә. Соңгы гасыр кешеләре бик кызганычлар икән.

Марат керә.

Марат. Карт хәтер — тишек иләк. Шырпыны онытып чыгып киткәнмен бит. Бая шушында утырган идем.

Әндәрҗан. Нишләп монда буталасың инде?

Марат. Хәзер, хәзер! Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчыкны кайнар чәй белән... Менә таптым! (*Чыга.*)

Фәридә. Сез кешеләрне бик ансат рәнҗетә аласыз икән.

Әндәрҗан. Һәркем үз урынын, үз эшен белергә тиеш.

Фәридә. Кем аны билгеләп куйган? Алламы?.. Күңелегездә усаллык. Күренеп тора.

Әндәрҗан. Гафу итегез. Зинһар, ташлап китмәгез.

Фәридә. Шушы бабай сезнең хатны миңа тапшырды. Әгәр ул булмаса, без бүген монда күрешә алмый идек. Почталар сирәк кагыла!

Әндәрҗан. Хезмәтенә күрә хөрмәтен алды.

Фәридә. Мин сезнең турыда яхшырак уйлый идем. Егетлекнең асылы егетнең йомшак күңелле булуында дип саныйм. Болай да тормышта катылык күп.

Әндәрҗан. Фәридә!

Фәридә. Хушыгыз.

Әндәрҗан. Туктагыз.

Фәридә. Соңгы сүз өчен күпме вакыт сорыйсыз? Бер минут.

Әндәрҗан. Бу аз.

Фәридә. Ике минут. Тик аңа карап хөкем карары үзгәрмәс.

Әндәрҗан. Бу да аз.

Фәридә. Усал булу өстенә комсыз да икәнсез әле.

Әндәрҗан. Әгәр сез мине электән белсәгез икән! Хөкем итәрдән алда озак кына төпченәләр, тикшерәләр.

Фәридә. Карак — кеше кесәсенә керде, кулыннан тотылды. Хөкем әзер.

Әндәрҗан. Сез мине шәхес буларак изәсез. Болай ничек аңлашыйкди без?

Ф ә р и д ә (*тукталып*). Беләсезме? Әгәр аңлашу теләсәгез, сез сүз сөйләмәгез, җырлагыз.

Ә н д ә р җ а н. Әгәр мин җырлый белмәсәм?

Ф ә р и д ә. Сөйләшә белмисез. Җырлый да белмәсәгез эшегез бөтенләй мөшкел. Өметсез.

Ә н д ә р җ а н (*йөткергәләп*). Күптән җырлаган юк.

Ф ә р и д ә. Бусы тагын да начаррак. Сез бүлмәдә кәгазь кимереп, урамга чыккач чүбек чәйнәп йөрүче безнең техник Әндәрҗанга бик охшагансыз икән.

Ә н д ә р җ а н. Алайса җырлыйм.

Ф ә р и д ә. Мин көтәм.

Ә н д ә р җ а н. Музыкасыз кыенрак.

Ф ә р и д ә. Сез берни дә ишетмисезмени?

Ә н д ә р җ а н. Ишетмим.

Ф ә р и д ә. Әнә!

Ә н д ә р җ а н. Нидер йөри, кыштырдый.

Ф ә р и д ә (*кычкырып*). Бәхетсез ананың баласы! Саңгырау һәм куркак!

Ә н д ә р җ а н. Ишетмим, хет суегыз.

Ф ә р и д ә. Әнә... Әнә!

Ә н д ә р җ а н. Тып-тын. Шылт иткән тавыш юк.

Ф ә р и д ә. Күл өстендә балык сикерде... Табан балыгымы? Әнә шомырт ботагын кош тирбәтте. Хуш ис бөркелеп китте. Әнә меңләгән агачлар тамыр куллары белән җир күкрәгендә капшаналар, азык эзлиләр. Чү, әнә төн патшасы сандугач!.. Кырмыска оясында ана кырмыска кыштыр-мыштыр йокыга китә алмыйча ята... Әнә Җир шары иксез-чиксез галәм киңлегендә оча. Җирнең базальт катлавында ниндидер шартлау әзерләнә... Атмосфераның югары ягында циклон өлгерә.

Ә н д ә р җ а н. Сез боларның барысын да ишетәсезме?

Ф ә р и д ә. Барысын да.

Ә н д ә р җ а н. Алайса, мин сезнең янда җырлый алмыйм.

Ф ә р и д ә. Булдыксыз.

Ә н д ә р җ а н. Мин бер җыр җырлармын, сез икенче мәгънә табарсыз.

Ф ә р и д ә. Җыр шуның өчен җырлана ич инде! Берне җырлыйлар, икенче нәрсә уйлыйлар.

Ә н д ә р җ а н. Сез мине җиңдегез. (*«Шомырт чәчәк атканда» җырын җырлый.*)

Ф ә р и д ә. Әйбәт... Язгы сулар акканда шомырт чәчәк атмый атуын, барыбер әйбәт. Матур җырладыгыз, сүзем юк!

Ә н д ә р җ а н (*кыюланып*). Ә бүләк?

Ф ә р и д ә. Нинди бүләк, әрсез алабай?

Ә н д ә р җ а н. Җыр өчен бүләк тиеш.

Ф ә р и д ә. Бакыр да җитәме, көмеш өмет итәсезме?

Ә н д ә р җ а н. Өлешемә көмеш чыксын, бер үбегез.

Ф ә р и д ә. Сезгә бирелгән вакыт бетте. Мин сезнең соңгы сүзегезне ишетмәдем. Сезне иртәдән кичкә кадәр җырлатып кына торырлык икән.

Ә н д ә р җ а н. Иртәдән кичкә кадәр куркыныч. Көндез —эш, төнлә кеше үз-үзенә әйләнә.

Ф ә р и д ә. Бүренең башын бүреккә салсаң да...

Ә н д ә р җ а н. Үпкәләдегезме?

Ф ә р и д ә. Гаҗәпләндем.

Ә н д ә р җ а н. Минем тавышкамы?

Ф ә р и д ә. Шундый җыр артыннан нинди тупас тәкъдим.

Ә н д ә р җ а н. Мин укыган китапларда үбүне тупаслык димәгәннәр иде болай.

Ф ә р и д ә. Теләсә кемне үбү — тупаслык, теләсә кемнән үптерү — кыргыйлык, түбәнлек.

Ә н д ә р җ а н. Әгәр мин көчләп үпсәм.

Ф ә р и д ә. Кешенең акылын — сүзеннән, асылын — фигыленнән беләләр.

Ә н д ә р җ а н. Мине төзәтергә соң инде, Фәридә җаным! (*Кызга якыная башлый.*)

Фәридә күке булып кычкыра, атылып М а р а т килеп керә.

М а р а т. Тол кеше — уяу кеше. Мин монда!

Ә н д ә р җ а н. Сезне кем чакырды? Барыгыз, бар!

М а р а т. Күке кычкырды бит.

Ә н д ә р җ а н. Тиле күкедер ул.

Марат чыга.

Ф ә р и д ә. Күрдем, тыңладым, сөйләштем. Сау булыгыз.

Ә н д ә р җ а н. Сез шушы хәлдә мине калдырып китәсезме?

Ф ә р и д ә. Болай калуыгызга шатланыгыз. Яңак сөякләрегез сау-сәламәт, урынында.

С ә р в и н а з, Җ а м а л, М а р а т үтеп баралар.

М а р а т. Тизрәк инде, тизрәк...

С ә р в и н а з. Бәй, теге егет бит бу.

М а р а т. Тиешле-тиешсезен күрмәгез әле, корткалар. Егет кешенең теше — тал чыбыгын сындырыр, егет кешенең эше — җиде кызны җылатыр.

Җ а м а л. Машинасына утырткач бик сөйләшкән иде, кызлар янында телен йоткан. (*Чыгып китәләр.*)

Фәридә. Сез дә китегез, Сәли-Кәли-Госман.

Әндәрҗан. Безнең мөнәсәбәтләрнең киләчәге өметсезмени?

Фәридә. Тамыры корыган.

Әндәрҗан чыга. Фәридә куак арасына бара.

Фәридә. Галия, Галия! (*Күке булып кычкыра.*) Күкү! Йоклаган минем матурым. Уян, уян, тор.

Галия. Ә, Фәридә, синме? Нинди матур төш күрдем мин, белсәң иде.

Фәридә. Ә мин нинди ямьсез өн күрдем, белсәң иде.

Галия. Йокладыммы, әллә юкмы, белмим.

Фәридә. Аерыл матур төшеңнән, иркәм.

Галия. Син ямьсез өнеңнән аерылдыңмы?

Фәридә. Очрашу тәмам. Ямьсезлегеннән тиз генә арынып булмас әле.

Галия. Сөйләштегезме?

Фәридә. Мин сөйләшергә теләдем, ул мөгрәде.

Галия. Вәгъдә бирештегезме?

Фәридә. Мөгердәгәнне аңламыйм.

Галия. Ни пычагыма килеп йөргән соң ул, хәчтерүш?

Фәридә. Үзем шуны синнән сорарга тора идем.

Галия. Без моннан китәбезме, әллә калабызмы?

Фәридә. Иртәгәдән дә калмыйбыз.

Галия. Син ни әйтсәң дә риза... Ах, нинди матур төш иде... Җиз чәчле бер егет миңа шунда бер җыр җырлады. Шомырт чәчәкләре турында, ахры...

Фәридә. Яхшы җырның яман мәгънәсе булуы бар, сагай... Йа Ходай, әллә тагын йоклап киткән инде?

Галия. Йоклыйммы, йокламыйммы, белмим.

Фәридә. Әйдә, алайса кайтыйк, ял итик. Әле безнең кызлык чорында Кәли-Сәли-Госманнар күп очрар. Без аларның барысын да җиңәргә тиеш.

Галия. Син бер кичтә өч егетне җиңдеңме?

Фәридә. Үзем дә шуны белергә теләр идем.

Чыгалар. Мыегын йолка-йолка Әндәрҗан керә.

Әндәрҗан. Марат бабай, Марат бабай!

Марат керә.

Марат. Котылдыңмы?

Әндәрҗан. Котылдыммы, тотылдыммы, Галия әйткәндәй, белә алмыйм. Китер тизрәк киемнәрне!

Марат. Мә. Курыкма, берәү дә юк. Усал нәмәрсәме?

Әндәрҗан. Ул усал түгел, мин йомшак. Син дә шунда...

М а р а т. Постта сак торырга кирәк инде ул.

Ә н д ә р җ а н. Кем кушкан сиңа атылып чыгарга? Мин бит, өч кат кычкыргач, дидем.

М а р а т. Кем санап торган аны, күке тавышы ишетелүгә атылып чыктым.

Ә н д ә р җ а н. Каян белгәннәр алар безнең парольне?

М а р а т. Мөгаен, тыңлап торганнардыр.

Ә н д ә р җ а н. Син ике яклы пычак түгелсеңдер бит?

М а р а т. Карт морякка шундый сүз...

Ә н д ә р җ а н. Йә, йә, ачуланма, аптыраганнан әйтүем. (*Киемнәрен алышынып Маратка бирә.*) Мә, боларын шыпырт кына минем палаткага кертеп куй. Берсе дә сизмәсен. Ашарлар.

М а р а т. Тешләре үткенме?

Ә н д ә р җ а н. Үзем йомшак. Җырлатты бит тәки... Борын асты кычыта. Мыек йөрткән теге җүләрне әйтер идем!

М а р а т. Һәркемнең үз акылы.

Ә н д ә р җ а н. Каян белгәннәр алар парольне, шунысы гаҗәп!..

Марат китә, Н а и л ә килә.

Н а и л ә. Әндәрҗан, син мондамыни?

Ә н д ә р җ а н. Наилә, син ничек эзләп таптың мине?

Н а и л ә. Бик таныш бер җыр ишетелгән кебек булды.

Ә н д ә р җ а н. Мин дә ишеттем. Тик ул кадәр матур җырламый ла инде.

Н а и л ә. Син матуррак җырлыйсың, Әндәрҗан. Тик син күптәннән җырламыйсың.

Ә н д ә р җ а н. Һәй, онытып бетердем инде җырларны.

Н а и л ә. Мин син җырлый дип уйлаган идем. Әллә үткән көннәребез кайтамы дигән идем.

Ә н д ә р җ а н. Төкер җырына!

Н а и л ә. Тик ул көннәр кайтмас инде, ахрысы... Син мине бөтенләй яратмыйсың. Син үзеңнең эш урыныңны, дәрәҗәңне генә сөясең. Менә шул! (*Чыгып йөгерә.*)

Ә н д ә р җ а н. Наилә, Наилә!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Иртә. Палаткалар янында тынлык. Палаткалардан ерак та түгел, агач төбенә көзге куеп, М а р а т  б а б а й ашыгып-ашыгып сакал кыра. Сакалын кырып бетергәч, мылтыгын кочаклап чыгып китә. Менә зур палатканың япмасы күтәрелә, аннан гадәттәгечә Н а и л ә чыга.

Н а и л ә. Саумы, шомыртым!.. Хәерле иртә, минем бердәнбер дустым. Тукта, мин нәрсә дидем? Минем бердән-

бер дустым дидемме? Шулай ук мин синең янында ялгыз калдыммыни? Тыныч кына, үз җаена аккан тормышыбыз үзгәрде дә куйды. Бәлки, кичәге төн төш кенә булгандыр?.. Бүген көн нәкъ элеккечә башланып китәр, элеккечә дәвам итәр. Сәгать... Сәгать... Менә хәзер Әндәрҗан уянып чыгар... Миңа карамыйча гына чүгәләп алыр... Чү, кем җырлый? Кичәге тавыш!

Еракта̃н җырлый-жырлый Әндәрҗан килә.

Әндәрҗан. Кояш нурын кочагыма
Төясем килә бүген.
Җирне, күкне, җилне, нурны
Сөясем килә бүген.
Нигә? Белмим.
Таңнан торып җилне куам
Нигә, нигә?
Шаян дулкын миңа туган
Нигә? Нигә?
Нур атыла кочагыма
Нигә, нигә?
Кемнән сорыйм, кемгә сөйлим?
Кемгә, кемгә? (*Керә.*)

Наилә. Миңа, Әндәрҗан, миңа сөйлә!

Әндәрҗан. Шаулама... Тыңла гына. Кызлар йоклыймы?

Наилә. Йоклый.

Әндәрҗан. Ишетәсеңме, әнә җирнең нәкъ үзәгендә акрын җир тетри башлый... Чәчәкләр күзләрен ачалар.

Наилә. Син авырыйсыңмы?

Әндәрҗан. Син берни дә ишетмисеңме?

Наилә. Ишетәм.

Әндәрҗан. Хәзер сынап карыйбыз. Сана.

Наилә. Чыбык сынды. Марат бабай йөри. Әнә бака кычкыра. Әнә кош сайрый.

Әндәрҗан. Моны бөтен кеше ишетә.

Наилә. Олы юлдан машиналар үтә.

Әндәрҗан. Бик аз. Ике колагы булган кешегә болар гына бик бәләкәй... Менә һәр иртәне син җырлап йөрисең. Нәрсә мәҗбүр итә сине җырларга?

Наилә. Матурлык.

Әндәрҗан. Болытлы, ямьсез көз көннәрендә дә җырлыйсың ич.

Наилә. Мәхәббәт.

Әндәрҗан. Җырлардан элек син ни ишетәсең?

Наилә. Анысы күңел эше, кемнең күңеле ни тели.

Әндәрҗан. Кайнар чәй эчәсем килә. Өйдә әнкәй пешергән кайнар көлчә белән утлы чәй... Шикәрне кетерт-кетерт тешли-тешли. Бәләкәй малай буласым килә.

Наилә. Аякларың юешләнеп беткән. Син почтага төштеңме әллә?

Әндәрҗан. Юк, мин күккә мендем. Аллалар, фәрештәләр янына.

Наилә. Кабул итмәделәрме?

Әндәрҗан. Үзең генә менмә, Наиләне дә ал диделәр.

Наилә. Акылсыз фәрештәләр икән.

Әндәрҗан. Нигә?

Наилә. Наиләне алырга әйбермени ул?

Әндәрҗан. Итәгемнән тартып җиргә төшердең. Чәй эчәсем килә, чәй! (*Кычкыра.*) Марат бабай!

Марат керә.

Бу нинди әкәмәт?

Марат. Хыянәтче сакалны кырып ташладым.

Наилә. Яшәреп киткәнсең, Марат бабай.

Әндәрҗан. Әбиләр авызына охшаган авыз... Кайнар чәең бармы?

Марат. Әби дип кимсетмә әле син!.. Чәй, чәйдәмени эш? Таптың сүз... Әнә чәй, эч!

Әндәрҗан чыга.

Наилә. Хәтерең калмасын инде, бабай.

Марат. Сөйләшә белеп сөйләшкән яхшы.

Наилә. Нигә миннән бер сүз дә сорамыйсың, Марат бабай? «Черкиләр ашап бетермәдеме?» диген...

Марат. Әй, черкиләрдәмени эш!.. Сакал җәзасын алды. Җамал карчык белән Сәрвиназ-каракашның һушын алам әле мин. (*Чыга.*)

Наилә. Шомыртым, син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?.. Ни үзгәрде? Каян, кемнән чыкты бу кодрәт? Нигә Әндәрҗан туры гына миңа карамый. Кинаяләр белән сөйли. Көпә-көндез җыр җырлап йөри. Шомырткаем, син барысына да шаһит бит. Нигә дәшмисең?!

Палаткадан Фәридә чыга.

Фәридә. Наилә!

Наилә. Берегез дә минем белән сөйләшмәгәч, мин үземә яңа иптәш таптым.

Фәридә. Әйт әле, кызларга матурлык нәрсәгә кирәк?

Наилә. Белмим.

Фәридә. Матурлык кызларга горурлык өчен кирәк.

Тән, җан сафлыгы... Матурлык, шуннан горурлык. Уйлый-уйлый мин шундый карарга килдем.

Н а и л ә. Сез очраштыгызмы?

Ф ә р и д ә. Әйе.

Н а и л ә. Ничек?

Ф ә р и д ә. Сорама...

Н а и л ә. Болай гына...

Ф ә р и д ә. Әйтәм алайса... Егет күрер күзгә әйбәт... Тик эче дә, тышы да безнең Әндәрҗанга охшаган. Бер аермалары гына бар: Әндәр балык кебек тып-тын йөзә, бу өздереп җырлый белә.

Н а и л ә. Җырлый белә?

Ф ә р и д ә. Әйе, нигә аңа исең китә?

Н а и л ә. Болай гына соравым... Син Әндәрне яратмыйсың.

Ф ә р и д ә. Син аны яраткан өчен мин сине дә яратмыйм. Син матур. Горур бул. Кайчагында без, кызлар, яңакка чалтыратасы урынга авыз ерабыз. Бер шәп кенә салсаң, авызын үлчәп ачар иде... Ялгыш сүз әйттеме — чалт берне! Авызын бер сантиметрга киңрәк җәйдеме — чалт, чалт!

Н а и л ә. Җир йөзендә егет токымын калдырмассың.

Ф ә р и д ә. Тыштан ялтырап, эчтән черек агач кебек калтырап торган чибәр егетләрдән сак бул!

Н а и л ә. Яңактан ут чыгарып кына егетләрне төзәтеп булса икән.

Ф ә р и д ә. Кеше алданмасын да, алдамасын да. Юынырга төшәсеңме?

Н а и л ә. Юындым. Су салкын бүген.

Фәридә төшеп китә, палаткадан Г а л и я чыга.

Г а л и я. Фәридә кайда?

Н а и л ә. Кичәге яраларын ялый.

Г а л и я. Фәридә яраланмас, нык ул...

Н а и л ә. Күңел яраларын...

Г а л и я. Ә-ә... (*Утырып йоклап китә.*)

Н а и л ә. Галия! Йокыга китте...

Г а л и я. Йоклыйммы, йокламыйммы, белмим...

Н а и л ә. Берүземә генә күңелсез, уян.

Г а л и я. Мин әллә кайчан йокламыйм... Синең Әндәрҗан белән сөйләшүеңне дә ишеттем. Тик бик шыпырт сөйләштегез, берни аңламадым... Фәридә сүзләрен ачык ишеттем.

Н а и л ә. Нинди нәтиҗәгә килдең?

Г а л и я. Нәтиҗә миңа үзе килә. Беркем дә мине сөйми, беркем дә мине карт карама янына күрешергә чакырмый...

Н а и л ә. Фәридәдән үрнәк алырга кирәк безгә. Мин үзем дә йомшак, җебегән, Галия! (*Чыга.*)

Галия, ак япмасына төренеп, кулгә төшеп китә. М а р а т керә, шәбәеп кенә атлый, йөренә. Җ а м а л килә.

Җ а м а л. Марат, Марат!

М а р а т (*борылып*). Әү.

Җ а м а л. Әстәгыфирулла, тәүбә, тфү-тфү... Тәүбә, тәүбә! Марат дисәң, Марат түгел. Димәсәң...

М а р а т. Кәҗә дисәң — сакалы юк, сыер дисәң — мөгезсез. Егет шәпме?

Җ а м а л. Нигә болай котырынып йөрисең?

М а р а т. Сакал кызларга ошамый.

Җ а м а л. Бер бабай җаны чыкканда да гыж-гыж килгән ди. Әллә «кыз» дигән, әллә җанын биргән.

М а р а т. Җан биргәндә дә кызлар уйларлык булгач, егет бабай булган инде ул!

Җ а м а л. Оят сүз сөйлисең түгелме, кем, Марат? Моның гөнаһысы бик авыр булыр бит.

М а р а т. Кайда Сәрвиназ-каракаш? Исе китсен әле бер. Сәрвиназ, Сәрвиназ! Чык монда!

Җ а м а л. Марат...

М а р а т. Ни сөйләрсең икән, Җамал карчык?

Җ а м а л. Оят булса да әйтим...

М а р а т. Нинди оят булсын, әйт.

Җ а м а л. Бүген иртән-иртүк таң этәчләре белән уяндым да әллә нишләп аягым Сәрвиназларга тартмады.

М а р а т. Күрдеңме сакал кыруның сихерен!

Җ а м а л (*ачуланып*). Нинди сихер? Тузга язмаганны әйләндерәсең. Сихер-михер дә, берни дә юк, алай ару сүзне кыек ишетсәң, кайттым киттем. Мин тагы аңа дип яшь карлыган яфрагы салып һинд чәе алып килгән булам.

М а р а т. Сихер инде, сихер! Югыйсә сине аякларың миңа таба тартып китерер идеме?

Җ а м а л. Синең белән гөнаһ диңгезендә батасыңны көт тә тор икән. Мәрхүмә Наһар ахирәт әллә ни уйлар. Әйдә, суынганчы чәеңне эчеп ал.

М а р а т. Тол кешенең эче салкын, Җамал карчык. Әйдә. Килүеңә рәхмәт!

Чыгып китәләр. Ф ә р и д ә юынып менә, теркелдәп С ә р в и н а з килә.

Ф ә р и д ә. Сәрвиназ-каракаш...

С ә р в и н а з. Исәнме, кызым-матурым.

Ф ә р и д ә. Марат бабай сине гел каракаш дип йөрдеме?

С ә р в и н а з. Минем мәрхүм Галием шулай дип йөри иде...

Ф ә р и д ә. Ә Җамал әби кайда? Сез гел бергә килә идегез.

С ә р в и н а з. Юк Җамал карчык.

Ф ә р и д ә. Кайсы төше авырта?

С ә р в и н а з. Юк ла.

Ф ә р и д ә. Сезне гел-гел бергә күреп күз күнеккән...

С ә р в и н а з. Син әйтәсеңме инде аны, мин әйтимме.

Ф ә р и д ә. Ачуланыштыгызмы әллә?

С ә р в и н а з. Нигә ачуланышыйк? Мал бүлешеп, авызыбызны тәмсезләп йөрисебез юк әле.

Ф ә р и д ә. Алайса, кайда соң ул?

С ә р в и н а з. Аны, кызым, сиңа гына сөйләсәм инде... Үзем дә килә-килә хәйраннарга калам. Менә бүген таң әтәчләре белән тордым да чәй эчеп тамак ялгап алдым. Кыштыр-кыштыр әзерләндем. Әзерләнеп беткәч, карасам, берүзем сезнең янга килеп ятам.

Ф ә р и д ә. Котлыйм.

С ә р в и н а з. Аптыраш, гел аптыраш.

Ф ә р и д ә. Сәрвиназ әби, сез кичә теге нефтьче егетне кайда очраттыгыз?

С ә р в и н а з. Аны әйтәсең икән әле. Юлда, Җамал карчык белән килеп ята идек, машина белән артыбыздан бастырдылар. Туктатып утырттылар. Юл буе сөйләшеп килде, ипле дә егет инде менә! Теле телгә дә йокмый.

Ф ә р и д ә. Исемен сорадыгызмы?

С ә р в и н а з. Үзе әйтеп торды, Зәки атлы икән.

Ф ә р и д ә. Зәки? Рәхмәт, Сәрвиназ әби.

С ә р в и н а з. Шунда кеше-мазар күрмәгәндә генә Марат бабайны чакыра алмассыңмы икән? Әллә ничек оят, тиз-тиз генә тамагына ашатыйм да китим әле.

Ф ә р и д ә. Әйдә, Сәрвиназ әби!

Чыгалар. Алар артыннан ук **Ә н д ә р җ а н** керә. **Ф ә р и д ә** бераздан борылып килә.

Ә н д ә р җ а н. Фәридә-ү!

Ф ә р и д ә. Әллә сүзең бар инде, Әндәрҗан?

Ә н д ә р җ а н. Хәлеңне белергә теләгән идем.

Ф ә р и д ә. Пульс кызыксындырамы, температура, кан басымымы?

Ә н д ә р җ а н. Барысы да.

Ф ә р и д ә. О!

Ә н д ә р җ а н. Иптәшләрчә генә сөйләшмисең инде?

Ф ә р и д ә. Яратмыйм күз буяуны, алдауны, хәйләне. Китәбез дип пыр тузынгач та, син хәлне сораша башладың.

Ә н д ә р җ а н. Аның өчен түгел, Фәридә.

Ф ә р и д ә. Барыбер китәбез.

Н а и л ә керә.

Ә н д ә р җ а н. Китегез, күземә күренмәгез, җәһәннәмгә җитегез.

Ф ә р и д ә. Менә ичмасам рәхмәт. Үз тавышың чыкты.

Н а и л ә. Әндәрҗан, бер сәгать эчендә сине җен алыштырдымы? Әллә иртән мин күргәне Әндәрҗан түгел идеме?

Ә н д ә р җ а н. Усал булсаң, яратмыйлар, таләп итсәң, ошатмыйлар. Инде кешечә ягымлы гына сөйләшәм дисәң, кылана диләр.

Н а и л ә. Көтүче малай болында сарыклар көтә икән. «Бүре бар, бүре!» — дип кычкырган бу... Авылдашлар күсәкләр тотып төшсә, бүре дә юк, берни дә юк. Тагын шулай алдаган малай.

Ә н д ә р җ а н. Беләбез, ахырын сөйләмәсәң дә була.

Н а и л ә. Иртән җырлап кайткан Әндәрҗан, хәзер...

Ф ә р и д ә. Әндәрҗан җырлый беләме?

Н а и л ә. Нигә белмәсен? Тик аны бит җен алыштырган, шул җырларга ирек кенә бирми! (*Чыгып китә.*)

Ә н д ә р җ а н. Инде бусы да тәмам канга тоз сала башлады.

Ф ә р и д ә. Бер җырла әле, Әндәрҗан!

Ә н д ә р җ а н. Сезнең белән җырларсың да, җыларсың да. (*Чыга.*)

Ф ә р и д ә. Марат бабай, Марат бабай!

М а р а т керә.

Шундый матур сакалыңны нишләттең?

М а р а т. Күтәреп йөри-йөри арыган идем, котылдым.

Ф ә р и д ә. Сине бер кеше көтеп тора.

М а р а т. Кем ул тагын?

Ф ә р и д ә. Сәрвиназ-каракаш.

М а р а т. Ул да килгәнмени?

Ф ә р и д ә. Бик шуклана башладың әле син. Япа-ялгызы килгән. Сине чакырды.

М а р а т. Чакырды дисеңме?.. Их, каһәр! Бу якта Җамал карчык, теге якта каракаш!.. Кичәге егет хәле кабатлана бит.

Ф ә р и д ә. Нинди егет ул, Марат бабай?

М а р а т. Ә, болай гына. Кичә бер әкият ишеткән идем.

Ф ә р и д ә. Ике көймәнең койрыгын тотып, ике хуҗаның боерыгына өлгермәкче буласыңмы?

М а р а т. Җитез кеше җилдән узар, бөтен җиргә борынын сузар. Киттем Сәрвиназ-каракаш янына! Җамал карчык күренсә, хәзер килә диген.

Ф ә р и д ә. Ярар.

Марат чыга. Җ а м а л керә.

Җ а м а л. Марат бабаң кайда?

Ф ә р и д ә. Сәрвиназ-каракаш чакырып алды.

Җ а м а л. Ә? Ул килгәнмени?

Ф ә р и д ә. Килгән шул.

Җ а м а л. Адәм көлкесенә калып беттем бит! (*Чыга.*)

М а р а т чабып керә.

М а р а т (*кычкыра*). Сәрвиназ-каракаш, мин хәзер! Җамал карчык!..

Ф ә р и д ә. Охшарга тырышып төлкегә, каласың бит көлкегә! (*Чыгып китә.*)

Марат әле бер якка, әле икенче якка чаба, Ә н д ә р җ а н керә.

Ә н д ә р җ а н. Марат бабай!

М а р а т. Вакыт юк. Җамал карчык. Сәрвиназ-каракаш... Җамал-каракаш... Сәрвиназ карчык...

Ә н д ә р җ а н. Тукта!

М а р а т. Тукталырга әмәл юк.

Ә н д ә р җ а н. Марат бабай, синнән яшерен-батырын юк, тагын бер кич теге мыекка әйләнергә туры килә.

М а р а т. Ә?

Ә н д ә р җ а н. Мине тыңламый, минем белән сөйләшеп тормый. Теге егеттән тагын хат тапшыр!

М а р а т. Башны бетерәсең, ахры, син.

Ә н д ә р җ а н. Фәридәдән башка яши алмыйм. Аңла минем хәлемне!

М а р а т. Бар, алайса, ике якта ике карчык, ничек булса да юмалап, шуларны тотып тор. Мин хәзер!

Икесе ике якка йөгерешеп китәләр, М а р а т әйләнеп керә.

М а р а т. Фәридә, Фәридә!

Г а л и я, Н а и л ә, Ф ә р и д ә керәләр.

Ф ә р и д ә. Без китәбез, Марат бабай.

М а р а т. Син мин карт юләрне кичер, теге мыеклы егет иртән хат калдырып киткән иде. Тәки шуны тапшырырга онытканмын!

Ф ә р и д ә. Хат?

Г а л и я. Алма, Фәридә!

Н а и л ә. Ертып ташла!

Ф ә р и д ә. Хат? Бир әле... Сәли-Кәли-Госман-Зәки... Нәрсә яздың икән?!

М а р а т. Фу, тәмам калтырап төштем, кесәмә тыгылсам, шунда хат!

Әндәрҗан керә.

Әндәрҗан. Марат бабай, Сәрвиназ-каракаш!
Марат. Монда алардан да хәтәррәк эшләр бар әле.
Әндәрҗан. Җамал әби үпкәли...
Марат. Хәзер, хәзер!
Галия. Матурлык — горурлык ул, Фәридә!
Фәридә. Ул мине тагын чакырган!.. Барам!
Әндәрҗан. Уф...
Марат. Егете бик шәп шул!
Галия. Мин бармас идемме, барыр идемме, белмим.
Наилә. Их Фәридә, Фәридә!
Фәридә. Барам!.. Эндәшми торыгыз... Минем барасым килә!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Карт карама яны. Кич. Сәрвиназ керә. Аның артыннан Марат килә.

Марат. Сәрвиназ-каракаш! Чак кына торып тор, сүземне тыңла...
Сәрвиназ. Юк, юк, Марат, тыңлар хәлләрем бетте.
Марат. Дөнья булгач, адәм башыннан нинди хәлләр кичми...
Сәрвиназ. Тыңламыйм, Марат, киттем! Хуш булып тор! (*Чыгып китә.*)

Марат кире якка чаба, аннан Җамал килә.

Марат. Җамал карчык, ичмасам син акыллырак бул.
Җамал. Акыллырак булам дип адәм көлкесенә калыр көнем юк, Марат. Хуш, исән бул, берүк мине гаепләп калма!
Марат. Сүз әйтергә ирек бирәсеңме син, юкмы?
Җамал. Менә мин киткәч, хет төне буе сөйләш! (*Чыга.*)
Марат. Кем белән сөйләшим? Шомырт агачы белән әңгәмә сугып торырга миңа унсигез яшь түгел ич! (*Чыга.*)

Пауза. Әндәрҗан белән Фәридә икесе ике яктан киләләр, Әндәрҗан мыек ябыштырган, костюм кигән.

Әндәрҗан. Фәридә!
Фәридә. Әйе, бу мин.
Әндәрҗан. Рәхмәт. Килмәссез дип уйлаган идем.

Фəридə. Килдем. Ике соравым бар.

Əндəрҗан. Ник килүегез аңлашылды.

Фəридə. Килүем өчен шатланыгыз да гаеп-кыеклар эзлəмəгез.

Əндəрҗан. Мин кичəгелəр өчен гафу үтенəм.

Фəридə. Тиз үзгəргəнсез.

Əндəрҗан. Кичə бит... роль шундыйрак иде.

Фəридə. Яман шəп уйнадыгыз сез кичə! Уйнап кына каравылчы картны кимсеттегез... Шаярып кына минем күңелгə пычак кадарга маташтыгыз.

Əндəрҗан. Əле сез барын да белмисез!.. Иң элек сезне тыңлап карыйк.

Фəридə. Беренчесе. Нигə сез туп-туры безнең янга, минем иптəшлəр янына килмисез?

Əндəрҗан. Хатаны кайда ясасам, шунда төзəтəсем килə.

Фəридə. Хатаны ясау гына ансат бит ул Сəли-Кəли-Госман...

Əндəрҗан (*əйтеп җибəрə*). Зəки.

Фəридə. Зəки. Хəзер икенче сорау.

Əндəрҗан. Мин бусыннан бик куркам.

Фəридə. Бусы иң-иң җиңел сорау булачак.

Əндəрҗан. Мин сезнең кулда.

Фəридə. Куян фермасында эшлəгəнем юк, зинһар, калтырап тормагыз, гадəтлəрен белмим.

Əндəрҗан. Алайса, нигə ул сорауны бирəсез?

Фəридə. Минем өчен мөһим ягы бар аның.

Əндəрҗан. Күктəн йолдыз чүпли алмыйм.

Фəридə. Белəм. Җир асты тирəнлегенə төшəргə яратасыз.

Əндəрҗан. Куйыйк... Эш турысында булса, алдан ук əйтеп куям, җавап бирмим.

Фəридə. Əйтегез əле, Сəли-Кəли-Госман...

Əндəрҗан (*əйтеп җибəрə*). Зəки.

Фəридə. ...Зəки. Сезнең иң яраткан җырыгыз кайсы җыр?

Əндəрҗан. Бу мин көткəнгə караганда да куркынычрак сорау.

Фəридə. Əгəр моннан да өркеп торсагыз...

Əндəрҗан. Сорау куркытмый, мин җавап биргəннəн соң сез чыгарачак хөкем куркыта.

Фəридə. Мин хөкемне чыгарып тормам.

Əндəрҗан. Дөньяда мондый кызлар барын белми идем əле.

Фəридə. Сез кызлар мəсьəлəсе буенча Берлəшкəн Миллəтлəр Оешмасында вəкилмени?

Әндәрҗан. Түгел лә.

Фәридә. Алайса, нигә боргаланып-сыргаланып торырга? Тотыгыз да җырлагыз! Ялгыз калган чакларда сез нинди буласыз? Үзегезне ялгыз дип уйлагыз. Мин юк.

Әндәрҗан. Күптәннән ялгыз калганым юк инде... Үзем ялгыз калсам да, күңелемдә ике кеше көрәшә!

Фәридә. Чакырыгыз, алайса, үзегезнең игезәгегезне! Килсен дә җырласын!

Әндәрҗан. Килде! (*Җырлый.*)

Кыр казлары үтте, санамадым.
Яз кайтырлар әле. Санармын.
Истәлеккә биргән кулъяулыгың
Ядкарь итеп көн дә карармын.
Кыр казлары кебек син дә киттең.
Көннәр, айлар үтте. Санадым.
Кайтырсың да аңларсың ла, җаным,
Ялгыз яшәүләрнең газабын.
Кыр казлары кайта, сәлам биреп,
Җилпи-җилпи канат кагынып.
Син генә юк, тагын ничә язлар
Яшәрмен мин сине сагынып.

Фәридә. Менә хәзер китсәм дә була.

Әндәрҗан. Бу — рәхимсезлек.

Фәридә. Килдем. Күрдем. Тыңладым.

Әндәрҗан. Җиңдем, көлдем, саубуллаштыммы?

Фәридә. Уйладым. Аңлаштым. Хушлаштым.

Әндәрҗан. Йөрәккә ут кабыздым. Бәхетне урладым. Качтым.

Фәридә. Эх, бу егетләр түземсезлеген!

Әндәрҗан. Егетләрдә дә йөрәк бар, алар бит кибет витринасына куйган сыннар түгел.

Фәридә. Хушыгыз. Мин моннан бөтенләйгә китәм.

Әндәрҗан. Нигә?

Фәридә. Шулай.

Әндәрҗан. Сезне берәрсе кимсеттеме?

Фәридә. Әйе.

Әндәрҗан. Кем?

Фәридә. Сез ул кешене кыйнарга уйлыйсызмы?

Әндәрҗан. Кирәк икән, кыйбат сорамам. Сөякләрен көлгә әйләндереп шушы күл төбенә чәчәрмен.

Фәридә. Алайса, барыгыз да безнең техникны тукмагыз.

Әндәрҗан. Әндәрҗаннымы?

Фәридә. Каян беләсез сез аны?

Әндәрҗан. Миңа теге... бабай сөйләде. Әйе, ул! Ару гына егет диде бит ул аны...

Ф ә р и д ә. Бабай өчен ару кеше, безнең өчен агу кеше. (*Наилә күренә.*) Кем йөри ул анда?

Н а и л ә. Бу мин, Фәридә... Сез монда икән.

Ф ә р и д ә. Кил, Наилә, таныш.

Н а и л ә. Мин күлнең теге ягында идем... Сез берәр кешенең җырлап узганын ишетмәдегезме?

Ф ә р и д ә. Син ул кешене эзләмисеңме?

Н а и л ә. Эзләмим. Таныш җыр кебек тоелды. Элегрәк, яшь чагында берәү шул җырны җырлый иде.

Ф ә р и д ә. Менә ничек.

Н а и л ә (*шыпырт*). Шул егетме инде бу?

Ф ә р и д ә. Үзем дә шуны белергә теләр идем. Әлегә бу егет Татарстандагы нефть корольләренең берсе, атаклы Сәли-Кәли-Госман-Зәки.

Н а и л ә. Сөйләшә белмиме әллә ул?

Ф ә р и д ә. Сөйләшүдән тыйдык. Җырлашып аңлашабыз.

Н а и л ә. Без дә шулай җырлашып танышкан идек, җылашып аерылыштык. Кичер, мин сезнең монда икәнлегегезне белмәдем!

Ф ә р и д ә. Башка урында күренергә егетемнең кыюлыгы җитми. Бабаларының бабалары маймыл түгел, куян булган.

Н а и л ә. Караңгыга качарга тырышкан егетләрдә өмет аз аларда, Фәридә! Үз башымнан кичердем. (*Чыга.*)

Ф ә р и д ә. Суга төшкән тавык кебек торабызмы?

Ә н д ә р җ а н. Мин үпкәләргә тиешме хәзер?

Ф ә р и д ә. Кыяфәтегез бик мескен...

Ә н д ә р җ а н. Бер кичтә үз-үзеңә ике тапкыр хөкем чыгарганны тыңлау җиңел түгел. Хушыгыз!

Ф ә р и д ә. Хуш, Сәли-Кәли-Госман...

Ә н д ә р җ а н. Зәки.

Ф ә р и д ә. Зәки! (*Китә башлый.*) Наилә, Наилә! (*Чыга.*)

М а р а т бабай керә, Әндәрҗан мыегын җиргә атып бәрә.

Ә н д ә р җ а н. Тагын чакырганны көтмәдең.

М а р а т. Соң ул кызыйлар икесе дә минем борын төбеннән үтеп киттеләр.

Ә н д ә р җ а н. Киттеләр...

М а р а т. Мыегыңны ташлама син, тагын кирәк булыр. (*Барып ала.*)

Ә н д ә р җ а н. Кирәк булмас!

М а р а т. Әй Әндәр, матур да җырлыйсың икән, юкка монда әрәм булып ятасың. Прәме артист... Мин яшь чагында...

Ә н д ә р җ а н. Синең яшь чагыңда ни булгандыр, белмим, әмма мине шул җыр харап итте дә.

Марат. Ай-яй, хәлең мөшкел. Кызлар лап-лоп китеп барганда, минем дә кот алынды.

Әндәрҗан. Синеке дә җиңел түгел.

Марат. Синнән киңәш сорармын дигән идем. Миңа нишләргә инде хәзер?

Әндәрҗан. Үзең миңа киңәш бир. Миңа нишләргә? Наиләгә ничек аңлатырга, Фәридәгә ничек белдерергә?

Марат. Кайсысын яратасың соң?

Әндәрҗан. Икесен дә. Ким дә түгел, артык та түгел, икесен дә яратам.

Марат. Мин дә икесен дә бит, малай.

Әндәрҗан. Фәридә белән Наиләнеме?

Марат. Нәрсәгә миңа Фәридәң белән Наиләң? Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчыкны.

Әндәрҗан. Бетте безнең башлар! Мә, киемнәрне ал да иплэп кенә үтеп кит.

Марат. Акрын. Теге кызларның берсе борылып килә.

Әндәрҗан. Килсен. Хәзер куркыныч бетте. Мыеклы егет чакта курыксам да, техник Әндәрҗан чакта мин берәүдән дә шүрләмим.

Марат. Мин киттем. Бетте безнең башлар! (*Чыга.*)

Наилә керә.

Наилә. Әндәр, бу син бит?

Әндәрҗан. Мин, Наилә.

Наилә. Нигә син гел миннән качу ягын каерасың?

Әндәрҗан. Качмыйм бит, каршыңда басып торам.

Наилә. Син җырладыңмы?

Әндәрҗан. Юк, мин түгел.

Наилә. Хәйләлисең. Син җырладың, син. Бу җырны син генә беләсең.

Әндәрҗан. Кызганычка каршы, мин үзем белгән җырларның барысын да онытгым.

Наилә. Ах, шулаймы? Күзгә карап ялганлыйсыңмы? Минем сиңа сәлам бирәсем юк! Хуш. (*Чыгып китә.*)

Әндәрҗан. Бөтен яктан һөҗүм, ә кулда корал юк. Булганы да тутыккан. Атмый.

Фәридә керә.

Фәридә. Әндәрҗан? Күптән йокы бүсәсең дип торам.

Әндәрҗан. Нишләп йөрисең, әрем тел?

Фәридә. Монда берәү постта торырга тиеш иде. Киткән. Димәк, мин аны хурлык баганасына кадаклый алмаганмын.

Әндәрҗан. Кем иде соң ул?

Фәридә. Телгә алырлык кеше түгел. Егет аламасы.
Әндәрҗан. Их Фәридә!
Фәридә. Шулай, Әндәрҗан.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Иртә. Палаткалар яны тып-тын. Мылтыгын кочаклаган, бишмәт кигән Марат керә. Әйләнгәләп йөри.

Марат. Йоклыйлар. Бөтенесе дә изелеп йоклыйлар. (*Кесәсеннән теге мыекны алып җиргә бәрә.*) Их, яшь чакларым булса... Тирә-як авылларында бер генә кыз да йоклый алмас иде. Шомырт чәчәк атканда кызлар йоклыймы? Тфү... Мылтыгы да атмый бит аның ичмасам. Шартлатып бер дер селкетер, котларын алыр идем. (*Чыгып китә.*)

Зур палатканың япмасы күтәрелә. Наилә чыга.

Наилә. Хәерле иртә, шомыртым. Син чәчәкләреңне коярга да җыенасың, ахры. Чәчәк урынында вак-вак кына тары кадәр яшел җимешләр чыгар. Димәк, синең чәчәк чагың юкка узмаган, аның нәтиҗәсе, җимеше булган!.. Ә без? Ә мин? Бөтен тормыш чуалды да китте. Бөтенебез талашып, ызгышып, дошманлашып беттек. Көннең тәртибе, тормышның яме тәмам югалды. Бүген йокымнан курка-курка гына тордым. Нәрсә булыр? Бүгенге көн тагын ниләр әзләп куяр. Фәридә дә, Галия дә минем белән юньләп сөйләшмиләр. Әндәрҗан беребезгә дә эндәшми. Җамал әби белән Сәрвиназ-каракаш бер-берсеннән качалар. Марат бабайны сүгәләр. Арага ниндидер егет килеп керде. Шулай итеп, бездә кырылыш, буталыш, шомыртым. Тагын нинди әкәмәтләр башланыр икән? Әндәрҗан каян кайтып килер: күктәнме, җирдәнме? (*Җырлый.*)

Йөгерә-йөгерә кудым җилне,
Тоттырмады җитез җил.
Ялгызлыктан газаплансаң,
Минем янга үзең кил.
Кил, кил, кил, гүзәлем!
Өзелә бит үзәгем!
Ак дулкыннарны учыма
Сыйдырырга теләдем.
Алар качты, белми китте
Үзәгем өзелгәнен.
Кояш нурын кочагыма
Төйисем килә бүген!

Җирне, күкне, җилне, нурны
Сөясем килә бүген.

Әндәрҗанның палатка япмасы күтәрелә. Әндәрҗан чыга. Чүгәләп, тураеп ала.

Әндәрҗан (*Наиләгә карамыйча гына*). Ничек, Наилә, почта кагылмадымы? Документлар кайтмадымы?

Наилә. Ю-юк.

Әндәрҗан. Нигә ул кадәр каушадың? Каушама, бүген килмәсә, иртәгә булыр. Барыбер үз дигәнебезне эшләрбез! (*Сөлгесен иңбашына салып, юынырга төшеп китә.*)

Наилә. Бу ни хәл тагын? Шомыртым, син күрдеңме, ишеттеңме? Әндәрҗан үз хәленә кайткан түгелме? Хәзер Марат бабай да килеп чыкса...

Мылтыгын кочаклаган Марат килеп чыга.

Марат. Саумы, кызым, черкиләр ашап бетермәдеме? Алар бит тәмлене яраталар.

Наилә. Синең кебек икән, Марат бабай. Син дә тәмледән баш тартып тормыйсың.

Марат. Бар чагында кадерен генә белмибез.

Наилә. Табу өчен югалтып карарга да кирәк бит.

Марат. Кайчагында көч салып эзләсәң табыла. Анысы да әйбәт. (*Чыга.*)

Наилә. Көн нәкъ элекке кебек башланды. Беркөн дә, теге чуалышлар башланган көн дә, нәкъ шушылай яралган иде. Хәзер безнең палатка япмасы күтәрелә дә аннан ак җәймәгә уралган, җылый-җылый шешенеп беткән, ямьсезләнгән Галия килеп чыга. Ай! (*Битләрен каплый.*)

Палаткадан чибәр, чиста киенгән Фәридә килеп чыга.

Фәридә. Наилә, бәгырем, карачы миңа. Матурмы мин? Чибәрме? Ә? Матур шул, матур! Тра-ля-ля! Ләкин шуны да искә ал: бу матурлык астында зирәк акыл яшеренгән... Көн дә матур, мин дә матур. Нигә син күксеп утырасың?

Наилә. Тешем сызлый.

Фәридә. Витамин җитми! Җебеп торган егетләрне тешләмәгәнгә ул. Менә тутаң сирәк-мирәк булса да тешләштерә, карачы минем тешләремне!

Наилә. Үтте инде, сызламый башлады.

Фәридә. Оныт чирләреңне! Мондый ямьле көнне сырхаулап торалармы... Ә, исемә төште. Нәрсә эшлисем бар икән дип уйлыйм. Галия йоклап ята бит әле. Әйдә, уятабыз.

Наилә. Иртә түгелме соң әле?

Икәүләп Галияне уята башлыйлар.

Ф ә р и д ә. Тор, алтыным, тор! Чират синеке булса да, бүген палатканы үзем җыештырам.

Н а и л ә. Чәйне үзем кайнатам. Тор.

Ф ә р и д ә. Җир йөзендә соңгы йокычы калганчы көрәшергә!

Н а и л ә. Салкын су бөркибезме?

Ф ә р и д ә. Иң яхшысы салкын күлгә илтеп салыйк!

Г а л и я (*күзен ачып*). Ә?

Ф ә р и д ә. Уянды, уянды!

Г а л и я. Ә мин йокламыйм да.

Н а и л ә. Галия дә, Марат бабай да төннәр буе йокламыйлар.

Г а л и я. Ул тол, минем дә ярым юк.

Ф ә р и д ә. Булыр ул тол, мут шайтан!

Н а и л ә. Күлгә төшәбезме?

Ф ә р и д ә. Әйдә, ялкау.

Г а л и я (*торып чыга*). И-и, кояш әнә кайда гына икән әле. Иң яхшы вакытны урладыгыз.

Н а и л ә. Барыбер йокламыйм дидең ич.

Г а л и я. Сезнең белән рәхәт күрмәссең.

Ф ә р и д ә. Атла, атла!

Галияне ике ягыннан култыклап алып бара башлыйлар.

Г а л и я. Туктагыз!

Ф ә р и д ә. Нәрсә бар?

Н а и л ә. Җыланмы?

Г а л и я. Мыек!

Ф ә р и д ә. Мыек?.. Чыннан да мыек... Һәм таныш мыек. Сәли-Кәли-Госман-Зәки патшаның мыегына бик охшаган.

Н а и л ә. Җырлыймы ул патшаң?

Ф ә р и д ә. Тавышы үзәк өзгеч. Нигә алай дип сорадың?

Н а и л ә. Бик гаҗәп, бик гаҗәп.

Г а л и я. Үтереп ташлаганнармы әллә аны?.. Мөгаен, безнең Әндәрҗанга очрагандыр да сугышканнар. Бу тегенең мыегын йолкып чыгарган.

Ф ә р и д ә. Чын мыекны йолкып чыгарырсың бик.

Н а и л ә. Бик гаҗәп, бик сәер.

Ф ә р и д ә. Син нидер беләсең, тик әйтмисең генә.

Н а и л ә. Җырлый дигәннән, Әндәрнең дә тавышы бик матур. Кичә дә, өченче көн дә мин ул җырламыймы дип чүт ялгышмадым.

Г а л и я. Хәзерге егетләрне әйтер идем, барысы бер фасон.

Ф ә р и д ә. Кирәге юк! Янсын-бетсен мыегы. Яшәсен матур көн, яшәсен чибәр Фәридә!

Г а л и я. Ә Галия яшәмәсә дә ярыймы?

Ф ә р и д ә. Галия дә яшәсен!

Н а и л ә. Сез бара торыгыз. Мин чак кына соңрак төшәрмен.

Ф ә р и д ә. Озаклама, ялгыз йөрү — ямьсезлек.

Г а л и я. Галиягә яшәмәсә дә ярый. Барыбер аны берәү дә яратмый, берәү дә хат язмый...

Чыгып китәләр. М а р а т үтеп бара.

Н а и л ә. Марат бабай, бу мыек сиңа таныш түгелме?

М а р а т. Парикмахерскийда эшләгәнем юк. Мин бывший моряк.

Н а и л ә. Юк, болай гына, читтән-читтән генә танышлык юкмы?

М а р а т. Үз мыегым үземә җиткән, кешенеке кештәктә!.. Син менә шуны әйт: Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчык нишләрләр диген? (*Чыга.*)

Н а и л ә. Әгәр шушы серле мыек булмаса, бүгенге көн гадәттәгечә башланды дияргә булыр иде... Юк, шомыртым, алай ук түгел икән. Хәзер, хәзер... Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчык чөкердәшеп килеп җитә торганнар иде. Бүген алар юк. Бетте тынычлык, бетте тормыш яме! (*Чыга.*)

С ә р в и н а з белән Җ а м а л аллы-артлы бик тәмләп сөйләшеп килеп керәләр.

С ә р в и н а з. И-и Җамал ахирәт, теге казлар уңган елны әйтәсеңме?

Җ а м а л. Шул инде, шул. Безгә каз өмәсенә унике кыз җыелган иде. Каз куыгы куеп, Ибраһимның котын алган идек.

С ә р в и н а з. Соңгы елларда өмәләр бетте.

Җ а м а л. Бар, каз куыгы шартлатып егетләрне куркытып кара.

С ә р в и н а з. Үзләре көне-төне әллә ни шартлаталар. Нефть эзлиләр икән.

Җ а м а л. Гәҗитәдән укыдым. Безнең район нефть диңгезе өстендә утыра, имеш...

С ә р в и н а з. Шулай, шулай.

Җ а м а л. Бу Марат күзгә-башка күренми әле.

С ә р в и н а з. Әллә азрак хәтерен чуалттыкмы кичә?

Җ а м а л. Чуалмас, Сәрвиназ ахирәт, нигә чуалсын?

Н а и л ә керә.

Н а и л ә (*шатланып*). Булды!

Җ а м а л. Ни булды, кызым?

Н а и л ә. Сез Марат бабай янына килдегезме?

Җ а м а л. Йокысыннан тормаганмы әллә?

Сәрвиназ. Шуның янына инде, кызым. Тагын кем янына килик. Без өч тол, өч дус.

Наилә. Марат бабай! (*Чыгып йөгерә.*)

Әндәрҗан, Галия, Фәридә күлдән юынып менәләр.

Әндәрҗан. Тирә-яктагы сазлыкны киптергәч, бу күл гаҗәеп ял урыны булачак.

Фәридә. Сәрвиназ-каракаш килгән!

Галия. Җамал әби дә монда.

Фәридә. Ә күл үзе кипмәсме соң?

Әндәрҗан. Минем исәпләп чыгаруларым буенча күл үзе кипмәскә тиеш. Шуның документларын көтәбез ич. Әгәр белер-белмәс килеш эшкә тотынсак, күлне харап итүебез бар.

Сәрвиназ. Бигрәкләр дә матур күл инде.

Җамал. Марат бабабыз җитешеп балык тотып куярмын дигән иде.

Наилә керә.

Наилә. Марат бабай югалган.

Җамал. Кит аннан.

Әндәрҗан. Әле генә сөйләшеп тордык ич.

Фәридә. Без дә күрдек.

Галия. Мин дә... күрдемме, юкмы, әйтә алмыйм.

Сәрвиназ. Кая китәр ул, гөнаһ шомлыгы?

Әндәрҗан. Беркая да китмәс.

Наилә. Бөтен җирдән карадым. Мылтыгын агачка элгән, үзе юк.

Кабаланып Марат кайтып керә, кулында пакет.

Марат. Почта, почта!

Әндәрҗан. Нинди почта? Каян килсен ул?

Марат. Сәрвиназ-каракаш белән Җамал карчыкны каршы алырга дип...

Сәрвиназ. Без монда ич инде, Марат.

Марат. Ничек? Миңа үпкәләмәдегезмени?

Җамал. Әйдә, Марат, үткән беткән, җилгә очкан. Мин, тиле күңел, әллә Сәрвиназның синең белән ялгыз гына очрашасы киләме икән дип, синең янга бер башым чыгып киткән идем.

Сәрвиназ. Ә мин Җамалда шундый яшертен уй юкмы икән дип борчылып берьялгызым китеп бардым.

Җамал. Сөйләштек тә аңлаштык, әйбәт булып китте.

Марат. Их, яшь чаклар искә төшеп китте. Шулай бервакытны...

Наилә. Беләбез, беләбез!

М а р а т. Сөйләдеммени? Кайчан өлгердем соң әле?
Г а л и я. Ә почта? Миңа әнкәйдән хат бардыр әле.
М а р а т. Нинди почта? Ә, хәзер...
Ә н д ә р җ а н. Бернинди почта юк.
М а р а т. Ничек юк? Менә ярты килолы хат.
Ә н д ә р җ а н. Документлар килгән! Бир әле, бир.
Н а и л ә. Документлар килгән!
Г а л и я. Шәп булган.
М а р а т. Ләкин иң кызыгы Фәридә өчен... Шулай олы юлда торам...
Ф ә р и д ә. Ялтыравыклы, бик шәп машина килеп туктады... Беләбез ич инде.
М а р а т. Юк. Пычракка батып беткән, иске генә машина. Канатлары какшый башлаган.
Г а л и я. Машинада егетләр.
М а р а т. Юк, дим ич, ике генә егет.
Ф ә р и д ә. Берсе кара мыеклы...
Г а л и я. Икенчесе җиз чәчле.
М а р а т. Каян беләсез?
Н а и л ә. Белмәскә, менә ич аның мыегы!
Ә н д ә р җ а н. Кызлар, безгә машина бирәләр! Өр-яңа машина!
М а р а т. Тукталдылар да, бабай, син мелиораторлар группасында эшлисеңме, диләр.
Ф ә р и д ә. Беләбез ич инде! Үзләренә эшкә чакыралар, фәлән-төгән.
Н а и л ә. Азагы кызык түгел. Яшь чакларыңны сөйлә булмаса, Марат бабай.
С ә р в и н а з. Без ул мыеклы егетне, Зәкиҗанны, бүген очраттык бит, әйе, сөйләшеп тә тордык. Кызлар, сезне сораштылар. Мыегы үз урынында иде.
Г а л и я. Саескан урлап монда китергән.
М а р а т. Шунда эшлим, дим.
Г а л и я. Сездә Фәридә дигән матур бармы диләр?
М а р а т. Юк шул. Сездә Галия белән Фәридә исемле кызлар бармы диләр.
Г а л и я. Ә?!
М а р а т. Менә сиңа мә!
Г а л и я. Нәрсә бу?
М а р а т. Хат. Фәридәгә дә, сиңа да хат. Егетләр үзләре бүген баян алып күл буена киләчәкләр. Бүген шимбә!
Ф ә р и д ә. Марат бабай, җитәр инде ялганларга.
М а р а т. Гомеремдә бер ялган сүз әйтсәм, җир упсын! (*Чокырга егылып китә.*)
Җ а м а л. Хак сүз аягыннан тотамы әллә?
Н а и л ә. Байтак бутадыгыз безне, Марат бабай.
Ф ә р и д ә. Гарык булдык.

Ә н д ә р җ а н. Туктагыз, монда Марат бабайның гаебе юк.

Ф ә р и д ә. Ә кемдә соң ул гаеп?

Ә н д ә р җ а н. Мин гаепле. Моңарчы ул хатларны Фәридәгә мин яздым, күрешергә дә мин бардым. Кызларны бер дә моннан җибәрәсем килмәде.

Н а и л ә. Әндәрҗан!

Ф ә р и д ә. Күңелемдә шушы шик бар иде.

Г а л и я. Мин дә... сизендемме, юкмы, белмим.

Җ а м а л. Ай, балам. Нигә алай эшләдең инде?

М а р а т. Яз бит, яз. Шомырт чәчәк атканда андый гына шуклыклар була инде.

Г а л и я. Ә бу егетләр чынмы?

М а р а т. Чын, чын, гөрс-мәрс килеп торган нефтьче егетләр.

Г а л и я. Фәридә, алайса, без китмибез инде?

Ф ә р и д ә. Китмибез. Документлар кайтты... Яңа машиналар бирәләр... Тагын, тагын...

Ә н д ә р җ а н. Дөрес эшлисез. Безнең эшләр расланган, монда шундый планнар, планнар!

Ф ә р и д ә. Әндәрҗанга җәза!

Ә н д ә р җ а н. Күктән йолдыз чүпли алмыйм.

Н а и л ә. Җырлатабыз! Көн яктысында бер җырласын!

М а р а т. Их, яшь чаклар, Сәрвиназ-каракаш, Җамал карчык!

Ә н д ә р җ а н. Җырларга була!

Г а л и я. Башла, Әндәрҗан.

Әндәрҗан җырлый башлый, башкалар аңа кушылалар.

Йөгерә-йөгерә кудым җилне,
Тоттырмады җитез җил.
Ялгызлыктан газаплансаң,
Безнең янга үзең кил!
Ак дулкыннарны учыма
Сыйдырырга теләдем;
Эштә янып, ялда уйнап
Үтә яшь гомерләрем.
Кояш нурын кочагыма
Төйисем килә бүген.
Җирне, күкне, җилне, нурны
Сөясем килә бүген!
Сөясем килә бүген,
Сөеләсем килә бүген!

П ә р д ә.

*Казан — Займище*
*1967*

# *Кара күзле кызлар*

*Комедия ике кисәктә, дүрт күренештә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Фирдәвес.
Сәләхи.
Бану.
Шәйхел.
Мәүланҗан.
Талип.
Айсылу.
Таңсылу.
Хәйбуш.
Чәчкә.
Гөлләр.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Арыш басуы. Коры елга. Алгы планда елга буенда ару гына куаклык. Яшел чирәм белән капланган ат юлы үтә. Юл кырында телефон баганалары. Ат туктаган тавыш ишетелә. Кулына бәләкәй генә төенчек тотып Талип керә. Аның артыннан Хәйбуш атлый.

Талип. Дөньяның оҗмахы, Хәйбуш энем, менә шушында. Бар рәхәт бергә җыелган: аулак, күләгә, җиләс... Арыш урагына төшкәнче адәм аяк басачак түгел. Уф...

Хәйбуш. Талип абый, ничек көне буе шушында ята аласың син? Җитмәсә, берүзең...

Талип. Аны белсәң син, Хәйбуш, хәчтерүш түгел, Талип абзаң булыр идең!.. Күпме сорашма, артыгын күрмә. Ашыкмасаң, куянны куып җитәрсең. Белдеңме?.. Йә, бар, бар... Көндәгечә, кайтышлый мине кереп алырсың.

Хәйбуш. Бүген булмый дип әйттем бит инде.

Талип. Кайчан? Ишетмәдем, ишетмәдем. Андый мәгънәсез сүзне ишетәсем дә килми.

Хәйбуш. Безнең почтага яңа начальник килә дидем ич инде! Шуны алып кайтам.

Талип. Миңа җәяү йөрергә ярамый. Ишеттеңме? Начальниклар күп, Талип абыең бер генә.

Хәйбуш. Берлеккә тәпиләрсең инде, Талип абый...

Талип. Җитмеш кешегә җитәрлек чирне берүзем күтәреп йөрим.

Хәйбуш. Сине җен кебек таза дип сөйлиләр бит!

Талип. Ычкын алайса, Хәйбуш-хәчтерүш!

Хәйбуш. Ай була инде, көн саен алып киләм, утыртып кайтам. Рәхмәт юк... Әллә үзеңне бик җиңел дип беләсеңме? Унар килолы егерме посылка салып кайтканда да алаша болай тирләми...

Талип. Бар, юлыңда бул!.. Ишетсен колагың: көтеп торам!

Ерактан тавыш килә: «Бәдәр малае! Бәдәр малае!»

Хәйбуш. Талип абый, нәни апаң килә!

Талип. Менә сиңа аулак! Чумдым... Кара аны... (*Янап куак астына поса.*)

Ашыгып, Айсылу керә.

Айсылу. Бәдәр малае! Хәбибрахман...

Хәйбуш. Ни бар, апа?

Айсылу. Нишлисең монда?

Хәйбуш. Вак-төяк йомыш бар иде... (*Куаклыкка ымлый.*)

Айсылу. Ярар, ярар! Сөйләп торма... Син, тиктормас, председательнең ни әйткәнен аңыштыңмы?

Хәйбуш. Аңламаска...

Айсылу. Яңа начальникны туры минем өемә төшерәсең. Аңыштыңмы, минем өемә! Юлда ук мактап кайт: өенең чисталыгы, үзенең уңганлыгы, диген... Кандаламазар кебек хәшәрәтнең герман сугышыннан бирле күренгәне юк, диген. Утыз ике чебие бар, диген.

Хәйбуш. Беләм лә инде. Таңсылу апа да әйткән иде.

Айсылу. Таңсылу? Ни катышы бар аның?

Хәйбуш. Сез икәү торасы бит! Ул да хуҗа ич.

Айсылу. Булмый торсын әле! Начальникка әйт: йортка Айсылу тәтәй хуҗа диген!

Хәйбуш. Ярар ла. (*Китә башлый.*)

Айсылу. Таңсылу бутап, буталып йөрмәсен! Председатель Мөхәммәтхан үземә аерып әйтте: начальникларның килеп-китеп йөрүе туйдырды, бусын, Айсылу тәтәй, фатирга да керт, өйләндереп тә җибәр. Төпләнсен, үзебездә калсын, диде. Миңа әйтте!

Х ә й б у ш. Беләм лә инде...

А й с ы л у. Алып кайтып, исән-сау гына бездә калса, өйләнсә, тавыкларым кара Хәсәннәргә ияләшмәсә, киләсе ел сабан туенда үзенә бер дистә буяган күкәй бирермен.

Х ә й б у ш. Нәрсәгә ул миңа?

А й с ы л у (*аңа ияреп бара*). Утыз ике чебине әйтергә онытма. Кала кешесе тавык-чеби өчен үлә ул...

Х ә й б у ш. Онытырлыкмы соң?! (*Чыгып китә.*)

Арба тавышы. Хәйбуш сызгырып, җырлап җибәрә. Айсылу кулын кашы өстенә куеп каранып тора. Ары-бире әйләнгәли.

А й с ы л у. Чәнчелгере... Сиңа кирәкмәгәндә машинасы чебен күк урала!..

Т а л и п Айсылудан ныграк качарга чамалап кузгала.

Ай, җылан бар! Бүре! Аю!..

Т а л и п. Нәни апа, курыкма...

А й с ы л у. Нишләп ятасың монда, суйлак?

Т а л и п. Нәни апа...

А й с ы л у. Бирермен мин сиңа нәни апаңны! Кыяфәтеңә кара! Чалбарыңа сырлан сарган. Сакалың биленә җиткән...

Т а л и п. Буа ерылды...

А й с ы л у. Кемгә охшап тудың икән син, бала!

Т а л и п. Сиңа охшаган диләр.

А й с ы л у. Кем әйтә?

Т а л и п. Бөтен авыл сөйли. Нәни апаң белән бер агачта пешеп, өзелеп төшкәнсез диләр.

А й с ы л у. Шуны лыгырдаган гайбәтченең теле өзелеп төшсен.

Т а л и п. Нәни апа... Хәйбушка ни куштың син?

А й с ы л у (*еламсырап*). Инде ни дип яманатымны саталар икән!.. Шулай инде ул, ятим кешене адым саен кыерсыталар!.. Өеңдә ир-атың булмасын, яклаучың булмасын...

Т а л и п. Мин ир-ат түгелмени синеңчә?

А й с ы л у. Кара, кара, бу бүселгәнне! Ирмени син? Өйләнеп пыр туздырып яшәмәгәч, җир җимертеп эшләмәгәч... (*Чырылдап.*) Нишләп ятасың син монда?

Т а л и п. Арыш өлгергәнне күзәтәм!..

А й с ы л у. Заманында тракторчы кисәге идең бит син!.. Әйтәм җирле, иртән югала, кич кайта... Шушында йокы бүсә икән, хөрәсән!

Т а л и п (*үз-үзенә*). Кичкә кадәр туктатырмын димә...

А й с ы л у. Күз көеге!..

Т а л и п. Нәни апа, Хәйбуш белән ни килештегез сез?

А й с ы л у. Ир булсаң, хатын-кыз эшенә тыгылма!

Т а л и п. Шулай да...

А й с ы л у. Кая олаккан бу машиналар?..

Т а л и п. Нәни апа... Мунчаңа су ташып бирермен, ишегалдын себерермен!

А й с ы л у. Белеп тор алайса. Почтага яңа начальник китертәләр. Каладан! Авылыбызда начальник булырлык юньле адәм бармы?.. Менә сине генә кара: нәрсәгә ярыйсың син?

Т а л и п. Мине онытып тор әле!

А й с ы л у. Председатель дөресен әйтә шул...

Т а л и п. Кайсы председатель?

А й с ы л у. Мөхәммәтхан инде! Авыл советы председателе.

Т а л и п. Дуслашкансыз, ахры, сез икәү?

А й с ы л у. Тутаңнан башка ни эш кыра ала ул?.. Менә шул яңа начальник егет кеше, имеш... Мөхәммәтхан әйтә, шуны фатирга керт, өйләндер. Авылда төпләнсен, ди...

Т а л и п. Өйләндерү синең кулдан килерме соң?

А й с ы л у. Менә дигән кыз алып кайтам мин аңа!

Т а л и п. Нигә алып кайтасың? Авылда кыз беткәнмени?

А й с ы л у. Авыл кызларын син тинтәк янына алып кайтып буламы соң?.. Тел очына килде, әйтим әле! Син, тунеяд башың белән, начальник күзенә күренеп йөрмә!.. Чәчеңне йолкып бетерермен. Ашарыңа әрбәлеккә, тавык оясы янына чыгарырмын...

Т а л и п. Эшең барып чыкса, миннән бер тартма караҗимеш.

А й с ы л у. Нишләп синнән? Син өйләнмисең бит?

Т а л и п. Эшләгән яхшылыкларың искә төште... Кече күңелле бит син, нәни апа! Гел яхшылык кына тансыклап торасың...

А й с ы л у. Ай Аллам, машина чыкты түгелме?

Т а л и п. Кайсы авылга барасың соң син?

А й с ы л у. Туктагыз, туктагыз, әй! (*Чабып чыгып китә.*)

Куак артыннан Т а ң с ы л у чыга.

Т а ң с ы л у. Талип, Талип!.. Мондарак кил әле!

Т а л и п. Олы апа? Гомергә басуга чыкмаган кеше...

Т а ң с ы л у. Ни сөйләште теге кынҗыр синең белән?

Т а л и п. Тапты инде... Нәни апа мине бик ярата бит ул.

Т а ң с ы л у. Теге яңа начальник турындадыр әле?

Т а л и п. Белгәч, сорашып торма инде, олы апа.

Т а ң с ы л у. Сорашасы, нитәсе юк! Йортка кем хуҗа? Мин! Барысы минеке! Үзем сөйләшеп фатирга да кертәм, өйләндерүен дә үзем өйләндерәм!.. Мөхәммәтхан мине эзләп килгән булган ул! Айсылуга йомыш кушып торамы соң?.. Үзем табам начальникка кыз!

Т а л и п. Нинди изге күңелле икәнсең син, олы апам! Алайса, ашык: нәни апа кыз алып кайтырга китте!

Т а ң с ы л у. Кыз?

Т а л и п. Кыз инде, кыз.

Т а ң с ы л у. Ул кынҗырга ияреп кем килсен?..

Т а л и п. Белгән, күргән кешесе бардыр! Ни әйтсәң дә, сигез ел димче булып йөри.

Т а ң с ы л у. Машина килә түгелме? Туктагыз, туктагыз! (*Чыгып китә.*)

Талип ялгыз.

Т а л и п. Унбиш ел мине өйләндерәм дип саташтылар... Унбиш елга унбиш мең кызның исемен атадылар. Йөзәрләгән Фәридәләр, меңәрләгән Мәдинәләр... Йа Ходай! Каян җибәрдең син безнең авылга яңа начальник? Инде безгә фатирга гына керсен... Мине онытып, аны өйләндерсеннәр! Сак бул, Талип, хәзер... Апаларыңа ярдәм ит!.. Котылдым, котылдым! (*Сикереп тора, ары-бире чаба.*) Тәннәрем җиңеләйде, йөрәк дөп-дөп тибә! Мин өйләнмим икән, хатын-кыз дигән җанварны якын китермим икән! Аларның чыр-чуыннан котылып торам! (*Мәтәлчек ата, сикереп тора. Музыка. Талип үзе җырлый, үзе бии.*)

Кызлар күрсәм, йөрәгем жу-у итә!..
Кызлар көлсә, күңелем шу-у итә!..
Дөньядагы афәт бит ул хатын-кыз!
Бер минут та тора алмый чыр-чусыз...
Тормыштагы кара хәсрәт хатын-кыз,
Бетмәс кайгы, бәла, нәләт хатын-кыз!
Өйләнмәдем, гомер буе өйләнмәм!
Ялгыз башым рәхәтлеккә өйрәнгән.
Кызлар күрсәм, йөрәгем жу-у итә!
Кызлар көлсә, күңелем шу-у итә!..

(*Туктый.*) Шул кыбырсыкларны йолдызларга тыңләп йөргән сантыйларны агач мылтык белән кырып бетерер идем!

Шулай дип куак ягына борылса, анда елмаеп Ф и р д ә в е с басып тора. Ул Талип җырлаганда ук кереп, велосипедын агачка сөяп куеп, бик бирелеп тыңлый һәм карап тора.

Ф и р д ә в е с. Хәерле көн, Талип абый.

Т а л и п. Хәерле кич, Фирдәвес. Хәерле кич...

Ф и р д ә в е с. Кичкә кадәр ерак шул әле, Талип абый.

Т а л и п. Хатын-кыз күргәч, күз алларым караңгылана...

Ф и р д ә в е с. Яшәргәнсең ич син, Талип абый! Ничек шәп биедең... Җырладың...

Т а л и п. Күземә күренде дип кенә уйла!..

Ф и р д ә в е с. Нигә шулкадәр яратмыйсың син хатын-кызны?

Т а л и п. Алар барысы да сиңа охшаганнар.

Ф и р д ә в е с. Миңа?

Т а л и п. Тиешле-тиешсез җиргә борыннарын тыгалар, кирәкмәгәнне ишетергә колакларын сузалар, сул аяктан торалар, абай булмасаң, аяктан егалар... Үзсүзлелек, кирелек, ялган, алдау, гайбәт, күремсезлек хатын-кызда тулып ята!..

Ф и р д ә в е с. Болар барысы да миндә бармы инде?

Т а л и п. Кияүгә чыккач, күрербез. Аңынчы син аларны оста гына яшереп тотасың...

Ф и р д ә в е с. Ха-ха-ха!..

Т а л и п. Авызыңны ерма, ертылмасын.

Ф и р д ә в е с. Сәләхи күзеңә чалынмадымы?

Т а л и п. Әйтәм бит! Теләгең юньледә түгел. Авылның ару егетен җәтмәгә эләктерергә йөрисең икән әле.

Ф и р д ә в е с. Уенны куеп торыйк әле, Талип абый. Күренмәдеме?

Т а л и п. Күренде. Бая ук кайтып китте.

Ф и р д ә в е с. Кайсы юлдан?

Т а л и п. Кемнең кайсы юлдан йөрүен караштырмыйм мин.

Ф и р д ә в е с. Табарбыз, Талип абый. Табарбыз. (*Чыга.*)

Т а л и п. Уф... Ниһаять, дөнья тынычланды... Сәләхиеңне күрми тор әле... Синнән башка да сару кайната торган егет. (*Сузылып ята.*)

Бераздан куыша-куыша Ш ә й х е л белән Б а н у керәләр. Шәйхел Бануны тотып ала, үбә.

Б а н у. Абау, Шәйхел, кеше күрсә!

Ш ә й х е л. Кеше — бүре түгел. Курыкма.

Б а н у. Сәләхи белән шушында очрашырга сүз куештыгызмы?

Ш ә й х е л. Әйе.

Б а н у. Матур урын сайлагансыз, матур!..

Ш ә й х е л. Кыр станын да шушында урнаштырмакчы булабыз.

Б а н у. Алайса, мин дә шушында күчеп киләм! Китапларым, шкафларым белән шушында яши башлыйм.

Ш ә й х е л. Тилекәй... Без өйләнешкәнгә күпме булды? Бер аймы?

Б а н у. Усал... Ай да өч көн!..

Ш ә й х е л. Улларым булса, унбиш яшьтән тыкырдатып өйләндерәм.

Б а н у. Нигә?

Ш ә й х е л. Өйләнгән кешедән дә бәхетлерәк адәм баласы юк икән!..

Б а н у. Шәйхел, күрче, кыңгырау чәчәге! Бәләкәй чакта без аның эченә каен җиләге тутырып ашый идек. (*Чәчәк җыя. Җырлый.*)

Кыңгырау чәчәге, зыйң-зыйң-зыйң...
Җил кагылса тирбәлә.
Үзен терелткән өчен,
Иркәләп искән өчен,
Рәхмәт укый җилләргә.
Кыңгырау чәчәге, зыйң-зыйң-зыйң...
Өзеп бирде сөйгәнем...
Чәчәкләр өзгән өчен,
Кадерлем, дигән өчен,
Кил, үбим, бөрлегәнем...

Б а н у. Шәйхел, кара малай, тот мине!

Ш ә й х е л. Ерак бара алырсыңмы?

Куышалар һәм Талип өстенә барып төшәләр.

Б а н у. Ай!

Ш ә й х е л. Ай түгел, аю.

Т а л и п. Бу дөньяда хатын-кыз аягы җитмәгән берәр тыныч почмак бармы? Кайда ул? Азиядәме, Африкадамы? Күрсәтегез шуны. Мәңге кайтмаска шунда олагам!

Б а н у. Котым калмады.

Ш ә й х е л. Талип абый, нишләп ятасың анда?

Т а л и п. Өйләнү кешенең барлы-юклы акылын да югалта диләр... Дөрес шул! Үбешергә, кочышырга өегездә урын беткәнме?

Б а н у. Кырда үбешү татлырак була, Талип абый!

Ш ә й х е л. Әнә Сәләхи дә килә! (*Кычкыра.*) Сәләхи! Сәләхи! Кара әле, кем килгән?

С ә л ә х и (*керә*). Кем? Бәй, Талип абый? Сиңа яңа өянәк ябышкан диделәр бит.

Т а л и п. Кешедән көләргә генә тугансың син, энем.

С ә л ә х и. Чынлап. Ике мәртәбә өегезгә кагылдым. Көндезләрен сине каядыр югала диләр.

Т а л и п. Нигә эзлисең мине? Минем синдә йомышым юк.

Сәләхи. Синеке юк икән, минеке бар! Монда очравың шәп булды әле. Шәйхел, мин Озын куак юлын урадым. Арыш — менә дигән! Ике-өч көннән өлгерә!..

Шәйхел. Абзаң чәчкән бит аны!

Сәләхи. Талип абыйның да монда булуы әйбәт, утырышыгыз, сөйләшеп алыйк әле бер.

Талип. Ярар, мин ятып кына тыңлармын инде...

Сәләхи. Хәерле булсын...

Бану. Кызык икәнсең син, Талип абый...

Сәләхи. Куеп тор... Шәйхел, машиналарны югары тизлеккә куеп, ныклы график булдырып, арышны ике-өч көндә теземнәргә салырга була дип уйлыйм мин...

Шәйхел. Булыр да, тракторчыларын каян табарсың?.. Үзең беләсең, куллары остаруга күпләр шәһәр ягын каералар...

Сәләхи. Ерып чыгарбыз. Менә Талип абыйны кире алырбыз.

Талип. Шул йомыш белән эзләдеңме мине?

Сәләхи. Унбиш ел трактор йөрткән кеше бит син, Талип абый. Шушы кырларга карап җаның түзеп ятарсыңмы әллә?

Талип. Ай була инде, ятам. Рәхәт!.. Дөньяның җәннәте шушы икән, дим... Ничек моңарчы белмәгәнмен?

Шәйхел. Бригадага кайтыр кебек сөйләнми әле ул.

Талип. Башта адәм хуры ясап куып чыгарыгыз да...

Бану. Сине бит, Талип абый, хезмәт дисциплинасын бозган өчен, су коеныргa да, кибеткә папироска да тракторга утырып йөргән өчен чыгардылар.

Талип. Син, Бану, ычкын моннан! Татарга тылмач кирәкми.

Сәләхи. Куеп тор... Боргаламый гына әйт: бригадага кайтасыңмы? Әллә әрәмтамак булып ятаргамы исәбең?

Талип. Кайтмыйм.

Сәләхи. Нигә?

Шәйхел. Планнар менә шулай чуала инде ул, Сәләхи!

Сәләхи. Бергәләп тотынсак, чуалдырмабыз.

Шәйхел. Былтыргы кебек әйле-шәйле йөрербез дә уракка да вакытында төшә алмабыз... Графигы да бозылыр...

Бану. Шәйхел, нигә бик тиз күңелең төште?

Шәйхел (*Талипка ымлап*). Күрәсез ич... Башкалар да аның кебек кылансалар...

Сәләхи. Талип абый, үзеңне кызганабыз. Адәм көлкесе булып күпме йөрергә мөмкин?

Бану. Эшләмичә ничек ята аласың? Таза, сәламәт кеше...

Т а л и п. Туктыйсыңмы, Бану, бытылдавыңнан, юкмы? (*Сәләхигә.*) Кайтыр идем мин бригадага. Тик бер шартым бар. Шуңа риза булмассыз.

С ә л ә х и. Тыңлап карыйк. (*Фирдәвес керә.*)

Ф и р д ә в е с. Сәлам замандашларга!

С ә л ә х и (*сикереп тора*). Фирдәвес?

Т а л и п. Күрдегезме?

Ф и р д ә в е с. Мин сезне әллә кайчан эзлим инде... Нигә, Талип абый әйтмәдемени?

Т а л и п. Мин сине төшкә керде дип торам. Бу ни, мәйтәм, төшке аштан соң начар төшләр керә башлады әле...

С ә л ә х и. Фирдәвес, утырып тор, әйдә... Менә Талип абыйның сүзе бар.

Т а л и п. Сүзем юк. Сөйләмим.

Ш ә й х е л. Нигә?

Т а л и п. Чит кешеләр арасында телем әйләнми!

Ф и р д ә в е с. Кемнәр алар чит кешеләр?

Т а л и п. Сез. Бану белән икегез!

С ә л ә х и. Фирдәвес... Безнең бүгенге сөйләшү бик әһәмиятле. Сез Бану белән Чуал буена барып каен җиләге ашый торыгыз.

Ф и р д ә в е с. Мин каен җиләге ашарга килмәдем.

С ә л ә х и. Беләм... Хәзер сүзне генә бетерәбез дә без дә сезнең янга барабыз. Көлтә бәйрәмен ничек үткәрү мәсьәләсен бергәләп хәл итәрбез.

Ф ә р д ә в е с. Ә хәзер нәрсә хакында сөйләшмәкче буласыз инде сез?

С ә л ә х и. Җир хакында, Фирдәвес... Өлгереп килгән арыш хакында...

Т а л и п. Ә ул сүзләрнең сезгә,— берегез китапханә эшчесе, икенчегез телефончы,— җирдән җәяүләп качкан кешеләргә ни пычагыма кирәге бар?

Б а н у. Кара инде боларны! Безне чит итәләр бит!

Ф и р д ә в е с. Сез, алайса, безне кеше яккан учакка кызынып йөрүче сөрхәнтәйләр дип кенә уйлыйсыз инде!.. Сез сөрәсез, чәчәсез, урасыз, җыясыз, ә без сезнең уңыштан көлтәләр бәйләп бәйрәм уздыручы гына, шулаймы? Ә минем бүген чын күңелдән сезнең белән бергә буласым килгән иде. Кырда аунап калган ялгыз башакны күрсәм дә җаным әрнүен, әрәм-шәрәм булган борчак-бодайларга карап күңелем кыйналуын сөйләрмен дип уйлаган идем...

С ә л ә х и. Мин каршы түгел, Фирдәвес. Тик беләсең бит... (*Шыпырт.*) Талип абыйны яңадан коллективка тартыйк инде!

Т а л и п. Читтән килеп өйрәтмәсеннәр безне!

Ш ә й х е л. Сөйлисеңме шартыңны син, юкмы?

Т а л и п. Шартым шул: әгәр дә мәгәр мин әйләнеп кайтсам... Сез, егетләр, Талип абыегызның ничек эшләвен беләсез! Тәүлегенә кырык сигез сәгать трактордан төшми ул!..

Б а н у. Шартыңны әйт син, Талип абый.

Т а л и п. Шарт бер генә: эш арасына хатын-кызны кыстырмыйсыз! Станда да эзләре булмасын аларның! Менә шул...

Ф и р д ә в е с. Алайса, безне куасыз инде?

С ә л ә х и. Фирдәвес, нигә андый каты сүз?.. (*Шыпырт.*) Безгә бүген Талип абыйны бөгәргә кирәк!

Т а л и п. Карап торма әле чит күзләрең белән!

Ф и р д ә в е с. Яхшы... Бану! Китәбез, әйдә...

Ш ә й х е л. Бану беркая да китми!

Б а н у. Фирдәвес китә икән, мин дә калмыйм! Без шушы колхоз кешеләре түгелме? Их, сез...

Ш ә й х е л. Ничек? Китәсең?

Т а л и п. Ха-ха-ха!

Ф и р д ә в е с. Сәләхи, күзләрең ачылмаган икән әле синең! Акны карадан аера белмисең икән... Безнең моңарчы сөйләшеп йөргәннәр берсе дә файдага булмаган!

Т а л и п. Ха-ха-ха!

Ш ә й х е л. Нигә ярыласың?

Т а л и п. Кайтам тракторга, Сәләхи!

С ә л ә х и . Фирдәвес, ашыкма!

Б а н у. Киттек булгач, киттек!.. Кыр хуҗалары...

Фирдәвес белән Бану чыгалар.

Ш ә й х е л. Мин Банудан калмыйм. (*Чыга.*)

С ә л ә х и. Талип абый, Шәйхел! Кырларны карап, график төзергә кирәк! Шәйхел!!! Фирдәвес...

Т а л и п. Ха-ха-ха!

С ә л ә х и. Талип абый... График мәсьәләсен иртәгәдән дә соңга калмый сөйләшербез! Очрашырбыз әле! (*Чыгып йөгерә.*)

Т а л и п. Ха-ха-ха! Тәннәрем җиңеләеп тора. Әллә нинди көн булды әле бу... (*Җаймәсен алып чыгып китә.*) Ял урынын алыштырырга туры килә!

Бераздан ат туктаган тавыш килә. М ә ү л а н җ а н керә. Бәләкәй генә, какча кеше. Аның артыннан Х ә й б у ш ияргән.

Х ә й б у ш. Мәүләнҗан абый, менә безнең колхоз басулары. Әнә безнең авыл... Әнә Чуал елгасы... Ярларында каен җиләге, искиткеч.

Мәүланҗан. Географияне шәп beләсең. Әйбәт... Ә бу нинди кешеләр?

Хәйбуш. Ә, бу безнең Сәләхи абый инде. Тракторчы. Безнең күрше. Гармуны да бар дип сөйләгән идемме?

Мәүланҗан. Аннан алда юргалап баручы кызны кем дип белик?

Хәйбуш. Фирдәвес лә ул!

Мәүланҗан. Шулмы инде безнең телефончы?

Хәйбуш. Үзе.

Мәүланҗан. Хәтәр атлап йөри икән, хәтәр... Ул Фирдәвес дигәнең кара күзлеме?

Хәйбуш. Кара бугай. Бәбәген бер акайтып җибәрсә...

Мәүланҗан. Кызык, бик кызык... Үзе кара күзле, үзе минем конторада эшли... Афзал абый ишетсә, ни әйтер иде икән? Кызык...

Хәйбуш. Мәүланҗан абый, кигәвеннең бик азган чагы!

Мәүланҗан. Ашыкма, кабаланма, Хәйбуш. Урыны бик шәп икән! Шушыннан баганаларны саный башларбыз.

Хәйбуш. Тиле кеше әйткәндәй, ул телефон баганаларын нигә санарга инде?

Мәүланҗан. Бөтен нәрсә ныклы тәртиптә, санаулы булырга тиеш.

Хәйбуш. Санамасаң да, урлаучы юк бит аны. Багана тек багана. Тик тора.

Мәүланҗан. Аңгыралыгыңны алай тиз күрсәтмә. Багана башына кара.

Хәйбуш. Карга кунганмы әллә?

Мәүланҗан. Йә, ни күрәсең анда?

Хәйбуш. Ни дип әйтергә дә оят инде...

Мәүланҗан. Оялу — кызлар гадәте.

Хәйбуш. Каргалар кунганнар да...

Мәүланҗан. Аңгыра булу өстенә, сукыр да икәнсең, Хәйбуш.

Хәйбуш. Ә син ни күрәсең, Мәүланҗан абый?

Мәүланҗан. Тимерчыбыклар күрәм.

Хәйбуш. Әй, чыбыкны мин дә күрәм лә аны!

Мәүланҗан. Менә шул чыбыкларның кая барганын беләсеңме?

Хәйбуш. Белмичә. Районга бара.

Мәүланҗан. Аннан кая?

Хәйбуш. Казангадыр инде.

Мәүланҗан. Бөтенләй үк караңгы түгел икәнсең әле. Казанга китә аның бер очы, Казанга. О, Казан! (*Пауза.*) Шул чыбыкның бу очында кем утыра?

Х ә й б у ш. Фирдәвес.

М ә ү л а н җ а н. Хәзер мин утырачакмын! Мин! Ә теге очында кем? Акылың бәләкәй шул, егет, аңламыйсың... Теге очында Афзал абыең утыра. Кайгырма, кеше итәм мин сине!

Х ә й б у ш. Син бит машина алам дисең.

М ә ү л а н җ а н. Шоферлыкка укытырмын.

Х ә й б у ш. Председатель җибәрми.

М ә ү л а н җ а н. Җибәрер! Әллә син мине чут салып утырырга гына начальник булып килә дисеңме? Күр әле бу буй-сынны!

Х ә й б у ш. Кыяфәт бар синдә, Мәүланҗан абый!

М ә ү л а н җ а н. Күкрәккә кара син, күкрәккә! Үзе үк орден сорап тора.

Х ә й б у ш. Шәп! (*Кесәсеннән папирос чыгарып тарта башлый.*)

М ә ү л а н җ а н. Әллә син тартасың да?

Х ә й б у ш. Суыргалыйм.

М ә ү л а н җ а н. Моннан болай минем янда шырпы юанлыгы папиросыңны күрсәтмә. «Казбек» көйрәтеп җибәр.

Х ә й б у ш. «Казбек» тагын да шәбрәк!

М ә ү л а н җ а н(*тәмәке кабыза*). Челем алып җибәрәм әле, челем! Мыек үстерәм! Менә мондый итеп. (*Күрсәтә.*)

Х ә й б у ш. Ә мыек нигә?

М ә ү л а н җ а н. Мыекта, энем, җегәр, мыекта! Ирлек шунда! Мыек белән әллә кайларда баш булып утырган кешеләрне беләм мин!

Х ә й б у ш. Мәүланҗан абый, син шигырьчеме әллә?

М ә ү л а н җ а н. Нигә юк белән баш черетергә? Дус бар минем. Тургайсин. Шагыйрь!.. Вәт кеше... Хикмәт шагыйрь булудамыни?

Х ә й б у ш. Хикмәт нәрсәдә соң?

М ә ү л а н җ а н. Хикмәтнең башы авылда. Авылның өстен аска әйләндерергә кирәк: надан ятасыз бит. Иген игә белмисез. Тып-тын. Бака күле кебек кайнап торсын ул авыл. Менә шулай кайнатырга килдем мин аны!

Х ә й б у ш. Бака күле кебек?

М ә ү л а н җ а н. Олысы-кечесе: «Ишеттегезме, почтага яңа начальник килгән!.. Ул шулай эшләгән, болай кушкан»,— дип шаккатып сөйләшә башласын! Югыйсә әллә шушы авылга почта начальнигы булып килер идемме мин?.. Шул шатлыклы хәбәрләр менә бу чыбыклар буйлап әллә кайларга барып ирешсен. Аннары Мәүланҗан абыең... нишләргә белер! Шунда хикмәтнең дәвамы булачак! Дәвамы!

Хәйбуш. Бездә сабан туенда гына халык кайнап тора. Аннары...

Мәүланҗан. Ашыкма, туйларны да ясарбыз. Туйлар качмас. Ә хәзер... Әйдә кузгалдык. Атыңны үкертеп ку. Авылга дулап барып керик. Кырда барганда җырла!

Хәйбуш. Кайсысын җырлыйм, Мәүланҗан абый?

Мәүланҗан. Кара күзләре белән, дип җырла әле.

Хәйбуш. Ә баганалар?

Мәүланҗан. Аларны санарга өлгерербез!

Хәйбуш (*җырлый*).

Карар инде, карар инде
Кара күзләре белән.
Өзәр инде үзәгемне
Матур сүзләре белән.

Шушы ярыймы?

Мәүланҗан. Катырак җырла. Мәүланҗан кайта дип әллә каян ишетеп торсыннар. Иртәгә үк дугаңа пар кыңгырау так. Кыңгыраусыз почта ташыйлармы? Очтык!

Арба тавышы. Сызгырып, җырлап чабып китәләр. Айсылу белән Чәчкә керәләр.

Айсылу. Менә, кызым Чәчкә, кайтып та җиттек. Бер атласак, ике сикерсәк, авылда ук булабыз.

Чәчкә. Айсылу апа, ул мине яратыр микән?

Айсылу. Яратмаган кая! Үзең чибәр, үзең калада яшәгән...

Чәчкә. Әгәр ул бик ямьсез булса?

Айсылу. Ирнең чибәре-ямьсезе булмый аның. Алар бар да матур.

Чәчкә. Әгәр ул чибәр дә булып, мине яратса...

Айсылу. Тутаң тотынса, булдыра инде ул! Әйдә, тизрәк атладык. Бүген күзенә бик күренеп йөрмәсәң дә ярар.

Чәчкә. Анысын чамаларбыз инде. Тәҗрибә юк түгел...

Чыгалар. Каударланып, Таңсылу керә.

Таңсылу. Кара син аны... Менә әкәмәт! Талип та үз гомерендә дөресен әйтер икән: теге кынҗыр кыз алып кайтып килә ләбаса!.. Юк, юк... Йортка мин хуҗа! Мин өйләндерәм аны!.. Гөлләр кызым килеп кенә җитсен... Юк, кынҗыр, начальникны сиңа биреп тору юк. Минеке ул! Минеке!.. (*Йөгереп чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл почта бүлекчәсе. Начальник бүлмәсе. Гади өстәл. Өстәлдә кәгазьләр. Өстәл янында ук аралык башлана. Аралыкта — тәрәзәчекләр. Стенада СССР картасы, вак-төяк рәсемнәр. Су багы, какшаган аяклы диван. Каршыда киң ишек. Ишеккә зур итеп: «Чит кешеләргә керү тыела» дип язылган. Пәрдә ачылганда, ул ишек ачык. Анда телефон аппараты янында Фирдәвес утыра. Начальник ягында ике тәрәзә. Шуларның берсе ачык. Ачык тәрәзәдә Сәләхи. Ул Фирдәвеснең эшләгәнен карап тора.

Сәләхи. Фирдәвес!

Фирдәвес. Ишетмим...

Сәләхи. Юкка рәнҗедең син кичә! Талип абыйны үз арабызга кайтару безгә бик кирәк иде. Әрәм булып ята бит. Шәп тракторчы... Арада ят кеше булганда, аның тәртә сындырырга яратуын беләсең ич!

Фирдәвес. Ах, шулаймы? Ят кеше!

Сәләхи. Ну, безнең белән эшләмәүче кеше.

Фирдәвес. Ишетмим.

Сәләхи. Синең янга керимме?

Фирдәвес. Укый-яза беләсеңме?

Сәләхи. Азрак ермачлыйм.

Фирдәвес. Алайса, ишектәге язуны укы да бу тирәдә күп чуалма. (*Шап иттереп ишекне яба. «Чит кешеләргә керү тыела» дигән язу күренеп кала.*)

Сәләхи. Алай... Чит кеше!.. Кара аны, кызый! Үкенерлек булмасын! (*Музыка. Сәләхи җырлый.*)

Агыйделнең буйларын
Сандал киеп буйлама.
Үзең ничек, мин дә шулай,
Ялыныр дип уйлама.

(*Кырт борылып чыгып китә.*)

Фирдәвес сак кына ишекне ача. Карый. Ишекне яба, Мәүланҗан белән Талип керәләр.

Мәүланҗан. Ир кеше — горур кеше, иптәш кем, Талип. Сүз — атылган ук. Башка квартирага күчәм!

Талип. Үпкәләмәгез берлеккә шул карчыкларга!

Мәүланҗан. Китапханәдә утырып кайттым... Ял итәргә кирәк! Китап — белем диңгезе. Диңгездә йөзеп арылган... Ә өйдә ниндидер шикле ыгы-зыгы.

Талип. Кунак килеп төшкән көнне шулай була ул!

Мәүланҗан. Шәп кунак! Йомырка тәбәсе — шыр тоз. Тавык шулпасында иткә караганда борыч күбрәк!

Талип. Хата киткән! Тавыгын нәни апа пешергән, тәбәсен олы апа кыздырган. Нәни апа шулпасына борычны олы апа, олы апа тәбәсенә тозны нәни апа салган.

М ә ү л а н җ а н. Ә мин шуны ашарга тиешме?

Т а л и п. Апаларның синдәй чибәр егетне кунак иткәннәре юк иде шул. Каушап киткәннәр...

М ә ү л а н җ а н(*ишекне ачып Фирдәвескә эндәшә*). Йә, Фирдәвес иптәш, безнең эшләр барамы? Яхшы, яхшы!..

Т а л и п. Йә, ничек, Мәүланҗан туган. Гафу итәсезме карчыкларны?

М ә ү л а н җ а н. Һәркем үзенә йөкләнгән эшне менә дигән итеп башкарырга тиеш! Һәркем тормышта үз урынын табарга бурычлы.

Т а л и п. Ансат түгел шул аны табу. Безнең авыл халкы надан да инде ул, кара да...

М ә ү л а н җ а н. Теле каты авыл халкының!

Т а л и п. Телләре каты булса да, тел төпләре йомшак аларның. Менә минем апалар да син дип үлеп торалар инде. Бөтерелеп йөриләр бит. Ике орчык кебек!

М ә ү л а н җ а н. Син тракторчы, алайса?

Т а л и п. Тракторчы кисәге... Менә уракка төшәргә диләр. Тын алырга да ирек бирмиләр! Һавалар да әллә нишләде. Уракка төшүгә, күкнең төбе иләкләнә. Дөнья матур ясалмаган!

М ә ү л а н җ а н. Нәрсә ул урак? Комбайнга утыр да тик боргала шөрепләрен. Үзе ура, үзе суга...

Т а л и п. Үзе җилгәрә дә әле.

М ә ү л а н җ а н. Кырның бер башыннан керәсез дә икенче башыннан чыгасыз. Бетте-китте! Син менә безнең эшне уйлап кара! Баш эшен... Син тракторчы инде, алайса?

Т а л и п (*шикләнеп*). Әйе.

М ә ү л а н җ а н. Атаклысымы? Мондые гынамы?

Т а л и п. Белмим тагын...

М ә ү л а н җ а н. Ярар, ярар, ярдәм итәрбез... Атаклысы булырсың!

Т а л и п. Кайтып карчыкларны сөендерим әле.

М ә ү л а н җ а н. Ярар, син дигәнчә булсын! Синең кебек алдынгы, эшчән колхозчының сүзен аяк астына салып таптамыйм. Күреп торам: син үзеңнең тырыш, атаклы тракторчы икәнлегеңне тыйнаклыгын аркасында гына яшердең!

Талип чыгып китә.

(*Мәүланҗан канәгатьләнеп бүлмәсен карап чыга. СССР картасы каршысына басып уйланып тора. Тиз генә Фирдәвес ягының ишеген ача.*) Йә, Фирдәвес иптәш, минем отчет ничегрәк? Очына чыгып буламы?

Ф и р д ә в е с (*бу якка чыгып*). Менә.

Мәүлан җан. Нәрсә бу?

Фирдәвес. Отчет. Төнәген кич үк төземдем мин аны.

Мәүлан җан(*өстәл янына утырып, бик аптырап*). Төнәген кич? Ничек алай бик тиз? Отчет һәм бер кичтә?..

Фирдәвес. Эшебез дә зур түгел бит. Бүлекчәбез кечкенә.

Мәүлан җан. Ничек алай зур түгел! Җиде мең багана гына бар! (*Кәгазьгә карап.*) Зур түгел, ә сыйфырларны тезгәнсең генә! Ферма тавыклары чүпләп бетерерлек түгел.

Хәйбуш (*ишектән башын сузып*). Мәүланҗан абый, монда Таңсылу әби килгән. Керсенме?

Мәүлан җан. Монда начальниклары отчет белән утыра!

Фирдәвес. Кулыгызны куегыз да, бүген җибәрергә кирәк.

Мәүлан җан. Алай ансат булгач, миңа кадәр эшләгән иптәш ник җибәрмәгән?

Фирдәвес. Өлгермәде ул. Егете армиядә иде. Офицер. Үтеп барышлый гына керде, алар өйләнештеләр...

Мәүлан җан. Син монда бер хата да юк дип ышанасыңмы инде?

Фирдәвес. Тиене тиенгә туры килгән.

Мәүлан җан (*бик шикле күз белән карана*). Бу ни бу?

Фирдәвес. Тугызлы ул.

Мәүлан җан. Тугызлыңның койрыгын болай туры итмә. Песи койрыгы кебек кәкрәеп торсын... Тугызлы нәрсәне аңлата?

Фирдәвес. Газета-журналларга язылу.

Мәүлан җан. Туксан ике процент? Менә ялгышың кайда бит!

Фирдәвес. Ялгыш түгел ул, үтәлеш шулай!

Мәүлан җан. Нигә туксан ике, ә йөз илле түгел?

Фирдәвес. Районнан ялгыш план җибәргәннәр, Мәүләнҗан абый.

Мәүлан җан. Район бервакытта да ялгышмый, Фирдәвес иптәш. (*Барып тәрәзәләрне ябып килә.*)

Фирдәвес (*кәгазьләр чыгара*). Менә карагыз. Ярты еллык планга биш данә «Мамык игү» журналы керткәннәр. Ике данә техник журнал өстәгәннәр.

Мәүлан җан. Ах, син техникага да каршы икәнсең әле!

Фирдәвес. Техник журналлар инглиз телендә, Мәүланҗан абый. (*Фирдәвес сүз арасында телефонга да барып килгәли.*)

Мәүлан җан. Ташлап тор телефоныңны. Көтәрләр!

Ф и р д ә в е с. Имзагызны менә монда куясы.

М ә ү л а н җ а н. Шушындый отчетка кул куяргамы?

Х ә й б у ш (*тәрәзәне ачып*). Таңсылу әби, боткам көя иде, ди. Керсенме?

М ә ү л а н җ а н. Песи ярларлык ботгасы кадалып киткән! Тыныч кына көйдерсеннәр!.. Хәйбуш, почтага беркемне якын җибәрмә: мөһим эш белән утырам!

Х ә й б у ш. Афзал абый килсә дә кертмәскәме?

М ә ү л а н җ а н. Аны да! Әй, юк, килә күрмәсен! Менә мондый хурлыклы отчетны күрә күрмәсен!

Хәйбуш югала.

Ярамый, Фирдәвес иптәш, үз җүләрлегебезгә үзебез пичәт сугып утырмыйк.

Ф и р д ә в е с. Монда безнең гаеп юк. Укыла торган газета-журналларга чикләү бирәләр, кирәге юкларны йөк итеп тутыралар.

М ә ү л а н җ а н. Район хакында андый сәламәт булмаган фикер йөртүеңне бетер.

Ф и р д ә в е с. Уйларга иренәләр. Аннан-моннан сыздин-быздин, һәм план әзер була!

М ә ү л а н җ а н (*шелтәләп*). Фирдәвес иптәш, мин сине бөтенләй аңламыйм?!

Ф и р д ә в е с. Ялгыш икәнен үзегез дә күрәсез ич.

М ә ү л а н җ а н. Күрмим.

Ф и р д ә в е с. Ә мин күрәм.

М ә ү л а н җ а н. Син дә күрмисең! Бәлки, район сезнең колхозда мамык чәчүне планлаштыра торгандыр, ә?!

Ф и р д ә в е с. Мамыкка аңа җылылык кирәк, кояш кирәк!

М ә ү л а н җ а н. Дус бар минем. Тургайсин. Шагыйрь! Шул әйткәндәй, безнең илдә иң якты, иң җылы кояш, Фирдәвес иптәш!.. Инглизчә! Безнең халык чит телләр өйрәнергә сусап тора. Оештырырга кирәк. Мәсәлән, нигә сиңа инглиз телен өйрәнмәскә? Әпе-чәпе килеп тик сөйләшеп йөр аннары урамда!

Ф и р д ә в е с. Безгә техникумда немец теле өйрәтәләр.

М ә ү л а н җ а н. Син техникумда да укыйсыңмыни әле?

Ф и р д ә в е с. Читтән торып.

М ә ү л а н җ а н. Алай бик шәп укыгач, тиз генә отчетыңны төзәт тә дөресен яз.

Ф и р д ә в е с. Дөреслек бер генә була бит ул, Мәүланҗан абый.

М ә ү л а н җ а н. Синең дөреслегең чалыш. Мин аны турылыйм.

Ф и р д ә в е с. Телефончы булып эшли-эшли ялган от-

четлар тапшырып туйдым инде мин. Аларның вакыты үтте хәзер, Мәүланҗан абый. Сезгә дә эшне ялган белән башлап җибәрергә киңәш итмим.

Мәүланҗан. «Мамык игү» журналын таратырга тырышу ялганмы синеңчә? Син бит авыл хуҗалыгында бернәрсә дә аңламыйсың! Шул шул... Инглиз журналларын да алдырырга! Безнең төп бурыч — халык арасына аң-белем тарату. Мин шулай аңлыйм. Иң мөһиме — культура! Отчет баргалаганчы ул журналларны таратып та бетерәбез без, Фирдәвес иптәш! Башлап син бер журналга язылаcың, аннары мин... Тукта, хакы ничек икән? Әһе, әһе, алты сум... миңа, начальник кешегә, язылу уңайсызрак булыр. Килде дә үз кулына барын ала дип әйтерләр!.. Менә Хәйбуш берне ала! Әй Хәйбуш!

Хәйбуш (*тәрәзәдә*). Ат әзер, Мәүланҗан абый. Җигелгән.

Мәүланҗан. Хәйбуш, синең китап укыганың бармы?

Хәйбуш. Минем үз китапханәмдә генә өч йөз китап бар.

Мәүланҗан. Хатаңны күрдеңме, Фирдәвес иптәш?.. Кемнәрнең юлын кисәргә торасың бит! Хәзер үк бер данә инглиз журналы яздыр үзенә. Хезмәт хакыннан тотып кал.

Хәйбуш. Мин бит аларча белмим.

Мәүланҗан. Татарчасын да белеп тумагансың. Өйрәнерсең... Фирдәвес иптәш, ал каләм, яз!

Фирдәвес. Нәрсә языйм?

Мәүланҗан. Инглиз телендә тагын ун данә журнал сора!

Фирдәвес. Кая куярбыз аларны?

Мәүланҗан. Инглиз теле түгәрәге оештырам.

Фирдәвес. Сез инглизчә дә беләсезмени?

Мәүланҗан. Иң мөһиме — оештыру. Тел белүче табылыр, Хәйбуш! Хәзер үк китапханәгә йөгер! Ун данә... Бер дә ким түгел!

Хәйбуш. Хәзер! (*Тәрәзәдә югала да ишектән Таңсылуны ияртеп керә.*) Менә Таңсылу әби боткам әрәм булды дип пошынып утыра. (*Чыгып китә.*)

Мәүланҗан. Таңсылу әби, бик вакытлы килдең! Син журнал укырга яратасың бит?

Таңсылу. Журнал? Минме?

Мәүланҗан. Күрдеңме, Фирдәвес иптәш! Хәзер үк бер данә «Мамык игү» яздыр үзенә.

Таңсылу. Нинди мамык?

Мәүланҗан. Мамык төсле мамык. Бишмәт эченә сала торган. Җил көнне колагыңа да тыгып йөрисеңдер әле.

Ф и р д ә в е с. Таңсылу әби, Мәуланҗан абый шаярта ул.

М ә ү л а н җ а н. Фирдәвес иптәш, шалтыраталар. Чыгып торыгыз әле!

Ф и р д ә в е с. Минем дә тыңлыйсым килә.

М ә ү л а н җ а н. Таңсылу әбинең үзенә генә әйтәсе сүзем бар.

Фирдәвес үз бүлмәсенә керә, ишекне яба.

М ә ү л а н җ а н. Таңсылу әби, беләсеңме син кем?

Т а ң с ы л у. Ай Аллам! Берәр хата кылдыммы әллә?

М ә ү л а н җ а н. Син кем һәм кем булырга җаең бар!

Т а ң с ы л у. Мөгаен, шулайдыр...

М ә ү л а н җ а н. Син бүгенге авылның аңлы, акыллы карчыгы булырга тиеш!.. Йөгереп кенә бар да күкәй саткан акчаңнан алты тәңкәсен әләктереп монда кил!

Т а ң с ы л у. Нигә алты тәңкә?

М ә ү л а н җ а н. Журналга язылам дидең ич.

Т а ң с ы л у. Алайса, син миңа ачуланмыйсың инде?

М ә ү л а н җ а н. Нәрсә өчен?

Т а ң с ы л у. Тәбәм тозлырак булган шул...

М ә ү л а н җ а н. Синдәй алдынгы карчык белән тәбә өчен ачуланышып торалармы?

Т а ң с ы л у. Шулай, бәбкәм, шулай.

М ә ү л а н җ а н. Әле тәбәсен дә ашарбыз, бәлешен дә. Гомер алда әле... Кем белсен... Бәлки, өйләнеп тә җибәрермен. Берәр чибәр кызны димләп тә куярсың... Бар, Таңсылу әби, акчаңны алып кил.

Т а ң с ы л у. Йөгерәм, бәбкәм, йөгерәм! Димләрсең дисеңме?

М ә ү л а н җ а н. Димләрсең, димләрсең!.. Алты тәңкә, онытма. Авылыгызда кара күзле кызлар бармы соң?

Т а ң с ы л у. Булмаган кая... Хәзер... Ботканы чебешләргә салам, кысыр тавыгымны тәгәрәтәм! (*Чыгып китә.*)

М ә ү л а н җ а н. Бер данәсе булды... Кая соң бу китапханәче?

Г ө л л ә р керә.

Г ө л л ә р. Керергә ярыймы?

М ә ү л а н җ а н. Рәхим итегез.

Г ө л л ә р. Исәнмесез, абый.

М ә ү л а н җ а н. Исәнмесез. Узыгыз. Мин шушы бүлекнең начальнигы.

Г ө л л ә р. Мине Таңсылу әби җибәрде. Бар, ди, уңайсызланма, ди.

М ә ү л а н җ а н. Таңсылу әби? Менә нинди алдынгы карчык булып чыкты ул!

Г ө л л ә р. Мин аны бик яратам. Минем әнкәй мәрхүмә белән ахирәт дус булганнар алар... Менә кичә үзләренә кунакка чакырды...

М ә ү л а н җ а н. Сез язылырга каршы түгел, алайса?

Г ө л л ә р. Бик тиз була ич!..

М ә ү л а н җ а н. Таңсылу әби аңлатып бетермәдемени?

Г ө л л ә р. Ул аңлатты! Бүген төн йокламадык...

М ә ү л а н җ а н. Алайса, кыюрак, кыюрак! Мондарак кил!

Г ө л л ә р. Анда ук керергә уңайсыз бит, абый... Кешефәлән күрер...

М ә ү л а н җ а н. Үзең чибәр генә икәнсең, күзләрең дә кара икән!..

Г ө л л ә р. Абый, алай ук оялтмагыз инде...

М ә ү л а н җ а н. Син акчаңны алып килдеңме соң?

Г ө л л ә р. Юк.

М ә ү л а н җ а н. Менә шушында кулыңны куй да алты тәңкә акчага йөгер!

Г ө л л ә р. Кулымны?

М ә ү л а н җ а н. «Мамык игү» дигән яңа журнал чыга башлаган. Халык талашып шуңа язылa.

Г ө л л ә р. Куям, абый, кулымны куям... Мин Таңсылу әби әйткәнгә генә...

М ә ү л а н җ а н. Кергәләп йөр. Күргән-белгәннәреңне монда җибәр!

Г ө л л ә р. Хушыгыз, абый.

М ә ү л а н җ а н. Исән бул, чибәркәй. (*Гөлләр чыга.*)

**Алъяпкычын да салырга онытkan А й с ы л у керә. Тыны беткән, кабаланган.**

А й с ы л у. Мәүланҗан балакаем, миңа да теге ягымлы сүзләрне әйт әле!

М ә ү л а н җ а н. Ягымлы сүзләр миндә җитәрлек.

А й с ы л у. Тавык шулпасы өчен кинә сакламыйм, диген.

М ә ү л а н җ а н. Әллә кайчан оныттым.

А й с ы л у. Бергә-бергә торырбыз, диген...

М ә ү л а н җ а н. Түзәрбез, әмма торырбыз...

А й с ы л у. Кыз димләрсең, диген.

М ә ү л а н җ а н. Кыз димләү асыл сыйфат.

А й с ы л у. Мин ике журналга язылам. Менә унике тәңкә акча алып килдем.

М ә ү л а н җ а н. Менә бусы сүз! Мең яшә! (*Яза.*) Мә квитанцияләрен. Рәхәтлән укып!

А й с ы л у. Ашка соңга калма! (*Чыга.*)

М ә ү л а н җ а н (*кулларын уып, бүлмә буйлап йөри*).

Мәүланҗанның эшләр түгәрәк!
Әйдә узсын әле түргәрәк!

(*Өстәлен карта астына ук илтеп куя.*)

Ч ә ч к ә керә.

Ч ә ч к ә. Менә мин дә килдем.

М ә ү л а н җ а н. Минем янгадыр инде!

Ч ә ч к ә. Исемем Чәчкә.

М ә ү л а н җ а н. Искиткеч матур исем, Чәчкә-гөл!

Ч ә ч к ә. Гөлләр түгел, Чәчкә! Мине Айсылу апа җибәрде.

М ә ү л а н җ а н. Бу апалар хакында ни әйтерсең?!

Ч ә ч к ә. Оялып торма, ди. Бар, кер, ди. Нигә оялып торыйм мин? Гарипме, кешегә күренерлек җирем юкмы?

М ә ү л а н җ а н. Күзләрең кара икән бит, сылу кыз!

Ч ә ч к ә. Әнкәй әйтә, тугач унбер ай туктаусыз җыладың, шунда күзең каралып калды, ди. Югыйсә нәселебездә кара күзле кеше юк...

М ә ү л а н җ а н. Кара күз — бәхетле күз!

Ч ә ч к ә. Мин ике ел шәһәрдә тордым!.. Авылга кайткан идем, китәсем килми. Авыл халкы шундый кунакчыл. Мин мул торырга, итне-майны ике куллап орырга яратам.

М ә ү л а н җ а н. Хәзер иң мөһиме: кешенең аң-белемен күтәрү. Аң-белемнең беренче билгесе «Мамык игү» дигән журнал уку.

Ч ә ч к ә. Рәсемлеме ул?

М ә ү л а н җ а н. Бит саен өчәр рәсем.

Ч ә ч к ә. Рәсемле журналларны яратып укыйм мин. Модалар журналын...

М ә ү л а н җ а н. Акчаңны алып ук килдеңме?

Ч ә ч к ә. Акчасын Айсылу апа түләрмен диде. Кулымны гына куям да...

М ә ү л а н җ а н. Менә монда... Кулларың, бармакларың...

Ч ә ч к ә. Мин кичкә табарак тагын керермен әле...

М ә ү л а н җ а н. Ишек һәрвакыт ачык!

Чәчкә чыга. Ф и р д ә в е с үз бүлмәсеннән монда керә.

Ф и р д ә в е с. Мәүланҗан абый... (*Бүлмәдәге үзгәрешләрне күрә.*) Сез монда тик ятмыйсыз икән!

М ә ү л а н җ а н. Тик ятар өчен килмәдек! Менә.

Ф и р д ә в е с. Нәрсә?

М ә ү л а н җ а н. Журналларны урнаштырып бетердем... Китапханәче белән сөйләшәсе калды. Хәйбуш! Хәйбуш!

Ф и р д ә в е с. Кайтып җитмәгәндер әле.

М ә ү л а н җ а н. Отчетны дөресләп яз.

Ф и р д ә в е с. Дөреслек бер генә була бит ул. Әйттем ич инде.

М ә ү л а н җ а н. Язарсың! Уйнама! Китапханәгә дә тондырсам... Кайда соң ул үзе! (*Чыгып китә.*)

Фирдәвес ялгыз.

Ф и р д ә в е с. Нәрсә тели бу кеше? Нигә безнең авылга килгән ул?.. Кызык... (*Бүлмә ишеген ачык калдырып, телефон аппараты янына утыра, җырлый.*)

Баганадан баганага
Телефон чыбыклары,
Уйлый башласаң, дөньяның
Күп инде кызыклары.
Алло-алло, кем кирәк?
Алып бирәм Тауларны.
Тоташтырам, кавыштырам
Җаны сөйгән ярларны...
Алло-алло, буш түгел,
Су тутырып куелган...

(*Урыныннан тора, бу якка чыга. Тәрәзәләрне киң итеп ача. Түше белән тәрәзә төбенә ятып бөтенләй башка көйгә җырын бетерә.*)

Әллә гашыйк булдым инде,
Һич китмисең уемнан.

М ә ү л а н җ а н белән Б а н у керәләр.

М ә ү л а н җ а н. Фирдәвес иптәш! Берәрсе ишетсә!

Ф и р д ә в е с. Бик әшәке җырладыммы әллә?

М ә ү л а н җ а н. Син бит җаваплы урында эшләүче кеше!

Б а н у. Саумы, Фирдәвес.

Ф и р д ә в е с. Исәнме, Бану. Ә тышта кояш... Бар җирдә кояш!

М ә ү л а н җ а н. Кояшның сиңа ни хаҗәте бар?

Ф и р д ә в е с. Кояш игеннәрне пешерә хәзер.

М ә ү л а н җ а н. Тотасыз да иген, иген дип сөрән саласыз. Безнең игеннән болайрак мөһим эшләребез күп... Барыгыз, Фирдәвес иптәш, эшегездә булыгыз.

Ф и р д ә в е с. Мөһим сүзләрегез бармы? Алайса, чыгам... (*Бүлмәсенә керә.*)

М ә ү л а н җ а н. Кәеф-хатирәләр кайсы тирәдә, Бану иптәш. Ничек йокладыгыз?

Б а н у. Рәхмәт... Тик моннан болай мине өйгә озата бармагыз.

М ә ү л а н җ а н. Ирегез көнләштеме?

Б а н у. Юк, юк! Ул бер сүз дә әйтмәде... Гомумән, бу хакта сүзне озайтмыйк без.

М ә ү л а н җ а н. Нигә озайтмаска?! Әгәр авылда шундый искелек калдыклары бар икән, сезнең белән мин дә сөйләшмәгәч, аны кемгә тапшырабыз? Сөйләшергә дә, көрәшергә дә кирәк!

Б а н у. Анысы шулай...

М ә ү л а н җ а н. Безгә комачаулаучы һәр искелекне җимереп атыйк, ди минем дус. Тургайсин. Шагыйрь!

Б а н у. Алай куркырлык ук нәрсәләр күрмим мин үзебездә...

М ә ү л а н җ а н. Күрергә кирәк... Үзем дә менә, ыргылып, искелек белән көрәшкә чыгасым килә. Халык алдында докладлар, беседалар үткәрергә телим. Йөзсеннәр аң-белем диңгезендә! Һәр йортка газета! Һәр кешегә журнал!

Б а н у. Боларны ишетү бик күңелле, Мәүланҗан абый.

М ә ү л а н җ а н. Тик менә вакыт ягы койтырак... Отчет әзерлисе бар... Эшне тәртипкә салырга кирәк... Мин гомуми ягын билгеләсәм, сез докладны конкрет әйберләр белән баетып, язып чыксагыз...

Б а н у (*аптырап*). Нинди темага доклад ясарга уйлыйсыз соң сез?

М ә ү л а н җ а н. Иң әһәмиятле темага!

Б а н у. Шулай да?

М ә ү л а н җ а н. Сез һәм без — бергә барабыз. Шуңа күрә безнең темалар да бер бит инде...

Б а н у. Авыл өчен иң әһәмиятлесе күбрәк иген үстерү, ит җитештерү...

М ә ү л а н җ а н. Ничек иген? Ягъни болай, теге арыш һәм борчак?..

Б а н у. Аларны үстерү бик кыен бит, Мәүланҗан абый...

М ә ү л а н җ а н. Арыш, бодай... Җирен трактор сөрә, яңгырын болыт китерә, җылысын кояш бирә... Һем, һем... Шул арыш арасына Кореяны кертеп булмыймы?

Б а н у. Ничек арыш арасына?

М ә ү л а н җ а н. Бергә бәйләп, менә шулай укмаштырып! (*Күрсәтә.*) Минем дус бар. Тургайсин. Шагыйрь! Шәп кеше. Корея хакында үкертеп яза инде менә! Бәлки, шул арыш-бодайларга катыштырып, Кореяны сөйләрбез? Мөһим тема бит ул! (*Картадан эзләнеп.*) Кайда соң әле үзе? Әһә, менә икән!

Б а н у. Корея анда түгел, сез Карелияне күрсәтәсез. Менә ул Корея.

Мәүланҗан. Кайчаннан бирле Кореяны анда күчергәннәр әле?

Бану. Сез шаян кеше икән, Мәүланҗан абый.

Мәүланҗан. Шук кеше мин, шук!

Фирдәвес ишекне ача, кычкыра.

Фирдәвес. Мәүланҗан абый, сезне сорыйлар!

Мәүланҗан. Афзал абыйдыр! (*Атылып килеп китә.*)

Бану ялгызы. Бераздан Шәйхел керә.

Бану. Шәйхел... Минем арттан килми калмас дип уйлап утыра идем! Сагынып беттем үзеңне.

Шәйхел. Шулай. Төнәген ярты төнгә кадәр китапханәдә бергә... Бүген тагын иртән бергә... Иртәгә нәрсә булыр? Берсекөнгә?

Бану. Ни сөйлисең син, җаным?

Шәйхел. Ә мин көне-төне тракторда булырга тиеш. Тизләтелгән график! Ярыш! Тышаулаган ат кебек бер урында әйләнәсең дә әйләнәсең!..

Бану. Син шаярып кына сөйлисең бит, әйеме, Шәйхел?

Шәйхел. Юк, шаяртмыйм! Мин боларның барысына да яралгыда ук тамыр чабарга булдым!

Сәләхи керә.

Сәләхи. Шәйхел, бу хәбәр дөресме?

Шәйхел. Бүген бөтен хәбәрләр дөрес!

Сәләхи. Син безгә хыянәт итәсеңме?

Бану. Ни эшләгән ул?..

Сәләхи. Мин сиңа ышанып килдем... Серләремне сөйләдем. Хыялларымны уртаклаштым. Бергәләп эшлибез, урабыз дип йөрдем. Инде көне килеп җиткәч кенә тәртәгә тибәсеңме?.. Бүгеннән акылыңа килмәсәң, без сине гафу итмәбез!

Талип керә.

Талип. Менә ничек бит ул, Сәләхи! Планнар шулай сүтелә ул!..

Сәләхи. Тамырың җирдә түгел икән синең...

Бану. Сәләхи, артык каты сүзләр әйтәсең. Шәйхелнең күңеле саф чынаяк кебек аның. Сак кагылмасаң, ватыла.

Шәйхел. Аны ваттылар инде! (*Чыга.*)

Талип. Сихерләгәннәр моны! Ипидер, сихерләгәннәр...

Бану. Нишләгән ул? Әйтегез әле, нишләгән?

Талип. Тракторын ташлап янгын сараендагы машинага эшкә күчте.

Бану. Булмас!

Т а л и п. Председатель белән сөйләшкәнен үзем күрдем. Ятып кына җыламады.

С ә л ә х и. Нигә горур түгел соң без!.. Ә, Талип абый! Игенче горурлыгы юк бездә! Нигә алай? (*Чыгып китә.*)

Т а л и п. Ничек соң, кырга барабызмы? (*Аңа ияръ.*)

Бану китәргә дә, китмәскә дә белми. Бүлмәдән М ә ү л а н җ а н белән Ф и р д ә в е с чыга.

М ә ү л а н җ а н. Гафу итегез, Фирдәвес иптәш. Казаннан Тургайсин шалтыратты. Дус бар минем. Шагыйрь... Сездә бер мөһим йомыш бар! Инглиз теле түгәрәге оештырам! Китапханәгә бер ун данә журнал алдырасы иде!

Б а н у. Алдырырбыз, Мәүланҗан абый. Хәзергә мин китим әле. (*Чыгып китә.*)

Ф и р д ә в е с. Ничек? Бану шулай тиз ризалаштымы?

М ә ү л а н җ а н. О, әле болай гына булачакмы! Тургайсин әйтмешли: «Алга, дуслар, алга!» (*Телефон шалтырый.*) Бөтен линияләр занят!.. Фирдәвес... Күзләрең кара ич синең!

Ф и р д ә в е с. Тыңламыйча ярамый.

М ә ү л а н җ а н. Куй әле!

Ф и р д ә в е с (*барып трубканы ала*). Бу — Афзал абый.

М ә ү л а н җ а н. Афзал абый? Ә?.. Тыңлыйм, иптәш начальник. Әйе. Яхшы. Урнаштым. Рәхмәт сезгә, Афзал абый. Бик вакытлы килгәнмен. Монда эш!.. Урнаштырам... Җәелдерәм... Арттырып үтим... Газета-журналлар таратуны көчәйтәм... Аңлату эшләрен киңәйтәм. Культураны ныгытам. Була. Эшлим. Тыңлыйм. Үземнең тормыш... Ул да әйбәт! Көйләнер!.. Мин өйләнмәгән бит әле. Өйләнергәме? Вакыт, бик вакыт, Афзал абый, иптәш начальник. Кызлар буа буарлык! Кара күзлеләре дә бар!.. Авылдамы?.. Колхозмы? Кызыксынмадым... Уракка? Шушы көннәрдә эшкә тотыналар дип ишетелде. Шул уңайдан күрсәтмәләр бирсәгез иде... Эшнең уртасында булырга? Оештырырга? Көчәйтергә? Ныгытырга? Ашыктырырга? Урып-җыю авылда иң мөһим эш?! Булды. Хәтергә сеңдердем. Төшендем. Уңыш бәйрәмендә туй?.. Сез минем туйга киләсез? Була! Үтим. Эшлим. Була. (*Трубканы куя, йөзендә гаҗәеп бер төчелек.*) Менә кеше!.. Мине һаман онытмаган!.. Тикшерә, барлый, өйрәтә! Фигура!

Х ә й б у ш керә.

Х ә й б у ш. Мәүланҗан абый, Таңсылу әби килгән. Тавык ашы пеште, кайтамы икән, ди!

М ә ү л а н җ а н. Өйлән, ди!

Х ә й б у ш. Тавык ите изелә, ди.

Мәүланҗан (*айнып*). Ә, кыргыйлар!

Фирдәвес. Вакытында ашап та алырга кирәк.

Мәүланҗан. Әле син китмәдеңмени?

Фирдәвес. Кая?

Мәүланҗан. Ишетмәдеңмени? Кырга, басуга!

Фирдәвес. Ни эшләрбез без анда?

Мәүланҗан. Урып-җыю авылда иң мөһим эш. Шуны хәтерегә сеңдер! Вакытында урып-җыйдың — оттың, соңга калдың — оттырдың, диде Афзал абый.

Фирдәвес. Мин аны беләм!

Мәүланҗан. Эшне турыдан-туры кырга күчерәм.

Фирдәвес. Ничек?.. Мин Афзал абыйның сүзен башкача аңладым. Почта да үз өлешен кертергә, ярдәм итәргә тиеш. Бик дөрес, газета-журналларны кырга илтербез, кыр станнарында витриналар оештырырбыз.

Мәүланҗан. Без иң мөһим эш белән турыдан-туры шөгыльләнергә тиеш... Без дә көн саен отчет язарлык булсын!.. Ә, отчет... Яздыңмы син отчетны?

Фирдәвес. Яз дисезме?

Мәүланҗан. Һичшиксез, яз!

Фирдәвес. Язарбыз, болай булгач. Тик бераз гына көтик әле, Мәүланҗан абый. Сез халыкка үзегезнең кем икәнлегегезне күрсәтегез, урып-җыю башлансын!

Мәүланҗан. Хәзер үк барып әйтегез, миннән башка башламый торсыннар... Ярар, уңышлар зуррак булгач, отчет язу күңелле булыр!.. Түгәрәкләр оештырам, журналларны таратам, урып-җыюга актив катнашам!

Хәйбуш (*тәрәзәдә*). Мәүланҗан абый, Айсылу апа килгән. Сөтле токмачым куера, ди.

Мәүланҗан. Сөтле токмачлар, боткалар... Мескен халык! Хәйбуш, атны җик! Кырга, кырга!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге урын. Монда кыр станы булырга тиеш. Төрле кирәк-яраклар китереп аударганнар да урнаштырып бетермәгәннәр. Җәйге матур көн. Куак янында Хәйбуш утыра һәм, бик бирелеп, күккә карап җырлый.

Хәйбуш. Карар инде, карар инде
Кара күзләре белән.
Өзәр инде үзәгемне
Фирдәвескәй, кара күзкәй
Матур сүзләре белән.

Фирдәвес керә.

Фирдәвес. Егет булып киләм дисең инде, ә, Хәйбуш...

Хәйбуш. Нигә?

Фирдәвес. Бер дә җырламыйча тормыйсың.

Хәйбуш. Өйрәнәм! Мәүланҗан абый ике көн инде шушы көйне генә җырлата...

Фирдәвес. Нигә җырлата икән ул?

Хәйбуш. Кем белсен! Дуслаштык үзе белән. Баганаларны санап чыктык. Җиде мең!

Фирдәвес. Тиз дуслашкансыз, тиз.

Хәйбуш. Мине шоферлыкка укытам, ди.

Фирдәвес. Кая китте соң әле үзе?

Хәйбуш. Сәләхи абыйны эзли.

Фирдәвес. Нигә эзли ул аны? Берәр сүз әйтмәдеме?.. Сәләхи белән очрашканнарын күрмәдеңме? Ни сөйләшәләр? Сәләхи кайда?

Хәйбуш. Күрмәдем. Ишетмәдем. Сәләхиләр вагон алырга киттеме шунда, белмим!..

Фирдәвес. Хәйбуш... Әйтми торыйм әле! (*Чыгып китә.*)

Мәүланҗан керә.

Мәүланҗан. Сәләхи күренмәдеме? Юк?.. Кайда соң ул?.. Ә кем китте әле моннан?

Хәйбуш. Фирдәвес лә ул. Әллә нишләгән...

Мәүланҗан. Хәтәр йөри, хәтәр!..

Хәйбуш. Нәселләре шундый. Абыйсын юкка гына генерал димиләр бит!

Мәүланҗан. Генерал? Фирдәвеснең генерал абыйсы бармы?

Хәйбуш. Бар. Башка елларны көлтә бәйрәменә кайта торган иде, быел күренми әле.

Мәүланҗан. Нинди көлтә бәйрәме?

Хәйбуш. Иртәгә уракка төшәбез дигән көнне яшьләр кичке уенга көлтәләр күтәреп чыгалар. Кызлар чәчләренә ал тасмалар, такыялар тагалар. Җырлыйлар, бииләр һәр елны яңа җыр чыгаралар. И-и кызык була анда! Җыела халык, җыела халык! Яше-карты аклан чирәмендә була!

Мәүланҗан. Көлтәләр күтәреп, ал тасмалар тагып... Бөтен авыл!.. Кем оештырган бу бәйрәмне? Кем уйлап чыгарган?

Хәйбуш. Берәү дә чыгармаган. Тоталар да үзләре җыелалар.

Мәүланҗан. Хәйбуш... Бу бит — фикер! Республика күләмендәге эш! Уракка төшәсе көнгә каршы дидеңме? Кайчан уракка төшәләр?

Хәйбуш. Дөрес булса, Талип абый иртәгә дип торды.

Мәүлан җан. Иртәрәк!

Талип керә.

Талип иптәш, кайчан урырга керешәсез?

Талип. Миңа барыбер.

Мәүлан җан. Бер-ике көн көтә аласызмы?

Талип. Телисең икән, бер атна! Талип барыбер үзенең гектарларын урачак! (*Казыклар кагып, юынгыч куя башлый.*)

Мәүлан җан. Яшә, Талип иптәш! Алдынгы тракторчылардан бер теләктәш таптык! Хәзер...

Сәләхи керә.

Сез миңа бик-бик кирәк бит, Сәләхи иптәш!

Сәләхи. Без агроном белән кырларны карап чыктык.

Мәүлан җан. Иң элек сезне кайнар котларга рөхсәт итегез.

Сәләхи. Ни өчен?

Мәүлан җан. Бик әйбәт уңыш үстергәнсез! Бигрәк тә менә бу бодайлар...

Хәйбуш. Арыш бит ул!

Мәүлан җан. Ни дидем мин?.. Әйе, арышлар... Бик күркәм, бик әйбәт!.. Мондый иген үстерүчеләр арасында геройлар да бардыр инде?

Сәләхи. Геройлар юк югын...

Мәүлан җан. Ә нигә юк?

Сәләхи (*көлеп*). Бу турыда уйлаган да юк безнең!

Мәүлан җан. Уйларга кирәк!.. Көлтә бәйрәмен кайчанга билгеләдегез?

Сәләхи. Бәйрәм бүген кич!.. Хәл кылынды инде: иртәгә арышны теземнәргә сала башлыйбыз.

Мәүлан җан. Ялгышасыз, Сәләхи иптәш, бәйрәм бүген булмый.

Сәләхи. Кем әйтте аны?

Мәүлан җан. Менә мин әйттем! Геройлар мәсьәләсен юкка гына кузгатмадым мин, Сәләхи иптәш. Игенне болай урып-җыймыйлар... Бәйрәм үткәрүне нигездә үзгәртергә кирәк.

Сәләхи. Безнең авылның үз җолалары бар.

Мәүлан җан. Болай эшлибез: мин тиз генә Тургайсинга хәбәр итәм. Дус бар минем. Шагыйрь! Ул күз ачыпйомганчы бер җыр язып ыргыта. Газеталар белән сөйләшә. Хәбәрче китертәбез. Фотокорреспондентлар. Радио кешеләрен. Казаннан, районнан кунаклар чакы-

рабыз. Афзал абыйны барып алабыз. Менә шунда гына көлтә бәйрәмен уздырабыз!

Хәйбуш. Радиодан? Газетадан? Кешеләр? Менә ичмасам бәйрәм булачак!

Талип. Кызык, бик кызык...

Сәләхи. Ә арыш?

Мәүланҗан. Нинди арыш?

Сәләхи. Күрәсезме, ничек дулкынлана ул! Безне чакыра!

Мәүланҗан. Арыш көтеп торыр.

Сәләхи. Көтми шул ул. Шуңа күрә без эшне быел яңача оештырырга торабыз да.

Мәүланҗан. Басудан чыгып качмас әле.

Сәләхи. Качмый, әмма коела.

Мәүланҗан. Хак эш таләп итә икән, коелсын! Калганы җитмиме әллә сезгә?

Талип. Миңа барыбер. Үз гектарларымны барыбер сыдырам мин!

Хәйбуш. Менә зур бәйрәм булачак! Безнең колхоз турында радиодан сөйлиләрме ул чагында?

Мәүланҗан. Киногa төшерерләр! Тургайсин эшли аны. Дус бар минем. Шагыйрь. Татарстанга данығыз китәр! Сәләхи иптәш, бу эшне миңа үз кулыма алырга рөхсәт итегез!

Сәләхи. Ничә көн кирәк булыр соң сезгә?

Мәүланҗан. Ике-өч көндә әйләндереп чыгарабыз аны.

Сәләхи. Белмим шул... Кызыктыргыч инде үзе, әй!.. Председатель, агроном белән сөйләшеп карарга кирәк.

Мәүланҗан. Алдынгы тракторчылар мине якласа, аларны да җиңәбез!

Хәйбуш. Менә әйбәт булыр!

Сәләхи. Вагонны китерәләр. Талип абый, әйдә әле!

Мәүланҗан. Килештек, алайса, Сәләхи иптәш!

Сәләхи. Уйлашырбыз. (*Талип белән чыгып китәләр.*)

Мәүланҗан. Хәйбуш!

Хәйбуш. Әү, Мәүланҗан абый!

Мәүланҗан. Колагыңны торгызып тыңла: син бүгеннән почта йөртүче түгел, минем махсус йомышчым. Зур эш башлап җибәрәм.

Хәйбуш. Ә почтаны кем йөртә?

Мәүланҗан. Анысы эш арасында! Буш вакытта. Иң мөһиме: урып-җыю! Тыңла: минем арттан бер адым да калмыйсың. Кирәк вакытта отчетлар, докладнойлар алып почтага чабасың. Тургайсинга, Афзал абыйга һәм башкаларга хәбәр итәрсең! Телефонда бүген Гөлчәһрә! Бөтен эшен ташлап минем боерыкларны үтәсен!

Х ә й б у ш. Моннан анда... Аннан монда... Була!

М ә ү л а н җ а н. Кәгазь, кәлам ал, яз! «Авыл хуҗалыгы эшләренә актив рәвештә катнашам. Кыр станын матур бер җирдә оештырдым. Көлтә бәйрәме дигән бәйрәм оештырам. Бәйрәмгә җыелган халыкка «Корея һәм безнең колхоз алдында торган изге бурычлар» дигән өч сәгатьлек доклад белән чыкмакчы булам». Яздыңмы?

Х ә й б у ш. Язуын яздым да, әллә ничегрәк бит әле бу!

М ә ү л а н җ а н. Төпченеп торма! Хәзер үк почтага чап! (*Чыгып китә.*)

Х ә й б у ш. Ничегрәк була соң инде бу, ә?

Ашыгып кына Ф и р д ә в е с керә.

Ф и р д ә в е с. Сәләхи китте дәме?

Х ә й б у ш. Фирдәвес, безнең авылга радиодан, газетадан кешеләр килә! Безне киногa төшерәләр. Сине дә төшерерләр әле менә, күрерсең.

Ф и р д ә в е с. Кем әйтте?

Х ә й б у ш. Мәүланҗан абый... Аннары көлтә бәйрәме бүген булмый.

Ф и р д ә в е с. Бусын да Мәүланҗан абыең әйттеме?

Х ә й б у ш. Әйе. Кызык та була инде, Фирдәвес!.. Тик менә... Шушы язуны укып кара әле. Берәр нәрсә аңлыйсыңмы?

Ф и р д ә в е с. Кая әле. (*Укый.*) Кем язды моны?

Х ә й б у ш. Язуын мин яздым, Мәүланҗан абый әйтеп торды. Ничек була инде бу, Фирдәвес... Бәйрәмне ул оештырмады ич!

Ф и р д ә в е с. Хәйбуш... Син егет булып киләсең инде. Аңла, син минем кулга бик кирәкле кәгазьне тоттырдың. Мәүланҗан куркыныч кеше ул...

Х ә й б у ш. Ничек? Шпионмы әллә?

Ф и р д ә в е с. Тизрәк Сәләхиләрнең күзен ачасы иде... Алар ялгышып, төзәтмәслек хаталар эшләп ташламасыннар! Булыш миңа, Хәйбуш.

Х ә й б у ш. Булышам, Фирдәвес. Ялганны җенем сөйми минем!

Ф и р д ә в е с. Бу язуны миндә калдыр. Мәүланҗанга, тапшырдым, дип әйтерсең.

Х ә й б у ш. Бу үзе ялган була ич!

Ф и р д ә в е с. Бу ялган — хаклыкны табу өчен кирәк! Бар, почтага чап! (*Хәйбуш чыга.*)

Китаплар күтәреп Б а н у керә.

Ә, Бану, килеп җиттеңме?

Б а н у. Китапларны кая куярга икән?

Ф и р д ә в е с. Куеп тор. Сәләхине шушында гына урала диделәр.

Б а н у. Уф... Әллә нигә арып, таушалып торам.

Ф и р д ә в е с. Син нигә бик күңелсез?

Б а н у. Әнкәй каклаган каз китергән иде, шуны Мылтык Вәлиләргә алып барган да бинокльгә алыштырып кайткан. Янәсе, пожар каланчасыннан мине карап ята!

Ф и р д ә в е с. Нишлиләр алар?.. Авылга кем килгәнен күрмиләрмени? Шәйхел Сәләхиләр белән булса икән...

Б а н у. Син үзең дә борчылгансың, Фирдәвес.

Ф и р д ә в е с. Куркыныч, ялганчы кеше ул Мәүланҗан абый... Аннан сагаерга кирәк. Хәзер менә Сәләхиләр белән йөреп, аларны үз ягына аударып маташа!.. Сәләхигә барып әйтергә уйлыйм... ничек әйтәсең? Минем сүзне ничек бәяләвен беләсең ич!

Б а н у. Чыннан да... Мәүланҗан — куркыныч кеше. Син аның планнарын ишетсәң, күрер идең...

Ф и р д ә в е с. Ничек Сәләхиләрнең күзен ачарга? Кем белән?

Б а н у. Белмим шул.

Ф и р д ә в е с. Күзләрен ачып карасалар, аның кем икәнлеген үзләре дә күрерләр иде...

Б а н у. Абау!..

Ф и р д ә в е с. Нәрсә бар?

Б а н у. Шәйхел монда да килеп җиткән. Әнә карап тора!

Ф и р д ә в е с. Кая качасың?

Б а н у. Кая булса да.

Ф и р д ә в е с. Юк, монда качып кына котылып булмый. Чарасын табарга кирәк. Өйрәт әле, Бану. Минем бер фикерем бар барын. Әйдә әле, киңәшик! (*Чыгып китәләр.*)

Куак астыннан зур бинокль аскан Ш ә й х е л килеп чыга. Юлдан Г ө л л ә р н е иярткән Т а ң с ы л у килә.

Т а ң с ы л у. Шәйхел улым, нигә көпә-көндез муеныңа туп асып йөрисең?

Ш ә й х е л. Көпә-көндез таладылар!

Т а ң с ы л у. Тиешле-тиешсез урында ятып йокладыңмы әллә, бала?

Ш ә й х е л. Йокы сиңа! Ул килгәннән бирле күз йомган юк!

Т а ң с ы л у. Кем?

Ш ә й х е л. Мәүланҗан... Бану артыннан сөйрәлә... Менә хәзер дә икесе дә шушында, кырда.

Т а ң с ы л у. Каһәр генә суксын! Шулайдыр дигән идем аны!

Ш ә й х е л. Ничек? Авыл арасына да таралдымы бу хәбәр?

Т а ң с ы л у. Берәр кыз димләрсең әле, дигән ягымлы гына бала, үзгәрде дә куйды бит.

Ш ә й х е л. Нинди кыз?

Т а ң с ы л у. Кара күзле чибәр кыз. Исеме Гөлләр. Әнә үзе!

Ш ә й х е л. Кем димләргә кушты?

Т а ң с ы л у. Мәүланҗан.

Ш ә й х е л. Мәүланҗан?.. Таңсылу әбекәем! Рәхмәтләр яусын сиңа! Үзем өйләндерәм мин аны!

Т а ң с ы л у. Бирсен Ходай!.. Гөлләр, кызым, без менә бу абыең белән әйләнеп килик әле! (*Чыгалар.*)

Т а л и п керә. Юынгычка су сала. Юынып ала. Күлмәген салып ямарга утыра. Г ө л л ә р аның янына килә.

Г ө л л ә р. Талип абый, үзем ямап бириммe?

Т а л и п. Үзем дә шәп ямыйм. (*Пауза.*)

Г ө л л ә р. Әгәр миннән иң авыр эш ни дип сорасалар, мин: «Кунакта яту»,— дип әйтер идем. (*Пауза.*)

Т а л и п. Нишләп йөрисең монда?

Г ө л л ә р. Белмим. Таңсылу әби алып килде. Әйдә дә әйдә, дип, каныма төште.

Т а л и п. Кунак булып яту күңелле түгел икән, кайт та кит!

Г ө л л ә р. Кайтасы да килми.

Т а л и п . Кирле-морлы сөйләшмәсә, хатын-кыз буламы соң ул!

Г ө л л ә р. Үги әни усал... Кечкенә чакта кыйный иде, хәзер сүзе белән боргычлый... Шуңа күрә, Таңсылу әби чакырып җибәргәч тә, чыгып киттем! Колагым тынып торсын, дидем.

Т а л и п. Синең әниең үгимени? (*Пауза.*) Мә, алайса, ямап җибәр. (*Күлмәген тоттыра.*) Бая багана күтәргәндә, сүтелеп китте.

Гөлләр ямый башлый.

Йә, эшләр барып чыгамы?

Г ө л л ә р. Нинди эш?

Т а л и п. Мәүланҗан кармакка эләгәме?

Г ө л л ә р. Исемә дә кереп чыкмый!

Т а л и п. Эләкми, шуңа күрә кирәкми.

Г ө л л ә р. Мин тыйнак, юаш кешеләрне яратам. Тын гына яшисем, бик күп эшлисем килә. Бик күп итеп, онытылып, бирелеп! Тик аның белән бергә, бергә!.. Өйдә беркем дә сөйләшмәсен иде. Күз карашыннан бар да аңлашылсын иде. Тып-тын... Почмакта күкеле сәгать... Ул гына бәхетле минутларны саный... Мә, Талип абый, булды.

Т а л и п. Кулың ятышлы гына икән болай! Ямау дип уйламассың.

Г ө л л ә р. Җиде яшемнән күлмәкләремне үзем тегәм... Бу Таңсылу әби кая китте болай?

Т а л и п. Әллә кая китмәс, караштыр.

Гөлләр чыга. Ш ә й х е л керә.

Ш ә й х е л. Талип абый, Мәүланҗанны күрмәдеңме?

Т а л и п. Минем бит биноклем юк. (*Чыгып китә.*)

С ә л ә х и керә.

С ә л ә х и. Янгынга каршы көрәш чараларын тикшерергә килеп тә җиттек диген!

Ш ә й х е л. Уеныңны ташла әле, Сәләхи. Әйтче, Мәүланҗан кайда?

С ә л ә х и. Кырга, иптәшләргә хыянәт итү уен инде синеңчә?

Ш ә й х е л. Без ничек тә килешербез, Сәләхи!

С ә л ә х и. Ә кыр? Ул хыянәтеңне гафу итәрме?

Ш ә й х е л. Мәүланҗан кирәк миңа, ишетәсеңме?! (*Чыгып китә.*)

Сәләхи Бану калдырган китапларны караштырып ала. Ф и р д ә в е с керә.

С ә л ә х и. Фирдәвес... Мин бүген көне буе синең хакта гына уйлыйм.

Ф и р д ә в е с. Сәләхи...

С ә л ә х и. Үпкәләмә син, ярыймы?! Кайчак тупасрак, дуамалрак та булып куям мин...

Ф и р д ә в е с. Сәләхи, көлтәләрне кайданрак урыйк икән? Хәйбуш атына төяп тә төшәрбез...

С ә л ә х и. Нигә ашыгырга? Бүген бәйрәм булмас та әле бәлки.

Ф и р д ә в е с. Арыш өлгермәгән дип таптыгызмы?

С ә л ә х и. Арыш өлгергән!.. Башка сәбәпләре бар.

Ф и р д ә в е с. Нинди сәбәпләр ул, Сәләхи?

С ә л ә х и. Болай гына, үзаралай гына сөйләштек әле. Председатель белән хәл итмәгән...

Ф и р д ә в е с. Сәләхи... Без бит быел кышлар буе сөйләштек. Иген әрәм-шәрәм итүгә кайчан чик куярбыз икән дип янып йөрдек. Сез махсус график төзедегез! Ә хәзер шулар барысы да ватыламы?

С ә л ә х и. Фирдәвескәй... Сиңа ни җитми? Кыр тутырып иген үстердек, тормыш яхшы, күңелләр көр! Шулар өстенә минем мәхәббәтем... Син һаман канәгать түгелме?

Ф и р д ә в е с. Минем бүген шаярасым килми, Сәләхи!.. Сез ялгышмыйсызмы?

С ә л ә х и (*ачулана башлый*). Ялгышны төзәтүчеләр бар бит безнең!

Ф и р д ә в е с. Юк, мин чынлап!

С ә л ә х и. Ялгышмабыз!

Ф и р д ә в е с. Сез Мәүланҗан абыйга артыграк ышанып җибәрмәдегезме? Ул кешенең кем икәнен беләсезме сез?

С ә л ә х и. Бер Фирдәвес кенә күрә дә, без барыбыз да сукырлар инде, янәсе!.. Синең бар нәрсәгә катнашып, тыкшынып йөрүең ошамый миңа, Фирдәвес!

Ф и р д ә в е с. Без дуслар бит, Сәләхи!

Т а л и п керә.

Т а л и п. Сәләхи, анда сине чакыралар!

Ф и р д ә в е с. Сәләхи, уйлап эшлә! Сак бул ул кешедән!

Сәләхи, Талип чыгалар.

Ф и р д ә в е с. Нигә тыңлата алмадым мин аны?

Х ә й б у ш керә.

Х ә й б у ш. Фирдәвес, минем кулда тагын бер документ!

Ф и р д ә в е с. Их Хәйбуш дус, Хәйбуш дус!..

Х ә й б у ш. Ни булды, Фирдәвес?

Ф и р д ә в е с. Мәхәббәт ул бер-береңә карашып тору гына түгел, мәхәббәт икең дә бер якка, бер максатка карау, дигән бер акыллы кеше! Бир язуыңны!

Х ә й б у ш. Укысаң, исең китәр. Ничек Шәйхел абыйның биноклен элдерергә инде? Күзәтеп йөрергә шәп булыр иде.

Ф и р д ә в е с (*укып*). Язуыңны миндә калдыр, үзең почтага чап.

Х ә й б у ш. Әрәмәгә керәм дә шунда качып ятам. Ат арды. (*Чыга.*)

Ф и р д ә в е с. Шушы язуларны Казанга тапшырырга кушкан бит. Нишләргә?

М ә ү л а н җ а н керә.

М ә ү л а н җ а н. Ә, Фирдәвес иптәш...

Ф и р д ә в е с. Сез һаман ашыгасыз, чабасыз.

М ә ү л а н җ а н. Тиздән менә шушы кырларга комбайннарны оркестр тавышы астында кертеп җибәрәчәкмен!

Ф и р д ә в е с. Аңа карап арыш күбрәк булырмы?

М ә ү л а н җ а н. Нәрсә?

**Фирдәвес.** Арыш, бодай күбрәк булырмы, дим. Беләсезме ипинең бәясен?

**Мәүланҗан.** Кызыксынганым юк.

**Фирдәвес.** Безнең күршедә Мәфтуха апалар тора. Ире сугышка киткәч, алты бала белән торып калды ул. Әнкәйнең бер-ике боткалык бодае бар икән. Шуны ярма ташы аркылы үткәргәч, Мәфтуха апаның кече улы кереп: «Түти, ярма ташыгызны гына булса да ялатыгыз әле»,— дип ялына икән. Шул малай хәзер ир кеше инде һәм, искергән дип, ярты бөтен ипине күз дә йоммыйча юынтык чиләгенә ташлый...

**Мәүланҗан.** Ул заманнар үтте. Без хәзер чиксез бай!.. Яшәү мөмкинлекләре үзгәрде. Минем шушы тормышны кайнатасым килә! Миңа иптәшләр кирәк. Терәк булырлык якын бер дус кирәк... Ә синең күзләрең нинди кара, Фирдәвес!

**Фирдәвес.** Зәңгәр күзләрне бер дә яратмыйсыз, ахры?

**Мәүланҗан.** Сәбәбе бар, Фирдәвес иптәш, сәбәбе!.. Кара күзләр бөтенләй башка... Фирдәвес, чык миңа кияүгә!

**Фирдәвес.** Нигә?

**Мәүланҗан.** Мин сине сөям.

**Фирдәвес.** Безнең кызлар киләләр!.. Айсылу апа түгелме бу?

**Мәүланҗан.** Айсылу апа? Ә? Мин монда юк! (*Чыга.*)

Чәчкәне иярткән Айсылу керә.

**Айсылу.** Мәүланҗан, Мәүланҗан!

**Чәчкә.** Безне күргәч качты.

**Фирдәвес.** Нигә эзлисез аны?

**Айсылу.** Журналларга язылдым. Көн саен чебеш суям. Минем дә кешечә картаясым килә. Бала сөясем килә!.. Бергәләп яшәрбез, диде. Бер кыз димләрсең, диде. Менә ул кыз! Кай җире ошамаслык! Күзе кара...

**Фирдәвес.** Син аңа чыгарга ризамы?

**Чәчкә.** Риза дип... Яратса, чыгам!

**Фирдәвес.** Бәлки, сез миңа ярдәм итәрсез? (*Уйлап тора.*) Тукта... Чынлап та... Өйләндерәм мин аны! Әйдә, Айсылу апа!

**Айсылу.** Кызым, Чәчкә, шушы тирәдә генә тор! (*Чыга башлыйлар, каршыларына Шәйхел керә.*)

**Шәйхел.** Мәүланҗан күренмәдеме?

**Фирдәвес.** Үзебез шуны эзлибез.

Чыгалар. Чәчкә агач арасына кереп китә. Шәйхел пыр тузып йөри, бинокленнән карый. Сәләхи керә.

С ә л ә х и. Их Шәйхел, Шәйхел... Әйт әле, ни булды сиңа?

Ш ә й х е л. Көнләшәм, Сәләхи.

С ә л ә х и. Нигә көнләшәсең?

Ш ә й х е л. Шагыйрь әйтмешли, иске гадәт икәнлеген беләм, ярatканга, ахры, көнләшәм...

С ә л ә х и. Яраткан кеше көнләшергә тиешме?

Ш ә й х е л. Ихлас, шулай! Гомер-гомергә шулай килгән инде ул.

С ә л ә х и. Синнән серем юк. Фирдәвес белән безнең мөнәсәбәтләр табышмак кебек. Әгәр мин аны көнләштереп сынап карасам? Яратамы ул мине, юкмы?..

Ш ә й х е л. Үзем дә каш ясыйм дип, күз чыгардым, ахрысы! Инде син сак бул... Кайда булыр бу Мәүланҗан! (*Чыга.*)

Агачлыктан Ч ә ч к ә чыга.

С ә л ә х и. Кем син, чибәр кыз?

Ч ә ч к ә. Сез миңа дәшәсезме? Мин Айсылу апалардагы кунак кызы.

С ә л ә х и. Кунак кызы, нигә кичке уеннарда күренмисең?

Ч ә ч к ә. Чакырганың булмады ич!

С ә л ә х и (*үкенгән булып*). Белгән булсам...

Ч ә ч к ә. Абый, кара әле, күзем карамы минем?

С ә л ә х и. Күзге кара төн кебек... (*Үз-үзенә.*) Бу кызый белә сынап караганда ничек булыр икән?..

Ч ә ч к ә. Ни бар, чибәр абый?

С ә л ә х и. Тагын шулай өзелеп «чибәр абый» диген әле.

Ч ә ч к ә. Әйтсәм, ни бирерсең?

С ә л ә х и. Өзелеп-өзелеп яратырмын!

Ч ә ч к ә. Әйем лә, уенга алган кешеләрне яратмыйм...

С ә л ә х и. Шаяртмыйм... Чибәр кыз, миңа кияүгә чыгасыңмы?

Ч ә ч к ә. Абый, нигә алай дисез?

С ә л ә х и. Син миңа бик, бик ошадың!

Ч ә ч к ә. Әллә?..

С ә л ә х и. Ризамы?

Ч ә ч к ә. Син мине яратырсыңмы соң?

С ә л ә х и. Каймак кына ашатып торырмын.

Ч ә ч к ә. Тагын уен-көлкегә борасың!

С ә л ә х и. Юк ла! Өйләнү уен-көлкеме әллә?

Ч ә ч к ә. Белмим шул инде... Әйтергә дә оят... Айсылу апа нәрсә дияр? Чакырыйммы?

С ә л ә х и. Син аңа әйтми тор. Әлегә берәүгә дә әйтмә! Бүген кич уенга төш. Шунда егетләр-кызлар җыелгач кына, тантаналы шартларда әйтербез.

Ч ә ч к ә. Без бүген өйләнешмибезмени әле?
С ә л ә х и. Азрак әзерләнергә дә кирәк бит!

Ш ә й х е л, Т а ң с ы л у, Г ө л л ә р керәләр.

Т а ң с ы л у. Безне күрде исә кача!

Т а л и п керә.

Т а л и п. Олы апа, кайтып китмәдегезмени әле?
Т а ң с ы л у. Кайтмыйбыз, кайтмыйбыз! Өзеп кенә әйтеп бирсен.
Г ө л л ә р. Таңсылу әби, кирәкми, кайтыйк... Оят бит болай!
Ш ә й х е л. Өйләндерәм мин аны!

Каршы яктан М ә ү л а н җ а н килә. Ул үзен эзәрлекләүче Айсылудан кача-кача килә дә мондагы төркемгә килеп бәрелә.

М ә ү л а н җ а н. Ай!..
А й с ы л у. Юк, Мәүланҗан туганым... Үзең әйттең, димләрсең, диден...
М ә ү л а н җ а н. Сүз арасында гына ычкынгандыр ул... Мин зур эшләр башлау алдында торам...

Ф и р д ә в е с, Б а н у һәм бер төркем к ы з л а р керәләр.

Т а ң с ы л у. Каршыңда кыз басып тора!
Т а л и п. Мәүланҗан, егет булсаң, егет бул!
Г ө л л ә р. Таңсылу әби, әйдә кайтыйк...
Ф и р д ә в е с. Нигә шулкадәр тавышланасыз?
Т а л и п. Менә Мәүланҗан өйләнә.
М ә ү л а н җ а н. Иптәш кем, Талип абый, өйләнмим мин!
Ч ә ч к ә. Монда мин кияүгә чыгам. Шуңа шаулыйлардыр...
С ә л ә х и. Чибәр кыз, дәшми тор!
Ч ә ч к ә. Нигә дәшмәскә? Бер-беребезне табыштык, яратыштык. Мин сиңа кияүгә чыгарга риза булдым. Ни исемле әле син?
С ә л ә х и. Сәләхи лә... Монда ярамый!
Ч ә ч к ә. Айсылу апа, без икәү булдык, исеме Сәләхи.
А й с ы л у. Юк, юк, Чәчкә кызым. Синең киявеңнең исеме Мәүланҗан.

Х ә й б у ш керә.

Т а ң с ы л у. Мәүланҗан Гөлләрнең кияве ул!
А й с ы л у. Чәчкәнеке!
Х ә й б у ш. Мәүланҗан абый, сугышчан боерык үтәлде!

М ә ү л а н җ а н. Килдеңме, Хәйбуш! Әйдә әле, мин сине көтә идем!

А й с ы л у. Җибәрмибез!

Т а ң с ы л у. Китми тор, Мәүланҗан улым...

Т а л и п. Нигә ятим баладан болай көләсең? Егет булсаң, кистереп кенә әйтеп бир!

Ш ә й х е л. Өйләнергә дигәч, өйләнергә! Кызларның кайсысын аласың?..

Ч ә ч к ә. Мин аңа чыкмыйм. Мин Сәләхинеке!

Ш ә й х е л. Сәләхи, нигә бер сүз дә әйтмисең? Ни сөйли бу кыз?

С ә л ә х и. Тукта әле...

Ф и р д ә в е с. Чыннан да, нигә Сәләхи дәшми?

С ә л ә х и. Без... без... Әйе... Өйләнешергә булдык!

Ш ә й х е л. Алайса, Мәүланҗан, кызның менә бусы сиңа!

М ә ү л а н җ а н. Мин өйләнмим... мин...

Т а л и п. Ничек өйләнмисең?!

Т а ң с ы л у. Өйлән!

Ф и р д ә в е с. Туктагыз, туктагыз... Эш менә нәрсәдә, егетләр... Мәүланҗан абый бүген миңа тәкъдим ясады!

С ә л ә х и. Ничек?

Ф и р д ә в е с. Һәм мин аңа кияүгә чыгарга риза булдым!

Гаҗәпләнгән, ухылдаган, уфылдаган авазлар.

Б а н у. Ни эшлисең син?.. Аны башкаларга күрсәтәсе урында...

Ф и р д ә в е с (*шыпырт*). Тик тор. Ашыкма! Вакыты килеп җитмәде әле...

Х ә й б у ш. Ничек болай булды соң әле бу?

Ф и р д ә в е с. Тик тор, Хәйбуш!.. Күрәсезме мин кемне сайладым? Нигә дәшмисез?.. Нигә котламыйсыз мине?

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук көннең киче. Авыл читендәге китапханә яны. Бакча. Бакчада эскәмияләр. Зур агач өстәл. Өстәл янында сыек кына яктылык биреп лампочка яна. Китапханә ишегендә йозак. Тәрәзәләре караңгы. Җылы, тымызык кич. Сәхнә аша Х ә й б у ш үтеп бара, аңа Б а н у очрый.

Х ә й б у ш. Әй, Бану апа, килен коймагы ашарга барабызмы?!

Б а н у. Эчемне пошырма әле, Хәйбуш. Бәйрәм буламы бүген, юкмы?

Хәйбуш. Әнә Фирдәвес килә. Аннан сора.

Фирдәвес керә.

Фирдәвес. Бану, нигә җәйләүдән кайтышлый кермәдең?

Бану. Аягым тартмады.

Фирдәвес. Нигә тартмады икән ул?

Хәйбуш. Магниты беткәндер.

Фирдәвес. Хәйбуш апаем, акыллы сүзләреңнән тегендә дә ялыктым. Бар, азрак уйнап ал әле...

Хәйбуш. Начальник хатыны булам дигәч тә, бакчага сыймый башлаган. (*Чыга.*)

Бану. Ни эшләдең син? Мәүланҗанның йөзен ачарга шундый уңайлы вакыт иде! Нигә бата башлаганда, аны тартып чыгардың?

Фирдәвес. Иртәрәк кебек тоелды... Сәләхинең фокусын сиздеңме? Мине шаштырырга маташа ул. Ә минем аны шаштырасым килде! Сукыр булганы өчен! Күзен ачып йөрмәгәне өчен җәзалыйсым килде.

Бану. Теге кыз белән сүз берләшкәннәр дисеңме?

Фирдәвес. Әлбәттә шулай.

Бану. Мәүланҗанның кем икәнен күрсәтәсе иде!

Фирдәвес. Күрсәтерлеге бар... Берәүләр аның өчен отчет яза, эшен эшли, икенчеләр доклад әзерли, китапханәдә утырып ирен газаплый, кемнәрдер аңа кыз ташый! Кемнәрдер аның кәефе өчен намусына каршы барып булса да, эш планын үзгәртергә тора... Аңа ул да аз! Ул авылның бар куанычын үзенә җыймакчы...

Бану. Иң чибәр кызын эләктермәкче...

Фирдәвес. Көлтә бәйрәмен үземнеке димәкче!.. Һәм безнең егетләр шул кешене танымадылар. Шәйхел аннан көнләште, димәк, аны үзеннән өстен санады. Сәләхи дә шулай ук... Нигә горур түгел безнең егетләр? Куллары дисәң, алтын, эшли беләләр...

Бану. Нишләмәкче буласың инде син?

Фирдәвес. Көлтә бәйрәме — изге бәйрәм! Аңа сафланып, чистарып барырга кирәк. Яшьләр бәйрәмгә җыелгач та, мин Мәүланҗанны аларга күрсәтергә уйлыйм.

Бану. Тизрәк булсачы! Шәйхел нишләргә белми. (*Чыгып китә.*)

Фирдәвес ялгыз. Авыз эченнән генә җырлый. Сәләхи керә.

Сәләхи. Мин авылны бетереп сине эзлим. Өегезгә дә кердем. Әнкәң кайгырган.

Фирдәвес. Барын да белсә, егыла-егыла көлер әле.

Сәләхи. Нишләдең син, Фирдәвес, нишләдең?

Фирдəвес. Əйт əле, Сəлəхи, син бəхетлеме?
Сəлəхи. Белмим.
Фирдəвес. Ничə яшь əле сиңа?
Сəлəхи. Егерме дүрт.
Фирдəвес. Бу яшьтə инде үз бəхетеӊ турында гына түгел, халкың бəхете, ил бəхете турында да кайгыртталар! Хуш, Сəлəхи.
Сəлəхи. Ташлап китəсеңме?
Фирдəвес. Сине дə яшь кəлəшең көтə торгандыр!
Сəлəхи. Тукта инде, сөйлəшик...
Фирдəвес. Фирдəвескə бүген туктарга ярамый. Ул туктый алмый. Барсын ул, барсын! (*Чыга.*)
Сəлəхи. Фирдəвес, гафу ит мине!

Хəйбуш керə. Сəлəхи бакчага керə, эскəмиягə утыра.

Хəйбуш. Минем эскəмиягə утыргансың!
Сəлəхи. Сыярсың əле.
Хəйбуш. Синең белəн бергə утырасы гына килми... (*Башка эскəмиягə күчеп утыра. Җырлый.*)

Аккош күллəрдə була,
Борыны суларда була,
Яшь чагында кемне сөйсəң,
Күңелең шуңарда була.

Сəлəхи. Хəйбуш!
Хəйбуш (*җырлый*). Яшь чагында кемне сөйсəң...
Сəлəхи. Үз тавышыңа үзең чукракландыңмы əллə?
Хəйбуш (*җырлый*). Күңелең шуңарда була...
Сəлəхи (*торып*). Синең бугаз киергəнеңне ишетəсе килə дисеңме əллə?
Хəйбуш. Ихтыярың бəрəңге: телəсə кая тəгəрə!
Сəлəхи. Бануны күрмəдеңме?
Хəйбуш. Кайтып китте.
Сəлəхи. Кара əле, килүче Бану түгелме?
Хəйбуш. Түгел. (*Җырлый.*)

Ике тургай, бер сандугач
Куакта сайрашалар...

Сəлəхи (*кинəт*). Хəйбуш, син мине күрмəдең дə, белмисең дə! (*Ашыгып чыгып китə.*)

Чəчкə керə.

Чəчкə. Əй, чибəр егет!
Хəйбуш. Мин чибəр егет түгел.
Чəчкə. Хəйбушмы əле синең исемең?

Хәйбуш. Кемгә Хәйбуш, ә менә синең кебек нечкә сыйракларга Хәбибрахман абый.

Чәчкә. Хәйбуш матуррак инде.

Хәйбуш. Ялагайланма.

Чәчкә. Менә син Сәләхине күргәнсеңдер әле, мөгаен!

Хәйбуш. Күрдем.

Чәчкә. Кайда? Нәрсә эшли ул шулай озак?

Хәйбуш. Болында аунап ябагасын коя иде.

Чәчкә. Тиле.

Хәйбуш. Безнең колхозның «Сәләхи» исемле айгыры бар. Сәләхи исемле егет тә бар. Сиңа шуларның кайсысы кирәк?

Чәчкә. Ә авылыгызда җүләрләр бармы, Хәйбуш?

Хәйбуш. Моңарчы юк иде, син килдең, беренчесе булырсың!

Чәчкә. Сәләхигә әйтеп кистерәм мин сине, малай актыгы!

Хәйбуш. Сәләхиләргә аяк басасы булма! Суга безнең тыкрыктан йөрисе булма, адым саен төлке капкыны куярмын!

Чәчкә. Телеңә төер чыксын!

Хәйбуш. Үә-үә-үә. (*Үртәп чыгып китә.*)

Чәчкә акырып җылый. Айсылу керә.

Айсылу. Нигә җылыйсың?

Чәчкә. Бөтенесе миннән көләләр, мыскыл итәләр...

Айсылу. Сәләхинең әнкәсе дә бик җылый, ди.

Чәчкә. Җылау түгел, шартласа да, Сәләхи минеке!

Айсылу. Йортка талаш белән аяк басу күңелле түгел инде.

Чәчкә. Ошатмаса, чыгып китәр, каенана карап ятасым килми.

Айсылу. Ай Аллам, әшәке сөйләшәсең бит! Илдә күренмәгәнне.

Чәчкә. Миңа кияүгә чыгарга кирәк. Гомер буе ата-ана җилкәсендә ятып булмый ич инде... Үземнең кыз булып йөрүемнән оялам!..

Айсылу. Нәрсәсе оят аның?

Чәчкә. Хәзерге заман кызлары табигатьтән мәрхәмәт көтеп кенә ятмыйлар, үз куллары белән даулап алалар! Сәләхи минеке: авылыгызны ут төртеп яндырырмын, тавыгызны ишәрмен, тегермән буагызны җибәрермен, әмма аны беркемгә дә бирмәм! Күп булдылар инде... Минем белән йөриләр дә, башкага өйләнәләр...

Айсылу. Әле дә ярый Мәүланҗанга насыйп булмагансың... гомере буе мине каргар иде...

Ч ә ч к ә. Ул карт ишәгеңнең поты бер тиен. Тракторчылар заманы хәзер. Сәләхи минеке! Тракторчы... Умырып эшли, умырып икмәген ала, ә мин умырып ашарга яратам! Сәләхи, Сәләхи ! (*Кычкырып чыгып китә.*)

А й с ы л у. Авылыбызга бәла алып кайтканмын лабаса! (*Чыга.*)

Ш ә й х е л белән С ә л ә х и керәләр.

Ш ә й х е л. Ишеттеңме, Сәләхи?

С ә л ә х и. Ишеттем, Шәйхел.

Ш ә й х е л. Күрдеңме, Сәләхи?

С ә л ә х и. Күрдем, Шәйхел.

Ш ә й х е л. Ничек котылырга инде бу бәлаләрдән?

С ә л ә х и. Аптырадым...

Ш ә й х е л. Әнә Мәүлانҗан килә... Тагын ник килә инде ул китапханә тирәсенә?

С ә л ә х и. Чыраен күрәсем килми шуның! (*Чыгып китә.*)

М ә ү л а н җ а н керә.

М ә ү л а н җ а н. А, Шәйхел дус... Ишеткәнсеңдер, өйләнәм!

Ш ә й х е л. Ишетелде...

М ә ү л а н җ а н. Туй көнен билгеләдем, кунаклар чакырдым. Унтугыз телеграмма гына җибәрдем! Син дә кил, түремә утыртырмын. Казаннан, Яңа бистәдән ике карчык китертәм. Бәлешләрне тәгәрәтеп кенә торсыннар...

Ш ә й х е л. Бәлешләрне Таңсылу әби дә бик шәп пешерә!

М ә ү л а н җ а н. Ха-ха-ха!.. Менә көлке!..

Ш ә й х е л. Нигә көләсең?

М ә ү л а н җ а н. Кызык иттем әле ул карчыкларны! Кыеш-мыеш кызларын миңа сөртергә маташалар бит!

Ш ә й х е л. Үзең димләргә кушкансың ич.

М ә ү л а н җ а н. Сүз арасында, уйнап кына, карчык кешегә башка нәрсә әйтәсең инде дип кенә ычкындырган сүз ул.

Ш ә й х е л. Алар менә чын күңелдән тырышып йөриләр.

М ә ү л а н җ а н. Нигә миңа димче? Үзем кемне алырга белмимме әллә?.. Иң чибәрен, кара күзлесен!..

Ш ә й х е л. Кара күзлесен дисең инде?

М ә ү л а н җ а н. Зәңгәр күзләрне җенем сөйми!

Ш ә й х е л. Нигә алай? Зәңгәр күзләр дә бик матур була ич!

М ә ү л а н җ а н. Зәңгәр күзләр куркыныч карыйлар... У-у, элек, мин сабын комбинатында эшләгәндә, бер кыз

бар иде. Зәп-зәңгәр иде күзләре. Тиешлесен-тиешсезен күрә торган, барына тыкшына торган кыз... Комбинаттан шул күзләр аркасында киттем мин...

Шәйхел. Алай...

Мәүланҗан. Бу Бану кайда соң?

Шәйхел. Бану?.. Нәрсәгә ул сиңа? Бану өендә һәм бүген китапханәгә килми дә. (*Чыгып китә.*)

Хәйбуш үтеп бара.

Мәүланҗан. Әй, Хәйбуш!

Хәйбуш. Нәрсә бар?

Мәүланҗан. Бар, йөгер, Бану апаңны алып кил.

Хәйбуш. Йөгермим. Бәйрәмгә төшәсем бар.

Мәүланҗан. Бәйрәм бүген булмый.

Хәйбуш. Ялганчы!

Мәүланҗан. Кем ялганчы?

Хәйбуш. Син дә, Фирдәвес тә, барыгыз да!.. Фирдәвес теге язуларны алып калды. Үзем дә җибәрми идем мин аларны!

Мәүланҗан. Алып калды?.. Фирдәвес? Кайда ул?.. (*Чыгып китә.*)

Хәйбуш көлә-көлә үтеп китә. Таңсылу белән Гөлләр керәләр.

Таңсылу. Әллә бүгенгә китмисеңме, кызым? Төнгә каршы юлга чыгып...

Гөлләр. Олы юлда машина өзелми.

Таңсылу. Нигә шул Мәүланҗанны ошатмадың инде? Мөхәммәтханның сүзен тыңласым килгән иде... Үземнең дә, бала сөеп, кешечә яшисем бик килә...

Гөлләр. Хуш, Таңсылу әби, гаепләп калма!

Таңсылу. Хуш, балам. (*Саубуллашалар. Таңсылу китә.*)

Гөлләр чемоданыннан яулык чыгарып бәйли. Караңгыдан Талип килеп керә.

Талип. Гөлләр...

Гөлләр. Минем китеш, Талип абый.

Талип. Гөлләр, китмә син...

Гөлләр. Эш сагындым. Каным оеды.

Талип. Эш монда да җитәрлек. Китмә.

Гөлләр. Нигә?

Талип. Нигә, нигә!.. Үзең дә беләсең ич инде...

Гөлләр. Белмим, Талип абый, белмим...

Талип. Бөтен кеше дә шул сүзне әйтә диләр бит. Менә минем әйтеп караганым юк! Үзем генә калган чакларда әйтергә тырышып карыйм, анда да телем әйләнми!

Г ө л л ә р. Ә син бер сүзен генә әйт!

Т а л и п. Менә яңа чалбарымны кидем.

Г ө л л ә р. Бик килешә.

Т а л и п. Сакалымны кырдым. Көн дә кырынам хәзер! Бүген бездә көлтә бәйрәме. Минем ул бәйрәмгә бер дә төшкәнем юк иде. Бүген төшәсем килә. Әйдә, бергә төшәбез!

Г ө л л ә р. Минем кайтасым бар бит.

Т а л и п. Кайтмыйм диден ич инде.

Г ө л л ә р. Нигә?

Т а л и п. Нигә, нигә! Син миңа бик ошадың...

Г ө л л ә р. Тагын бер кабатла әле.

Т а л и п. Бер әйткәндә дә теземнең җегәре бетте!

Гөлләр Талипны үбеп ала.

Син мине үптеңме? Үбү шулай буламыни инде? Ах Гөлләр! Әйдә бәйрәмгә! Иртәгә уракка! Дуылдатабыз икән! Юк, Талип та патша! Мин дә патша! (*Җитәкләшеп чыгып йөгерәләр.*)

М ә ү л а н җ а н үтеп бара, аңа каршы Ч ә ч к ә очрый.

Ч ә ч к ә. Сәләхи, Сәләхи!

М ә ү л а н җ а н. Сәләхи юк монда.

Ч ә ч к ә. Мәүлянҗан абый, әй, Мәүлянҗан абый.

М ә ү л а н җ а н. Нәрсә бар?

Ч ә ч к ә. Күңелем синдә генә иде. Кара аны, үкенерсең. Шул шайтаның белән тора башлагач, Чәчкә исеңә бик төшәр...

М ә ү л а н җ а н. Юлыңда бул!

Ч ә ч к ә. Барыбер сиңа чыкмаган булыр идем, карт җен! (*Чыга.*)

Ф и р д ә в е с керә.

М ә ү л а н җ а н. Бу нинди сүз, Фирдәвес иптәш!

Ф и р д ә в е с. Нинди сүз?

М ә ү л а н җ а н. Бәйрәм дә бәйрәм дип шашалар! Бүген бәйрәмне үткәрергә ярамый!

Ф и р д ә в е с. Нигә ярамый?

М ә ү л а н җ а н. Ашыгырга ярамый.

Ф и р д ә в е с. Ни өчен аны көттерергә? Арыш өлгергән... Сизәсеңме, хәтта исе монда килеп җитә!

М ә ү л а н җ а н. Минем өчен, синең өчен, үзебез өчен көттерергә кирәк! Авыл безнең өчен яшәргә тиеш... Фирдәвес, кара күзем!.. Шундый туй уздырырбыз, абыеңны, генералны чакырырбыз...

Ф и р д ә в е с. Нинди генералны? Мәсгуть абыйны әйтәсеңме? Кайтты ул.

М ә ү л а н җ а н. Ничек кайтты?
Ф и р д ә в е с. Монда Әлмәттә генә эшли ул. Нефтьче.
М ә ү л а н җ а н. Генерал нефтьчеме?
Ф и р д ә в е с. Генерал — кушамат. Бик таза гәүдәле, калын тавышлы булганга аны генерал дип йөртәләр.
М ә ү л а н җ а н. Димәк, мине алдаганнар! Мине һәр адымда алдап торалар!
Ф и р д ә в е с. Сез аңлап кына җиткермәгәнсездер, Мәүланҗан абый. Кем сезне алдасын?
М ә ү л а н җ а н. Син дә мине алдарга маташасың бит! Йә, әйт әле! Нигә минем отчетларны тоткарлап калдың?
Ф и р д ә в е с. Ялган отчетларны җибәрәсем килми.
М ә ү л а н җ а н. Алар киткән булырга тиеш.
Ф и р д ә в е с. Нигә юк нәрсәләрне үз өстегезгә аласыз? Көлтә бәйрәмен сез уйлап чыгармаган бит.
М ә ү л а н җ а н. Кем уйлап чыгаруындамы эш? Ул уйлап тапкан да беткән. Бәлки, әллә кайчан үлгәндер инде!
Ф и р д ә в е с. Көлтә бәйрәмен беренче тапкыр минем әткәй оештырган.
М ә ү л а н җ а н. Бик әйбәт! Әткәңә нәрсәгә аңа исем? Аңа дан нигә? Ә миңа кирәк ул! Миңа бик күп кирәк, аңлыйсыңмы?!
Ф и р д ә в е с. Ул күпне кем бирергә тиеш соң?
М ә ү л а н җ а н. Халык.
Ф и р д ә в е с. Ни өчен?
М ә ү л а н җ а н. Мин берәү генә, халык күп! Мин аларны җитәкләргә тиеш. Син минем янда. Рәттән. Без бергә җир җимертербез!
Ф и р д ә в е с. Менә хәзер бәйрәмгә төшәргә ярый!
М ә ү л а н җ а н. Бәйрәм булмый бүген!
Ф и р д ә в е с. Без бар халыкны дәштек! Иртәгә урак башлана! Бәйрәм бүген була!

Ш ә й х е л, Б а н у, С ә л ә х и, Х ә й б у ш, Т а л и п, Г ө л л ә р керәләр.

Ш ә й х е л. Менә алар!
Б а н у. Фирдәвес, авылны кузгаттың да үзең кайда йөрисең?
М ә ү л а н җ а н. Фирдәвеснең эше бар!
Ф и р д ә в е с. Ул эш өчен сез кирәк миңа, дусларым! (*Кәгазьләр чыгара.*)
М ә ү л а н җ а н. Нишлисең син, җүләр!
Ф и р д ә в е с. Кызык кына бер-ике язу укыйм. Тыңлыйсызмы? (*Укый.*) «Көлтә бәйрәме дигән нәрсә оештырдым. Кырдагы машиналарны сугышчан хәлгә китердем... Урып-җыю эшләрен тулаем үз кулыма алдым. Кыр станын төзүгә җитәкчелек иттем».

М ә ү л а н җ а н. Чамалап, Фирдәвес иптәш!

С ә л ә х и. Кем язган моны? Укы әле, укы!

Ф и р д ә в е с (*укый*). «Авыл халкы искиткеч надан. Мин аларга түгәрәкләр оештырдым. Иген игәргә өйрәтәм мин аларны!»

Ш ә й х е л. Әкиятме бу, чын эшме?

Х ә й б у ш. Чын! Мәүланҗан абый язды бит аларны.

М ә ү л а н җ а н. Мин яздым. Әллә берәр ялган сүз бармы монда? Идейный яктан хата фикер бармы? Тарих өчен язылган сүзләр болар.

Ф и р д ә в е с. Чүпләрдән шактый арындырасы тарихны пычратып маташасыз бит, Мәүланҗан иптәш!

М ә ү л а н җ а н. Син үзеңнең булачак ирең белән ничек сөйләшәсең?

Ф и р д ә в е с. Мин, Мәүланҗан иптәш, сезне сынарга гына теләгән идем. Мин сезгә кияүгә чыкмыйм!

М ә ү л а н җ а н. Ничек алай? Туй көне билгеләнгән, кунаклар чакырылган.

Ф и р д ә в е с. Мин чакырмадым, мин билгеләмәдем.

М ә ү л а н җ а н. Афзал абыйга хәбәр иттем. Тургайсинга. Дус бар минем. Шагыйрь.

С ә л ә х и. Ни өчен сиңа кияүгә чыгарга тиеш соң ул?

М ә ү л а н җ а н. Кире уйларга миннән рөхсәт юк.

Ф и р д ә в е с. Гел-гел рөхсәт белән генә дә эшләп булмый.

М ә ү л а н җ а н(*янап*). Приказга буйсынмый кара.

Ф и р д ә в е с. Кем чыгарган приказ ул?

Акрын гына х а л ы к җыела. Шау-шу.

М ә ү л а н җ а н. Чыгармаган булсалар, хәзер чыгарам. Утыр, яз. Почта күләмендә мин начальник. Син минем кул астындагы кеше. Яз! Юк, алай тиз генә котыла алмассың. Җиде мең баганага начальник диләр мине!

Ф и р д ә в е с. Мин багана түгел бит. Кеше. Кешеләр без.

М ә ү л а н җ а н. Яз. Ә сез таралыгыз! Бәйрәм булмый бүген!

Ф и р д ә в е с. Язмыйм! Мин акылсыз приказларга буйсынмыйм.

М ә ү л а н җ а н. Менә кая барып җиттең син! Әгәр син мине тыңламасаң, мин Афзал абыйны... Ул үз чиратында иптәш Сафинны... Иптәш Сафин үз чиратында... Әйтергә дә куркыныч! Дәүләт каршында мөһим җинаять!

Ф и р д ә в е с. Менә шушы кеше безнең кадерле икмәгебезне ашап, безнең тәмле суларыбызны эчеп яшәргә тели! Безнең матур, изге бәйрәмебезне бүләргә тели!

Сәләхи. Рәхмәт сиңа, Фирдәвес!

Мәүланҗан. Алай ансат кына эшләмиләр! Юк. Мәүланҗан андыйлардан түгел ул! Кияүгә дә чыгарсың... Тычкан баласын чыелдаткандай чыелдатырмын мин сине! Көч бездә! Беләсеңме мин кем... Сез кыргыйларга акыл, бәхет алып килгән кеше мин! Мин... Мин!

Таңсылу керә.

Таңсылу. Ай Аллам, харап булдык!

Шәйхи. Ни бар, Таңсылу әби?

Сәләхи. Ни булды?

Таңсылу. Мәүланҗан, сине эзлим.

Мәүланҗан. Ә? Нәрсә бар?

Таңсылу. Тыным бүленде.

Мәүланҗан. Тизрәк бул!

Фирдәвес. Утыр, Таңсылу әби, ашыкма.

Таңсылу. Таягын алганнар, фәсен салдырганнар.

Мәүланҗан. Нәрсә? Кемнең фәсен?

Таңсылу. Әле генә районнан шалтыратканнар. Афзал абыеңны урыныннан алганнар! Иске гөнаһлары да күп булган, яңалары да җитәрлек ди.

Мәүланҗан. Булмас! Ялган хәбәр бу! Якты кояшыбызны, зирәк акыллы Афзал абыйны! Аннан башка ничек яшәрбез?

Фирдәвес. Дусларым, халык җыелды, әйдәгез бәйрәмгә!

Бану. Карагыз әле, ай чыгып килә!

Сәләхи. Йолдызлар атылалар!

Таңсылу. Гөлләр, балам, син китмәдеңмени?

Гөлләр. Китмәдем, әбкәй, китмәдем!..

Таңсылу. Алайса, җир җимерелми, кояш сүнми инде?

Фирдәвес. Сүнми, әби, сүнми! Җирне җимерерлек көч юк. Чөнки Җир йөзендә кешеләр яши! Әйдәгез, егетләр! Көлтәләр кайда? Бәйрәмне башларга вакыт!

Шау-гөр. Көлтәләр күтәрәләр, гармун, уен-җыр. Чыгып китәләр, Мәүланҗан бераз ялгыз. Чәчкә керә.

Чәчкә. Сәләхи, Сәләхи!

Мәүланҗан. Ник акырасың?

Чәчкә. Мәүланҗан абый, син генә ярдәм итә аласың. Синең кулда көч...

Мәүланҗан. Кулымны сындырдылар.

Чәчкә. Синдәге акыл...

Мәүланҗан. Башымны ашадылар.

Чәчкә. Кем ашады?

М ә ү л а н җ а н. Юлымны кистеләр! Нинди якты, киң юлга чыга идем.

Ч ә ч к ә. Кем кисте?

М ә ү л а н җ а н. Әнә алар. Ишетәсезме?

Ч ә ч к ә. Кая барыйм! Кияүгә чыктым дип, авылга хәбәр иттем...

М ә ү л а н җ а н. Моннан китәргә кирәк.

Ч ә ч к ә. Мәүланҗан абый!

М ә ү л а н җ а н. Ә? Куркыттың!.. Борыл әле ай яктысына! Зәңгәр күзле бит син!

Ч ә ч к ә. Юк, юк! Күзләрем кап-кара минем. Ай яктысында гына...

М ә ү л а н җ а н. Сабый комбинатында эшләгәндә, бер кыз бар иде. Күзләре зәп-зәңгәр. Кая барсам, ни эшләсәм, мине күзәтеп кенә тора бу. Шул чагында зәңгәр күзләрне сөйми башладым. Комбинаттан китәргә туры килде! Әле дә ярый Афзал абый! Бөек кеше! Авылга бар син! Шуннан күтәрелә башла, дип акыллы киңәш бирде. Эшкә урнаштырды. Зәңгәр күзләрне күрсәм, йөрәгем ярсый башлый иде. Монда кара күзле башымны ашады. Кара күзле кыз!.. Ух...

Ч ә ч к ә. Мәүланҗан абый, өйлән син миңа!

М ә ү л а н җ а н. Сиңа өйләнеп нишләрмен мин?

Ч ә ч к ә. Безнең авылда да почта бар. Начальник булырсың.

М ә ү л а н җ а н. Почталар күп, ләкин Афзал абый бер генә... Почталар күп, ләкин аларда да зәңгәр күзле кызлар, әй, кара күзле... юк ла, зәңгәр күзле кызлар бар! Күрәсең бит... Аны да... Мине дә...

Ч ә ч к ә. Үлгәнме әллә?

М ә ү л а н җ а н. Үлгән. Әнә шуның кебекләр тереләй тотып башын ашаганнар!

Ч ә ч к ә (*акырып елый башлый*). Тереләй үкмени?

М ә ү л а н җ а н. Чү! Әнә үзләре киләләр! Афзал абый кадәр Афзал абыйны ашаган кешеләр килә! Ух, димәк, алар бәйрәмнәрен үткәрергә булганнар!

Ч ә ч к ә. Монда таба киләләр!

М ә ү л а н җ а н. Качарга кирәк. Син ат җигә беләсеңме?

Ч ә ч к ә. Белмим!.. Мәүланҗан абый, өйлән син миңа! Мин сине бик яратам. Бергә-бергә җаен табарбыз.

М ә ү л а н җ а н. Ярар. Тик кара аны, кызый! Беләсеңме мин кем идем!

Ч ә ч к ә. Киләләр. Кая барабыз?

М ә ү л а н җ а н. Киләләр. Әйдә караңгыга! (*Чыгалар.*)

Агач башларына эленгән төрле төстәге лампочкалар кабынып китә. Уенга катнашучылар көлтәләр күтәреп сәхнә алдына киләләр. Җыр һәм бию.

Гел көләч, гел көләч
Булсын безнең йөзләр.
Гел аяз, гел аяз
Булсын безнең көннәр.
Эш ямьле ул,
Яши белсәң!
Яшәү кызык,
Эшне сөйсәң!
Биегез, биегез!
Җир тетрәсен!
Югары күтәрик
Муллык көлтәсен!
Гел көләч, гел көләч
Булсын безнең йөзләр,
Гел аяз, гел аяз
Булсын безнең көннәр!

Пәрдә.

*Мәскәү—Урта Баграж—Коктебель—Казан*
*1962—1963*

# *Җиз кыңгырау*

*Драма дүрт пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Разия.
Хөрмәтулла.
Мәүлә.
Чәчкә.
Гәрәй.
Хәбир.
Бикбулат.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хөрмәтуллаларның өй эче. Өй иркен. Юан аяклы өстәл. Калын такталардан нык итеп ясалган урындыклар. Уң якта өйалдына чыга торган ишек. Сулда кече як ишеге. Зур мич. Бер якка тимер мич тә куелган. Көн кичкә авышкан. Разия, көянтә күтәреп, судан кайта. Суын тиз генә кече якка кертеп куя да бу якка чыга. Чишенми-нитми генә тәрәзә бозын эретеп, урамга карый башлый. Кабалана. Кече яктан Хөрмәтулла керә. Ул бераз Разияга карап тора.

Хөрмәтулла. Урамда ниең калды? Бик йотылгансың...

Разия. Болай гына...

Хөрмәтулла. Болай гына булса ярый... Телең белән бозны ялама, салкын тидерерсең.

Разия (*чишенеп*). Тимәс, әткәй. (*Өйалдында аяк тавышы ишетеп, Хөрмәтулла Разияга карый.*)

Хөрмәтулла. Болай гына булмаган икән шул.

Мәүлә керә. Ул күренүгә, Разия кече якка чыга. Мәүлә, күзләре белән Разияны эзләп, бер сүз дә дәшми басып тора.

Йә, ни йомыш?

Мәүлә. Миңа Разия кирәк иде.

Хөрмәтулла. Ул өйдә юк.

Мәүлә. Өйдә бит, Хөрмәтулла абзый. Яңа гына коедан кайтты. Артыннан бастырып килдем.

Хөрмәтулла. Йомышың булса, урамда гына бетер идең.

Мәүлә. Анысын Разия белән сөйләшербез.

Хөрмәтулла. Нәрсә ул кадәр, кендегегез берекмәгәндер ич?

Мәүлә. Беләсең килә тагын үзеңнең.

Хөрмәтулла. Синең белән бүләсе малым юк, сүзем дә шушының белән бетте.

Мәүлә. Синеке булмаса, минеке бар, Хөрмәтулла абзый!

Хөрмәтулла. Синеке мәгълүм! Җыелыш саен: «Хөрмәтулла кебекләрне колхоздан куарга кирәк, андыйларның койрыгына басарга күптән вакыт!» — дип кем кычкырды?

Мәүлә. Мин.

Хөрмәтулла. Беләсең икән үзең дә!.. Сүзең беттеме? Ә мин үлмәдем дә, бетмәдем дә. Рәхәтләнеп яшим, Аллага шөкер! Кара әле! (*Өй эчен күрсәтә.*) Барысы җитеш, барысы мул. Синең кебек ач әрләннәргә үч итеп, күкрәк киереп яшим.

Мәүлә. Шөкрелең бөкрелерәк, беләбез... Калып торсын берлеккә. Бүгенгә Разия кирәк иде.

Хөрмәтулла. Юк диләр сиңа, Ходай кошы!

Мәүлә. Чебен булып очмагандыр бит, өегез шактый нык күренә.

Хөрмәтулла. Кызыгасыңмы, әрлән?! Телеңне тешләдеңме, сүзең беттеме?

Мәүлә. Сиңа бетте.

Хөрмәтулла. Ә минем кызымның сине күрәсе дә, сөйләшәсе дә килми.

Мәүлә. Кайчаннан бирле кызлар үз аталарын егетләр янына вәкил итеп җибәрә башладылар әле?

Хөрмәтулла. Яхшы ата балалары дип өстә! Алланың биргәненә куанам, кызым бер генә булса да, үземә охшаган.

Мәүлә. Яхшы кеше булу өстенә, яхшы ата да икәнсең әле син.

Хөрмәтулла. Әллә түгелме? Мин аны унике яшеннән әнисеннән алып калдым. Керен үзем удым, ашын үзем пешердем. Карадым. Ятим булып, күңеле китек булып үсмәсен, дидем.

Мәүлә. Күңел мәсьәләсе караңгы ла ул.

Хөрмәтулла. Кемгә ничек! Менә шулай. Күзеңне май янында бөтерелгән ач песи сыман елтыратып йөрмә.

Яратмаганым песи!.. Кердең, утырдың, бер ягында олы мич, икенче ягында кече мич. Зәһәрең җеби башлады! Ләкин Хөрмәтулла абзаңның йөрәге алай тиз генә җеберлек итеп коелмаган. Корыч аның йөрәге! Андый йөрәктән булат кылычы коярга була, Гали пәкесе!

Мәүлә. Карап тотмасаң, корыч та тутыга.

Хөрмәтулла. Тутыкса да, корыч булып кала, кәлҗемәгә әйләнми.

Мәүлә. Йөрәкнең ниндилеген берзаман дөнья үзе күрсәтә бит, Хөрмәтулла абзый! (*Чыга.*)

Хөрмәтулла. Алдыннан артың матур. (*Авыз эченнән генә җырлап ала.*)

Бүлмәдән Разия чыга.

Разия. Киттеме?

Хөрмәтулла. Кызгансаң, артыннан йөгер.

Разия. Кызганам димим, сорадым гына.

Хөрмәтулла. Сорама да! Тагын килер бу, валлаһи! Җирбит! Килеп карасын... Сине дә әйтер идем, мин югында азгансың!

Разия. Әткәй!

Хөрмәтулла. Дәшмә! Эте-бетенең миңа чокыр казып, батырырга йөргәнен беләсең. Балта эшенә өйрәник, Хөрмәтулла кебекләргә колхоз байлыгы эләкмәсен, дип, тамаклары ярылганчы акырыштылар. Шундый әтрәкәләмнәргә сер бирмәс өчен, эт тормас җирләрдә муеннан карга бата-чума урман кисеп йөрдем. Монда кайтсам, мине кара канга батырырга йөргән малайлар өемә киләләр, түремә узалар. Ни йомышы бар бу ач әрләннең синдә?

Разия. Син югында Хәбир абыйдан, Бикбулат абыйдан башка ир затыннан бер генә кеше дә бу бусаганы атлап кермәде, әткәй.

Хөрмәтулла. Бикбулат. Бикбулат... Минем файдага кереп йөргәндер дисеңме? Шул кереп күңелеңне яздырып йөрмәсә, уең өй тирәсендәрәк булыр иде. Лапас түбәләре ишелә башлаган, болдыр такталары купкан.

Разия. Кадаклап та карадым инде мин аларны...

Хөрмәтулла. Ни эзли башласаң, шул урынында түгел. Менә бу кыңгырауларны кем алып кергән инде? (*Киштәдән кыңгыраулар алып күрсәтә.*)

Разия. Күрше Рабига апаларның Искәндәре кергән иде. Мин амбарга онга чыккан идем. Әллә ни арада минем янга кергән дә алган.

Хөрмәтулла. Ата-бабадан калган малны тарата башладыңмы?

Разия. Чите кителмәгән бит. Алса, уйнады да куйды.

Хөрмәтулла. Уйнамасын! Уенчык түгел ул. Мин аларны гомерем буе саклаган. Әзгә кертермен мин сине, кызый. Борынгыны сакларга өйрәтермен. Бая әйткәннәрне эшләдеңме?

Разия (*бүлмәдән китаплар алып чыга*). Тычкан кимереп бетергән бугай аларны.

Хөрмәтулла. Изге китапларнымы?

Разия. Изге икәнен белмәгәндер шул, надан бит тычкан халкы!

Хөрмәтулла. Телеңә салынма! Бабаңнан калган бик әйбәт бер коръән булырга тиеш иде. Күн тышлы. Аны табып китер. Тиз бул.

Разия. Гомер буе чарлакта аунаган кадими китапларны нигә дип эзләтәсең, әткәй?

Хөрмәтулла. Нигә кирәклеген үзебез беләбез. Ә син артыгын төпченмә, тиз картаерсың. (*Киенеп чыгарга әзерләнә.*)

Разия. Тагын кая чыгып югаласың инде? Кайтканыңа атна булды, гел өйдә тормыйсың. Бернәрсә сорашмыйсың. Ике ел берүзең ничек яшәдең дип, аз гына кызыксынып идең. Югыйсә кыңгыраулар, болдыр, лапас... Аларга нәрсә булсын? Ә тере кешене...

Хөрмәтулла. Син исән-сау, күрәм. Тамагың тук, беләм. Лапас димә син. Ул җимерелеп төшәргә дә күп алмый. Минем сүземнән чыкмасаң, сиңа берни дә булмас. Синең Бикбулатларыңнан йөз мәртәбә үткенрәк мин. Алар заманча яши, мин үземчә! Моның өчен йөрәк кирәк!.. Кыңгырауларны кеше күзеннән читкәрәк җыеп куй. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Китапларны да тазарт, арула, тышларын ябыштыр. Аларны киштә түренә тезеп куй! (*Чыга.*)

Разия идән себереп ала. Җыештыра. Акрын гына атлап Мәүлә керә.

Разия (*тагын сискәнеп*). Мәүлә?

Мәүлә. Курка ук башлагансың...

Разия. Әткәйне күрергә теләсәң, ул өйдә юк.

Мәүлә. Минем йомышым синдә, Разия, беләсең. (*Пауза.*) Кунак килгәч, утыр диләр иде бездә.

Разия. Кирәкми, Мәүлә, утырма. Күрешмик дидем ич.

Мәүлә. Нигә?

Разия. Үзең дә бик әйбәт беләсең.

Мәүлә. Яратасың ич син мине!

Разия. Ярату түгел бу, юк!

Мәүлә. Исеңдәме, без быел май таңын кайда каршыладык? Су буенда! Син шунда миңа: «Сөям сине!» — дип пышылдадың...

Р а з и я. Мәүлә, зинһар...

М ә ү л ә. Миңа ул сүзне беркемнең дә әйткәне юк иде. Пышылдап кына әйткән сүзеңнән яр буендагы таллар хәрәкәткә килде, кошлар уянды. Таулар да куанычларыннан биегәеп китте. Кеше сүзенең бөек булуын миңа син күрсәттең! Хәзер шул сүзеңне кире аласыңмы? Бирмим!

Р а з и я. Сөйләшмикче, зинһар, без бу хакта.

М ә ү л ә. Нигә болай үзгәрдең син? Калтырыйсың.

Р а з и я. Син үзең үзгәрдең, Мәүлә.

М ә ү л ә. Мин элекке кебек үк, кара әле. Менә гәүдәм дә шул, аякларым да... Йөрәгем дә: «Разия, Разия!» —дип сулкылдый. Күлмәгем яңа да, галстугым яңа. Боларын мин каладан алып кайттым. Сиңа да бүләгем бар минем.

Р а з и я. Рәхмәт. Миңа берни дә кирәкми.

М ә ү л ә. Хәтта минем сөюем дәме?

Р а з и я. Әйе... Ул да... (*Пауза.*)

М ә ү л ә. Мәхәббәтсез яшәп булмый, Разия. Әле мин Казанга киткәндә генә син мондый түгел идең. Үзем имтиханнар тапшырам, үзем синнән хат көтәм... Язмадың... Кайткач яныңа фермага бардым, сөйләшмәдең. Өеңә килдем. Анда да беребезнең телен икенчебез белмәгән төсле аңлаша алмыйбыз.

Р а з и я. Очрашмыйк без, Мәүлә, ярамый.

М ә ү л ә. Беләм... Тагын әтиең! Ул кайткан!

Р а з и я. Әткәйгә тел тидермә! Икегез талашканга да әрним. Очрашырга ярамый дидемме, аңла, ярамый! (*Йөгереп бүлмәгә кереп китә.*)

М ә ү л ә. Разия, нигә ярамасын! (*Керә башлый, әчтән Разияның «Кермә!» дип кычкырганы ишетелә. Мәүлә аптырап карап тора да чыга башлый, туктый, кире борылып өстәлгә матур күн перчатка куя.*) Разия, бүләгемне калдырам! (*Чыга.*)

Р а з и я керә. Йөгереп тәрәзәгә бара. Бозны эретеп, урамга карый. Өстәл янына килеп утыра. Перчатканы күрә. Җырлый.

Р а з и я. Чәчәкләр күп, ләкин чәчәк өзмим,
Табу өчен шундый ислесен.
Мин тапканчы шундый бик ислесен,
Гөл үсмәсен,
Җил дә исмәсен.

(*Тәрәзә каршысына килеп баса.*) Ә җилләр исәләр... Яз да килер. Язлар да үтәр... Яз урынына яз килер... Гомер урынына гомер килмәс... (*Чәчкә керә.*) Ә-ә... Син йөрисең икән...

Ч ә ч к ә. Башка берәүне көтә идеңме әллә?
Р а з и я. Кемне көтим? Берәүне дә көтмим.
Ч ә ч к ә. Көткәндә генә килеп керергә мин сиңа кодагый әбиең түгел. Көтмәсәң дә килә беләм. Юл такыр. (*Чишенә.*)
Р а з и я. Килгәч утыр инде.
Ч ә ч к ә. Утырырга да исәп. (*Пауза.*) Клубтан кайтып киләм. Терлекчеләр өчен кино күрсәттеләр. Нигә килмәдең?
Р а з и я. Вакытым булмады. Кәефем дә...
Ч ә ч к ә. Син элек киноларны калдырмый идең.
Р а з и я. Син дә мине әрләргә кердеңме?
Ч ә ч к ә. Әллә ул да?..
Р а з и я. Әйе, ул да кагылып чыкты.
Ч ә ч к ә. Очрашмыйбыз дигән идең ич.
Р а з и я. Казаннан кайтканнан бирле күрешмәдек... Кинога да ул очрар дип бармаган идем... Үзе кергән тагын... Бер күрештек, берәгәйле булды.
Ч ә ч к ә. Юкка бармадың. Ул киноны сиңа карарга иде. Хыялланырга яратасың ич! Күрер идең илдә нинди фермалар барлыгын! Сыерлары нинди! Ә җиленнәре! Күәскүәс инде менә! Елына биш меңне бирәләр.
Р а з и я. Җитәр безгә — каткан тезгә ике меңе дә. Хайваннарның канын суырып сөт арттырыр хәлем юк.
Ч ә ч к ә. Саташмыйсыңмы син, Разия?
Р а з и я. Үзем дә шуны белергә теләр идем.
Ч ә ч к ә. Өч ел бер фермада эшлибез, аңламыйм мин сине.
Р а з и я. Мин югынданиләр сөйләшәсез сез? Мине астыртын, хәйләкәр дисезме?
Ч ә ч к ә. Син әйбәт кыз, Разия! Синнән көнләшкән чакларым да еш була. Тик соңгы көннәрдә кинәт үзгәрдең.
Р а з и я. Дөнья белән бергә үзгәрәбез. Сез дә тик тормыйсыз бит. Син техникумга укырга кердең, Мәүлә институтка ук!
Ч ә ч к ә. Дөнья борылган якка борылмадың шул син!
Р а з и я. Анысын кем белгән инде! Синеңчә, алай, минемчә, болайрак. (*Пауза.*) Нәрсә шулай текәлеп карап торасың?!
Ч ә ч к ә. Кулларың нинди зур, көчле синең. Егетләр кулы сыман.
Р а з и я. Әйтмәсәнә шуны җаннарымны көйдереп! Үзем белмимме әллә?!
Ч ә ч к ә. Нигә аңа гарьләнәсең? Яшьтән эшләп үскәнгә лә ул!
Р а з и я. Яшьтән эшләп үсүне бик рәхәт дип беләсең-

ме? Унике яшеңдә әниеңнән калып кара әле! Бигрәк тә шундый усал әткәй белән... Аңа ни, эшлә генә!.. Мине бар дип тә белмәде бит ул. Шундый дәү, йөнтәс әткәй белән икәү генә калганда әнә теге караңгы почмакка поса идем дә сәгатьләр буе кымшанырга куркып утыра идем.

Чәчкә. Мин булсам әллә кайчан ташлап китәр идем ул карачкыны.

Разия. Әйтергә ансат! Ата кеше бит ул, җүләр. Син дөньяга килүеңбелән дә аңа бурычлы. Аннары үзе дә ятим калды ич...

Чәчкә. Ата дип урталай өзелеп булмый инде, синең үз көнеңне күрәсең бар.

Разия. Үз көнең дип, яшибез инде шунда.

Чәчкә. Әле яши генә башладык, дустым!

Разия. Рәхәт көннәрем бик аз булды моңарчы, бик аз! Менә синең иң рәхәт көннәрең кайсы чакта була?

Чәчкә. Беләсең ич, ерак әбиемнәрдә кунакта!

Разия. Ә менә минем ерак әбиемнәргә дә дүрт ел барганым юк! Дүрт ел!.. Иң рәхәт көннәремне үткәргән Аксуны, әбиемне дүрт ел күргәнем юк.

Чәчкә. Үтер, хак икән шул! Нигә, әй?

Разия. Моңарчы сөйләмәдем... Бер егет белән танышкан идем мин анда.

Чәчкә. Ярата идеңме син аны? Ә ул?..

Разия. И-и, белсәң иде син... Укый иде ул. Казанда. Аксуга кунакка гына кайта иде. Бер җәйне шулай иптәшләрен авылга алып кайткан. Егетләр, кызлар шаулашып тыкрыктан су коенырга төшеп баралар. Чибәр, шәп киенгәннәр. Ә мин, теземнән туфракка чумып, әбиләр бакчасында бәрәңге өям. Битем яргаланган, кулларым зур, кытыршы... Ул мине күрүгә кул болгады... Үлепләр киттем менә! Шул кайтуында мин аны чишмә буена чакырдым. Сандугач оясы күрсәтәм, дидем.

Чәчкә. Килмәдеме?

Разия. Килмәсә кана!.. Килде! Үзе кебек үк купшы киенгән бер кыз ияртеп килде. Алар күренүгә, мин куаклар артына качтым. Ул минем нигә чакыруымны аңламаган. Мин аны уйлап төннәр буе сандугач тавышын тыңлап ятамдыр дип исенә дә кертмәгән ул. Качтым да җиргә капланып озак кына еладым. Беренче мәртәбә үземнең арзанлы күлмәгемә, йон оек кигән тупас аякларыма, иләмсез дәү кулларыма, котсыз чыраема шул егет булып карадым. Тормышым мәгънәсез, кызыксыз күренә башлады.

Чәчкә. Әллә кем түгелдер әле! Исең киткән икән!

Разия. Шул егет янына бастырып үземнең бәямне

билгеләдем. Уйлап кара: укыган, чибәр егеткә минем кебек каткан тезле тупас кыз нигә кирәк?

Чәчкә. Ә үз эшләрең? Мин, Мәүлә?

Разия. Тыңлап бетермәдең... Үртәлеп авылга кайттым, фермада эшли башладым. Герой буласым, макталасым килде. Мәүлә белән шул чакта дуслаштык. Инде барысы да онытылды дип йөргәндә...

Чәчкә. Мәүләне ни дип читкә тибәрәсең?

Разия. Ул егет тә нәкъ Мәүлә укырга кергән институтта укый иде.

Чәчкә. Укыса соң? Мәүлә белән очрашырлар дисеңме?

Разия. Укыган егеттән бер мәртәбә йөрәк ярасы алдым инде, тәмен татыдым. Җитәр!

Чәчкә. Мәүлә андый егетмени?

Разия. Мәүлә дә үзенең кемлеген күрсәтәчәк. Казанга озатканда, минем дә укыйсым килә, дигән идем...

Чәчкә. Укыма дидеме?

Разия. Авызын тутырып көлде. Бик җиңел дип беләсеңме син аны, укуны, ди.

Чәчкә. Кит аннан!

Разия. Менә сиңа юаш Мәүлә!

Чәчкә. Күңелемнең иләс-миләс чагы дип, эшеңне дә онытма инде син.

Разия. Күңелсез миңа. Чәчкә, яшисе килми. Әткәй югында, менә ул кайтыр, киңәшербез, аңлашырбыз дип өметләнә идем...

Чәчкә. Эх, синең урында булсаммы мин... Менә мине берәү дә сөйми. Әйт әле, нигә икән?

Разия. Ничек итеп киңәш бирим ди сиңа, Чәчкә... Шунысын гына беләм: сыер савучы бәхетле булсын өчен литрлар саны арту гына җитми шул. (*Пауза.*)

Чәчкә. Яшермичә әйт: сиңа Гәрәй ошыймы?

Разия. Беләм, ул сиңа ошый.

Чәчкә. Мине яратмый шул ул! Читкә китәм дип күзе акайган! Аны көтсәң, карт кыз булып утыр да кал! Көнләшәм мин синнән, Разия! Сине яраталар! Башыңны исәрлеккә салып йөрүең генә ару түгел.

Разия. Чү!

Ишектә Гәрәйнең башы күренә.

Гәрәй. Аулак өйгә керергә мөмкинме?

Разия. Тизрәк бул инде, суык кертәсең.

Гәрәй (*керә*). Саулармысыз.

Чәчкә. Кайсыбыз сау, кайсыбыз түгел.

Гәрәй. Сүзне чирледән башлыйк! Кайсыгыз сау түгел?

Разия. Анысын үзең сизен, Гәрәй.

Гәрәй. Ягез, ягез, икегез дә минем күзгә карагыз әле! (*Кызлар күлә-күлә карыйлар.*) Шулай икән! Яман чир ябышкан икән! Икегезгә дә!

Чәчкә (*чытлыкланып*). Бәлки, дәвасын да әйтерсең?

Гәрәй. Икегез дә бүгеннән калмыйча кияүгә чыгыгыз.

Разия. Бик риза, алучы гына юк.

Гәрәй. Карата белергә кирәк. Тилгәннәр күрсен өчен аулакта күбрәк булыгыз, ешрак клубка барыгыз. Күрерләр дә алырлар. Аучылар күбрәк булсын өчен кала хатыннары сусардыр, тиендер асып йөриләр.

Разия. Кая инде безгә сусар-тиеннәр!

Чәчкә. Кая инде безгә тиен тотарлык аучылар!

Гәрәй. Әллә мин начар аучымы? Аулак өй икәнен берегез дә әйтмәде, сизенеп килдем.

Чәчкә. Мине күреп килгәнсеңдер әле.

Гәрәй. Кояштыр, күрмәдем!

Чәчкә. Ә каян белдең?

Гәрәй. Исеңнән. Син узган урамнардан ясмин исе килә. Күземне йомдым да, бардым да бардым.

Чәчкә. Чынлапмы?

Разия. Бу суыкта борыныңны бик сузып йөрсәң, өшегәнен сизми дә калырсың.

Гәрәй. Менә, армиядә бергә булган иптәшләрдән тагын хат алдым. Чакырып җибәргәннәр. Кузгаласыңмы син, әллә тамыр җибәрәсеңме дип язганнар.

Разия. Ясмин бакчасында төпләнү начармы әллә?

Гәрәй. Фу, нинди әшәке сүз! Төпләнү, төпкә китү.

Чәчкә. Тузганак чәчәге төсле җил уңаена очасың килә инде синең. Барасың, барасың да ышыграк урынга ятып ял итәсең.

Гәрәй. Әйе. Барам — эшлим. Туям — китәм. Паспорт ян кесәдә, хатын куенда... Хатын ясмин гөле кебек, ялыктырмый!

Чәчкә. Син буш мылтыкка тагын хатын.

Гәрәй. Бер чыгып китсәм, авылны искә алган да юк. Ике ятып бер төшемә керми. Бертуктаусыз кыймылдасым, алга барасым килә минем.

Чәчкә. Бер максатсыз алга да алга.

Гәрәй. Хәтта йоклаганда да үрмәлим мин. Караватта йокларга ятсам, мич арасында уянам.

Разия. Синең рәхәт. Йорт-җирең юк. Күз терәп торган атаң юк.

Гәрәй. Күңел уйнап, кытаклап тора! Соң үзегез чамалагыз: көзге пычраклар башлануга, машинамны гаражга куям да җир кипкәнче кырын ятып, борын сызгыртам. Алтын кулларым белән тирес көрим. Ни Алла-

га, ни муллага, ни үземә — файда юк. Бер ел көрим... ике... Ун ел көрим!

Чәчкә. Гомерең шулай эш белән, хезмәт белән үтсә начармы?

Гәрәй. Сине тыңлаганда акыл риза, ә күңел һаман кымырҗый!.. Әллә малай чактагы кебек берәрсенең морҗасына кар тутырасы инде?.. Әллә югары очтан берәр капка урлап, түбән очка төшереп куясы? Иптәшлеккә барасызмы?

Чәчкә. Кая кабаланасың тагын?

Гәрәй. Чыгам әле, барам... Юатмадың ич!

Чәчкә. Тагын аз гына утыр инде.

Разия. Барсын, барсын. Исән бул, Гәрәй. Капка янында озак торма, бездән чыкканыңны күрмәсеннәр. (*Гәрәй чыга.*) Шулай да мин синең урыныңда булсам, елый-елый егетләр артыннан йөрмәс идем!

Чәчкә. Кеше ялгыш юлга кереп китәргә торганда, кайбер кызлар кебек борчак чүмәләседәй ишелеп утыра алмыйм!

Разия. Аның юлының ялгышлыгын каян беләсең?

Чәчкә. Ничек шуны аңламыйсың, Разия? Болай да җилбәзәк, чуар йөрәк. Чыгып китсә, кем булып кайтыр?

Разия. Гыйшкым көчле, шуңа күрә тагылырга торам диген...

Чәчкә. Анысы да бар. Әмма болай да мин Гәрәйне ташламас идем. Ул бит безнең иптәшебез.

Разия. Ташласана хушбуйлы сүзләреңне! Синең нигә шулай сукалавыңның сәбәбен белми дисең инде? Беләм, нигә кергәнеңне дә беләм. Монда сине Мәүлә, җибәрде бит!

Чәчкә. Түгел! Хәер, ул җибәрсә, ни булган?

Разия. Бар, диде, шул кызыйга ярдәм ит, диде. Шулаймы? Бәхетен табарга булыш, диде. Үзем белмәгәнне, үзем күрмәгәнне ничек табышырсың икән? Бәхет — сүз түгел бит ул, Чәчкә... Мин аның ни икәнен белмим.

Чәчкә. Разия, мин сиңа үпкәлим.

Разия. Ә мин сиңа, бөтен дөньяга әллә кайчан үпкәләгән инде, шулай да түзәм. (*Ярсып тәрәзә янына килә, урамга карый, кычкырып җибәрә.*) Әткәй кайта! Кит тизрәк, чык!

Чәчкә. Әткәй, әткәй... Кеше төсле генә сөйләшә башлыйсың... (*Киенә.*) Утыр инде күзле бүкән шикелле үз күләгәңне үзең саклап!

Разия. Кеше килгәнне яратмый бит.

Чәчкә. Үзең дә яратмыйсың инде, атаңа сылтыйсың гына. Ул читтә чакта да бик кинәндермәдең. (*Чыга.*)

Р а з и я. Койма буйлап кына йөгер, күрмәсен! Фермага төшкәндә безгә кагыл! (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Х ө р м ә т у л л а белән Х ә б и р керәләр.

Х ө р м ә т у л л а. Әйдүк, Мөхәммәтхәбир, әйдүк! Рәхәтләнеп чишенеп җибәр, Аллага шөкер, өй җылы.

Х ә б и р. Кызың өйдәме, Хөрмәтулла абзый? (*Чишенә.*)

Х ө р м ә т у л л а. Өйдә, өйдә... Тик минем кызым таушалмаган ефәк ул! Сүземнән чыкмый, шөкер. Яхшы ата баласы инде, кем, Хәбир! (*Утырышалар.*)

Х ә б и р. Бер кузгалгач, шактый йөрдең син. Кайларда булдың?

Х ө р м ә т у л л а. Алай ерак китмәдек. Договорны төньякка дип төзегәннәр иде, Пермь тирәсеннән узмадык.

Х ә б и р. Йөргән җирләрдә шәп булды дисең инде?

Х ө р м ә т у л л а. Ялгыштың син минем белән китмичә! Вербовщик килгәч ни кыстадым, язык дидем. Йөргән аякка йөрем иярә, менә кырык фесметр агачка язуын тоттырып ук җибәрделәр. Мондагы лесничийга ачкыч яратсаң, кырык янына тагын бер кырыкны өстәрбез!

Х ә б и р. Кырыклысы гына яшәсен, һай эттәгенәсе!

Х ө р м ә т у л л а. Синең өй дә бик кыегайган, ямьшәйгән икән... Алла теләсә, менә сиңа да бер буралык агач чыгарырбыз.

Х ә б и р. Быел ук кузгата алмам, хәл җитмәс, Хөрмәтулла абзый. Бала-чага да ишле, әллә ни мантып булмый...

Х ө р м ә т у л л а. Аңлыйм, бик аңлыйм! Колхозның аның, үлмәслек бирсә, шуннан артмас инде. Аптырама, менә авыл советының диләнкәсен кисәргә алмакчы булып торам. Миңа шәп кенә бер иптәш кирәк булачак. Бер җәй эшләсәң, үзеңне буралы итәм дә куям!

Х ә б и р. Ай-һай, Хөрмәтулла абзый! Колхоз җибәрмәс, хәзер ул чутка бик катыланды бит, син белгән заман түгел!

Х ө р м ә т у л л а. Катыланды? Эш башында әлеге дә баягы Бикбулат ич! Өшегән нәрсә! Председатель итеп сайлаганда ук кул селкедем мин аннан. Әгәр ул каты куллы булса, син алардан да уздыр! Алар чуерташ икән, син алмаз бул. Үзем көйләрмен, курыкма.

Х ә б и р. Алар дип, без бергә уралабыз инде...

Х ө р м ә т у л л а. Китмичә зур хаталык эшләдең син! Муеннан бата-чума урман кисеп йөрү рәхәттин булмаса да, монда уен эредән бара. Балта чапкан саен, көмеше чылтырый, агачны еккан саен, кәгазе кыштырдый! Агачы ява тора, алтыны ява тора! Менә!

Х ә б и р. Кит аннан! Килсә дә килә икән бәхет адәм баласына!

Х ө р м ә т у л л а. Умырдым инде, шөкер изгеләргә, умырдым!

Х ә б и р. Без дә тик ятмыйбыз! Безгә ни, монда да әйбәт!

Х ө р м ә т у л л а. Язга чаклы кайтмаска да уйлаган идем, сагынылды. Хәзрәт үлгәнен ишеткәч, күңелләр нечкәрде, эх-х!..

Х ә б и р. Гүр иясе булды шул...

Х ө р м ә т у л л а. Урыны оҗмахның түрендә булыр, бик әйбәт яшәде. Байлыгы да бар иде, ил алдында абруен да тотты. Сүзе үтә иде мәрхүмнең, мине бик якын күрә иде... Җеназасын кем укыды? Кем соңгы юлга озатты?

Х ә б и р. Минәчтин абзый маташтырды.

Х ө р м ә т у л л а. Тапкансыз инде кешесен дә! Минәч карт ни белә ул? Ике бозауга кибәк аера алмаганны!

Х ә б и р. Тырмаштыргандыр инде.

Х ө р м ә т у л л а. Монда тырмаштыру гына аз! Ходай каршысына басарлык итеп озата белергә кирәк, күңел белән, кем, Хәбир! Әйе, картлар сирәгәя, теге дөньяда нәнкир-мөнкирләр белән очрашыр чак җитә. Йә, адәм уллары, дөньялыкта ничек яшәдегез, дип сорарлар бит, ә?

Х ә б и р. Эш арасында аларны уйларга вакыт та калмый дигәндәй...

Х ө р м ә т у л л а. Хәзрәт үлгәнгә кайгырдыкларммы соң? Авыл картларын әйтәм, аксакалларны?

Х ә б и р. Кайгырдылар дип, ашын ашаган, яшен яшәгән, без дә үләчәк...

Х ө р м ә т у л л а. Ничек соң, намазлыкны онытып бетермиләрме?

Х ә б и р. Кем ничектер инде, мин үзем гает көнне бер укыйм да, корбан бәйрәмендә бер маташтырам...

Х ө р м ә т у л л а. Ярамый алай, Хәбир туган!.. Кызым, Разия! Чәй куеп җибәр! Менә Хәбир абыеңны сыйларбыз. Кала күчтәнәчләре дә ашарсың, Алла боерса...

Х ә б и р. Мәзәк, икмәктер мәзәк! Үзгәргәнсең син! Байтак аракы эчтек синең белән, Хөрмәтулла абзый!..

Х ө р м ә т у л л а. Тәүбә диген!.. Тәүбә!.. Хәзер мин әйтәм, хәзрәт урынына кемнерәк чамалап торасыз?

Х ә б и р. Исән чакта әллә ни кирәген күрмим, үлгәч кем булса да ярар, дим.

Х ө р м ә т у л л а. Ничек алай ярар? Тузга язмаганны сөйлисең, Хәбир туган!

Х ә б и р. Бөгештермә инде, Хөрмәтулла абзый! Яртың булса, кая, салыйк та, фермага төшәсем бар!

Х ө р м ә т у л л а. Тәүбә диген, ахмак! Иманың юкмы әллә синең? Менә, йөргән җирләрдән бик дәртләнеп кайттым әле. Әллә, мин әйтәм, Ходаның рәхмәте белән авылыбызда мәчет салып җибәрик микән, дим.

Х ә б и р. Бәладән башаяк! Әллә ниләр бутама әле син!

Х ө р м ә т у л л а. Шыр җибәрмә! Совет үзе рөхсәт итә!

Х ә б и р. Итсә дә, кемгә кирәк ул мәчет? Уку өе бар, клубы бар, киносы көн дә. Яңа мәктәп салырга җыенабыз. Кем йөрсен ул мәчеткә?

Х ө р м ә т у л л а. Син! Адәм балаларының җаннары турында син уйлан! Тәмуг кисәве булып бетәбез бит!

Х ә б и р. Кеше ни дисә, миңа шул ярый. Кирәк дисәләр, әйдә чурт с ним, кирәк! Киңәш чутына килгәндә, минем грамыт ягы бик чамалы. Терлек-туар көтеп гомер уздырдым. Кышын каравылчы, җәен көтүче.

Х ө р м ә т у л л а. Барыннан да бигрәк син — кеше! Мөселман!

Х ә б и р. Ярый-ярый, син әйткәннәрне картлар арасында кузгатып карармын.

Х ө р м ә т у л л а. Менә-менә, мәчетсез булмый, диген. Аның бит никахы, сөннәте дигәндәй. Тукта әле, син азрак акча булмасмы дигән идең бугай. Мәле, бер-ике йөзне тот әле.

Х ә б и р. Рәхмәт инде. Озак тотмам. Кызга яңа пәлтә алдык та менә кысылып калдык.

Х ө р м ә т у л л а. Изге нияттә тор.

Х ә б и р. Һе, урман кисәргә түгел, хаҗга барган кеше күк сөйләшәсең, ә!

Х ө р м ә т у л л а. Тукта, чәй эчеп китәрсең.

Х ә б и р. Эчкән чаклар булыр. Фермага төшәргә вакыт. Иншалла, бөтенләйгә кайткансыңдыр?

Х ө р м ә т у л л а. Бөтенләйгә, боерган булса. Тыныч кына, матур гына авылда яшисем килә. Хуш, алайса. Кара, кешесен белеп, чамалап сөйләш. (*Хәбирне озатып, Разияга кычкыра.*) Әй, син! Йокладыңмы әллә? (*Разия керә.*) Нигә кунакка чәй кертмәдең?

Р а з и я. Кушмадың ич.

Х ө р м ә т у л л а. Йә, ярар, килгән бер ачкакка чәй әрәм итеп булмас. Самоварың кайнадымы? Керт монда, үзең дә утыр.

Р а з и я. Хәзер кертәм. (*Табын әзерли.*)

Х ө р м ә т у л л а. Синең эшләр пешә бугай анда. Идарә янындагы тактада фамилиябезне күрдем. Мине язганнар дип куркып китсәм, син икәнсең. (*Чәй эчәләр.*)

Р а з и я. Мин ул.

Х ө р м ә т у л л а. Ярар. Алла боерса, ферма сыерларын савып, тирес көрәп йөрүдән туктарсың. Эшләр җайга салынырга тора.

Р а з и я. Әлегә зарланмыйм. Иптәшләр бик әйбәт. Күңелле.

Х ө р м ә т у л л а. Менә мине ныграк карарсың. Тәрбия ягы да күбрәк соралыр хәзер, картаеп барам. (*Пауза.*) Шикәреңне ваграк, ипиеңне зуррак кабып эч.

Р а з и я. Ярар.

Х ө р м ә т у л л а. Капка ачылды түгелме?

Р а з и я. Җил шаярадыр.

Х ө р м ә т у л л а. Аңгыра күке! Нинди җил булсын! Җыештыр ятьрәк чәеңне! (*Үзе, самоварны эләктереп, кече якка чаба. Табынны тиз-тиз җыештырып алалар.*)

Разия кече якка чыга. Б и к б у л а т керә.

Б и к б у л а т. Рөхсәт бармы керергә? Исәнмесез.

Х ө р м ә т у л л а. Һе, Бикбулат түгелме соң бу? Саумы, туганкай! Хурлап йөри дисәм, хак булмас, чәйдән генә купкан идек...

Б и к б у л а т. Кайтуыңа атна була, Хөрмәтулла абзый, идарәдә күләгәңне күрсәтмисең. Мактаргамы шул кешене, хурларгамы?

Х ө р м ә т у л л а. Кайткан кеше янына килгәндә чибәррәк була инде ул, Бикбулат. Җае шулай аның, җоласы шул. Күчтәнәченнән авыз итәсең, тегесе-монысы. Яле, Разия кызым! Яңарт чәеңне! Абзаңны сыйлап җибәрик.

Б и к б у л а т. Чәйләп үк тормам, өйдән ныгытып чыктым.

Х ө р м ә т у л л а. Аннары бик картаелды, Бикбулат. Иртән торуга, аякларым гөбе булып шешә менә.

Б и к б у л а т. Ай-һай, бетәшәсең әле син. Авырыйм, карт, дисең, үзең ике ел урман кисеп яттың.

Х ө р м ә т у л л а. Кая инде урман, исеме генә шунда! Каравыл өендә мич ягып, әрдәнә сакладым.

Б и к б у л а т. Ялгышмасам, син өч елга договор төзегән идең?..

Х ө р м ә т у л л а. Сагыныллы димме... Тазалык та шәптән түгел, иртәрәк кайттым.

Б и к б у л а т. Акчаны күрәдеңме?

Х ө р м ә т у л л а. Кая инде, җан асрарлык биреп тордылар.

Б и к б у л а т. Самолетта кайткансың ич.

Х ө р м ә т у л л а. Кырып-себереп, кесә төбен кагып инде! Бер утырасы да килеп китте.

Б и к б у л а т. Әллә бик ашыктыңмы? Колхозны сагындыңмы?

Х ө р м ә т у л л а. Кадап сөйләшәсең, кем, Бикбулат. Без колхозның үги баласы түгел лә...

Б и к б у л а т. Хак сөйлисең. Әгәр уеңда да шул булса, әйбәт! Кайтуыңны ишетеп шатландым.

Х ө р м ә т у л л а. Бер-бер йомышың булгандыр, мөгаен.

Б и к б у л а т. Балтаң кыстырып чыгып китмәссеңме инде?

Х ө р м ә т у л л а. Берәр яры ризык тартмаса, бөтенләйгә...

Б и к б у л а т. Үзең өчен генә сорамыйм, Разияга бик кыен бит.

Х ө р м ә т у л л а (*сагаеп*). Аңа ни булган?

Б и к б у л а т. Шулкадәр хуҗалыкны еллар буе ялгыз сөйрәп кара әле! Нигә интегәсең, сат сыерыңны, бер көтү сарык асрама, дип кат-кат әйттем үзенә.

Х ө р м ә т у л л а. Кала марҗасы күк сумка тоттырмакчы син минем кызга, Бикбулат, шулаймы?

Б и к б у л а т. Фермадан алганы да бик җиткән. Елына күпме алганын беләсеңме син аның? Хәер, белмәсәң, ике елга бер генә тапкыр булса да акча салыр идең.

Х ө р м ә т у л л а. Курыкма, балам өчен, үз каным өчен тырышам! Тукта әле, син нәрсә ул кадәр Разия да Разия дип сайрыйсың? Кеме син аның? Мин аның әтисе, мин аны карыйм. Тәрбия итәм. Ә синең ни дәхелең бар?

Б и к б у л а т. Разия минем дә кызым ул. Уйлап кара әле, синең юньле-башлы авылда торганың бармы? Юк бит! Син күрмисең бит аның ничек интеккәнен, без күрәбез.

Х ө р м ә т у л л а. Нинди интегү? Нинди сүз бу? Бикбулат, кызым бер генә! Яшәгәнем аның өчен. Дөньялыкта миннән ул кала! Мин исән чакта безнең арага чөй какма! Ишеттеңме?!

Б и к б у л а т. Алай...

Х ө р м ә т у л л а. Менә шулай.

Б и к б у л а т. Авылда нишләргә уйлыйсың инде?

Х ө р м ә т у л л а. Дөньяныкын белеп булмый, мин алай план төзеп яшәргә яратмыйм... Бик картаелды, бик бетәштем...

Б и к б у л а т. Балаларга яңа мәктәп төзеп бирергә булдык. Яңача итеп. Ике катлы. Менә кара әле. (*Сызымнар күрсәтә.*)

Х ө р м ә т у л л а. Мәктәп? Яле, яле, күрсәт. Шушындый мәктәпне бездә салмакчысыз, ә? Валлаһи, шәп була! Шәп! (*Пауза.*) Мәктәп кирәк нәрсә, әлбәттә, авыл күрке... Тик андый зур эшкә акчагыз җитәрлекме? Теге... күпмегәрәк чамалап торасыз?

Б и к б у л а т. Проекты өчен генә дә йөз меңне түләдек.

Х ө р м ә т у л л а. Йөз меңне? Осталарга күпме бирергә уйлыйсыз?

Б и к б у л а т. Күпме хезмәт көне куелган, шунча булыр.

Х ө р м ә т у л л а. Хи-хи! Ора алмас зур күтәрер, ди.

Башлап ташларга уйлыйсыз икән. Хезмәт көненә кем мәктәп җиткерсен?

Б и к б у л а т. Киләсе хуҗалык елында акчалата түләүгә күчәргә уйлыйбыз, быелга юк. Син киткәннән бирле читтән яллап эшләткәнебез юк югын, менә дигән төзүчеләр бригадабыз бар.

Х ө р м ә т у л л а. Андый осталарың булгач, нигә Хөрмәтуллага килдең соң?

Б и к б у л а т. Осталарның күбесе яшьләр. Арада бер өлкән кеше начар булмас иде.

Х ө р м ә т у л л а. Санга сугып килүең өчен рәхмәт. Мәктәпләр белән кайнашырлык көчем калмады, Бикбулат.

Б и к б у л а т. Эшләмичә ята торган кеше түгел син. Күптәннән бер-беребезне беләбез. Алтын куллы кеше бит син, Хөрмәтулла абзый. Тик элеккеге еллардагы кебек балта күтәреп күрше колхозларны каезларга чыгып китә алмыйсың хәзер, заманасы үтте.

Х ө р м ә т у л л а. Яшь чагында таулар актардык та бит.

Б и к б у л а т. Үз колхозыңда казык та какканың юк синең!

Х ө р м ә т у л л а. Саулыгым булса, синдәй председательнең сүзләрен аяк астында калдырыр идемме соң?!

Б и к б у л а т. Бәяңне күтәрергә чамалама, заман һәрберебезгә үз бәясен куйды хәзер!

Ишектә М ә ү л ә күренә.

М ә ү л ә. Керсәм ярыймы, Бикбулат абый?

Б и к б у л а т. Әнә хуҗадан сора.

М ә ү л ә. Хуҗаның җавап бер... Сезне монда китте дигәч чыдамадым, йөгердем.

Б и к б у л а т. Менә шушы атаман үзенең егетләре белән фермаларны җиткереп куйды инде, Хөрмәтулла абзый.

Х ө р м ә т у л л а (*мыгырдый*). Һем... һем... яхшы!

Б и к б у л а т. Һәм әйбәт эшләделәр.

М ә ү л ә. Мәктәп проектын карарга җыенган идек тә.

Б и к б у л а т. Менә ул.

М ә ү л ә. Нигә күрсәтәсез сез аларны бу кешегә?

Б и к б у л а т. Тукта әле, олы кешеләр алдында нәрсә дип тупас сөйләшәсең?

М ә ү л ә. Бикбулат абый, сез җавап бирмәдегез миңа.

Б и к б у л а т. Киңәшәбез.

М ә ү л ә. Аның беләнме? Беләсезме соң сез аның кем икәнен!

Б и к б у л а т. Мәүлә энекәем, бу бит мәктәп! Мәктәп! Монда тере кешеләр укыячак. Фермада теге яки бу уры-

ны килеп бетмәсә дә сыерлар дәгъва белән йөри алмаслар...

М ә ү л ә. Без начар эшләдекме?

Б и к б у л а т. Күз алдында мактап торам лабаса! Тик Хөрмәтулла абзый кебек оста белән киңәшеп алабыз икән, монда баш ярылып, күз чыкмаган.

Х ө р м ә т у л л а. Курыкма, авызыңнан калҗаны тартып алырга җыенмыйм.

Б и к б у л а т. Менә күрдеңме, эш сызымнарга барып җитмәде дияргә дә була.

М ә ү л ә. Бәлки, аны безнең өстән күзәтче итеп тә куярсыз?

Б и к б у л а т. Рәхәтләнеп куям.

М ә ү л ә. Куегыз! Оста, янәсе! Остарды, әлбәттә. Балта осталары сугыштан кайтмады, ә болар шуннан файдаландылар. Кайда тәгәрмәч сугалар, арба-кабык төзәтәләр, уч тутырып акча алалар! Аракы чөмерәләр! Килеп карасын әле мәктәп төзелешенә!

Б и к б у л а т. Киләм дигәне юк бит әле!

Х ө р м ә т у л л а. Куып чыгарам мин сине, малай актыгы!

Б и к б у л а т. Чү, ашыкма. (*Мәүләгә.*) Син дә кызма. Киңәшле эш таркалмас дигәннәр.

М ә ү л ә. Кем белән киңәшәсең бит.

Самовар күтәреп Р а з и я керә.

Р а з и я. Әткәй, чәй кайнады.

Х ө р м ә т у л л а. Чәй? Шушы малайгамы?.. Ә-ә, китер алайса!

М ә ү л ә. Мин чәй эчмим! Йөрәгемә ярамый...

Х ө р м ә т у л л а. Эчмә, эчмә, сакла саулыгыңны.

Р а з и я. Утырыгыз инде, кунаклар. Кузгалмагыз... Әткәйнең күчтәнәчләреннән авыз итегез. Әткәй, кыста, зинһар!

М ә ү л ә. Эчегез, эч, Бикбулат абый, миңа карамагыз. (*Чыга.*)

Б и к б у л а т. Миңа да вакыт...

Х ө р м ә т у л л а. Кергәлә, Бикбулат. Карчыгыңны алып, иркенләп килеп утыр.

Б и к б у л а т. Ишеттеңме, эшчеләр янына кушам дисәң дә, булмый икән әле! Ә синә гомереңдә бер мәртәбә булса да, авыл өчен изгелек кылырга кирәк!

Х ө р м ә т у л л а. Изгелек?.. Ә?! Ни дидең?..

Р а з и я. Китмәгез инде, утырыгыз. Әткәй!

Б и к б у л а т. Рәхмәт, Разия. (*Чыга.*)

Р а з и я. Нигә кыстамадың? Нигә утыртмадың?

Х ө р м ә т у л л а. Сәнәктән көрәк булган Бикбулатның аягына егылырга кушар идеңме? Кирәк тапса, үзе егылсын!

Р а з и я. Кеше төсле матур итеп, чөкердәшеп бер яшәрбезме без, әткәй? Ачылып китеп, иплән кенә бер сөйләшсәң икән! (*Кич була. Бүлмәгә акрын гына караңгылык иңә. Хөрмәтулла уйга чумып бөкрәеп утыра.*) Мин сине шундый көттем, әткәй...

Х ө р м ә т у л л а. Көтсәң, кайттым...

Р а з и я. Бүген әнкәй үлгәнгә сигез ел тулды.

Х ө р м ә т у л л а. Ә-ә? Шулай ук булдымыни? Ай гомерләр, яшәгән кебек тә түгел.

Р а з и я. Онытып та бетердең син аны, бер тапкыр искә алганың юк...

Х ө р м ә т у л л а. Заманалар үзгәрә тора... Җайлаша да, яраша да белергә кирәк... Бары шул гына!

Р а з и я. Нәрсә уйлыйсың, әткәй? Син сөйләшмәгәч, миңа күңелсез.

Х ө р м ә т у л л а. Болай гына.

Р а з и я. Ут кабызып җибәримме?

Х ө р м ә т у л л а. Кирәкми. Нәрсә уйлыйммы? Менә мәктәп. Ике катлы... Миннән башка булдыра алмаслыкларын да беләм, ә барасым, булышасым килми... Җиңелрәк яшәргә иде! Ә син ни уйлыйсың?

Р а з и я. Күңелем синең болай яшәвеңә рәнҗеш белән тулы, башкача берни уйлый алмыйм... Исеңдәме, әнкәй үлгәч озак та тормады сыер бозаулады. Син район үзәгенә пекарня салырга йөри идең... Киттең, бөтен эш миңа өелде... Сыер савулары читен иде дә соң! Елый-елый сава идем. Бармакларымның көче җитмәгәч, менә шулай учларым белән ябыша идем.

Х ө р м ә т у л л а. Үпкәләмә, кызым, төрле чаклар булгандыр.

Р а з и я. Бердәнбер юанычым ак песи баласы иде. Сыер янына чыксам да, ияреп чыга, йокларга ятсам да, янымнан китми. Мин сыер имиеннән туп-туры аның авызына сөт агыза идем. Берзаман шундый остардык, тамчысын җиргә төшермибез! Син кайттың да песи баласын асып куйдың...

Х ө р м ә т у л л а. Булгандыр... Рәнҗеткән чаклар да күп булгандыр. Заманалар, кызым, заманалар!

Р а з и я. Ичмасам хәзер әйбәт кенә, тыныч кына яшик инде!

Х ө р м ә т у л л а. Кызым, түгәрәгем!.. Сулаган сулышым да синең өчен бит! Үги ана кулында җәбер күрмәсен дип өйләнмәдем, салкын түшәктә йоклыйм...

Р а з и я. Кермә Мәүлә белән сүзгә!

Х ө р м ә т у л л а. Нәрсә-ә?! Син тагын сүз әйтмичә тыңлагач та! Туктат вәгазеңне! Ул малайның исемен телгә алсаңмы?..

Р а з и я. Әткәй, мин сине борчырга теләмәгән идем.

Ч ә ч к ә керә.

Ч ә ч к ә. Нигә караңгыда утырасыз?

Р а з и я. Хәзер яндырам. (*Ут кабыза.*)

Ч ә ч к ә. Әнекәем, киенмәгән дә!

Р а з и я. Хәзер китәбез.

Х ө р м ә т у л л а. Ерак барасызмы?

Р а з и я. Эшкә. Фермага төшәсе бар.

Х ө р м ә т у л л а. Көндез төшкәнең җитмәгәнме?

Ч ә ч к ә. Бүген без дежур, төнгә дә калабыз әле.

Х ө р м ә т у л л а. Мин югында да шулай өйне ташлап төннәрен сыерлар янында кала идеңме?

Р а з и я. Булгалады, әткәй.

Х ө р м ә т у л л а. Шәп итәсең икән! Син киткәч, мин монда нишләрмен?

Р а з и я. Аш пешердем. Итен табакка бушатып мич алдына куйдым. Самовар...

Х ө р м ә т у л л а. Моннан болай төшмәссең инде, кызым. Житкәндер. Еллар буе коры-сары ашап ашказаным да авырта, тешем сызлый, миңа тәрбия кирәк.

Р а з и я. Әткәй, эш бит. Юаныч та ул миңа, куанычым да шул.

Х ө р м ә т у л л а. Карт әткәңнең сүзен егасың инде?..

Ч ә ч к ә. Җүләрләнәсеңме әллә, Разия. Күрче, бөтенләй җебеп төшкән.

Х ө р м ә т у л л а. Котыртма!

Ч ә ч к ә. Кем? Минме? Эшләмә дип үзең котыртасың ич!

Х ө р м ә т у л л а. Юньсез, кит... Юкса очырып чыгарырмын.

Ч ә ч к ә. Чыгарды диярләр бит, Хөрмәтулла абзый. Бәйдә тота алмассың, юк. Байтак тоттың инде син аны мунчала тышауда!

Р а з и я. Чәчкә, дим!

Ч ә ч к ә. Кара-кара, сусыз самовар төсле эреп аккан.

Р а з и я. Хәзер, хәзер...

Х ө р м ә т у л л а. Разия, кызым... Уф, күкрәгемә ябышты...

Р а з и я. Чәчкә, бүгенгә үзең генә төш инде, яме?

Ч ә ч к ә. Ике ел үзең генә яшәгәндә, маймылдан кешегә әйләндеңме дип йөри идем, юк икән...

Хөрмәтулла. Бавыр микән бу, бөер микән... Уф, кыса!

Чәчкә. Мә, бая сораган китабыңны алып килгән идем.

Хөрмәтулла. Китабыңны да үзең белән ал, эзеңне сыпырт!

Чәчкә. Разия, әллә телеңне йоттыңмы?

Хөрмәтулла. Өйрәтмә балама юньсезлек!.. Кирәк нәрсәне мин аңа үзем өйрәтермен.

Чәчкә. Сиңа тагын!

Разия (*шелтәләп*). Чәчкә!

Хөрмәтулла. Юньсезләр...

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Апрель урталары. Җылы язгы кич. Эңгер-меңгер иңеп килә. Урам. Клуб яны. Агачлар арасында эскәмиядә Чәчкә утыра. Ул кемнедер көтә, як-ягына карангалап ала. Тыңлана. Урамнан ашыгып Разия үтеп бара, кулында төенчек. Ул Чәчкәне күрмичә узып китә башлый, абайлап, борылып килә.

Разия. Нишләп утыруыңны беләм... Синең кайгыларың миңа булсын иде!..

Чәчкә. Белмисең. Мин ташу акканны тыңлыйм. Урман кары кузгалган, ахры. Сызадан су төшә.

Разия. Кичәге җылы яңгыр кузгаткандыр аны.

Чәчкә. Кеше күңелен җебетерлек тә берәр яңгыр яусын иде. (*Шелтәләп Разияга карый.*)

Разия. Нәрсә дидең?

Чәчкә. Бар инде, бар. Ашыгасың бугай.

Разия. Мәхәббәт яңгыры теләп утырасың икән! Яңгыр боткасы пешер, ырымнарын үтә. (*Китә башлый.*) Ә күзләрең нигә кызарган?

Чәчкә. Чебен-черки кердеме шунда.

Разия. Нинди чебен булсын ди әле?

Чәчкә. Чебен булмаса, җил кергәндер. Барыбер түгелмени?

Разия. Йөрәгеңә таракан кергән синең. Шул тыкырдата торгандыр.

Чәчкә. Рәхмәт.

Разия. Теге җилкуар Гәрәйне көтәсең бит?

Чәчкә. Көтәм.

Разия. Бу кадәрле арыш боламыгы булырсың икән. Елый-елый егет артыннан чабасың. Кешесе кеше булса ярар иде тагын. Исеме дә Гәрәй бит аның. Гәрәй — төрле якка тәгәрәй!

Чәчкә. Калмыйм артыннан. Җилкуар икәнен дә

беләм. Юньсез икәнлеген дә. Шулай да көтәм һәм көтәчәкмен. Тагын ни әйтерсең?

Р а з и я. Әйтерлеген калдырмадың.

Ч ә ч к ә. Кадалып китегез, дисеңме? Юк әле, кадалмыйбыз, бәхетле булырга уйлап торабыз. Синеңчә, кемдер, кайдадыр, Хөрмәтулла картның шундый-мондый кызы бар, ул би-ик хәтәр кыз икән, аңа менә шундыйрак егет кирәк, кәнфиттән әвәләгән булсын, прәннектән катырган булсын дип, әфсенләп-төфсенләп малай үстереп ята дисеңме? Адресыңны тапмаслар! Сөйсәң, аның җилкуарлыгын уйлап тормыйсың. Син генә ул, сырт өстендә тишекле сөяк, берәр җире ошамаса, «ах-ух» килеп җиде чакрым чабасың.

Р а з и я. Нигә алай, нигә болай дип кеше йөрәгендә казынырга барыгыз да оста. Мәхәббәт хирурглары! Бәлки, минем ул йөрәкне берәүгә дә күрсәтәсем килмидер.

Ч ә ч к ә (*сагаеп*). Чү, тыңла әле. Машина гөжли түгелме? Машинамы?

Р а з и я. Юк, су гына шаулый.

Ч ә ч к ә. Исән-сау кайтып җитә алса гына ярар иде.

Р а з и я. Кайтыр.

Ч ә ч к ә. Юатырга омтылып та карамыйсың инде, таш бәгырь!

Р а з и я. Мин эш белән юанам, әйдә фермага!

Ч ә ч к ә. Иртәрәк бит.

Р а з и я. Китапханәгә кереп тор, монда бик салкын.

Ч ә ч к ә. Кермим. Кайтып җиткәнен үз күзләрем белән күрим дим. (*Пауза.*) Бар инде, ашыга идең бит.

Р а з и я. Анда да күңелсез, эшкә кул бармый. (*Пауза.*) Син мине ярышка чакыргансың икән.

Ч ә ч к ә. Әйе, син тагын җыелыштан качкан идең.

Р а з и я. Качмадым. Вакыт булмады. Әткәй кайткач, өй арасыннан һич бушап булмый. (*Пауза.*) Ярышсыз да савармын әле. Инде бик кысасың икән, мине җиңдем дип уйла.

Ч ә ч к ә. Көрәшсез генә җиңү кирәкми миңа.

Р а з и я. Башкалар белән көрәш, беткәнмени кызлар фермада!

Ч ә ч к ә. Минем синең белән ярышасым килә. Һәм җиңәсем килә.

Р а з и я. Теләгем юк.

Ч ә ч к ә. Нигә инде, дустым?

Р а з и я. Кайвакытта сезнең кебек буласым килә... Яныгызга йөгереп, йөгереп түгел, очып барыр идем!.. Шатланасым, онытыласым, юньсез малайларга гыйшык тотасым килә!.. Бусага янына килəм дә тукталам... (*Чыга.*)

Ч ә ч к ә. Разия, Разия! Төенчегеңне оныттың!

Р а з и я (*керә*). Төенчек? Минме? Бөтенләй хәтеремнән чыккан. Тукта әле, нигә үзем белән алдым соң әле мин боларны? Исемә төште! (*Эскәмиядән төенчеген алып, чыга башлый. Ферма ягыннан килүче Мәүлә күренә. Аны күргәч тә Разия кире борылып килә.*)

Р а з и я. Чәчкә, Чәчкә! Кая качасың?

Ч ә ч к ә. Китапханәдә йомышым бар! (*Чыга.*)

Мәүлә керә.

М ә ү л ә. Йөз елга бер булса да ялгыз очрашырга язган безгә. Исәнме, Разия.

Р а з и я. Исәнме.

М ә ү л ә. Фермадан кайтып киләм.

Р а з и я. Кая бардың дип сорамадым ла, Мәүлә.

М ә ү л ә. Сине күрергә дип төшкән идем.

Р а з и я (*куркынып*). Бер-бер хәл бармы әллә?

М ә ү л ә. Булмыйча!

Р а з и я. Нәрсә булды, Мәүлә? Кулыңда нәрсә ул?

М ә ү л ә. Минем контроль эшләрем кайтты. Сызылмалы геометриядән шулкадәр куркып йөргән идем, беләсеңме, миңа бишле куеп җибәргәннәр!

Р а з и я. Чынмы, Мәүлә? (*Дәфтәрләрне карый башлый.*) Боларның барын да син үзең эшләдеңме?

М ә ү л ә. Шундый сөендем! Алу белән синең янга фермага йөгердем.

Шул вакытта агач башында карга кычкырып җибәрә, Разия дәфтәрләрне жиргә коя.

Р а з и я. Ай!

М ә ү л ә. Курыкма, буялмады.

Р а з и я. Аны әйтмәгән идем... Кояш баеганда карга кычкырганны ишетсәң, яхшыга түгел ди безнең әткәй.

М ә ү л ә. Ә сандугач сайравын ишетсәң?

Р а з и я. Анысы, мөгаен, яхшыгадыр!

М ә ү л ә. Нинди матур синең елмаюың!.. Телисеңме, мин бүген төне буе сезнең тәрәз төбендә сандугач булып сайрыйм.

Карга тагын кычкыра.

Р а з и я. Китим әле, китим!

М ә ү л ә. Әбиләр әкиятенә ышанып борчыма, зинһар, үз-үзеңне!

Р а з и я. Бер дә әкият түгел. Менә мин синең фермага барганыңны күрмәсәм дә, синең анда икәнлегеңне белдем бит.

Мәүлә. Менә бусы кызыграк!

Разия. Бер дә кызык түгел, ышанмыйсыңмы? Мә, кара. Менә боларны сиңа кайтарып бирергә дип алган идем.

Мәүлә. Бүләкне кире кайтармыйлар.

Разия. Мә перчәткәләреңне... Мә, шәһәргә баргач берәр матурга бүләк итәрсең. Рәхәтләнеп кисен!

Мәүлә. Алмыйм.

Разия. Ал, ал... Бүген өй җыештырганда килеп чыкты. Күз көеге булып ята, күренгән саен җанны әрнетеп.

Мәүлә. Үземне дә, бүләгемне дә каһәрлисең...

Разия. Сыймый алар минем кулга, Мәүлә!.. Кулларым...

Мәүли. Китмә!

Разия. Кичке савымга соңга калдырасың.

Мәүлә. Бүген клубка чыгасыңмы?

Разия. Нишләп йөрим, аяк асты бик пычрак бит!

Мәүлә. Иртәгә иртәнчәк яңа мәктәпнең нигезен салабыз. Карарга киләсеңме?

Разия. Вакыт булмас бит, Мәүлә.

Мәүлә. Алайса, сүзем бетте. (*Разия чыга башлый.*) Килерсең дип уйлаган идем. Мин, иптәшләр белән, беренче тапкыр мәктәпкә ышанып тотынабыз... Синең балаларың өчен, минем малайлар өчен...

Разия. Аякларым боз булып катты.

Мәүлә. Килмисең, алайса?

Разия. Килә алмам шул... Кулдан килмәгәч, вәгъдәсен дә бирмим. Хуш, Мәүлә. (*Йөгереп диярлек чыгып китә.*)

Мәүлә эскәмиягә утыра, тәмәке кабыза. Кулына таяк алып җирдә сызыклар сыза башлый. Чәчкә керә.

Чәчкә. Тел белән әйтеп бетермәгәннәрен җиргә язарга булдыңмы?

Мәүлә. Әллә тыңлап тордың?

Чәчкә. Нишләп тыңлыйм?.. Кыяфәтең күшеккән күркәнекенә охшаган. Шуңа әйтүем.

Мәүлә. Синеңчә, шушы хәлдә мин арыслан күк ыргылып торырга тиешлеме?

Чәчкә. Арыслан күк үк булмасаң да, куян төсле сикергәләп тор, ичмасам. Сөеклеңне күргәнсең, борының салынган.

Мәүлә. Чәчкә, аңлата аласыңмы: нигә кешеләр бертөсле туалар, үлгәч тә бертөсле тын гына яталар, нигә алар бертөсле яши, сөя алмыйлар икән?

Чәчкә. Әйем лә, үземнеке белән дә баш каткан! Син шуны әйт менә, Гәрәйләргә бер-бер хәл булмагандыр бит?

М ә ү л ә. Булмас дип өметләник. Идел бозы кузгалмаган әле. Яңгыр явар дип кем уйлаган.

Ч ә ч к ә. Юл бетәчәге көн кебек ачык иде. Син җибәрдең аны!

М ә ү л ә. Мин?!

Ч ә ч к ә. Тагын кем булсын? Бикбулат абый өйдә юк.

М ә ү л ә. Гәрәйне тотып буламы соң? Цементка нәрәт кайтканын ишетүгә идарәгә йөгереп килгән. «Станцага мине җибәрегез, кайтсам, үзем алып кайтам, кайтмасам, юл төшкәнне көтеп ятачакбыз!» — дигән. Дөрес инде, бүген кайтып җитмәсә, үзе дә бүленеп кала, эш тә өзелә.

Ч ә ч к ә. Син шулай дип ашкындыргансың аны!

М ә ү л ә. Кабинага утырганда итәгенә ябышып ялындым!..

Ч ә ч к ә. Кайтып җитсә, миңа хәбәр иттер әле.

М ә ү л ә. Кош булып очып төшәрмен!

Ч ә ч к ә. Онытма!.. Мәүлә, ярыш договорларын кабат карарга туры килә, Разия минем белән ярышудан баш тартты.

М ә ү л ә. Нишли ул кызый?.. Ашыкмый тор әле.

Ч ә ч к ә. Ашыгасы да, көтәсе дә юк. Онытма, яме! (*Чыга.*)

Мәүлә ялгызы. Б и к б у л а т керә.

Б и к б у л а т. Әй, Мәүлә! Тукта әле!

М ә ү л ә. Кайтып җиттеңме, Бикбулат абый?

Б и к б у л а т. Кайтып та җиттем, ишеттем дә.

М ә ү л ә. Безнең халык язлыкта сөйләмичә түзәме соң? Авызлары ерылган — яз!

Б и к б у л а т. Йөрергә өйрәнмәгән килеш чабарга тотынгансың, энем.

М ә ү л ә. Ничек алай?

Б и к б у л а т. Бригадирлар риза булмаган. Парторг каршы чыккан. Кем рөхсәте белән Гәрәйне цемент алырга җибәрдең?

М ә ү л ә. Мин гаепле.

Б и к б у л а т. Председатель авылдан чыгып китүгә шундый хәл! Мин дә гаепле, димәк. Кадрларны үстерә белмәгәнмен.

М ә ү л ә. Гәрәй тәҗрибәле шофер, машинага берни булмас.

Б и к б у л а т. Юатты берәүләр! Үзе исән-сау кайтырмы? Менә мәсьәлә кайда! Машина... Машина табылыр! Әле генә телефоннан шалтыраттым, Идел өстенә су чыккан, берәүне дә уздырмыйлар.

М ә ү л ә. Яңгыр явар дип уйламадык шул.

Б и к б у л а т. Бала-чагаларча кылангансың. Оят!

М ә ү л ә. Алай бик картларны яратасыз икән, әнә Мотыйгулла абзыйга да күз төшерегез. Ишек яңаклары, наличниклар ясарга тиешле оста өч көн инде эшкә чыкмады.

Б и к б у л а т. Аңа нәрсә булган тагын?

М ә ү л ә. Ураза тота! Авыр эшкә ярамыйм, ди.

Б и к б у л а т. Зимагур Мотыйгулла ураза тотамы?

М ә ү л ә. Сезнең җан дустыгыз, киңәшчегез Хөрмәтулла болгата. Авылда сүзләр йөри башлаган. Имеш, гомер буе шабашкыда йөргән Хөрмәтулла да Аллага ышана башлагач, дин кайта икән, мәчет салалар икән, дип сөйлиләр.

Б и к б у л а т. Эчем пошып тора иде, рәхәтләнеп көлдердең, рәхмәт.

М ә ү л ә. Ул Хөрмәтулла эшне бозып ташламасын, дим. Иртәгә нигез ташлары салырга картларны чакырган идек. Килмәсәләр ни кылырбыз?

Б и к б у л а т. Картлар белән җайларбыз! Гәрәйләр башымнан чыкмый!.. Син дә шул. Мондый чакта кешене юлга чыгаралармы соң?

М ә ү л ә. Түзәр чама калмады, Бикбулат абый. Сынап карыйсы килә, эшкә тотынасы килә?

Б и к б у л а т. Муенын сындырса, кем җавап бирер?

М ә ү л ә. Үзем.

Б и к б у л а т. Йә, ярый! Молодцы! Аңлыйм мин сезне! Сабан туе җиткәч, чабыш атын аранда кем тота ала? Көне җиткәч ястык калынлыгы Идел бозы да кузгала!.. Әйдә идарәгә! Тагын шалтыратып карыйк. Узып китмәгәннәрме? (*Ашыгып идарәгә китәләр.*)

Урамнан йөгереп килүче Г ә р ә й каршыга килүче Х ө р м ә т у л л а белән бәрелешә.

Х ө р м ә т у л л а. Тфү, дөмеккерләре! Бөтенесенең дә күзе чыккан инде әллә?

Г ә р ә й. Үзеңә саграк булырга кирәк, абзыкаем.

Х ө р м ә т у л л а. Бәй, Миңнулла малае түгелме соң син?

Г ә р ә й. Бүген иртәнгә тиклем шул исемне йөртә идем.

Х ө р м ә т у л л а. Хәзер үзгәрдеңмени, әкәмәт?

Г ә р ә й. Үз ирегем белән Иделдәге бозлы суга чумып чыктым. Янымда поп кына булмады... Чуаш көмешкәсен эчтем дә урыс мич башына менеп җылындым. Кем булам мин хәзер?

Х ө р м ә т у л л а. Бәрәкалла! Сине уйлап килә идем, Мөхәммәтгәрәй. Уйлап та бетердем, каршыма тып итеп килеп чыктың. Яхшыга бу, Аллаһе боерса.

Г ә р ә й. Авыз ачарга барыйк дисәң, булмый. Әле генә

бер сарык боты белән унике тәлинкә ашны әйләндереп салдым.

Хөрмәтулла. Авыз ачарга түгел...

Гәрәй. Йомарга дисәң дә башка иптәш эзлә. Кояш баеганнан соң авызымны йомып тора алмыйм, җырлыйсым килә!

Хөрмәтулла. Чак кына сабыр ит инде, Ходай кошы.

Гәрәй. Мәчет салырга акча сорасаң, бирмим. Дин — эфьюн. Белдеңме?

Хөрмәтулла. Тукта инде, тәтелдәдең! Авылдан китәргә чамалыйсың дип ишеттем.

Гәрәй. Син карт зимагур, Хөрмәтулла абзый, киңәшләрең бармы?

Хөрмәтулла. Киңәшнең дә ниндие әле!

Гәрәй. Давай киңәшеңне, тик сәдака сорамаска! Килештекме?

Хөрмәтулла. Әллә безгә кереп утырабызмы?

Гәрәй. Идарәгә чабам.

Хөрмәтулла. Сүзем зурдан иде, аны урам уртасында кузгату читен... Бераз читкәрәк китмибезме, ичмасам?

Гәрәй. Турысын гына суктыр да бетерик.

Хөрмәтулла. Менә син ятим үскән бер малай. Гомерең әби-бабаңның бозавын көтеп узды. Күпме кыен ашадың...

Гәрәй. Тарихка кагылма син, тимә аңа!

Хөрмәтулла. Хәзер үзәгенә барып җитәм. Ни өчен читкә китәргә теләвеңне дә беләм. Иркенәясең килә синең. Читтә дә читне табу кыен хәзер, Мөхәмммәтгәрәй! Аю базлары бетте алар!.. Кайда да иркенәергә була. Аның өчен акча гына кирәк.

Гәрәй. Булса зыян итми, әллә биреп торасың?

Хөрмәтулла. Яшәгән саен, олыгайган саен кешеләргә күбрәк ярдәм итәсе килә.

Гәрәй. Кара әле, шәп кеше икәнсең син, Хөрмәтулла абзый! Кая, бир.

Хөрмәтулла. Нәрсәне?

Гәрәй. Акчаңны!

Хөрмәтулла. Ашыкма! Акча агач башында әле ул!

Гәрәй. Хәзинә яшердеңме?

Хөрмәтулла. Яратам җор егетләрне, хи-хи! Менә миңа бик акчалы бер урын эләгергә тора. Алтын күл инде менә. Тот та чум.

Гәрәй. Чумарсың да, алтынны күп эләктереп быкыр-быкыр төпкә китәрсең. Куркыныч.

Хөрмәтулла. Валлаһи, кәмит икәнсең син!

Идарә ягыннан М ә ү л ә килә.

М ә ү л ә. Гәрәй кайткан! Үзең генәме, машинаң да иярдеме?

Г ә р ә й. Гәрәй, Гәрәй кайткан, бүләк алып кайткан! Комачауладың. Без монда Хөрмәтулла абзый белән чуму буенча спорт секциясе оештырырга тора идек. Тем более, минем тәҗрибә дә бар.

М ә ү л ә. Булдымы, алып кайттыңмы?

Г ә р ә й. Сөйләп бетер, Хөрмәтулла абзый, бу егеткә карама, шундый дуамал инде ул!

Х ө р м ә т у л л а. Әйе... Ни, эткәй мәрхүм әйткәндәй, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума, әйе.

Г ә р ә й. Син нәрсәдер башканы сөйли башлаган идең.

Х ө р м ә т у л л а. Машинаң белән берәр юл чыбык-чабык алып кайтып булмасмы дигән идем, сөйләшербез әле, Мөхәммәтгәрәй! (*Чыга.*)

М ә ү л ә. Ярылам бит, сөйлә тизрәк!

Г ә р ә й. Кирәк урында өздең, сере бар иде! Бу карт тиккә генә кайтмаган!

Б и к б у л а т керә.

М ә ү л ә. Исән-сау!

Г ә р ә й. Сәламнәр һәм кәләмнәр!

Б и к б у л а т. Ничегрәк соң, егет, юллар уңдымы?

Г ә р ә й. Көч-хәл белән, әй!

М ә ү л ә. Рәхмәт, Гәрәй, муеннан элмәкне алдың!

Г ә р ә й. Базадагыларның каннарына төштем үзем дә. Бирмәскә маташалар. Имеш, сезнең нәрәтләргә биреләчәк цемент килеп җитмәгән, диләр. Шыпырт кына складка сыздым! Дөнья цементы! Болары кем өчен, дип сорыйм. Беренче чираттагы төзелешләр өчен, диләр. Директорга тузынып мендем, малай, барыбер алдым. Склад мөдире, безнең Хөрмәтулла абзыйга охшаганрак бәндә, ришвәт өметләнеп кенә бирмәгән икән! Тешен шыгырдатып калды!

М ә ү л ә. Рәхмәт сиңа, Гәрәй.

Г ә р ә й. Кызлар күк төчеләнмә инде.

Б и к б у л а т. Юл ничек? Идел нишли?

Г ә р ә й. Юл төрлечә. Идел тик ята. Нигә аңа исегез китә?

Б и к б у л а т. Үткәрмиләр, имеш, диләр. Атлы милиция тора, диләр.

Г ә р ә й. Милиция-мазар күрмәдек, үттек тә киттек.

Б и к б у л а т. Булдырдың, сине мактасаң да урынында.

Г ә р ә й. Соңыннан кемне мактасыларын беләбез! Мәктәпне председатель Бикбулат чакта бригадир Мәүләләр салган иде дип сөйләрләр.

Б и к б у л а т. Мәктәпне салышу сиңа күңелсез булырмы?

Г ә р ә й. Күңелле дип, таш ташырмын инде, бүрәнә, ком...

М ә ү л ә. Бүген цемент алып кайтып җиткереп тә кәефең күтәрелмәдеме?

Г ә р ә й. Кәеф күтәрелде, тик цемент кайтканга түгел, склад мөдире теш шыгырдатып калганга кәеф килде! Әйдә, калсын. Тартырга бирегез әле. Юл буе тәмәкесез интегеп кайттым. Чыланган...

М ә ү л ә. Әй, ашык әле, хәтеремнән чыккан! Фермага чап син, Чәчкә бик көтә иде.

Г ә р ә й. Әллә көтә? Чабам, алайса! (*Тукталып.*) Ә син? Без кайчандыр ул сукмаклардан бергә йөри идек...

М ә ү л ә. Бар инде бар, көйрәп кисәүгә сабышыр!

Г ә р ә й. Кешеләр берәр атнага сөйләшүләрен онытып торсыннар иде. Телдән калгач, ишарәнең, ымнарның ни аңлатканын төшенә башларлар иде, бәлки, алар!

М ә ү л ә. Хикмәтле сүзләр сөйлисең бүген син.

Г ә р ә й. Бүген мин үземне кеше итеп тоям. Бары шул гына! (*Чыга.*)

Б и к б у л а т. Яратам тәвәккәл егетләрне!

М ә ү л ә. Яратасыз?.. Алайса, нигә миңа әләкте әле бая?

Б и к б у л а т. Үзеңне тәвәккәл димәкче буласыңмы? Аяк өстеңдә йоклап йөрисең кайчак! Эх!..

Урам буйлап Х ә б и р йөгереп бара.

Х ә б и р. Кайда Бикбулат? Председатель кайда?

Б и к б у л а т. Хәбир, нәрсә бар? Ник чабасың?

Х ә б и р. Мәүләсе дә монда икән! Рәхмәт сиңа, егет, утырттың мине, уф...

Б и к б у л а т. Сөйлә.

М ә ү л ә. Нишләп мин? Үзең бит, Гәрәй мине станцага утыртып барсын әле, дип ялварып безгә килдең!

Х ә б и р. Олы кыз явыз! Электр үтүге кирәк, күмерлесеннән башка ис тия дип колак итемне кимерде. Күрмәгәнне күрсәтте бу үтүк! Яңадан Гәрәйгә ышанып юлга чыксам, ух мин аны! Машинасына утырасым юк, ярты гомеремне юлда калдырып кайттым.

Б и к б у л а т. Яле, яле, өр әле! Станция буфетлары көнетөне эшли.

М ә ү л ә. Бик әйбәт, бик тыныч йөреп кайттык дип сөйләде ул.

Х ә б и р. Һе, күрдегезме?! Тыныч кына!.. Олы кыз явыз, ул гаепле! Кияүгә алучы да юк бит үзен! Мәүлә, яучыла, бүген тотып бирәм.

Б и к б у л а т. Юньләп сөйлисеңме син, юкмы?

Х ә б и р. Хәйран эшләргә тарыдык, валла! Әй! Иделгә килеп җиттек берзаман. Юл бик җебегән, шурли-шурли киләм. Карасам, боз өстенә су чыккан. Яр буена бер көтү машина җыйналган. Карасы-агы, эресе-вагы... Беттек, калдык, дим үз-үземә. Безнең башкисәрнең исе дә китми. Килеп җитүебез булды, мине кузовка куып менгерде. Кабинасын шартлатып япты. «Бер-бер әкәмәт сизсәң, үзең чамала» ди бу. «Имеш, монда чират саклаудан файда юк, безне анда дуслар көтеп тора». Идел төбендә сине шайтаннар көтә, су аналары, дим тегеңә! Кереп киттек су ерып. Барабыз шулай, барабыз, боз сыгылып-сыгылып кала. Идел уртасы бит! Плащым белән башымнан бөркәндем дә капланып яттым. Теге малай сызгырыпмы-сызгырып бара, милицияләр торба аша кычкыралар, ә аның машинасы улый гына! Аңыма килгәндә чыгып җиткән идек, тегенең артыннан ияргән шоферлар мактыйлар үзен.

М ә ү л ә. Черегән усак яфрагы күк калтыраган син, алайса?

Б и к б у л а т. Ярар, Хәбир. Исән-сау кайткансың, бик дөбердәп йөрмә.

Х ә б и р. Ул малайга күз-колак булырга ие, Бикбулат. Бер-бер төштә муенын сындырыр ул, валла!

Б и к б у л а т. Син барсаң алып кайтмас идең, мин барсам алып кайтмас идем! Ә эш көтә! Әйдә, Мәүлә, нәрәткә кадәр эшне бетерик.

М ә ү л ә. Борыч сибеп кайнар шулпа чөмер, Хәбир агай! Олы кызыңа сәлам әйт!

Китәләр. Хәбир чыга башлый, Х ө р м ә т у л л а белән очраша.

Х ө р м ә т у л л а. Бикбулат идарәгә киттеме?

Х ә б и р. Шунда булмыйча, иртәгә мәктәп сала башлыйлар икән.

Х ө р м ә т у л л а. Беләм... Үзе генәме?

Х ә б и р. Юк. Мәүләне дә ияртте.

Х ө р м ә т у л л а. Итәккә тагылган тигәнәк күк йөри икән! Ну, эләктерәм әле үзләрен! Өемә кайтсам, беләсеңме, минем бакчага кем кергән?

Х ә б и р. Кәҗәләрдән җык күрәбез...

Х ө р м ә т у л л а. Син үзең кәҗә! Укучылар кереп тулган. Кар суы тотабыз, диләр. Тоттырырмын мин аларга!

Х ә б и р. Кайтып, борычлы кайнар шулпа чүмерәсем бар.

Х ө р м ә т у л л а. Ярты бакчаңны кисеп алсалар, белер идең син!..

Х ә б и р. Нишләп минекен киссеннәр? Синекен дә кисмәделәр, ярты бакчаңны Разия үзе колхозга бирде.

Х ө р м ә т у л л а. Бирми торсын, кулы кыска... Бикбулатны әйтәм, ятим кызны шултиклем кыерсытмаса!.. Иман калмады бәндәләрдә, шунысы әрнетә... Бакча нәрсә, иман ягы уйлата!

Х ә б и р. Алай инде, алай...

Х ө р м ә т у л л а. Нигә бу арада күзгә-башка чалынмыйсың?

Х ә б и р. Эш муеннан, Хөрмәтулла абзый, өйдә дә, фермада да... Яз бит!

Х ө р м ә т у л л а. Изге рамазан аенда ахирәтне күбрәк кайгыртырга кирәк тә бит, юк, колхоз дигәннәре картларга да тынычлык бирми.

Х ә б и р. Тик ятып булмый ла ул, хәлдән килгәнче кыймылдыйбыз. Әле менә станцага барып кайттык. Үтүкне аны Гәрәй дә алып кайта ала! Юк, яңа элеватор сала башлаганнар, шуны карап кайттым...

Х ө р м ә т у л л а. Төп яңалыкны әйтмисең әле син.

Х ә б и р. Әллә берәр нәрсә сөйлиләр?

Х ө р м ә т у л л а. Авыз ачарга баргалыйсың, үзең көндезләрен шыпырт кына ашап ятасың, диләр.

Х ә б и р. Кем әйтә?

Х ө р м ә т у л л а. Менә мин әйтәм. Ай-һай, Мөхәммәтхәбир, Аллаһе Тәгаләне алдыйсың, бәндәләрнең күзен буйыйсың. Гөнаһысын кемгә илтерсең?

Х ә б и р. Кеше сүзе кеше үтертә, Хөрмәтулла абзый.

Х ө р м ә т у л л а. Ышанмадым мин аңа. Безнең Хәбирме, димен, юк, булмас, димен. Без аның белән ике бармак кебек янәшә үстек! (*Пауза.*) Теге мәсьәлә ничегрәк соң?

Х ә б и р. Кайсысын әйтәсең?.. Эчелде шул, күрше Зариф малае армиядән кунакка кайткан, икебезгә бер яртыны салдык.

Х ө р м ә т у л л а. Мөхәммәтхәбир!

Х ә б и р. Ә, аны әйтәсең икән, аңладым! Бөтенләй хәтердән чыккан. Авыз күтәреп мактаныրлык чут юк, Хөрмәтулла абзыкаем. Кайсы әйтә, мәчет булса ару булыр иде, ди. Кайсы, кем тотынсын аңа, акчасын кем бирсен, ди. Фәйзерахман карт әйтә, быел бер тиен дә арттыра алмыйм, малайга люлкеле матай алам, ди. Миңлегалинең расхудлы елы, карчыгы белән Казахстандагы кызына кунакка бара. Аңа әйтеп тә тормадым.

Х ө р м ә т у л л а. Җыен динсез-дәһри белән сөйләшергә сиңа кем кушкан? Әнә Мотыйгулла: «Мәчет өчен димәктә, сыерымны сатып булса да акча бирәм!» — дип тора.

Х ә б и р. Кем мин ул кадәр? Кем мине тыңлый? Ә Мотыйгулланың сыерын әйтеп куюың ярады.

Х ө р м ә т у л л а. Менә, менә, яхшы адәмнәргә мисал итәрсең!

Х ә б и р. Сыеры турында Бикбулатка әйтергә кирәк дим. Әйбәт сыер, әле өч кенә бозау бозаулаган, авылдан ычкындырмаска иде аны.

Х ө р м ә т у л л а. Мулла турында сүз кузгаттыңмы?

Х ә б и р. Кузгаттым да... Кирәк чагында Минәчтин абзый укыштырыр әле, дигән булалар.

Х ө р м ә т у л л а. Булалар, булалар... Авыл советының диләнкәсен кисәргә килештем, минем белән кул алмашка барасыңмы?

Х ә б и р. Ачуланма, Хөрмәтулла абзый, анысын да булдыра алмыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Син бүген авызыңны җимеш дип белеп тилебәрән орлыгы белән ачмагансыңдыр?

Х ә б и р. Турысын гына әйткәндә, кулым тартмый. Сиңа ияреп бер мәртәбә адәм көлкесенә калдым инде, җитәр.

Х ө р м ә т у л л а. Буралы буласың килми инде?

Х ә б и р. Бикбулат әйтә, быел алдынгы колхозчыларга бураны үзебез юнәтәбез, ди. Кистереп, китереп, өен күтәреп бирмәкчелар.

Х ө р м ә т у л л а. Синең кебек салам сыйракларның авызларын да күтәртеп калдырабыз дип өстәмиме? Алдынгы колхозчы, имеш!

Х ә б и р. Нигә, хәзер көтүчеләр пачутта, муллага биргесез... Ел килешләре әйбәт кенә торса, безнең сыерлар ару гына кышлыйлар.

Х ө р м ә т у л л а. Бура күтәреп бирәләр! Тоттырганнар иде ди... Әз терәттеләр синең ишеләрне кәкре каенга! Адәм баласы бер-берсен алдап яши!

Х ә б и р. Кешегә ни булса, миңа да шул булыр. Аеры малны бүре ашый. Турысын гына әйткәндә, ил талап авызга кергән хәлвәдән, җир тарап авызга кергән икмәк татлырак дигәннәр, борынгылар.

Х ө р м ә т у л л а. Мин ил талаучы булып чыктыммы?

Х ә б и р. Алай ук димәсәм дә... Гаделлек белән яшисем килә!

Х ө р м ә т у л л а. Гаделлек белән яши алмыйсың син!

Х ә б и р. Нигә?

Х ө р м ә т у л л а. Мин бит кайбер нәрсәләрне беләм!

Х ә б и р (*каушап*). Нәрсәне?

Х ө р м ә т у л л а. Моңарчы берәүгә дә чыгармадым, чамала.

Х ә б и р. Тфү! Искә төшермә шуларны! Күптәнге хәлләр бит... Юк, юк, Хөрмәтулла абзый. Ул хакта ишетәсем дә килми, хуш!

Йөгереп диярлек чыгып китә. Хөрмәтулла: «Ишетсен колагың, безнең сүз уртада калды!» — дип кычкырып кала. Бикбулат белән Мәүлә керәләр.

Бикбулат. Күрдеңме, Мәүлә, ә син килмәс дигән идең.

Хөрмәтулла. Сиңа зур бер йомышым бар, Бикбулат.

Бикбулат. Сизенәм! Материаллар кайтты, цементлы булдык. Күптән көтә идем мин сине.

Мәүлә. Кайнар коймак пешереп...

Хөрмәтулла. Мәктәпкә тотына алмыйм, Бикбулат. Саулыгым чамалы. Бүген килми дә идем, бакчама...

Бикбулат. Авыл советы диләнкәсен кисәргә тотынасың икән. Аның агачлары камыр күк йомшак, мамык төсле җиңел, алайса?..

Хөрмәтулла. Лесничий көчләп үзе бирде. Урман эшен беләсең, асылда, син безнең эшче, диде.

Мәүлә. Урман эшен, дидеме, әллә хәйлә-алдау юлларын беләсең, дидеме?

Хөрмәтулла. Һәйт, малай актыгы, затсыз!

Бикбулат. Икенең берен сайладым дисеңме?.. Хәзер без сайларбыз инде!

Хөрмәтулла. Яхшылык белән килгән карт кешене өркетәсең, Бикбулат. Син Мәүләгә карама, хәзерге яшьләрдә иман нуры юк аларда. Юл күрсәтүче бер Ходай юк, куркытучы тәмуг юк!

Бикбулат. Йомышың ни?

Хөрмәтулла. Җибәрмә балаларны бакчама! Талатма көпә-көндез!

Мәүлә. Йомышы да йогышлы икән!

Хөрмәтулла. Законны бозарга ярамый бит... Мин законның бер генә кылын да селкетмим! (*Мәүләгә күрсәтеп.*) Бу малайлар әллә ни сөйләгәч тә... (*Күз яшьләрен сөртә.*)

Бикбулат. Артыгын сөйләмиләр сыман.

Хөрмәтулла. Күңелемдә бер тамчы әшәкелек юк! Менә азрак баш-күз алыйм, савыгыйм, колхозда да җимертеп эшләрмен...

Бикбулат. Кая инде сиңа!.. Агач мулла булырга чамалап йөрисең.

Хөрмәтулла. Син дә шул гайбәткә ышангач.

Бикбулат. Менә нәрсә, Хөрмәтулла абзый, күз яшенә Мәскәү генә түгел, без дә ышанмыйбыз. Бакча синеке түгел, Разияныкы. Ул ничек дисә, шулай булыр.

Хөрмәтулла. Ә мин? Дөньяда яшәмим дәмени инде?

Мәүлә. Ике җанга футбол кыры тиклем бакча!

Хөрмәтулла. Олыларга кадер юк синдә!

Ферма ягыннан Разия килә. Әтисен күреп, ул кире борылырга уйлый. Соңыннан, бер карарга килеп, төркемгә якынлаша.

Бикбулат. Менә Разия үзе дә килә. Бик вакытлы килеп чыктың, кызым. Сугыйк кызуында!

Разия. Бикбулат абый!..

Бикбулат. Кыюрак, кыюрак! Менә кемнән үрнәк ал син, Хөрмәтулла абзый. Агачыннан ерак тәгәрәгән алма! Сөйлә, Разия!

Разия. Бикбулат абый... мин... иртәгә сыер саварга минем урынга бер кеше билгеләгез.

Мәүлә. Авырыйсыңмы әллә, Разия?

Бикбулат. Әллә ял гына кирәкме? Арыдыңмы?

Разия. Мин яңадан анда төшмим.

Мәүлә. Ни булды тагын, Разия?

Бикбулат. Ашыкма, сеңлем. Бездә алай көчләп эшләтү юк. Тик, нигә болай кинәт? Ни булганын сизми калдык без?

Хөрмәтулла. Көчләп эшләтү юк, имеш...

Разия. Бер дә алай кинәт түгел. Озак уйладым, озак газапландым. Җитәр. Бүгеннән башлап мин анда эз басачак түгел!

Мәүлә. Ни булды соң анда бүген, әйт!

Разия. Бара алмыйм. Барасым килми.

Хөрмәтулла. Күрдегезме? Ятим баланы кая китереп җиткердегез! Көне-төне, җәен-кышын эштә, ал-ял юк. Кызым, бичарам, килче яныма! Мине егып таптамакчы булдылар кайберәүләр, барып чыкмады. Менә кем өчен яшим мин!.. Ул да минем өчен... Бергәләп урман кисәрбез, кызым, балам... Хәләл көчем белән тапкан урманны икәү кисәрбез, яме? Безне беркем кауламас, эшләрбез, арысак, утырып ял итәрбез. Үз иркебездә. Әйдә, кызым, киттек, балам, өйдә ял итәрсең!

Разия. Син аңламадың, әткәй.

Хөрмәтулла. Бик аңладым. Үз баламның җанын аңламыйммы соң?

Бикбулат. Яхшы, Разия. Без уйлашырбыз.

Хөрмәтулла. Уйлагыз, уйла. Сезгә шуның өчен акча түлиләр.

Разия теләр-теләмәс кенә аңа ияреп, чыгалар.

Мәүлә. Нишләргә соң, нишләргә?

Бикбулат. Баскан җиреңдә йоклыйсың дип юкка гына әйттемме?

Мәүлә. Нишләргә?

Ферма ягыннан Г ә р ә й белән Ч ә ч к ә күренәләр. Мәүлә аларга каршы йөгерә.

Зинһар, тизрәк! Ни булды?

Ч ә ч к ә. Шулай буласы билгеле иде инде.

Г ә р ә й. Эшләр шулайрак, Мәүлә...

М ә ү л ә. Миңа төрттерүеңме бу?

Ч ә ч к ә. Яшь кыз йөрәгенә чыдый алмый яши. Яшь егетнең гаебе бер дә юкмы?

М ә ү л ә. Белә-белгәннән мин аңа яхшылык кына теләдем.

Б и к б у л а т. Димәк, ул гына җитмәгән, Мәүлә.

М ә ү л ә. Өйрәтегез, нишлим?

Ч ә ч к ә. Казанга киткәндә берәр нәрсә абайламадыңмы?

М ә ү л ә. Белмим... Кайткач ул минем белән очрашмады, бүләгемне кабул итмәде.

Г ә р ә й. Син нигә дип юрадың инде?

М ә ү л ә. Әткәсе! Шул гаепле!

Б и к б у л а т. Уйларга кирәк, балалар.

М ә ү л ә. Кайда, нинди ялгыш ясадык соң без? Нигә кеше абынгач кына без аның язмышы хакында уйлаша башлыйбыз?

Г ә р ә й. Нигә?

Ч ә ч к ә. Әйе, нигә?

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман. Матур алан. Юл уза. Май урталары. Шомыртлар ап-ак чәчәктә. Куаклыктан Р а з и я килеп чыга. Чишмәгә ятып су эчә. Калкулыктагы яшел үләнгә ята. Акрын гына җырлый.

Яшь наратка сөялеп көтәм сине,
Чәчләремне сыйпап җил исә.
Дулкынланып китә чәчәк исе,
Акрын атлап янга син килсәң...

Кулына чыбыркы тотып Х ә б и р килеп керә.

Х ә б и р. Син икәнсең әле, безнең кызлар дип торам.

Р а з и я (*сикереп тора*). Мин идем шул...

Х ә б и р. Ят, нигә торасың? Самый җырлап ята торган чак бит!

Р а з и я. Хәбир абый, мин сезнең кыз түгелмени?

Х ә б и р. Кем белсен сине!

Р а з и я. Хәбир абзыкаем, син дә шул сүзне әйткәч...

Х ә б и р. Әйттермә. Үзең гаепле. Монда нишләп ятасың? Бөтен кеше эштә, чәчүдә, ә син кояшта йокы симертәсең.

Р а з и я. Әткәйне көтәм.

Х ә б и р. Юк нәрсәне көтеп, бәхетеңнән колак какма. Ташла син ул атаңны, әшәке кеше ул. Ышан миңа!

Р а з и я. Әшәке... Урлаганмы, талаганмы ул? Синең дә яман атың чыккан чакларың бар иде, Хәбир абый. Төрмәдә утырдың, аннан кайттың... Әгәр син әшәке дип барысы да йөз чөерсәләр, нишләр идең?

Х ә б и р. Беләсеңме, кем аркасында утырдым мин ул төрмәгә?

Р а з и я. Мин синең судьяң түгел идем.

Х ә б и р. Әткәң аркасында! Кем чакырды мине урман кисәргә? Ул! Ул котыртмаса, хайваннарыма гомергә хыянәт итәсем юк иде. Аның тәмле теленә ышанып каравылчы булып кердем. Кызыктым да хата кылып ташладым. Беләдер идеңме шуны?

Р а з и я. Каян белим? Бәлки, син аны менә хәзер генә, көнчелектән генә уйлап чыгарасыңдыр. Дөрес булса, судта төбенә төшкән булырлар иде.

Х ә б и р. Әйтмәдем. Үзем ачык авыз булгач, кеше бутыйсым килмәде.

Р а з и я. Хәзер әткәйне түбәләү җиңел! Бөтенегез тел чарлый, колаклар тонды.

Х ә б и р. Сине кызганам.

Р а з и я. Кызганма, Хәбир абый, мин хәерче түгел.

Х ә б и р. Нинди сыер савучы идең заманында! Сыер савучының пачутын беләсең! Өченче көн җәйләүгә ничек озатканнарын күрсәң иде!

Р а з и я. Хараптыр инде.

Х ә б и р. Бүген кич безнең кызлар янына килеп чык.

Р а з и я. Ни күрмәгән мин анда?

Х ә б и р. Ул яшеллек димсең, ул матурлык...

Р а з и я. Алары монда да җитәрлек.

Х ә б и р. Менә яңа өй җиткереп киләләр.

Р а з и я. Җәй көне өйнең хаҗәте шулкадәр генә.

Х ә б и р. Радиоалгыч куйдылар, Илһам Шакировны кырын ятып кына тыңлыйбыз хәзер.

Р а з и я. Исең киткән икән. (*Пауза.*) Минем сыерлар ничегрәк?

Х ә б и р. Менә аларны мактап булмый. Сыер булмадылар, бәла булдылар алар. Шулар аркасында җык күрәбез. Мүкләгең үткән төнне кайтмады.

Р а з и я. Кайтмады?

Х ә б и р. Качып бозаулап ята инде, явыз.

Разия. Нигә көтүгә кудыгыз соң аны?

Хәбир. Теге, синең урынга килгән кызый актыгы белеп бетермәгән. Килү мәшәкате белән чуалып безнең дә күз җитмәгән. Урманда үлән аз. Председательнең колагына черки булып кердем: ашыкмыйк, мин әйтәм, берике көн көтик, үлән бераз кабарсын. Җәйләүгә чыгар чакмы соң? Кызлар ирек бирмәделәр, урманның иң ямьле чагы, чыгабыз да чыгабыз, имеш. Сыерлар чыкты да таралды. Чабалар да чабалар. Иңкү урыннарда кар ята бит әле. Сыер ул кызлар төсле чәчәк иснәп кенә тук була алмый. Менә Мүкләкнең бозавын бүре ашап куйса?!

Разия. Бусы миңа ошый!

Хәбир. Нәрсә ошый сиңа, төнлә туган кыз?

Разия. Мактадың-мактадың да, теттереп хурлыйсың.

Хәбир. Кем хурлый? Нәрсәне? Мактанам мин! Районда беренчеләрдән җәйләүгә чыктык. Сөт артты. Тик холыксыз Мүкләгең генә... Үзеңә охшаган: кача!

Разия. Баш бирмиме?

Хәбир. Койрыгын да күргән юк. Кыңгырау-фәлән булса, усалрак малларның муенына тагып җибәрер идем, кыңгырау таба алмыйм.

Разия. Хәбир абый, безнең амбарда әллә ничәү алар.

Хәбир. Үзең әйтмешли, мин сезнең амбарның мөдире түгел лә!

Разия. Әткәйдән сорап карагыз.

Хәбир. Сорамыйм.

Разия. Нигә?

Хәбир. Атаңны һаман белмисең икән. Бирми ич ул!

Разия. Хәбир абый, әткәй өйдә югында син ике ел безгә кергәләп йөрдең. Бер дә болай сөйләшми торган идең.

Хәбир. Иң әүвәл нигә кереп йөрдең дип сора. Сине күзәтеп йөрдем ич мин!

Разия. Нигә мине күзәтергә?

Хәбир. Әткәң кушып китте, караштырып тор, диде. Азынып китмәсен, диде.

Разия. Нигә алай?

Хәбир. Мондый хурлыкка төшмәсәң, бүген дә сөйләмәгән булыр идем.

Разия. Инде миңа да каныга башладыгызмы?

Хәбир. Әткәң яшәгән заманда ярыкка кысылырга җай булгандыр, мәгәр бел: сиңа бик читен булачак! Син кызганыч!

Разия. Ялынып сезгә килмәм!

Мәүлә керә.

Х ә б и р. Алай ук димә, кызым.

М ә ү л ә. Әйтсен иде! Юкка тыйдың, Хәбир абый.

Р а з и я. Тагын бер гаепләүче! Аңа ни кирәк икән тагын?

М ә ү л ә. Миңа берни дә кирәкми. Хәбир абыйны эзләп килүем.

Х ә б и р. Әллә?

М ә ү л ә. Бикбулат абый тузына. Бар әле, сыер өчен сиңа эләгәчәк!

Х ә б и р. Күңелем сизгән иде аны! Төшемдә дә коега егылдым... Каян бәла чыгып тора диген! (*Чыгып китә.*)

Р а з и я. Озак текәлеп торасың. Танымыйсыңмы әллә?

М ә ү л ә. Таныйм. Хәзер таныйм инде. Кайсы сукмакка кереп качарсың икән дип кенә көтәм.

Р а з и я. Качмыйм. (*Пауза.*) Кая качыйм? Монда без кисә торган диләнке.

М ә ү л ә. Ябыккансың димме?

Р а з и я. Син нигә монда урманда әле?

М ә ү л ә. Җәйләүдә оя корып бирдек. Йорт. Иртәгә авылга кайтабыз.

Р а з и я. Кичә җырлап үткәнеңне ишеткәч тә, шулайдыр дип күңелемә килгән иде.

М ә ү л ә. Оялттың... Тавышым ямьсез минем. Кеше ишетмәгәндә җырлыйм җырлавын... Эшне кичә бетерә идек, Мүкләкне эзләштек.

Р а з и я. Мине дә эзләгәнсең икән. Әткәйдән сорагансың...

М ә ү л ә. Телемә үпкәлим, сораган идем шул.

Р а з и я. Бүген кирәгем беттеме?

М ә ү л ә. Бүген эзләвемнең сәбәбе икенчерәк... Уттай эш өстендә колхоздан качып утын кисеп йөрисең... Ике көннән җыелыш... Сине чакырабыз.

Р а з и я. Их, Мәүлә, Мәүлә! Шуларны сөйләр чакмы бу?!

М ә ү л ә. Башка вакытта сине күреп булмый, качасың.

Р а з и я. Җыелышка чакыртып сөйләшергә булдың инде?..

М ә ү л ә. Җомга саен өегездә картлар җыела икән. Син дә аларга булышасың диләр...

Р а з и я. Картлар җыела дисең... Җылый-җылый әткәйгә ялынганны берегез дә белми!.. Бәлки, мин син җүләрне күрер өчен кичләрен сезнең урамнан урап кайтамдыр? Анысын берегез дә сизми!.. Бәлки, мәктәп нигезен салганда мине эзләп килүеңне теләгәнмендер? Ә син... чакырдың да оныттың.

М ә ү л ә . Нигә син кире шулай? Нигә башкалар төсле түгел?

Р а з и я. Без барыбыз да бертөсле булсак, ничек бер-беребезне табышыр идек?

М ә ү л ә. Без борчылабыз, Разия.

Р а з и я. Сезнең бар да җайлы, рәхәт. Мин беркайчан да сез татыган бәхетне күрмәдем. Минем яшьлегем булмады да диярлек. Иркәләүгә, наз сүзләренә мохтаҗ идем мин. Һәрбер ягымлы караш минем өчен дөнья бәясе торса, бәләкәй генә кимсетү дә минем өчен коточкыч авыр хәсрәт! Тормыш мине көннән-көн ныграк кимсетә хәзер. Барыгыз да мине узып киттегез. Менә син дә... Аңла: шулай берәм-берәм мин якын дусларымны югалта барам. Сезнең белән рәттән бара алмыйм, чөнки мин наданрак, карарак кыз.

М ә ү л ә (*ачуланып*). Үз-үзенне ныграк яратасың син!

Р а з и я. Мине башкалар яратмаганга ул.

М ә ү л ә. Ә мин?

Р а з и я. Башкалар белән бергә борчылам дидеңме?.. Син мине аңлый алмыйсың, беләм. Тезе ямаулы чалбар киеп, пычкы чүбенә батып беткән күлмәктән йөргәндә мине аңлый ала идең! Мин сине ярата идем, без икебез дә бердәйләр идек...

М ә ү л ә. Ә син, нинди генә булсаң да, минем күңелгә якын, кадерле.

Р а з и я. Якын булганга, уртак сүзләрне авыл арасында тараттыңмы?

М ә ү л ә. Чарасыз калдым, Разия. Нидер үзгәртергә тиеш.

Р а з и я. Белмим. Башым җитми. (*Пауза.*) Нинди агач бу, кәүсәсе бигрәк төз. Менә минем дә тормышым шушы агач кебек туп-туры булыр кебек тоела иде миңа: өй, хуҗалык, әткәй... Фермага барам, бәхетлемен! Өйгә кайтам, әллә ничек...

М ә ү л ә. Буталчык сөйлисең. Нидер яшерәсең, уеңның очын югалтырга тырышасың. Әткәң хакынамы?

Р а з и я. Чү, урман колак ул, кычкырма!

М ә ү л ә. Сөйләшәсе килә, Разия. Кил бүген кичкә нәкъ шушы урынга! Мин сине көтәрмен.

Р а з и я. Котыртма күңелемне. Әллә ни эшләп ташлавым бар.

М ә ү л ә. Килерсең, яме. Вакытың бар, беләм.

Р а з и я. Кичкә кадәр ерак шул әле. Агач авар да, мине басып китәр.

М ә ү л ә. Алайса, хәзер үк бергә китәбез. Чәчкәләр куаныр иде!

Р а з и я. Әткәй... Ул килер хәзер... Бөтенегез белән талашып беткәндә дә әткәйне карамыйча ярамый.

М ә ү л ә. Кич белән килерсеңме?

Р а з и я. Кем белсен...

М ә ү л ә. Бик нык көтәрмен!

Р а з и я. Син хәзер кит моннан, Мәүлә... Сине көтәләрдер.

М ә ү л ә. Миннән бигрәк алар сине көтә, Разия. (*Чыга.*)

Р а з и я. Көтәләр... Көтәм!.. (*Кычкырып карый.*) Көтәм! (*Тавышы кайтаваз булып яңгырый.*) Нигә соңлады бу эткәй? (*Пауза.*) Көтә-ә-әм!

Чыгып китә. Б и к б у л а т белән Ч ә ч к ә керәләр.

Б и к б у л а т. Аклануны яратмыйм.

Ч ә ч к ә. Юк, юк. Мин сездән бер тамчы да риза түгел. Ашыктырдыгыз, ашыктырдыгыз, идарә членнары белән бәхәскә кердек.

Ч ә ч к ә. Чыгуын бик вакытлы чыктык, Бикбулат абый.

Б и к б у л а т. Ә сөт? Районның уртача күрсәткеченнән чак-чак кына югарырак...

Ч ә ч к ә. Разия сыерлары сөтне киметте...

Б и к б у л а т. Җитмәсә берсен югалттыгыз!

Ч ә ч к ә. Мүкләк — бер кешегә дә баш бирми торган кире нәрсә!

Б и к б у л а т. Алма агачыннан еракка тәгәрәми икән шул! Ул Хөрмәтулла кызын сыек чыбык белән ярыр идем... Берегез дә аның кадәр сава алмый. Үзен күрәсезме?

Ч ә ч к ә. Әткәсе саклый аны...

Б и к б у л а т. Юк, мин сездән бер дә канәгать түгел!

Ч ә ч к ә. Иртәдән алып колак төбендә выжлаган председательдән без дә канәгать түгел, алайса!

Б и к б у л а т. Чү-чү, һич тә ачуланырга исәбем юк. Чәчү әйбәт кенә бара, кукуруз квадратлары күңелгә ятышлы, бәрәңге дә бетеп килә, сезгә дигән өй дә ару гына чыккан, инде килеп, шулар өстенә бүген минем туган көнем!

Ч ә ч к ә. Нигә аны элегрәк әйтмәдегез? Котлыйм, Бикбулат абый.

Б и к б у л а т. Язгы чәчү өстендә туган председательдән дә бәхетсезрәк кеше бармы икән? Кая инде котлаулар! Иртә таңнан ут йотып йөрисең. Менә Мүкләкне тапсагыз, сөтне арттыра башласагыз, шуннан башка берни кирәкми.

Ч ә ч к ә. Кызлар бер зуррак самовар булса иде диләр. Чәйнектән эчкән чәй йөрәккә ятмый.

Б и к б у л а т. Аппетит шәп сезнең: радиоалгыч куйдык, сәгать. Икешәр ак җәймә, китаплар, аптечка, бадминтон... Хәзер самовар! Җәйләүдә ресторан ачыйк та стадион төзик диярсез бер көнне!

Ч ә ч к ә. Сөт аласыгыз килсә, ачарсыз да, төзерсез дә!

Б и к б у л а т. Булыр. Хәбир әнә булмастайны таптыра! Кыңгырау кирәк, ди. Ияр табыгыз, ди. Ияре дә бар. Кыңгыравын каян табарбыз? Элек көтүчегә ничек тә ярый иде. Хәзер ул да безне куалый!

Ч ә ч к ә. Элек син дә гектарыннан фәлән кадәр сөт, фәлән тонна ит дип сорамый идең бит.

Б и к б у л а т. Икмәктер, дөрес!.. Үзгәрде безнең тормыш... Менә син дә, кайчан гына әле, нәни генә кызчык идең!

Ч ә ч к ә. Үзең дә кайчан гына көлеп кенә сөйләшә торган, ягымлы гына бригадир идең. Хәзер коры гына, усал гына председатель булып барасың.

Б и к б у л а т (*көлә*). Сезгә корырак торганда да таманрак!

Ч ә ч к ә. Кешегә ул гына җитми шул, Бикбулат абый! (*Шомырт агачыннан ботак, сындырып бирә.*) Кайчагында аңа чәчәк бәйләме дә бик кирәк!

Нәкъ шул вакытта якында гына машина туктый. Йөгереп Г ә р ә й керә.

Б и к б у л а т. Рәхмәт, Чәчкә акыллым...

Ч ә ч к ә. Наз кирәк адәм баласына, Бикбулат абый...

Б и к б у л а т. Нечкәрттең күңелемне, рәхмәт.

Г ә р ә й. Менә эшләр кая бара икән! Җәйләүгә ашыгуның сере ачылды! (*Чәчкә көлә.*) Урман аулагында, икәүдән-икәү генә, күзне күзгә терәшеп...

Б и к б у л а т. Гәрәй, син нишлисең монда?

Г ә р ә й. Комачаулыйммы? (*Чәчкә көлә.*)

Б и к б у л а т. Соң син кукуруз җиренә ашлама чыгарырга тиеш идең бит!

Г ә р ә й. Тиеш идем дә... Син дә әллә ни эшләрга тиештер дә, менә монда...

Ч ә ч к ә. Әле мин сиңа ландыш чәчәкләре җыям, Бикбулат абый!

Б и к б у л а т. Гәрәй!

Г ә р ә й. Эш бетте. Ташып бетердек.

Б и к б у л а т. Кит? Ышанмыйм.

Г ә р ә й. Минем дә ышанасы килми дә бит.

Б и к б у л а т. Нәрсәгә?

Г ә р ә й. Менә чәчәкләр... Чәчкә... букет... ландышлар!

Б и к б у л а т. Чәчәк исеннән исергән, ахры, син, малай! Акылдан шашма!

Г ә р ә й. Мин шашканда гына әле чыдарлык иде, икәүләп шаша башласак, беребез кая барыр?

Ч ә ч к ә. Бикбулат абыйга бүген илле яшь тулган.

Г ә р ә й. Эх, белгән булсам! «Суккан өчен телеграмм, синнән тиеш йөз грамм»,— дип телеграмм сугар идем.

Яки: «Иллегә җиткәнсең — котлыйбыз, үлсәң үл инде — тотмыйбыз!» — дип адрес язып тапшырыр идем.

Б и к б у л а т. Котлауларың өчен кайнар рәхмәт. Нигә монда килеп чыктың, шуны аңлат.

Г ә р ә й. Машинагыз урман кырында тора. Тукта әле, димен, моның хуҗасы еракта түгелдер...

Ч ә ч к ә. Бикбулат абый, нигә машинагызны анда калдырдыгыз?

Б и к б у л а т. Ай-һай, иллегә җиткән кешенең йөрәге юк дип уйлыйсыз инде сез.

Ч ә ч к ә. Барын бар да, сүрелә торгандыр инде ул.

Б и к б у л а т. Урман буйлап киләм шулай, тәрәзәмә шомырт чәчәкләре тиеп-тиеп кала. Үзем газ йотып утырам. Бар иде, дим үземә-үзем, тарантаска утырып кына, ашыкмый-кабаланмый терек-терек юрткан чаклар!

Г ә р ә й. Илле яшьлекләр атка күчсен, машиналар безгә калсын!

Б и к б у л а т. Бер көндә эштән чыгарасың ич син аны!

Г ә р ә й. Чыгармыйм — чәч машинасыннан башлап, атом бозваткычына кадәр бөтен машиналарны йөртәм.

Б и к б у л а т. Стоп, бүген тормозларың эшләми, Гәрәй. Атом тирәсендә синең өйрә сыек. Укырга кирәк, энекәш, укырга! Сигез класс белән теркелдисеңме?

Г ә р ә й. Шул чама.

Б и к б у л а т. Барасыңмы? Җибәрәбез. Механик булып кайтырсың.

Г ә р ә й. Белмим шул...

Ч ә ч к ә. Бара да, кайта да!.. Барам диген инде.

Б и к б у л а т. Безгә менә юньле уку тәтемәде. Сугыш!.. Шул бүлде безнең гомерне. Ә син укы!.. (*Китә башлый.*) Йомышыңны әйтмәдең, Гәрәй.

Г ә р ә й. Йомыш дип... Ашлама таратучылар куш йодрык кадәр кисәкләрне аннан-моннан гына атканнар да киткәннәр. Яңгырга кадәр ваклатмасаң, кукуруз урынына тимгел-тимгел кутыр гына үсәчәк.

Б и к б у л а т. Шуның өчен монда килеп йөрдеңме?

Г ә р ә й. Нигә?

Б и к б у л а т. Юбилей көнендә кешене бимазаламыйча булмый инде? Ярар, чарасын күрермен. Тик монда озак юанма, авылга кайт, син миңа кирәк! (*Чыга.*)

Ч ә ч к ә. Йә?

Г ә р ә й. Нәрсә «йә»?

Ч ә ч к ә. Бикбулат абый китте.

Г ә р ә й. Иллегә җитеп, кайчан китәргә кирәклеген дә белмәсә!

Ч ә ч к ә. Шәп әкият уйлап чыгардың син!

Гәрәй. Нинди әкият?
Чәчкә. Йодрык-йодрык ашламалар турында.
Гәрәй. Нинди әкият булсын, ди! Баядан бирле шуңа эчем пошып йөри иде.
Чәчкә. Эчең пошканы да әйбәт әйбәтен... Бу очракта ялганлаган булсаң минем өчен күңеллерәк иде!
Гәрәй. Ярар инде, оялтма.
Чәчкә. Ни булган иде инде сиңа, бернинди ашламалар юк, мин сине сагынып килдем, дисәң?
Гәрәй. Сагынуым да хак.
Чәчкә. Исән-сау торасыңмы? Күренде инде...
Гәрәй. Юк әле, күренмәде. Күрсәтимме? Йом күзеңне!

Чәчкә күзләрен йома, Гәрәй үбәм дигәндә генә Хөрмәтулла керә.

Хөрмәтулла. Разия күренмәдеме?
Чәчкә. Син югында Разия айга очты.
Хөрмәтулла. Әйтер идем инде... Барыгыз да айга очу турында лыгырдыйсыз... Җиргә керәсегез бар, гүргә иңәсегез бар! Шуны онытмагыз! Оятсызлар!
Гәрәй. Әллә оят сатасың? Синдә арзан товар инде ул, Хөрмәтулла абзый. Берәр кило алыйкмы. Чәчкә?
Хөрмәтулла. Ну тапсам, ну тапсам!.. (*Чыга.*)
Чәчкә. Күрсәтә алмадың, гарьлек! Күк йөзен, кояшны Хөрмәтулла эшләпәсе каплады, гарьлек!
Гәрәй. Безнең кояшны каплый алмас! Ач күзеңне зуррак!

Чәчкә томырылып Гәрәйнең кочагына керә, атылып Мәүлә килә.

Мәүлә. Чәчкә, Чәчкә!
Гәрәй. Тфү! Штраф! Нигә кеше аланына рөхсәтсез керәсең? Знак куелган, күрмәдеңме?!
Мәүлә. Аланнар бүлешкәндә мин Казанда идем. Миңа дигән алан кайда?
Гәрәй. Ярын күрер өчен кеше мең хәйлә белән әллә кайлардан килеп йөри...
Чәчкә. Ни кирәк иде, Мәүлә?..
Мәүлә. Тавышың, тавышың! Тук песи күк мырлыйсың...
Чәчкә. Көне бигрәк матур бит...
Мәүлә. Чәчкә, Разия хакындагы җыелышны беразга кичектереп торыйк әле.
Гәрәй. Сезнең аркада барын кичектерергә туры килә! Тапкан сүз сөйләр вакытын!
Чәчкә. Ни булды сиңа?
Мәүлә. Бер айга гына... Унбиш көнгә!
Чәчкә. Сәбәбен әйт.

М ә ү л ә. Сәбәбе юк... Шулай кирәген йөрәгем сизә.

Г ә р ә й. Булмады синнән, җебегән! Сөйгән кызны җыелышка куеп торалармы, җүләр! Иртәгә минем машинага төяләбез дә урманга киләбез. Атасы күз алдында урлыйбыз да китәбез. Машинага кыңгыраулар, чиккән сөлгеләр тагабыз. Башта мин сине өйләндерәм. Аннан соң... аннан соң... (*Чәчкәгә карый.*) Син мине! Яхшылыкка ияреpгә әзер мин!

М ә ү л ә. Белмибез без Разияны, үз бизмәнебезгә салып кына үлчибез.

Ч ә ч к ә. Үз бизмәнең юк синең, Мәүлә! Шуның өчен безгә салынасың!

М ә ү л ә. Ярый, җыелырбыз. Оят, хурлык, безнең чор кешесе колхоз эшеннән баш тарта дип сүгәрбез. Әллә безнең чор яшьләре тегәрҗеп белән сугып куйган эздән баручы кургашын солдатлармы? Аларның ялгышы, абынулары булмасмы? Җыелыш җыйсак та, мин анда бер сүз дә әйтмәячәкмен!

Ч ә ч к ә. Әйтмә! Башкалар гаепле чакта ядрә күк атылып чыга идең, хәзер үзеңә тигәч посып ятасыңмы? Ниндидер бөршәйгән Хөрмәтулла безнең арабыздан иң якын кешебезне тартып алды, син шуңа түзеп торачак!

Г ә р ә й. Кызма ул тиклем, бензиныңны сакла!

М ә ү л ә. Кеше бит ул, нечкә хисле кеше, әйбәт кеше, яхшы кеше! Хөрмәтулла аның яхшылыгыннан файдалана да...

Ашыгып, ярсып Х ө р м ә т у л л а керә.

Х ө р м ә т у л л а. Минем кызыйны күрмәдегезме?

Ч ә ч к ә (*аны тыңламыйча, Мәүләгә*). Нигә ул файдалана, нигә без түгел?!

Х ө р м ә т у л л а. Разия күзегезгә чалынмадымы?

М ә ү л ә. Нинди Разия?

Х ө р м ә т у л л а. Тиз онытасың, егет!

Ч ә ч к ә. Юк, күренмәде.

Х ө р м ә т у л л а. Агач ега торган бауны да алган... Бер-бер хәл булмаса ярар иде.

М ә ү л ә. Нәрсә-ә-ә?

Г ә р ә й. Ни каркылдыйсың син, Хөрмәтулла абзый?

Ч ә ч к ә. Туктагыз әле, егетләр! Ой, беттек!

М ә ү л ә. Кайчан күрдең син аны? Кайда?

Х ө р м ә т у л л а. Минем бер гаебем дә юк.

Ч ә ч к ә. Харап булгандыр! Бер көн очраганда да иңемә башын куеп җылады.

М ә ү л ә. Булмас! Юкны юрамагыз.

Г ә р ә й. Эзләргә кирәк!

Ч ә ч к ә. Син ашадың кызыңның башын, Хөрмәтулла абзый! Син гаепле!

Х ө р м ә т у л л а. Ну тапсам, ну тапсам!

М ә ү л ә. Чәчкә, җәйләүгә йөгер, кызларны чакыр! Мин көтүчеләрне алып бу якка китәм. Гәрәй! Авылга оч!

Х ө р м ә т у л л а. Ә мин?

М ә ү л ә. Җәһәннәмгә юл туп-туры!

Ч ә ч к ә. Нигә егет булып тумадым икән!

Хөрмәтулла чыга.

М ә ү л ә. Без табарбыз аны!

Шул вакытта Х ә б и р килеп керә.

Х ә б и р. Чәчкә, Чәчкә!

Ч ә ч к ә. Бетте баш!

Х ә б и р. Мүкләк табылды!

Ч ә ч к ә. Мүкләк табылды, Разия югалды!

Х ә б и р. Нишләп югалсын? Разия алып кайткан Мүкләкне! Чуп-чуар бик матур бозавы да бар. Чабып йөри.

М ә ү л ә. Кайда алар? Менә әйткән идем бит...

Х ә б и р. Җәйләүдә калдылар. Сине эзләп мин монда чаптым. Хайван хуҗасын сизә шул! Разияга тавыш биргән!

Ч ә ч к ә. Әйдәгез!

Г ә р ә й. Чәчкә, хәзер кемгә ашыгырга кирәклеге билгеле!

Ч ә ч к ә. Бармыйча, күрмичә йөрәгем урынына утырмас!

М ә ү л ә. Әйдә, Чәчкә!

Г ә р ә й. Чәчкә, кич белән...

Ч ә ч к ә. Килермен! Көт! (*Мәүлә белән чыгып китәләр.*)

Г ә р ә й. Хәбир абый, берне тарттыр әле. Сигаретым беткән.

Х ә б и р. Үзем дә менә өченче көн инде ваклап куян тизәге генә тартам.

Г ә р ә й. Саран да соң син, Хәбир абый.

Х ә б и р. Юмарт булсаң, берәр пачка «Казбек» алып менеп бир.

Г ә р ә й. Икмәктер алып менәм. Тик бер шартым бар: минем Чәчкәнең сыерларын ныграк кара инде.

Х ә б и р. Алып менмә. Болай булгач, кирәкми.

Г ә р ә й. Нишләп?

Х ә б и р. Сатылмыйм.

Г ә р ә й. Мин юри генә әйттем бит.

Х ә б и р. «Минем Чәчкә» дисең, наян!.. Минем олы кызга да бер кияү табасы иде бит!.. Курыкма, Чәчкә болай да сыерларның телен белә.

Г ә р ә й. Сандугач телен белә ул, карлыгач телен!

Х ә б и р. «Казбек» алып менәсең, болай булгач?

Г ә р ә й. «Эльбрус» алып менәм. Шүрәле бармагы буе. Тәме, тәме! Берәү тарта, дүртәү тончыгып тора. Бер суырсаң. Мәскәү күренә башлый. Мәскәүне күргәнең бармы?

Х ә б и р. Кая инде, Казанга бармаганга ун ел! Олы кыз...

Г ә р ә й. Юл төшсә, Казанга алып барырмын!

Х ә б и р. Рәхмәт, кем, Гәрәй, мәшәкатьләнмә! Папируска акча әрәм итмә. Ярамаган тагын безгә түтәлтрест! Син дә йорт кузгатырга чамалыйсың дип ишетәм.

Г ә р ә й. Чын булса, шулай дип торалар. (*Пауза.*) Булмаса булган икән, синең «Эльбрус»ны гына көйрәтеп җибәрик. (*Тәмәке тарталар.*)

Х ә б и р. Колхоз диләнкәсе яныннан үткәндә бу агачларның кайсысы минем буралык булыр икән дип үтәм. Ну арада шәпләре бар!

Г ә р ә й. Мәүләләр тиздән кисә башлыйлар.

Х ә б и р. Син аңа бераз әйткәлә инде, ни диген... Дус егетең бит. Миңа шәбрәк агачлардан әзерләсен.

Г ә р ә й. Мә тәмәкеңне.

Х ә б и р. Нигә, тәмсезме?

Г ә р ә й. Сатылмыйм.

Х ә б и р. Уйнап кына әйттем лә. Йә, хуш. Сыерлар янына барырга вакыт. Мүкләк табылгач, җәелеп киткәнмен.

Г ә р ә й. Әйдә, утыр машинага! Бер җилдерим үзеңне!

Х ә б и р. Аллам сакласын, утыраммы соң? Үз гомерем үземә бик кадерле.

Г ә р ә й. Их, куян йөрәк!

Хәбир бер якка, Гәрәй җырлый-җырлый икенче якка чыгып китәләр.

Кара сыер көтүдә...
Яшь җиңгәчәй мунча яккан,
Чыдап булмый төтенгә!

Сәхнә бераз буш тора. Р а з и я керә.

Р а з и я. Нигә качтым мин алардан? Белеп торам, алар мине күрергә йөгерделәр бит! Нигә очрашмадык? Нинди әшәкелек, кирелек бар минем йөрәгемдә? Каян килгән үҗәтлек бу? Үзем бардым, үзем эзләп таптым, нигә сөенечен уртак итмәдек? (*Елый, иелеп, битен юа.*)

Башы-күзе акайган Х ө р м ә т у л л а керә.

Х ө р м ә т у л л а. Кайда ышкылып йөрдең син, юньсез кыз?

Р а з и я. Урманда идем.

Х ө р м ә т у л л а. Кайсы куак төбен ястык иттең? Кем белән идең?

Р а з и я. Мүкләк сыерым белән.

Х ө р м ә т у л л а. Ялганлыйсың бит!

Р а з и я. Ялганлавымны белгәч, нигә төпченәсең, әткәй?

Х ө р м ә т у л л а. Күңелеңнең囗 эштә түгеллеген һәр көн күреп торам. Шул Мәүләләр ягына каерыласыңмы?

Р а з и я. Каерылыр да идем, соңгарак калдым.

Х ө р м ә т у л л а. Күзләрендә үк мөрәүвәт юк бит, атага шулай карыйлармы?

Р а з и я. Карыйм. Карыйм да, туктачы, бу ата бер генә мәртәбә булса да: «Балам!» — дип сөеп, җылы сүз әйттеме икән дип уйлыйм. Таба гына алмыйм шул сүзне! Гомере буе мине талады.

Х ө р м ә т у л л а. Сузма, бау түгел!

Р а з и я. Үлгәнче әнкәйне рәнҗеттең, аннан миңа ябыштың! Издең! Әти кеше шундый буламы? Тагын ни телисең инде?

Х ө р м ә т у л л а. Мин сине ниндидер узгынчы малайлар өчен үстермәдем. Нәсел-нәсәпнең абруен мирас итәрлек, кара көнемдә терәк булырлык кешегә кияүгә чыгып, өемә бәхет, тынычлык алып килсен дип үстердем мин сине.

Р а з и я. Кара көнгә мине дә ияртеп алып бармакчы инде син? Әткәй, син бик теләсәң дә, менә бу агачлар җиргә карап үсә алмыйлар, алар күккә үреләр!

Х ө р м ә т у л л а. Йом авызыңны! Сиңа ни булды?

Р а з и я. Миңа нәрсә булмас? Менә син нигә шулай озак тордың, тагын кара көннәрне юксынып йөрүеңме?

Х ө р м ә т у л л а. Синең ала күзле Мәүләң аркасында. Мәчет салырга мая туплый башлаган идем, Мотыйгулла пай да керткән иде. Синең малайларың барып котырткannar да, бүген акчасын кире алып китте.

Р а з и я. Аны Мәүлә түгел, мин котырттым.

Х ө р м ә т у л л а. Син?

Р а з и я. Мин.

Х ө р м ә т у л л а. Ничек?

Р а з и я. Синең изге юлда түгеллегеңне генә сөйләп бирдем. Көндезге сәхәрләреңне, мич арасындагы самогоныңны!.. Кычкырма, әткәй. Мин арыдым. Синең җырны җырлап, синең өчен яши-яши арыдым. Безнең юллар аерылды, шуны да сизми калгач, нинди ата инде син?!

Х ө р м ә т у л л а. Тукта-тукта... Төшме, өнме бу?! Йо-

мырка тавыкны, бәрән сарыкны өйрәтәме? Ю-юк, атасын санламаган бала бездә юк. Мә ал! (*Разияның яңагына сугып җибәрә.*) Азрак булса, айнытмаса, тагын өстим! (*Суга.*)

Р а з и я. Аһ... (*Тынсыз бөгелеп төшә.*) Аһ... (*Иелеп елый.*)

М ә ү л ә белән Ч ә ч к ә керәләр.

М ә ү л ә. Разия!

Ч ә ч к ә. Ни булды, җаным?

Х ө р м ә т у л л а. Сезгә ни кирәк?

Ч ә ч к ә. Разия, тынычлан. (*Хөрмәтуллага.*) Кычкырма, монда саңгыраулар юк.

М ә ү л ә. Хөрмәтулла абзый, синнән ят ис килә, кәләмфереңне кабарга оныткансың.

Х ө р м ә т у л л а. Иснәнмә, көчек!

М ә ү л ә. Их, син дә кеше исеме күтәреп йөрисең бит! Киттек, Разия!

Р а з и я. Кая?

М ә ү л ә. Безнең белән.

Р а з и я. Ялгыз каласым килә... Бары тик ялгыз... Әнкәй булсын иде... Әнкәй юк...

Ч ә ч к ә. Болай ярамый бит, дустым.

Р а з и я. Ни яраганын, ни ярамаганын бу дөньяда миңа кем аңлата ала?! (*Чыгып китә.*)

Х ө р м ә т у л л а. Тотыгыз, тот! Ул асылынып үләчәк! Бая да бау алып кайдадыр йөреп килде. Җибәрмәгез!

М ә ү л ә. Юк. Тотарга кирәкми. Барсын. Эзләсен. Урманда сукмаклар күп, кайсысы белән китсә дә безнең янга чыгар.

Х ө р м ә т у л л а. Тотыгыз, тот! Китә, ычкына!

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хөрмәтуллалар ишегалды. Тәрәзә буенда каен, зелпе агачлары. Бер якта амбар. Биек, нык койма. Таң вакыты. Көтү яңа гына киткән. Хайван тавышлары, машина тавышы ишетелеп кала. Амбардан берничә кыңгырау тотып Разия чыга. Өй болдырына чыгып, Х ө р м ә т у л л а аңа кычкыра.

Х ө р м ә т у л л а. Ник мыштырдыйсың, авыр аяк! Көтү киткәнгә биш былтыр, ә син һаман ураласың.

Р а з и я. Ә?

Х ө р м ә т у л л а. Тиз буласыңмы дим?! Кичә дә эшнең рәте булмады.

Р а з и я. Эшнең дисеңме? Өлгерербез...

Х ө р м ә т у л л а. Кулыңда нәрсә ул? Кыңгыраулар? Ярминкәгә барырга җыенмыйсыңдыр бит?

Р а з и я. Ә?

Х ө р м ә т у л л а. Колагына чүбек тутырган.

Р а з и я. Колак авырта... Төнлә дә сызлады...

Х ө р м ә т у л л а. Элек шундый кыңгырауларны тагып ярминкәгә чаба торганнар иде. Мин бәләкәй идем әле. Ярминкәдән кайтучыларның кыңгырау тавышын ишетүгә, басу капкасына йөгерешә идек. Без капка ачабыз, алар безгә учы-учы белән прәннек, кәнфит чәчәләр! Без талаша-талаша җыябыз!.. Безнең чабарлык атлар юк иде, кыңгыраулар гына... Ут өертеп яшиләр иде заманында!

Р а з и я. Кем ут өертеп яшәгән, кем ачы кыяк тешләгән.

Х ө р м ә т у л л а. Күргән кеше күк сөйләшәсең.

Р а з и я. Күрмәсәм дә беләм. Укып беләм.

Х ө р м ә т у л л а. Каян килгән галим! Сигез ел йөреп көчкә-көчкә җиде класс бетердең.

Р а з и я. Әле укырга соң түгел.

Х ө р м ә т у л л а. Мәктәптән тыеп бик дөрес иткәнмен, болай да телең авызыңа сыймый. Ун ел укыганнар да буш лыгырдаудан уза алмый. Кара инде, кояш тәртә буе сикергән, ә ул лыгырдый да лыгырдый. Колхоз эшенә генә төш алдыннан чыгып төш авышканда кайталар, анда ярый. Җыен ятьрәк!

Р а з и я. Мин әзер.

Х ө р м ә т у л л а. Кыңгырауларны урынына кертеп куй.

Р а з и я. Мин аларны урманга алып барам.

Х ө р м ә т у л л а. Алайса муеныңа так. Ха-ха-ха! Күрсеннәр!..

Р а з и я. Алып барам.

Х ө р м ә т у л л а. Сазап беткәч, кыңгыраулар белән уйнар идеңме, тиле!

Р а з и я. Хәбир абый сораган иде. Сыерлар качып интектерә, ди. Нигә җәфаланасың, димен. Бер-ике качкынрагының муенына бәйләп җибәрсәң, әллә каян ишетелеп торыр! Сыерлар сөт җыеп ярминкәдән кайтсыннар әле. Чың-чың итеп...

Х ө р м ә т у л л а. Шулай ансат кына илтәсең дә бирәсең инде.

Р а з и я. Ичмасам, файдага ярарлар. Югыйсә мин белә-белгәннән бирле амбар почмагында күгәреп яталар. Кара инде, ничек тоныкланганнар.

Х ө р м ә т у л л а. Хәбир аның өчен акча түләр дип уйлыйсыңмы?

Р а з и я. Уйламыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Кыш көне әҗәткә ике йөз тәңкә алган иде, аны да түли алмый әле.

Р а з и я. Болай гына, бушка бирәм.

Х ө р м ә т у л л а. Тимә син аларга, кузгатма!

Р а з и я. Якты көнгә чыксыннар, күгәрә башлаганнар.

Х ө р м ә т у л л а. Күгәрсәләр, солидол белән майлап җибәр шәпләп.

Р а з и я. Нәрсәгә кирәк алар безгә? Ат алырга, ярминкәгә чабарга җыенмыйсың...

Х ө р м ә т у л л а. Кагылма йөрәк ярама! Тинтәк кыз, кагылма! Дөньяны белеп булмый, әллә ниләр килеп чыгар әле.

Р а з и я. Юк. Белеп була икән дөньяны. Мин генә сиңа ышанып, тагын нинди бәхетсезлек килеп чыгар икән дип көтеп, пошынып йөрдем.

Х ө р м ә т у л л а. Тагын өянәгең башланамы?

Р а з и я. Башланмый, бетәргә азаплана.

Х ө р м ә т у л л а. Хуш. Нәрсә әйтмәкче буласың болай чәпчеп?

Р а з и я. Кыңгырауларны бирмәсәң, урманга аяк та атламыйм!

Х ө р м ә т у л л а. Кыңгырауларны? Минем кыңгырауларымны?

Р а з и я. Барсам да, Хәбир абыйга кыңгыраулар илтергә генә барам бүген.

Х ө р м ә т у л л а. Ә иртәгә?

Р а з и я. Иртәгә бөтенләй бармыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Нишләмәкче буласың инде син, ягъни мәсәлән?

Р а з и я. Уйлап карарга булыр! Вакыт җитте бугай. Уйламыйча ярамый. Адашкан кеше туктап уйлый, аннан соң гына бара башлый, диләр. Кыңгырауларыңның тавышы матур! Нинди матур, көмеш тавышлы алар. Күгәреген бетергән идем, тавышлары ачылып китте... Туйда гына тагарлык...

Х ө р м ә т у л л а. Бир әле монда!

Р а з и я. Туйда, дугада, чуар сөлгеләр арасында чыңчың итсен иде алар!..

Х ө р м ә т у л л а. Тилермә!

Р а з и я. Сиңа барыбер кирәкләре юк.

Х ө р м ә т у л л а. Гомеремнең бизәге булган кыңгырауларны корчаңгы сыерларның муенына тагаргамы?

Р а з и я. Корчаңгы сыерлар юк анда!

Х ө р м ә т у л л а. Хыялымны, өметемне, юанычымны!.. Бир, кызым, рәнҗетмә! Югыйсә!..

Р а з и я (*тыныч кына*). Менә нәрсә, эткәй. Бүген төне

буе йоклый алмыйча уйланып чыктым. Юллар аерылды дип кичә әйткән идем инде. Синең юлыңның тирән бер упкынга килеп төртелгәнен караңгы төндә ап-ачык күрдем! Син олы юлларда яңгыратып узасы кыңгыраулар амбар почмагында мүкләнеп, пәрәвезгә уралып ятып калганнар! Олы юлларга башка кешеләр чыккан! Мә, кыңгырауларыңны! Син аларны шылтыратып кына юл сала алырсыңмы үзеңә, шикләнәм. Теләсәң нишлә, мин үз юлыма китәм.

Хөрмәтулла. Ата кешене упкынга төртеп төшерәсең инде?

Разия. Сиңа бик күпләр кул сузып карады.

Хөрмәтулла. Китми тор. Ансат кына җибәргәннәр иде, ди. Юк, мин синең ишеләрне генә хак юлга кертә алам әле! Җегәрем бар! (*Йодрыкларын йомарлап Разияга килә башлый. Разия кыңгырауларны чыңлатып ташлый да балта ала.*)

Разия. Шаярма, әткәй.

Хөрмәтулла. Үтерәм, буып ташлыйм!

Разия. Якын килмә, әткәй. Бер мәртәбә сугып карадың, берәгәйле булды. Тагын бер атласаң...

Хөрмәтулла. Үз муеныма элмәк тартучыны куенымда үстергәнмен бит... Ходаем, нинди гөнаһларым өчен!.. Үтерәм!

Капка шыгырдый, Хәбир килеп керә. Ул күренүгә, Разия балтасын ташлый да урамга чыгып китә. Хәбир ачык чырайлы, күтәренке күңелле.

Хәбир. Исәнме-саумы, Хөрмәтулла абзый! Шәп йокладыкмы?

Хөрмәтулла. Таң тишегеннән нишләп йөреш?

Хәбир. Идарәдән кайтышлый кагылуым. Кыңгырауларың бик җилле күренә, безгә алып барырга ниятләдеңме?

Хөрмәтулла. Сезгә!.. Бар белгәнегез теләнү.

Хәбир. Болай гына соравым. Бирәсең килмәсә, ихтыярың.

Хөрмәтулла. Җанны талыйсыз, шунсына дәва юк! Гомерегез теләнеп үтә.

Хәбир. Ай, юк, ялгышасың, Хөрмәтулла туган! Синнән теләнә торган заманалар узды. Яшереп булмый, теләнгән чаклар булды. Шуның шаукымы калды бит синдә, шул еллар шаукымы. Үзеңне элеккеге алпавытларча тота башладың. Эш кешесе идең бит син үзең. Азалакта син салган тегермән бүген дә тарта!.. Курыкма, кыңгырау теләнергә кермәдем, күргәч кенә телем ты-

елмады. Әҗәтемне түли алмаганга оялып йөри идем, шуны китердем. (*Акча бирә.*) Тиздән хезмәт көненә гел акча гына бирә башлыйбыз, ди Бикбулат.

Х ө р м ә т у л л а. Акча китермәгәнсең син, уй китергәнсең! Ниятең начарлыкта, күренеп тора. Акча бирәләр, ди, тот капчыгыңны.

Х ә б и р. Гел син юраганча гына булмас, Хөрмәтулла абзый.

Х ө р м ә т у л л а. Мин юраганча да булыр! Иркенәймә! Мин тегене әйтсәм?!

Х ә б и р. Нәрсәне?

Х ө р м ә т у л л а. Синең хәтерең кыска булса да, законның хәтере озын аның! Каравылчы булып торганда сатып җибәргән ике машина тактаны! Бер көнне йокыңнан торуга: «Исән-сау гына торасыңмы, Хәбир абзыкаем, гадел кеше, алдынгы көтүче!»— дип кызыл погоннар килеп керсә, нәрсә дип сайрарсың?

Х ә б и р. Бары белән дә, югы белән дә өркетмә. Җинаятем өчен җәзасын татыдым. Синең тәмле телеңә алданып каравылчы булып кердем. Син котырттың мине! Минем ул шоферларны күргәнем дә, белгәнем дә юк иде. Синең аркада дүрт елга утырттылар мине!

Х ө р м ә т у л л а. Ике машина тактаңны да белгән булсалар, дүрт ел белән генә кала идеңме?

Х ә б и р. Адәм түгел, бүре икәнсең! Йә, ни кылыйм? Мулла буласың киләме? Миңа димәгәе, мулланың мулласы, ахуны, мөфтие бул! Мин сине мулла итеп куя алмыйм! Минем сыерлар, Аллага шөкер, мулласыз да бик тәмле сөт бирәләр!

Х ө р м ә т у л л а. Дурак син, шпана! Гомерең кибәк ашап, йон чыгарып үтте.

Х ә б и р. Гомерең буе мине талавың гына аз булса, мә, йөрәгемне кимер инде, ачарбак!

Х ө р м ә т у л л а. Корт син, кеше түгел! Чүпрәк! Нәрсәгә миңа синең кыршылып беткән йөрәгең! Син минем белән бер ел гына урман кис! Бер ел гына! Бер диләнкә диләр аны! Агачы-бүрәнәсе, кабыгы-мунчаласы! Синең белән миңа гомер буена җитәрлек байлык бар анда. Тыңла, бер генә ел! Бер ел үзем теләгәнчә яшәсәмме, аннары кайбер кешеләр белән сөйләшә белермен.

Х ә б и р. Булмый. Кыстама. Болай мин иркенләп яшим, рәхәтләнеп ипекәй ашыйм.

Х ө р м ә т у л л а. Мин тегене барып тишсәм?

Х ә б и р. Ә мин барып сөйләп кайтсам?

Х ө р м ә т у л л а. Нәрсә әйтә аласың? Күңелем саф, чынаяк кебек.

Хәбир. Синең хакта белгәннәрнең барын да сөйләсәң... Һу-у!

Хөрмәтулла. Лыгырдама, мордар!

Хәбир. Мин лыгырдамам... Белгәннәремне теш артында тотарга хәлемнән килә. Син дә мине оныт! Дөньяда юк дип бел! Кирәк икән, үзем турында үзем сөйләп бирермен. Белдеңме! Дөньяда саф күңел белән яшәүдән дә олырак нәрсә юк. Ураза тотмавым да дөрес. Врачлар кушмый. Коданың күңеле булсын дип кенә авыз ачарга бардым. Баксаң, ул үзе дә миннән читенсенеп кенә маташтыра икән! Берлинны айкаган солдат ураза тота ди! Шулай, теге дөнья дип куркытып бу дөньяда тәмугка тыкма кешеләрне!

Хөрмәтулла. Тәмугтан да хәтәррәктә — төрмәдә черетәм мин сине!

Хәбир. Тәмуг белән генә куркытып эш барып чыкмыймы? Төрмәдә булсам булырмын, булмаган урын түгел, эшләрмен дә ашармын! Сиңа кол булмам! (*Чыгып китә.*)

Хөрмәтулла. Хәбир, Мөхәммәтхәбир! Алла бозавы! Мин шаярдым гына. Билләһи, уйнап кына! Сынап кына!.. Кая югалды тагын бу кыз! Разия, Разия!

Кемдер урамнан нечкә тавыш белән «Әү!» дип кычкыра. Бу — Гәрәй. Ул көлә-көлә килеп керә.

Хөрмәтулла. Шаяртыр кеше тапкансың, юньсез малай.

Гәрәй. Теш сызлыймы, Хөрмәтулла абзый?

Хөрмәтулла. Сызлый...

Гәрәй. Салкын аракыдандыр ул, Хөрмәтулла абзый.

Хөрмәтулла. Их-их-хи!..

Гәрәй. Безнекеләр кайда?

Хөрмәтулла. Нинди безнекеләр?

Гәрәй. Безнекеләр инде, Мәүлә, Разия.

Хөрмәтулла. Монда беркем дә юк.

Гәрәй. Күрәм. Гаҗәп, монда көтәрбез дигәннәр иде.

Хөрмәтулла. Нигә монда? Кая барасыз?

Гәрәй. Барабыз! Бик ерак барырга исәп!

Хөрмәтулла. Күренүең әйбәт булды әле, әллә кайчаннан бер гәп бар иде сиңа!

Гәрәй. Әйтеп кал. Вакытым санаулы.

Хөрмәтулла. Турысын әйтәм, Мөхәммәтгәрәй...

Гәрәй. Гәрәй генә!

Хөрмәтулла. Читкә китеп йөрмә син! Менә миңа пычкы тартышырга, ботак-сатак кисешергә әйбәт кенә бер иптәш кирәк буласы иде. Әллә быелга минем янда гына эшләп торасыңмы?

Г ə р ə й. Мин?

Х ө р м ə т у л л а. Кулай кеше син! Тəвəккəл, кыю, көчле.

Г ə р ə й. Синең белəн?

Х ө р м ə т у л л а. Эшкə дə өйрəнерсең, акча санарга да...

Г ə р ə й. Күпме акча бирəсең?

Х ө р м ə т у л л а. Булыр, акчасы да булыр.

Г ə р ə й. Ун мең булырмы?

Х ө р м ə т у л л а. Алай ук булмаса да, ким булмас. Җаена карап инде, эшенə карап... Эһем-эһем дигəндəй, килəсеңме?

Г ə р ə й. Ун мең! Вəт моны акча дисəң дə ярый. Ун мең күп буламы ул, Хөрмəтулла абзый?

Х ө р м ə т у л л а. Кесəгə сыймаса да, чүлмəккə сыя!

Г ə р ə й. Менə шул бер чүлмəк акчаны мин сиңа бүлəк итəм. Ə син өй түбəңə менеп өч мəртəбə: «Мин җүлəр!» — дип кычкыр.

Х ө р м ə т у л л а. Чү-чү, кеше ишетмəсен!

Г ə р ə й. Сызгыра белəсеңме син?

Х ө р м ə т у л л а. Оятсыз!

Г ə р ə й. Карганма! Сакалыңнан тотып селкермен. Мин сиңа теге кем түгел... Урман кисəргə, тотмыйсыңмы? Мин бəлəкəй чагында ишек яңагын төзəткəн өчен əбинең актык тавыгын суйдырган идең. Миңа калса, үз яңагыңны бушлай да төзəтеп бирермен.

Х ə б и р белəн Б и к б у л а т керəлəр.

Б и к б у л а т. Менə ул! Саумы, Гəрəй.

Г ə р ə й. Мəүлəлəр монда булырбыз дигəннəр иде.

Б и к б у л а т. Бар, машинаңны үрлəт. Хəбир абыеңны да утыртып менəрсең.

Х ə б и р. Ходай сакласын, утыраммы соң!

Г ə р ə й. Курыкма, Хəбир абый, бишектə тирбəткəн кебек кенə алып барырмын. Гомерем миңа да бик кадерле, өйлəнəм!

Х ə б и р. Шулай дип кенə юмаласаң инде.

Х ө р м ə т у л л а. Хуҗаны күрмəмешкə салынасыз инде?

Б и к б у л а т. Чыннан да, күрми торабыз. Исəнме, Хөрмəтулла абзый.

Х ө р м ə т у л л а. Исəнлек чамалы... Җылы диңгез буена бар, дилəр врачлар... Йокы керми! Төне буе убыр төсле йөрим дə йөрим...

Б и к б у л а т. Диңгез буена бар, дəвалан.

Х ө р м ə т у л л а (*кулын селкə*). И-и-х!

Б и к б у л а т. Синең аркада без дə бүген йокы күрмəдек.

Х ө р м ə т у л л а. Əллə?

Б и к б у л а т. Ярты төндə Мəүлə килеп уятты... Иртəн

идарә утырышы булып узды. Синең исемне дә телгә алдык.

Хөрмәтулла. Һаман кузгатасыз инде?

Бикбулат. Иртәгәдән сыер-сарыкларыгызны колхоз җиренә чыгарудан туктатыгыз.

Хөрмәтулла. Иске авыздан яңа сүз! Нишләп?

Хәбир. Идарәнең карары шулай.

Хөрмәтулла. Мин хайваннарны кая куйыйм?

Бикбулат. Ишегалдың киң бит, ябып асра. Мәгәр колхоз җиреннән бер бөртек печән бирдермим.

Хәбир. Әмерикада диме, малларны гел бәйдә тоталар икән. Шулар төсле буласың инде, Хөрмәтулла абзый.

Хөрмәтулла. Үземне бөгә алмагач, гаепсез малларга ябыштыгызмы?

Бикбулат. Малларыңны асрый алмасаң, килеп әйт. Дәүләт бәяләре белән барын сатып алырбыз.

Хәбир. Сыерларын читкә җибәрмәскә кирәк, сыерларын! Бик әйбәт нәселдән, сөтләч!

Хөрмәтулла. Хайваннар минеке түгел, Разияныкы.

Бикбулат. Разияның синнән аерылып чыгу турындагы гаризасын бүгенге идарәдә карадык.

Шул вакыт капкадан Разия, Мәүлә, Чәчкә килеп керәләр.

Хөрмәтулла. Кызым, балакаем, кадерлем!

Хәбир. Ну, артист!

Хөрмәтулла. Дөресме?

Гәрәй. Дөрес булмаса да, ялган түгел.

Хөрмәтулла. Өрмә, синнән сорамыйлар.

Разия. Сөйләшкән идек бит.

Хөрмәтулла. Ә мин? (*Бикбулатка.*) Тамагыгызга сөяк булып кадалдымы Хөрмәтулла? Сыйдырмыйсызмы? Куралмыйсызмы?!

Мәүлә. Сөяк түгел, киемгә сарган тигәнәк кенә син.

Гәрәй (*Хәбир янына килеп*). Бер җилдереп алып меним әле үзеңне!

Хәбир. «Эльбрус» тарттырыйммы үзеңә? Идарә утырышында гына тартам мин аны!

Гәрәй (*тартманы ачып*). Тирес ич бу!

Хәбир. Ялгыш биргәнмен! Мә, бусын тот.

Разия. Монда беркемне дә гаепләргә кирәкми, әткәй.

Хөрмәтулла. Кызым, акыл өйрәтәсең... Син... Кит, ләкин кайтып керер көнеңне онытма! Алар барысы да авыз ералар. Тик атаңнан да якынны каян табарсың? Хәзер үк идарәгә барам да районга, Казанга шалтыратам.

Бикбулат. Шалтырат, Хөрмәтулла абзый. (*Кыңгы-*

*рауларны күреп.*) Эх, кыңгыраулары! Гәрәй, күрәсеңме? Туй кыңгыраулары!

Х ө р м ә т у л л а. Тимә, Гәрәй, кагылма. Үтермә.

Б и к б у л а т. Разияны яңадан сыер савучы итеп куябыз.

Х ә б и р. Һай, шәп!

Ч ә ч к ә. Әлегә җәйләүдә торыр, көзгә безгә кайтыр.

Г ә р ә й. Ничек инде безгә? Син үзең безгә күчәсең ич!

Ч ә ч к ә. Безгә дигәнем без инде, син дә мин!

Г ә р ә й. Ачык сөйләш!

Х ө р м ә т у л л а. Бикбулат!

Б и к б у л а т. Сөйләшенеп, килешенеп беттек сыман.

М ә ү л ә. Без килешенгән!

Х ө р м ә т у л л а. Кызымны беркая да җибәрмим.

Б и к б у л а т. Соңгарак калдың, Хөрмәтулла абзый. Соң дигәннән, җәмәгать, кояш кая күтәрелгән! (*Чыга.*)

Х ө р м ә т у л л а. Таралыгыз моннан, тарал!

Р а з и я. Тотма, әткәй. Синең күңелне беләм ич мин. Күпме көннәр, атна-айлар шушы ишегалларында, шушы өйдә бергә яшәдек. Үзең читтә булсаң да, рухың монда иде. Почмакларда, амбарда, базда...

Х ө р м ә т у л л а. Бикбулат, Бикбулат! Тере килеш тыкма кабергә! Казанга шалтыратам! Телеграмма сугам! (*Йөгереп чыгып китә.*)

Х ә б и р. Борчыл, кызым, борчыл. Алай гына булыр инде ул. Сабыр гына бул! Янына барма, акылга килеп, үзе ялынсын!

Г ә р ә й. Хәбир абый, кузгалдыкмы?

Х ә б и р. Кузгалыйк булмаса.

Ч ә ч к ә. Разия, сиңа булышырга кирәкмиме?

Р а з и я. Юк, җаным, чемоданны тутырып куйган идем, башка алыр нәрсәм юк.

Ч ә ч к ә. Бик күңелле яши идек бит без, Разия! Тагын да күңеллерәк булыр хәзер. Син безнең белән бергәбергә, эх! Ландышлар чәчәк атты!

Р а з и я. Чынмы?

М ә ү л ә. Син килер дип кичә бер кочак җыйган идем мин аларны!

Ч ә ч к ә. Кызлар куаныр инде! Әйдә, Гәрәй, машинага! Тизрәк!

Х ә б и р. Гәрәй, бик үк тизләмә, яме?

Гәрәй, Хәбир, Чәчкә чыгып китәләр.

Р а з и я. Без дә тиз, иеме, Мәүлә?

М ә ү л ә. Вакыт җитте. Җыен, Разия.

Р а з и я. Куркам. Төнлә син килеп тәрәзә какканда сискәнеп киттем дә, шуннан бирле йөрәгем дөп-дөп тибә.

М ә ү л ә. Курыкма... Мин синең янда дияр идем, моны үзең дә анык беләсең.

Р а з и я. Ялгыз калдырмассыңмы? Ташлап китмәссеңме? Мин бит тормышта синең төсле эре атларга өйрәнмәгән. Кармалап кына юл-сукмакны табам.

М ә ү л ә. Сөеклем-кадерлем минем!

Р а з и я. Тагын бер тапкыр кабатла, зинһар...

М ә ү л ә. Сөеклем, сөеклем!

Разия өйалдыннан чемоданын алып чыга.

Р а з и я. Кузгалдыкмы?

М ә ү л ә. Чемоданың җиңел синең...

Р а з и я. Күңелдәгесе авыр... Икесен дә күтәрә алырсыңмы?

М ә ү л ә. Шулай да алга барырга кирәк.

Р а з и я. Алга... Әнә, Гәрәй килеп җитте!

М ә ү л ә. Киттек, Разия.

Машина тавышы. Урамнан көлгән, сөйләшкән тавышлар килә, аннары барысы да тына. Тып-тын, дәү ишегалдына Х ө р м ә т у л л а кайтып керә. Җирдә яткан кыңгырауларга абына.

Х ө р м ә т у л л а. Киткәннәр! Алып киткәннәр!.. Минем кыңгырауларым, минем кыңгырауларым!

Җиргә капланып елый. Бу тавыш иртәнге рәхәт тынлыкта шулкадәр сәер яңгырый, белеп булмый, әллә ач эт чиный, әллә җиргә капланган чал чәчле, нык гәүдәле карт елый.

П ә р д ә.

*Ноябрь, 1959. Казан*
*Апрель, 1960, Переделкино*

# *Хәдичәнең кече улы*

*Драма ике кисәктә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Р ә ш а т.
Х ә д и ч ә.
Г ы й л ь м и я.
Г ө л н а з.
С о л т а н.
К а м и л.
А р т у р.
Р а я н.
Л ә л ә.
Н ә җ и б ә.
Ю а н х а т ы н.
О з ы н к е ш е.
М и л и ц и о н е р.
П о ч т а л ь о н.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Шәһәр читендәге тын урамнарның берсе. Уңда челтәр кәрнизле сары йорт. Йортның бер башында Хәдичәләр, икенче башында Гыйльмия яши. Бакча. Яз. Сулда урам коймасы. Капка. Койма биек түгел, урамнан кешеләр үтсә, күренеп тора. Йорт ишеге янына кызыл флаг эленгән. Еракта оркестр уйный. Ул яктан җил, ахрысы, оркестр тавышы бер көчәя, бер ерагая. Бакчада шактый тәртипсезлек. Җирдә корыган ботаклар ауный, уен барышында кешеләр еш кына шул ботакларга эләгәләр, абыналар. Аркасы купкан эскәмиядә, агачлар арасында Х ә д и ч ә белән Г ы й л ь м и я утыралар. Хәдичә башын тезенә салган. Гыйльмия ак чәчле, шактый юанайган хатын.

Х ә д и ч ә (*башын күтәреп тыңлана*). Гыйльмия, күршем, ахирәтем! Бар син, бар. Кунакка ике мәртәбә чакырып киттеләр үзеңне, ә син бәйрәм көнне дә мине саклап ятасың.

Г ы й л ь м и я. Демонстрация бетте, ахры, тавышлар тына төште.

Хәдичә. Сәгать ничә?

Гыйльмия. Икеләр тирәсе.

Хәдичә. Бая ук ике булды дигән идең.

Гыйльмия (*сәгатен селкеп*). Алга киткәли.

Хәдичә. Бәйрәмгә көне килде. Чалт аяз. Үзе җылы... (*Тыңланып.*) Рәшат һаман кайтмый.

Гыйльмия. Бәйрәм бит! Яшь чаклары. Йөреп калсыннар.

Хәдичә. Сәгать ничә?

Гыйльмия. Кереп ял ит, Хәдичә. Йоклап ал. Болай да икешәр смена эшлисең, бәйрәм төнен дә заводта үткәреп кайттың.

Хәдичә. Бәйрәмдә дә кешеләр күмәч ашарга тиешләр бит, Гыйльмия. Бер мин генә түгел, күпме кешеләр эштә! Тимер юлда, заводларда, һавада...

Гыйльмия. Яшьрәкләр эшләсен! Ә син... авырыйсың да шикелле. Төсең юграк...

Хәдичә. Сине дә аңлау кыен... Әле генә «яшьләр йөреп калсын» дидең... Инде эшләсеннәр, дисең... Бер кулга ике кашык тотып ашарга кушасың... Авырмыйм, Гыйльмия, менә монда чәнчештереп ала алуын... (*Йөрәген күрсәтә.*)

Гыйльмия. Анысы миңа таныш. Анысы кайгыдан. Үлгән артыннан үлеп булмый. Бетеренмә. Нурислам яхшы яшәде.

Хәдичә. Ничек дип уйлап ятадыр, белгән юк. Кайтып сөйләми...

Гыйльмия. Барыннан да бигрәк, сез гомер буе бергә булдыгыз!

Хәдичә. Балалардан гына кадер-хөрмәт күрә алмады.

Гыйльмия. Нишлисең, заманасы шул. Балалар атаанадан читтә яшәргә яраталар...

Хәдичә. Рәшат та кайтмас микәнни? Атналар буе юньләп күрә алганым юк үзен.

Гыйльмия. Эшләмә икешәр смена.

Хәдичә. Икешәрне эшләмәгәч, безгә кем китереп бирә, Гыйльмия?

Гыйльмия. Рәшатың ипле, акыллы бала. Кешелекле. Гадел.

Хәдичә. Дүрт бала үстереп, канаты каерылган кош сыман утыр инде хәзер! Тыйма, Гыйльмия, син ул хисне белмисең. Күршем, ахирәтем булсаң да, белмисең. Синең бала үстереп караганың юк.

Гыйльмия (*әрнеп*). Хәдичә!

Хәдичә. Мин юансын дип бәйрәм итмичә калдың... Менә мин сиңа ниләр әйтәм! Түз, яме!.. Дүрт бала! Өчесе читтә, җәһәннәмдә!.. Әтиләре үлеп, берсе кайтып күрен-

мәде. Ярый, кызларның яшь балалары да булсын, ди... Ә Рәис! Олы улыбыз...

Гыйльмия. Рәис гаҗәп кеше булып чыкты.

Хәдичә. Син гаҗәпләнмисең инде анысы...

Гыйльмия. Бәгырьгә үтәрлек итеп әйтәсең, Хәдичә.

Хәдичә. Синең тәрбияң! Урал, Себер дип син аны җилкендердең! Себер турындагы синең әкиятләреңне тыңлап геолог булып китте бит ул!

Гыйльмия. Нишлим, Себер турында начар сүз әйтә алмадым шул.

Хәдичә. Ник бер тиен акча салсыннар... Миңа кирәкми... Миңа бик аз да җитә... Әнә кечесен укытып чыгарасы бар. Кеше итәсе бар... Рәшат исән-аман кайтып керсә, бүгеннән башлап сиңа эз дә бастырмыйм! Җитте. Төпчек улым юаш булсын, хыялсыз булсын, тик үз янымда калсын. Беркая җибәрмим монысын. Байтактан кызып йөри идем, әйттердең. (*Торып баса.*) Сәгать ничә?

Капкадан Ләлә керә дә, йортка узып бара.

Гыйльмия. Сезгә кунак килә, Хәдичә.

Хәдичә. Ләлә, кызым, без монда әле.

Ләлә. Исәнмесез, Хәдичә апа! Сез эштә түгелмени?

Хәдичә. Әлерәк кенә кайттым...

Ләлә. Ә Рәшат кайда?

Хәдичә. Мин каян белим? Сез бергә түгел идегезмени?

Ләлә. Бергәсен бергә идек... Тик ул кайтып җитмәгән... Кызык.

Гыйльмия. Нәрсәсе кызык булсын инде аның?

Ләлә. Гыйльмия апа да монда икән! Бәйрәмегез котлы булсын.

Гыйльмия. Аңлат син, без дә төшеник.

Ләлә. Кирәк тапса, Рәшат үзе аңлатыр әле! (*Чыга.*)

Гыйльмия. Кыбырсык! Киленең шундый була күрмәсен!

Хәдичә. Кереп ятып торыйм булмаса мин.

Гыйльмия. Безгә генә керик дияр идем, төнлә кунаклар килеп төште.

Хәдичәне озата. Почтальон керә.

Почтальон. Нургалиевләр кирәк иде. Аларга телеграмма.

Гыйльмия. Сөенче! Үземә бирегез, тапшырырмын.

Почтальон. Бәйрәмнәр күңелле узсын! (*Чыга.*)

Гыйльмия. Рәистән! Себердән. Хәдичә, Хәдичә... Тукта, тукта... Ни дигән? «Әти, әни, Рәшат! Сезне бәйрәм

белән кайнар котлыйм», дигәнме? Ах, оятсыз... Ах, җирбит... Үлгән этисен бәйрәм белән котлап ята... Адресы үзгәрсә дә, күңеле бер дә тоймый микәнни аның?

Артур керә.

Артур. Хәерле көн.
Гыйльмия. Рәшат кайда, Артур?
Артур. Үзем аны эзлим.
Гыйльмия. Нигә бергә түгел соң сез? Ни булды?
Артур. Гомергә килешмәслек итеп талаштык.
Гыйльмия. Тапкансыз көнен!

Өйгә кереп китә. Артур чыгып барганда капка тибендә Юан хатын белән очрашалар.

Юан хатын. Ах, Артур!..
Артур. Аңа? Сез дә Рәшатларга киләсезме?
Юан хатын. Мин бернинди Рәшатны да белмим. Ах, Артур!.. Нигә килми башладыгыз сез безгә?.. Күрер идегез, белер идегез... Мәрьям бөтенләй азынды... Миңа әллә нинди сүзләр әйтә! Беркөнне таяк белән кабыргама китереп төртте... Без ул квартирада кала алмыйбыз! Әгәр сез чарасын күрмәсәгез, Мәрьямне ташлап чыгабыз! Сезнең классташыгыз, ә сез килеп тә карамыйсыз...
Артур. Апа... Беләсез ич... Мәрьям мине кире какты. Килеп йөрмәскә кушты...
Юан хатын. Шул әшәке кызга чара табылмас микәнни? Сез белмисез бит, ул мине кабергә кертә!..
Артур. Мин ашыгам, апа! (*Чыга.*)

Юан хатын шунда ук тынычлана. Бик кызыксынып йортны күзәтә. Өйдән Гыйльмия чыга.

Гыйльмия. Йортлар идарәсе бәйрәмдә дә эшлимени?
Юан хатын. Кем сезгә мине йортлар идарәсеннән диде? Түгел, зөбәрҗәтем, мин болай гына...
Гыйльмия. Сезгә кем кирәк иде соң?
Юан хатын. Болай гына дидем ич, алтыным... Менә йорт урыны матур икән дим... Тып-тын. Трамвайлар да йөрми. Аулак. Монда йорт бушый икән дип ишетелде...
Гыйльмия. Нишләп бушасын? Без торабыз ич монда? Бер башында Хәдичәләр, икенче башта мин.
Юан хатын. Ялгыш сөйләгәннәрдер, алтыным! Халык бит әллә ниләр сөйли хәзер... Дөнья бетә икән, диләр... Кем аңа ышансын? Йорты әллә кем түгел икән түгелен... Мәгәр урыны... Прима...
Гыйльмия. Йорты да нык әлегә, нигезе дә...

Юан хатын. Ялгыш җибәргәннәр мине, күгәрченем. Бәйрәмнән кайтышлый кереп чыгыйм дигән идем. Гафу итегез! (*Чыга.*)

Гыйльмия ялгызы. Капка ягыннан әйләнеп килә. Утыра. Пауза. Урамнан Солтан кайтып керә.

Солтан. Ни хәлләрдә, Гыйльмия?

Гыйльмия (*сискәнеп*). Котны алдың... Ай күрде, кояш алды, кая югалдың, Солтан?

Солтан. Якташ профессорга барган идем. Мөхәррәмовка. Тиз генә әйләнеп кайтам дисәм, милицияләр безнең якка берәүне дә җибәрми икән. Бүленеп калдым да, бәйрәм тамашасы күреп, арып-талып кайтып киләм.

Гыйльмия. Төнлә, юл килеп арыгансыңдыр, дип сөйләшеп булмады. Сораша алмый да калдым.

Солтан. Гөлназ белән калдыгыз бит!

Гыйльмия. Ачуланма, Солтан, кызың бераз төмсәрәк кебек тоелды.

Солтан. Сөйләшмиме?

Гыйльмия. Иртән ишегалдын әйләнгәләп керде дә көне буе китап укый. Иске журналлар актара. Инде ятсына дисәм, җитеп беткән кыз лабаса.

Солтан (*көрсенеп*). Ятсынуы да бардыр... Казанга беренче килүе...

Гыйльмия. Аяклары сау түгел дип ишеткәч, бик хафаланган идем, болай чибәр генә йөри икән.

Солтан. Куанабыз инде анысына! Дүртенче классны бетергәнчегә кадәр мәктәбенә кул арбасы белән илтеп йөрдем. Үзенә күрә герой ул! Сиңа охшаган. Бишенчедән рәтләнә башлады. Хәзер Аллага шөкер.

Гыйльмия. Төскә-биткә дә бик чибәр икән, күз тимәсен.

Солтан. Шул чибәрне сиңа китердем, Гыйльмия.

Гыйльмия. Нинди сүз булды бусы тагын?

Солтан. Үзебездә калса, мәктәпне тәмамлый алмас дип курыктык. Җиткән кыз булгач, үзенең бала чактагы гариплегеннән кимсенде. Гел өйдә утыра. Гел өйдә. Күчәргә киңәш бирделәр аңа. Мөхәррәмовка да шуңа барып кайттым. Якташ бит! Мәгъкуль күрә. Рөхсәт итсәң, синдә фатирда торып торыр. Укыр.

Гыйльмия. Юк, Солтан. Алып кала алмам. Юк.

Солтан. Тормышың көйле икән, Арыслангәрәең хакындагы яхшы хәбәрләрне газетадан укыдык. Пенсиягә дә чыккансың.

Гыйльмия. Алары шулай. Тик кызыңны фатирга кертмим.

С о л т а н. Шулай үпкәң зурмы миңа, Гыйльмия?

Г ы й л ь м и я. Ялгыз мин! Бик ялгыз! Яратып, үз итеп, сыенып яшәгән күршеләрем бар иде. Шул гаилә таралды да китте. Моннан утыз биш ел элек ничек ялгыз калган булсам, хәзер дә шулай.

С о л т а н. Ә-ә, менә син кайчакларны онытмыйсың икән!

Г ы й л ь м и я. Әйе, синең эшләр гел уң булды. Себердән син кызылгвардеец дигән дан белән кайттың. Биләүдә исемең язылган кылыч... Бәхетле өйләндең. Балаларың үсте. Ә мин?.. Иргә чыгып өч көн торып калдым. Шуның өстенә никадәрле бәла... Юк, Солтан, алып кала алмыйм кызыңны!

С о л т а н. Әгәр үзем беразга калып торсам?.. Кызны бер дә алып кайтасы килми бит.

Г ы й л ь м и я. Башка җирдән фатир тап.

С о л т а н. Фатиры табылыр, анда Гыйльмия апасы булмас. Синең белән аралашсын дигән идем... Күңеле төшенке. Ә син, гомереңбуе төшенкелекне белмәдең. Файдаң тияр иде кызга!.. Синең дә читенрәк чагың, минем дә кыздан аерыласы килми. Төпчек бала бөтенләй үзгә икән ул... Тотармын да калып торырмын, ә?

Г ы й л ь м и я. Нишләрсең син монда?

С о л т а н. Эшләрмен! Ташчы ич мин.

Г ы й л ь м и я. Һаман ташчы гынамыни әле син? Ни гомерләр узып һаман солдат булып кына калгансың...

Тәрәзәдән Х ә д и ч ә н е ң башы күренә.

Х ә д и ч ә. Гыйльмия, бая почта тавышы килгән кук булды.

Г ы й л ь м и я. Рәистән... Телеграмма. Хафаланырсың инде... Хәбәрләрне алмаган әле ул... (*Телеграмманы бирә.*)

Х ә д и ч ә (*укып*). Аһ!.. (*Югала.*)

Г ы й л ь м и я. Күршем кәефсезләнебрәк тора. Ай элек кенә ирен җирләдек.

Керел китә. Солтан тәмәке кабыза. Г ө л н а з керә.

Г ө л н а з. Менә эткәйне көт! Кайткан да пыскытырга тотынган. Юлың уңдымы?

С о л т а н. Уңды дияргә ярый. Мөхәррәмов абыең чәйгә дәште үзеңне.

Г ө л н а з. Гомергә күрмәгән кешене ничек табынга чакырырга мөмкин?

С о л т а н. Сине белмәсә, мине белә. Егет чакта бергә сугышып йөрдек. Хәзер генә...

Г ө л н а з. Бакчаларын гел карамаганнар. Иртәдән бир-

ле шуңа җаным әрнеп торды... Ботак-сатакка абынып йөриләр, сукмакны чистартмыйлар. (*Ботакларны җыештыра.*)

Солтан (*аңа булыша*). Чыгарлар да бераз эшләп керерләр.

Гөлназ. Чыкмадым инде. Күрше апа эштән кайтты. Йә сораштыра башлар дидем.

Солтан. Ничегрәк соң, кызым, монда ошыймы?

Гөлназ. Син киткәч ничек яшәрмен дип куркам...

Солтан. Әллә беразга үзем дә калыйммы дип ниятләп торам. Казан да сагынылган.

Гөлназ. Каласыңмы, әткәй? Менә шәп булачак! Тәрәзә алдындагы буш түтәлләргә миләүшәләр чәчәрбез.

Солтан. Казан ошадымы дип сораган идем.

Гөлназ. Ошый... Тын бирेдә. Нәкъ бездәге кебек. Бәләкәй чагымда, сез «Казан, Казан» дип сөйләгәч, шәһәр урамнары калайдан дип уйлый идем мин.

Солтан. Мәктәп тә якында гына. Больница да ерак түгел.

Гөлназ. Мин авырмыйм ич инде, әткәй.

Солтан. Гыйльмия апаң белән дуслаш. Себердә революция ясап, Колчакка каршы сугышып йөргән хатын ул. Ире дә... Тик анысы разведкага киткән җиреннән кайтмады. Гаярь егет иде Арыслангәрәй!

Гөлназ. Әткәй, нигә элегрәк Гыйльмия апа турында берни дә сөйләми идең? Сугыш хатирәләрен сөйләгәндә гел «Мөхәррәмов та Мөхәррәмов» иде... Кунакка килгәнебез дә булмады...

Солтан. Нишләп алай булсын? Сөйләгәнбездер.

Гөлназ. Юк иде шул менә. Быел кыш, Арыслангәрәй абый турында газеталарда язгач, Гыйльмия апа исеме дә ишетелә башлады.

Артур белән Камил керәләр.

Камил. Рәшат өйдәме икән? Сез белмисезме?

Солтан. Нинди Рәшат?

Гөлназ. Өйдә юк ул, өйдә юк.

Артур. Менә әйттем бит, ышанмаган идең.

Гөлназ. Әйдә, әткәй, өйгә керик.

Солтан. Әйдә, кызым. Тамак ялгарбыз да чыгарбыз, мин сиңа шәһәр күрсәтермен.

Өйгә кереп китәләр.

Камил. Ничек, ничек дидең әле син? Акрынрак сөйлә.

Артур. Ул турыда акрын сөйләп булмый! Акрын

сөйләргә ярамый! Мәрьям әнкәсен үләр дәрәҗәгә китереп җиткергән... Мин бер нәрсәне сорарга гына оныткәнмын. Нигә килгән иде икән ул Рәшатларга?!

Камил. Соңгы көннәрдә Рәшатның Мәрьямгә тартылуын ишеткәндер бәлки?

Артур. Мәрьямнең әнисенә кызы кем белән булса да барыбер түгелме, икән?

Камил. Кая олагыр бу егет?

Артур. Әнә кайта!

Рәшат керә.

Камил. Кая югалдың син?

Рәшат. Беләсең килә тагын үзеңнең! (*Артурга.*) Син, егет, миңа шуны әйт: Мәрьямнең кеме син? Дустымы, түгелме?

Камил. Син без сораганга жавап бир, Рәшат.

Рәшат. Камил, буталма. Син бернәрсә дә аңламыйсың. Иң яхшысы, китеп тор моннан! Минем Артур белән егетләрчә генә сөйләшәсем бар!

Артур. Ә минем юк.

Рәшат. Яратасыңмы син Мәрьямне?

Камил. Тукта инде, ничек алай сорарга мөмкин?

Рәшат. Тыгылма син, Камил! Йә, Артур!

Артур. Миннән җавап таләп итәргә кем соң син?

Рәшат. Кыз баланың язмышы белән уйнадың да хәзер читкә таймакчы буласыңмы?.. «Мәрьям белән без», «Мин Мәрьям белән!» дип һаваланып сөйли идең бит. Хәзер ни үзгәрде?

Артур. Ни үзгәргәнен миннән дә шәбрәк үзең беләсең ич!

Рәшат. Белсәм, сорамас идем!

Камил. Егетләр.

Рәшат. Китеп тор моннан, җебегән салма!

Артур. Менә бит син ничек... Иптәшне рәнҗетү сиңа берни тормый...

Рәшат. Күрә торып безнең сүзгә кысылмасын! Син дә читкә борма. Нәрсәсе үзгәрде Мәрьямнең?

Артур. Мәктәптә даны чыкты... Әнисе ничә мәртәбә директор янына килеп китте...

Рәшат. Ә син директор янына кичә мәртәбә кердең?

Артур. Нишләп керим мин анда?

Рәшат. Син бит ир кеше, егет! Мәрьям синең иптәшең... Син якларга тиеш идең аны!

Камил. Әнисен җәберләп яшәгән кызны Артур ничек якласын? Мин аның әти-әнисен синнән яхшырак беләм. Артур менә дигән гаиләдә үсә.

Р ә ш а т. Ә Мәрьямнең әнисен син барыбыздан да яхшырак беләсеңме, Камил? Эх, сез!.. Май демонстрациясенә чыккач, үги ана кулында үскән ятим кызга кул бирмәскә сүз куешканнар!

К а м и л. Ә син... артыңнан берәү дә иярмәгәнен абайладыңмы?

Р ә ш а т. Иң әрнеткәне дә шул булды! Димәк, без үзебез бернәрсә дә уйлый белмибез икән... Мәрьямнең анасы директорга имеш-мимешләр сөйли... Имеш-мимешләрне Артур башкаларга җиткерә... ә без... авызларыбызны бәлшәйтеп, колакларны шәңкәйтеп имеш-мимешләргә ышанабыз!..

А р т у р (*Камилгә*). Әйттем бит. Килеп йөрү генә калды!

К а м и л. Рәшат, көндез бер тапкыр бөтен классның кәефен кырдың. Инде кич очрашкач та кичәнең ямен җибәрәсе булма.

Р ә ш а т. Яратасыз да үз кәефегезне кайгыртырга!

А р т у р. Кичәгә барышлый кагылырбыз. Уйлана тор!

К а м и л, А р т у р чыгып китәләр. Рәшат йөгереп өйгә керим дигәндә генә, чиләк күтәреп чыгып килүче Г ы й л ь м и я г ә бәрелә, су түгелә.

Г ы й л ь м и я. Син?

Р ә ш а т. Гафу итегез, Гыйльмия апа. Хәзер алып кайтам.

Г ы й л ь м и я. Кайда йөрдең болай эт сугарып?

Р ә ш а т. Ничек? Ничек?

Г ы й л ь м и я (*ачуланып Рәшат өстенә килә*). Кайда йөрдең?

Р ә ш а т (*аптырап*). Гыйльмия апа, бүген бәйрәм ич. Демонстрациядә булдык.

Г ы й л ь м и я. Иптәшләрең әллә кайчан кайттылар!

Р ә ш а т. Бер мәшәкать килеп чыкты шул!

Г ы й л ь м и я. Ә монда анаң... Төнге сменадан кайтып сине көтеп газаплана!

Р ә ш а т. Өйдәме ул?

Г ы й л ь м и я. Авырый. Керми тор. Чак йоклап китте. Борчыма.

Р ә ш а т. Гыйльмия апа, чынлап авырыймы?

Г ы й л ь м и я. Менә бу телеграмманы укуга чак егылып китмәде.

Р ә ш а т (*телеграмманы алып*). Рәис абыйдан... Эх-х...

Г ы й л ь м и я. Шушы кулларым белән Рәисне дә иркәләдем бит... Тирбәттем... Бер тиен акча салыр ла... Бер хат!..

Р ә ш а т (*кычкырып диярлек*). Гыйльмия апа!

Өйдән Г ө л н а з чыга.

Г ө л н а з. Нигә шулай кычкырасыз сез?

Р ә ш а т. Ә сезгә нәрсә кирәк? Нигә катышасыз?

Г ө л н а з. Кычкыргач, кемнедер чакырасыз дип торам.

Г ы й л ь м и я. Балалар үсәләр дә ата-аналарын ташлыйлар, Гөлназ. Оныталар. Тәрбия итмиләр... Менә сез дә... Әнкәләрен хезмәтче хатынга әйләндерделәр!

Р ә ш а т. Сез... сез... дөрес сөйләмисез. Укып бетергән көнне үк мин заводка эшкә керәм... үзебез практика узган механика заводына... Әнкәйгә бер эш тә эшләтмәм!

Өйгә кереп китә.

Г ы й л ь м и я. Үз балаларым кебек якын итә идем мин аларны! Юанычым да, куанычым да шулар иде...

Г ө л н а з. Баядан бирле «Рәшат та Рәшат» диләр. Шулмы инде?

Г ы й л ь м и я. Әйе... Тукта, ни йомышлап йөри идем соң? Бакчага су сибим дигән идем бит.

Г ө л н а з (*аңа ияреп бара*). Болары кашкарыйлармы?

Г ы й л ь м и я. Яратасыңмы?

Г ө л н а з. Яратам! Төн гөлләрен ныграк яратам, Гыйльмия апа. Безнең бакча артыннан гына инеш ага. Ә без әткәй белән яр буйларын тутырып гөлләр чәчәбез... Гыйльмия апа, нигә сезнең бездә булганыгыз юк?

Г ы й л ь м и я. Анысын әткәңнән сора, кызым.

Г ө л н а з. Сорадым...

Г ы й л ь м и я. Белерсең әле! Калсаң, әнә шул Рәшат белән бер класста буласың инде. Ул да унынчыда бит.

Г ө л н а з. Булдыра алсам, калабыз инде. Әткәй, сездә торып торырбыз, ди.

Г ы й л ь м и я. Кунакка йөрешмәсәк тә, без әткәң белән иске дуслар.

Г ө л н а з. Без дә дуслашырбыз, яме, Гыйльмия апа.

Г ы й л ь м и я. Хәзер... дуслашырга да куркам. Дуслашасың, йөрәгеңнең бер өлешен дустыңа бирәсең дә, соңыннан үзеңә читен була. Шундый инде мин: мавыгуларсыз яши дә алмыйм үзем! Әмма бик ялгышам хәзер. Кешеләрне аера алмый башладым. Күңелемнең үткенлеге бетте...

Өйгә кереп китә. Гөлназ ялгызы. Ишетелер-ишетелмәс көнә җырлый.

Г ө л н а з. Нигә болай моңландыра яз?
Иртә-кичен күңел кузгала.
Язгы чәчәкләрдән күзен алмый,
Ник моңая икән кыз бала!

Л ә л ә керә. Өйгә керәсе була да туктала, Гөлназны күрә.

Л ә л ә. Исәнмесез.

Г ө л н а з. Хуш килдегез.

Л ә л ә. Сез Гыйльмия апалардамы?

Г ө л н а з. Ул өйдә. Рәхим итегез, керегез.

Л ә л ә. Юк, юк, кирәк түгел. (*Пауза. Икесе дә берберсенә сынашып карашалар.*) Сез кунакка килдегезме?

Г ө л н а з. Юк. Мин укырга дип килдем.

Л ә л ә. Шулаймыни? Берәр курскадыр инде?

Г ө л н а з (*елмаеп*). Сезгә Рәшат кирәкме?

Л ә л ә. Әйе дисәң дә ярый... Без бер мәктәптә укыган идек... Мин хәзер институтта инде! Беренче курста!

Г ө л н а з. Алайса, нигә өйләренә туп-туры барып кермисез?

Л ә л ә. Без бүген бераз үпкәләштек... Берәр нәрсә белән мавыкса, дөньясын оныта торган гадәте бар... Дөресрәге, бүген генә түгел инде...

Г ө л н а з. Нинди киңәш бирим икән соң сезгә? Мин Рәшатыгыз белән таныш та түгел...

Өйдән Р ә ш а т атылып килеп чыга. Аны күрүгә Гөлназ өйгә кереп китә.

Р ә ш а т. Ләлә! Мин сине көттем!

Л ә л ә. Бер син генә көтәсең микән мине? Корымга буялгансың.

Р ә ш а т. Аш җылытып йөрим.

Л ә л ә. Көтсәң, килдем инде менә. Ник көткәнеңне әйтеп кара.

Р ә ш а т. Сагындым...

Л ә л ә. Һе-е! Бер син генә сагынасыңмы мине?

Р ә ш а т. Алайса, нигә килүеңнең серен үзең белдер.

Л ә л ә. Кичкә хәтле сөйләшеп куясы иде.

Р ә ш а т. Ә, син дә шул хакта икән!

Л ә л ә. Шул хакта. Артурлар белән тагын бәхәскә кереп, бәйрәм кичәсенең ямен җибәрмә.

Р ә ш а т. Мин хаклы булсам дамы?

Л ә л ә. Булсаң ни? Алар күп. Күпчелек кайда — хаклык шунда. Борынгы хакыйкать.

Р ә ш а т. Ә Мәрьям?

Л ә л ә. Мәрьям бәйрәмгә килми ич. Аны чакырмадылар!

Р ә ш а т. Аны мин чакырдым!

Л ә л ә. Чакырмадың!

Р ә ш а т. Чакырдым. Ул киләчәк. Ул килер. Ул килми икән, мин кичәгә катнашмыйм.

Л ә л ә. Ә мин?

Р ә ш а т. Син дә катнашмыйсың булып чыга.

Л ә л ә. Ансат хәл итәсең син!

Р ә ш а т. Киресенчә, сез бик ансат уйлыйсыз!

Л ә л ә. Рәшат! Институттагы бик күп күңелле кичәләрне ташлап, бәйрәмне сезнең белән үткәрергә булдым. Синең үтенечне тыңлап!

Р ә ш а т. Рәхмәт, Ләлә.

Л ә л ә. Ә хәзер кичәгә бармыйбыз дисең...

Р ә ш а т. Ә без — син, мин, Мәрьям — өчебез аерым кичә уздырырбыз.

Л ә л ә. Өчебез?! Ә мин кичәгә Раян абыйны да чакырган булсам?

Р ә ш а т. Минем аны чакырганым юк.

Л ә л ә. Минем дә Мәрьямне чакырасым килми. Бу дөньяда синнән башка берәү дә юк дип уйлыйсыңмы әллә?

Р ә ш а т. Әйе. Дөньяда хакыйкать бар. Ул бер. Мин аңа табынам, Ләлә, китмә әле! (*Сүзен әйтеп бетерә алмый, ишектә хәле киткән Хәдичә күренә. Рәшат йөгереп аның янына бара. Ләлә агачлыкка атлый.*) Әнкәй!

Х ә д и ч ә. Кайттыңмы, балам.

Р ә ш а т. Әнкәй, хәлең ничек, әнкәй?

Х ә д и ч ә. Авырмыйм, балам, юк. Авырмыйм. Ләлә нигә күренми? Килсен. Син кайтуга кайнар аш өлгертә алмадым шул. Әллә нишләп йоклап киткәнмен. Оятлы булдым. Менә тинтәк.

Р ә ш а т. Җылыткан аш та бик тәмле, әнкәй. Карын ачып кайткан иде...

Х ә д и ч ә. Без дә Гыйльмия апаң белән бик күңелле утырдык. Мин кайтуга, безнең урамнан демонстрация уза башлады. Карарга чыктык. Ул халык, ул халык! Сәламәтләр, көләчләр...

Р ә ш а т. Ял иткәнсең, күңелең күтәрелгән.

Х ә д и ч ә. Йөрәк аз-маз чәнчеп алгалый... Менә бергәләп кайнар чәй эчеп тә җибәрсәк, анысы да узар. Ләлә нигә безнең янга килми?

Р ә ш а т. Чәй куйыйммы, әнкәй?

Х ә д и ч ә. Үзем, үзем! Кичәгезгә барасыңдыр? Зарыгып көткән идең син аны... Ләлә алырга да кергәнмени? Чәй ашлары әзерләп каршы ала алмадым шул.

Р ә ш а т. Бармам, ахры, ул кичәгә мин, әнкәй.

Х ә д и ч ә. Иптәшләрең белән тынышмыйсың, балам...

Р ә ш а т. Синең янда, өйдә утырырмын.

Х ә д и ч ә. Мине саклап ятарга, чирлеме мин?

Р ә ш а т. Әйдә, әнкәй, өйгә керик. Авырыйсың син.

Х ә д и ч ә. Кояш сукмадымы икән мине? Башым әйләнә... Рәис абыеңның телеграммасын күрдеңме?

Р ә ш а т. Бүген үк хат язам мин аңа! Суганын-борычын җәлләмичә!.. (*Хәдичә һушы китеп болдырга егыла.*) Әнкәй, әнкәй! Ләлә!

Л ә л ә. Ни булды, Рәшат?

Р ә ш а т. Йөгер! Су алып чык.

Л ә л ә. Хәзер. (*Кереп китә.*)

Р ә ш а т. Әнкәй, әнкәй!..

Хәдичәне күтәреп эскәмиягә яткыра. Өйдән С о л т а н, Г ы й л ь м и я, Г ө л н а з, Л ә л ә чыгалар. Тавыш, ыгы-зыгы.

Г ы й л ь м и я. Хәдичә, ни булды, Ходаем?

Р ә ш а т. Егылды. Әнкәй егылды!

С о л т а н. Тизрәк врач чакыртырга кирәк.

Г ы й л ь м и я. Хәдичә, Хәдичә дим... Үз-үзеңне аямыйсың шул син. Бәйрәм көнне врачын каян... Машинамазар булса, больница монда, урам аша гына...

Урамнан А р т у р керә.

А р т у р. Рәшат, син ничек? Әзерме?

Л ә л ә. Тс-с-с!

А р т у р. Хәдичә апага ни булды?

Р ә ш а т. Беләсеңме... Әнкәй һушын җуеп егылды...

Г ы й л ь м и я. Солтан, телефон шунда чатта гына. Ноль өчкә шалтырат. Тиз бул! (*Солтан чыгып китә.*)

Х ә д и ч ә (*калкынып*). Әллә врач чакыртасыз инде? Кирәкми.

Г ы й л ь м и я. Сөйләшми тор. Синең хәлең юк. Мә, су йот.

Х ә д и ч ә. Каралдым инде. Докторлар алар күзгә күренгән чирне генә ансат табалар...

Г ы й л ь м и я. Ят беләгемә. (*Аны кочып тора.*)

Р ә ш а т. Кайсы төшең авырта, әнкәй? Тагын йөрәгеңме?

Х ә д и ч ә (*торып утыра. Чәчен рәтли*). Узар, узар, балам.

Г ы й л ь м и я. Эх, Хәдичә... Уза узуын...

Х ә д и ч ә. Бала чагымда, эшләгәне генә җитмәгәч, әнкәй мескен хәер сорашырга чыга иде. Подвалда яши идек без. Салкын буранлы көннәрдә чиркәү каршысына чыгып баса иде бичара. Бозлы тәрәзә төбенә түшем белән ятып, аңа карап торам. Күпләр үтеп китәләр, берни бирмиләр иде... Күңелемнән: «Нинди мәрхәмәтсез кешеләр бар дөнья йөзендә!»— дип сыкрый идем... Безнең заман шундый иде, барын кичердек... Хәзер нәрсә... Үзебез рәхәт татый алмадык, ичмасам, балаларыбыз күрсен дип гомер буе тырышабыз... Нурислам шулай яшәде... Үлеп

китте... Безнең балалар да миһербансыз, мәрхәмәтсез булырлар дип кем уйлаган... Гыйльмия!

Гыйльмия. Мин монда, җаным.

Хәдичә. Монда шул. Син дә монда. Синең дә балаларың юк. Кыры янган пар тургайлар күк без...

Гыйльмия. Нигә алай дисең? Менә Рәшатың!

Артур. Рәшат!

Ләлә. Мәрьям дип өзгәләнгән була тагын!

Хәдичә. Рәшатка сүз әйтмәгез. Әле берни дә эшли белми ул. Рәшат — яшь...

Гыйльмия. Хәдичә, башка балаларыңа үпкәлә, мәгәр Рәшатка сүз әйтәсе булма.

Хәдичә. Һәммәсенә бер йөрәк кенә бирелгән шул... Олысы өчен кайгырганда, төпчеге өчен дә кайгырыла...

Солтан керә.

Солтан. Такси тотып алдым.

Гыйльмия. Ул да ярап торыр. Үзебезнең больницага гына алып барырбыз. Яле, Гөлназ кызым, булыш миңа. Син, Рәшат, өйдә генә кал.

Рәшат. Әнкәйне үзем илтәм.

Гыйльмия. Күренми тор бераз. Аңла!

Рәшат. Аңлый алмыйм, Гыйльмия апа... Бернәрсә аңламыйм!

Солтан, Гыйльмия, Гөлназ Хәдичәне алып чыгып китәләр. Машина кузгалган тавыш.

Ләлә. Алып киттеләр...

Артур. Хәдичә апаның таныrлыгы калмаган...

Рәшат. Рәис абыйның телеграммасы!.. Алар гаепле монда...

Артур. Тукта әле, нигә гаеплене эзли башладың?

Ләлә. Ни сәбәпле Мәрьямгә тартылуың ачыкланды, Рәшат.

Рәшат. Ни сөйлисез сез? Безнең өй эченнән сез нәрсә беләсез?

Артур. Күрдек бит. Күргәне җитәр.

Раян керә.

Раян. Әй, шевелюра! Нигә моңайдың?

Ләлә. Раян абый!

Раян. Үзе.

Ләлә. Әйтергә дә уңайсыз... Укучылар арасында ошап бетәрме икән сиңа, Раян абый?

Раян. Тырышып карагыз! Мәҗлесне миңа ошарлык итәргә тырышыгыз.

Л ә л ә. Мәҗлес түгел, кичә.

А р т у р. Тән чымырдап тора әле бүген.

Р ә ш а т. Әнкәйне больницага алып киттеләр... Һәм Гыйльмия апаның мине ияртәсе килмәде.

Р а я н. Мәктәпнең алдынгы комсомолецы бүгенге мәҗлеснең үзәгендә була алмас, алайса?

Р ә ш а т. Димәк...

Р а я н. Дөрес. Ял ит, җүләр. Йөрмә.

Л ә л ә (*салкын гына*). Бармыйм дисеңме?

А р т у р. Соңга калмыйк.

Р ә ш а т. Барыгыз.

А р т у р. Ахыр чиктә, берәр сүз әйт инде! Мин сине әнкәңне начар караганың өчен гаепләмимм. Юк, анысы минем вазифага керми. Синең моңарчы гаделлек сакчысы, фәрештә булып кылануыңа гына гаҗәпләнәм.

Р ә ш а т. Ләлә, барма. Калдырма ялгызымны!

Л ә л ә. Ничек инде, Рәшат? Кунаклар алдында оят булыр.

Чыгалар. Рәшат ялгызы.

Р ә ш а т. Китте. Киттеләр. Әнкәй дә, Ләлә дә...

Җиргә чүгәли. Г ө л н а з керә.

Г ө л н а з (*акрын гына Рәшат янына килә, карап тора*). Әллә җылыйсың инде син? Алай булгач, син ул тиклем бозылмаган әле.

Р ә ш а т. Син кем?

Г ө л н а з. Җыла син, җыла. Дәшмә. Мин сиңа комачауламам.

Сәхнә караңгылана. Пәрдә төшә. Музыка. Пәрдә ачылганда шул ук сәхнә. Флаг кына алынган. Агач араларында гөлләр. Аларның кайсыберләре шау чәчәктә. Өй тәрәзәләре ябык. Пәрдә ачылганда сәхнәдә Г ы й л ь м и я белән С о л т а н. Солтан еш-еш суырып тәмәке тарта. Гыйльмия алъяпкыч япкан, җиңнәрен сызганган, чәчәкләр белән булаша. Агачлыктан Гөлназның җыры ишетелә. Ул үзе күренми.

Г ө л н а з. Каурый кебек җиңел болытлар
Зәңгәр күккә сыенып үттеләр.
Күрдеңме син,
Өлгердеңме
Күз салырга аларга?
Сагыну утларында янарга,
Сагыну утларында янарга!..

Г ы й л ь м и я. Көндәгедән иртәрәк кайттың бүген.

С о л т а н. Кайттым шунда. Төштән соң юньле эш тә булмады. Измә китермәделәр. Измә көтеп утырганда бе-

тон-измә заводыннан комиссия килде. Халык контроле килгән! Буталдылар шунда...

Г ы й л ь м и я. Ашыйсың киләдер?

С о л т а н. Буфетка кагылдым...

Г ы й л ь м и я (*санап*). Бер, ике, өч... Утыз ике төп.

С о л т а н. Болары да үсәр дисеңме?

Г ы й л ь м и я. Кызлар кулы тигәч, үсмиме ди? (*Пауза.*)

С о л т а н. Безнең китәр көннәр якынлаша... Кайтасы килә башлады.

Г ы й л ь м и я. Миңа тагын ямансу булыр инде. Тагын мавыгылды. Гел шулай, мавыгам да җәфаланам!

С о л т а н. Үзеңә шундый бер кыз үстерергә иде, Гыйльмия.

Г ы й л ь м и я. Чү!

Солтан янына килә, икәүләшеп Гөлназның җырын тыңлыйлар.

Г ө л н а з. Шул болытлар минем хыялларны
Үзләренә иптәш иттеләр...
Күрдеңме син,
Өлгердеңме
Күз салырга аларга?
Сагыну утларында янарга,
Сагыну утларында янарга...

Г ы й л ь м и я. Кыз дисең син, Солтан. Мөмкин идеме соң ул? Гражданнар сугышын тәмамлап, Казанга кайтып урнашкач, Арыслангәрәемне сагынып җылаган чакларда: «Ичмасам, балабыз булмаган»,— дип өзгәләнә идем. Чит илдә, ак эмигрантлар газетасы: «Арыслангәрәй разведкага барган җиреннән Кытайга качты»,— дип язып чыккач, монда да хәлләр булды... Ул чагында исә ялгызлыгыма куандым. Берия шайкасы фаш ителгәч кенә Арыслангәрәйнең кисәк-кисәк туракланып үтерелүе мәгълүм булды.

С о л т а н. Мин аның хыянәт итүенә бер чакта да ышанмадым.

Г ы й л ь м и я. Соңра, яхшы гына адәмнәр кияүгә димләп карады, чыкмадым. Аннары күршегә Хәдичәләр күчеп килде, ишегалды тулы бала булды. Сөяргә генә өлгер идең!

С о л т а н (*кырыс*). Әйе, шулай дип сөйлиләр...

Г ы й л ь м и я. Күңелемне ачып салдым, сиңа ошамады. Курыкма, сиңа төрттерергә уйлаганым юк. Гәрчә, бераз төрттергәндә дә яраган булыр иде. Эштән нигә иртәрәк кайттым дисең әле?

С о л т а н. Әй, вак-төяк чуалчык була ла эштә!

Гөлназ керә.

Гөлназ. Әткәй, мин су коенырга барыйммы?

Солтан. Коен, кызым. Тик сак йөр. Рәхәтләнеп кал, китәргә дә күп калмый...

Гөлназ. Башланмаган бер ай бар ич әле! (*Чыга.*)

Солтан. Су коенам, диде. Үзе бит яулыгы да алмады.

Гыйльмия. Чыннан да. (*Пауза.*) Ай Аллам, сәгать алты булган лабаса. Хәдичә янына барырга соңга калам бит.

Солтан. Берәр көн бармасаң, ярамасмы? Үзең дә ялга мохтаҗ.

Гыйльмия. Рәшат кайткач, бергәләп барырга сөйләшкән идек.

Солтан. Гыйльмия! Байтактан бер сүз әйтмәк булып йөрим. Салават күпере дип алданып, сабын куыгы артыннан гына йөрисең бит син.

Гыйльмия. Шулай да булсын ди. Тагын ни әйтерсең?

Солтан. Башка балаларын белмим, мәгәр Хәдичәнең бу малае өметле түгел. Укуын ташлавына да кул куймадым, әйе...

Гыйльмия. Анысын мин дә хупламадым.

Солтан. Хәзерге заманда, аяз көндә пар нарат арасында адашкан булып йөрүе бер дә егетлек түгел.

Гыйльмия. Ярый. Анысын мин дә шулай уйлыйм ди. Шуннан нәрсә?

Солтан. Нәрсә дип, үзең беләсең!

Гыйльмия. Ху-уш! Рәшат начар егет ди. Риза! Начар егет! Җайсыз егет! Энәле егет! Шырпылы егет! Мин нишләргә тиеш инде, синеңчә? Юк-юк, сөйләшәсең икән, күзгә кара!.. Мин бит телгә генә ышанмыйм, миңа кешенең күзе дә кирәк! Җаны!..

Солтан. Үзеңә тынычрак булыр иде диюем...

Гыйльмия. Мәктәптә нинди гауга купканын беләсең бит! Хәдичәнең кайнарлык белән әйтеп ташлаган сүзләре янган утка май булган анда. Тик бел: гауганың сәбәбе тирәнрәк!.. Рәшат яхшы укый. Тырыш... Дөньяда иң читене тырыш кешеләргә икәнлеген беләсеңме син? Аларны яратмыйлар, эшчәннәрне күпләр сөймиләр. Чөнки алар гел хәрәкәттә, гел үсештә... Тырышлыклары белән ялкауларга комачаулый алар... Ярый, мин дә кул селкедем ди Рәшаттан! Барыбыз да әйбәт, татулар, аны юк дип саныйк ди... Менә минем иремә кара ягылганга утыз ел узса да, партия ул эшне кабат карауны тиеш тапты. Миллионнардан берәү, рәхмәт төшсен аңарга, туктачы, бу Арыслангәрәйне нигә әле акгвардиячеләр «без-

нең егет» дип язып чыкты соң, монда бер-бер әшәке ният юк микән, дип актарына башлаган. Кул кушырып тормаган. Гафу ит, Солтан, мин карт булсам да, коммунист. Бер шырпыдан кабынмыйм, мәгәр, кеше яккан учакларда кызынып йөрүчеләрдән дә түгелмен!

Солтан. Уйла дип, киңәш бирергә теләвем генә...

Гыйльмия. Артык озак уйланырга яратасың, Солтан!

Солтан. Замана шуңа өйрәтте бит, Гыйльмия.

Гыйльмия. Дөрес түгел, ай, дөрес түгел, Солтан. Замана безне көрәшергә өйрәтте. Бирешмәскә өйрәтте. Сатмаска өйрәтте. Сатылмаска өйрәтте... Үз-үзеңнең йомшаклыгыңны акларга теләп, күләгәгә кермә син!.. Ярар. Соңга калдырасың мине.

Солтан. Рөхсәт итсәң, мин дә иярер идем.

Гыйльмия. Тик бер шартым бар: Хәдичә янына кергәч, Рәшатның мәктәпне ташлавы турында ләм-мим.

Солтан. Ана күңеле болай да сизәдер инде... Күлмәгемне генә алышып чыгыйммы?

Гыйльмия. Бар.

Солтан өйгә кереп китә. Капкадан Юан хатын керә.

Юан хатын. Әйтегезче, йомшагым, бу кеше озак торырга килдеме?

Гыйльмия. Нәрсә кирәк иде сезгә?

Юан хатын. Беләсем килә: пропискага кергәнме ул, юкмы?

Гыйльмия. Ни өчен беләсегез килә инде сезнең?

Юан хатын. И-и, күгәрченем. Белгән нәрсә комачауламый ул! Корал ул белгән нәрсә!.. Кулымнан килсә, бөтен дөньяның серен тик үземнеке итәр идем. Кайчаннан бирле бутала бу абзый, нишләп китми?

Гыйльмия. Чыгып китегез моннан!

Юан хатын. Урыны, урыны! Люкс! Тормыш түмен бәһали тоган ханымга охшамыйсыз сез! Юк, юк!..

Юан хатын чыга. Солтан керә.

Гыйльмия. Карачкы!

Солтан. Ә мин ару күлмәгемне киеп чыккан булам тагын.

Гыйльмия. Сиңа әйтмим лә! Соңга калабыз.

Чыгалар. Пауза. Ләлә белән Камил керәләр, ишекне тартып карыйлар.

Ләлә. Өйдә юклар!

Камил. Сиңа зур куаныч булды бусы.

Л ә л ә. Гыйльмия апа бу вакытта Хәдичә ана янында больницада була.

К а м и л. Рәшатны күрми китмибез, Көтик.

Л ә л ә. Вакыт бик кадерле. Камил.

К а м и л. Китапларың янында. Укый тор. Мин дә укыйм.

Л ә л ә. Әгәр минем өйдә эшләрем булса?

К а м и л. Аларын гадәттәгечә әбиең белән әниең карар.

Л ә л ә. Белдең бик! (*Иреннәрен турсайтып утыра. Икесе дә укый башлыйлар.*) Камил, исеңдәме? Мәрьям өчен Рәшатны ничек гаепләп йөргән идең син! Карчыгадай ташланган идең!.. Бүген үзең Рәшат кебек үк вак.

К а м и л. Укы. Зиһенең ачылыр.

Л ә л ә. Шул Мәрьямнең нәрсәсенә кызыккандыр ул!

К а м и л. Тагын нинди акыллы сүзләрең бар? Бөтенесен әйтеп бетер дә, телең ял иткән арада, мин азрак дәрес карармын.

Л ә л ә. Кызлар белән сөйләшә белмисең син. Өйрәнәчәк тә түгел... Сине тыңлап килде дип һаваланма, үзем... үзем... (*Урамнан узып баручы Артурны күреп кычкыра.*) Күрче, кем ул? Артур!

А р т у р. Камил нишләп монда утыра? Җитмәсә, үзе генә дә түгел.

К а м и л. Син дә монда кер.

А р т у р. Китапханәгә барам. Бераздан кагылырмын. Ризамы?

Л ә л ә. Мин ул беразны көтәргә тиешме?

К а м и л. Юк. Хәзер үк кер.

А р т у р (*кереп*). Магнит буласың килә инде? Үзәккә урнашасың килә?

К а м и л. Утыр монда. Ләлә, син монда.

А р т у р. Бер минуттан ары утырмыйм.

К а м и л. Шакир абый әйтә...

А р т у р. Нафталинлы класс җитәкчесе нәрсә ди? Хаха, тапкансың классикны! Цитировать итәсең!

К а м и л. Рәшат имтиханнарын бирергә тиеш, ди.

А р т у р. Шакир абыйга матур отчет кирәк. Анысы ачык. Нигә Ләләне иярттем дисең? Ә-ә, хәрби стратегия. Бөтен юнәлешләрдән һөҗүм!

К а м и л. Рәшат белән очрашып сөйләшик.

А р т у р. Мәктәпне ташлап, нче участокка кара эшче булып кергәндә бездән киңәш сорамады бит!

К а м и л. Егетләрчә юньләп сөйләшкән дә юк ич безнең!

А р т у р. Анысы инде, Камил дус, синдәй активистлар эше.

К а м и л. Китәсеңме?

А р т у р. Менә монысы минем эш. (*Кузгала. Бераз баргач туктый.*) Нигә күз буярга? Яхшы булып нигә кыланырга? Син монда Рәшатны көтәсеңме? Легендалар дөньясыннан пәйда булган Гөлназ кирәк ич сиңа! Менә нәрсә. (*Югала.*)

Л ә л ә. Дөрес! Мин, ачык авыз, вөҗданым кушмаган хәлдә, сиңа ияреп йөрим. Барыгызга да кызыл ирен кирәк! Рәшатка да, сиңа да! Тинтәк мин! Тинтәк! (*Чыга башлый, шып туктый.*) Камил, әнием килә! Монда мине күрсә, бетте баш!

Агачлар арасына кереп кача. Н ә җ и б ә керә. Ишекне тартып карый, борылып килгәндә Камилне күрә.

Н ә җ и б ә. Камил?! Нишлисең монда?

К а м и л. Минем монда булуым гаҗәп түгел, Нәҗибә ханым. Менә сезнең...

Н ә җ и б ә. Ләләмнең бер китабы калган иде. Эштән кайтышлый кереп ал, диде Ләләм. Өйдә юклар икән.

К а м и л. Үзе кереп алса ярамаганмы? Һаман сезне йөгертә.

Н ә җ и б ә. Йөгерәм! Фигурам бозылмас! Аннары Рәшат кебек бандит янына нишләп минем кызым кереп йөрсен?

К а м и л. Бандит ук икән!

Н ә җ и б ә. Һай, надан! Син бүген безнең участокта ниләр булганын күрсәң... Төштән соң берәү дә юньләп эшләмәде, барысы да шул бандит аркасында!.. Ә безнекеләр, безнекеләр... «Син югал моннан! Син теләсә кемне сата аласың. Кыйнап, әтиеңне кабергә, әниеңне больницага керткәнсең!» дип кычкырдылар.

К а м и л. Шул гына җитмәгән иде! Ул кара гайбәтне, Рәшатны мәктәптән китәргә мәҗбүр иткән нахак сүзне эшчеләр арасына кем җиткерде?! Кайсы явызы!

Н ә җ и б ә. Килде начальство, килде башлыклар! Гомер узып андый тамашаны күргән юк иде.

К а м и л. Кем таратты шул гайбәтне дим мин?!

Н ә җ и б ә. Һи-и, эте-бете азмы бу заманда? Теге, сезнең белән укый башлаган зәгыйфь аяклы кыз, Рәшат янына эшкә килеп йөргән була... Рәшат күк тиле-милене каратмаса, ул аксакка кемнең күзе төшсен?

К а м и л. Мин уйлаганга караганда күп мәртәбәләр көчлерәк икән бу гайбәт!

Тыңлап торган җиреннән чыдамы беткән Л ә л ә атылып чыга.

Л ә л ә. Җитте, әнием!

Н ә җ и б ә. Ләләм, син дә мондамыни?

Л ә л ә. Телеңне шулкадәр тыя алмассың икән!

Н ә җ и б ә. Шымчылык иттеңме?

Л ә л ә. Иттем...

Н ә җ и б ә. Ярар, ишеткәнең файдага булсын, Ләләм. Тик, зиһенем җитми, аңламыйм: аты-чабы чыккан бу йортка ничек аяк басасы иттең? Кызның исеме кыл өстендә, кылдан төшсә, ил өстендә!

Л ә л ә. Әнием, кыскарак тот!

К а м и л. Нишләргә? Ничек араларга Рәшатны... Гөлназны...

Н ә җ и б ә. Сине шушы каһәр суккан йортта күрим дә ди, дуламыйм да ди. Рәхәтләнеп дулыйм! Көне буе ачуыма буылып йөргән идем. Яхшы кешеләр ни уйлар? Раян Булатович... Хәер, күп сөйләшмәскә куштың бугай... Бандит янына кереп йөргән кыз бала турында бөтен Казан ишетер!!!

Л ә л ә. Әнием, үзең ишеттерәсең бит.

Н ә җ и б ә (*аның саен кыза төшеп*). Камил, син ияртеп килдеңме Ләләмне?

К а м и л. Рәшат безнең дустыбыз.

Н ә җ и б ә. Ни сөйли бит! О-о, башы беткере! Дөмеккере! Адәм баласына җәфа булып туган затлар!.. Тфү! Ләләм, кит Камил яныннан, кит, әшәкесе йогар!

К а м и л. Нигә дәшмисең, Ләлә? Әллә Рәшат файдасына бер генә сүз дә әйтә алмыйсыңмы? Кайчандыр ярата идең бит син аны!

Н ә җ и б ә. Ялган! Яла! Гайбәт таратасың, малайский тавык баш.

Л ә л ә. Рәшат минем дустым түгел. (*Ул сөйләгәндә Нәҗибә зур канәгатьләнү белән башын кагып тора.*) Дус итәрлек кеше чишмәдәй саф булсын ул, Камил. Фәрештәдәй йомшак җанлы булсын.

Н ә җ и б ә. Тормышта андый кешене табарга мөмкин булганда, юлдан язган Рәшат кемгә кирәк? Минем кызым! Үз кызым! Үз каным, фигылем, афәрин, бу малайның авызын каплadың!

Л ә л ә. Ә хәзер... тизрәк моннан китик, әнием.

К а м и л. Рәхмәт, Ләлә.

Н ә җ и б ә. Җавап бир, кызым. Безнең нәсел шундый. Яманны җәзасыз калдырма.

Л ә л ә. Ярар инде, әнием...

Н ә җ и б ә. Юк, юк.

Л ә л ә. Рәшатның үз юлы, минем үземнеке. Җитәрме, әнием?

К а м и л. Юкка алып килгәнмен сине Рәшат янына дияр идем... үземә файдасы булды!.. Синең ишеләрдән

бары тик качып кына котылып була дияр идем... Рәшат тагын барып капкан!..

Л ә л ә. Камил, кая барасың?

К а м и л. Кая барырга кирәклеген син әйтеп бирдең, Ләлә! (*Чыга.*)

Л ә л ә. Камил, Камил!

Н ә җ и б ә. Әрәм итмә тәмле телең шул селәгәй малайга!

Л ә л ә. Үпкәләде. Синең дә шул, төкерегең ярага эләксә, җиде чакрым чабарсың.

Н ә җ и б ә. Кара, кара! Бот буе малайга исе киткән.

Л ә л ә. Үзе бот буе булса да, абыйсы безнең институтта укыта. Шундый чибәр абый, үзе өйләнмәгән, квартирасы бар!

Н ә җ и б ә. Укыган кешегә кызыкма син, мал табардаена кызык! Җаны булсын, малы булсын! Җанын учында, малын юлында тот! Укыганның күзе утта, белерсең әле. Һәй, нәрсә әле без, тиле күкеләр сыман, чит кеше ишегалдында кычкырышабыз? Ызгышырга үз өебез беткәнмени?

Л ә л ә. Китап дип яңадан керәсе булма, калса калыр!

Чыгалар. Кечкенә пауза. Ю а н  х а т ы н керә.

Ю а н  х а т ы н. Үзгәрешләр... Үзгәрешләр тели күңелем!.. Урыны, урыны... Болар ише җир кортлары яши торган урынмы соң бу?.. Кызны куып чыгарабыз... Фатирны сатабыз... Әһә! (*Солтан Гөлназны ияртеп кайтып керә, чырае сытык.*) Әй, сез! Кайчан китәсез инде моннан?

С о л т а н. Безме?

Ю а н  х а т ы н. Сез инде, сез. Син һәм синең кызың. Без китәргә килмәгән!

С о л т а н. Бер көн тормас идем, бер көн!

Г ө л н а з. Әткәй!

Ю а н  х а т ы н. Сүзең өметле яңгырады... Үзгәрешләр көтеп җирси минем нечкә күңелем... Эх-х-ма! (*Чыга.*)

Г ө л н а з. Нинди куркыныч апа...

С о л т а н. Куркынычның кайсы яктан янавын сизмисең әле син. Уйламыйсың.

Г ө л н а з. Ачуланышмыйк, әткәй.

С о л т а н. Су коеныргa бара, имеш. Ә мин аңа ышанып, колагымны шәңкәйтеп озатып калган булам...

Г ө л н а з. Барырга ниятләп чыккан идем, әткәй! Больница яныннан үтеп китәм дигәндә... Рәшат очрады.

С о л т а н. Безне күргәч, нигә качты?

Г ө л н а з. Белмим.

С о л т а н. Намусы саф түгел, вөҗданы керле! Шуңа кача!

Гөлназ. Рәшатның моңаеп басып торганын күрдем дә янына килдем.

Солтан. Беләсеңме, ул малай бүген ниләр бутап бетерде? Үзен чак тәпәләп ташламадылар.

Гөлназ. Ни өчен, әткәй? Нәрсә өчен?

Солтан. Яши белмәгәне өчен.

Гөлназ. Син нигәдер куркасың. Мине Рәшаттан читләштерәсең килә. Нигә?

Солтан. Әйтсәм әйтим...

Рәшат белән Гыйльмия күренәләр. Солтан, кулын селкеп, бер читкәрәк китә. Рәшат эш киеменнән, күн итек кигән, чәчен кыскарткан, кояшта каралган. Ул теләр-теләмәсрәк кенә ияреп килә!

Гыйльмия. Больница янына барып җиткәч, әнкәй янына керми китәләрме? (*Солтанга.*) Соңга калдык. Бер какча гына сестра туры килде, ләң-ләң өрә, тәки кертмәде. Әйберләрне көч-хәл белән алды. (*Ишеккә бара башлый.*)

Солтан. Ачкыч миндә.

Гыйльмия. Чәй куя торасыгыз калган. Рәшат та ачыккандыр. (*Өйгә керә, тәрәзәләрне ачып җибәрә.*)

Солтан. Кәефләр ничегрәк, яшь егет.

Гөлназ. Әткәй!

Рәшат. Сез миңа гел «яшь егет» дип эндәшәсез. Минем исемем бар.

Солтан. Шулай икән? Исемең дә бар икән, ә? Ә минемчә, юк!

Рәшат. Томанлырак сөйлисез.

Солтан. Үз исемен һәркем көч куеп ала. Шәп әйттемме? Менә мин ташчы. Гөлназ укучы. Ә син кем?

Рәшат. Менә хәзер һәркем аңларлык булды.

Солтан. Кыен булыр сиңа яшәү.

Рәшат. Миңа ансаты кирәкми.

Гөлназ. Әткәй!

Солтан. Син аны яклама! Син берни дә белмисең!

Гөлназ. Юын, дим... Өс-башыңмы алыш, дим...

Солтан. Әле ярый үзем монда калганмын... Ялгызыңны яшәтерлек түгел икән монда, юк икән! Ялгышма, кызым! (*Чыга.*)

Рәшат. Әйтеп бетерсен иде. Тегендә,囗 эштә, ул дәшми калды!.. Сүз әйтәсе дә килде, дәшмәде!

Гөлназ. Нәрсә булды соң, Рәшат?

Рәшат. Прораб миңа башка җирдән эш эзләргә кушты.

Гөлназ. Нишләп алай? Үзе чакырып алган иде бит!.. Начарлык кылдыңмы?

Р ә ш а т. Яхшы булсын дип тырышкан идем.

Г ө л н а з. Яхшылык кешеләрне алай усалландырмый, Рәшат. Әткәйнең болай ачуланганын хәтерләмим мин. Рәшат, тормышта усал кешеләр бик аз.

Р ә ш а т. Килешәм. Мәгәр алар бар!

Г ө л н а з. Нигә гел сиңа гына очрап торалар алар?.. Нигә миннән дөреслекне яшерәсең?

Р ә ш а т. Мин яшермим, Гөлназ. Алар яшерергә телиләр! Алар! Прораб һәм аның әшнәләре! Берничә генә кеше алар, шулай да барысын өркетеп торалар.

Г ө л н а з. Сүзләрнең катысын сайлыйсың син.

Р ә ш а т. Һич алай түгел, Гөлназ! Мин әле йомшакмын. Йомшаклыкның сәбәбе дә бар: ни эш күрсәткәнем бар соң? Ир-егетнең сүзеннән алда эше иярергә тиеш. Беләм. Ә мин яңа башладым, сүз кузгатырга иртәрәк тә кебек... Әллә шуңамы, алар беравыздан «сатлык җан!» дип акырышканда җебедем дә төштем. Авызым ачам, сүзем чыкмый... Әткәң шунда сүзгә катнашырмы дип торам... Минем хаклы икәнемне белә ич ул!

Г ө л н а з. Тагын ничек ерып чыгарсың инде?

Р ә ш а т. Унтугызынчы кварталны ике ел салалар инде. Мин шунда эшлим. Җиде торак йорт, мәктәп, балалар бакчасы салына... Атна элекме, ун көнме шунда, төзелешкә бульдозер килде. Ишегалдындагы тауларны хәтерлисеңме, шуларны тигезләргә.

Г ө л н а з. Хәтерләмичә! Йә, йә.

Р ә ш а т. Бульдозер эшли, берзаман астан машина-машина измә калдыклары чыга, тимер детальләр, тәрәзә рамнары, ишекләр...

Г ө л н а з. Шуннан?

Р ә ш а т. Квартал көзгә өлгерергә тиеш. Тизләтәбез дип материалларны язын-көзен чикләүсез биргәннәр. Салкынрак көн булдымы, эшчеләр эчтә утыра, измә ката, туңа! Туңган измәне машинасы-машинасы белән тондырганнар, ыргытканы бере кар, балчык арасына уралып аста кала барган. Күпме агач материалларны яндырганнар, ватканнар, металл, такта әрәмгә киткән.

Г ө л н а з. Прораб ни караган?

Р ә ш а т. Раян абыймы? Кышкы сезонда бөтен җирдә шулай эшлиләр ди ул. Санарга яратам шул мин! Тоттым да беркөн күпме цемент, нихәтле материал юкка чыкканын санадым. Математикадан гел бишле иде бит минем. Артур, кабак баш, гел көнләшә иде. Иптәшләргә санын әйттем. Әрәм булган цемент — тау икән; аста ятып черегән металлны прокат станы аша үткәреп калай ясасаң, төзелеш мәйданын тоташтан капларлык калай чы-

гачагын исәпләп бирдем. Менә шул. Гап-гади арифметика.

Гөлназ. Бик үк гади түгел икән шул.

Рәшат. «Кит» диделәр. Киттем. Кая барыйм?.. Әнкәй янына инде...

Гөлназ. Үзең аның янына да кермәгәнсең...

Рәшат. Кызган шәпкә барын сөйләп ташлармын дип курыктым. Аңа ярамый... Әнкәйне хәзер бик нык сакларга кирәк!

Гөлназ. Мин әткәй белән сөйләшермен.

Рәшат. Нәрсә ул мич арасында сөйләшү! Тегендә, төзелеш мәйданында әйтсен иде ул үз сүзен! Сөйләшмә син аның белән!

Гөлназ. Мин кеше түгелмени? Син әнә кемнәр белән бәхәскә керә аласың, мин әткәйне булса да ышандыра алмаммыни?! Их, Рәшат! Бүген сине күрәсем килгәнне белсәң! Бүләк тә әзерләп куйган идем үзеңә!

Рәшат. Бүләк?

Гөлназ түтәлдән бер матур чәчәк өзеп ала.

Гөлназ. Бүген соңгы звонок шалтырады... Шундый күңелле булды, шундый күңелле! Түзмәдем, бер почмакка посып җыладым.

Рәшат. Әйе шул. Сине котларга кирәк.

Гөлназ. Котла, Рәшат, котла.

Рәшат. Имтиханнарны җиңәсең дә җиңәсең хәзер.

Гөлназ. Әйдә, имтиханнарны бергә бирәбез?

Рәшат. Бергә дисеңме? Күңелгә хуш бу сүзең, Гөлназ!

Раян керә.

Раян. Бер сүз бар иде сиңа, егет.

Рәшат. Уф...

Раян. Бу чибәркәйнең ишетмәгәне яхшырак. Бар, сеңлем, китабыңны караштыра тор. (*Гөлназ чыга.*) Әнкәңнең хәле ничек, Рәшат?

Рәшат. Зарланырлык түгел. Арулана.

Раян. Бик әйбәт... Тынычлык кирәк аңа! Дөньяда тыныч яшәүдән дә рәхәте юк. Китапча яшәп берәүнең дә уңганы юк.

Рәшат. Харам ризык ашарга өндисезме?

Раян. Харам ризык миңа да сеңми. Әмма тормыш кайчагында ашата!

Рәшат. Рәхәттер ул барын да шул тормыш дигәнгә сылтап теләсәң ничек яшәү! (*Кискен.*) Нигә килдегез: мин сездән киттем ич!

Р а я н. Син тына торганнардан түгел. Яшьсең, яшьлегеңә барасың. Тагын да зуррак хаталар ясарсың дип куркам.

Р ә ш а т. Тормыш тәҗрибәм аз, шулай да сизенәм! Тиктомалга йөрмисең! Күпмедер цемент һәм башка вактөякләр өчен синең ис китми! Бу гаебең өчен, күп булса, шелтә чәпәрләр. Шелтәдән куркып кына миндәй малай-шалай катына килмәс идең... Хәзер уйлашыйк: кечкенәдән куркасың, икән, зуррак гаебең дә бар дигән сүз!

Р а я н. Тугач та кендек әбиең ник муеныңны бормады икән синең?!

Чыга. Пауза. Бераздан Рәшат та чыгып китә. Өйдән Г ы й л ь м и я, Г ө л н а з чыгалар.

Г ы и л ь м и я. Кайда алар?

Г ө л н а з. Әле генә шушында талашалар иде.

Г ы й л ь м и я. Ничек, ничек булган дисең?

Г ө л н а з. Рәшатка төзелештән китәргә кушканнар! Гыйльмия апа, ул миңа сөйләде, мин аңа ышанам, аның бер гаебе дә юк.

Г ы й л ь м и я. Рәшат, Рәшат! (*Җавап юк.*) Китәргә кушканнар диген... (*Солтан чыга.*) Әһә, менә кем сөйләп бирә хәзер безгә!

С о л т а н. Мин юньле-башлы сөйли алмам шул.

Г ы й л ь м и я. Гөлназ, әйдә әле, кызым, минем белән.

Г ө л н а з. Мин әзер.

Г ы й л ь м и я. Узган юлы да йоклабрак калдым... Хәзер алай итмәм! Төбенә тоз салмый туктамам!

Г ө л н а з. Мин дә сезнең белән барам, Гыйльмия апа.

С о л т а н. Анда хәзер берәү дә юк, барысы таралыштылар.

Г ы й л ь м и я. Без табарбыз... Иң кирәкле кешесен табарбыз! Солтан, син дә бездән калышма! Әйдәгез!

Чыгып китәләр. Пәрдә. Музыка. Төзелеш мәйданы. Р а я н күренә. Ул төзелеш мәйданы буйлап йөри, нидер исәпли, яза. Почмактан күзәтеп, моңарчы посып торган Н ә җ и б ә н е күрә.

Н ә җ и б ә. Ай!

Р а я н. Сез монда икәнсез, Нәҗибә апа.

Н ә җ и б ә. Сине ничекләр ташлап китим соң, балам? Йә бер кирәгем чыгып куяр дип йөрим шунда.

Р а я н. Мине яратуыгызны беләә идем, шушы кадәр үктер дип уйламадым. Рәхмәт сезгә!.. Ә хәзер кайтыгыз.

Н ә җ и б ә. Алай димә, Раян Булатович! Кирәк чагында килә белгән, кирәк чагында китә белгән кешедән дә кирәгрәк кеше юк, ди иде минем бабай! Теге малай тагын монда бутала әле!

Р а я н. Иснəнəме? Үзе генəме?

Н ə җ и б ə. Аны мин дə күзəтмəсəм, кем сиңа килеп əйтер?

Р а я н. Бик яхшы! Тегендə сүз бетмəгəн иде!

Н ə җ и б ə. Кичкə хəтле бер эшем дə юк, шушы тирəдə булырмын. (*Чыга.*)

Раян белəн Р ə ш а т бер-берсенə каршы баралар.

Р а я н. Күңел тыныч түгелме?

Р ə ш а т. Яшермим: тыныч түгел.

Р а я н. Менə бусы миңа ошап китте! Димəк, телəсəк, без килешеп тə китə алачакбыз!

Р ə ш а т. Мин сезнең участоктан китмəскə булдым. Куарга сəбəбегез юк, ə мин китмим. Калам.

Р а я н. Эшчелəр күзенə ничек күренеп йөрерсең?

Р ə ш а т. Əйе, эшчелəр шактый штраф түлəргə тиешлəр... Бер караганда, моңа мин сəбəпче! Ə икенче яктан караганда?.. Кыскасы, мин китми торырга булдым. Бутады-бутады да качты дип əйтүлəрен телəмим!

Р а я н. Əйттермəс идем əле!

Р ə ш а т. Ə мин уйлауларын да телəмим!

Г ы й л ь м и я, С о л т а н, Г ө л н а з керəлəр.

Р а я н. Бусы тагын нинди делегация? Гражданнар, сезгə ни кирəк?

Г ы й л ь м и я. Раян, боргаланмый-сыргаланмый гына əйт: нигə килгəн идең син безгə бая?

Р а я н. Сезнең тынычлыкны бозарга түгел, Гыйльмия ханым. Ил белəн килдем, чир белəн түгел!.. Эчегез пошмасын.

Г ы й л ь м и я. Безнең йортка, безнең кеше янына килгəнсең икəн, ул безнең уртак эшебез була. Эчебез дə поша.

Р а я н. Кысылганны бер дə яратмыйм бит мин, Гыйльмия ханым!

Р ə ш а т. Бу юлы бераз кысылырга туры килер, Шəфиев!

Р а я н. Риза. Кысылырмын. Менə Солтан агайны аяп калдым. Аңа штраф булмаячак.

С о л т а н. Миңамы? Рəхмəт алайса... (*Гөлназны бер читкəрəп дəшеп.*) Нигə бу җəнҗалга Гыйльмия апаңны катнаштырасыз?

Г ө л н а з. Ул үзе килде бит!

С о л т а н. Ə кем чакырып чыгарды?

Г ө л н а з. Анысы мин. Гыйльмия апа гадел кеше ул.

С о л т а н. Дөньяда гаделлек кенə өстенлек итми шул.

Р а я н. Хак сүз! Менә кемнән акыл сорагыз сез! Рәхмәт, Солтан агай.

Г ы й л ь м и я. Тиз табышкансыз сез, ишәй белән кушай. Әйтәм җирле бүген кара коелып кайткан иде. Штраф сала язганнар икән берәүләргә!

С о л т а н. Инде гаепле булып мин калдыммы?

Г ы й л ь м и я. Курыкма, син бер чакта да гаепле булып калачак түгел. Курыкма... Ут та, су да тимәс сиңа! Җил-яңгырдан үзең ышыкланырсың... Штраф та башкаларга төшәр! Сүзен дә Рәшат кебекләргә калдырырлар. Тик, Раян, син дә аңа өметләнмә! Кыенга килсә, беренче булып ул сине ташлап качачак!

Р ә ш а т. Күңелле булып китте әле бу!

С о л т а н. Олы кешене сүгәләр, ул шуңа шатлана!

Р ә ш а т. Гыйльмия апа! Төзелештә сезнең тавыш яңгырагач, җиңеләеп киттем. Барысы да әйбәт булыр. Мин әле мәктәпкә дә барачакмын. Имтиханнарны да бирәчәкмен.

Г ы й л ь м и я. Без барыбыз да сиңа ышанабыз.

Р ә ш а т. Рәхәт икән ул ялгыз түгеллегеңне тою!

Р а я н. Ялгыз түгел? Иртәгә күрерсең! Берәрсе сиңа кулын бирерме? Әнә, иптәшләрең узып бара! Сине күрделәр алар! Күрделәр дә качалар! Чумадан качкан күк сыпырталар.

Г ы й л ь м и я. Бәлки, алар синнән качалардыр?

Р а я н. Моны тикшерү кыен түгел!

Р ә ш а т. Күрмәмешкә салышабыз диген...

А р т у р белән Л ә л ә керәләр.

А р т у р. Исәнме, малай. Ачуланма, вакыт юк. Имтиханнар.

Р ә ш а т. Бер минутка да тукталыр әмәл калмады диген?..

Л ә л ә. Бездән башка да байтак кеше җыйналган монда.

Г ы й л ь м и я. Иптәшегез чакырып тора. Бәлки, сез аңа шушы мизгелдә бик кирәктер? Бәлки, аңа сездән башка бүген бик кыендыр?!

Р а я н. Тукта, тукта, Гыйльмия ханым! Үзләре аңлашсын. Без, мыекка чорнап, читтәрәк торыйк.

А р т у р. Эшләр чак кына җиңеләйсен инде, Рәшат.

Р ә ш а т. Имтиханнар җитте шул... Беләм! Мин сезне көтебрәк тә торган идем бүген.

А р т у р. Без кергән дә идек... Ләлә белән... Бая!

Л ә л ә. Кайчан? Әйе бит әле!

Нәҗибә керә.

Нәҗибә. Артур! Нигә йогышсыз ялган сөйлисең? Минем Ләләмнең бу бандит янына кайчан кергәне бар?!

Гыйльмия. Эх, Раян! Катышмыйк дисең син, ә үзең борылыш саен капкын салып куйгансың!

Артур. Азга гына кагылган идек. Без бит кайнар сумалага кунган саескан хәлендә хәзер — койрыкны алсаң, томшык ябыша! Хе-хе! Синең эш рәхәт! Мәктәпкә төкереп яхшы иттең! Егет!

Гыйльмия. Аның мәктәпкә төкергәне юк.

Артур. Үзенчә яшисең! Ирләрчә! Буйсынмыйсың! Кызыгам.

Рәшат. Беркөн, Ләлә, сезгә сугылган идем. Әниең кертмәде. Өченче көн шәүләңне бакчада күреп калгандай булдым. Кайда идең син үзең?

Солтан (*Гөлназга*). Әйдә кайтыйк, кызым.

Ләлә. Кичләрен өйдә тормыйм, Рәшат.

Артур. Кызыгып карап торам! Бай тормыш белән яшисез!.. Шушы йортларны син саласың инде, ә?!

Гөлназ. Рәшат, ышанма син аңа!

Ләлә. Әллә Артур ялган сөйли дип беләсеңме?

Рәшат. Кергән идек дисең... Берәр йомышыгыз бар идеме?

Раян. Ягез, йә. Монда ачыклык җитми.

Нәҗибә. Барысы ачыкланган... Бигрәк тә бүген! Бу малай эштән куылган... Нокта куелган!

Гөлназ. Аны берәү дә кумаган. Кемне куарлар, анысын карарбыз. Ул үзе киткән моннан.

Ләлә. Мәктәптән дә үзе китә, эштән дә... Ай-һай!

Раян. Афәрин, Ләлә!

Рәшат. Бүген дәресләр беткән көн... Бүген соңгы звонок... Иртәдән бирле колагымда чыңлый... Бүген төзелештә чәкәләшкән көн!.. Бүген монда аңлашу көне... Бер көнгә күбрәк булып китте бугай... (*Камил керә.*) Менә тагын берегез... Йә, нигә сөйләмисең? Сүзең бар ич!

Камил. Рәшат, сине ни өчен эштән кудылар?

Гөлназ. Эх!

Рәшат. Юк. Гөлназ! Кайтмыйм мин болар янына мәктәпкә! Менә Камил... Ул үзенчә яхшылык теләп килгән... Мине куган булсалар, аңа ансатрак! Ул яхшылык эшләгән булып күренә ала!.. Гайбәт аларның барыннан да көчлерәк икән!..

Гыйльмия. Әйе, Рәшат... Мин дә ансат кына көйләнер бу хәл дип уйлаган идем...

Р ә ш а т. Әле бүген иртән генә башкачарак уйлаган идем! Кайтмыйм мин болар янына!

Чыга.

Г ы й л ь м и я. Нигә килдең син, Камил? Нигә саксыз сүз әйттең?

К а м и л. Мин белмәдем...

Г ө л н а з. Белмәгәч, көтеп торалар аны!

С о л т а н. Кызым!

Г ө л н а з. Болай ярамый, әткәй!

Л ә л ә. Раян абый, әйдә безнең белән.

Н ә җ и б ә. Үз кызым, үз каным!

Р а я н. Сезнең белән рәхәтләнеп барам.

К а м и л. Солтан абый! Ичмасам, син миннән качма. Мин бит начарлык теләмәгән идем! Сөйләшик әле бер икәүләп!

С о л т а н. Сөйләшсәк сөйләшик...

Л ә л ә. Киттек, Артур!

Г ө л н а з. Һәм яңадан килмәссез дә инде.

К а м и л (*Ләләне нык кына күзәтеп*). Кем белсен әле анысын...

Г ө л н а з. Мин беләм, мин!

Г ы й л ь м и я. Кызым минем, кызым. Әйдә, Рәшат янына кайтыйк... Әйдә, әйдә!

Р а я н. Ха-ха-ха!

Г ы й л ь м и я. Көләргә ашыкма, Раян. Жыларга туры килмәсен! Әйдә, кызым!

П ә р д ә. Музыка.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Идел буе. Яр. Сулда бәләкәй генә тау. Куаклар. Бик матур, кояшлы көн. Еpoints Ерактарак гармун тавышы. Көлү, чыр-чу, сөйләшүләр. Мәктәптә уку елы тәмамланган. Ап-ак күлмәк кигән унынчы класс кызлары Идел буена төшкән. А р т у р белән К а м и л керәләр.

К а м и л. Карале. Ләлә түгелме бу? Күптәннән күренгәне юк иде.

А р т у р. Шул.

К а м и л. Ләлә, Ләлә!

А р т у р. Кирәкми. Ул егете белән.

К а м и л. Егете белән бергә йөрергә өлгерер. Килсен безнең янга!

А р т у р. Рәхәтләнеп йөрсеннәр.

К а м и л. Кайгы-хәсрәтләре юк дисең инде?

Артур. Әллә синең кайгың бармы?

Камил. Юк югын да, шулай да күңел тыныч түгел. Җан әрни!

Чыгып китәләр. Раян белән Ләлә керә. Раян утырырга тели. Ләлә карыша.

Ләлә. Барыйк инде, Раян.

Раян. Икәү генә буласың килмиме?

Ләлә. Яхшы түгел. Ишеттең бит, малайлар чакырды. Бая иптәш кызлар кычкырып калды. Без качабыз да качабыз.

Раян. Гомер буе алар итәгенә тагылып йөрмәссең.

Ләлә. Ачуланды да! Үзең, мин салкын канлы, дигән буласың. Өрмәгән җиргә дә утыртмам, дисең...

Раян (*кырыс*). Куләгәңә табынып йөреп туйдым! Иртәннән институтта, кичләрен тагын әллә кайда!

Ләлә. Иске дуслар бит, Раян.

Раян. Барыбер тиздән аерылышасыз, таралασыз.

Ләлә. Һәй, без былтыр таралдык та беттек. Быелгылар таралмыйбыз, диләр. Бөтен класслары белән Түбән Кама шәһәренә, химкомбинатка китәбез, диләр.

Раян. Ха-ха-ха!

Ләлә. Сиңа көлке... Ә миңа аларның бердәмлекләре ошый. Бөтенләй таралышып беткән класс иде бит. Камилләр, Мәрьямнәр башлап йөри!

Раян. Көлмичә соң... Шәһәр төзергә китәләр, имеш, химкомбинатка... Берсе минем участокка килеп эшләп карады инде. Рәшат исемле чибәрне әйтәм.

Ләлә. Аның исемен телгә алмаска сүз беркеткән идекме?

Раян. Бөтенләй хәтердән чыгару да ярамас. Гыйбрәт!

Ләлә. Кемгә гыйбрәт кирәк әле монда?

Раян. Син аның әкәмәтләренең нигез тамырына төшен. Раян абыең белән Рәшат арасында сайланып, икеләнеп торган чагың булды бит. Таныйсыңмы хатаңны?

Ләлә. Әйе. (*Төшенке тавыш белән.*) Әйе... (*Пауза.*) Инде икеләнергә урын юк. Соң. Син егет булып чыктың. Әнием дә өзлексез сине мактый. Минем әнием сирәк мактый, мәгәр бу юлы белеп мактый сыман.

Раян. Мактый? Өченче көн ничек карап куйды!

Ләлә. Шиккә төште. Мине гел аулакка алып китәсең.

Раян. Без бит ерак булсак та кардәшләр.

Ләлә (*яшел ботак сындырып алып Раянны кыйный*). Кардәш белән төнге икегә хәтле йөриләрме?

Раян. Бер генә булды ла ул. (*Ялынып.*) Кабатлыйсы иде!

Л ә л ә. Ун кирәкме әллә аңа? Туңып беткәнмен... Кайтып яткач аякларыма җылы керми генә бит!..

Р а я н. Анысы нервыдан.

Л ә л ә. Иел әле... (*Раянның колагына пышылдый.*)

Р а я н. Кит аннан!

Л ә л ә. Бәби алып кайтам әле мин сиңа.

Р а я н. Бәби?

Л ә л ә. Икеләнү дисең син... Хәзер мин ике ут арасында. Институттан син читләштердең. Хәзер аңлыйм, эреләр янында чүп булып йөргәнче, ваклар янында хан булуны артыграк күрүчән син. Дөрес! Сиңа иләшкәннән бирле, гел синең төсле уйлый башладым.

Р а я н. Сиңа моннан китәргә туры килмәгәе, Ләлә.

Л ә л ә. Кая тагын?

Р а я н. Әлбәттә, минем белән бергә.

Л ә л ә. Сине кая күчерәләр?

Р а я н. Эш болайрак тора, Ләлә. Моңарчы бары сөйләү уңайсыз иде. Престиж! Хәзер бәбәй миңа ярдәмгә киләчәк! Болай. Рәшат башлаган күңелсезлектән соң мин Казаннан китеп торырга карар иттем. Яңа якларга. Йә нефтькә, йә химиягә. Яңа җирләрдә иске гөнаһлар онытылып тора.

Л ә л ә. Әле кайчан гына «Яңа квартира бирәләр, өлкән прораб итеп күтәрәләр» дип сөйләгән идең.

Р а я н. Сөйләгән идем сөйләвен... Коллектив кыры карый! Баштарак, эшчеләр дәшми калгач, мине яклыйлар дип уйлаган идем. Алай ук түгел икән шул... Теге җен карчыгы Гыйльмия райкомга барган. Булды анда хәлләр! Хәзер нефть сүзе модада. Тиз генә модадан төшмәс тә. Бер-ике ел шунда эшләп биографияңне бизәсәң, гомер буе күкрәк кагарга җитә. Даны нәсел-нәсәбеңә кала.

Л ә л ә. Каян беләсең сил боларны?

Р а я н. Замана өйрәтә.

Л ә л ә. Бигрәк кинәт әйттең...

Р а я н. Китәсе килмиме?

Л ә л ә. Алай кистермә. Уйлашырга җай калдыр. Малайлар класслары белән котырынып йөриләр икән, ахыр чиктә, бу бер уен гына. Без китәбез икән, бу уен түгел... Бәби... (*Җыламсырый.*)

Р а я н. Кияүгә чыгуыңны да класс җыелышына куеп тәгаенләр идең син.

Л ә л ә. Бу синең тәкъдим ясавың идемени?

Р а я н. Әйе, коллективизм корбаны! Җавап алмыйча мин сине беркая җибәрмим. Хәзер үк әйт.

Л ә л ә. Хәзер үк дисең икән. Ашыктырасың!.. Хәзер үк... Син гел кауладың мине, ярсып ашыктырдың. Ба-

рам да барам, егылырмын төсле. Кем күтәреп торгызыр мине? Раян, синме?

Раян. Егылмыйча гына яшәп булмый. Өйрәнә тор.

Ләлә. Мин язмышымны сиңа тапшырдым. Саклый алырсыңмы син аның бәхетен? Китик дисең син. Ансат! Монда Казан. Монда Идел. Монда әти. Монда чакта син якын, үз. Ә анда?

Раян. Бәйдәге этең булырмын, Ләлә.

Ләлә. Сүзләр болар, Раян.

Раян. Кайчаннан минем сүзләрнең базары төште?

Ләлә. Калыйк Казанда, Раян.

Раян. Ярамый, Ләлә.

Ләлә. Нишләп ярамасын? Нигә җанны борчыйсың?

Раян. Борчылмый гына хатын булып булмый.

Ләлә. Мине кызганмыйсың икән, сөймисең дигән сүз.

Китәргә тели. Рәшат керә. Пауза.

Раян (*ясалма көлеп*). Бәхетле очрашу! Яхшыга юрыйк.

Рәшат. Бүреләр дә, кешеләр дә бер планетада яшиләр. Исәнме, Ләлә.

Ләлә. Саумы, Рәшат! Раян, озаклама, көтәм. (*Чыга.*)

Рәшат. Раян «абый» түгел икән. Яңалык! Сез кичерәйдегезме, ул үстеме?

Раян. Суыграк булса да, суга чумып чык, егет. Бераз капкансың сыман, төсең качкан.

Рәшат. Һаман мине кайгыртасың, ә? Хәзер: «Әнкәң ни хәлдә?»— дип сорарсың...

Раян. Бу хәлдә кеше арасында көлкегә кала күрмә дим.

Рәшат. Синме кеше? Әйе, кеше, әмма алама бүре төсле.

Раян. Бүген минем кәефле көн. Әйтеп кал.

Рәшат. Әлегә җитәр.

Раян. Гөберле бака да дөньяда яши. Бәлки, ул бик файдалыдыр, әмма кешеләр аңа кагылырга куркалар. Сытылыр да бөтен тирә-якны агулар төсле. Менә син дә шундый! Шулай да мин сине гафу итәм. Бөтен яктан җиңелдең!

Рәшат. Әлегә отыш синдә. Ләкин оту — җиңү түгел әле.

Раян. Ләлә кирәкме сиңа?

Рәшат. Кайчангысы? Бүгенгесеме?

Раян. Төрле яктан йолыктылар сине, яшь күркә! Хуш!

Чыга.

Рәшат. Бар, прораб Раян Шәфиев! Кит! Мин монда калам... (*Иделгә карап тора. Утыра. Чыбык ала. Җиргә*

*бер сүзне яза да укый.*) «И сөеклем, сөеклем!» Күңелдә туган шушы сүзне кемгә әйтергә? Кемгә багышларга? «И сөеклем!» Кем син? Кайда син?

Гөлназ җыры ишетелә.

Гөлназ. Күңелемнең назлы гөлләренә
Сары сандугачлар кунмаган.
Сары сандугачны көтә-көтә
Назлы гөлкәйләрем сулмаган...

Рәшат, оялттың мине!!!

Рәшат. Ак күлмәк сиңа бик килешә, Гөлназ.

Гөлназ. Рәхмәт.

Рәшат. Идел буена төштем. Шәһәрдә эссе...

Гөлназ. Искиткеч хозур икән монда.

Рәшат. Идел бу урыннарга да килеп җитәр дип кем уйлаган. Без, бәләкәй чакта, әнә теге ак маякны күрәсеңме, шул турыга барып, чирәмдә бишташлы уйный торган идек. Хәзер анда ак дулкыннар. Кешенең кодрәтенә исең китәр.

Гөлназ. Идел түгел бу, Рәшат, диңгез! Син шулай дигәндә, диңгез сүзендә бер яңгыраш, яшертен ым ишетәсеңме?

Рәшат. Диңгез... Диңгез ярына килгәч, кеше көчәеп, дәртләнеп китәргә тиеш. Ә мин моңаеп йөрим.

Гөлназ. Ә нигә моңланасың?

Рәшат. Син дә моңланасың бит!

Гөлназ. Бусын ялгыштың.

Рәшат. Нигә ялгызың? Нигә классташлар янында түгел?

Гөлназ. Алар танцевать итәләр. Ә мин... белмим.

Рәшат. Көләсеңдер әле?

Гөлназ. Рәшат, Рәшат, акыллы малай! Минем култык таякларын ташлавыма бер генә ел! Дүртенче класска тиклем мин утырып та тора алмадым.

Рәшат (*маңгаена сугып*). Җүләрмен! Сиңа утырырга урын да тәкъдим итмәгәнмен! (*Гөлназның кардай ак күлмәгенә карап.*) Пиджагыма утыр.

Гөлназ. Кирәкми. (*Көлеп.*) Утырыйк булмаса. (*Утыралар.*)

Рәшат. Уку да, яшәү дә кыен булган икән сиңа.

Гөлназ. Нишләргә кушар идең соң? Үләргәме? Юк, әлбәттә. Яшисем килде минем. Көчле буласым килде.

Рәшат. Ә кешеләр... (*Сүз таба алмый.*) Синең...

Гөлназ. Гариплегемә ничек карадылармы?

Рәшат. Кайберәүләр көләргә яраталар.

Г ө л н а з. Көлгәннәр көлә торсын!

Р ә ш а т. Исең дә китмиме?.. Ә мин... Хәтереңдәме... Беренче май көнне, әнкәйне больницага озаткач, мин япа-ялгызым калдым. Өйгә кердем. Ул идән тутырып иске хатларны чәчкән. Әткәйнең сугыштан язган хатлары. Янында без булмагач, үлгән әткәй белән юаныргa тырышкан ул. «Без булмагач!..» Ата-ана өчен аяусыз сүздер ул... Без бар да, юк та... Икенче көнне дәрескә барырга чыктым. Капка төбебездә тукталдым. Урамнан кешеләр эшкә бара, ә мин... аларга кушылып китә алмыйм. Өс-башым пычрак, тәнем керле кебек... Ә мәктәптәгесен үзең күрдең. Үзең шаһит.

Г ө л н а з. Яклап сүз әйтә алмадым. Үзем дә яңа идем.

Р ә ш а т. Сиңа үпкәли аламмы соң!

Г ө л н а з. Безнең гомер алда әле, Рәшат.

Р ә ш а т. Артта калганын ямерәбезме?

Г ө л н а з. Артта калганы да үзебезнеке! Төзелештә син хаклы булып чыктың.

Р ә ш а т. Хаклы... Эшчеләр һаман штраф түлиләр. Рәхмәт укыйлармы алар миңа!.. Әткәңнең сөйләгәнен ишеткәнең юкмыни?

Г ө л н а з. Минем әткәй...

Р ә ш а т. Ул да кеше! Аның да миңа үз мөнәсәбәте бар!

Г ө л н а з. Әйдә, классташлар янына!

Р ә ш а т. Кирәкмәгән сүз кузгатты дисеңме?.. Бармыйм, Гөлназ.

Г ө л н а з. Имтиханнар әзерләшергә миңа да, Мәрьямгә дә ярдәм итүеңне барысы да беләләр...

Р ә ш а т. Кирәкми, сөйләмә аларын... Хуш!

Г ө л н а з. Мине ташлап кая барасың?

Р ә ш а т. Кичне каршыларга. Сердәшем янына. Әнә тегендә корыган дәү агач бар. Мең тармаклы! Элек ул ямь-яшел кыя кебек иде. Суда утырып корыды. Шуның сихерле ботагына менәм дә, барын да белә торган карт ябалакка әйләнәм мин.

Чыга. Гөлназ аны озата. К а м и л керә.

К а м и л. Баядан бирле сине эзлим. Ни кызык таптың монда?

Г ө л н а з. Нигә Рәшатны эзләмисең?

К а м и л. Ул да төшкәнмени? Түзмәгән икән. Кайда ул?

Г ө л н а з. Корыган имән башында. Менә кайда.

К а м и л. Сиңа бер сүзем бар. Шуны гына әйтәм дә, аның янына барабыз.

Г ө л н а з. Сүз миңа кирәкми, сүзгә Рәшат мохтаҗ. Ачыкканда — аш, сусаганда — су, йөрәк дәвасы — татлы сүз...

К а м и л. Тиз араларда аерылабыз, Гөлназ.

Г ө л н а з. Ул көнне ашыктырыр идем мин!

К а м и л. Нигә алай?

Г ө л н а з. Күңелеңне кузгатасым, уятасым килә!

К а м и л. Ул күптән уянган, Гөлназ... Сине күргәннән бирле тук та тук тибә.

Г ө л н а з. Уянган йөрәк андый булмый... Җирдәге кайгы-хәсрәткә битараф кала алган йөрәк уянмаган әле ул!

К а м и л. Әллә елыйсың инде?

Г ө л н а з. Үзебезнең гамәлләребез өчен, үткәндәге хаталар өчен елыйм. Чү, туктыйм. Оят!

К а м и л. Ялгышлар күп булды, Гөлназ, килешәм. Аның үзендә дә гаеп бар.

Г ө л н а з. Гаеп юк дип кем әйтә?.. Ләкин аңа карап күңелне тыеп буламы?

Чыгып китәләр. Г ы й л ь м и я белән С о л т а н керә.

Г ы й л ь м и я. Карыйм да бәхетем арта. Балалар бии. Әти-әниләр тамаша кылып тора... Һәрбарчасы бәхетле... Хәдичә бичара гына дару иснәп ята.

С о л т а н. Хәйран тамаша икән шул монда!

Г ы й л ь м и я. Син Иделгә карап торырга яратасыңмы, Солтан?

С о л т а н. Идел бездән ерак. Бездә бәләкәй генә инеш.

Г ы й л ь м и я. Идел булмаса, мин әллә кайчан юкка чыгар идем. Ул шундый дәү, көчле, аңа сыенып була. Иделгә карасам, мин яшәреп китәм. Идел тынычландыра.

С о л т а н. Көчлегә сыенасың инде.

Г ы й л ь м и я. Рәшатка бүләк итәрмен дип фотоаппарат алган идем. Мәктәп бетергән көнне генә күрсәтермен дигән идем.

С о л т а н. Нишлисең, тормышка ашмаган хыяллар да кала!

Г ы й л ь м и я. Ул миңа балам кебек иде...

С о л т а н. Аңлаштык ич инде, Гыйльмия, гаеп бездә! Хаталанганмын.

Г ы й л ь м и я. Башкалар аны җәберләгәндә син тик карап тордың. Оят! Онытырлык итмәдең.

С о л т а н. Оят дип, оят инде, башны ташка орыйммы?

Г ы й л ь м и я. Әгәр син үз күләгәңә басарга үзең куркып тормасаң, әгәр син тәвәккәлрәк булсаң, минем гомер юлы да башкачарак узар иде. Шулай түгелмени?

С о л т а н. Битемә төкерсәң, җиңелрәк булыр иде.

Г ы й л ь м и я. Җиңең белән сөртенер идең дә: «Ай-һай, болыты да күренми, каян тамды бу яңгыр?» — дияр идең!

С о л т а н. Минме әрнемәгән? Синең бусагаңны атлап керү ансат булдымы миңа? Гөлназ китерде мине! Гөлназ!.. Төннәр буе сезне уйлап ыңгырашам... Сине, Арыслангәрәйне! Дөрес, башкачарак яшәгән булыр идең син...

Г ы й л ь м и я. Тукта! Колакларым гөж-ж иттереп китте. Кемдер башыма кусәк белән суккан төсле булды. Тот мине, ычкындырма.

С о л т а н. Арыслангәрәйне тиешсезрәк чакта телгә алдым бугай.

Г ы й л ь м и я. Кайтыйк, Солтан, тизрәк калага кайтыйк! (*Сикереп тора. Очып китәргә теләгәндәй куллары селки, киң күлмәк итәкләре җилдә җилферди. Күкне иңләп болытлар шуыша. Идел өсте сүрәнләнә, карала.*) Тизрәк, тизрәк! Такси булыр әле.

С о л т а н. Бәхеттән мәхрүм итәсең. Гөлназга карап туймадым бит әле! Унынчы класс тәмам!..

Г ы й л ь м и я. Тизрәк, тизрәк!

Сәхнә артында берничә мәртәбә: «Тизрәк, Солтан, тизрәк»,— дигән сүзләр ишетелә. Л ә л ә белән Р а я н керәләр.

Л ә л ә. Нигә син мине йолыккалап кына торасың?

Р а я н. Үз казым, йолыксам да була.

Л ә л ә. Ә чыны?

Р а я н. Көн ямьсезләнде. Китик дигән ымым иде.

Л ә л ә. Кайчан китәргә кирәклеген миңа күкләр хәбәр итми. Мин аны үзем беләм... Иректә соңгы көннәр, кинәник!

Р а я н. Син аларга иш түгел, Ләлә. Син студентка. Синең Раяның бар. Ирең. Синең...

Л ә л ә. Сөенденме, юкмы?

Р а я н. Сөенмичә. Өйләнешмәгәннәрдән яралган бала йә мәхәббәтне бетерә, йә гашыйкларны бергә бәйли. Син минем хатыным!

Л ә л ә. Кызганычка каршы, бу шулай.

Р а я н. Бәхеткә каршы түгелмени?

Л ә л ә. Тупас син! Кеше арасында йолыккалыйсың.

Р а я н. Көн кичегә. Безнең кешедә эшебез юк.

Л ә л ә. Иртәгә дә көн бар.

Р а я н. Иртәгә соң булуы бар.

Л ә л ә. Болай кискен сөйләшми торган идең син. Раян, исеңдәме, теге Болак буендагы йортны тапшырганда... (*Раян булып йөреп күрсәтә.*) «Үзебез салган йортны тапшырыр алдыннан мин ялгыз гына буш бүлмәләр буйлап йөрим... Шул чакта мин үземне яратам... Буяу исе мине татлы исертә, бүлмә ачкычларының көмеш кыңгыраудай чыңлавы мине айныта... Ләлә туташ, сезнең серле

күз карашыгыз...» (*Тукталып.*) Әле күпме генә вакыт узган, син шул күзләргә авыз ерып, һич исең китмичә карап тора аласың.

Раян. Авыз ермыйм. Арттырма.

Ләлә. Шулай сөйләгәндә син миңа баһадир булып тоела идең. Төзелешләрдәге краннарны курүгә кылт итеп хәтергә син киләсең, шуларга күз салсам, дәү кулыңны изәп мине син чакырасыңдыр, дәшәсеңдер кебек тоела иде.

Раян. Мин үзгәрмәдем.

Ләлә. Аның каравы, мине үзгәрттең. Нигә иптәшләрдән аерасың мине?

Раян. Мин бит беләм... Рәшат килер дип көтәсең син... Иптәшләрең арасында да аны күрәсең килә.

Ләлә. Нигә гел каныгасың син аңа? Теге цемент вакыйгасында да үзеңне сәер тоттың.

Раян. Сәер тотмыйча... Барып капканны теләр идеңме әллә?

Ләлә. Тагын бер яңалык!

Раян. Югары маркалы байтак цемент әрәм булган. Күпме көч, транспорт расходлары сарыф ителгән. Материаль кыйммәтләр юкка чыккан! Башны җүләргә салыбрак йөрмәсәң, аркаңнан сыйпамаслар!

Ләлә. Синең дә гаебең бар идеме анда?

Раян. Гаеп дип...

Ләлә. Мин чын дөресен белергә телим.

Раян. Синнән яшәрергә дә җыенмыйм. Хәзер һәммәсе уртак булачак. Син хуҗалык кешесенә кияүгә чыгасың, күнегә тор. Андый шухыр-мухырлар һәр төзелештә дә була. Әгәр без шулай кыланмасак, читкә-чотка сатып җибәргән материалларны, цементны, башкасын ничек списать итәр идек?

Ләлә. Эзне чуалтыр өчен Казаннан качам, диген. Качуым шик-шөбһә тудырмасын өчен, үзем белән хатынны да алам, диген.

Раян. Синең өчен хәзер барыбер түгелмени?

Ләлә. Ахыр чиктә, барыбер.

Раян. Син минем хатыным. Безнең кесә дә, табын да уртак.

Ләлә. Минем җаным юкмы әллә?

Раян. Җаның да минеке.

Ләлә. Чәчең белән җир себерерсең... Мин йөргән җирдә келәм булып түшәлерсең.... Матур перспектива!

Раян. Язылышабыз да шәһәрдән китәбез. Анда күз күрер.

Ләлә. Безне анда көтәләрме?

Р а я н. Безне моннан куалар.

Л ә л ә. Минем... минем... өлкән прораб Раян Шәфиев белән чак кына мактанасым килгән иде... Шәһәр уртасындагы яңа квартирабыз белән... Группада иң беренче кыз булып кияүгә чыгасым килә иде... Кызларның, малайларның күзен яндырасым килгән иде.

Н ә җ и б ә белән А р т у р керәләр.

А р т у р. Әнә ич алар. Парлап йөриләр.

Н ә җ и б ә. Күзем бар, күрәм. (*Артур чыгып китә. Нәҗибә Раян каршысына баса, ачулы күзләрен тутырып карап тора да җиргә төкерә. Ләләне җитәкләп ала.*) Әйдә!

Л ә л ә. Әнием, син бит больничныйда.

Н ә җ и б ә. Бу хәлләргә каберемнән торып та килгән булыр идем.

Р а я н. Берәр яман эш бармы әллә, Нәҗибә апам?

Н ә җ и б ә. Шөкер Ходайга, булмый калды. Үзем йоклабрак йөрсәм, әллә нинди бәла-казалар күрәчәкбез икән. Әйдә, кызым, сиңа монда йөрү килешми.

Л ә л ә. Кая чакырасың? Ни кылануың бу, әнием?

Н ә җ и б ә (*тынычланып*). Эзләп җаным чыга язды. Кемне очратсам да: «Шушында гына парлашып йөриләр иде»,— диләр. Киттек!

Л ә л ә. Раян да безнең белән барамы?

Н ә җ и б ә. Ул карачкыга ни калган икән?

Л ә л ә. Әнием, китермә ачуымны.

Н ә җ и б ә. Бакча карачкысы! Жулик! Ялганчы! Бандит!

Р а я н. Ха-ха-ха!

Н ә җ и б ә. Өстерәлчек. Чумарачы.

Р а я н (*тыела алмыйча көлә*). Ха-ха-ха!

Л ә л ә. Әнием, Раян минем ирем.

Н ә җ и б ә. Шулай булмый калуыма сөен, Ләләм. Хәлләр бар икән дөньяда! Барын беләм дип йөри идем, томана зирәк икәнмен ич!

Л ә л ә. Ни сөйләсәң дә соңардың. Без өйләнешкән.

Н ә җ и б ә. Әрәмнәр киткән икән башларың! Кемгә, кемгә бит!

Р а я н. Ха-ха-ха! Эчне кату алды.

Н ә җ и б ә. Аны эшеннән куганнар.

Л ә л ә. Кусалар ни. Икенчесен табар.

Н ә җ и б ә. Аның, аның... Үтерде! Бетерде, үләт! Ике җирдә ике баласы...

Р а я н (*тыныч диярлек*). Нәрсәм үзгәрде? Кечкенә генә чатагым бар икән, аннан сезгә ни зыян? Мин мин инде ул.

Л ә л ә. Мин мин булып кала алмыйм... Рәшатны

сөйдем... Мәктәпнең атаклы егете иде... Анысы нишләде! Хәзер монысы кем булып чыкты.

Нәҗибә. Йөрмә, дидем мин сиңа!

Ләлә. Йөр, дидең. Кочагыңда эрет шуны, дидең.

Раян. Туктагыз! Бетерегез бу шайтан кәмитен! Югыйсә!.. Кәмитне мин акчага сатып ала алам!

Нәҗибә (*аңа ябышып*). Кая? Кая китешең? Ансат кына ычкыныр иде бугай! Кызым! Әйт!

Ләлә. Барам. Раянга барам. Риза. Синеке булам. (*Әнисенә.*) Ичмасам, сездән котылырмын! Тавышыңны ишетмәс өчен әлләниләр бирер чакларым күп. Туйдым! Раянда кол булырмын! Синең янда җәһәннәм кисәве идем. Мин Раянны сайлыйм!

Нәҗибә. Кайтыйк әле, сайлап күрсәтермен!

Раян. Җиттеме сезгә?!

Рәшат узып бара. Ләлә янында туктала. Пауза.

Рәшат. Барыбыз да монда икән. Раян абыйны яңа хезмәт белән котладыгызмы?

Ләлә (*Нәҗибәгә*). Сасытып өлгергән әле!

Нәҗибә. Бер-ике кешегә генә әйттем.

Раян. Ләләм!

Рәшат. Мин моны белә идем диярлек, Нәҗибә апа. Явызлык йөз булса да, бер дөреслек аны җиңә икән. Күкрәкләр киңәеп китте менә.

Раян. Кит моннан. Синнән башка да сару кайный.

Рәшат. Харам азык сеңеп җитмиме?!

Нәҗибә. Йолкыш тавык! Алама күркә! Син көчеккә ни җитмәгән тагын?

Ләлә. Әнием, син авыру. Син больничныйда!

Рәшат. Сикертәме кияү! Кикертер дә әле ул.

Раян. Без монда бер семья. Үз эшебез. Үз сүзебез.

Ләлә. Дөрес. Раян минем тормыш иптәшем.

Рәшат. Шулкадәрле үк сукырайдыкмы без!

Раян. Рәхмәт, Ләләм. Миңа хәзер бернәрсә дә куркыныч түгел!

Нәҗибә. Кызым, икесе яныннан да кит!

Рәшат. Ләлә, ялгышларны төзәтү, ай, читен, бел!

Раян. Яхшы чакта ычкын моннан. Ләләдән көнләп миңа яла яктың. Ләләдән көнләшеп чүп өемендә актарындың, кикриксез әтәч. Ләкин, хәтереңә ал: мин мин булып калырмын. Ә син... гомерең буе капка төбендә аунарсың, Павка Корчагин!

Рәшат. Кем, кем дидең? Кабатла бер!

Ләлә. Рәшат, сабырың җый. Талашмагыз.

Рәшат. Юк!

Р а я н. Кит, малай актыгы.

Р ә ш а т. Ничек телең барды?

Р а я н. Бездә тел дә, йодрык та бар.

Р ә ш а т. Кем икәнлегеңне әйтеп биримме?

Р а я н. Синең төсле шымчы түгел, әләкче түгел.

Р ә ш а т. Башкача әйткәнне барыбер аңламассың! Мә!

Раянга җан көче белән китереп суга, Раян атылып барып төшә. Г ө л н а з, К а м и л, А р т у р керәләр.

Л ә л ә. Рәшат!

Г ө л н а з. Рәшат!

Л ә л ә. Раян, имгәнмәдеңме?

Р а я н. Ну, шалама, әләктең хәзер.

Н ә җ и б ә (*чәрелди*). Пычагы бар! Пычагы! Беләк буе! Үзем күрдем. Үзем шаһит.

А р т у р (*Гөлназга*). Ә син безне Рәшат хакында ялгышкан дисең.

Р а я н. Ну, батырам...

Р ә ш а т. Түзмәдем. Кадерле бер кешемнең исемен атады.

К а м и л. Башкача аңлашып булмый идеме?

Р ә ш а т. Булмый! Башкача булмый, ышанасызмы?

Н ә җ и б ә. Судка! Туп-туры судка! Утыртырга! Янына бармагыз. Пычагы бар, кинжал! Аршын ярым булыр. Үзем күрдем!

Р а я н. Болай гына калдырыр дисезме? Күптән кызышып йөри идем, үзе килеп капты. Шаһитлар җитәрлек. Син барасың. Син. Син дә! Шапылдатып биш елны ясап куялар. Урыны шунда!

Г ы й л ь м и я белән С о л т а н керәләр. Аларны күреп Рәшат сискәнеп китә.

Р ә ш а т. Гыйльмия апа, ни булды?

Г ы й л ь м и я. Улым...

С о л т а н. Рәшат энем, әйдә, ятьрәк бул әле. Такси да көтеп тора, акчасын да суга дигәндәй, шоферы көтмим дип дулаша.

Г ы й л ь м и я. Улым, ятим калдык бит... улым...

Р ә ш а т. Әнкәй...

Г ы й л ь м и я. Ятимнәр булып калдык шул, балам.

Р ә ш а т. Булмас. Хатадыр. Ышанмыйм.

Чыгарга бара, Раян аны килеп тота.

Р а я н. Кая, кая? Тиз генә ычкынырмын юк. Җылы кулдан милициягә тапшырам мин сине. Үлгәннәр көтәр, монда без бар!

Р ә ш а т. Әнкәй...

Р а я н. Артур, Камил! Таныш булырсыз.

Л ә л ә. Адәмнең асылы икәнсез, Раян абый!

Г ы й л ь м и я. Улым, бердәнберем булып калдың...

Р ә ш а т. Әнкәй... Булмас, булмас!

П ә р д ә.

Беренче пәрдәдәге күренеш. Өйнең тәрәзәләре ачык. Менә аларның берсеннән Г ө л н а з н ы ң башы күренә. «Әткәй, әткәй, минем сумкамны күрмәдеңме?» — дип кычкыра да югала. Тынлык. Каяндыр өй артыннан Рәшат килеп чыга. Акрын гына атлап бакча буйлап йөренә. Үзе дә сизмәстән бер яфрак өзеп ала, авызына каба. Бер ноктага текәлеп шактый вакыт уйланып тора. Урам ягыннан Ю а н х а т ы н керә. Муенында эре гәрәбәләр, кулында сап-сары сумка. Күзләре ут уйнап тора. Ишегалдына керә дә өйне караштыра, шуннан соң гына Рәшатны абайлап ала.

Ю а н х а т ы н. Ай, гафу итегез.

Р ә ш а т. Гафу үтенергә сезнең гаебегез юк ич.

Ю а н х а т ы н. Мин сезне күрми дә торам.

Р ә ш а т. Сезнең миңа караганыгыз да юк.

Ю а н х а т ы н. Аh... Шулай икән шул... Йортны карадым. Шәрифҗан абый җибәргән иде... Әйе... Шәп йорт бит, иеме?

Р ә ш а т. Монда бернинди дә Шәрифҗан тормый.

Ю а н х а т ы н. Сез Шәрифҗан абыйны беләсезме әллә? Белмисез? Шундый кешене! Гаҗәп! Бөтенләй искиткеч! Шәhәрдә аны белмәгән беренче кешене очратам. Аны барысы да беләләр? (*Серле.*) Ул минем бик якыным.

Р ә ш а т. Калада монысын да яхшы беләләрме?

Ю а н х а т ы н. Шәрифҗан абый монда йорт бушый дигән иде.

Р ә ш а т. Атаклы Шәрифҗан абыйның торыр җире беткәнме әллә?

Ю а н х а т ы н. Нишләп алай уйлыйсыз? Ул мине кайгырта...

Р ә ш а т. Сезнең торыр җирегез калмадымы?

Ю а н х а т ы н. Гаҗәп егет икәнсез сез! Торыр җирем бар... Кыскасы, Шәрифҗан абзый безне — икебезне кайгырта. Йорт бушый дип шул әйтте.

Р ә ш а т. Ялган информация.

Ю а н х а т ы н. Кемдер үлгән диме шунда? (*Һаман йортны күзәтә.*) Шәп булыр иде. Урыны — люкс. Тынычлыгы — прима. Теләгәндә Шәрифҗан абый килеп ял итәр... Хәзер бит дөньяга әллә нинди машиналар кайтарып тутырдылар, кешегә урын калмады. Бөтен җирдә шау-шу! Ис! Затлы сөякләргә чыдар әмәл юк. Ни пычагыма кирәктер шул тиклем машина? Тә-әк, без байтактан чамалап йөрибез... Урыны ла урыны! Миңа моның искереп беткән өе

хаҗәт түгел... Анысын сүтеп ыргытып менә дигән коттедж салдырабыз. Ванна, газ... Балкон... Тимер капка... Биек таш койма өстендә очлы сөңгеләр. Аларын акка буятам! Ак төс яратам мин. Романтично!.. Хәзер гүзәл йортлар салалар бит... Бу юкәләрне кистереп, монда беседка...

Р ә ш а т. Бу агачларны кисәргә ярамый. Монда йорт бушый дисәләр дә, дөрес түгел.

Ю а н  х а т ы н. Шаяртасыз! Шәрифҗан абый күрәзә ул! Җир астыннан йөргән җыланны да күрә ала.

Р ә ш а т. Бу көнгә кадәр монда җылан күренгәне юк иде.

Ю а н  х а т ы н (*үпкәләп*). Кем әйтә монда җылан бар дип? Кояштыр, сез әллә ничек... (*Серле.*) Шәрифҗан абый әйтә, монда, йортта, бер хулиган малай белән ләпшердек карчык кына калды, ди. Хулиган малайны төрмәгә ябып куячаклар...

Р ә ш а т. Ә карчык?

Ю а н  х а т ы н. Карчык үлә, әлбәттә.

Р ә ш а т. Хулиган малай мин ул.

Ю а н  х а т ы н. Мин кеше танымыйммы? Күземнең нуры беткәнме? Сез шундый чибәр, акыллы...

Р ә ш а т. Мин! Мин! Һәм сезнең өчен монда бер генә квадрат җир дә бушамый! Вон! Чыгып олагыгыз. Үлә?! Гыйльмия апамы? Үлми! Яши! Мин яшәтермен аны! Мин дәвалармын! Ял йортына җибәрермен... Озатырмын, каршы алырмын. Бик озак яшәр ул, матур көннәрне, ямьле кичләрне күрер. Вон!

Ю а н  х а т ы н. Гафу итегез, гафу! Сез нәрсә, Ходаем...

Р ә ш а т. Мин сезне беләм, шуңа күрә гафу итмим. Май алдыннан квартирагызда очраштык. Оныттыгызмыни? Сез Мәрьямнең әнисе бит. Квартир алыштырыр өчен Мәрьямне куасыз! Азыныр өчен аулак квартир эзлисез... Вон!

Юан хатын курка-курка чыгып китә. Г ө л н а з  керә.

Г ө л н а з. Шундый ямьсез кычкырдың... Ут бар дип торам...

Р ә ш а т (*тәмәке кабызып*). Мине күмәргә тырышып йөрүче үләксә козгынын куркыттым...

Г ө л н а з. Син озак тордың...

Р ә ш а т. Озаграк шул...

Г ө л н а з. Гариза калдырдыңмы?

Р ә ш а т. Җирдә андый урыннар бар икән, Гөлназ... Анда кешеләрне гаризасыз да кабул итәләр.

Г ө л н а з. Син райкомолда булмадыңмыни?

Р ә ш а т. Рәшат зыяратта булды.

Г ө л н а з. Рәшат, беләм... аңлыйм... шулай да! Син килештең бит... Берәр елга Казаннан китеп тор! Мин кичә райкомолда сөйләшеп чыктым. Гыйльмия апа да кергән анда. Бүген алар сине көтә. Хәл итәргә кирәк.

Р ә ш а т. Кирәк. Беләм. Тик бүген түгел. Иртәгә, ярыймы?

Г ө л н а з. Без бүген китәбез. Билетлар алынган. Телисеңме, мин тагын барып кайтам. Әйдә, икәү барыйк.

Р ә ш а т. Кирәкми, Гөлназ. Үзем барырмын. Сөйләшермен. Әле бая Мәрьямне очраттым. Апаларына күчкән. Түбән Камага барсак, бер бригадада эшләрбез, ди. Сиңа сәлам әйтте.

Г ө л н а з. Билетларны бүгенгә аласы калмаган.

Р ә ш а т. Поезд ничәдә? Озата төшәрмен.

Г ө л н а з. Кичке җидедә лә!.. Тик мин сине болай ташлап китә алмам!

Р ә ш а т. Әгәр мин Түбән Камага болай гына, ияреп кенә китсәм.

Г ө л н а з. Син класстагы барлык комсомоллар төсле бер хокукта, путевка белән кит.

Р ә ш а т. Бүген үк дисеңме? (*Пауза.*) Барам!

Г ө л н а з. Аннан туры өйгә кайт, Рәшат! Яме!

Сикереп диярлек өйгә керә, кул болгый. М и л и ц и о н е р керә.

М и л и ц и о н е р. Сез Нургалиев түгелме?

Р ә ш а т. Әйе, мин.

М и л и ц и о н е р. Сез кирәк әле миңа.

Р ә ш а т. Рәхим итегез.

М и л и ц и о н е р. Сез кайда эшлисез, туган?

Р ә ш а т. Әлегә беркайда да эшләмим.

М и л и ц и о н е р. Нигә?

Р ә ш а т. Өченче төзү-монтаж трестында идем. Кабан күле буендагы яңа йортларны беләсезме?

М и л и ц и о н е р. Унберенче йорттан үземә квартира бирәләр, ордеры кесәмдә.

Р ә ш а т. Шунда эшли идем дә... китәргә туры килде.

М и л и ц и о н е р. Ярамый, туган. Эшләргә кирәк. Сезнең өстән безгә язалар.

Р ә ш а т. Нәрсә язалар?

М и л и ц и о н е р. Төрлесен, туган. Эшләми, диләр, урлаша, диләр. Эчә, диләр. Тагын әлләниләр. Әнкәңне белә идем мин. Әйбәт апа иде.

Р ә ш а т. Рәхмәт.

М и л и ц и о н е р. Син, туган, чарасын күр. Эшкә урнаш. Язганнары яладыр, беләм, мәгәр бер пункты рас икән, Төзәт син аны.

Р ә ш а т. Классташлар Түбән Камага, химкомбинатка китәргә җыена. Мине дә чакыралар... Читен әлегә монда! Китеп, эш белән мавыгып онытыласым килә.

М и л и ц и о н е р. Бар, туган. Юлың уң булсын. Китәр көнеңне ачыклагач, безгә кереп чыгарсың. Мин яңа участковоегыз Исмәгыйлев абыең булам.

Р ә ш а т. Керермен. Хушыгыз.

Чыгалар. С о л т а н белән Г ө л н а з керә.

Г ө л н а з. Тарих китабымны таба алмыйм.

С о л т а н. Синең белән тарихка эләкмәсәм инде монда! Җыйма чүп-чар!

Г ө л н а з. Бусы китапханә китабы.

С о л т а н. Күземә чалынганы юк.

Г ө л н а з. Ә-ә, беркөн агач күләгәсендә утырган идем, шунда калгандыр! (*Йөгереп карап килә.*) Анда да юк.

С о л т а н. Тагын нинди эшләрең калды? Исемлеген язып бир.

Г ө л н а з. Нигә языйм ди?

С о л т а н. Көн туса яңа эш уйлап табасың. Туйдым.

Г ө л н а з. Тиккә йөрмим ич. Мәктәпкә барам. Кызлар янына барам... Тагын...

С о л т а н. Синең бу хикмәтләреңнең чиге булмаячак! Анда безне әнкәң көтә... Гомумән, мондагы ыгы-зыгыдан тизрәк чыгып ычкынырга кирәк... Китабыңны-митабыңны белмим, билетлар монда, кесәдә, үз вакытында вокзалга, туп-турыдан сәфәр!

Г ө л н а з. Китәбез, бүгеннән калмыйбыз. (*Еламсырый.*) Өйне сагындым, әнкәйне...

С о л т а н. Бу көмеш яшьләрең әнкәңне сагынып түгел бугай шул...

Г ы й л ь м и я керә.

Г ы й л ь м и я. Рәшат кайтмадымы?

Г ө л н а з. Кайтты да райкомолга китте.

С о л т а н. Диспетчермыни, кая киткәнен гел белешеп тора.

Г ы й л ь м и я. Баруы әйбәт. Юлы уңсын. Аңлашсыннар. Әле почмактагы яшелчә кибетен тикшереп кайтып киләбез. Халык контроле! Чибәр генә эшләп яталар...

С о л т а н. Безне озатырга кайтмыйсыңдыр дип уйлаган идем.

Г ы й л ь м и я. Кызыйны озатмый каламмы соң?.. Ә син кая чыгып югаласың тагын?

С о л т а н. Кибетләрне әйләнәм. Мөхәррәмов янына кереп чыгам.

Гөлназ. Мине шуларга алып бармадың тәки, әткәй...
Солтан. Сине алып барырлыкмы соң? Телчәнгә әйләндең, усалландың!
Гөлназ. Усалландыммы? Әй, әткәй!

Агачлыкка кереп югала.

Гыйльмия. Озак йөрмә. Аш салырмын.

Солтан чыга. Гөлназның җыры ишетелә. Гыйльмия тыңлый.

Гөлназ. Каурый кебек җиңел болытлар
Күңелемә сыенып үттеләр,
Йөрәгемнең назлы гөлләренә
Шифа-дәваларын сиптеләр...
Күрдеңме син,
Өлгердеңме
Күз салырга аларга?
Сөю утларында янарга,
Сөю утларында янарга...

Җыр соңында Гыйльмия Гөлназны килеп кочаклый.

Гыйльмия. Кызым, кызым, бирешмәдең. Әйбәт укыдың.
Гөлназ. Икеләнгән чакларымда янымда син булдың, Гыйльмия апа.
Гыйльмия. Рәшатны ташлама. Үзең өчен яшәргә өлгерерсең. Үзең турында гына уйлама.
Гөлназ. Рәшат берзаман кайтыр. Кичке мәктәптә унынчыны бетерер. Без яңадан бергә-бергә яши башларбыз. Рәшат мине тимераякта йөрергә өйрәтәм, ди. И-и, кызык булыр! Минем тимераякка да, чаңгыга да басканым юк әле. Тизрәк җитсен иде кыш!
Гыйльмия. Җиргә кыш килсә килсен, безнең күңелләргә суык иңмәсен.
Гөлназ. Без икебез дә Рәшатны яратырбыз. Ятимлеген сизмәслек итәрбез.
Гыйльмия. Шулай булыр, кызым. Шулай булыр, балам.
Гөлназ. Сез әткәйгә үпкәләмәгез. Ул үзе дә сизенә...
Гыйльмия. Солтан үзе үпкәләмәсен. Без бит иске дуслар. Олыгая төшкән саен иске дуслар азая... Азайган саен аларның кадере арта. Яшьлекне сагынган саен, иске дусларны юксынасың...
Гөлназ. Без дә дуслармы, Гыйльмия апа? Казанда минем дә дусларым күп хәзер!
Гыйльмия. Исән-сау йөреп кайт. Сагындырырсың инде!

Г ө л н а з. Атна-ун көн торам да, әйләнеп киләм.

Г ы й л ь м и я. Илленең аръягына чыккан кеше белән унсигез яшьлек кызның тизлеге бердәй түгел шул. Синең ун көнең миңа ун атна!..

Өйгә кереп китә, Гөлназ борчылып Рәшатны көтә. Капкадан Л ә л ә керә.

Л ә л ә. Бу синме? Күз төбем кычыта... Күрмим. (*Ишегалдына уза, бакчаны карый.*) Монда чәчәкләр үсә иде, беткәннәр икән.

Г ө л н а з. Үсәрләр әле. Җире бәрәкәтле монда, йомшак.

Л ә л ә. Чәчәкләр белән мавыгу чоры бездән узды...

Г ө л н а з. Нишләп узсын әле?

Л ә л ә. Сиңа килеп тә җитмәгән анысы... Яши башламагансың бит әле син. Тормыш белән күзгә-күз очрашканың юк... Күңелсез нәрсә икән ул тормыш!

Г ө л н а з. Күңелсез итмә, бизә.

Л ә л ә. Чәчәкләр беткән. Яз узып китте дигән сүз. Ә мин абайламый да калдым. Син язны яратасыңмы?

Г ө л н а з. Хәзер кышны ныграк яратырмын төсле. Өметем кышта!

Л ә л ә. Ә мин көзне яратам... Тирән көз... Ташландык бакчаның үлән сарган аллеялары... Беркем юк... Сары яфраклар коела... Син сары сагышка батып йөрисең дә йөрисең... Күптән язылган кабер ташлары... Һәрбер таш — кеше. Һәр кеше — табышмак. Кем булган ул?.. Кемне сөйгән? Кем ул? Менә син, Гөлназ, кем?

Г ө л н а з. Син борынгы китаплардан алып әзер сүзләр сөйлисең.

Л ә л ә. Әзер сүзләр җанны коткармасмы дим... Үз сүзләремне белмим, буталам... Раян машина алып кайткан. Машина! Әле быел язын гына машина минем иң-иң зур хыялым иде. Ә бүген шатланмадым. Бензин исенә башым әйләнде.

Г ө л н а з. Үз аягың белән үз җиреңә тып-тып басып йөрүдән дә ләззәтлерәк ни бар икән бу дөньяда?!

Л ә л ә. Без язылыштык... Чәчәкләр... Шиңгәннәр. Бүген чыгарып аттым... Кияү! Быел язын гына бу да минем өчен зәңгәр хыял иде! (*Пауза.*) Рәшат өйдәме?

Г ө л н а з. Сүзегез булса, әйтеп калдырыгыз.

Л ә л ә. Кеме соң син аның?

Г ө л н а з. Дусты.

Л ә л ә. Бала! Рәшатны тота алмассың син. Хәер, тыңлама син мине... Күз кабакларым кычыта...

Г ө л н а з. Без дуслар аның белән, һәм мин сезнең Рәшат белән очрашуыгызны теләмим.

Л ә л ә. Дуэльгә чакырасыңмы? Тел белән ярышабызмы, әллә кул беләнме?

Г ө л н а з. Әниегез килгән.

Н ә җ и б ә керә.

Н ә җ и б ә. Шушында утырадыр дип уйлаган идем аны... Нинди юньсезлек бу, Ләләм? Кичә, өченче көн кияү җилтерәтеп алып кайтты үзеңне. Талашып бөтен урамга фаш булдыгыз. Аю мае сөрткәннәрме әллә шушы йортка?

Л ә л ә. Миңа Рәшат кирәк.

Г ө л н а з. Барыгыз, Ләлә.

Л ә л ә. Мин аны күрмичә китмим.

Н ә җ и б ә. Ошамаганны сөйләмәсәнә! Сулагайлап салып җибәрермен, җыбыткы. Кияү ни әйтер? Тузынып, ут чәчеп көтте-көтте дә машинасына утырып чыгып чапты.

Л ә л ә. Чапсын... Дуласын. Мин Рәшатны көткәнне Раян да белә. Гөлназ, көнлисеңме?

Г ө л н а з. Бу сорауга мин җавап бирмим.

Л ә л ә. Көнләмә. Көчсез көндәш мин сиңа.

Н ә җ и б ә. Ир хатынымы син, урам пумаласымы?

Л ә л ә. Акырма! Кем икәнлегемне белер өчен дә Рәшатны көтеп утырам мин.

Н ә җ и б ә. Алып кайтмыйча китмим!

Турсаеп барып утыра. А р т у р белән К а м и л керәләр.

Г ө л н а з. Күрмәдегезме?

К а м и л. Әлеге очрашкан юк. (*Пауза.*)

А р т у р. Бүген тәгаен юлгамы, Гөлназ?

Г ө л н а з. Сәгать җидедә...

К а м и л. Җидегә кадәр синең уең җидегә төрләнер.

Г ө л н а з. Алайса, нигә килдегез сез?

К а м и л. Бөтенләй калсаң да сүзебез юк...

Л ә л ә. Артур олысымакланган. Эндәшми дә.

А р т у р. Теш сызлый. Өченче көн ауга барган идек, дүрт сәгать суда утырдым.

Л ә л ә. Коры барып буш кайттыгызмы?

А р т у р. Бер үрдәк, ике чүрәкәй.

Г ө л н а з (*күзе һаман капкада*). Ничек жәлләмичә атасыз шуларны... Балалары кала бит...

Л ә л ә. Ә без машина сатып алдык...

К а м и л. Рәшат өйдә юк икән...

Л ә л ә. Гаҗәп. Без нәкъ элеккеге төсле барыбыз да аны көтәбез... Кайсыбыз яратмый, кайсыбыз көнләшә, кайсыбыз дошман күрә, ә барыбыз да көтәбез.

А р т у р. Безнең башка мәсьәлә.

Л ә л ә. Синеке дә билгеле! Һе, акыллы баш! Классыгыз белән китмәс өчен таныш врачларыңнан справка җыеп йөргәнеңне белмиләр, ди. Сунарга да врач белән бардың бит син!

А р т у р. Ләлә бәла!

К а м и л. Элеккеге кебек түгел, Ләлә. Рәшат миңа туганым кебек якын хәзер... Элеккеге кебек ваемсыз булмыйк.

П о ч т а л ь о н керә.

П о ч т а л ь о н. Рәшат Нургалиев кирәк иде. (*Дәшмиләр.*)

А р т у р. Әллә бөтен шәһәр эзлиме үзен?

П о ч т а л ь о н. Монда юкмы ул? Аны судка чакыралар.

А р т у р. Камил! Безнең бәхәсләргә чик куелды. Оттырдың. Рәшат та Рәшат, имеш. Мәктәпнең йолдызы! Алтын медаль алырга тиешле Рәшатка әнә суд повесткасы... Ә безнең кесәдә көмеш медаль!

Л ә л ә. Ничек алай булсын?

К а м и л. Нидер бутыйсыз. Бирегез әле. Әһә, аны Раян Шәфиев судына шаһит итеп чакыралар икән. Менә!

Л ә л ә. Монысы аңлашыла!

Н ә җ и б ә сикереп тора.

Н ә җ и б ә. Башы беткере малай, дөмеккере!

А р т у р. Татарда да сүгенү сүзләре бар, ә?

Л ә л ә. Судка мин дә барам. Раян үзенең гаепләрен миңа тулаем икърар итте.

П о ч т а л ь о н. Нургалиев почтага керсен, монда аңа ике йөз сум акча, хатлар, телеграмма бар.

Г ө л н а з. Олы апасы кайтам дип язган, телеграмма шуннандыр. (*Почтальонга.*) Ул хәзер кайтып җитәргә тиеш. Керер, кайту белән керер. (*Почтальон чыга.*) Гыйльмия апа, Гыйльмия апа! Рәшатка хат бар! Телеграмма килгән.

Г ы й л ь м и я керә.

Г ы й л ь м и я. Яле, яле.

К а м и л. Рәшатны Түбән Камага алып китәбез. Бу хәл кылынган. Класстан калдырмыйбыз.

Г ы й л ь м и я. Эх, бу хатлар, акча иртәрәк килгән булса. Хәдичә исән чакта дим...

Л ә л ә. Рәшат барырмы соң?

Г ы й л ь м и я. Сезнең урында булсам, Ләләне дә китәргә өндәр идем мин. Ямь тапмый ул монда!

Нәҗибә. Каян килгән нәнкә... Барына тыгыла, барына борын төртә... Синнән сораганнар иде ди!

Гыйльмия. Мин сезне дә берәр яры озатыр идем, Нәҗибә ханым! Сез бит микроб кебек... Үзегез бәләкәй генә, кылган эшләрегез исә... (*Урамда машина тавышы. Шау-шу. Аһылдаган тавышлар. Машина зәһәр чинап ерагая.*) Бу нинди шау-шу?

Гөлназ. Нинди ямьсез тавышлар?

Ләлә. Машинасы ач песи сыман чинады.

Гөлназ. Монда таба киләләр. Әткәй дә шунда инде әллә?

Камил. Шунда.

Артур. Теш, парин, шундый нәрсә икән ул...

Гөлназ. Әткәй.

Тавышлар көчәя. Алдан Солтан, аның артыннан берничә кеше Рәшатны күтәреп керәләр. Эскәмиягә салалар.

Солтан. Менә шушында. Иплэп, иплэп...

Гөлназ. Сөеклем, нишләттеләр?

Ләлә. Рәшат!

Гыйльмия. Читкәрәк кит әле.

Нәҗибә. Кызым, дим... Чуалма, дим... Кит, дим...

Солтан. Мин кайтып килә идем. Каршыдагы кибеттән чыксам...

Озын кеше. Мин күрдем! Мин! Бу егет йөгерә-йөгерә урам буйлап бара иде. Бик шатланган иде, ахрысы, авызы ерык. Почмактан машина килеп чыкты. Өр-яңа зәңгәрсу «Победа»!

Ләлә. Зәңгәрсу «Победа»? Өр-яңамы?

Солтан. Төсен абайламадым.

Озын кеше. Син дә күрдең ич! Ну, мин әйтәм, хәзер бер әкәмәт була. Бу егет уңга каерыла, шофер да уңга бора. Егет сулга керә, шофер да сулга!.. Тычкан белән мәче уйнаган кук! Шундый кызык! Син дә күрдең ич! Егет, юл сабыйм дипме, уртагарак тартылган иде, машина үзен бәрде дә китте.

Гыйльмия. Аягы өстеннән узган. Такта китерегез, чүпрәк!

Гөлназ. Авыртамы, Рәшат җаным? Аяклар бик кадерле бит ул...

Озын кеше. Бу егет сулга, шофер да сулга! Егет уңга, шофер да уңга бора. Син дә күрдең ич!

Солтан. Күрдем.

Ләлә. Номерын күрмәдегезме?

Озын кеше. Күзлегем тирләде. Курыксам гел шулай тирли.

Л ә л ә. Сиксән дүрт — җитмеш тугыз түгелме?
С о л т а н. Шулай бугай.
Н ә җ и б ә. Вәт шыр тиле... Вәт шыр җүләр...
Г ы й л ь м и я (*бәйләп*). Рәшат, артык кысмадыкмы?
Р ә ш а т. Гыйльмия апа! Гөлназ... Камил дә монда... Мин бардым. Кесәмдә комсомол путевкасы.

Сыбызгы тавышы. Милиционер керә.

М и л и ц и о н е р. Ягез әле, ягез. Кем күрде? Нинди машина иде? Егетнең хәле ничек? Инспекция килгәнче кузгатмаска иде дә бит!
С о л т а н. Анысын уйлап җиткермәдек. Тузанда ят-кызасы килмәде.
Г ө л н а з. Менә бу озын агай күргән.
О з ы н к е ш е. Минме? Кем? Күрдем дип раслый алмыйм. Күзлегем тирли минем. Хатыным ачулана башласа да тирли...
Г ы й л ь м и я. Әһә!
С о л т а н (*анын якасыннан алып*). Күргәнеңне күрмәдем дип калыр идеңме әллә? Бәдбәхет! Икәү күрдек ич!
Г ы й л ь м и я. Шулай кирәк, Солтан.
К а м и л. Күргән, күргән.
М и л и ц и о н е р. Чәбәләнмәгез, гражданин, тагын кем күрде?
Р ә ш а т. Исмәгыйлев абый? Менә очраштык та.
Л ә л ә. Ашыгыч ярдәм килде.
Г ы й л ь м и я. Улым, хәлең ничек?
Р ә ш а т. Әйбәт.
Г ы й л ь м и я. Башың исән, күңелең сау. Бирешмә!
Л ә л ә. Күрмәсәм дә шаһит була алам: бу Раян этнең эше!
Н ә җ и б ә. Харап иттең... Хәер, батыр инде әйдә, котыл!
Л ә л ә. Зәңгәрсу «Победа». Рәшатка үчле иде ул!
М и л и ц и о н е р (*язарга әзерләнә*). Сезнең исем-фамилиягез.
Г ы й л ь м и я. Әйдәгез, алып чыгыйк.
Р ә ш а т. Тереләм мин. Бик тиз тереләм.

Чыгалар. Машина тавышы. Озату. С о л т а н белән Г ө л н а з керәләр.

С о л т а н. Бүген дә соңга калдык...
Г ө л н а з. Мин хәзер китә алмыйм, эткәй. Теләсәң ни әйт. Тәмам терелеп җиткәнче... Унынчы классны тәмамлаганчы...
С о л т а н. Син миннән көчлерәк булырсың, ахры.

Г ө л н а з. Мин Гыйльмия апа янында калып торам...

Г ы й л ь м и я, Л ә л ә, К а м и л, А р т у р, Н ә җ и б ә керәләр.

С о л т а н. Күрәчәге шулдыр. Яшь тән. Төзәлер.

Г ы й л ь м и я. Аягы төзәлер. Ә күңеле?! Йә, әйтегез әле: дәүләт милкен туздырган өчен судка бирәләр. Машина белән таптаткан өчен дә җәзасын алыр. Кеше күңелен җәрәхәтләгән өчен кем җавап бирә? Ул җавапның микъдары күпме? Йә, кайсыгыз әйтә ала шуны?! Йә, кайсыгыз? Кайчан төзәлер аның йөрәге?

Г ө л н а з. Мин җавап бирә алам... Мин аны бер чакта да ташламам.

Г ы й л ь м и я. Рәхмәт, кызым. Нәкъ менә синнән шушы җавапны көтә идем мин... Синнән, Гөлназ кызым.

Ачу белән Ләлә, Артур, Камил, Нәҗибә алдына килеп баса, Гөлназны җитәкли. Музыка.

П ә р д ә.

*1958, Казан*

# *Яланаяклы кыз*

*Драма өч пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Әлфинур.
Таймураз.
Гөләндәм.
Хәниф.
Шәмәрдән.
Айгөл.
Закир.
Роза.

## ПРОЛОГ

Бөтен залга радио:

«Маяк» радиостанциясе сөйли. Мәскәү вакыты белән төнге сәгать ике. «Туганнарны, ата-аналарны эзлибез» циклыннан ике йөз дә җиденче тапшыруыбызны башлыйбыз. Икенче июль, 1963 ел.

...апалы-сеңелле Нестеренколар, Надя белән Людмила, кырык беренче елның июлендә югалган әниләре Клавдия Петровнаны эзлиләр...

...кырык икенче елда Ленинградтан озатылган Николай Баталов үзенең энесе Владимирны эзли. 1939 елны туган...

...Әлфинур белән Таймураз Даишевлар кырык беренче елда Байбүләк детдомына тапшырылган кызлары Гөләндәмне эзлиләр. Мең тугыз йөз... туган...»

Музыка. Радио тавышын аерып булмый башлый, акрын гына пәрдә ачыла.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Тау битендә нарат урманы. Офык күренми дә. Тоташтан калын, кара урман килә-килә дә, алгы планда агачлар сирәгәя. Иңкүлек. Куе чикләвек куаклары. Җәйнең үтә рәхәт, яшел чагы. Әле аны көньяк кояшы да ялап бетермәгән, төньяк җилләре дә аның сафлыгын талап, йолкып китмәгәннәр. Шундый һәйбәт көндә, шундый рәхәттә кашлары җыерылган Хәнифне күрү сәер дә, шикләндерә дә... Ул ашыгыч кына чыгып китәргә җыена, аның юлына Закир аркылы төшә.

Хәниф. Тотма, Закир. Барыбер кайтып китәм! Ялның яме бетте, кызыгы калмады...

З а к и р. Алайса, без дә монда калмыйбыз.

Х ә н и ф. Сез икәү...

З а к и р. Соң... (*Ачу белән.*) Аяк атларга да бирми бит! Килә дә кадала, килә дә ябыша. Юньле сүзе булса икән... Иртәдән бирле бер балык башы!

Х ә н и ф. Минем дә түзәрем калмады, Закир. Сез әле аны сирәк-мирәк кенә күрәсез... Минем хәлне аңлады-гызмы инде? Без бит аның белән бер түбә астында яшибез. Эшкә бергә чыгып китәбез. Кайтканда да ул мине көтеп тора. Ялгыз йөри алмый, янәсе! Ялгызлыкны сөйми, янәсе!

З а к и р. Синең урында булсаммы, ташлар идем дә чыгып китәр идем, Хәниф абый.

Х ә н и ф. Бик китәсе, Әлфинур апа кызганыч. Аны кызганам. Мин дә чыгып китсәм, бер түбә астында алар икәүдән-икәү калалар. Болай әле, өчәү булганда, түзәргә дә була иде. Соңгы көннәрдә, Урал ягына барып кайтканнан соң, чын ябышкакка әйләнде. Ярар, Роза кайда?

З а к и р. Таймураз абыйның мине култыклап алуы булды, йомыш тапкан булып тайды Розам.

Х ә н и ф. Менә адәм дисәң дә адәм! Яшьләрнең үз көннәре барын аңламыйдыр ул!

З а к и р. Ач талпан булды тәки... Кадала да тора!

Х ә н и ф. Хуш, Закир!

З а к и р. Таймураз абый килә! Безне күрде! Кул болгый!

Х ә н и ф. Сыздым!

З а к и р. Хәниф абый! Мине Роза көтә! Хәниф абый, әгәр син китсәң, мин аның капкынына эләгәм... Китмә инде. Коткар безне!

Х ә н и ф. Яхшы. Бар. Тап Розаңны. Көннең матурлыгы белән кинәнегез!

З а к и р. Чаптым! (*Чыга.*)

Хәниф түземсезләнеп көтеп тора, гасабилана. Т а й м у р а з керә.

Т а й м у р а з. Хәниф, Хәниф! Дөнья бетереп сине эзлим. Киңәшәсе бер сүз бар иде. Сүз дип, фикер, уй!

Х ә н и ф. Өйгә кайткач инде, Таймураз абый.

Т а й м у р а з. Әллә кайтырга җыендың?

Х ә н и ф. Шундыйрак ният бар.

Т а й м у р а з. Табигатькә чыксам, башыма бер фикер килми калмый, Хәниф... Нарат урманы кешенең уйлау сәләтен арттыра бит! Кан тизрәк йөри башлый, йөрәк тә шәбрәк тибә... Кеше ял итә, ә мин әллә нинди планнар белән янып йөрим!

Х ә н и ф. Сезгә дә ял итәргә кирәк, Таймураз абый.

Т а й м у р а з. Юк, юк! Адәм баласы бар булганын эшкә җигәргә тиеш! Тәнеңдә соңгы тере күзәнәгең калганчы эшлә дә эшлә! Эш агачы гына җимеш бирә, дигән Такташ.

Х ә н и ф. Тукай, Таймураз абый!

Т а й м у р а з. Кем әйтсә дә барыбер! Фикеренә игътибар ит: эш агачы дигән!.. Агач дигәч, мин эшче кешенең, эш сөяр кешенең тамырланып торган кулларын күз алдына китерәм!

Х ә н и ф (*гасабиланып*). Фикер килде дигән идегез, Таймураз абый.

Т а й м у р а з. Хәзер шуңа барып җитәм. Иң алдан фикер туган шартларны ачыклыйк... Урманның миңа тәэсире турында әйткән идем инде... (*Ул сөйләгән арада Хәниф чыгып китә, Закирны эзләп йөрүче Роза керә. Таймураз ялт итеп аңа карап ала да сөйләвен дәвам иттерә.*) Фикернең кайда тууы да мөһим аның, Хәниф! Мәсәлән, бу шәһәргә килү теләге миндә кайчан тууын беләсеңме син?

Р о з а. Хәниф абый монда юк!

Т а й м у р а з. Тыңла син, тыңла! Мин сөйләгәндә тыңларга өйрән. Яшьләр өчен бик кыйммәтле фикерләр әйтәм мин! Тормыш тәҗрибәм җитәрлек. Акыл бирерлек күзәтүләрем дә бар... Кайда тукталган идем әле? Хәер, анысы мөһим түгел!..

Р о з а. Хәниф абый кайда?

Т а й м у р а з. Яшәгән саен акыл арта димим, акылы юк кеше аны каян алсын? Ташта борчак үсми... Бүген генә башыма килгән фикер ифрат дәрәҗәдә кызык булачак!..

Р о з а. Закирны күрмәдегезме?

Т а й м у р а з. Менә бит урманга чыгуның файдасы! Әгәр бергәләп урманга чыкмасак... Әгәр шәһәрнең ун еллык юбилеен бәйрәм итүне оештырмасак... Әгәр күз алдымда сез йөрмәсәгез...

Р о з а. Закир күренмәдеме дип сораган идем!

Т а й м у р а з. Тыңла син! Өлкәннәрне тыңларга өйрән!.. Әгәр өлкәннәр булмаса, яшьләр пар нарат арасында адашып калырлар иде! (*Ул сөйләгән арада Роза чыгып китә, Таймураз һаман сөйли. Розаны эзләп Закир үтеп бара, туктала.*) Әнә, ишетәсеңме, күке кычкыра!.. Үзе күренми, кычкыра! Гомер үткәне дә сизелми, күренми, ә кесәңдәге сәгать аны санап тора! (*Кесә сәгате чыгарып карый.*) Уһу! Вакыт ничек тиз үтә!..

З а к и р. Тотмагыз инде, Таймураз абый! Табасы кешем бар.

Т а й м у р а з. Башлаган фикеремне әйтеп бетерим, кабаланма. Менә сез яшьләр. Яшьләр өчен нәрсә мөһим?

Юк, юк, олыларга хөрмәт, анысы болай да аңлашыла! Ватанга турылыклы булу, үз халкыңны сөю... Болары белән дә тирәнтен килешәм! Мин конкрет алам! Менә сезнең шәһәр яшьләре өчен бүген нәрсә мөһим? Менә синең өчен, Закир? Син безнең трестның алдынгы бригадиры...

Закир. Алдынгы идем...

Таймураз. Тагын булырсың! Һу, минем планнарны белсәң!.. Хуш, яшермә! Мин сиңа ата кебек! Трестның баш инженеры дип санама мине, иң якын туганыңа сөйләгәндәй сөйлә: ни кирәк сиңа хәзергесе көндә?

Закир. Розаны табарга кирәк.

Таймураз. Һе-й, яшьлек! Еракка карарга өйрән! Киңрәк уйлан!.. Үзеңнең тәҗрибәң җитми икән, өлкәннәрне тыңла... Менә шулай бит ул, Закир туган, гомернең, гомер баскычының бер аратасына менеп җиткәч, үзең турында түгел, замана турында уйланасың... Яшьләр турында, әйе, әйе, сезнең турыда да безгә уйларга туры килә!.. Менә син үзеңә ни кирәген дә яхшылап белмисең икән, ә мин нәкъ шул турыда уйланам бүген! Шул турыда баш ватам... Тирә-юньдә һәркем үз көне турында гына уйлый торгандыр, ә мин кешелек турында, дөнья турында уйлыйм. (*Ул сөйләгәндә Закир чыгып китә. Әлфинур керә. Таймураз, берни үзгәрмәгән кебек, һаман сөйләвен дәвам иттерә.*) Дөнья турында уйларым мине үзебезнең шәһәргә алып кайта! Без бит шушы шәһәрне өр-яңадан төзүче иң зур трест!..

Әлфинур. Беттеме?

Таймураз. Әлфинур! Очравың гаҗәп әйбәт булды әле. Мин монда яшьләр турында шундый уйларга чумдым...

Әлфинур. Яшьләр үзләре нәрсә диләр соң?

Таймураз. Гаҗәп алар! Каядыр ашыгалар, кабаланалар! Алар яшендә ашыгалармы соң? Менә безгә ашыгырга кирәк... Тәндә көч, сихәтлек барында өлгерергә, өлгерергә!

Әлфинур. Нинди яңа фикер килде инде синең башка?

Таймураз. Яңа дип, яңа да түгел инде ул... Күптән сөйләшеп йөрибез дигәндәй... Ләкин, ничектер, моңарчы кул җитми иде... Кул да җитми, күнел дә керми иде. Менә бүген, монда, урман авызында, яшьләрне күргәч, фикерем ныгыды. (*Көлә.*) Күкрәккә көч керде!

Әлфинур. Һаман әйләнеп-тулганып йөрисең. Өзеп әйт.

Таймураз. Яшьләргә культура йорты кирәк икән, Әлфинур! Безнең техника йорты гына җитми аларга. Җайланган, шуларга аталган махсус бина да кирәк.

Ә л ф и н у р. Ә акча?
Т а й м у р а з. Нинди акча?
Ә л ф и н у р. Культура йортына акча сорап карадагыз ич сез. Якындагы ике-өч елда акча булмаячак дип җавап бирделәр. Үзең кайтып сөйләгән идең.
Т а й м у р а з. Ике-өч ел көтәргә ярамый. Ике-өч ел көтә алмыйм мин! Яшьләргә культура йорты быел кирәк. Менә бүген, иртәгә.
Ә л ф и н у р. Шәһәрдә кирәк нәрсәләр күп... Безнең, больница да кысанланып бара.
Т а й м у р а з. Больница да салабыз!
Ә л ф и н у р. Ә культура йорты?
Т а й м у р а з. Аны да!
Ә л ф и н у р. Акча каян бирәләр?
Т а й м у р а з. Җирле мөмкинлекләрдән чыгабыз. Шәһәр башкармасыннан беркадәр ала алсак... Үзебездән... Башка объектлардан бераз кисәбез дә, нигезен салабыз... Аннары бирми карасыннар! Казан юлына сукмак салачакмын...
Ә л ф и н у р. Акча бирмәячәкләр.
Т а й м у р а з. Нигә син минем планнарыма каршы төшәсең, Әлфинур? Мин шундый итеп, барын нигезләп уйладым. Дәлилләрем нык!.. Башкаларны ышандыра алам.
Ә л ф и н у р. Нигә юкка тараласың? Вакыты җитәр, син теләгәннәрнең бары булыр.
Т а й м у р а з. Көтәргә чамам юк...
Ә л ф и н у р. Шәхси машиналарга гараж салдыра башладың. Акча бирмәделәр. Нигезендә алабута үсә... Стадион төзелеп бетмәгән.
Т а й м у р а з. Бетерәбез аларны!
Ә л ф и н у р. Берсен бетермәгән килеш башлама икенчесен.
Т а й м у р а з. Булдырып чыга алмас дисеңме?
Ә л ф и н у р. Димим, мәгәр шигем бар.
Т а й м у р а з. Нигә алай?.. Әлфинур! Син минем хатыным. Гомер юлыма син шаһит. Син барын да беләсең. Мин элегрәк берни эшли алмый идем. Колачым тар иде, үзең дә беләсең! Ниһаять, теләгәнемә ирештем. Мин баш инженер! Хуҗа! Үз хуҗалыгымда эшне башлап җибәрдем...
Ә л ф и н у р. Әйе... Син, ниһаять, баш инженер... Син элегрәк тә баш була ала идең. Түбән Камага бар, диделәр. Ризалашмадың. Башка урыннарга тәкъдим ясап карадылар. Үпкәләмә: шүрләдең. Нигә монда килгәч кенә шулай гаярьләндең әле син?

Таймураз. Син минем янга гомерлеккә килдең, Әлфинур...

Әлфинур. Йортлар, гаражлар, стадионнар... Төрлесе-төрле җирдә чәчелеп ята.

Таймураз. Син төзүче түгел бит. Син врач!

Әлфинур. Мин сине врач буларак та, кеше буларак та беләм.

Таймураз. Белмисең, белмисең!

Әлфинур. Таймураз, безнең кайгы уртак түгелме әллә? Кайгылары уртак кешеләр бер-берсен яхшы аңлыйлар.

Таймураз. Үтенәм, бүгенгә генә булса да искә төшермә аны.

Әлфинур. Күп ташламалар сорыйсың бүген!

Таймураз. Бүген минем бәйрәм. Безнең яңа шәһәрнең бәйрәме. Нефтьчеләр, төзүчеләр шәһәренең нәни генә булса да юбилее. Уйласаң, күзгә яшьләр килә. Күңелдә дәрт кайный! Әллә ниләр эшләп ташлардай булам! Төннәрен юкка гына сикереп тора дисеңме мине? Үз гомеремдә бәйрәм итәргә дә хакым бардыр ич минем?!

Әлфинур. Куанычыңны тиешенчә уртаклаша алмыйм, кичер... Әмма нихәл итим, Таймураз?.. Син үтенеп чакыргач, тормышыбызны башкачарак күз алдына китергән идем мин... Син: «Гөләндәмне эзләп чыгып китәм»,— дигән көннән башлап, сиңа булган мөнәсәбәтем бөтенләй үзгәргән иде. Син дә бөтенләй башка кеше идең. Күңелең күтәренке, кәефең әйбәт иде синең. Таймураз тәвәккәлләгән икән, тапмый кайтамы соң ул! дип ышанып сине көттем... Егет чагың кайткан төсле иде... Шуннан бирле тынычлана алмыйм.

Таймураз. Син минем хәлгә дә кер.

Әлфинур. Сине һаман дәрәҗәң борчый. Мине түгел, дәрәҗәңне кайгыртасың.

Таймураз (*өметсезләнеп*). Шушында гына утыр, Әлфинур. Монда тып-тын. Әйбәт. Коры. Сабырлан. (*Пауза.*) Бу сөйләшү хата булды, сизәм. Яшьләр турында сүз кузгатмаска иде миңа!

Әлфинур. Сөйлә, сөйлә син. Туктама.

Таймураз. Болай да кирәгеннән артык ычкындырып ташладым.

Әлфинур. Сөйлә, зинһар. Мин көтәм.

Таймураз. Барыбер, ни сөйләсәм дә, син көткән сүзне әйтә алмам, Әлфинур.

Әлфинур. Барын да сөйлә, берсен калдырма! Ничек утырып киттең? Самолетта барганда ни уйладың?.. Күктә чакта кешеләр Аллаларга якынрак торалар, алар уйлана-

лар... Сине кем каршылады? Беренче булып кемне очраттың? Ул ни диде? Вагын-төяген онытырга да рөхсәтем юк.

Таймураз. Меңенче кат сөйләтәсең...

Әлфинур. Үзең мәҗбүр итәсең.

Таймураз. Барын да беләсең ич инде.

Әлфинур. Сөйләгән саен нидер өстисең, ачыклыйсың. Иң кирәген онытып калдырмадыңмы?

Таймураз. Онытмадым, Әлфинур, онытаммы соң?! Күргәне бере, очраганы бере шуны әйтте: «Безнең Урал детдомнарында Татарстаннан шактый бала тәрбияләнгән. Ләкин алар арасында сезнең кызыгыз Гөләндәм Даишева юк»,— диделәр.

Әлфинур. Ничек юк? Бар иде бит ул! Бар иде.

Таймураз. Юк. Саналмый. Элекке хезмәткәрләрне, пенсионерларны йөреп чыктым. Гөләндәмне белүче очрамады. Сугыш еллары иде бит. Учреждениеләр яңарган. Кешеләр таралган. Архивлар буталган.

Әлфинур. Шул гынамы?

Таймураз. Синең җаныңны җылытырлык берәр хәбәр булсамы? Эх! Җилдәй исәр идем, яшендәй яшьнәр идем.

Әлфинур. Бигрәк саран сөйләдең бүген. Кыска! Кызыбыз Гөләндәм, бәлки, табылмас та, әмма шушы уртак хәсрәткә синең мөнәсәбәтеңне ачыклыйсым килә... Без унике ел аерым тордык... Ялгызлыкка күнегә алмасам да, башны ташка орган юк иде! Гөләндәмне табам дип, югалган кешенең исемен атап, күңелне кузгаттың да, тагын бер кат җәрәхәтләдең.

Таймураз. Сынама мине, Әлфинур. Сугыштан кайткач күпме эзләгәнемне, ничаклы интеккәнемне беләсең.

Әлфинур. Бүгенгесен белергә телим.

Таймураз. Ни эзлисең син миннән?

Әлфинур. Моннан егерме еллар элек булган Таймуразны. Шук, шаян, кыю егетне. Йөзең ачык булган өчен ярата идем бит мин сине. Туры караганың өчен... Ә хәзер күзләреңне яшерәсең... Ул чактагы Таймураз үз кызының югалуына һич тә ышанмас иде.

Таймураз. Өметемне өзгәнем юк. Табылыр! Гөләндәм табылырга тиеш.

Әлфинур. Нигә ул сүзләрне миңа карап әйтмисең?

Таймураз. Тик алдан ук килешик: бер-беребезне борчымаска! Син бит врач кеше, беләсең, талкыма үзеңне! Көчеңне сакла. Тыныч бул. Тыныч яшик.

Әлфинур. Тыныч кына яшик дигәндә, мин: «Посыбрак торыйк, безнең гөнаһларыбыз күп», дигән яшертен өндәү ишетәм.

Таймураз. Ничә еллардан соң без бергә! Без икәү! Кадерен белик.

Әлфинур. Юк, без өчәү.

Таймураз. Хәнифне саныйсыңмы?

Әлфинур. Аның белән без дүртәү. (*Көлә.*) Ә Гөләндәм кияүгә чыккан булса? Без хәзер синең белән әбибабай булып кавышмадыкмы икән?

Таймураз. Хәнифнең безгә күчеп килүенә рәнҗемәдеңме?

Әлфинур. Соңарып булса да минем белән киңәшәсең үзең тагын... Ризамын. Әйбәт кенә егет күренә. Тик ул гына миңа җитми.

Таймураз. Аңладым.

Әлфинур. Хәзер өйгә кайтыйк.

Таймураз. Нигә ашыгырга? Бәйрәм! Күрәсе, сәламлисе кешеләр бар.

Әлфинур. Әгәр ул кайтып, көтеп торса? Без хәбәрне бөтен өлкәләргә дә җибәрдекме?

Таймураз. Барысына да! Җитмәсә, ничә кат!

Әлфинур. Үзенең күзенә чалынмаса, белгән кешеләре укыр.

Таймураз. Ул укырга тиеш. Гөләндәм сиңа охшаган иде.

Әлфинур. Син шунысын да хәтерлисең әллә?.. Күпме кирәксез кешеләрнең йөз-кыяфәтен хәтерлим, ә сабыемның, нарасыемның йөзен оныттым... Мин ашыгыйм булмаса, син үз вакытың белән кайтырсың.

Таймураз. Соңгы үтенечем: тап үзеңә берәр шөгыль! Чигү җепләре алып кайт. Тек. Укы. Рәсем яса! Элек ясый идең ич!

Әлфинур чыга. Таймураз озатып кала. Хәниф керә. Әлфинурны күреп кычкыра.

Хәниф. Әлфинур апа!

Таймураз. Тимә. Кайтсын.

Хәниф. Ялгызы бит... Мин дә кайтырмын дигән идем.

Таймураз. Бүгенгә ялгызы калса да ярар.

Хәниф. Ялгызлык аның өчен чир дигән идегез.

Таймураз. Син мине аңларга тырыш! Мин сине гади мастердан өлкән прораб иттем. Иң зур төзелешкә керттем. Ниһаять, шәһәрдә фатирга кытлык заманда мин сине үз куышыма алдым... Син мине тел төбеннән аңларга өйрән. Син аңлы, акыллы егет бит!

Хәниф. Квартирага күчәргә чакырганда мондый шартлар куймаган идегез.

Т а й м у р а з. Яңадан кабатламам да. Әлегә синең өскә шул йөкләнә: Әлфинур апаңны кара! Юат. Уйланыр вакытын калдырма.

Х ә н и ф. Сезне шактый еллар аеры торган диләр. Дөресме?

Т а й м у р а з. Кемнең гомере шома гына, туры гына бара? Бигрәк тә без кичкән заманда? Ниләр күрмәдек, ниләр булып узмады? Сугышы дисеңме, берсе дә калмады.

Х ә н и ф. Тормыш шомарак барса, рәхәттер инде?

Т а й м у р а з. Синең Таймураз абыең бар. Мин эшли башлаганда янымда андый кеше юк иде. Күп чакларда киңәш сорар иптәш табалмыйча башлар ката иде. Ялгыз идем мин! Син андый фаҗигане белмә!.. Киңәш сорар кешең юк чакта кыен иде, киңәшеңне алыр кешең булмау аннан да читенрәк. Тыңла мине! Ярарга тырыш. Өйрән. Белгәнемне кызганмам.

Х ә н и ф. Төзелештәге хәл борчый мине, Таймураз абый!

Т а й м у р а з. Анысы синең маза түгел! Бу Илья Петровичмы? Шул! Горком секретарена сүзем бар! (*Ашыгып чыгып китә.*)

Х ә н и ф. Инде ничек котылыйм дип торганда, яхшы булды! Таймураз абый да көннән-көн сәерләнә бара. Төптәнрәк уйласаң, һәркем сер йомгагы. Тәгәри дә бара! (*Урман сукмагыннан Гөләндәм белән Айгөл киләләр, кулларында җиңел чемоданнар. Хәниф аларга каршы бара.*) Мәсәлән, менә син, яланаяклы кыз, кем син?

Г ө л ә н д ә м. Минме? Миңа эндәшәсезме?

Х ә н и ф. Син инде, син! (*Юри усалланып.*) Тик яшермә!

Г ө л ә н д ә м. Ачык кына әйтә алмыйм.

Х ә н и ф. Син кеше булып өлгермәдеңмени?

А й г ө л. Нәрсә аңлашып торасың шуның белән, Гөләндәм. Юлда тора икән, тип тә очыр.

Х ә н и ф. Сезнең кемлекне сорап торасы да калмады. Тоттыгыз да паспортыгызны, характеристикагызны, белем турында таныклыкны күрсәттегез.

А й г ө л. Бутамасана. Милицияме син? Әллә болай гынамы?.. Документлар кирәк дисәң, шулай әйт, ачык сөйләш!

Х ә н и ф. Миңа кәгазь кирәкми.

А й г ө л. Баптистырсың, каһәр! Урман уртасында исәрләнеп, кеше җанында казынып йөрмәс идең.

Х ә н и ф (*көлеп җибәрә*). Ачуланышмыйк әле. Болай гына соравым, үпкәләшмик. Уйланып бара идем, сез очрадыгыз. Нигә бәйрәмнән болай иртә кузгалдыгыз дисәм...

Чемоданнарга күз салып туктала. Ниһаять, Гөләндәмгә дә җан керде, ул да сүзгә катнашырга булды.

Гөләндәм. Без бәйрәмнән түгел шул. Тегеннән, ни, ерактан...

Айгөл. Бәйрәмнән диген! Бәйрәмнең дә ниндиеннән! Пәри туеннан!

Хәниф. Мин сезне үзебезнең кызлар дип белдем.

Айгөл. Өйрән, егет, үзеңнекеләрне танырга!

Хәниф. Тану бер, белү икенче. Шулаймы? (*Китәргә җыена.*)

Гөләндәм. Абый, ашыкмагыз әле.

Хәниф. Кирәк шул. (*Тагын күзе төшеп.*) Ә син нигә яланаяк йөрисең?

Айгөл. Җүләр булганга йөри.

Гөләндәм. Җүләрлектер, мөгаен... Күптәнге хыялым, абый! Ямь-яшел үләннәрне ерып урман арасында яланаяк йөрисем килә иде. Рәхәт!

Хәниф. Чүлдән, урмансыз яклардан кайттыңмы әллә?

Гөләндәм. Яланаяк йөргәнегез бармы? (*Хәниф баш чайкый.*) Шул шул, тәмен белмисез. Җирнең сулыш алуы ишетелә, тавышы.

Хәниф. Син басып торган җир нәрсә дип пышылдый хәзер?

Гөләндәм. Тонык кына гүли! Әллә иркәләнә, әллә иркәли...

Хәниф. Гүләсә, безнекеләр бии дигән сүз!

Айгөл. Калдыр бер-ике папирос.

Хәниф. Тартмыйм.

Айгөл. Аракы да эчмисеңдер син, пешкән шалкан.

Хәниф. Сыйларга дәртең бармы?

Айгөл. Чибәр-чибәр кызларны кочасыңмы, ичмасам, хәчтерүш?

Хәниф. Бусы тирән сер. Бусын син басып торган җир дә пышылдамас!

Айгөл. Юктыр синнән, котелок.

Хәниф. Бәлки, бардыр.

Айгөл. Бөтенләй үк өшегән түгелсең, алайса? Гәпләшик! Син шушы шәһәрдә муен бөгәсеңме?

Хәниф. Ничек, ничек?

Айгөл. Эшлисеңме, диюем. Аңлашылмыймы? Муеның бөгәсең дә, мөгезләрең терәп җир актарасың!

Хәниф. Шушында.

Гөләндәм. Кем булып? Кайда?

Хәниф. Төзелештә прораб мин.

Гөләндәм (*сискәнеп*). Ай!

Хәниф. Үкчә шәрифләргә нарат энәсе кадалдымы?

А й г ө л. Прораб кынамыни? Фи-и... Кыланышыңа карап, тишекле сөяк дип уйларсың. Минем үземнең эти полковник. Гөләндәмнең этисе... этисе... доктор! Әнисе очучы, герой!

Х ә н и ф. Сез үзегез кемнәр буласыз соң?

А й г ө л. Без яхшы ата балалары.

Г ө л ә н д ә м. Юлаучылар без, абый... Бәхет эзләүчеләр.

А й г ө л. Бер танышыбызны эзләп килдек. Ялгышмасак, ул шушында булырга тиеш.

Х ә н и ф. Кайсы участокта эшли?

А й г ө л. Шофер гына!.. Бишенче баракта тора.

Г ө л ә н д ә м. Бигрәк ямьсез шул барак дигәннәрең!

А й г ө л. Шәмәрдән исемле. Фартовый егет!

Х ә н и ф. Шофер?

А й г ө л. Озын гына. Кара гына. Калын гына кашлы. Сул беләгендә зәңгәр якорь. Җитәрме?

Х ә н и ф. Кара гына егет дисезме?

Г ө л ә н д ә м (*уңайсызланып*). Белмим мин, күргәнем юк.

Х ә н и ф. Харисовмы?

А й г ө л. Үзе. Беләсең икән! Якыннармы?

Х ә н и ф. Монда, урманда ул.

А й г ө л. Дәшеп уз әле шуңа. Иске дусларың көтә диген!

Х ә н и ф. Әйдәгез үзегез дә. Шәһәребезнең ун еллыгын бәйрәм итәбез.

Г ө л ә н д ә м. Барабызмы, Айгөл?

А й г ө л. Утыр тик кенә. Үзе килсен.

Х ә н и ф. Сау бул, яланаяклы кыз! (*Чыга.*)

Г ө л ә н д ә м. Сөйләшә белмисең син, Айгөл. Аракы, тәмәкеләрне нигә китереп кыстырырга? Фу, кеше ни уйламас?!

А й г ө л. Телгә осталыгым юк. Әмма һәрбер кешене тикшерергә кирәк безгә.

Г ө л ә н д ә м. Моннан болай эш белешергә дә сине җибәрмим. Алмыйлар дисең дә, борылып чыгасың. Анда да шулай булгандыр әле, аракы дип, тәмәке дип тәтелди башлагансыңдыр.

А й г ө л. Үзең йөр, бик кирәгең бар иде ди! Тапты нәнкә! Җаныем, кая гына тыгылсаң да, иң әвәл паспортыңа күз салалар... Ә-ә, асыл кошлар икән, дип кенә кырт кисәләр. Ярый әле, Шәмәрдән телеграм сукты, йөрер идең тәмле телеңне аркылы тешләп.

Г ө л ә н д ә м. Акча күпме калды безнең? Минем өлешемне бир.

А й г ө л. Хәзер нәрсәгә акча? Монда Шәмәрдән бар! (*Пауза.*)

Г ө л ә н д ә м. Ә мин бая шундый курыктым. Котым калмады.

Икесе дә үләнгә сузылып яталар.

А й г ө л (*акча санап*). Егерме ике тәңкә!.. Тапкансың куркыр кеше.

Г ө л ә н д ә м. Шулай аз калганмы?

А й г ө л. Мә, тот унысын.

Г ө л ә н д ә м. Күзгә карап «кем син?!» дип тора бит.

А й г ө л. Пешмәгәне күренеп тора. Яшел!

Г ө л ә н д ә м. Ә күзе матур... Ә, Айгөл, чынлап торып шулай сорасалар ни дияр идең?

А й г ө л. Ә син үзең?

Г ө л ә н д ә м. Белгән юк.

А й г ө л. Башка кайгың юк икән, тик кенә ят. Иректә без хәзер. Янда, артта конвойлар юк. Өреп бармыйлар. Ни теләсәк, шуны эшләрбез.

Г ө л ә н д ә м. Кеше төсле яшәсәк иде диген!

А й г ө л. Бәхетле буласы килә!

Г ө л ә н д ә м. Үткән юлларга кабат төшмәсәк иде. (*Торып йөри.*) Кешеләр белән туганнарча яшәсәк иде. Кайгы-шатлыклар уртак булсын иде! Эшләсәк иде... Берәр кеше безне кунакка өенә чакырсын иде... Өй... Квартира! Минем әни исән бит! Еракта калды калуын, шулай да адресын югалтмыйм. Менә. (*Сумкасыннан кәгазь алып күрсәтә.*) Эшләп торыр урын юнәтсәм, аны да үз яныма чакырам.

А й г ө л. Берәрсенең куенына бөгәрләнеп кереп ятасы иде дә гомерлек рәхәткә чумасы иде.

Г ө л ә н д ә м. Килер бит?

А й г ө л. Чакыр, чакыр! Үзеңне детдомга илтеп ыргыткан карачкыны муеныңа менгер!

Г ө л ә н д ә м. Барыбер ана ул. Ягымлы күзләре белән бер карасын иде әле, аркамнан сөйсен иде.

А й г ө л. Минем ул яктан рәхәт. Ата-ана дип тыпырчынасы юк. Үлеп котылганнар.

Г ө л ә н д ә м (*җырлый*).

Кара урманга кердем утынга дип,
Алмагачлар кистем балан дип.
Нигә ят кешенең күңеле каты —
Ялгышып та әйтми «балам!» дип.

А й г ө л. Җырын нәкъ көненә китердең.

Г ө л ә н д ә м. Ишеткәнең бар иеме?

А й г ө л. Мин меңне ишеткән, меңне җырлаган. «Граждане, послушайте меня!..» Шәмәрдән сау булсын!

Г ө л ә н д ә м. Ә мин эшкә керәм.

А й г ө л. Алсалар керерсең. Алмасалар нәрсә? Кәбестәме?

Г ө л ә н д ә м. Ахыр чиктә менә бу прораб егетне эзләп табам. Исемен сорыйсы калган... Әйдә, киттек! Шәмәрдәнең шунда диде ич. Тотабыз да барабыз. Без кемнән ким?

А й г ө л. Үзе килсен. Без берәүдән дә ким түгел. Без артык!

Г ө л ә н д ә м. Монда ятып бәям күтәрелер дисеңме?

А й г ө л. Менә күрерсең...

Шәмәрдән керә.

Ш ә м ә р д ә н. Сәлам Айгөлгә!

А й г ө л. Шәмәрдән!

Ш ә м ә р д ә н. Күрешмәгәнгә ике елдан арттымы?

А й г ө л. Теге вакытта тиз ычкындың үзең. Җитез!

Ш ә м ә р д ә н. Куянны аяклары коткара. Ә бу кем?

А й г ө л. Гөләндәм шушы инде. Язган идем бит.

Ш ә м ә р д ә н. Гөләндәм, Гөләндәм, нурны ала гөлләрдән! Безнең кысан шәһәр ник кысан дип йөри идем, синең кебек чибәрләр җитмәгәнгә икән!

А й г ө л. Җилпенмә! Йөземе яшел, эчеңә тияр. Син монда болай да йөзәсеңдер әле.

Ш ә м ә р д ә н. Сабынлап юып чыгаргандай чип-чиста.

А й г ө л. Без арыдык, ачыктык. Станцадан урман аркылы гына чыгасы дигәч, Гөләндәм «җәяү барыйк» дип каныма төште. Урының әзерме?

Ш ә м ә р д ә н. Әзер дип...

Г ө л ә н д ә м. Әзер урынга мин бармыйм.

Ш ә м ә р д ә н. Айгөл, мин ышанып ук бетмәгән идем. Урыны табылыр... Башкасы гына бераз кәйрәк... Бер планым бар! Мондый чибәрләр килгәч, айгырны иярләми ярамас! Чак кына көтеп торыгыз.

А й г ө л. Берәр нечкә бил белән саубуллашасың бармы?

Ш ә м ә р д ә н. Ашыкма, пешәрсең. (*Чыга.*)

А й г ө л. Күрдеңме? Бөркет!

Г ө л ә н д ә м. Миңа менә шушы кырмыскалар ошый төшә.

А й г ө л. Тегендә мастерскойга килгәләде ул. Син аны күрмирәк калдың.

Г ө л ә н д ә м. Мин аның янына бармыйм, Айгөл.

А й г ө л. Башыңа төшсә, барырсың.

Г ө л ә н д ә м. Ул синең танышың. Синең якының. Миңа беркем дә түгел. Язмышымны чит кешеләр кулына тапшырып туйдым. Аяк терәп сорар вакыт җитте: кешеме мин, бәндәме?

А й г ө л. Тс-с... Шәмәрдәннән алай тиз ычкына алмассың!

Г ө л ә н д ә м. Хәзер үк китәм. Үзем барам. Үзем табам. Бәхете дә, михнәте дә үземчә булыр.

Чыга башлый. Т а й м у р а з, Х ә н и ф, З а к и р, Р о з а керәләр.

Т а й м у р а з. Яшьләрдә өмет! Картларга таян, яшьләргә өметлән... Менә без, сезнең белән бергә, тау-ташларны актарачак!..

Х ә н и ф (*аны бүлдереп диярлек*). Харисов килмәдеме әллә? Мин әйтеп киткән идем аңа.

А й г ө л. Нинди Харисов? Ә-ә, килер әле.

З а к и р. Без китсәк тә ярыймы, Таймураз абый?

Х ә н и ф. Күрәсезме, Таймураз абый, өстәмә көчләр килә. Комсомоллармы?

А й г ө л. Алай ук түгел лә...

Р о з а. Хуш киләсез, кызлар. Кай яклардан?

Г ө л ә н д ә м. Ярый, Айгөл. Хуш.

А й г ө л. Гөләндәм! Бездә сүз кыска, беләсең.

Т а й м у р а з. Гөләндәм? Синең исемең Гөләндәмме?

З а к и р. Әйдә, Роза!..

Т а й м у р а з. Хәниф, син дә иркенләп йөр.

Х ә н и ф. Минем монда буласым килә иде дә...

Т а й м у р а з. Бар, бар! (*Хәниф теләр-теләмәсрәк, Закир белән Роза атылып чыгып китәләр.*) Синең исемең чыннан да Гөләндәмме? Фамилияң ничек? Даишева түгелме?

Г ө л ә н д ә м. Минем китеш, абый кеше. Ә исемем чыннан да Гөләндәм. Фамилиям Зиннурова. Документлар күрсәтергәме?

Т а й м у р а з. Зиннурова икән... Гөләндәм...

Г ө л ә н д ә м. Берәр кешегә охшатасызмы әллә, абый кеше?

Т а й м у р а з. Бер Гөләндәмне белә идем мин... Күптән инде. Шул бик кирәк иде миңа. Бикләр дә кирәк иде! Синең ата-анаң бардыр, Гөләндәм?

А й г ө л. Ятимнәр без. Икебез дә детдомда тәрбияләндек.

Т а й м у р а з. Детдомда? Шаяртмасагыз, монысы ифрат дәрәҗәдә кызык икән! Зиннурова синең чын фамилияңме, Гөләндәм? Гафу ит, үз фамилияңме дип соравым иде.

Г ө л ә н д ә м. Айгөл, гадәтенчә, бераз ялгышты, абый кеше. Әнием бар минем. Курган дигән җирдә яши.

Т а й м у р а з. Әниегез бар икән!..

А й г ө л. Ана дисәң аны!.. Карачкы диген, алкоголик!

Т а й м у р а з. Әһә!.. Хәзер аның белән очрашасыңмы?

Г ө л ә н д ә м. Тирәнгә керәсез, абый кеше, килешми! Хәзергә очрашырга язмасын инде! Сау бул, Айгөл!

Т а й м у р а з. Нигә очрашасыгыз килми?

Г ө л ә н д ә м. Ике ел колониядә утырып чыктык без, абый кеше. Асыл кошлар диләр безне.

Т а й м у р а з. Бусы ни өчен тагын?

А й г ө л. Прокурордыр бу!

Г ө л ә н д ә м. Тегү мастерскоенда эшли идек. Детдом мастерскоенда. Эшкә өйрәнә идек. Шуннан кыйммәтле әйберләр югалды. Кемдер урлады, безгә сылтадылар.

Т а й м у р а з. Андый хәлләр дә була. Монысына да ис- китми!

Г ө л ә н д ә м. Колониядән чыктым менә дип, әни янына ничек кайтасың? Лутче җир тишегенә... Иң элек кеше төсле яши башларга кирәк. Аннан очрашканда да ярар.

Т а й м у р а з. Димәк, сезнең кая китүегезне, нишләп йөрүегезне хәзергә берәү дә белми?

Г ө л ә н д ә м. Нигә дип безгә бәйләнәсез? Кем сез?

Т а й м у р а з. Ничә яшь соң сиңа, балам?

Г ө л ә н д ә м. Күп инде, абый кеше. Ике кул бармагын икешәрләсәң дә җитмәс. Егермене үткәнгә дә ике ел. Урманда ялгыз йөрергә дә курыкмаска була. Хушмы, Айгөл?

А й г ө л (*шыпырт, янап*). Көт диләр сиңа!

Т а й м у р а з. Гөләндәм... Яшең дә шундый... Чәчләрең дә...

Г ө л ә н д ә м. Нигә миңа ияләсез сез, абый кеше!

Т а й м у р а з. Мин өйгә кайтам. Өйгә...

Г ө л ә н д ә м. Кайтыгыз. Нигә тукталдыгыз?

Т а й м у р а з. Шикле күренәммени соң? Танышыйк: Таймураз Даишев булам мин. Төзү трестының баш инженеры.

Г ө л ә н д ә м. Алла булсагыз да сезгә иярмим.

А й г ө л. Кыз баланы япа-ялгызын ир-ат белән җибәрәмме?!

Т а й м у р а з. Безгә сөйләшеп алырга кирәк. Карышма, кирәк, Айгөл! Шулай бит синең исемең, әйеме? Акыллы бул, кит башка шәһәргә. Бөгелмәгә, Салаватка, теләсәң кая.

А й г ө л. Акылың алтын икән!

Т а й м у р а з. Юл чыгымнарын түлим, машина белән илтеп урнаштырам. Анда да ярдәм итеп торырмын. Кит кенә!

А й г ө л. Сәбәп? Нигә китим ди мин?

Т а й м у р а з. Аңлатырмын. Хәзергә беразга гына безне калдырып тор.

Айгөл. Тормыйм.

Гөләндәм. Яле, Айгөл. Китеп торчы. Нәрсә маташтыра ул?

Айгөл. Ул-бу сизелсә, мин монда гына. Онытма! (*Чыга.*)

Гөләндәм (*паузадан соң*). Абый, Айгөл китте.

Таймураз. Күрдем. Каян иярдең син мондый юлдашка?

Гөләндәм. Бәлки, мин аның үзен ияртеп йөримдер?

Таймураз. Күзләрең артык саф... Аның күзендә ат тоягы эзе бар... Синдә исә сабый күзләре, җинаятькә кулың баргандыр дип уйламыйм.

Гөләндәм. Нишлисең... Язмыш икебезгә уртак сукмак билгеләгән. Мине әнкәйдән алып детдомга китергәннәр, ул анда булган. Бер группада яшәдек, бергә укыдык. Эшкә дә бергә озаттылар, колониягә дә. Моңарчы сыенып яшәгән идек, аркалар бер-берсен җылыта төсле иде, ә күзләребез төрле якка караган. Белгән юк, моннан ары без барасы юллар тармы, киңме...

Таймураз. Синең туганнарың да, беркемең дә юк инде?

Гөләндәм. Нинди кеше сез? Җанны суырасыз... Әллә кайда басып торсагыз да әрсез бармакларыгыз белән тәнне капшыйсыз кебек.

Таймураз. Гаеплемен! Сиңа берни белдермичә, кайбер нәрсәләрне ачыкларга теләгән идем.

Гөләндәм. Ерак туганнарым бар-барын... Тик алар әни белән арадашлыкны күптән өзеп бетергәннәр.

Таймураз. Әтиең кем?

Гөләндәм. Әти сугыштан каты яраланып кайткан да озак яшәмәгән... Шуның кайгысыннан әни эчәргә сабышкан.

Таймураз. Гөләндәм! Мин синең әтиең булып чыксам ни диярсең?

Гөләндәм. Юк, юк, абый кеше. Сез бит акылсыз түгел. Түгелдер бит?

Таймураз. Тыңлап бетер.

Гөләндәм. Юк, юк, тотмагыз да, нитмәгез дә.

Таймураз. Әти-әниле буласың киләме?

Гөләндәм. Андый бәхет кешегә бер генә бирелә.

Таймураз. Безнең кызыбыз буласың килмиме?

Гөләндәм. Сез акыллы бит, җүләр түгел, әйеме, абый кеше?

Таймураз. Мине аңларга тырыш син. Сораш. Бел!

Гөләндәм. Шикле адәмнәр белән аш та, эш тә бүлешмим дигән сүзем бар. Нәзер әйттем! Яңа шәһәргә

килүемнең сәбәбе дә шул. Яңа урамнар, яңа кешеләр. Үземнең дә яңарасы килә. Ике елда уйларлык нәрсәләр булды, абый кеше.

Таймураз. Сиңа да, үзебезгә дә яхшылык телим, Гөләндәм. Синең кулыңда безне хәсрәттән коткарырлык җай бар.

Гөләндәм. Ризалашмыйм, абый кеше.

Таймураз. Шәһәргә ашыкма син. Колониядән чыкканнарга бездә дә пешереп куймаган.

Гөләндәм. Барыбер ризалашмыйм. Үз хәсрәтем үземә.

Таймураз. Бүлешик, Гөләндәм! Син минекен ал, мин синекен! Утырып тор. Тыңла. (*Гөләндәм утыра.*) Бер кеше була. Шат, бәхетле. Башкалар теләсә ни уйласын, ул үзенчә бәхетле яши! Тын гына, яхшы гына. Җайлы гына урында эшли. Әйбәт кенә яшәп ятканда семьясы бозыла.

Гөләндәм. Ир гаепләме, хатынмы?

Таймураз. Хатыннан башлана. Эш сөючән, талантлы врач хатын иреннән гаеп таба башлый... Әкәм-төкәм кебек үз кабыгыңа төренеп яшисең дип бәйләнә... Ниһаять, боларның балалары туа. Балага зур өмет баглый ир!.. Әмма бала ике арадагы җәнҗалны тагын да көчәйтеп кенә җибәрә. Хатынны Мәскәүгә аспирантурага җибәрәләр. Ир: «Китмә, баланы тәрбия кыл»,— дип ялынса да, хатын үзсүзләнеп китеп бара.

Гөләндәм. Ул шуннан кайтмадымы?

Таймураз. Ир, ягъни ата кеше, баланы алып башка шәһәргә күчеп китә, эзен югалта. Баланы ана кулына бирәсе килми. Хаталана, әлбәттә, әмма ул чакта аны-моны уйламый әле... Озакламый сугыш башлана. Ирне фронтка алалар. Ул, баланы детдомга тапшырып, фронтка чыгып китә. Ә тиздән бу детдомдагы балаларны Урал ягына озаталар да госпиталь ясыйлар.

Гөләндәм. Ә ана нишли, ана?!

Таймураз. Ул да сугышта катнаша. Ир белән хатын Берлинга җитеп очрашалар. Туган илгә бергә кайталар. Бала гына табылмый.

Гөләндәм. Югаламы?

Таймураз. Югалган кызның исеме Гөләндәм... Аның әтисе мин. Әнисе өйдә аны көтеп утыра.

Гөләндәм. Ул сезне гафу иттеме?

Таймураз. Юк, гафу итмәде. Сугыштан кайткач без уникe еллап аерым тордык. Өйләнеп тә карадым мин, тик күңел һаман аңа тартылды. Гомер үтеп бара, менә олыгайдык, салмакландык. Кайгыбыз уртак. Югалган кызыбыз уртак. Мине монда, нефть районына яңа шәһәр

төзергә җибәрделәр. Эш авыр, катлаулы... Ялгызлык җанны кимерә... Миңа нидер җитми, дәртләнеп кенә керешәм дисәм, йә уңга, йә сулга сөрлегәм... Нишлисең, башымны иеп Әлфинур апаң катына бардым. Кайт, дип ялындым... Гөләндәм исеме авызымнан чыккач кына ризалашты... Монда күчеп килде. Бергә торабыз. Тик аерым торуларым бергә чаклардан рәхәтрәк булган икән!.. Сәбәбе — кызыбыз юк!

Гөләндәм. Кызыгыз сезне бер чакта да кичермәс. Ярата алмас ул сезне!

Таймураз. Гаебем зур... Тик аңа карап хәзер ни үзгәрә?

Гөләндәм. Хатыныгыз кызганыч.

Таймураз. Кил син, бездә кал. Килеш-килбәтең туры килә. Үткән гомерең гаҗәп уңайлы. Фамилияң башка икән, сугыш елларында нинди буталышлар булмагандыр дисең? Сугыш башланганда Байбүләк детдомыннан алып киткәннәр дип сөйли башласаң, үз биографияң тап кына килә. Риза бул!

Гөләндәм. Юк!

Таймураз. Өч бүлмәле квартира. Иркен. Мул. Дәрәҗәбез, абруебыз яхшы. Шәһәрдә институтның кечкке филиалы. Укытырмын? Коткар мине. Кешечә тыныч яшисем килә!

Гөләндәм. Әгәр чын Гөләндәм табылса?

Таймураз. Моңарчы табылыр иде инде...

Гөләндәм. Тагын ялган белән яши башларгамы? Юк, юк!

Таймураз. Кызыбызга бик охшагансың... Әлфинур сине бик нык яратыр. Нечкә хисле, ягымлы хатын ул. Аңа син кирәк! Миңа ул кирәк! Безгә син кирәк!

Гөләндәм. Гадел буласы килә, абый. Сез дә гадел яшәгез.

Таймураз. Монда таба киләләр... Безне хәзер бергә күрмәүләре хәерлерәк. Йә килешеп китәрбез...

Гөләндәм. Өметләнмәгез, абый.

Шулай дисә дә, Таймураз белән бергә куак артына кереп китә. Роза белән Закир керәләр.

Закир. Тизрәк, тизрәк!

Роза. Туфли үкчәмне кубардың!

Закир. Хәниф абыйны табарга кирәк.

Роза. Кайда төзәттерермен инде бу туфлиемны? Шәһәр диген инде... Аяк киеме төзәтер урын да юк бит.

Закир. Төзелеп беткәч булыр... Салалар бит!

Роза. Уф... Закир, тукта, тын алыйм. Теге егет сиңа ни пышылдады?

З а к и р. Бәла! Чаган күлендә коенучыларның сәгатьләрен, акчаларын җыеп алганнар.

Р о з а. Кайсы явызы бәйрәмнең ямен качырып йөри икән?

З а к и р. Еракка китә алмаслар. Күлне урыйлар! Егетләр анда!

Р о з а. Туфлием туфли гына түгел иде. Әйдә!

Чыгалар. Куак артында Г ө л ә н д ә м күренә.

Г ө л ә н д ә м. Мин дә ашыгыйм әле, абый кеше, китим. Яратмыйм ыгы-зыгы башланганын. Бер күрдем, берәгәйле булды.

Т а й м у р а з. Утларга саласың бит! Соңгы сүзең шулмы?

Г ө л ә н д ә м. Ишеттегез бит.

Т а й м у р а з. Шәһәрдә калсаң, шуны да онытма: монда сөйләнгәннәр монда сеңсен.

Чыгып китә. Атылып диярлек А й г ө л керә.

А й г ө л. Тукта инде, ни сөйләштегез?

Г ө л ә н д ә м. Сиңа кирәкле сүзләр түгел, Айгөл.

А й г ө л. Син миннән шулай тиз аерылырмын дисеңме?

Г ө л ә н д ә м. Кайгылы кеше икән ул да...

А й г ө л. Тутый кош, тиз-тиз генә ычкынырмын дисеңме?

Ш ә м ә р д ә н керә.

Ш ә м ә р д ә н. Гөрлисезме, күгәрченнәр. Тирә-як тынмы?

А й г ө л. Тын шикелле.

Ш ә м ә р д ә н. Мә, синең өлеш.

А й г ө л (*акча алып*). Нигә бик аз монда? Минем санау буенча күбрәк булырга тиеш... Аннары: син котылдың, мин камыт кидем. Сине дә чага ала идем ич мин! Өстә!

Ш ә м ә р д ә н. Җитмәсә, боларын ал. Тизрәк яшер. Дружинниклар иснәнә.

А й г ө л. Оһо! Ярыйсы нәрсәләр! Беразын Гөләндәмгә биреп тор.

Ш ә м ә р д ә н. Шәмәрдән бурычлы булып яшәргә яратмый.

Г ө л ә н д ә м. Сәгать? Акчалар? Каян алдың?

Ш ә м ә р д ә н. Хөзер Ильяс коеп калдырган. Шуларны җыйдым.

**Гөләндәм.** Хәзер үк илтеп бир.

**Шәмәрдән.** Айгөл, ни кылана бу йон тәпи?

**Айгөл.** Яшел дидемме? Надан, укымаган.

**Шәмәрдән.** Сез килгән хөрмәткә тырышып йөрим, ә сез...

**Гөләндәм.** Айгөл, алма! Гомеремдә дә кеше әйберенә кагылганым юк.

**Айгөл.** Бир тизрәк, куян!

**Гөләндәм.** Айгөл, тотынма. Үкенерсең. Төкер Шәмәрдәнеңә! Әйдә минем белән.

**Айгөл.** Тотынма диләр сиңа, күлмәкне ертасың.

**Шәмәрдән.** Бу ялантәпи ошап тора әле миңа, Айгөл. Тәртәгә җигелергә өйрәтмәгәннәр икән тегендә. Йомшак мөгаллимнәр арасында яшәгәнгә охшый. Өйрәтәбез аны, законга кертәбез. Тот шәпләп кенә шуларны.

**Гөләндәм.** Ал кулыңны!

**Шәмәрдән.** Керфекләрең күбәләк канаты кебек!.. Яшьлегеңне кызган.

**Гөләндәм.** Мин синең янга килмәдем. Бурычым юк.

**Шәмәрдән.** Сине минем янга җибәрделәр. Ксива әллә кайчан килеп җитте. Боерык!

**Гөләндәм.** Тотынма, шакшы!

**Шәмәрдән.** Каурый татыйсың киләме? (*Пычак чыгара.*)

**Айгөл.** Кан чыгарма, Шәмәрдән.

**Шәмәрдән.** Алайса, тот бер беләгеннән. Бик әйбәтләп кенә акчалары, сәгатьләре белән илтеп тапшырыйк үзен. Дружинниклар каракны эзләп интегәләр булыр. Ә ул монда икән. Атла, фәрештә!

**Гөләндәм.** Җибәр! Кычкырам!

**Шәмәрдән.** Тавышың матур булса, кычкыр.

**Гөләндәм.** Ай!

**Шәмәрдән.** Төрмә баландасын сагындыңмы? Кандалалы сәкеләр төшеңә керәме?

Гөләндәмне ике яктан эләктереп алалар, Шәмәрдән Айгөлгә күз кыса.

**Айгөл.** Сагынган, сагынган!

**Гөләндәм.** Абый! Таймураз абый! Килегез! Коткарыгыз! Таймураз абый!

Таймураз керә. Аны күргәч Шәмәрдән белән Айгөл качалар.

**Таймураз.** Син чакырдыңмы, Гөләндәм? Синең тавышмы? Әллә колагыма гына ишетелдеме?

**Гөләндәм.** Мин... Мин риза, абый!

**Таймураз.** Коткаручым, рәхмәт! Мәңге онытмам!

Хәзер үк өйгә кайтабыз... Кайтырга базмыйча утыра идем... Коткаручым! Фәрештә! Юлда барын өйрәтермен, киттек!

Г ө л ә н д ә м. Тизрәк моннан китик без, югалыйк.

Чыгалар. А й г ө л белән Ш ә м ә р д ә н н е ң башы күренә.

Ш ә м ә р д ә н. Нәрсә булды бу?

А й г ө л. Аңышмый калдым.

Ш ә м ә р д ә н. Әләкләргә барамы?

А й г ө л. Йөрмә. Борчыма үзеңне. Әләкли белсә, бер гаебе юк килеш ике ел кандала симертер идеме?

Ш ә м ә р д ә н. Айгөл! (*Кочаклап үбә.*)

А й г ө л. Шәмәрдәнем, бөркетем!

Ш ә м ә р д ә н (*такмаклый*).

Бу дөньяда иң кадерле
Ике нәрсә бар, диләр:
Берсе яшьлек заманасы,
Берсе сөйгән яр, диләр!

А й г ө л. Бөркетем!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Таймуразлар квартирасы. Зал ягы. Бүлмәләргә һәм кухняга керә торган ишекләр. Бер якта диван-кровать. Аның янында Гөләндәмнең чемоданы. Көн кичкә таба. Т а й м у р а з белән Ә л ф и н у р кунак озаталар. Күңелле хушлашу, саубуллашу. Тынлык. Урамда машина гөрләгән тавыш кына ишетелеп кала. Таймураз белән Әлфинур, бер-берсенә карарга кыймыйчарак, ике якта ике ят булып басып торалар.

Т а й м у р а з. Котылдык, ниһаять.

Ә л ф и н у р. Кунакларны тәмле сүз белән озатасың син.

Т а й м у р а з. Сине кызганам. Артык ешладылар. Гөләндәм кайтканнан бирле көн саен кунак. Кич саен кемдер килә. Бүген инде берәүне дә көтмәгән идем.

Ә л ф и н у р (*табынны җыештыра, Таймураз аңа булыша*). Кешеләр шатлыклы өйләргә йөрүчән булалар. Аларга рәнҗергә ярамас, рәхмәт кенә әйтик!

Т а й м у р а з. Кунаклардан соң арып калам... Көне буе иңем белән йөк ташыган кеше төсле булам... Мунчага барып кайтасы инде әллә?

Ә л ф и н у р. Өченче көн генә бардың бит.

Т а й м у р а з. Тән кычыта, җан тыныч түгел.

Ә л ф и н у р. Гөләндәм кайтканга сөенәсең дип йөрим мин тагын.

Таймураз. Кунаклардан ялыктым дип кенә әйттем.
Әлфинур. Күңелле генә сөйләштек.
Таймураз. Шә-әп! Искиткеч!
Әлфинур. Нигә, врачларның шәһәр төзелеше турында гәп алып барулары ошамадымы сиңа? Хәзер врачлар да төшеп калганнардан түгел...
Таймураз. Элек, Культура сарае салабыз дигәч, мине пешекли идең. Хәзер әнә урыны да ошамый башлады сиңа!
Әлфинур. Бер якта биш йөз машиналы автохуҗалык. Икенче якта райсоюз складлары. Уртада кысылып торган Культура сарае кемгә ошар икән?
Таймураз. Ошаса-ошамаса, монысын миңа сөйлә! Үземә! Түремә кунаклар тутырып мине чәйнәүдән тукта.
Әлфинур. Кунаклар белән сөйләшәсе сүзне алдан планлаштырып куеп булмый, Таймураз. Җыелыш түгел ич монда, мәҗлес.
Таймураз. Мин бу шәһәргә нигез салдым. Байтак йортлар торгыздым. Җир асты коммуникацияләренең картасы саклана дырмы, мин аларның барын яттан беләм. Мин! Болар барысы да минем гомер бәрабәренә эшләнә!
Әлфинур. Сиңа шушы шәһәр ошыймы?
Таймураз. Ошый.
Әлфинур. Кояш җитми миңа, Таймураз, кояш!
Таймураз. Кояшка туймасаң, пляжга бар, болынга чык.
Әлфинур. Пляжда нефть... Болында нефть... Кояш телим! Урамнарның сүзсез, җансыз булуына күңел риза түгел. Без төзи торган йортларның һаман-һаман биш катлы булып, детдом балалары төсле соры гына, юаш кына, курка-курка бер-берсенә елышып, бер-берсен күләгәләп торуларына йөрәк әрни. Шундый бай нефть районнарында халкыбыз мәңге горурланырлык шәһәр салырга иде.
Таймураз. Кешеләргә торырга квартира җитми! Матурлык соңыннан!
Әлфинур. Алайса, нигә чәчеләсең? Нигә төзелешләрне ваклыйсың? Бөтен җирдә фундаментлар...
Таймураз. Миңа илле тулып узган. Мин ашыгам. Мин өлгерергә тиеш...
Әлфинур. Нигә ашыкканыңны әйтимме?
Таймураз. Әйтсәң дә минем файдага булмас ул.
Әлфинур. Яшьрәк чакта, егәрле чакта сиңа байтак җаваплы эшләр тәкъдим итеп карадылар. Син ул чагында үз өстеңә җаваплылык алырга курыктың. Хәзер шул үкенечле көннәреңне кайтарырга омтыласыңмы?
Таймураз. Омтылам дисәм, ни әйтерсең!
Әлфинур. Алайса, уйлап эш ит! Син салдырган йорт-

лар арасыннан кешеләр кар базыннан өшеп чыккан кебек күгәреп килеп чыкмасыннар. Ансат бит ул, Чупай тавын кисеп ташы да квадратлап-оялап өеп куй!

Таймураз. Син кайчандыр шәфкатьлерәк идең...

Әлфинур. Мин һаман шундый ук, Таймураз!

Таймураз. Гөләндәм диден, кызыбыз табылды... Инде күктән кояшны алып төшеп бирә алмыйм, бигайбә.

Звонок. Шәмәрдән керә.

Шәмәрдән. Ишегегез бикле түгел икән. Исәнмесез.

Әлфинур. Саумысез.

Шәмәрдән. Кызыгыз... Гөләндәм кирәк иде. Йомышым бар.

Әлфинур. Узыгыз. Менә урындык. Утырыгыз.

Таймураз. Гөләндәм өйдә юк.

Шәмәрдән. Утыр дигәннәр берәүгә! (*Көлә.*) Һәм ике елны чәпәгәннәр! Керермен әле. Гөләндәм кайткач! (*Чыга.*)

Таймураз. Кем бу? Нишләп йөри.

Әлфинур. Ике-өч тапкыр кереп чыкты инде. Нигәдер Гөләндәм өйдә юк чакка туры килә.

Таймураз. Әйт, йөрмәсен!

Әлфинур. Гөләндәм кайтканнан бирле син күзгә күренеп үзгәрәсең. Кызыбыз табылды, бурычым үтәлде, гөнаһларым юылды дип санавыңмы бу?

Таймураз. Шәфкатьсез булма, килешми. Гөләндәм «әнкәй» дип өзелеп тора. Күңелең каткан булса да йомшарырлык.

Әлфинур. «Әткәй» дип өзелгәне күренми.

Таймураз. Бу очракта мин ашыкмыйм.

Әлфинур. Үз-үзеңә ышанасың инде?

Таймураз. Гөләндәм кайда?

Әлфинур. Нигәдер озаклады. Кайтырга бик вакыт иде аңа.

Таймураз. Әлфинур... (*Пауза.*) Кунаклар килә башлады исә, син аны оста гына өйдән чыгарып җибәрәсең.

Әлфинур. Нигә икәнен сизмисеңме?

Таймураз. Ни уйларга да белмим.

Әлфинур. Читенсенә ул.

Таймураз. Үз әткә-әнкәсе янында, үз өендә нигә читенсенсен!

Әлфинур. Нишлисең, әлегә шулай. Беркөн Салихлар килгәч, күлмәгенә ике тапкыр чәй түкте, каушады.

Таймураз. Салих судья бит, күрер күзгә дә кырыс... Моннан ары чыгарып җибәрә торган булма. Әнкәй мине яратмый икән дип уйлар.

Әлфинур. Чыгып керәм дигәч, каршы килгәнем юк.

Сизгер ул, хисле кыз. Кунаклардан соң йокыга китә алмый. Безнең бүлмә ишегенә килеп-килеп китә.

Таймураз. Ян бүлмәне аңа биреп, үзебез монда чыгабызмы әллә?

Әлфинур. Аны да әйтеп карадым, риза булмады.

Таймураз. Ә син төннәрен нигә йокламыйсың?

Әлфинур. Йокламыйм дигәнем юк әлегә.

Таймураз. Ишек төбенә килеп йөргәннәрен үзе сөйлиме?

Әлфинур. Юк. Үзем беләм. Аналар барын да беләләр, Таймураз.

Таймураз. Барын дамы?

Әлфинур. Бөтенесен дә. Аналар йоклаганда да ишетәләр, хәтта күрәләр. Ана йөрәге бер чакта да йокламый... (*Җыештырып, рәтләп бетерәләр.*) Рәхмәт, булыштың. Азрак ял итеп алыйм, булмаса.

Таймураз. Йокла!.. Төннәр буе планнар корып, шәһәрләрнең искеләрен җимереп, яңаларын корып ятма. Анысын миңа калдыр...

Әлфинур елмаеп башын чайкый, бүлмәгә кереп китә. Таймураз ишекле-түрле йөри. Гөләндәм кайта.

Гөләндәм. Кунаклар киттеме? Бездә берәү дә юкмы?

Таймураз. Әниең генә өйдә.

Гөләндәм. Савыт-саба җыештырырга дип ашыккан булам тагын. (*Тик басып тора да чыгарга тели.*)

Таймураз. Куалармы әллә сине? Өйдә утыр.

Гөләндәм. Әнкәй күренми...

Таймураз. Хәл җыярга ятты. Унбер кешене ашатып-эчертеп озату җиңел түгел. Утыр, утыр...

Гөләндәм. Ни бар?

Таймураз. Зинһар, пышылдап сөйләшмә.

Гөләндәм. Мин пышылдамыйм.

Таймураз. Өч адымнан тавышыңны ишетеп булмый. Үз-үзеңне кыюрак тотарга вакыт.

Гөләндәм. Мин сез кушканнарның барын үтәп киләм. Дөрес эшләмәсәм, төзәтегез.

Таймураз. Өеңдә дә, төшеңдә дә хәтереңдә тот: мин синең әтиең.

Гөләндәм. Монысын беләм.

Таймураз. Ата буларак, мин синең өчен барын да эшлим. Ашатам, эчертәм, киендерәм. Кеше арасында, бигрәк тә әнкәң алдында, миңа йомшак кына иттереп «әткәй» дип эндәш.

Гөләндәм. Сез барын да беләсез. Нигә мөмкин түгелне дә кушасыз?

Таймураз. Кирәкмәгән вак-төякләрне әллә кайчан оныттым! Хәзер син минем кызым. Минем кызым этисен яратырга тиеш.

Гөләндәм. Әнкәй берәр нәрсә сизәдер дип шикләнәсезме?

Таймураз. Шул гына җитмәгән иде!

Гөләндәм (*тагын пышылдап*). Сезгә... эткәй дип... әйтә алмыйм. Теләсәгез нишләгез. Әнкәйне алыштыра алсам да эткәм хатирәсен пычратасым килми. Мин аны күрмәгән, белмәгән. Мин аңа «эткәй» дип әйтергә өлгерә алмый калдым. «Эткәй» сүзе аның белән бергә үлде. Мөгаен, әйбәт кеше булгандыр ул... Менә миндә еш кына ике кеше, капма-каршы ике җан көрәшә. Яхшысы эткәй ягыннан киләдер дип уйлыйм...

Таймураз. Тагын ни сүзең бар?

Гөләндәм. Мин чын Гөләндәмне дә уйлыйм...

Таймураз. Син аны уйлама, оныт. Без уйлаганы да җиткән.

Гөләндәм. Мин аның гадел урынын алдым. Чын Гөләндәм бу очракта нишләр иде икән дип баш ватам. Аның хатирәсен дә сакларга бурычлы ич мин!

Таймураз. Ул юк инде хәзер. Син безнең чын кызыбыз. Мин синең чын этиең. Әлфинурның чын ире!

Гөләндәм. Салават күпере матур да, аннан йөреп булмый. Безгә ярасын да ди... Без, сезнең белән, намуссыз кешеләр. Әнкәйне алдау читен.

Таймураз. Ул сине ярата!

Гөләндәм. Мин артык кинәт ризалашканмын. Хәер, уйлап торырга вакыты тар булды шул! Бутыйлар иде мине тегеләр! Хәзер тора-тора шаккатам: моннан да аяусызрак җинаятьнең булуы мөмкинме соң?.. Әллә карак исемен тагын бер кат күтәреп, төрмәгә китеп барасы гына калганмы?

Таймураз. Бар, алайса, кер дә әниеңә бөтенесен сөйләп бир. Аның хәле җиңеләерме? Буласы булган, буявы сеңгән.

Гөләндәм. Анысын да беләм... Тик буявы кара буяу...

Таймураз. Сине бер егет сорап кергән иде.

Гөләндәм. Шуннан качып торып өстәл җыештырырга соңга калдым да. Кунакларның киткәнен күргән идем мин.

Таймураз. Нәрсә кирәк аңа? Кем ул?

Гөләндәм. Карак ул. Бур.

Таймураз. Нигә аны тотып бирмисең? Өебездә генә дружинник.

Гөләндәм. Миннән башка тотсыннар иде аны...

Хәниф керә.

Таймураз. Менә атаклы дружинник үзе кайтты. Без караклар турында сөйләшә идек.

Хәниф. Хәерле кичләр. Каян сезнең телгә керде әле ул?

Таймураз. Дружинник, барыннан да бигрәк, психолог булырга тиеш. Үзең бел. Нигә шулай сөйләштек без?

Гөләндәм. Кирәкми, Хәниф абый. Баш ватмагыз.

Таймураз. Әнә Гөләндәм кино карап кайткан.

Хәниф. Бусы мине сынавыгыз. Андый картина бармый бүген. Менә мин телефон будкасы янында бер егетне очраттым. Киткәндә дә шунда иде, хәзер дә шунда каравылда тора. Мине күрүгә ялт кына кача.

Таймураз. Менә бусы егет сүзе! Сеңлеңне саклап өйдәрәк утырсаң, безнең күңелләр дә тыныч булыр.

Гөләндәм. Кирәкми, Хәниф абый. Берүк саклый күрмәгез. Күзәтеп йөрсәгез, мине... бөтенләй... кирәкми, яме?

Хәниф. Безнең Гөләндәм үзен үзе саклый алырлык... Бүген эшләгәнен карап тордым. Молодец!

Гөләндәм. Иртәгә безне башка объектка күчерәләр икән...

Хәниф. Культура сараена дигән акча бетте... Сәбәбе шул.

Таймураз. Бирерләр!

Хәниф. Нигәдер ашыкмыйлар, Таймураз абый!

Таймураз. Йокы алдыннан кәефемне бозма, Хәниф.

Хәниф. Әллә ничеккә китте әле эшләр, Гөләндәм... Трестның акчасы әллә кайларга чәчелгән!

Таймураз. Хәниф, җиттеме сиңа!

Хәниф. Җыелышта сөйләтмисез. Өйдә авыз ачтырмыйсыз. Сездән күчеп китәрмен, ахры, мин, Таймураз абый.

Гөләндәм. Нигә, Хәниф абый, нигә?

Хәниф. Мин бит син кайтканчы дип кенә кергән кеше, Гөләндәм. Хәзер кирәгем калмады да шикелле.

Таймураз. Ни дип әйтергә инде сиңа?

Хәниф. Таймураз абыйның өметен дә акламадым бугай?.. Егетләр жәл. Әнә Закир белән Роза өйләнешәбез дип квартира көтеп йөриләр. Ә йортларны тәмамларга дигән акча беткән...

Гөләндәм. Китмәгез, Хәниф абый.

Хәниф. Мин бит монда Әлфинур апаны юмаларга дип кенә чакырылган кунак! Шулаймы, Таймураз абый?

Гөләндәм (*таң калып*). Сез дәме? (*Телен тешләп туктала.*)

Хәниф. Мин мәсьәләне балаларча, беркатлырак аңлап,

аны юатып йөргән булдым... Ул арада Таймураз абый кулга иядәндереп тә өлгергән. Хәзер ни әйтсәм дә, өйдәш сүзе булып кына ишетелә.

Таймураз. Үзеңә сузылган кулга сугасың инде?

Хәниф. Сукмыйм, Таймураз абый. Ләкин сузылган кулдан хәер дә көтеп тормам.

Таймураз. Яхшылыкка явызлык белән җавап бирерсең дип көтмәгән идем. (*Кереп китә.*)

Гөләндәм. Нәрсәгә алай диде ул?

Хәниф. Булмады, Гөләндәм! Уен-көлке белән генә китеп барырмын дигән идем, булмады. Каян сүзне башладым!

Гөләндәм. Сүзне сез кирәгендә башладыгыз...

Хәниф. Ичмасам, син мине дөрес аңла, яланаяклы кыз!

Гөләндәм. Әйтмәгезче шул сүзегезне!

Хәниф. Әллә мине җибәрәсең килми инде?

Гөләндәм. Сез китсәгез... мин дә монда калмыйм?

Хәниф. Нигә, Гөләндәм? Нигә, кадерле сеңлем минем?.. Тукта! Эш артыннан куып мин берәр нәрсәне белми калдыммы әллә?

Гөләндәм. Бәлки...

Хәниф. Бүген иртән дә сорамакчы идем. Харисов һаман синең тирәдә уралamy?

Гөләндәм. Күргәнсез ич.

Хәниф. Нигә кача ул миннән?

Гөләндәм. Белмим. Мин берни аңламыйм. Урамда очрата да тиле кеше күк тик карап тора. Бара башласам, иярә. Туктасам, дәшми. Күзләре белән генә ашый, капшый, әллә ниләр эшли.

Хәниф. Әгәр ул сине борчый икән, мин аның белән сөйләшә белермен.

Гөләндәм. Борчуларым Шәмәрдән генә булса икән, эх!

Хәниф. Син миннән нидер яшерәсең. Сөйләшик. Син миңа туган сеңлем кебек. Иң якыным син.

Гөләндәм. Алайса, нигә моннан күчәсез?

Хәниф. Таймураз абыйның канаты астында мин һаман чебеш булып калачакмын. Миңа чебеш булырга ярамый. Мин аның күп хаталарын күрәм. Аңа ашыгыч ярдәм кирәк. Хәзер барыбыз да моны аңлыйбыз. Иртәгә, бәлки, соң булыр.

Гөләндәм. Сез миңа бик якын, Хәниф абый. Үзегез дә якын, сүзегез дә ягымлы.

Хәниф. Гади телгә күчергәндә ничегрәк аңларга инде бу сүзне?

Гөләндәм. Сезне мин... тегендә очрашканда ук, хәтерегездәме, урманда... беренче тапкыр күргәндә үк

ярата идем... Сездәй егет минем хыялымда йөргәндер, мөгаен... Очрадыгыз, барын тамырдан, тирәннән үзгәрттегез. Янымда сез булмасагыз, бу йортта кала да алмас идем мин!

Х ә н и ф. Әнкәң сине бик ярата...

Г ө л ә н д ә м. Мин дә аны бик яратам! Ләкин, күпме еллар узган. Уйлап карасаң, без бит хәзер ят кешеләр кебек...

Х ә н и ф. Син юкта да гел искә төшереп кенә тора ул.

Г ө л ә н д ә м. Җитәр, зинһар, кыйнамагыз мине!

Х ә н и ф. Ни борчый синең күңелеңне, Гөләндәм?

Г ө л ә н д ә м. Туктагыз.

Ә л ф и н у р бүлмәдән чыга да яшьләргә карап тора.

Ә л ф и н у р. Кызым!

Х ә н и ф. Гөләндәм, әнкәң дәшә.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй... Мин тыңлыйм, әнкәй.

Ә л ф и н у р. Балам, карап кына керче: почта килмәгәнме?

Г ө л ә н д ә м. Бая юк иде. Хәзер карап керәм. (*Чыга.*)

Ә л ф и н у р. Күңелсезләнгәнсең дип әйтимме?

Х ә н и ф. Аптыраштарак калдым.

Ә л ф и н у р. Гөләндәмме?

Х ә н и ф. Ул.

Ә л ф и н у р. Хәниф... син аның белән саграк бул. Артыгын төпченә торган гадәтең бар... Вакланма, үткәннәрен сораштырма. Әлегә кирәкми. Читенсенә ул!

Х ә н и ф. Безнең сөйләшкән ишетелеп тордымы?

Ә л ф и н у р. Ишетмәсәм дә, беләм.

Х ә н и ф. Нидән курка ул? Кемнән?

Ә л ф и н у р. Чәй эчәсеңме?

Х ә н и ф. Иптәшләр белән ашханәдә ашап чыккан идек. Рәхмәт.

Ә л ф и н у р. Өйдән читләшә башладың...

Г ө л ә н д ә м керә.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй, менә газеталар, журнал.

Т а й м у р а з керә.

Ә л ф и н у р. Бүген дә хат юк...

Т а й м у р а з. Кемнән шулай өзелеп хат көтәсең?

Ә л ф и н у р. Гомер буе көтеп гадәтләнгәнгә, ахры, кичке почта берәр яңа хәбәр китерер төсле.

Т а й м у р а з. Яшьләр нигә өйдә утыралар? Киче бик матур күренә. Әле хәзер генә уйлап яттым. Бассейн төзелеп бетүгә, көн саен шунда йөри башлыйм.

Ә л ф и н у р. Йөзә белмисең бит, Таймураз. Батып үләрсең.

Т а й м у р а з. Өйрәнермен!

Х ә н и ф. Әйбәт теләк!

Т а й м у р а з. Велосипед алып кайтмый да булмас әле. Үлчәнгән идем, авырлыгым арта төшкән. Әллә берәр спорт секциясенә язылыргамы?

Ә л ф и н у р. Тагын нинди яңалыклар бар?

Т а й м у р а з. Газетадамы? Менә, фельетон. Тәэминатчылар дәүләтне кимерә, журналистлар аларны!

Х ә н и ф. Сез газетаны фельетоннан карый башлыйсыз икән.

Т а й м у р а з. Ә аның ни гаҗәбе бар?

Х ә н и ф. Күңеле тыныч булмаган кешеләр газетаны фельетоннан укый башлый ди торган иде минем әти.

Ә л ф и н у р. Мин аталар һәм аналар турында укырга яратам. Ә син, кызым?

Г ө л ә н д ә м. Мин ана белән бала турында... (*Ишектә звонок.*) Үзем ачам.

Х ә н и ф. Юк, үзем.

Чыга да З а к и р белән Р о з а н ы ияртеп керә.

Р о з а. Бүген өйдә утыру гөнаһ. Хәерле кич, Әлфинур апа.

Ә л ф и н у р. Узыгыз, уз. Өе барлар өйдә утыра, нишлисең? Сезгә квартира кайчан диләр?

З а к и р. Кызыл кар яугач диебрәк торалар.

Т а й м у р а з. Һм-м... (*Яратмыйча бүлмәгә кереп китә.*)

Ә л ф и н у р. Чәй куеп җибәр, кызым. Үзең пешергән тәмле сумсалар белән яшьләрне сыйла. Бу юлы кунаклар синеке! Алар синең янга килгән. Мин журналлар караштырыйм. (*Чыга.*)

Г ө л ә н д ә м. Чыннан да, сез минем кунакларым бит!

Р о з а. Закир, кыбырсыма. Сумса белән чәй эчеңне тишәрме әллә?

З а к и р. Хәниф абый, кил әле.

Г ө л ә н д ә м. Сез чак кына утырып торыгыз! Хәзер чәй куеп җибәрәбез... Сумса бар... Яңа бал бар... Бергәләп сыйланабыз! Хәниф абый да ачыгып кайткандыр. (*Чыга.*)

Х ә н и ф. Йә, Закир. Баядан бирле кыткылдап торуыңны сизәм.

З а к и р. Көндез безнең баракка милиционер килеп китте. Югалган нәрсәләрнең исе чыкмый, ди.

Х ә н и ф. Чыгар. Табылыр.

З а к и р. Кырык ел үткәчме?.. Мин теге шома егеттән шикләнәм. Әле хәзер дә, карыйбыз, сезнең йорт тирәсендә урала.

Х ә н и ф. Шулаймы?.. Мине хәзер икенче мәсьәлә борчый. Гөләндәмгә йогынтысы зур ул шоманың!

Р о з а. Тыкрыкка борылган идек, Айгөл дигәне монда таба килә.

З а к и р. Нурсыз кешеләр алар. Ямьсезләр.

Х ә н и ф. Әйдәгез әле!

Р о з а. Гөләндәм хәзер чәй кертә.

Х ә н и ф. Чәйгә кайтабыз! Күреп, якасыннан алып сөйләшик әле бер... Ни хакы бар аның?.. Кем ул?! Шуны белмичә торып, Гөләндәм белән сөйләшә алмыйм!

Чыгалар. Кухнядан чәй дирбияләре тотып Г ө л ә н д ә м керә.

Г ө л ә н д ә м. Роза!.. Хәниф абый... Закир... Киткәннәр. Чыгып та киткәннәр... Бер сүз әйтмичә... Минем кунакларым... качканнар...

Нәрсәләрне өстәлгә урнаштыра. Ә л ф и н у р керә, кулында журнал.

Ә л ф и н у р. Хәниф, таныш, Оскар Нимайерның зур мәкаләсен басканнар.

Г ө л ә н д ә м. Кем ул Оскар Нимайер?

Ә л ф и н у р. Бразилия архитекторы. Ленин премиясе лауреаты.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй... Сез врач... Төзелеш газеталарын да укыйсыз...

Ә л ф и н у р. Хәнифләр кайда?

Г ө л ә н д ә м. Берәве дә юк. Мине кухняда калдырып чыгып качканнар... Бер сүз әйтмәделәр... Саубуллашмадылар...

Ә л ф и н у р. Синең урында мин дә үпкәләр идем. Ләкин түзем бул. Ашыгыч эшләре булгандыр. Аңлашырсыз.

Г ө л ә н д ә м. Роза да киткән.

Ә л ф и н у р. Утыр яныма, кызым. Икәүләп сөйләшеп алыйк.

П а у з а.

Г ө л ә н д ә м. Син гел эштә, әнкәй... Кичләрен дә бушамыйсың.

Ә л ф и н у р. Синең кулларың да сөялләнгән...

Г ө л ә н д ә м. Азрак булыр инде.

Ә л ф и н у р. Бетон эше сиңа авыррак. Тегү мастерскоена гына керәсең калмаганмы? Мин белештем, аларга кешеләр кирәк.

Г ө л ә н д ә м. Юк, әнкәй. Анда кермим. Тегү-чигү тәмам.

Ә л ф и н у р. Бәлки, минем янга керерсең? Башта санитар кыз булырсың... Аннан укырсың...

Г ө л ә н д ә м. Әлеге юк, әнкәй. Аяк астымда каты җир барын тоймыйча, беркая да күчмим.

Ә л ф и н у р. Бусы белән куандырдың, кызым. Бер чакта да җиңелне эзләмә... Ләкин соңга да калма! Гомер кыска.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй... Охшамаган якларым булса, әйт. Шыксыз гадәтләрем дә күптер инде минем. Өй җылысы күреп үсмәгәч...

Ә л ф и н у р (*аны сөеп*). Укырга кирәк сиңа, кызым. Уку кешегә диплом гына түгел, яшәү рәхәте дә, акыл да, ышаныч та бирә. Уку кешене буйсынмаска, горур булырга да өйрәтә. Менә син минем төзелеш газеталары укуыма игътибар иттең. Укыйм! Күнегелгән. Әткәң белән бер тигезлектә торып сөйләшер өчен укыйм... Сүз җаеннан чыккач әйтим, әткәң белән ягымлырак бул, кызым.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй!.. Син аны яратасыңмы?

Ә л ф и н у р. Кызым, кызыкаем... Кыен сорау бирәсең... Безнең мәхәббәт күп сынаулар аша узды... Ул бит... ул бит... бик кәттә егет иде! Остазы профессор Осташевский аннан бик күп нәрсәләр көтә иде... Тик нигәдер укып бетереп диплом алгач ул кинәт үзгәрде, вагайды. Юк кына бер урынга керде дә тып-тынычта шыпырт кына утыра бирде. Хәзер гаярьләнеп карый, барып чыкмый... Безнең мәхәббәтнең бөгелгән, шартлап сынган чаклары да булды. Әмма безне бәйләүче җеп булып икебез арасында һәрвакыт син тордың, кызым. Синең табыласыңа шикләнмәдем мин, табылгач, әтисез итәсем дә килмәде. Аннары, миннән башка әтиең бөтенләй буталып калыр иде. (*Пауза.*)

Г ө л ә н д ә м. Кайчагында бала кебек ул...

Ә л ф и н у р. Ялгыз калудан бик курка. Хәнифне үз яныбызга алдыртты...

Г ө л ә н д ә м. Хәниф абый бездән күчеп китәргә йөри.

Ә л ф и н у р. Китмәс. Мин үтенермен.

Г ө л ә н д ә м. Юк, әнкәй, ул китәм дип үзеп әйтте.

Ә л ф и н у р. Таймураз, Таймураз! (*Таймураз керә.*) Хәниф берәр сүз әйтмәгәндер бит сиңа?

Т а й м у р а з. Бүгенме? Хәниф әйткәннәрнең барын җыя башласаң...

Ә л ф и н у р. Китәм дип әйтмәгәндер бит?

Т а й м у р а з. Китсә, каршы килеп тә булмас.

Ә л ф и н у р. Сәбәбен аңлаттымы соң?

Т а й м у р а з. Иптәшләр чакыра, диде. Бергә-бергә күңелле булыр, диде.

Ә л ф и н у р. Минем белән сөйләшмичә нигә ашыгырга иде аңа?

Г ө л ә н д ә м. Чакырып кайтыйммы, әнкәй?

Ә л ф и н у р (*уйланып*). Юк, үзем, кызым, һавага чыгып керәсе дә килә иде. (*Чыга.*)

Т а й м у р а з. Тиешле-тиешсез хәбәрләрне әнкәңә әйтмә дип кисәтмәдемме?

Г ө л ә н д ә м. Аның ачуын мин чыгармадым.

Т а й м у р а з. Кая инде, мин сәбәпче монда, мин!

Г ө л ә н д ә м. Ул барын да белә!

Т а й м у р а з. Әлбәттә, белә. Минем аннан бер яшертен эшем булганы да юк. Әнкәң алдында намусым саф.

Г ө л ә н д ә м. Ә мин?

Т а й м у р а з. Нәрсә, син? Ничә тапкыр кабатларга тагын: син безнең үз кызыбыз!

Г ө л ә н д ә м. Шулай булса кана! Ә әнкәй... беренче тапкыр шушы бусаганы атлап керүгә барын сизенде. Сез дә шул, мине күрүгә, төче елмаеп, чалыш-чолыш атлап: «Кызым, кызым!» дип үбәргә килә башладыгыз... Шул чагында әнкәй миңа түгел, сезгә ныграк карап торды. Онытмагыз, мин генә түгел, сез дә ныклы сынау астында.

Т а й м у р а з. Сабый булма. Җүләрләнмә. Сынау чоры күптән узды.

Г ө л ә н д ә м. Ничек ризалаштым мин? Ул бит изге җан!.. Таймураз абый, озатыгыз мине моннан. Тотмагыз, үгетләмәгез.

Т а й м у р а з. Тукта, тукта.

Г ө л ә н д ә м. Үтенәм...

Т а й м у р а з. Менә бассейнга бергәләп йөрербез. Велосипед белән шәһәр тирәли сәяхәткә чыгарбыз... Гөмбә җыярга барырбыз. Гөмбә яратам, җыярга барганым юк...

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй генә түгел, Хәниф абый да, Закир белән Розага тиклем, барысы да минем кемлекне белә.

Т а й м у р а з. Ничек?

Г ө л ә н д ә м. Нигә минем чәемнән йөз чөереп чыгып качтылар алар?.. Минем беренче кунакларым... Мин начар кеше... Мине берәү дә яратмый.

Ш ә м ә р д ә н керә.

Ш ә м ә р д ә н. Дөрес әйтмисең, Гөләндәм.

Г ө л ә н д ә м. Рөхсәтсез кердеңме?

Ш ә м ә р д ә н. Уйланып килә идем, күңел нечкәреп китте. Карыйм: ишек ачык. Тәрәзәләр ачык. Хуҗалар яхшы кешеләр икән, дим. Һәм алар өйдә булырга тиешләр димен. Ялгышмаганмын.

Т а й м у р а з. Килгәнсең икән, утыр.

Гөләндәм. Аңа дигән урын монда түгел...
Шәмәрдән. Ха-ха-ха!
Таймураз. Чәй ясап кертче, кызым. Тамагым янып тора.
Гөләндәм. Чәй? Аңамы? Өлешемә шушы кунак калдымы?
Таймураз. Авырыксынсаң, үзем... (*Чыга.*)
Гөләндәм. Авызыңны бик ерма, карга очып керер.
Шәмәрдән. Айгөл белән араны кырт өздем. Мәңгегә. Иптәшләрдән аерылдым. Бөтенләйгә. Капчык авызын бәйләдем. Бәйләдем дә ыргыттым. Җәһәннәмгә! Алатырбалатыр, тау ягында таң атыр. Җиңел дип беләсеңме, һә! Баш очымда булат кылыч хәзер. Һәр урам сират күпере. Синең янга килми әмәлем юк. Тәкатемне калдырмадың.
Гөләндәм. Эзәрлекләмә мине, Шәмәрдән.
Шәмәрдән. Аңлашыла. Хәер, бик үк аңлашып бетми.
Гөләндәм. Күләгәңнән үк куркам! Карак бит син, бур.
Шәмәрдән. Менә төтенең килеп җитте. Шәп. Үтә шәп. Тик гадел түгел. Кешедән сафлык, турылык сорыйм диген. Шәп! Якасыннан аласың да, әйдә, чыгарып сал уртага сафлыкны дип бакырасың. Кем син үзең, йон тәпи?! Мин бу судка отвод бирәм! Судьясы начар... үз бармагы балга буялган!
Гөләндәм. Сиңа шул сүзләрне әйткәндә, үз бәгырем өзгәләнми дип беләсеңме?
Шәмәрдән. Кызый, минем белән килешмичә беркая барыр җирең юк. Алда-артта читән, бер чеметәм дә китәм...
Гөләндәм. Булмас!
Шәмәрдән. Кем идең дә кем булдың? (*Тәрәзә янына кукраеп баса.*) Килгән юлларыңа борылып кара, яланаяклы кыз. Әнә-ә, юлың! Бу йортка нинди хәйлә белән килеп керүеңне бик шәп беләбез. Ата-ананың җылы канатын сагындыңмы? Шәп! Иркәлектә кәнфит суырасы килдеме?
Гөләндәм. Сиңа миннән ни кирәк? Акчамы?
Шәмәрдән. Акча бездә бер букча.
Гөләндәм. Ни?
Шәмәрдән. Үзең кирәк.
Гөләндәм. Нәрсәгә хаҗәт мин сиңа?
Шәмәрдән. Тукта! Тормозларың эшләми. Тауга менмә. Уйнарга гына ниятләсәм, муенымны үткен пычак астына куяммы мин? Уйла! Мин дә кеше, Гөләндәм. Әти карт та исән минем, әни карчык та. Мамадышта торалар. Буйдаклата трай тибүдән туйдым. Үз оямны ко-

рырга вакыт. Өйләнергә телим! Миңа баш инженер кызы кирәк. Аз да түгел, күп тә түгел, безнең өчен чүп тә түгел!

Гөләндәм. Мин инженер кызы түгел.

Шәмәрдән. Кызы, кызы!.. Моңарчы андыйлар минем ишелергә бик карамыйлар иде. Син, Гөләндәм, кыланма. Син баш инженер кызы. Кармакта утырасың син, шыртлака балыгы кук. Синең бер генә юлың калды: тотасың да миңа кияүгә чыгасың. Мин дә шушы йортка күчеп киләм. Бабайны дөбердәтеп чыгарабыз да иң шәп бүлмәсенә хуҗа булабыз. Шәп булачак, фартовый булачак! Муен да, баш та җәл түгел. Мифтахетдин картның игелексез малае шәһәр хуҗаларының берсенең кияве!

Гөләндәм. Мин кыз бала, Шәмәрдән. Шуның белән горурланам, һәм синеке булмам да.

Шәмәрдән. Башка юл юк сиңа.

Гөләндәм. Мин аларның кызы түгел. Син яхшы беләсең.

Шәмәрдән. Кызы, кызы!

Гөләндәм. Хәзер әнкәй кайтып керә. Мин аңа бөтенесен ачам. (*Ишек янына бара. Таймураз керә.*)

Таймураз. Гөләндәм!

Гөләндәм. Мин әнкәйне каршыларга чыгам.

Таймураз. Аны үтерәсең киләме? (*Шәмәрдәнгә.*) Ә син яшь бунтарь, юк белән минем кызымны өркетмә.

Шәмәрдән. Өркетмим. Без иске дуслар. Үзебезчә сөйләшәбез.

Таймураз. Гөләндәм, безнең бүлмәгә кереп тор, кызым.

Гөләндәм. Ничек яшәргә соң? Ничек гомер итәргә?

Таймураз. Шыпырт кына. Тыныч кына. (*Гөләндәмне бүлмәгә кертеп җибәрә.*) Ә сине нишләтим? Милициягә тапшырыйммы, әллә үзем генә изеп ташлыйммы? Кил якынрак! Үзең яши белмәгән башың белән кеше тормышына тыгыласыңмы?

Шәмәрдән. Нигә, ярамыймы әллә?

Таймураз. Кил мондарак. Курыкма, ашамам.

Шәмәрдән. Ашатам дип тә тормыйм.

Таймураз. Син аны күптән беләсеңме?

Шәмәрдән. Миннән сер ала алмассың.

Таймураз. Анысы яхшы. Синнән ярдәм кирәк миңа.

Шәмәрдән. Миннән?

Таймураз. Синең кулда көч бар.

Шәмәрдән. Синең кулда власть.

Таймураз. Шүрләмә! Мин дә авызымда сүз тота беләм.

Шәмәрдән. Аңлатыбрак сөйлә, начальник.

Таймураз. Син мондагы каракларның башлыгымы?

Ш ә м ә р д ә н. Әкият сөйлисең, начальник.

Т а й м у р а з. Сизенәм: Гөләндәм сиңа буйсына. Тыңлат син аны! Җәза белән куркыт.

Ш ә м ә р д ә н. Үзең куркыт.

Т а й м у р а з. Ул монда калырга тиеш. Ә мин, үз чиратымда, яхшылыкны берчакта да онытмам. Андый кеше түгелмен.

Ш ә м ә р д ә н. Фартовый начальник! Шәп!

Т а й м у р а з. Йә, мин синнән сүз көтәм.

Ш ә м ә р д ә н. Кем сатыла соң монда? Ни бәягә? Гөләндәмме? Минме? Әллә синме, зур начальник? Мин бит фраер түгел!

Т а й м у р а з. Кая барасың?

Ш ә м ә р д ә н. Да ну вас! Кит юлдан!

Т а й м у р а з. Бөтереп таш капчыкка тыкканны көтәсеңме? (*Шәмәрдән чыгып китә. Таймураз бүлмә ишеген ачып Гөләндәмне чакыра.*) Чык. Кунагың китте. (*Гөләндәм керә.*) Беләм, сиңа җиңел түгел. Миңа ансат дип беләсеңме? Яшәү беребезгә дә җиңел бирелми. Мин үз теләкләремә ирешү алдында торганда гына...

Г ө л ә н д ә м. Уйлаган саен куркынычрак... Әгәр әнкәй начар кеше булса икән... Изге җан бит! Гөнаһсыз фәрештә!

Т а й м у р а з. Бу маңканың янавына игътибар итмә. Мин анымы... Кая керер тишеген тапмас.

Чыгып китә. Гөләндәм ялгызы. Пауза. А й г ө л керә.

А й г ө л. Сиңа ни җитми тагын?

Г ө л ә н д ә м. Айгөл?

А й г ө л. Аһ, ирек, дидең. Чыктык... Яңа җирләр дидең... Кайттык. Ата-ана дидең. Булмастай күк күренгәне дә булды. Эш дидең. Теләгеңә ирештең. Сөйгән ярына тикле таптың. Тагын ни кирәк сиңа?

Г ө л ә н д ә м. Син санаганнарның барын биреп, бер генә нәрсә алыр идем!

А й г ө л. Ни ул?

Г ө л ә н д ә м. Намуслы, керсез исемемне.

А й г ө л. Ай-һай!

Г ө л ә н д ә м. Бары тик шуны гына алыр идем! Бер генә нәрсә!

А й г ө л. Шушы хәчтерүш кенә кызда күпме хәйлә, мәкер булыр дип кем уйлаган? Ничә ел мулла мәчесе янында яшәлгән, белмәгәнмен кемлеген. Намуслы исем кирәк аңа. Шәмәрдәнне нигә алдың, алайса?!

Г ө л ә н д ә м. Син миңа күптән ышанмыйсың.

А й г ө л. Бир Шәмәрдәнемне. Аннан карармын.

Г ө л ә н д ә м. Ал.

Айгөл. Канга-кан, парма-пар сугышабыз. Ташлыйсыңмы ирекле баштан Шәмәрдәнне?

Гөләндәм. Нәрсәгә кирәк ул миңа? Җиңеллек, бәхет, рәхәтлек китерә торган бәндәме? Поткайлары бер тиен. Ал гына шул сагызыңны. Ал да башыңа сыла!

Айгөл (*еламсырап*). Тәре баганасы күк баса да, синең тәрәзәгә карап ката. Хәзер синең яннан чыкмады диярсеңме? Аяк башыма басып узды, мине күрмәде. Күзе тонган. Сукырайган. Сихерләнгән! Кире кайтар Шәмәрдәнне, юкса!..

Гөләндәм. Бутама минем буталган башкайларымны! Үз җаеңны үзең кара! (*Йөгереп чыгып китә.*)

Айгөл. Ансат! Яр бирмәк, җан бирмәк, диләр.

Гөләндәмнең чемоданын тартып чыгара, тиз-тиз актарына. Әлфинур керeп карап тора.

Әлфинур. Мин дә эзләшимме?

Айгөл. Ай!

Әлфинур. Искәрмәстән эндәшеп куркыттыммы әллә?

Айгөл. Гөләндәмнең иптәш кызы мин... Без бергә килдек... Бергә, чын... Алкам белән тасмам аның чемоданында иде. Ал тасмам белән алкаларым.

Әлфинур. Яхшы, яхшы. Эзлә. Гөләндәм үзе кайда соң?

Айгөл. Тегендә, теге бүлмәдә.

Әлфинур. Нигә чакырмадың үзен? Тизрәк табып бирер иде. Болай әйберләрен тараткансың.

Айгөл. Юк! Чакырмагыз. Кирәкми!

Әлфинур. Ихтыярың. Чакырмыйм.

Айгөл. Без талаштык.

Әлфинур. Шулай да сорыймчы: нигә ул анда, син монда?

Айгөл (*тураеп*). Ну... Ул анда!.. Ну, мин монда ди!

Әлфинур. Гаҗәпләнәм. Шуңа сорадым.

Айгөл. Барыгыз, милиция чакыртыгыз. Телефоныгыз бар. Карак тоттым дип кычкырыгыз. Разбуй салыгыз.

Әлфинур. Иң элек, кычкырудан син тукта.

Айгөл. Туктасам да, туктамасам да барыбер түгелмени? Бетәсе баш беткән.

Әлфинур. Кил, яныма утыр. Менә шулай. Чибәр генә кыз үзең, нигә шулай нык буянасың?

Айгөл. Мин карак түгел. Мин әйбер урларга кермәдем.

Әлфинур. Мин сиңа бер сүз дә әйтмәдем шикелле. Тынычлан.

Айгөл. Мин эзләдем генә... Гөләндәмнең әнисенең адресын эзләдем.

Әлфинур. Әйберләрен тараткансың...

Айгөл. Адресны гына, бары шуны гына...

Әлфинур. Гөләндәмнең әнисе — мин.

Айгөл. Юк, мин чын әнисенең адресын дим.

Әлфинур. Мин аның чын әнисе. Үз әнисе. Ул минем үз кызым.

Айгөл. Аның башка әнисе бар!

Әлфинур. Шуннан?

Айгөл. Адресын табам да, үз әнисен чакыртып китерәм. Кызының ниләр кыйратып ятуын күрсен монда!

Әлфинур. Каян уйлап чыгардың син мондый кеше ышанмас йогышсыз сүзләрне?

Айгөл. Мин ул кызны бала чагыннан беләм.

Әлфинур. Мин дә аны бала чагыннан беләм. Менә шушындый нәни чагыннан бирле.

Айгөл. Ул сезгә яшерен ният, астыртын уй белән килеп керде.

Әлфинур. Ә син үз ниятеңне бик әйбәтләрдән дип санныйсыңмы?

Айгөл. Адрес менә монда, чемоданда.

Әлфинур. Гөләндәм безнең кызыбыз, ишетәсеңме? Безнең кызыбыз!

Айгөл. Түгел!

Әлфинур. Моннан болай бу ялганны, әшәке ялганны беркайда да, берәүгә дә сөйләмәм дип сүз бир.

Айгөл. Ничек алай булсын?

Әлфинур. Шулай. Үз кызын анадан да шәбрәк кем белә?

Айгөл. Алайса, чемодандагы адрес ялганмы? Аның моңарчы сөйләгәннәре бар да уйдырмамы?

Әлфинур. Бәлки. Ничек булса да, моңарчы Гөләндәм сиңа серен ачмаган.

Айгөл. Аннан булыр! Хәйләкәр ул, комсыз. Әрсез.

Әлфинур. Минем кызым тырыш, эшчән бала. Ә менә син нинди кыз, әйтүе читен. Чемоданны актардың да әйбәтләп тутырып та куймадың...

Айгөл. Ул минем иске дустымны, Шәмәрдәнне тартып алды.

Әлфинур. Шуңа ярсыдыңмы?

Айгөл. Ярсырсың да...

Әлфинур. Шулайдыр дип уйлаган идем аны.

Айгөл. Шәмәрдән миңа әйләнеп тә карамый хәзер.

Әлфинур. Карарлык нәрсә тапмыйдыр. Бел, алайса: Гөләндәм Шәмәрдәннән ничек котылырга белми йөри. Ул башка берәүне ярата.

А й г ө л. Ярата?

Ә л ф и н у р. Шулайдыр дип беләм.

А й г ө л. Сез милициягә хәбәр итмисезме?

Ә л ф и н у р. Киресенчә, син минем кызымның иптәше. Димәк, миңа да бик якын, кадерле кеше. Ялгышмасам, син әлегә беркайда да эшләмисең шикелле?

А й г ө л. Шәмәрдән эшкә кермә дигән иде...

Ә л ф и н у р. Минем янга эшкә киләсеңме? Больницага.

А й г ө л. Мин бит укымаган.

Ә л ф и н у р. Эшләрсең, күнегерсең, укырсың. Шуннан Шәмәрдәнне карап карарбыз. Ризамы?

А й г ө л. Башым әйләнеп китте. Сез мине әллә нишләттегез.

Т а й м у р а з керә.

Т а й м у р а з. Хәниф кайтты. Күрдеңме?

Ә л ф и н у р. Юк әле.

Т а й м у р а з. Өлкәдән авторитетлы комиссия килгән. Архитекторлар, проектчылар. Арада бер профессор да бар.

Ә л ф и н у р. Сиңа ярдәмгәме, Таймураз?

Т а й м у р а з. Ярдәмгә килгән комиссия халык контроленнән вәкил ияртеп килми, Әлфинур ханым!

Ә л ф и н у р. Сиңа кыенлык киләме?

Т а й м у р а з. Әлбәттә!

Ә л ф и н у р. Ә башкаларга? Яңа төзелә торган шәһәргә?

Т а й м у р а з. Шатланасыңмы?

Ә л ф и н у р. Юк, Таймураз, сине уйлап борчылам.

Т а й м у р а з. Комиссия председателенең кем икәнен беләсеңме? Профессор Осташевский! Остазым! Бу кем тагын?

А й г ө л. Без танышлар инде, абый.

Т а й м у р а з. Шул гына җитмәгән иде!

А й г ө л. Тегендә, урманда... Бәйрәмдә...

Т а й м у р а з. Мин сезне беренче тапкыр күрәм! Беренче һәм соңгы тапкыр!

Ә л ф и н у р. Айгөл бу. Гөләндәмнең иптәш кызы.

Г ө л ә н д ә м белән Х ә н и ф керәләр.

Х ә н и ф. Әлфинур апа, сөенче.

Ә л ф и н у р. Ишеттек, Хәниф. Таймуразның остазы килә. Остаз белән очрашырга мин дә каршы килмәс идем...

Х ә н и ф. Шәп шул!

Т а й м у р а з. Хәниф яңа дагаланган ат күк, тыпырдап кына тора.

Г ө л ә н д ә м. Хәниф абый, инде күчмисезме? Каласызмы?

Х ә н и ф. Аптырабрак торам, Гөләндәм... Бер уйласам китәсем килә, икенче уйлаганда...

Г ө л ә н д ә м. Әнкәйгә ямансу булыр дип куркам.

Ә л ф и н у р. Кызым, балам!

Х ә н и ф. Гөләндәм, синең сүзне аяк астына сала алмыйм: калам!

А й г ө л. Апа, сезнең бер генә кызыгыз югалган идеме?

Ә л ф и н у р. Әйе. Нигә?

А й г ө л. Нишләп мин дә сезнең кызыгыз түгел икән?!

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

**Таймуразлар яши торган йортның ишегалды. Утыргычлар. Яшь агачлар. Урам якта тәбәнәк кенә бетон коймалар. Агач артында Ш ә м ә р д ә н басып тора, кемнедер көтә. Өйдән Х ә н и ф чыга. Аны күргәч, Шәмәрдән качарга җыена, туктала.**

Х ә н и ф. Юкка качасың, барыбер күрдем.

Ш ә м ә р д ә н. Ай күрде, кояш алды. Юк мин монда!

Х ә н и ф. Егетләрчә генә сөйләш әле бер. Ничә чыксам да, син үз постыңда. Нигә?

Ш ә м ә р д ә н. Моны сездән башка бәяләүче генә юк.

Х ә н и ф. Сабыр төбе сары алтын, дигәннәр.

Ш ә м ә р д ә н. Төптәге сары алтынга төшеп җитәргә минем чыдамым җитмәс... Безгә өстәрәктәге көмеш тә ярар!

Х ә н и ф. Ул өйдә юк. Эштә.

Ш ә м ә р д ә н. Беләм.

Х ә н и ф. Белгәч, нигә һаман монда?

Ш ә м ә р д ә н. Мин сезне көтәм.

Х ә н и ф. Көткәч, нигә качасың?

Ш ә м ә р д ә н. Өйрәнелгән гадәт. Гадәтләрдән тиз генә арынып булмый.

Х ә н и ф. Минем бер дә вакыт юк бүген. Казаннан комиссия килгәнен ишеткәнсеңдер?

Ш ә м ә р д ә н. Миңа ярдәмгә дә берәр җирдән комиссия чакыртып булмыймы? Шәфкать комиссиясе?

Х ә н и ф. Син аңа мохтаҗмы? Минемчә, мохтаҗ түгел.

Ш ә м ә р д ә н. Харисовны тыңларга берәүнең дә вакыты юк. Ә Харисовның йомышы зур.

Х ә н и ф. Кичкә таба бер сугылырсың әле.

Ш ә м ә р д ә н. Аңа кадәр түзәр чамам калмады. Менә. (*Төргәк суза.*)

Х ә н и ф. Нәрсә соң бу? Әманәтме? Кемгә тапшырыйм? Аңамы?

Ш ә м ә р д ә н. Сүтеп кара. Танырсың.

Х ә н и ф. Сәгать? Акчалар? Каян алдың боларны?

Ш ә м ә р д ә н. Алучысы мөһим түгел. Ул үлде. Тапшыручысы мин. Анысын онытма.

Х ә н и ф. Нигә боларны миңа китердең?

Ш ә м ә р д ә н. Ул белә. Ул минем белән сөйләшми. Син аңа әйтерсең. Шәмәрдән китерде диярсең. Башкасын төпченмә, әйтмәм.

Х ә н и ф. Яратасыңмы?

Ш ә м ә р д ә н. Муенымны кылыч астына куйдым. Беркем ышанмас!

Х ә н и ф. Бу сүзләрең белән син минем муенны да кылыч астына куясың, егет!

Ш ә м ә р д ә н. Аңлыйм. Аны яратмый мөмкин түгел. Кем кемне хәзер. Ул хәл итсен. Аңа тапшырыйк!

Х ә н и ф. Кичкә кырын кагыл әле.

Ш ә м ә р д ә н. Харисов үз антына турылыклы. Кисте —каплады!

Х ә н и ф чыгып китә. А й г ө л керә.

А й г ө л. Һаман шушында. Һаман. Ничә борылсаң, шушы капканы саклый. Оҗмах капкасымы әллә ул?

Ш ә м ә р д ә н. Зур бер яңалык әйтимме?

А й г ө л. Әйт, әйт, Шәмәрдән!

Ш ә м ә р д ә н. Җир шары түгәрәк икән бит, әй!

А й г ө л. Магеллан!.. Сиңа шундый кушамат бирергә кирәк. Бөркет түгел син!

Ш ә м ә р д ә н. Берәр урында тотынир тоткаң булмаса, тәгәрәп төшәрлек дәрәҗәдә түгәрәк... Тырышып-тырышып шул тотканы эзлим. Кирәк чакта күңел биреп укылмаган, географияне дә, топографияне начар беләм икән...

А й г ө л. Табып булыр сыманмы?

Ш ә м ә р д ә н. Өзеп әйтмим. Мәгәр табылыр сыман.

А й г ө л. Әлфинур апа өйдәме?

Ш ә м ә р д ә н. Әләкләргә килдеңме? Шымчылык итәсеңме?

А й г ө л. Йомышым бар.

Ш ә м ә р д ә н. Кил монда. Мондарак, мондарак! Анда кеше күрә. Шаһитларны яратмыйм.

А й г ө л. Ай, җибәр!

Ш ә м ә р д ә н. Килеп йөрмә дидемме мин сиңа? Бусы ае гына, йолдызларын күрсәтергә дә күп алмам.

А й г ө л. Кулың келәшчәмени... Инженер кызы кирәк инде сиңа?

Ш ә м ә р д ә н. Кем кызы булуы кирәкми хәзер. Миңа Гөләндәм булса, шул җиткән.

А й г ө л. Ә мин?

Ш ә м ә р д ә н. Үч саклама миңа, Айгөл. Мин бит чын-чынлап карак та түгел. Моңа кадәр чын кеше дә булмаганмын. Анысы да факт! Мин — шофер. Машинамны яратам. Түт-түү! Тегендә, сез детдомда чакта, отрезларны үзем өчен урламадым. Акчасы миңа тәтемәде аның! Куркыттылар. Йомшак идем, җебегән идем. Сарык идем. Төядем дә чыктым... Монда да... Сез килгән көнне... Янәсе, егетлек күрсәтәм... Бурычлы булып каласым да килмәде. Рәхмәт, тегендә мине батырмадың, аядың... Ләкин бел: син теләгән егет мин түгел.

А й г ө л. Әлфинур апа янына эшкә керимме әллә дип йөрим. Чакырган иде.

Ш ә м ә р д ә н. Синеме? Үз янынамы?

А й г ө л. Эшкә кереп карарга исәп.

Ш ә м ә р д ә н. Синең кем икәнлегеңне белми ич ул? Белсәме, бусагасына якын китермәс!

А й г ө л. Тиле. Ул барын да синнән-миннән яхшы белә. Бөтенесен дә. Сине дә, мине дә, аны да! Телсез калдыңмы? Менә тутаң да шулай телсез, өнсез калды...

Ш ә м ә р д ә н. Берни дә белми ул. Син чактыңмы?

А й г ө л. Үземне үзем чагарга чаянмы мин? Синең карак икәнлегеңне әйтү файдагамы миңа? Гөләндәмнең үз кызы түгеллеген дә белә. Мин әйтмәдем.

Ш ә м ә р д ә н. Стоп! (*Якасыннан ала.*) Соңгы статьяны оныт! Ялгышып төшеңдә дә кабатлыйсы булма.

А й г ө л. Икмәктер, кояштыр, белә! Егет чырае күрмим, белә!

Ш ә м ә р д ә н. Каерма тәртәне зиректән, шартлап сынар.

А й г ө л. Бер генә мәртәбә булса да, ышан!

Ш ә м ә р д ә н. Әкият. Күптән куып чыгарыр иде.

А й г ө л. Чемодан актарганда мине килеп тотты. Милициягә шалтыратмады.

Ш ә м ә р д ә н. Бар, бар, сыз моннан!

А й г ө л. Синең кайгың түгел, эшкә урнашырга кирәк миңа. Тегү мастерскоена кердем. Анда да урын бар! Куркам! Түзмәм мин. Урлармын! (*Пауза.*) Белмисеңме, аларның бер генә кызлары югалдымы икән?

Ш ә м ә р д ә н. Бар, бар! Үзләреннән сораш!

А й г ө л. Гөләндәм түгел, мин бу йортта кадерле булыр идем. Син аны түгел, мине сөяр идең.

Ш ә м ә р д ә н. Алар кызы булу өчен дә күп нәрсәләр кирәк бит, тилекәй!

А й г ө л. Арттырып та җибәрер идем. Син бит мине белмисең. Мин кеше өчен үлеп китәм!

Ш ә м ә р д ә н. Әнә, кершәнең тир белән ага... Юк, минем сөйгән ярым була алмас идең син.

Айгөл. Гарьлек... Нигә теге чакта җырладың алайса? Берсе яшьлек заманасы, берсе сөйгән яр, имеш!..

Шәмәрдән. Кемнең яшьлеге нинди бит! Минем яшьлек — җүләрлек булган. Мин аның узуына куанам. Ярар, тай син моннан! Мин үземә дә, сиңа да ышанып бетмим.

Айгөл. Сиңа ышанып хараплар булды шул газиз башым!

Шәмәрдән. Әйдә, бер акыл булыр.

Чыгалар. Пауза. Гөләндәм белән Роза керә.

Гөләндәм. Кайтып та җиттек. Менә безнең өй. Күрче, Роза. Безнең өй. Мин шушы йортта яшим. Икенче катта. Әнә минем тәрәзәм! Безнең өй! Безнең ишегалды. Безнең агачлар. Безнең капка. Мин «мин» булсын өчен боларның барысының да булуы кирәк икән.

Роза (*утырып*). Эссе. Эсселек тә синекеме?

Гөләндәм. Безнең капка янында булгач, минеке! Менә бу агачларга суны ешрак сибеп, тизрәк үстерермен! Безнең холодильникта салкын куас бар. Үзебез пешердек. Әйдә, сыйлыйм.

Роза. Рәхмәт, Гөләндәм. Кайтырга вакыт. Закир киләм дигән иде. Көттергәнне яратмый башлады егетем.

Гөләндәм. Кайчан өйләнешәсез?

Роза. Закирга аңа хет бүген үк...

Гөләндәм. Әллә син сөйгәнең белән кавышырга ашыкмыйсың?

Роза. Ашыгып ни файда?

Гөләндәм. Ничек инде алай?

Роза. Кайчан «безнең» өй булыр! Минем тәрәзә! Безнең ишегалды!.. Шалашта да яшәр идең, көләрләр! Без «без» булсын өчен барысы да кирәк. Әнә, минем иптәш кызларымнан берәү. Өйләнештеләр. Кыз баздә, егете Закирлар янында, өч урам аша. Йорт өлгергәнне көтә-көтә дошманлашып беттеләр.

Гөләндәм. Үзең Закирың янына ашыгасың, үзең, һәр көн мине озата киләсең.

Роза. Сәбәбен белмисеңме?

Гөләндәм (*аптырап*). Белмим.

Роза. Без дуслар түгелмени?

Гөләндәм. Әнкәй шушы атнада минем фамилиямне дә үзгәртәбез, диде. Мин Гөләндәм Даишева булам. Зиннурова кызганыч-кызганычын, әмма бусы төплерәк, ышанычлырак. Дөрес бит?

Роза. Даишева булып та озак йөри алмассың.

Гөләндәм. Авызыңнан җил алсын.

Роза. Закирның фамилиясе Хөббетдинов. Фамилия

дә булдымы шул! Мин, Алла боерса, Закирга үз фамилиямне бирәм. Алмый икән, Хөббетдинова буласым юк!

Г ө л ә н д ә м. Ә мин... кияүгә чыксам да Даишева булып калам.

Р о з а. Белгән юк инде. Киявең кем булыр бит әле!

Г ө л ә н д ә м. Роза, чыннан да, дус итеп кенә озата киләсеңме мине?

Р о з а. Шулай булмыйча, тиле! Мин бит авыл кызы, Гөләндәм, эчемдәге — тышымда. Гади мин!.. Тик шулай да, алай икәнлегемне Закирга әйтмә.

Г ө л ә н д ә м. Нигә?

Р о з а. Ул мине дөньяда бердәнбер дип белә...

Г ө л ә н д ә м. Закир да мине якын күргәнгә генә безнең тирәдә ураламы?

Р о з а. Кичләрен без гел шушы урамнарда йөрибез. «Синең» урамнар вакытлыча, төнгә генә «безнең» урамнарга әйләнә!

Г ө л ә н д ә м. Тыныч шул безнең яклар.

Р о з а. Тыныч шул.

Г ө л ә н д ә м. Ә мин, җүләр, әлләниләр уйлап бетерәм! Бүген әнкәй өчен борчылып торам әле. Үткән төнне без бер тамчы йокламадык дисәң дә була. Аптырап икәүләшеп бакчага чыгып утырып карадык. Чәчәк исе!.. Яратам матурлыкны, чиксез яратам. Җирне яратам. Бәләкәй чакта мин гел яланаяк йөри торган идем. Детдомда чакта, дим.

Р о з а. Детдомда? Син үзең хакында гел сөйләмисең, Гөләндәм?

Г ө л ә н д ә м. Ә синең ни беләсең килә?

Р о з а. Юк, кирәкми, кирәкми. Әнкәң сорашмаска кушты. Узганнарны уйласа, ул борчыла, ди.

Г ө л ә н д ә м. Сорашмаска куша, дип... Искитәрлек берни дә юк, Роза... Үкенечләр дә күп. Яшәлгән шунда!

Р о з а. Мин хәзер өйгә кайтам да Закирны монда алып киләм. Безне өй куасы белән сыйларсың.

Г ө л ә н д ә м. Миңа кунакка киләсез булып чыга, алайса?

Р о з а. Киликме соң?

Г ө л ә н д ә м. Качмаслык булсагыз, килегез генә!.. Нигәдер бүген ялгыз каласым килми. Хәниф абый да тиз кайтмыйм диде.

Р о з а. Алай ялгыз кала алырсың микән?

Г ө л ә н д ә м (*каранып*). Кем бар анда?

Р о з а. Күләгәң килеп җиткән.

Г ө л ә н д ә м. Күләгә кояштан гына була, Роза. Кем?

Р о з а. Кем булсын, Шәмәрдән инде.

Гөләндәм. Безгә таба киләме?

Роза. Туп-туры.

Гөләндәм. Күрәсем килми шуны!

Роза. Гөләндәм, уйнамый гына әйтче, иркәм, без белмәгән нинди яшерен көче бар бу кешенең синең алда?

Гөләндәм. Шулайдыр дигән идем аны!

Роза. Турысын сораганга үпкәләмә.

Гөләндәм. Менә ни өчен миңа ияреп кайтасың син? Шәмәрдән мине сагалый, сез Шәмәрдән белән мине күзәтәсез. Шулаймы?

Роза. Ул күренүгә, коелып иңәсең. Сөясеңме әллә син аны?

Гөләндәм. Минме? Нәфрәтләнәм. Күрә алмыйм. Җенем чыга.

Роза. Моның өчен синең сәбәпләрең җитәрлекме? Алайса, нигә аның эзен суытмыйсың?

Гөләндәм. Акыллы Роза. Сизгер Роза... Шәмәрдәнне белмисең шул син!

Роза. Син яхшы беләм дисең ич.

Гөләндәм. Мин дә белмим аны.

Роза чыга. Шуны гына көтеп торган Шәмәрдән атылып керә.

Шәмәрдән. Әнкәң янында түгел икәнсең.

Гөләндәм. Түгел.

Шәмәрдән. Кичә төн буе нидер серләштегез. Беләсем килә, баш авырта башлады.

Гөләндәм. Шуннан?

Шәмәрдән. Шөгергә чыгып китә торган юл чатында олы бер таш ята иде.

Гөләндәм. Кайда, кайда?

Шәмәрдән. Шул үзеннән-үзе вакланып чәрдәкләнгән. Тора-тора таш та үзгәрә икән!

Гөләндәм. Безнең икебездән кайсыбыз алдарак үзгәрер инде?

Шәмәрдән. Икебез дә.

Гөләндәм. Шәмәрдән!

Шәмәрдән. Үз исемемне яратмыйм. Кушамат кебек ул. Синең иреннәреңнән матур гына яңгырады. Беренче тапкыр үз исемемнән канәгать булдым. Тагын бер кабатлачы!

Гөләндәм. Тынычландым гына дигәндә, аяз көндәге болыт күк, син килеп чыгасың...

Шәмәрдән. Җиргә күләгә иңә!.. «Эт кояшы, кит, кит! Безнең кояш, кил, кил!» Шулаймы?

Гөләндәм. Эт кояшы туңдыра... Күрмисеңмени, монда барысы да үзгәрде.

Шәмәрдән. Минем кояш чыкты, монда сиңа урын бетте дисең инде.

Гөләндәм. Әнкәй мине ярата. Рәхәтләнеп эшләп йөрим. Үз йортым. Үз гаиләм. Без Хәниф абый белән бик тату... Яраткан дусларым бар. Шул чагында сиңа мине җәфалау рәхәтме?

Шәмәрдән. Син Хәнифне күрдеңме бүген?

Гөләндәм. Күрдем.

Шәмәрдән. Бер сүз дә әйтмәдеме ул?

Гөләндәм. Юк. Оныт мине, Шәмәрдән.

Шәмәрдән. Булдыра алмыйм. Ярамый да.

Гөләндәм. Хәзер нишләмәкче буласың инде?

Шәмәрдән. Сине коткарырга уйлыйм.

Гөләндәм. Әрсез син, Шәмәрдән.

Шәмәрдән. Рәхмәт. Ләкин бу минем бердәнбер яхшы сыйфатым түгел.

Гөләндәм. Инженер кияве буласың килә инде?

Шәмәрдән. Сволочь ул синең әткәң!..

Гөләндәм. Сүгенмә, бу йортта изге кеше тора. Әнкәй!.. Сиңа борынгы бер җыр җырлап биримме?

Шәмәрдән. Миңамы? Җырла, Гөләндәм.

Гөләндәм (*җырлый*).

Олы юл буенча атлар килә,
Ни төягән икән атларга?
Үз бәхеткәйләрең булмагач,
Эшләп ярамыйсың ятларга!..
Кара урманга кердем утынга дип,
Алмагачлар кистем балан дип.
Нигә ят кешенең күңеле каты,
Ялгышып та әйтми балам дип!

Әнкәй шушы җырны яратып җырлый иде минем!

Шәмәрдән. Кайсы әнкәй, Гөләндәм?

Гөләндәм. Әнкәй... Нәрсә дидең әле син?

Шәмәрдән. Юк, юк, әнкәңә сүз юк. Чыннан да ихлас кеше күренә ул. Шәп! Менә атаң гына... Мин үзем дә чиста кеше түгел. Төрлесен күргәнем бар, әмма мондый затсызны очраткан булмады. Ахыр чиктә, миңа язгансыңдырмы, юктырмы, анысы караңгы, мәгәр яхшы чакта бу тирәдән ычкынып кал.

Гөләндәм. «Ялгышып та әйтми балам дип!» Ишеттеңме?

Шәмәрдән. Соңыннан авырлыгы төшкәч, үкенече зуррак булыр.

Гөләндәм. Монда әнкәй бар. Ул көчлерәк. Мин аңа кирәк. Ул миңа.

Ш ә м ә р д ә н. Мине уйнап кына да санга тыкмыйсың инде?

Г ө л ә н д ә м. Синеме, Шәмәрдән?

Ш ә м ә р д ә н. Гарип, төзәлмәслек имгәк дисең. Уйлап кара менә, Гөләндәм. Моңарчы мине яхшы сүз, үгет белән тәрбия итмәк булдылар. Колакка да элмим мин яхшы үгетне! Кешеләр ничек төзәләдер, белмим, минем үземне бүтән нәрсә сындырды. Үземнән дә әшәкерәк кеше очраттым мин! Аны күреп тетрәнеп киттем! Күңел акрын гына яхшылык юксына башлады. Әйбәт кеше буласы килми дисеңме? Кара йөрәкләр минем дә ачу җенен кузгата икән. Атаң... Ух, аны! Сатлык кеше! Шуңа күрә сине бу йорттан тартып аласым килә...

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй көчлерәк. Ул ирек бирмәс.

Ш ә м ә р д ә н. Трестның баш инженеры кияве булудан тантаналы төстә баш тартам. Бер сүзең, бер ым кагуың җитә: моннан алам да сызам!

Г ө л ә н д ә м. Кая?

Ш ә м ә р д ә н. Намуслы бала бит син. Торган саен авыррак булыр. Нефть ягында калалар азмы хәзер? Эшләрбез, үзебезчә тормыш башларбыз. Син миңа ышан гына. (*Закир белән Роза күренәләр.*) Китим булмаса...

Г ө л ә н д ә м. Китмә. Нигә минем иптәшләрдән өркергә?

З а к и р. Сәлам, Гөләндәм.

Г ө л ә н д ә м. Сәламеңне алдык. Сез танышлармы? Бу егет Шәмәрдән.

З а к и р. Читтән-чоттан гына йөрсәк тә, танышлар.

Ш ә м ә р д ә н. Беләбез.

Р о з а. Сезнекеләр кайтмадымы?

Г ө л ә н д ә м. Әлегә юк. Әнкәй кайтышлый эткәй янына кагылам дигән иде.

Р о з а. Ни хәлләр соң, Шәмәрдән?

Ш ә м ә р д ә н. Үзем әйбәт. Машинам төзек. Квартира бирсәләр, момент ташып куям үзегезне.

З а к и р. Комиссия бик каты эшли диләр. Шәһәрнең хәлен бераз яхшыртырлар кебек.

Ш ә м ә р д ә н. Гөләндәм! (*Гөләндәмне читкә дәшә.*) Монда кеше артык күп җыелды... Ят казга урын юк. Тайыйм мин.

Г ө л ә н д ә м. Кемнән куркасың?

Ш ә м ә р д ә н. Атаңнан... Йә кайтып керер.

Г ө л ә н д ә м. Ихтыярың.

Ш ә м ә р д ә н чыга.

Р о з а. Без кунакка килдек, Гөләндәм! Теге тәмле куасың беттеме?

Г ө л ә н д ә м. Ай, рәхмәт! Әйдәгез, өйгә керәбез.

З а к и р. Куасың булса, чыгар монда гына. Өйгә бераз соңрак керербез. Хәниф абый кайтсын, яңалыкларны ишетик.

Г ө л ә н д ә м. Ә мин яңалыклардан куркам бүген! (*Кереп китә.*)

Р о з а. Нигә курка ул яңалыклардан?

З а к и р. Табигый хәл. Яңалыклар артык күп бит аның өчен!

Гөләндәм куас алып чыга. Х ә н и ф кайта.

Х ә н и ф. Минем кибегеп кайтканны белгәнсең, Гөләндәм. Рәхмәт. (*Эчә.*)

Р о з а. Без кибекмәгәнме? Ә безгә? Безгә?

Г ө л ә н д ә м. Хәзер, дустым. Хәниф абый, әнкәй кайда?

З а к и р. Утырыш беттеме?

Х ә н и ф. Әлфинур апа шунда кереп калды...

Г ө л ә н д ә м. Ә син, Хәниф абый?

Х ә н и ф. Утырыш бетеп җитмәде әле. Хәзер тәмамлана. Тәнәфес ясадылар да, мин яңадан кермәдем.

Г ө л ә н д ә м. Алай ярыймыни?

Х ә н и ф. Үзем дә шуңа аптырап кайтып киләм. Таймураз абыйны кызгандым. Әллә ничек!.. Ул соңгы көнгә чаклы, соңгы минутларга тиклем профессорына өметләнде. Моннан әллә ничә еллар элек профессор Осташевский әйткән фикерләргә таянып, шуларны калкан итеп яши иде бит ул. Ә профессорның чыгышы гаять каты булды...

Г ө л ә н д ә м. Хәзер нәрсә булыр инде?

Х ә н и ф. Профессор берәүне дә аямады. Проект оешмаларына да эләкте, мондагы хуҗалык, төзү оешмаларын да тетеп салды.

З а к и р. Ә Таймураз абый?

Х ә н и ф. Үзегез күз алдына китерәсез инде!

Г ө л ә н д ә м. Әйдәгез, керик әле. Мин сезне куас белән сыйлармын... Ни булыр инде безнең өйдә? Ни булыр?.. Әнкәй кайтып җитсен иде, ичмасам!

Өйгә керәләр. Пауза. Музыка. Ш ә м ә р д ә н керә, Т а й м у р а з кайта. Алар очрашалар. Өйдән Г ө л ә н д ә м чыга.

Т а й м у р а з (*Шәмәрдәнгә*). Син дә килдеңме?

Ш ә м ә р д ә н. Килдем.

Т а й м у р а з. Яраланган арысланны караргамы?.. Ялгышасың! Тай моннан!

Ш ә м ә р д ә н. Гөләндәм, әйткән сүзләремне исеңдә тот! (*Чыга.*)

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй кайда?

Т а й м у р а з. Нигә миннән «Хәлең ничек, эткәй?» дип сорамыйсың?

Г ө л ә н д ә м. Мин әнкәйне каршыларга барам.

Т а й м у р а з. Әнкәй, әнкәй... Тапкан бер сүз!

Г ө л ә н д ә м. Тагын ялгыштыммы? Бер сүз дә әйтмәдем ич.

Т а й м у р а з. Кеше рәтеннән ул да сүз әйтер иде! Ул да! Койрыгыңны кысып кына яшә!

Г ө л ә н д ә м. Мин...

Т а й м у р а з. Ә син? Ә мин? Ә без?! Әнкәңә, сөекле, кадерле әнкәңә, изге кешегә бер ым гына каксам да җитә бит! Шундук бетәсең бит! Тын! (*Өйгә керә.*)

Г ө л ә н д ә м. Шәмәрдән! Шәмәрдән! Син кайда? (*Эзли.*) Роза! Роза, чык әле! (*Роза керә.*)

Р о з а. Безнең өй булса, холодильник сатып алсак, мин дә шулай тәмле итеп ризыклар пешерер идем...

Г ө л ә н д ә м. Роза, иркәм, акыллы бул, бар тиз генә Шәмәрдәнне эзләп тап!

Р о з а. Мин ялгыш ишеттемме?

Г ө л ә н д ә м. Бусы ялгыш түгел. Тиз үк килеп җитсен.

Р о з а. Берәр нәрсә аңлатырсың, бәлки.

Г ө л ә н д ә м. Аягыңның берсе монда, икенчесе тегендә булсын.

Роза чыга. Х ә н и ф белән З а к и р күренәләр. Алар күренүгә Гөләндәм кача.

З а к и р. Кая югалдылар бу кызлар?

Х ә н и ф. Әлфинур апаны каршыларга киткәннәрдер.

З а к и р. Без дә барабызмы?

Х ә н и ф. Әйдә. Юлда мин сиңа бер әкәмәт сөйләрмен. Теге егет кызык итте бит безне... Урманда югалган әйберләрне хәтерлисеңме?..

Чыгып китәләр. Р о з а белән Ш ә м ә р д ә н керә. Гөләндәм аларны каршылый.

Р о з а. Алып килдем.

Г ө л ә н д ә м. Шаулама, Роза, шыпырт кына. Рәхмәт. Хәзер бар. Закирларны куып җит. Алар... әнкәйне каршыларга киттеләр.

Р о з а. Ялгышмыйсыңмы син, кызый.

Г ө л ә н д ә м. Бар, бар, Роза. Ашык.

Р о з а. Тотармын да бер үпкәләрмен әле үзеңә. (*Чыга.*)

Ш ә м ә р д ә н. Син чынлап та мине чакырдыңмы?

Г ө л ә н д ә м. Чакырдым. Ник икәнен генә белмим. Кыскасы, Хәниф абыйлар урланган әйберләрнең кемдә икәнен белгәннәр... Бу бер.

Ш ә м ә р д ә н. Ә мин аларны үзем китереп бирдем.

Г ө л ә н д ә м. Син?.. Ә, аңлыйм... Ә миңа нәрсә эшләргә соң? Кояш байый. Түтәлләрне чүп басып бетергән. Агачларга су сибелмәгән. Әнкәйгә бүген утармын дигән идем. Әнә тегендә тюльпаннар утыртырбыз дип сөйләшкән идек... Агын, кызылын, салават күпере төсләрен. Ник чакырган идем соң мин сине? Бары да бетте, Шәмәрдән.

Ш ә м ә р д ә н. Мин бетмәдем. Каршыңда басып торам.

Г ө л ә н д ә м. Син хаклы булып чыктың. Моннан китәргә туры килә.

Ш ә м ә р д ә н. Тыңлыйм.

Г ө л ә н д ә м. Мин корган хыяллар — кичке мәктәп, яңа паспорт, институт, төзелешләр, дуслар — һәммәсе дә бер минутта көл булды. Бары очты. Югалды.

Ш ә м ә р д ә н. Шәмәрдән калды. Мифтахетдин картның игелексез улы.

Г ө л ә н д ә м. Син минем җайсыз чагымнан файдаланмассың, ышанам. Кирәкми. Дус булып кына кал... Күңелем башкада. Мәңгегә!.. Син гараждан машинаңны алып чыга аласыңмы?

Ш ә м ә р д ә н. Тырышып карармын.

Г ө л ә н д ә м. Озат мине кая булса да. Миңа әнкәй белән очрашырга ярамый. Хәниф абыйны күрергә ярамый.

Ш ә м ә р д ә н. Кайсысы гаепле? Кемнең кулы уйнады?

Г ө л ә н д ә м. Гаепне гел-гел кешеләрдән эзләмик. Үзем гаепле, Шәмәрдән, үзем! Хәтереңдәме, тегендә, урманда, мин сездән качтым. Сездән түгел, үткәндәге ялгышларымнан, талымсызлыгымнан качам дип уйлаган идем. Күңел бары тик яхшылык кына тели иде. Сафлык кына юксына иде. Мөгаен, Айгөл сәбәпче дә булгандыр, үзем дә ачык авыз идем, байтак хаксызлык күрдем бит! Күңел гарык иде. Күңел сафлык теләде, ә аяклар кая китерде? Кем бусагасын атлап кердем мин? Кемне «әнкәй» дип атарга батырчылык иттем. Кемнең иң якты, иң мөкатдәс хисләрен алдадым? Моннан да әшәкерәк, кешелексезрәк ялганның булуы мөмкинме?..

Ш ә м ә р д ә н. Нәкъ менә шул чагында инде кайберәүләргә Шәмәрдән кирәк. Башкаларга күренергә ярамый, Шәмәрдәнгә ни дә бата! Нигә син кылган эшләрең өчен минем алда да кыенсынмыйсың?

Г ө л ә н д ә м. Синең алдамы?

Ш ә м ә р д ә н. Әйе. Минем алда.

Г ө л ә н д ә м. Сине... Үз ишем итеп санаганмындыр...

Ш ә м ә р д ә н. Юк! Мин андый түгел. Узганнарымнан ваз кичәм!

Гөләндәм. Мин сиңа аңлатып хатлар язармын. Гомерем буе рәхмәт укырмын.

Шәмәрдән. Миңа сәдака кирәкми. Мондый Гөләндәмне озата алмыйм. Мондый Гөләндәм белән беркая китмим. Син миңа гараждан машинамны урлап чыгарга кушасың!

Гөләндәм. Ә кая чабасың син?

Шәмәрдән. Машина яллыйм. Берәрсен сатып алам!

Чыга. Айгөл керә.

Айгөл. Һаман шушында... Һаман... Куып җибәрдеңме?

Гөләндәм. Түгел.

Айгөл. Әлфинур апа кайтмадымы?

Гөләндәм. Әлфинур апа кайтып җитмәде.

Айгөл. Сиңа ни булды?

Гөләндәм. Безнең кояш сүнде, эт кояшы килде...

Айгөл. Кайталар!

Әлфинур, Хәниф, Закир, Роза керәләр.

Хәниф. Гөләндәм, кая югалдың син, Гөләндәм!

Әлфинур. Кызым, хәерле кич. Кайтып җиттем, кызым. Авырмыйсыңдыр бит?

Гөләндәм. Чигәләрем ут булып яна.

Әлфинур. Күбрәк эшләп ташладыңмы әллә?

Хәниф. Гөләндәм... Хәбәрләр шәп. Генпланны үзгәртәләр. Культура сараен башка урынга салырга билгеләделәр. Шәһәр үзәген үзгәртеп корачакбыз. Мең үзгәреш...

Закир. Таймураз абыйга читен булыр инде...

Роза. Монда калмас ул, китәр. Баш инженерлыктан гади инженерга төшерсеннәр әле.

Әлфинур. Беркая да китмәс. Аңа монда эш җитәрлек. Кызым, эткәң өйдәме?

Гөләндәм. Булмәсендә... Нидер язамы, укыймы...

Өйдән Таймураз чыга.

Таймураз. Кунаклар... Тагын кунаклар...

Әлфинур. Нигә утырышны ташлап киттең, Таймураз? Мин сине алырга кергән идем.

Таймураз. Йөрәге ярылып үләр дип курыктыңмы?

Әлфинур. Юк, Таймураз. Шулай да, әйтер сүзем бар иде.

Хәниф. Безгә дә ишетергә ярыймы, Әлфинур апа?

Әлфинур. Безгә гыйбрәт, сезгә сабак. Таймураз, син

дә тыңла... Дару ачы булса да йотабыз... Борын-борын заманнарда Болгарда атаклы бер баһадир булган. Ул исән чакта, егәрендә чакта, тирә-яктан Болгарга бер генә дошман да керә алмаган. Менә баһадир картайган, әҗәле җиткәнен сизеп, бердәнбер улын, үзе шикелле үк батыр егетне чакырып китергән. «Улым, дигән, менә сиңа ук белән җәя, менә сиңа алмаз кылыч. Болгарда бу җәяне киерер кеше син генә... Бу кылычны тотар батыр син генә. Юкка-барга кылычыңны күтәрмә, дигән, кирәк чакта каушап та төшмә, дигән». Карт баһадир дөнья куйгач, гаскәр башы булып улы калган. Карт баһадирның үлемен ишеткән дошманнар тиз үк колакларын торгызганнар һәм Болгар иленә яу килгән. Кешеләр ах-ух килеп яшь батырга хәбәр салганнар. «Яу килә, яу!» дигәннәр аңа. Яшь батыр келәмдә кырын ятып шәраб эчә икән. «Күпме алар?» дип сораган ул. «Илле җайдак» дигәннәр аңа. «Илле җайдак өчен алмаз кылыч күтәрер хәлем юк» дигән батыр. Дошманнар болгарларның елкыларын, терлек-туарларын куып алып киткәннәр. Йөз җайдаклы яу килгәч тә урыныннан купмаган батыр, биш йөз дошман килгәч тә кузгалмаган. Берзаман Болгар күген тузан баскан. Дошман кара болыт булып килә икән. Халык ярдәм сорап батырга тагын хәбәр салган. Ниһаять, эшнең уеннан узганын сизенгән батыр. Угын-җәясен алган, кылычын биленә тагып, яуга каршы чыккан... Килә дошман, илне кара күмергә әйләндереп килә... Батыр җәяне тартып карый, тарта алмый. Күзеннән ике бөртек тонык яшь кенә тәгәрәп төшә. Кылычка тотына, күтәрә алмый, беләкләре зәгыйфь. Көче беткән, егәре юк. Менә шулай... Осташевский сине бик яхшы аңлаган! Соң алды җаваплы эшне кулына, ди. Дәрт бар, дәрман юк... Кайгырма, Таймураз, бу хикәяне яшьләр өчен сөйләдем. Син бит менә дигән инженер!

Гөләндәм. Әнкәй! Чәй әзерлимме?

Хәниф. Шәп булыр ул, Гөләндәм.

Әлфинур. Рәхмәт, кызым.

Закир. Без дә баш тартмыйбыз.

Таймураз. Кунаклар, тагын кунаклар... Барысын бозарга минем бер сүзем җитә ич! Тукталыгыз!

Гөләндәм. Сизенәм... Коралның кем кулында булуын мин бүген бик ачык аңладым... Кулда көч барында алмаз кылычны күтәреп калыйм дисезме?

Әлфинур. Кирәкми, кызым. Әткәң акыллы кеше. Ул мондый үзгәрешне генә кичерерлек көч табар.

Шәмәрдән керә.

Ш ә м ә р д ә н (*Айгөлгә*). Чакыр Гөләндәмне!

А й г ө л. Шаулап йөрмәсәнә!

Ш ә м ә р д ә н. Гөләндәм, булды.

Г ө л ә н д ә м. Хәзер, хәзер... Әнкәй... әйтми түзәрем калмады...

Т а й м у р а з. Тик тор диләр сиңа!

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй, мин сезнең кызыгыз түгел бит. Мине ул алып кайтты. Тормышымның читен, авыр вакытында очратты да ризалаштырды.

Х ә н и ф. Эх, кирәкми иде, Гөләндәм!

Ә л ф и н у р. Нигә алай булсын, кызым? Син минем үз кызым, үз йөрәк парәм!

Ш ә м ә р д ә н. Гөләндәм!

Ә л ф и н у р. Син безнең үз кызыбыз. Шулай бит, Таймураз.

Т а й м у р а з. Гафу ит мине, Әлфинур...

Ә л ф и н у р. Менә шулай! Әле бит гомер узмаган. Әнә, шәкертләрең янында. Хәниф, Закир...

Т а й м у р а з. Булдыра алсагыз, барыгыз да кичерегез.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй!

Ә л ф и н у р. Үз кызым, үз йөрәк маем... Хәниф тә үз улымдай якын. Айгөл нигә читтә тора? Барыгыз да минем яныма килегез.

Г ө л ә н д ә м. Әнкәй!

А й г ө л. Сезнең бер генә кызыгыз югалмаган икән, әнкәй!

Х ә н и ф. Рәхмәт сиңа, Гөләндәм.

Ш ә м ә р д ә н. Мин дә сезнең янга килимме?

Ә л ф и н у р. Балаларым минем, балаларым!

П ә р д ә.

*Сентябрь, 1963; февраль, 1964*
*Казан*

# *Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз...*

*Драма ике бүлектә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Ш а ф и к а.
Р и н а т.
Н а и л.
Л ә м и г а  а п а.
К а ш ш а ф.
Г ө л б а н у.
Л а р и с а.
Л ю с я.
В а н я  Ж у к о в.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Ләмигалар ишегалды. Н а и л койма такталары кадаклап маташа. Чүкече, балта-пычкысы бар. Нәкъ шундый ук балта, пычкы-чүкеч тотып К а ш ш а ф керә.

К а ш ш а ф (*паузадан соң*). Әйтсәң-әйтмәсәң күреп торам: хата яшисең, энекәш!

Н а и л. Нишләп, Кашшаф абзый?

К а ш ш а ф. Күп адәмнәр үзләренең ничек яшәүләре турында уйлап та карамыйлар. Ике ятып бер төшләренә дә керми. Яшиләр шунда... Көн артыннан барыбер көн уза! Кояш барыбер чыга!.. Чабата артыннан чабата туза... Чабата тузганына карап кына гомер узганны чамалаучылар да бар, энекәем!.. Менә син дә, күреп торам, гаҗәпләнәм, шуларның берсе икәнсең.

Н а и л (*паузадан соң*). Олы гаеп ташладың, Кашшаф абзый.

К а ш ш а ф. Риза түгелме?

Н а и л. Олы кеше, аксакал әйткәч карышырга базмыйм инде. Бәлки, шулайдыр...

К а ш ш а ф. Менә! Билне тиз бирүең дә шуны раслады: хата яшисең! Кешегә комачаулыйсың. Димәк ки,

кешегә комачаулыйсың икән инде, үзең өченрәк яшисең булып чыга. Дөньяга ник тудың? Җиргә-күккә синнән ни файда?

Н а и л. Аңлап ук бетерә алмыйм, Кашшаф абзый.

К а ш ш а ф. Нишләп син монда?

Н а и л (*тукталып*). Ни... Мин монда кергән идем... Күршеләр бит! Шафика өйдә юкмы дигән идем... Ләмига апа күрде дә: «Барыбер әлегә тик йөрисең, ичмасам, койманы төзәт,— диде.— Кашшаф абыең төзәтә башлаган иде, биле кузгалып, эше ярым-йорты килеш калды»,—диде.

К а ш ш а ф. Биле кузгалган, имеш... Балта эшенә үзем өйрәттем, бил дип зарланганымны ишеткәнең булдымы? Былтыр Чуал күперен сукканда ниндәен дөмбәскә күтәреп субай кактык, ә?!

Н а и л. Ишеткән юк.

К а ш ш а ф. Бер башлаган эшен ярты юлда туктаткан дигәнне ишеткәнең бардыр, алайса?

Н а и л. Анысын да юк.

К а ш ш а ф. Бәс, шулай икән, анаң яламаган нәрсә, тукта, эшләп бетермәгән икән, моның берәр сере юкмы дип уйларга иде!.. Җитмәсә, эшеңнең рәте-чираты күренми. Шулай кагалармы тактаны, кубар хәзер үк! Сүт!

Н а и л. Билең төзек, Кашшаф абзый, ышанам, мәгәр күз бирешкән синең. Чалыш түгел, икмәк!

К а ш ш а ф. Олы кеше әйтә икән, чалыш!

Н а и л. Олы кешегә дә ышанып бетмәскә үзең өйрәттең... Аннары, кешегә: «Үзең өчен генә яшәмә!» —дип әйтү җиңел ул! Ә син? Үзең?!

К а ш ш а ф. Үз мәнфәгатем өчен генә киләмме бу нигезгә?!

Н а и л. Аңламыйм, икмәк, Кашшаф абзый! Боргалыйсың бүген димме, пигамбәрләрчә сөйләшәсең.

К а ш ш а ф. Утыр, алайса. Утыр да тыңлап бак. Куй чүкечеңне. Пигамбәрләрчә диденме?.. Алай... Кем нигезе янында утырабыз без?

Н а и л. Шафикалар нигезе янында.

К а ш ш а ф. Менә бит! Томана зирәк! Ләмига апай нигезе янында, Ләмига!.. Ә син анын кем икәнлеген беләсеңме?

Н а и л. Белмичә. Шафиканың әнисе...

К а ш ш а ф. Их-ма, егет!.. Ләмига тол ул... Ятим. Гомере буе ятим... Мин дә тол хәзер. Җиңгәңне җирләгәнгә җиде ел. Җиде ел мин шушы нигезгә сукмак салырга ымсынып йөрдем. Җиде кыш, җиде җәй! Җиде елга җиде җылы сүз ишеткәнем булмады. Барыбер йөрдем! Сердә-

шем салкын түшәк... Юлдашым Җидегән йолдыз... Йолдызга карыйм да елларны саныйм... Ләмига моңарчы «бала!» дип яшәде. «Кызым!» димәгән сулышы булмады... Шафика да Шафика! Менә син дә «Шафикалар нигезе» дип каркылдыйсың... Ләмиганың барлыгын белмисең дә, уйлап та карамыйсың. Килгәлим һаман, өметләнәм... Утыннарын ярам, казаннарын ямыйм... Менә койма... Бер-ике көнгә сузалмаммы дигән идем. Монда син үсеп җиткәнсең икән... Үскәнсең икән. Шафикаң белән су буенда, болында очраш! Бибиләтиккә бар!

Н а и л. Белмәдем бит, Кашшаф абзый.

К а ш ш а ф. Белмәгәннең беләк тә авыртмый, ә белгәннең йөрәк сыза!.. Тукта әле, кайда соң хуҗалар?

Н а и л. Шафика Түбән авылда икән. Кодачалары чирләгән диме... Ә Ләмига апа Мәрьямнәргә чүпрә сорарга китте.

К а ш ш а ф. Егет, егет! Утыртканнар икән сине чүпрәгә.

Н а и л. Кашшаф абый!

К а ш ш а ф. Ләмига апаң чүпрә ише нәрсәгә күршегә йөриме? Ярты авыл аның үзенә йомышка йөри... Ярый, анысы да шулай булсын... Син коралларыңны җыештыр да кит моннан.

Н а и л. Шафиканы көтәм.

К а ш ш а ф. Кайтмый ул бүген.

Н а и л. Кайта!

К а ш ш а ф. Ләмига апаңның кулында төенчеге бар идеме?

Н а и л. Бар иде. Ак яулыкка төреп чүлмәк тоткан иде бугай.

К а ш ш а ф. Менә, әйттем бит!

Н а и л. Юктыр, ышанмыйм. Булмас. Тагын куна җибәрәме? Зираткамы?

К а ш ш а ф. Кичә Шафиканың ни кылганын ишеттеңме?

Н а и л (*паузадан соң*). Ишетмичә... Су алып кайтканда ата күркәгә очраган да көянтә-чиләген ташлап чапкан... Көтү каршыларга төшкән малайлар бу кәмиттән тәгәри-тәгәри көлгән!.. Печән җыйган җирдә болында калуын чамалаган идем мин аның!.. Мөгаен Ләмига апа аңа ашарга алып киткәндер!

К а ш ш а ф. Аңлатып биргәч, төшендең тагын!

Н а и л. Ләмига апа да кансыз икән... Кызын интектерә!.. Барсам инде...

К а ш ш а ф. Бу юлы киңәш бирә алмыйм.

Наил чыга. Кашшаф Наил каккан коймаларны кубарып ала. Л ә м и г а керә, кулындагы чүлмәген күрсәтмәскә тели.

Л ә м и г а. Авырткан бил белән мәшәкатьләнмәскә иде, Кашшаф абый!.. Наил кайда соң?

К а ш ш а ф. Китте ул. Ашыкты.

Л ә м и г а. Ай-һай, ашыкты микән?

К а ш ш а ф. Кызыңны калдырып кайттыңмы?

Л ә м и г а. Шафика янына җибәрмәгәнсеңдер бит?

К а ш ш а ф. Юкка газаплыйсың кызыңны.

Л ә м и г а. Зарланганы бармы әллә?

К а ш ш а ф. Югын юк та, күренә ул!.. Хуш, кызың куркак, ди. Шуннан нәрсә? Бар кеше дә җан сакларга тырыша. Менә мин гражданнар сугышының койрыгын гына булса да күргән кеше. Нигә син кызыңның куркак булуына кимсенәсең?

Л ә м и г а. Син кимсенмәс идеңме? Элекке заман булса бәет чыгарырлар иде Шафика турында! Куркак кеше — кол була. Кызымның хөр фикерле булуын, үзен җирдә иркен сизүен телим.

К а ш ш а ф. Курка икән, димәк, аның яшисе килә! Бигрәк тә кыз балага куркаклык килешә генә аңа! Һич башкача түгел.

Л ә м и г а. Юатырга яратасың мине, Кашшаф абый. Сүзләрең хаксыз булса да рәнҗемим.

К а ш ш а ф. Юатуым түгел иде, Ләмига! Күңелдәген сөйләдем. Син бит шундый, юк белән дә үзеңне бетерәсең. Кирәкми.

Л ә м и г а. Мактангалап куйсаң да, белмисең икән син мине, Кашшаф абый.

К а ш ш а ф. Беләм дип... Яшь чагыңны беләм. Кияүгә чит авылга киттең. Аннан кайткач, аннан кайткач... кояшың да, аең да кызың булды, урак урганда да үзеңнән калдырмадың.

Л ә м и г а. Бара-бара куркучан бер җан үстердемме?! Их, Кашшаф абый, Кашшаф абый! Биш-алты балаң булсын икән ул, арада берсе куркучан дисәләр дә, исем китмәс иде! Берәү бит! Бердәнберем!.. Аның шундый булуына үзем гаепле! Үзем!

К а ш ш а ф. Бала анага охшый инде, беләм.

Л ә м и г а. Монда башкачарак, Кашшаф абый... Асылгәрәйне сәнәкчеләр үтергәнен ишетеп беләсеңдер, онытмагансыңдыр?

К а ш ш а ф. Гайрәтле хатын син, Ләмига!

Л ә м и г а. Тыныч кына бу турыда синең белән сөйләшә алганга әйтәсеңме?

К а ш ш а ф. Әйе.

Л ә м и г а. Белим дисәң, бел инде... Яз көне иде. Сәнәкчеләр Асылгәрәйне, мине, тагын берәүне инеш бу-

ена сөйрәп алып төштеләр... Үзеннән бәке чаптырдылар. Чаба бу, чаба, җилкәсеннән пар күтәрелә. Каш астыннан миңа да карап алгалый. Сизә күңелкәем, үткер балтасы белән явызларга селтәнәсе килгәнен күрәм, мәгәр бер кырыйда мин бар! Мине газаплардан тизрәк коткарыр өчен ашыгып-ашыгып үзенә бәке чапты бахыр! Шул төннең таңында мин бәбәй таптым... Кош оя типми торган игелексез таңда... Язын! Шуңа куркак булды да ул. Ни яшерергә тырышсам да үз йомшаклыгымны җиңә алмадым, баламны кулга алуга бөтен тәнем дер-дер килә иде.

Кашшаф. Гайрәтле ана син, Ләмига!

Ләмига. Самавыр куеп җибәрәсе калган, Кашшаф абый. Наилне кая китте диден әле син?

Кашшаф. Шафика исемен ишеткәч, бик колагын торгызды, тәгаен генә белмим...

Ләмига. Ул аның кайда икәнен белдеме?

Кашшаф. Мин чамаладым.

Ләмига. Монысын ялгышкансың, Кашшаф абый.

Кашшаф. Наил әйбәт егет. Кулыннан эш килә.

Ләмига. Әйтәм җирле койманы гөл иткән!

Кашшаф. Анысы минем гаеп. Мин кушмадым.

Ләмига. Сизәм...

Кашшаф. Болай гына да килгәләр идем, гаепләүче дә булмас, синнән оялам.

Ләмига. Әллә гашыйк булдым дип әйтәсең дә килә инде?

Кашшаф. Сине белә барганнан бирле ныграк тартылам...

Ләмига. Кирәкми, Кашшаф абый...

Кашшаф (*ашыгып*). Наил болай ару егет ул!

Ләмига. Ул әйбәттер дә, кызым менә... Куркак кеше гашыйк була алмый. Әйе, ни кылыйм, кызым шундый. Күк күкрәсә, түшәк астына кереп кача; бакадан, әтәчтән курка, тычканнан куркып келәткә керми, кар базына төшми. Үгез белән кәҗә тәкәсен әйткән дә юк... Мотаһарлар куркә алган икән... Калганын ишеткәнсеңдер?.. Кая инде гыйшык хәлләре әлегә?

Кашшаф. Ләмига, синең үз гомерең бар бит.

Ләмига. Бала гомернең дәвамы... Асылгәрәй белән икебезнең гомер дәвамы!.. Бәкегә этеп төшергәндә ул кулын миңа болгады! Миңа!.. Шундый гаярь кешенең шундый кызы бар икән, ул да минем генә гаеп. Минем генә!..

Кашшаф. Койма төзәтергә иртәгә килимме?

Ләмига. Кил, Кашшаф абый. Кил.

Кашшаф. Сау бул, Ләмига.

Чыга. Сәхнә караңгылана. Иртә. Печән кибәне янында Наил йоклавы ята. Таяк тотып Л ә м и г а керә.

Л ә м и г а. Киләм шулай, киләм... Ни гаҗәп — таягым әле уңга, әле сулга каерыла. Олыгайганмын, адымым чалыш дисәм, синең җилкәңне эзли икән! Һайт!

Н а и л. Ләмига апакаем, икмәктер, әле генә килүем.

Л ә м и г а. Ялган ант эчкән кешене, беләсеңме, нишләтәләр?

Н а и л. Сине алдап булмаслыгын беләм, шулай да берлеккә кичер.

Л ә м и г а. Сорама да, кичермим дә. Тагын эшне бозгансың!

Н а и л. Япа-ялгыз болында кунганын белә торып, ничек өйдә утыра алыйм ди?.. Ләмига апа, минем мондалыкны белми ул.

Л ә м и г а. Мин шуны әйтми каламмы?

Н а и л (*чынлап ук куркып*). Әйтмә, Ләмига апакаем, берүк белдермә. Якты дөнья йөзен күрсәтмәс.

Л ә м и г а. Минем куркучан кызымнан да өркеп торгач, нинди егет ди инде син?!

Н а и л. Куркак түгел ул! Түгел! Бер төнен зиратта утырды... Көндез урманда калдырылган яулыгын төн уртасында берүзе барып алды.

Л ә м и г а. Син боларны каян беләсең? Яле, яле, анда да каравыллап йөрдеңме? Мин ныгайсын, көчәйсен дип әмәл эзлим, ә ул?!

Н а и л. Күрше кызы... Ялгызын йөртә алмадым. Бер-бер хәл булса? Күзенә убыр күренсә? Бар диләр бит... Йөрәге ярылып үлсә?.. Анам бул, Ләмига апакаем, берүк чишмә серне! Әйдә, тизрәк моннан китик, сизенеп калмасын.

Л ә м и г а. Куян батып үләргә дип буа янына чабып килгән. Бакалар аннан куркып сикерешкәннәр. «Вай» дигән куян... Батыр икәнмен мин!

Н а и л. Качмыйк, алайса. Теләсә нишләтсен. Риза.

Л ә м и г а. Кызым!..

Ш а ф и к а керә.

Ш а ф и к а. Әни! Наил дә мондамы?

Л ә м и г а. Туңмадыңмы, кызым?

Ш а ф и к а. Курыкмадыңмы дип соравыңмы, әни?.. Туңмадым, кая ул туңу! Киресенчә, берара шундый бөркү булды. Эссе! Туктаусыз тартар кычкырды. Гел миңа атап эндәшкән кебек. Телләрен генә белмим.

Н а и л (*үзен-үзе җиңеп*). Черки бик талады.

Ш а ф и к а. Кайда? Келәтегездәме?

Н а и л. Мин монда идем, Шафика. Якында гына.

Ш а ф и к а. Шулайдыр дигән идем аны.

Н а и л. Ничек?

Ш а ф и к а. Зиратта әүлияләр кабере янында утырганда да киртә буенда шикле тавыш ишеттем. Кемдер үрмәли иде... Урманда да тып-тып арттан килә идең.

Н а и л. Тып-тып килмәдем, оекчан идем!

Л ә м и г а. Йоклый алмагансыңдыр инде, кызым. Йокың килдеме?

Ш а ф и к а. Уй килде. Сөйләп кенә булмый аны... Менә кояш баеды... Җир белән күк аллы-гөлле пәрдәгә төренеп бергә тоташа. Төн белән татлы уй берегә... Күкнең җиденче катын аҗаган ачып-ачып җибәрә. Күкне төнлә генә күзәтеп була икән бит! Тирә-яктә тирән сер... Моны ничек аңлатасың?.. Наил генә комачаулады миңа!

Н а и л. Мин? Минем гаебем бармы?

Ш а ф и к а. Төн белән минем арага син кердең. Сер белән минем арада син буталып йөрдең... Әнә, рәтләп бир, ичмасам, тырмамның теше сынган.

Л ә м и г а. Кайтып киләсеңдер, кызым? Ашарыңа да алмадым.

Ш а ф и к а. Кайтмыйм инде... Ипием бар! Суым татлы! Эш җитәрлек.

Л ә м и г а. Печәнчеләр чынкый кузгалганчы чәй эчеп кил. Төче коймак пешерермен. Кашшаф абыең яңа бал китерде. Бал — йөрәк ашы. Озак юанма, яме. (*Чыга.*)

Н а и л. Кая, тырма тешең нишләгән?

Ш а ф и к а. Төче коймак яратсам да, төче малайларны җенем сөйми.

Н а и л. Белдем инде, белдем. Көтеп торам. Йә, сүк.

Ш а ф и к а. Гаебен белгән кеше дәшми дә тора белсә икән!

Н а и л. Кушсаң, дәшмәм дә.

Ш а ф и к а. Читкәрәк китеп шакылда. Монда минем урын... Ишелеп йоклап ята бугай...

Н а и л. Кичә бик арылган, Шафика. Алты кибән куйдык. Төнлә дә йоклап булмады. Таң алдыннан оныталганмын... (*Пауза. Наил шакы-шокы тырма белән маташа.*) Нигә кайтып килмисең инде? Әниең көтәр.

Ш а ф и к а. Син сорамас микән дип кайтмыйм.

Н а и л. Менә сорадым.

Ш а ф и к а. Күрмисеңмени? Таң белән сөйләшәм, иртә белән.

Н а и л. Шафика дим!

Ш а ф и к а. Тартарлар ул исемне синнән матуррак, әйтә. Төне буе Ша-фика, Ша-фика дип тәкрарладылар.

Н а и л. Яратам мин сине, Шафика.

Ш а ф и к а. Исән-сау торасыңмы, кодагый? Ишетмәдем.

Н а и л. Кычкырыйммы?

Ш а ф и к а. Барыбер таң җиле алып китәр. Таң җиле — фәрештәләр сулышы. Алар ялганны сөйләми.

Н а и л. Шашып яратам. Үлеп яратам.

Ш а ф и к а. Мин җил белән сөйләшәм! Күкләр белән!

Н а и л. Ни эзлисең син анда?

Ш а ф и к а. Минем әни әйтә, кеше җирдән дә, күктән дә үзен эзли, ди.

Н а и л. Ни кылана бу Ләмига апа? Зиратта кундырды, урман аша уздырды, болында төн саклатты. Инде болыт дип, күк дип шаштыра кызын!.. Әйтсәң, тавыклар көләр... Мә тырмаңны.

Ш а ф и к а. Рәхмәт. Кулыңа рәхмәт, телеңә түгел. Ә хәзер тик кенә утыр. Дәшмә. Тыңла.

Пауза. Еракта кемдер кычкырып уза: «Сугыш! Сугыш!»

Н а и л. Шафика дим...

Ш а ф и к а. Тукта әле.

Н а и л. Печәнчеләр кузгаламы? Соңладылар алар бүген.

Ш а ф и к а. Каян инде бу ямьсез өн? Җирдәнме, күктәнме? Кошлар сайраудан туктады.

Н а и л. Китап укый-укый саташкан, ахры, син, кызый. Бернинди тавыш юк.

Ш а ф и к а. Чыннан да, тып-тын.

Т а в ы ш. «Сугыш! Сугыш!»

Ш а ф и к а. Тыңла әле, тыңла!

Н а и л. Син тыңлаган да бик җиткән.

Ш а ф и к а. Аера алмыйм. Тыңла дим, зинһар.

Н а и л. Тыңлыйм ич инде.

Т а в ы ш. «Сугыш! Сугыш!»

Ш а ф и к а. Баядан бирле шул тавыш ишетелә, ни әйткәнен генә аера алмыйм.

Н а и л. Сугыш ди түгелме?

Ш а ф и к а. Анысын мин дә ишетәм. Ни әйтергә тели соң ул?

Н а и л. Илайныкылар җыелган иде. Донбасстан Рәхми кайткан. Кузбасстан Кәрим. Уралдан Җамалый. Кунакка. Җыен агайне җидесе дә тиле тәүкәл, әллә шулар өелешеп сугышып ятамы? Кичен генә тартма белән акбашларны алып кайттылар. Акбаш күңелне каралта диләр. Җәйләре, сабан туйлары сугышсыз узмый.

П а у з а.

Ш а ф и к а. Син төннәрен бер дә курыкмыйсыңмы?

Н а и л. Куркуның ни икәнен белмим.

Ш а ф и к а. Илайныкылар өелешеп сугышып ята дисең... Рәхми күсәк күтәреп чыга, Җамалый тәртә... Шушындый матур дөньяда нигә сугышып ятарга?

Т а в ы ш. «Сугыш! Сугыш!»

Ш а ф и к а. Тагын кычкыралар!

Н а и л. Тамагына таш кергере. Акыр, акыр... Илайныкылар сугышканга минем сырт сызламый. Үз танаулары кара канга батсын.

Ш а ф и к а. Затсызлар алар. Усаллык каннарында бар...

Н а и л. Ярар, төкер шуларга.

Ш а ф и к а. Мин куркам...

Н а и л. Төнлә курыкмаганны...

Ш а ф и к а. Хәзер куркам.

Н а и л. Җүләр дияр идем, үпкәләрсең.

Чаң кагалар.

Ш а ф и к а. Ишетәсеңме, пожар!

Н а и л. Ут-мазар күренми. Төтен дә юк. Офыклар чипчиста. Тын-тын.

Ш а ф и к а. Чаңны Шафика батыр шәрәфенә кагалардыр дисеңме?

Н а и л. Шулар, Илайныкылар котыра. Узган елны да чаң теленә бишәү асылынып өзеп төшерделәр.

Ш а ф и к а. Йөрәгем сикерә.

Т а в ы ш. «Сугыш! Сугыш!»

Ш а ф и к а. Юк! Бу Илайныкылар кузгаткан гаугагына түгел!

Н а и л. Аз гына утырыйк инде. Син миңа бер сүз дә әйтмәдең.

Ш а ф и к а. Белмәгәндә мин тагын да ныграк куркам! Әйдә!

Н а и л. Кәҗә бәрәне күк сикерәсең!

Сәхнә караңгылана. Бик күп аяк тавышлары. Тып-тын. Өздереп гармун уйный. Саубуллашу җыры.

И р л ә р.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде тузаннар.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Х а т ы н - к ы з л а р.

Бүген төнлә төшләремдә
Кара су, кара урман.
Шул кара су, кара урман
Без аерылырга булган.

Ирләр.

Биек тауның башларында
Җир җиләкләре кипкән.
Китәр вакытларым җитте,
Бир кулларыңны, иркәм.

Хатын-кызлар.

Урак урып, зурат куеп,
Талды безнең беләкләр.
Әллә суларга акты микән
Без теләгән теләкләр.

Берничә көн узган. Печән кибәне янында алар икәү.

Шафика. Сау бул!

Наил. Ашыктырма инде!

Шафика. Иптәшләреңнән артта каласың дим. Ярамый.

Наил. Алар да бик ашыкмыйлар. Әнә!

Шафика. Вакыты шундый, ашыгыр чак.

Наил. Ашыксыннар... Күрәсеңме, монда берәү дә юк.

Шафика. Нигә булмасын? Монда мәңгелек бар! Болын... Елга... Син бу елганың исемен онытма: Чуал!

Наил (*кырыс*). Юк, җиткән сиңа. Туктал укудан. Күзеңне ач, исәр! Сугышка китеп барам.

Шафика. Беләм.

Наил. Белсәң шул... (*Кочакларга тели.*) Без монда икәүдән-икәү генә. Үзем куйган кибән. Син җыйган печән.

Шафика. Кулың телеңә иярмәсен. Тый аны!

Наил. Минем сугышка китүне аңламый бу, икмәк!

Шафика. Анысын аңлыйм. Бу сугышның нигә, кемгә кирәклеген генә аңлап бетермим.

Наил. Үз башыңа төшәсе юк, аңлама!.. Ә егетләр әнә башкача җырлыйлар. «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз» диләр.

Шафика. Аяусыз җыр.

Наил. Туң бәгыреңә барып тидеме?

Шафика. Тиде. Кая тигәнен әйтмим.

Наил. Торма, алайса, ярты чакрым читтә. Кил мондарак! (*Кызны кибән янына тартып китерә.*) Сөясеңме мине, юкмы?

Шафика. Сискәнеп киттем.

Наил. Сөясеңме, юкмы? Белеп китим дим. Шулай сорарга хакым бардыр бит?

Шафика. Әйттем ич, белмим дидем. Кичә әйттем. Өченче көн.

Наил. Инде бүген дә белмәгәч! Өйрәтә торган мәк-

тәбе юк... Яратасың икән, әйт тә бир. Сөясең икән — исбатла.

Шафика. Ничек итеп? Нигә? (*Сак кына үбә.*) Җиттеме?

Наил. Оста! Ансат котылыр идең бугай... Бул минеке!

Шафика. Наил! Мин сине көтәрмен!

Наил. Минеке булып кал син.

Шафика. Синеке?

Наил. Сукырдыр син, икмәк! Сугышка чыгып барам мин, үлемгә. Ишетмәдеңмени? Йә, нишлибез? Моның белән хисаплашмый кала алмыйсың.

Шафика. Оял, Наил. Җир белән күк каршында...

Наил. Күктә түгел мин, кибән янында! Җирдә!

Шафика. Син җирнеке, мин күкнеке. Нинди ерак безнең ара! Күк белән җир ал шәфәкъта генә бергә кушыла... Ә син... мине үзеңнеке итмәкче буласың?.. Көндез дә җир белән күк тоташкан чак була. Күк җиргә яшен ташы булып ярып төшә...

Наил. Әкият сатар чакмы соң, икмәк!

Шафика. Өч көн буе шуны туглыйсың: минеке, минеке... Сузма дим кулыңны!

Наил. Бер үптермәдең, кочтырмадың...

Шафика. Әрсез син бүген.

Наил. Әрсез түгел, кыю.

Шафика. Бүгеннән үзеңә өстенлек сорый башладың. Иңеңә шинель кунмаган әле... Сугыштан соң бездәйләргә нинди сан булыр? Әйтмәм дигән идем, әйттерденең... Бел, мин дә китәм!

Наил. Абзар артынамы? Үртәшмә, кызый.

Шафика. Сугыш башланганын белгәч тә шуны уйлый башладым. Чаң тавышы икебезне дә чакырмадымы әллә?

Наил (*таң калып*). Анаң! Шул җибәрә сине сугышка! Шул! Ул кушкан. Ул котырткан.

Шафика. Ул да.

Наил. Үзе ялгыз каламы?

Шафика. Мин аңа иптәшләрне күп калдырам.

Наил. Кемне?

Шафика. Кырны. Болынны. Аклан чирәмен. Кашка тауны. Зәңгәр Чуалны. Чүке чишмәсенең ак балыкларын.

Наил. Бакадан куркасың, җыланнан. Күркә күреп ике чиләгеңне яньчедең... Китәм дисәң, тавыклар егылып көләр.

Шафика. Мин бака тотарга бармыйм.

Наил. Фашистны белмисең әле син.

Ш а ф и к а. Ул мине беләме? Фашист та мине белми ич. Белсә, илемә басып кермәс иде.

Н а и л. Немец түгел, күршемдә яшәп мин белмәгәнмен сине! Агач икәнсең син, туң күчән, боз кисәге.

Ш а ф и к а. Ә син куркак!

Н а и л. Нәрсә-ә-ә!

Ш а ф и к а. Үләргә әзерләнү — куркуның ахыр чиге. Куркак мең үлә дигәннәр.

Н а и л (*таң калып*). Кем сөйли моны? Гали батырмы? Гыйльфан Батыршинмы? Папанинчымы? Үләм дигәнем булмады, булмас та.

Ш а ф и к а. Нәфесеңә ирек таләп иттең! Якамаябышып давайладың. Курку түгел идеме бу? Батып барган кеше генә туктаусыз бер сүзне кычкыра, башкача аның чарасы юк. (*Йөгереп чыгып китә.*)

Н а и л. Их син, акыллы баш!

Л ә м и г а керә.

Л ә м и г а. Минем кызым кайда?

Н а и л. Солдат кызыңмы?

Л ә м и г а. Кирәк икән, солдат та булыр һәм булдырыр.

Н а и л. Әнә. Зәңгәр Чуалда зәңгәр җеп агыза.

Л ә м и г а. Көлмә борынгы гадәтләрдән. Җепнең бер очы кендек каны тамган җирдә калыр. Икенче очын үзе белән алыр. Югалтмый саклар... Наил, сакла минем кызымны.

Н а и л. Мин бит Алла түгел, Ләмига апа.

Л ә м и г а. Кирәк чагында Аллага юлны үзем табармын... Җирдә юл табу читен кайчакта.

Ш а ф и к а керә.

Ш а ф и к а. Әни! Җепнең очы агып китте! Калганын чылатып үзем белән алам!

Л ә м и г а. Тукталган бер җиреңдә, эчкән бер суыңда җебеңне чак-чак кына өзеп агыз... Чир-чорларың аксын... Яман күзләрдән сакласын... Исән-аман йөр. Яман юлларга тап булма! Уйладыңмы? Ниятләдеңме? Ниятең ныкмы?

Ш а ф и к а. Нык, әни. Бик нык.

Л ә м и г а. Калам дисәң, бер сүзем юк.

Ш а ф и к а. Әни! Тигез буласым килә. Кемнеңдер янымда үсеп китүен теләмим. Ул калкыр да калкыр, ә мин аның күләгәсендәме? Сөймим эт кояшы — күләгәне!

Л ә м и г а. Ни әйтим? Ил алдында бурычларым күп, ә улларым юк. Синең җилкәгә төшә. Шафика, син миңа ул да, кыз да!

Н а и л. Күрше белән күрше арасы җир белән күк арасы кадәр икән! Икмәк!

Л ә м и г а. Яуга чыкканда барың да бер булырга кирәк, Наил. Юлчы тауда, егет яуда сынала.

Ш а ф и к а. Рәхмәт, әни.

Л ә м и г а. Исән йөрегез, сынатмагыз.

Н а и л. Күз яшьләрең юкмы әллә синең, Ләмига апа?

Л ә м и г а. Сугыш әле башлана гына! Бүгеннән үк җылый башласаң, күз яшең җитмәс.

Н а и л. Без барып җиткәләгәнче бетеп тә куяр әле!

Л ә м и г а. Белгән юк... Белгән юк...

Саубуллашалар. Ләмига ялгызы. Җыр.

И р л ә р.

Актым мин сулар булып,
Тукталдым күлләр булып.
Күз алларымда торырсың
Чәчәкле гөлләр булып.

Х а т ы н - к ы з л а р.

Өй түбәсе кыйгач такта,
Анда баскан күгәрчен.
Җитәр язлар, сайрар кошлар,
Шунда ничек түзәрсең?

К а ш ш а ф керә.

К а ш ш а ф. Озаттыңмы, ана?

Л ә м и г а. Киттеләр. Әнә тузан уйный.

К а ш ш а ф. Кал дип бер тапкыр да әйтмәдеңме?

Л ә м и г а. Юлы гадел. Үзе: «Барам!» — диде. Баламның гадел юлына аркылы төшимме?.. Хәер-фатихамны биреп озаттым.

К а ш ш а ф. Әллә җыламыйсың да, Ләмига?

Л ә м и г а. Теге төндә, Асылгәрәй белән хушлашкан төндә, күземнең күле кипте... Җылыйм җылавын... Бердәнберем бит! Балам.

К а ш ш а ф. Йөрәк парәң! Өметең!

Л ә м и г а. Борчылуым да бар: кош оя типмәс таңда туды ул... Язын... Шунысы шикләндерә.

К а ш ш а ф. Нидән шикләнәсең?

Л ә м и г а. Сак булсын. Яманнан. Хыянәттән. Сатылудан. Әсирлектән. Гариплектән. Җиңеп кайтсыннар.

К а ш ш а ф. Яшермичә әйт әле: сынавыңмы бу синең?

Л ә м и г а. Сынавым да. Ул моны белә. Моңарчы сынаганнар уен булып калды. Язмыш әнә нindине әзерләгән. Кайтыр юлы ак булсын! Сау булыгыз, оланнар!

К а ш ш а ф. Үзең дә сау бул, Ләмига. Күпне күрдең, тирәнтен кичерәсең. Син — җирнең хәтере. Мин шулай уйлыйм. Мин синең кебек үк була алмас идем.

Л ә м и г а. Кашшаф абый, үзең дә ике улыңны озаттың бит!

К а ш ш а ф. Киттеләр.

Л ә м и г а. Кайтыр юллары өзелмәсен!

Сәхнә караңгылана. Урман авызы. Агачлар шәрә. Солдат киеменнән Н а и л белән Ш а ф и к а.

Н а и л. Яфраксыз урман үлгән кебек... Октябрь!

Ш а ф и к а. Син һаман үлем турында.

Н а и л. Киресенчә, сине күрүгә күкрәктә көч арта.

Ш а ф и к а. Авылдаш! Моңарчы күрешкәләп тордык, хәл белешеп.

Н а и л. Язмышка рәхмәт... Шәфкать туташы булуың белән котларгамы сине?

Ш а ф и к а. Соңга калдың. Шәфкать туташы моннан элегрәк туды. Абайламый калдың.

Н а и л. Соңга кала торган хаталыгым бар икән минем!

Ш а ф и к а. Иң беренче тапкыр операция өстәле янына баскач булды анысы... Авыр яралы яшь кенә егетне кертеп салдылар. Сакал-мыек та чыкмаган әле үзенә... Миңа аягын тотып торырга куштылар... Күземне чытырдатып йомдым. Берзаман, аңыма килсәм, киселгән аякны күтәреп коридорда йөрим икән...

Н а и л. Егетләр миннән көләләр...

Ш а ф и к а. Ә миннән көлмәделәр...

Н а и л. Моңарчы кызлар кочып караганым юк дигән идем, күземне ачырмыйлар хәзер. (*Пауза.*) Теге... ранный егет элемтәче идеме әллә?

Ш а ф и к а. Белмим.

Н а и л. Каян элемтәгә китереп тыктылар... Элемтәченең кайда йөрүен беләсеңме син?

Ш а ф и к а. Штаб тирәсендәдер инде.

Н а и л. Иң алда!

Ш а ф и к а. Иң алда разведчиклар... Кызыгам шуларны ишетеп!

Н а и л. Иптәшләр көлә... «Их, солдат!» диләр. Үлә калсаң, теге дөньяда ни сөйләрсең диләр?

Ш а ф и к а. Ә син бу дөньяда сөйләрлек итеп яшә!

Н а и л. Аерылмас борын икебез ике якка карыйбыз. Бул минеке!

Ш а ф и к а (*паузадан соң*). Син алдан кузгал, якташ.

Н а и л. Шәфкатьсез син, җансыз.

Ш а ф и к а. Хәзер утка керәм дип, ташлама сорый-

сыңмы? Юкка. Без тигезләштек. Җырдагы кебек. «Дан приказ ему на запад, ей в другую сторону».

Н а и л. Үзеңә дә берне җырлап биримме?

Ш а ф и к а. Җырлачы, Наил. Ичмасам, якты бер хатирәң калыр.

Н а и л.

Стенада сәгать суга...
Минутын ялгыштырмый.
Арабызда кара урман,
Шул безне кавыштырмый.

Ш а ф и к а. Рәхмәт, Наил. Ә хәзер хушлашыйк. Гадәт буенча хатын-кыз озатып кала.

Н а и л. Команда ишетелмәде бит әле.

Ш а ф и к а. Үтенәм, кит.

Н а и л. Кара суда зәңгәр җеп агызасың бармы?

Ш а ф и к а. Бар шул.

Н а и л. Элемтәгә өйрәттеләр... Теләсәң кая, хет дошман тылына телефон суза алам... Синең күңелгә генә элемтәм юк. Таш син. Анаң кебек. Ул ничә еллардан Кашшаф абыйны тинтерәтеп йөртә.

Ш а ф и к а. Хурлыйм дип, син мине мактадың. Әни кебек буласы иде!.. Хуш! Минем зәңгәр җебем синең кайгыларны да алып китсен!

Сәхнә караңгылана. Җыр. Җыр һаман ишетелеп-ишетелеп китә. Урман. Көз. Күл буе. Йөк машинасы. Машина янында Ринат белән Шафика. Ринат карта карый.

Р и н а т. Хәзер, хәзер...

Ш а ф и к а. Син безнең кайдалыкны тәгаен беләсеңме?

Р и н а т (*ярсып*). Үзебезнең кайдалыкны картага карамыйча да беләм мин! Без нәрсә... Тыныч күл буенда. Әнә елга, күрдеңме? Күлгә коя. Әнә күпер. Без барасы юл. Күпер аша... көнчыгышка! Ләкин... Дошман кайда икән? Дошман...

Ш а ф и к а. Кырыгынчы елда чыккан картада фашистның кайдалыгын күрсәтмәгәннәрдер инде.

Р и н а т (*ачулы*). Кайда да кайда... Ә ни файда?

Ш а ф и к а. Күлнең исемен генә сорадым.

Р и н а т. Нигә ул сиңа? Исемсез күл. Төпченмә юкбарны!

Ш а ф и к а. Нишләп төпченмәскә? Күпме вакыт уратып йөртәсең? Ни олы юлга алып чыкмыйсың, ни санбатка барып җитә алмыйбыз.

Р и н а т. Санбатыңа илтеп җиткерермен, курыкма.

Ш а ф и к а. Машинаңда нәрсә соң синең?

Р и н а т. Машинада? Күрәсең ич, токмач, ярма, лавр яфрагы. Кучтәнәчләр.

Ш а ф и к а. Нигә кузгалмыйбыз соң без?

Р и н а т. Радиатор кызган.

Ш а ф и к а. Салкын су тутырдың ич син аңа.

Р и н а т. Тутырса? Машинасы кызган шоферның да азрак суынасы юкмы? Мә, ипи аша, карының ачкандыр.

Ш а ф и к а. Ач та, тук та түгел тамак.

Р и н а т. Эләккәндә ашап кал! Сугышта шуны онытма: туры килгәндә корсагыңны шыплап тутыр.

Ш а ф и к а. Тупас сөйләшәсең.

Р и н а т. Детдом малае. Бездә шулай сөйләшәләр... Армиягә алындым. Анда да шулай сөйләшәләр икән!

Ш а ф и к а. Синең беркемең дә юкмыни? Туганнарың?

Р и н а т. Юк. Егерме беренче елгы ачлыкта...

Ш а ф и к а. Ә хатының кайда?

Р и н а т. Кайдадыр йөри, юньсез!

Ш а ф и к а. Ничек?

Р и н а т. Күрешә алган гына юк! Белмим дә әле, кемдер, ниндидер... Өлгермәгән әле мин. Яшел!

Ш а ф и к а. Машинаны хәтәр йөртәсең.

Р и н а т. Анысы детдомнан ук. Мотор яратам.

Ш а ф и к а. Ни хәтле узып, исемеңне сорамадым.

Р и н а т. Ринат мин.

Ш а ф и к а. Русларда да шундый исем буламыни?

Р и н а т. Кем сиңа рус ди? Синең шикелле үк чикылдап торган татар.

Ш а ф и к а. Исән булсаң, әллә ниләр ишетерсең.

Р и н а т. Үзең бит кабарган күркә күк утырып киләсең. Исәнме! Исем-шәрифләрең ничек?

Ш а ф и к а. Әни Шафика кушкан. Әти юк... Әни бер башы...

Р и н а т. Элек Спарта дәүләтендә ир баласы юкларны сугышка җибәрмәгәннәр... Син дә ялгыз икән... Үзеңнән соң кылган эшләрең, һич югында, балаларың да калмый икән, нигә туып торырга? Сан тутырыр өчен генә яшисе килми...

Ш а ф и к а. Бусын рас әйттең. Тагын самолетлар!

Р и н а т. Ишетәм. Фашистлар!

Ш а ф и к а. Бер дә ялгышмадың моңарчы.

Р и н а т. Алар!

Ш а ф и к а. Яхшы чакта ычкынып калыйк.

Р и н а т. Ашыкма. Кая очалар икән, чамалыйк.

Ш а ф и к а. Безнең өскә киләләр.

Р и н а т. Әйе.

Ш а ф и к а. Китик тизрәк, китик! Монда киләләр, монда! Безне күрсәләр... Качыйк! Самолетлар гүли.

Р и н а т. Курыкма.

Ш а ф и к а. Кем курка? Беттек!

Р и н а т. Тукта!

Ш а ф и к а. Бетердең башымны! Гүргә күмәргә йөрткәнсең икән уратып. Әни!..

Р и н а т. Тукта диләр сиңа. Тын!

Ш а ф и к а. Качыйк, әнекәй генәм, качыйк! (*Чаба башлаган җиреннән Ринат аны тотып ала.*)

Р и н а т. Тилермә, Шафика.

Ш а ф и к а. Бетүләрем гел шушы икән!

Р и н а т. Ят!

Ш а ф и к а. Тотма мине! Җибәр. Җиб-бәр! Бетерәсең киләме? Әни! Әнекәй генәм!

Самолет моторлары улый, бомба шартлый.

Р и н а т. Тыпырчынма. Тешләмә кулны!

Ш а ф и к а. Үлдем! Беттем! Әни, бәхил бул!

Р и н а т. Үлмисең, үлмисең. Тешләмә генә.

Ш а ф и к а. Беттем... Кит, кит!

П а у з а.

Р и н а т (*торып карана*). Тор, Шафика. Киттеләр. Тор, тор.

Ш а ф и к а. Ишетмим.

Р и н а т (*шаяртып*). Мин сине я-ра-там!

Ш а ф и к а. Китсәнә... Колакка мамык тутырган кебек. (*Тора.*) Ничек безне күреп алганнар алар?

Р и н а т. Безне түгел, күперне. Әнә көйрәп ята. Җимерделәр.

Ш а ф и к а. Үлдем дип торам.

Р и н а т. Җүләр! Машинага таба чаба! Анда токмач дип белдеңме әллә, песнәк?

Ш а ф и к а. Нәрсә соң анда?

Р и н а т. Граната тартмасы белән токмач тартмасын да аера алмаган башың белән фронтта нишләмәкче буласың син?

Ш а ф и к а. Мин алдашырга өйрәнмәгән.

Р и н а т. Алдаумы бу, чыпчык? Хәйлә, стратегия, сер!

Ш а ф и к а. Менә, йомшаклыгымны күрдең дә, хәзер үртәшәсең. Әле песнәк, әле чыпчык.

Р и н а т. Җүләр! Бомбежкага беренче эләгүеңме?

Ш а ф и к а. Беренче дип... Беренче!

Р и н а т. Сугышта бөтен кеше курка. Курыкмыйм дигәннәргә ышанма. Кеше үлемсез түгел. Ләкин сугышта гына үлми кеше, барыбер үлә. Аның үлемсезлеге дә бар — иле, туган теле, мәхәббәте, нәселе... Шулар юата, шуларны уйлыйсың да куркуга баш бирмисең.

Ш а ф и к а. Башта бик курыктым... Аннан күңелгә бер-бер артлы акылсыз, салкын уйлар килде.

Р и н а т. Юлдашымның ниләр уйлаганын беләсе килә килүен!

Ш а ф и к а. Нәрсәгә допрослыйсың? Хуҗа булды тәки!

Р и н а т. Юлдашымның дидем! Алда ниләр булмас дисең?

Ш а ф и к а. Урыны аулак дим... Икәүдән-икәү генә дим... Бу егет форсаттан файдаланып мине мәсхәрәләп ташламасын дим...

Р и н а т. Син бомбалардан түгел, миннән курыккан, алайса? Ха-ха-ха!

Ш а ф и к а. Авыр гәүдәң белән миңа шуйдый капландың, котым калмады.

Р и н а т. Торып машинага чаба башлагач мин дә каушадым. Гранаталар детонациядән дә шартлый башлый.

Ш а ф и к а. Кузгалабызмы?

Р и н а т. Кузгалырбыз... Тик кая барырга?

Ш а ф и к а. Мин сине белмим. Мин санбатка барып җитәргә тиеш. Югыйсә әллә ни уйларлар.

Р и н а т. Күпер җимерек.

Ш а ф и к а. Юлда барганда, ичмасам, өмет җылыта...

Р и н а т. Нинди авырлык килсә дә өметеңне югалта күрмә!

Ш а ф и к а. Кеше сүзен сөйлисең.

Р и н а т. Үз сүзем! Мин сугыш башланганда армиядә идем бит, чиктә. Машинада. Шуннан бирле киләм... Егетләр анда калды. «Их, гранаталар күбрәк булса!» — дип, танкларга каршы сугышып үлделәр. Онытырлык түгел... Авыр эштә бер көн икегә санала. Сугышның һәр көне — бер атна. Шуннан чыгып исәпләсәң, хәзер миңа ничә яшь? Егерме бер түгел, күбрәк. Сиңа ничә?

Ш а ф и к а. Барын да белер иде бугай.

Р и н а т. Димәк... Бүген кичергәннәреңне дә өстәсәң, сиңа да... Уһу... бүрек белән бәреп егарлык кына түгел! Кузгалдык. Килешеп куябыз: юлда карышмаска, һәр сүземә буйсынырга. Кәҗәне монда калдыр!

Ш а ф и к а. Көт бер генә минут. (*Йөгереп, елгада җеп очы агызып килә.*)

Р и н а т. Ни ырымладың син?

Ш а ф и к а. Үзем беләм... Хәзер без туры юлны табарбыз!

Чыгалар. Мотор тавышы. Кайдадыр аталар. Тынлык. Төн. Р и н а т белән Ш а ф и к а керәләр.

Р и н а т. Ырымыңның файдасын күрмим, кызый.

Ш а ф и к а. Без кайда? Нигә болай урап-чурап йөрибез? Нигә дәшмисең?

Р и н а т. Син монда калып тор, мин разведкага барып киләм.

Ш а ф и к а. Миңа санбатка барырга боерылган. Нигә адаштырып йөртәсең син мине?

Р и н а т. Кычкырма. Тын! Урман — колак ул, онытма.

Ш а ф и к а. Бу ни бетмәгән урман булды бу? Тагын төнгә калдык.

Р и н а т. Мә, ике кулыңа ике граната.

Ш а ф и к а. Әйем, йә шартлап китәрләр.

Р и н а т. Мин кичке уенга җыенмыйм, Шафика. (*Пауза.*) Бәлки, мин бөтенләй әйләнеп кайтмам.

Ш а ф и к а. Кайтмый кара! Командирыңа әйтеп...

Р и н а т. Сабый! Минем командирларның кайда ятып калганын белсәң син...

Ш а ф и к а. Мин синнән калмыйм.

Р и н а т. Тыңла, алайса! Тик шыр җибәрмә... Һаман да төшенмисеңмени соң син? Уңга барып карадыкмы? Анда дошман. Сулга каерылдык, анда танклар. Фашистлар. Хәзер бер юнәлештә генә өмет калды: алга!

Ш а ф и к а. Ник башта алга бармадык соң без?

Р и н а т. Чөнки анда да дошман иде! Олы юлга, алар өстенә чак барып чыкмадык. Мотоциклчыларны күрдеңме?

Ш а ф и к а. Алар безнекеләр түгел идемени?

Р и н а т. Сине борчымаска иде исәп... Ничек тә ычкынырбыз, юлын табарбыз дип өметләндем... Гранаталарны илтеп җиткерергә иде тизрәк! Хәзер без олы юлдан ерак та түгел. Алда зур авыл булырга тиеш. Олы юлдагы авылга фашист кермәгәндер дип әйтә аласыңмы? Юк! Тик син курыкма.

Ш а ф и к а. Мин курыкмыйм.

Р и н а т. Машина куелыкта, күренми. Хәзер ипләп кенә авыл тирәсеннән әйләнеп килик. Хәвеф-хәтәр юк икән, юлга чыгып карарбыз.

Ш а ф и к а. Әгәр анда хәвеф-хәтәр булса?

Р и н а т. Булуы мөмкин, бик мөмкин. Анда да җаен табарбыз.

Ш а ф и к а. Чү, нидер кыштырдады.

Р и н а т. Менә син дә разведчик булып барасың.

Ш а ф и к а. Кемдер йөри!

Р и н а т. Граната ыргыта beləсеңме?

Ш а ф и к а. Мәктәптә өйрәтеп азаплаганнар иде.

Р и н а т. Кемдер болай таба килә. Абына-сөртенә чаба!

Ш а ф и к а. Берне тондырып карыйммы?

Р и н а т (*кычкырып*). Тукта! Кем килә?
Ш а ф и к а. Туктады.
Р и н а т. Кем син? Чык, атам!
Ш а ф и к а. Эндәшми! Дошман!
Л а р и с а. Бу мин.

Керә. Кулында төенчек.

Ш а ф и к а. Хатын-кыз түгелме?
Р и н а т. Хәзер бөтен кеше шикле. (*Ларисага.*) Нишләп йөрисең монда?
Л а р и с а. Адаштым.
Р и н а т. Каян киләсең?
Л а р и с а. Тегеннән мин.
Р и н а т. Кая барасың?
Л а р и с а. Монда.
Р и н а т. Тегендә-монда йөрер чакмы хәзер? Кулыңда нәрсә?
Л а р и с а. Абыкаем, зинһар, мине үтермәгез.
Р и н а т. Кайсы авылдан?
Л а р и с а. Сез үзегез кемнәр соң?
Ш а ф и к а. Үзе сораша башлады әле бу!
Л а р и с а. Ходаем, монда хатын-кыз да бар икән.
Р и н а т. Монда хатын-кыз юк. Монда Кызыл Армия сугышчылары гына бар.
Л а р и с а. Сез чыннан да кызылармеецлармы? Алдамыйсызмы? Армия өченче көн үк узды моннан... (*Якынрак килә.*) Кызыл йолдызлар! Үзебезнекеләр.
Р и н а т. Хәзер сөйли аласың. Кая барасың? Каян?
Л а р и с а. Үзебезнекеләр... Зур авылдан мин. Немецлардан качып барам.
Р и н а т. Сездә дә фашистлармы?
Л а р и с а. Кайда гына юк ул каһәрләр хәзер... Минскида...
Р и н а т. Ничә көн радио тыңлаган юк! Йә, йә...
Л а р и с а. Бөтен җирдә алар! Авылларда, шәһәрләрдә...
Р и н а т. Әйе.
Ш а ф и к а. Без камалышта. Ачыкланды...
Л а р и с а (*куркып*). Сез безнеңчә сөйләшмисез!
Р и н а т. Безнеңчә сөйләшәбез. Телебез генә башка. Татарлар без. Татарстаннан. Иделдән. Казаннан. Ленин Казаныннан.
Л а р и с а. Үзебезнекеләр икән. (*Елый.*)
Ш а ф и к а. Үзебезнекеләр, апа, үзебезнекеләр.
Л а р и с а. Якшәмбедә немецлар керде. Авылдан байтак кешебез гаскәр белән чигенде. Ә мин дивана, шыр тиле, сантый! Калдым... Ни булыр, димен? Тол хатынга кем тисен... Сугыш ул ирләр эше, димен... Фашистлар,

димен, килгән юллары белән тиз генә китәрләр, димен... Безнекеләр тиз кайтыр микән?

Ринат. Нигә качасы иттең?

Лариса. Шиккә төштем. Бер дә китәргә килгәндәй кыланмыйлар. Актык чиккә җиткергәне шул булды, авылыбызга алпавыт кайтты.

Шафика. Алпавыт?

Лариса. Күрсәгез иде, и-и-и... Безгә янәшә урамда гына больница. Сукыр әчәгемне шунда кистеләр минем. Элек шул алпавыт йорты булган. Пан! Пан Терлецкий! Шул өч-дүрт немецны ияртеп кайтты да чирлеләрне өерләп куып чыгарды.

Ринат. Син шуннан китәргә булдыңмы?

Лариса. Таяк белән яра-яра куалар, мин сиңа әйтим! Шуннан бар халыкны чиркәү каршысына җыйдылар. Офицер сөйләде, Терлецкий тәрҗемә итеп торды. «Совет власте мәңгегә бетте» диделәр.

Шафика. Кешеләр шуңа ышаналармы?

Лариса. Төрлесе бар. Кая карама фашистлар!

Ринат. Безнең детдом да элекке алпавыт утарында... Безнең малайларны да куарга алпавыт кайтачакмы?!

Лариса. Бүген Терлецкий мине чакырып кертте дә: «Анаң гомере буе безнең өйне җыештырды, әтиең юртакларны карады. Хәзер синең чират, марш кухняга!» — дип акырды. Тавышы, нәп-нәзек, мыегы җеп кебек, саламдыр сыйраклары... Ә күзендә яман ут!.. Кичкә кырын өй җыештырырга чакырып керттеләр. Аны-моны караштырырга маташам, берзаман арттан берәү килеп асылынды. Карасам, пан үзе! Караватка ук сөйри бу мине! Тибеп очырдым да чыгып качтым менә... Әни бер кыерчык икмәк белән вак-төяк кенә әзерләп өлгерде...

Ринат. Синең хәлләр дә әйбәттән түгел икән.

Лариса. Яман, бик яман! Абыкаем, җаныкаем, зинһар, мине коткарыгыз. Кая барырга хәзер? Нишләргә?

Шафика. Нишләргә кирәклеге билгеле... Кая барырга дигәндә, белмим...

Лариса. Уйларга да, кузгалырга да куркам. Сезнең кычкырганны ишеткәч, тәмам үлдем.

Ринат. Ияр безгә, апа.

Лариса. Сез кая юл тотасыз соң?

Шафика. Үзебезнекеләрне табарга кирәк.

Лариса. Үзебезнекеләр... Калды микән инде алар? Бармы икән? Саранча кук бастылар, явызлар.

Ринат. Менә ич! Каршыңда басып торалар үзебезнекеләр. Күрмисеңмени?! Әйдә, апа! Калма! Син юлларны беләсең, бездә көч, киттек бергә-бергә!

**Атыш тавышлары. Фонарь утлары уйный. Этләр өрә. Сәхнә караңгылана Урман. Көз. Җепшек кар ява. Машина буксовать иткән тавыш. Ринат, Шафика, Лариса тавышы. Машина бераздан чинап туктый. Өчесе дә арып-талып сәхнәгә керәләр.**

Л а р и с а. Үләм... Сеңерләрем өзелде. Буыным калмады. Сөяк-санакларым көл булды... Сез дә, күрегезче, кыяфәтегезгә карарга куркыныч.

Р и н а т (*паузадан соң*). Бер төрерлек тәмәке калды.

Ш а ф и к а. Монда килегез, апа, монда корырак.

Р и н а т. Утырыгыз, утыр, ардыгыз. (*Пауза.*) Соңгысы булганы өчен мин аны тартмый торам. Кирәк булып куюы бар. Үзем тартуны ташлыйм. Саулыкны сакларга кирәк.

Л а р и с а. Янам. Аякларым манма су.

Ш а ф и к а. Тагын ява.

Л а р и с а. Бездә шулай инде. Көзен баткан кояш язын гына якты чыраен күрсәтә. Көн-төн ишә.

Р и н а т (*картасын карап*). Унике чакрым уздык.

Л а р и с а. Уздык дисеңме? Өстерәлдек диген инде.

Ш а ф и к а. Кичәгедән кимрәк.

Л а р и с а. Кыз чагымда машинага утырып йөрү турында хыяллана идем мин. Күрәчәгемә ашкынганмын икән... Шул аяксыз аркасында җык күрәбез. Кара инде бу кулларымны, кабартма-кабартма шеште бит! Сызлый, үтерә.

Ш а ф и к а. Икмәк биримме, апа? Ринат, син дә аша.

Р и н а т. Юк, юк... Унике километр... Бүген беренче тапкыр кешеләр очрады. Алар безне күрүгә шырлыкка кереп качты... Берәр әмәл уйлап тапмасак, бензин бетә.

Л а р и с а. Синең бу хәсрәт машинаң күз яше белән бармыйммы? Туйганчы бер җылар идем! Дөньяны баскандыр бу кара козгын фашист мәлгунь. Юлларга баш тыгарлык түгел, танклары улый. Сукмакларда, авыл аралnetwork мотоцикллары. Күккә күтәрелеп карармын димә, анда да алар!

Р и н а т. Нигә качты теге кешеләр? Шулай ук хәлләр яманмыни?

Ш а ф и к а. Куркытмагыз әле, апа. Ашап ал, Ринат, тамагыңа капмыйсың.

Р и н а т. Үзең, үзең, Шафика!..

Л а р и с а (*җиргә капланып*). Беттек!

Ш а ф и к а. Самолетлар!

Л а р и с а. Бер, ике, өч... Йөз! Меңǃ.. Мәскәүгә очалар! Киткәндер инде, Мәскәү дә тормас!

Р и н а т. Апа! Күп һәм кирәкмәгәнне сөйлисез! Беләсезме, немец самолетларында нинди җайланма бар? Алар куркаклар сөйләшкәнне ишетә алалар!

Л а р и с а. Булыр, булыр. Бетте, дәшмим.

Ш а ф и к а. Уздылар... Уф... (*Ларисага.*) Сүзегез ошамый, апа. Алай «бетте дә бетте» дип аһ орырлык булгач, алпавыт Терлецкийның ыштанын юарга гына калырга иде!

Л а р и с а. Мин ни дигән ул тиклем? Синең фашистны күзмә-күз күргәнең юк. Күргәч сөйләшерсең.

Р и н а т. Бензин бетеп килә...

Ш а ф и к а. Кая кадәр җиткерербез?

Р и н а т. Үзебезнекеләргә кадәр.

Л а р и с а. Кайда соң алар үзебезнекеләр?

Р и н а т. Кайда булса да бар алар. Бар! Самолетлар очамы? Парадка очмый ич алар. Бар! Бензин бетсә этеп барырбыз! Үзебезнең егетләрне табарга тиеш мин. Барырбыз. Барабыз ич әле! Болай да ярты юлны этеп барабыз.

Л а р и с а. Шул нәләт суккан машина булмаса, әллә кайчан...

Ш а ф и к а. Машинада нәрсә икәнен беләсеңме?

Л а р и с а. Күз бар, күрәм! Тик аннан ни файда? Фронт аша узармын дисезме? Үзегезне харап итәрсез, мине.

Ш а ф и к а. Ринат! Апаның сүзендә дөрес бер тармак бар. Ардык, ачыктык. Бик. Тирә-якта дошман. Юлларда алар, баш тыгарга куркыныч. Безне моңарчы сазлык, батфаклыклар коткарды. Шулар ук безнең башка җитәр дә, ахры. Бензин ахыр чигенә җитте. Аннары ни?

Р и н а т. Юк.

Л а р и с а. Кызыл Армия синең бер машина гранатаңа калганмы?

Р и н а т. Юк! Теләсәгез сез икәү китегез. Мин калам. Бензинын да юнәтермен, юлын да табармын. Бер машинамы, икеме, эш анда гына түгел. Күрдем мин. Безнең егетләр: «Их, гранаталар!» — дип, танк астында калып үлделәр. Мин алып барып җиткерәчәкмен.

Л а р и с а. Син батып үләчәксең. Безнең урманнарны белмисең син. Яңгырлар болайга киткәч, аннан машина түгел атлы да уза алмый. Тәбе ул безнең урман. Ә кеше анда тычкан баласы!

Р и н а т. Шафика! Бу апа кем сүзен сөйли, ишетәсеңме?

Ш а ф и к а. Чамалыйм!

Р и н а т. Терлецкий тегермәненә су коя!

Ш а ф и к а (*аны тотып*). Тынычлан.

Р и н а т. Ат... Өченче көн иясез атлар күрдекме? Ат табарга тырышып карыйм.

Ш а ф и к а. Ринат... Ташлап китәр димә. Юк, ташламыйм. Нишләсәң дә мин синең янда калам. Мин көчле. Куркак та түгел. Машинаңны этәрмен, чыбык ташырмын, агач кисәрмен.

Л а р и с а. Син япь-яшь... Безне үтерәчәкләр болай.

Р и н а т. Без үзебезнекеләрне табарга тиеш. Алар белән кушылырга. Үләргә ярамый. Рөхсәт юк! Югалсак, безнең хакта ни уйларлар? Ни әйтерләр?!

Л а р и с а. Моңарчы яшереп килдем. Авырыйм мин. Тәнем кыза.

Ш а ф и к а. Авырыйсыз, беләм.

Р и н а т. Авыру — тере кеше әле ул. Хәзер кузгалабыз. Төнгә чаклы күпмедер уза алабыз бит! Аннан берәр яры ат юнәтеп булмасмы.

Ш а ф и к а. Өзмик өметне.

Р и н а т. Чүгез әле!

Л а р и с а. Самолетлар! Беттек!

Р и н а т. Түгел. Артиллерия. Туптан аталар. Димәк, фронт ул хәтле ерак түгел. Мин хәзер чыбык кисәм. Көлтәкөлтә бәйләп юлга түшим. Без котылырбыз. Чыгарбыз.

Ш а ф и к а. Көлтәләрне мин ташып торам, Ринат.

Р и н а т. Син ял ит, Шафика. Ял кирәк сиңа. Ял. (*Чыга.*)

Л а р и с а. Баш әйләнә. Дөнья зыр-зыр килә.

Ш а ф и к а. Аталар... (*Пауза.*) Апа, моннан болай чирең турында аңа белдермә. Минем маңгайны тотып кара әле.

Л а р и с а. Әллә син дә янасың инде?

Ш а ф и к а. Түз. Тешең кысып түз!

Л а р и с а. Бар икән. Үзен-үзе җәлләмәгән кешеләр дә бар икән.

Ш а ф и к а. Чыда! Сукранудан файда юк. Ишетеп торасың, аталар. Немец башына ява бу туплар.

Р и н а т керә.

Р и н а т. Ягез, кызлар, кузгалып карыйк! Без узарбыз! Узарбыз. Бирешмәгез генә!

Чыгалар. Җыр. Сәхнә караңгылана. Көз. Салкын. Блиндаж янында Ш а ф и к а ялгызы. Л а р и с а керә. Ул шинель киеп өлгергән, башында шәльяулык.

Л а р и с а. Егетең кайтмаган икән.

Ш а ф и к а. Каян белдең, Лариса апа?

Л а р и с а. Көзгегә кара.

Ш а ф и к а. Кайтмады шул. Көтәм.

Л а р и с а. Ашханәдән килешем. Камалыштан чыгуымны белгәннәр дә көне-төне сыйлыйлар мине. Ничә килога артканмындыр, чын. Әле менә тирли-тирли биш чынаяк уттай кайнар чәй эчтем. Шикәр белән! Авызым көя, ә эчем тагын да кайнарракны сорый. Кара әле, муен тамырыма чуан чыгарга маташамы? Үтереп сызлый, төннәрен йоклый алмыйм.

Ш а ф и к а. Аз-маз кызарган.

Л а р и с а. Каным әшәке минем. Туңарга һич ярамый, чуан баса. Өченче ел кияүгә чыга язып калдым. Шул чуан гаепле. Егетем районда эшли иде, киномеханик. Авылга кунакка кайтты. Ә минем... чуан гына... Утыра да алмыйм. Басып торабыз. Җилкәдә дә чуан, күкрәктә дә. Җилкәгә кулын сала, алып ташлыйм. Күкрәккә үрелә, боргаланам.

Ш а ф и к а. Туеңа хәтле төзәлер.

Л а р и с а. Очты инде туйлар. Ачудан күрше кызын алды-китте егетем...

Ш а ф и к а. Ничә яшьтә соң син, апа?

Л а р и с а. Егерме биштә. Картрак күренәмме? Шулай диләр шул.

Ш а ф и к а. Көлмисең дә, елмаймыйсың да...

Л а р и с а. Көләрлекме соң?

Ш а ф и к а. Елар чакта көлә белергә кирәк, апа!

Л а р и с а. Юк, сугыш хатын-кыз эше түгел.

Ш а ф и к а. Сугыш барыбызга да тигез төшә.

Л а р и с а. Алайса, мин башкача хатын-кыздыр. Өй яратам мин. Өй тавыгы диләр иде миңа. Стенада пар аккош чигелгән келәм... Чәчеңне таратып ак мендәрдә ятасың да ятасың... Син мине тыңламыйсың!

Ш а ф и к а (*карап*). Ринат күренми.

Л а р и с а. Менә бит... Ни җәфалар күреп камалыштан котылып чыктык... Теге егетне әйтәм, Ринатны, рәхмәт инде, сине, мине коткарды. Җен икән. Ул булмаса икәүләшеп ябышып ката идек. (*Шыпырт.*) Аны тагын особый отделга чакырдылармы?

Ш а ф и к а. Шунда.

Л а р и с а. Әй, курыктым да мин анда! Теге, чәчен керпе әнәсе күк кенә калдырган сары егет бар бит, базык кына особист, кадап-кадап сорый инде менә!.. Әйткәнгә ышанмый, төпченә. Машинасын ташлаганга сүгәләрме Ринатны?

Ш а ф и к а. Граната тартмаларын беркем тапмаслык итеп күмдек. Урынын билгеләдек. Машинаны яндырдык. Дошманга калмасын! Тагын ни сорыйлардыр?..

Л а р и с а. Сорамыймы ул керпе? Башын бетерер әле, мин әйтте диярсең.

Ш а ф и к а. Бигрәк озаклады...

Л а р и с а. Ринаттанераграк бул. Корымлы чуен янында чуалсаң ни булып бетәсен беләсең.

Ш а ф и к а. И-и, апа!..

Л а р и с а. И-и димә, белмисең син аны!

Ш а ф и к а. Туганнан бирле беләм. Бишектән...

Л а р и с а. Сез бер авылданмыни?

Ш а ф и к а. Юк. Моңарчы күргән-белгән кешем түгел. Фронтта таныштык.

Л а р и с а. Туганнан бирле беләм диден түгелме соң?

Ш а ф и к а. Синең шулай булганы юкмы? Бер дә белмәгән кешене очратасың да гаҗәпкә каласың: ул кешене әллә кайчаннан беләсең икән инде! Холкы, сүзләре, гадәте җанга якын.

Л а р и с а. Фронтта бер көнлек инде... барысы да... Бүген бар, иртәгә юк. Әнә, повар егет миңа каш сикертеп маташа...

Ш а ф и к а. Бүген бар икән, иртәгә дә булуы мөмкин. Бүген юк икән, иртәгә буламы-юкмы әле.

Л а р и с а. Әнә, кояшың чыга!

Ш а ф и к а. Күрәм.

Л а р и с а. Моның авыз бик ерык бүген!

Р и н а т керә.

Ш а ф и к а. Озак тоттылар.

Л а р и с а. Бөтенләй алып калсалар да берни кылыр хәлең юк.

Р и н а т. Юллап, йолып алырга бармас идеңме әллә, Лариса апа? Теге керпе чәчле шәп егет булып чыкты. Мин разведкага эләктем, син дә бездән ерак булмыйсың.

Ш а ф и к а. Ә машина?

Р и н а т. Тегесе янганнан бирле әллә ничек...

Л а р и с а. Разведка дигәннәре бик куркыныч түгелме? Бар икән, үзе теләп утка керер адәмнәр дә калган икән. (*Туктап.*) Ә мин? Мине нишләтәләр?!

Р и н а т. Сезнең хакта сүз булмады, апа.

Л а р и с а. Мин нишләрмен?

Ш а ф и к а. Кил минем янга санбатка. Кием бирерләр, тамагың тук булыр. Файдаң тияр.

Л а р и с а. Тавык суйганда да күршегә кереп кача торган кешене санбатка... Бакадан куркам, еланнан. Үгез белән кәҗә тәкәсен әйткән дә юк... Юк, мин синең шикелле батыр йөрәкле булып тумаган. Аннары, күргәннәре дә җитәрлек булды. Бая ашханәдә ишек шыгырдады, самолетлар килә дип котым калмады. Куркам мин!

Р и н а т. Тылга кит, алайса, эшкә урнаш.

Л а р и с а. Бигрәк бәхетсез булды башкайларым... Бер җирдә танышым, туганнарым юк. Нишләрмен? Ничек яшәрмен?

Р и н а т. Ил белән бергә күрәбез, апа.

Ш а ф и к а. Тукта әле, Ринат! Апа! Менә безнең өйнең адресы. Тот та безнең авылга кит!

Л а р и с а. Сезнең авылга?

Ш а ф и к а. Әни анда берьялгызы. Ул сиңа урын бирер. Карар.

Л а р и с а. Сугыш анда килеп җитмәсме?

Р и н а т. Синең теләкне үтәп булса да, җиткермәскә тырышырбыз!

Л а р и с а. Ничегрәк булыр икән соң? Килешерме? Син монда, ә мин анда кайтып керсәм...

Ш а ф и к а. Әнигә күп итеп сәлам әйтерсең!.. Кочып алыр ул сине. Җибәрергә күчтәнәч кенә юк.

Р и н а т. Нигә булмасын? Менә исле сабын. Консервалар.

Л а р и с а. Кемнән дип тапшырырмын боларны? Кияевеңнән дипме?

Р и н а т. Апа! Минем турыда бер сүз ычкындырасы булмагыз!

Ш а ф и к а. Кызыңнан, диген. Безнең авыл кызыл яр астында... Турыбызда куш өянке... Әнигә әйт, бик сагына, диген. Бик... Тик минем өчен борчылмасын! Кош оя типмәс көнне туганмын мин... Шулай да кайтырмын! Әнине борчымаска тырыш. Тыштан белдермәсә дә эчтән көя ул. Бары да әйбәт, диген.

Л а р и с а. Ә егетеңә? Сөйгәнеңә ни әйтим?

Ш а ф и к а. Аңамы? Берни дә әйтмәссең!

Р и н а т. Хәерле юл сиңа, апа! Татарстанга сәлам!

Ларисаны озаталар.

Ш а ф и к а. Хәерле юл!

Р и н а т. Барыр юлымы бу аның, кайтыр юлымы? (*Шафикага.*) Син аның урынында булырга теләр идеңме?

Ш а ф и к а. Бик теләр идем! Кайтып килер идем... Әни янына.

Р и н а т. Ә язмышыңны алыштырырга теләр идеңме? Атна-ун көннән ул кызыл яр астында булыр. Куш өянке яныннан үтеп китәр. Син утырган җылы сәкедә утырыр. Сиңа карап ничә еллар балкыган самавырдан чәй эчәр.

Ш а ф и к а. Сүзләрең рас... Уйнатма күңелемне! Кызыл ярны кар каплаган!.. Өянкеләр шәп-шәрә... Өянке астыннан йөгереп уйнаган нәзкәй бил дә юк. Ул бүтән. Ул башка.

Р и н а т. Алайса, күз яшеңне яшер.

Ш а ф и к а. Ни кызыктырсаң да берни үзгәрми, Ринат. Язмышымны алыштырмас идем!

Р и н а т. Бу сүзләреңне үз файдама кабул итсәм, үпкәләмә. (*Җылы итеп.*) Рәхмәт, Шафика. Кичкә кадәр вакыт бар. Учак ягыйммы?

Ш а ф и к а. Рөхсәт итәләрме соң?

Р и н а т. Фронт ерак дияргә була. Камалыштан чыгуны бәйрәм итәргә ярыйдыр бит?

Ш а ф и к а. Фронт ерак түгел түгелен, менә бәйрәмнәргә ерак.

Р и н а т. Олы бәйрәмгә хәтле кече бәйрәм. (*Учак кабыза.*)

Ш а ф и к а. Учакны тиз кабыздың.

Р и н а т. Шырпысы санаулы, урман юллары өйрәтте.

Ш а ф и к а. Бу учак матуррак.

Р и н а т. Учак тирәсен син бизисең. (*Пауза.*)

Ш а ф и к а. Сүзне кайчан шулайракка борырсың дип курка идем... Бая Лариса апа егет турында сорагач та тартылып алдың.

Р и н а т. Барыбер берни әйтмәдең.

Ш а ф и к а. Нәрсә әйтим? Өйрәт.

Р и н а т. Сөйгәнең бармы диде бит.

Ш а ф и к а. Нигә әле бу турыда син түгел, ул сорады? Мин синең соравыңны тели идем. Бик. Яшермим. Чын. Сугыш үзе дә һәркемгә сорауны туп-туры бирә бит! Ничегрәк син? Кем син? Ничек яшәргә җыенасың? Һәм барына да җавапны туп-туры таләп итә. Монда инде кемгәдер аркаланып, ышыкланып кала алмыйсың, иеме? Соравыңны нигә көттем дисеңме? Сиңа җавап бирәсе килгәнгә генә түгел... Кешегә җавап биргәндә үз-үзеңне дә тикшерәсең. Туры куелган сорау уйлата. Туры җавап бирергә кирәклеге мең кат ныграк уйлата. Бер егетем бар иде минем... Егетем дип, танышым, күрше малае. Яратам дип тә йөрде. Дус та идек. Ләкин мин аның сорауларына җавап бирә алмый идем. Әгәр ярату шуның төсле генә булса, дия идем... Ярату өчен якын кешеңне генә түгел, үзеңне дә белергә кирәктер, иеме? Күп кешеләр өсләренә нинди йөк, бурыч алганнарын уйлап та тормастан: «Яратам!» — дип кычкыралар.

Р и н а т. Үпкәләмә, тәҗрибәле, күпне күргән кеше күк сөйләдең.

Ш а ф и к а. Соңгы көннәрдә гел уйлыйм мин. Төнлә дә, көндез дә. Тегендә, юлда чакта, күңелемнән генә гел синең белән сөйләшә, кайчагында бәхәсләшә идем.

Р и н а т. Мин дә!

Ш а ф и к а. Ни әйтә идең син миңа?

Р и н а т. Минем уйлар гадирәк. Үзем төсле... Сайланырга, чагыштырырга мине сөйгән күрше кызы булмады.

Ш а ф и к а. Үртәшмә, малай!

Р и н а т. Ут төшермә тагын! Болай да янам! (*Пауза.*) Сине исән-аман алып чыгаммы, шуны булдыра алырмын-

мы дип уйладым. Үзем үлсәм үләм, сине саклап калам, дип кат-кат эндәшә идем сиңа.

Шафика. Мин моны белә идем.

Ринат. Каян? Ничек?

Шафика. Бөтен гаҗәбе дә шунда! Син юлда бер сүз әйтми идең миңа, карамый идең, якынрак елышырга тырышмый идең, сагызланмый идең. Шулай да бөтен уйлаганыңны аерым ачык белеп килә идем. Ни булды миңа? Ни булды безгә?

Ринат. Ни булды безгә?

Шафика. Өстә, өстә! Янсын учагың!

Ринат. Ни булды соң безгә?

Шафика. Сугыш бит, Ринат...

Ринат. Сугыш, Шафика.

Шафика. Мин кинәт кенә дөньядагы бар нәрсәне аңлый башладым. Ышанасыңмы, җирнең әйләнгәненә хәтле тоям. Хәтта куркыныч. Юньлегәме икән? Үлемгә булмасын димен... Бер шигырь тыңлыйсыңмы?

Ринат. Әйдә.

Шафика.

> Кызыл нурлар чәчә учак тирә-якка.
> Караңгыда йокымсырап урман ята.
> Ян, учагым, дөрли-дөрли! Мин куаныйм!
> Кирәк булса, синең белән кушылып яныйм.
> Ян, учагым, төнге урман тынлыгында,
> Биесеннәр яшь каеннар ал нурыңда.
> Дулый-дулый көчеңне бир бөтен якка —
> Чәчрәсеннәр очкыннарың бик еракка!

Ринат. Кинәтлеге мине бик куркыта: яраттым сине!

Шафика. Мин дә, Ринат... Менә күрше егете очрасын иде хәзер! Барын аңлата алыр идем.

Ринат. Ул аңлар дисеңме? Гашыйклар телен, гашыйклар күңелен берәү дә аңламый... Ул кайда?

Шафика. Сугышта. Элемтәдә. Кыю егет ул. Әйбәт.

Ринат. Кыю булсын. Кыюлар кирәк.

Шафика. Сугышка гашыйклар кирәкми дисеңме?

Ринат. Алар да кирәк.

Ваня керә.

Ваня. Кызылармеец Булатов!

Ринат. Син икәнсең, Ваня. Менә таныш. Якташ кыз, Шафика.

Ваня. Якташ? Эх, якташ кызлар... Якташлар!

Ринат. Ваняның авылында фашистлар. Ул Көнбатыш Белоруссиядән.

Ваня. Чеховтагы төсле Ванька Жуков мин... Хәзер менә: «Авылга, Бабайга» дип хат язып кара... Чехов Ванькасының хаты, бәлки, барып та җиткәндер... Безнең авылга җитмәс! Юк!

Шафика. Утыр, Ваня, җылын.

Ваня. Рәхмәт. Кузгалырга вакыт, Ринат.

Ринат. Мин әзер, Ваня.

Ваня. Сиңа бер минут вакыт. (*Чыга.*)

Шафика. Булатов икәнсең син.

Ринат. Булатов кына.

Шафика. Сау бул.

Ринат. Син санбаткамы?

Шафика. «Ей в другую сторону!» Таптым санбатны, бу юлы адаштыра алмассың.

Ринат. Эзләрне югалтышмыйк.

Шафика. Риза. Хуш.

Ринат. Сау бул!

Шафика. Безнең учак янсынмы?

Ринат. Европа дөрләгәндә безнең учак кына нәрсә ул?!

Шафика. Алай димә... Безнең учак, бәлки, иң гайрәтлесеседер?

Ринат. Мәхәббәт учагы! Риза. Шулай булсын!

Шафика. Булатов икәнсең. Ә без Каюмова булабыз.

Ринат. Беләм. Онытмам. Мәңге.

Шафика. Сиңа дип әзерләгән адресымны Ларисага бирдем. Хата булмадымы?

Ринат (*көлә*). Болай да онытмам. Куш өянке астындагы өй. Кызыл яр астындагы авыл.

Шафика. Кызганыч Ваня!

Ринат. Кызганычлар күп. Шуның өчен бүген без монда, кызыл яр астында түгел.

Шафика. Бәлки, бер үбәрсең дә? Күрәм, кыймый торасың. Сизәм. (*Үбешәләр.*) Беренче мәртәбә...

Ринат. Актыгы булмасын.

Шафика. Учакны кара син! Җирне җылыта, күктән төшкән кар бөртекләренә дә баш бирми. Яши!

Ринат.

Ян, учагым! Дөрли-дөрли! Мин куаныйм!
Кирәк булса, синең белән кушылып яныйм!

Сәхнә караңгылана. Команда тавышы. Бик күп аяк тавышлары. Җыр.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Гади авыл өй эче. Урамда кыш. Урамда җыр. Л ә м и г а ялгызы.

И р л ә р.

Без урамнан үткән чакта,
Күтәрелде тузаннар.
Исән булсак, бер кайтырбыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Х а т ы н - к ы з л а р.

Әллә кайлардан күренә
Безнең колхоз гөлләре.
Былтыр түгел, быел икән
Аерылышу көннәре.

К а ш ш а ф керә.

Л ә м и г а. Әйдүк, Кашшаф абый, әйдүк. Түремә уз! Самавырым да кайный... Күңелем дә җирсеп тора иде.

К а ш ш а ф. Узып ук тора алмам. Ашыгам. Рәхмәт, Ләмига.

Л ә м и г а. Бригадир булганнан бирле яшен ташына әйләндең син, утың гына күренеп кала. Утың елтырый, үзең юк. Ә күрәсе килә. Эчне бушатып элеккечә сөйләшеп утырасы килә.

К а ш ш а ф (*паузадан соң*). Китүчеләрне озатырга да чыкмадың шикелле?

Л ә м и г а. Чыга алмадым. Әллә нигә хәлем китеп тора. Әлерәк кенә урманнан кайтып кергән идек. Кар бик күп бит быел. Урман-кырларына эскерт-эскерт өйгән. Һич чыгармын димә.

К а ш ш а ф. Салкын тигереп кайтмагансыңдыр бит? Ай-һай, зәһәр! Салкыны дим...

Л ә м и г а. Кап-кайнар чәй эчеп җибәргәч узар әле, Кашшаф абый.

К а ш ш а ф. Утыныңны миннән башка гына алып кайттым диген...

Л ә м и г а. Синең вакытың юклыкны беләм, Кашшаф абый. Җан яхшы сүзгә мохтаҗ, яхшы сүзеңә рәхмәт.

К а ш ш а ф (*ишарәли*). Аның белән бардыңмы?

Л ә м и г а. Аның белән.

К а ш ш а ф. Ул иркәҗан ниндирәк заттан соң? Пычкы тота беләме, хәсрәт?.. Син төягәндә учын шапылдатып көч биреп кенә тормагандыр бит?

Л ә м и г а. Нишләп алай итсен? Авыл кызы ласа. Эшкә япьтәш кенә күренә болай. Көче дә бар. Тик менә...

К а ш ш а ф. Әйтеп бетермәдең, Ләмига.

Л ә м и г а. Самавырым сүнәргә маташамы?.. (*Борылып карап керә.*) Әле бая каным катып тыңлап тордым — егетләрнең тавыш сыек! Былтыргылар түгел инде... Яшьләр...

К а ш ш а ф. Яшьләре күбрәк булсын иде әле!

Л ә м и г а. Минем капканы кагасыңмы?

К а ш ш а ф. Һич алай түгел!.. Хәзер һәр җан кат-кат санаулы дим... Саны кимегән саен, адәмнең кадере артыр икән! Менә егерме биш кешене урман чыгарга озатып йөрим. Язу килде.

Л ә м и г а. Егерме биш! Безнең авылданмы? Күпмегә?

К а ш ш а ф. Егерме биш дастуен кеше аяк терәп эшләгәндә дә айга җитәрлек план төшерделәр. Аларга, иң кимендә, җиде-сигез таза ат кирәк. Аларга айлык туклыклы азык кирәк! Фураж!

Л ә м и г а. Тыңлыйм, Кашшаф абый, тыңлыйм.

К а ш ш а ф. Хәбәрләрем күңелсез булса да, тыңла! Ун кешене окопка сорыйлар. Иң җегәрлеләрен! Җиде малай иртәгә таңнан ФЗУга китә. Заводларда кеше җитми.

Л ә м и г а. Тыңлыйм, Кашшаф абый, тыңлыйм.

К а ш ш а ф. Тыңлавын тыңлыйсың да, бүген бер дә синең файдага сүз чыгар төсле түгел әле. Их, суык тышта, ә?!

Л ә м и г а. Зиһенемнең таралган чагы, Кашшаф абый. Онытылып бирәр ярамаган эш кылып ташладыммы?.. Гомер буе, җаемнан торып, гел татлы сүз сөйләдең, бүген катырак әйтеп ташласаң да риза-бәхил. Бер-береңне төзәтә торган замана!..

К а ш ш а ф. Йөрәге татлыдан гына татлы сүз чыга диләр... Рәхмәт, Ләмига.

Л ә м и г а. Чәем дә вакытын белеп кенә өлгерде. Каракаршы утырып чәйләмәгәнгә никадәр көннәр узды?

К а ш ш а ф. Эчсәм дә эчәрмен шул.

Л ә м и г а. Ашап эч. Менә кабартмасы. Сары май.

К а ш ш а ф. Нигә тегене чакырмыйсың?

Л ә м и г а. Бераз соңрак аның көен дә көйләрмен.

К а ш ш а ф. Чеби дә анасы канаты астында шул тиклем ятмыйдыр, Ләмига! Нишлисең син?! Өф-өф итеп мич башында тотарга чирле чебешме ул, йә?!

Л ә м и г а. Чак кына түзик, Кашшаф абый... Чак кына!

К а ш ш а ф. Инде сине белеп бетердем дип кенә уйлыйм, ялт итеп тагын бер мөгез чыгарасың. Инде, ярый, сабабын күрерлек: үз кызыңа гомереңне багышладың. Иреңә биргән антың булгандыр, башкасы... Риза! Үз көнең, үз тормышың булмаса да, менә дигән кыз үстердең. Ә бу!..

Л ә м и г а. Мөгаен, миңа язганы шулдыр... Миңа диг-

әне, өлешемә чыкканы шулдыр... Гомерем шулдыр... Менә син, Кашшаф абый, базарга барып кергәч иң әүвәл нәрсә күрәсең?

Кашшаф. Базар күрәм. Халык мыжлап тора, корт күче кебек. Шуны күрәм.

Ләмига. Ә мин... базарга чыксам... базар күрми кайтам... Аяк басуга берәүне очратам да шул кеше миңа җитә... Нишлим, гадәтем шундый.

Кашшаф. Нигә син ул базарда тагын башканы күрәсең, мине түгел?..

Ләмига. Син дә ярдәмгә мохтаҗмыни, Кашшаф абый?

Кашшаф. Яратам, Ләмига... Күрмәсәм, күңелем китек... Сабы сынык чалгы кебек яшим бит... Үткерлегем дә бар, бизем дә исән, ә сап юк... файдасызга уза гомер!

Ләмига (*көлемсерәп*). Шушы булдымы каты сүзең?

Кашшаф (*гарьләнеп*). Сиңа көлкедер дә...

Ләмига. Бер дә көлке түгел. Түгел, һич.

Кашшаф. Сүземнең катысы шул: башыңа бәла алдың, Ләмига. Күпме синдә ята инде? Икмәгеңне ашый. Бакуация белән килгәннәр бер ул гына түгел. Һәркайсы хәл кадәренчә кыймылдый. Алар да кыяр бакчасыннан түгел, фронт ягыннан кайткан. Бомба астында да калганнар, яраланганнар да, бала-чагасы да үлгән. Өс-башлары чат бет иде кайтканда. Мунчаларда кундырдык... Хәзер менә, шөкер, тернәкләнеп киләләр. Идарә утырышында карар чыгардык. Бакуация белән килгәннәрнең һәркайсына бишәр кило он! Синдәге хөрәсән ялкавы ни йөзе белән төшеп алыр икән аны?

Ләмига. Эшләр ул, чыгар. Тик чак кына түзеп булмыйммы?

Кашшаф. Какой-такой түзү! Булмый. Ишетмәдеңмени? Кайларга гына җибәрми кешене шушы бәләкәй Югары авыл! Кайларга көч, дәрман биреп торырга тиеш без! Ил безнең җилкәдә... Ә ул ил җилкәсенә менеп атланган имгәк! Ярамас!

Ләмига. Сабыр дигәнем шуңа, Кашшаф абый. Эч син, эч!.. Тагын берне ясыйммы?.. Ие, кызымны камалыш дигән кара нәләттән коткарган кеше кайтты. «Безнең урманнарда адәм түгел, аю адашыр»,— ди. Шул җәһәннәм түреннән кызымны ул алып чыккан! Монда ай түгел, ел ятса да шөкрана гына итәрлек.

Кашшаф. Югары авылдан егерме биш кеше урманга!

Ләмига. Бик күп, Кашшаф абый...

Кашшаф. Ун кеше окопка! Җиде малай ФЗУга! Җибәрми кара! Бармасаң төрмә! Син теләсәң нишлә, мин аны урман кисәргә җибәрәм!

Л ә м и г а. Урман?

К а ш ш а ф. Алайса, окопка!

Л ә м и г а. Окопка?

К а ш ш а ф. Бигайбә, ФЗУга җибәрә алмыйм. Малайларны сорыйлар.

Л ә м и г а. Сугыш гел аера гына дип уйлый идем мин әүвәл. Түгел икән. Кавыштыра да икән сугыш... Шафика белән ул кавышкан. Аның белән без кавыштык... Ярар. Уйлашырбыз.

К а ш ш а ф. Чәең-сыең өчен рәхмәт... Үзең әйткәндәй, уйның тиз йөгергәнен ярата торган заман. Хуш!..

Чыга. Пауза. Г ө л б а н у керә.

Г ө л б а н у. Синең дә тәрәзәләр каткан. Элек бер дә боз төшерми идең... «Тәрәзә күңел төсле ул — кеше белән дөнья арасының ниндилеген сөйләп тора»,— дия идең.

Л ә м и г а. Утынны кысыбрак тотам. Алып кайтулары бик читен.

Г ө л б а н у. Теге өйдәме?

Л ә м и г а. Өйдә.

Г ө л б а н у. Кайда?

Л ә м и г а. Һаман шунда. Мич башында.

Г ө л б а н у. Көндез дә шунда ауный икән.

Л ә м и г а. Эчкә төшкән суыгым чыгып бетми, ди.

Г ө л б а н у. Бөтен күзәнәкләренә суык тутырып кайткан икән! Әйтәм җирле бүген очкан чыпчыклар туңып төшә!..

Л ә м и г а. Тимә. Ятсын бераз!

Г ө л б а н у. Ялкауга, аңкауга синнән сан юк иде элгәре. Әче телең белән яман көйдереп ала идең!.. Юк, юк, әрләргә кермәдем. Наилемнән хат юк. Госпитальгә салдылар дигәне килде дә тынды... Очып барып кайтыр идем дә... Бүгеннән урман кисәргә китәргә кирәк. Саубуллашырга керүем. Кызлар икәүдән-икәү генә кала. Берсенә җиде, икенчесенә унбер... Ут-күз чыгармасалар ярый ла... Күз-колак булгала, күршем.

Л ә м и г а. Тукта, Гөлбану, ашыкма.

Г ө л б а н у. Ашыкмый ярамый.

Л ә м и г а. Сине дә җибәрәләр икән. Ирең, ике улың фронтта... Балаларың вак...

Г ө л б а н у. Өйлә чәен эчкәч тә кузгалабыз. Сиңа әйтмәдеме?

Л ә м и г а. Миңа түгел, аңа әйтте.

Г ө л б а н у. Җибәрәсеңме соң?

Л ә м и г а. Ничекләр җибәрим, күршем? Кайларга? Менә

бүген җыенып урманга бардык... Әчкәрәк керик дим, ике кулы белән чытырдап иңемә ябышты. Җылый.

Гөлбану. Нишләп?

Ләмига. Курка. Агач ауганда күрсәң иде син аны! Дөп иткән тавышка ул да җиргә аумасынмы? Бума чире бар дип торам. Баксаң, курка икән!

Гөлбану. Кит аннан! (*Бот чабып көлә.*)

Ләмига. Куркак икәнен белә идем... Базга төшми, абзарга керми. Нишләтим?! Беркөн авыл өстеннән аэроплан узды. Үлә дип торам.

Гөлбану. Әллә нинди кешеләр була икән ул.

Ләмига. Үпкәләр идем, үз кызым шулайрак иде бит.

Гөлбану. Үзең белерсең инде. Сүзем шул: Наилдән, башкалардан хәбәр-хәтер булса ирештерергә тырыш...

Ләмига. Монысын эшли алмам, Гөлбану.

Гөлбану. Нигә?

Ләмига. Урман кисәргә мин дә барам.

Гөлбану. Ай Ходаем, саулыгың юк бит, Ләмига. Урман кисү — белен ашау түгел, беләсең.

Ләмига. Башка чарам юк. Безнең йорттан да кемдер бармаса, каян алсын Югары авыл кешене?!

Гөлбану. Ә ул?

Ләмига. Аның өчен барам да. Аны әлегә җибәрә алмыйм.

Гөлбану. Әйтсәм дә кеше киңәшен тота торган холкың юк. Ике йортка баш булып калырсыңмы дип өметләнгән идем.

Чыга. Мич башыннан Лариса төшә.

Лариса. Күрше апа нигә шулай күңелле итеп көлде?

Ләмига. Болай гына.

Лариса. Тагын мине тешләгәндер инде.

Ләмига. Алай димә. Әйбәт кеше ул. Ничә ел күрше булып торып, бер тапкыр сүзгә килмәдек.

Лариса. Аңлыйм! Тоталар да мине сүгәләр! Керәләр дә мине... Теге бабай да!

Ләмига. Нишләп бабай булсын ди ул? Түгел. (*Паузадан соң.*) Әйе, сиңа бераз үпкәләре бар. Ярый. Анысын үз вөҗдан хөкемеңә куйыйк... Ә хәзер шуны киңәшик: безнең өй эченнән теребез урман кисәргә барырга тиеш.

Лариса. Ничек? Урман?

Ләмига (*паузадан соң*). Бәрәңге базда. Он чоланда. Утын лапаста. Су инештә. Шырпы гына юк. Утка соскы тотып күршеләргә йөрерсең. Акыллы булып, ут саклый алсаң, алар сиңа керер.

Лариса. Мин берүзем каламмы? Мин куркам.

Л ә м и г а. Беребезгә бармыйча ярамый. Ярамый. Ил күзенә күренә алмабыз югыйсә... Сиңа кайда яхшырак буласын мин уйладым инде. Курыксаң да монда бер башың. Ә куркудан үлгән кеше юк. Үлмәссең. Кеше арасында түгелсең, хәлеңне белдермә. Анда ишле кеше арасында читенрәк булыр иде сиңа.

Л а р и с а (*ялынып*). Ләмига апа!

Л ә м и г а (*кырыс*). Беләм. Камалышта күргән җәфаларыңны беләм. Баш түбәңә ышкылып очкан аэропланнарны да беләм... Ике-өч бөртек ак чәчең шаһит! Бомбалар ничек ыжгырганын да онытмадым... Алпавытны да сөйләдең... Кызымны, бердәнберемне, өметемне дошман арасыннан йолып алып чыгуыңны да хәтерлим. Мәңге онытмам! Рәхмәт! Меңе, артыгы белән рәхмәт. Шуның өчен — җылы түрем сиңа! Якты өем — сиңа! Күрше апаң ни сөйләмәс, ахыр чиктә, син аның улын түгел, минем баламны коткаргансың! Барысы сиңа... Синең мәшәкатьләрең, казаларың миңа булсын. Риза. Тынычланганчы яшә. Савык. Савыгырсың, беләм.

Л а р и с а. Ул урман еракмы?

Л ә м и г а. Моннан күренми. Станцадан ике көнлек юл.

Л а р и с а. Оялам, Ләмига апа.

Л ә м и г а. Оятыңны читкә куеп, мине тыңла. Учагыңда ут сүнмәсен. Мал-туарларны кара, ашат-эчерт. Гөлбану апаңның кызларына күз-колак бул. Син — олы кеше. Син күпне күргән. Шафикадан хат килсә, җибәреп тор. Авыл белән элемтә өзелмәс. Хуш.

Л а р и с а. Рәнҗеп китмәгез, Ләмига апа.

Л ә м и г а. Нигә сиңа рәнҗим? Син үзең рәнҗетелгән кош. Гитлерга нәләт укыйм. Ул гаепле! Аннары шул... Менә Шафиканың күлмәге... Яулыгы... Алъяпкычы... Киемнәре... Шуларны ки.

Л а р и с а кече якка чыга. К а ш ш а ф керә.

К а ш ш а ф. Әллә үзе әзерләнеп ята инде?

Л ә м и г а. Үзем.

К а ш ш а ф. Мин дә барам.

Л ә м и г а. Тагын бергә туры киләбез, Кашшаф абый.

К а ш ш а ф. Ни әйтим, Ләмига?

Л ә м и г а. Әйтми тор, Кашшаф абый! Хуш, Лариса!

Чыгалар. Урамда җыр. Җыр дәвамында пәрдә төшеп тора. Пәрдә ачылганда Шафика күлмәген кигән, яулыгын-алъяпкычын бәйләгән Лариса лампага ут кабызып маташа. Нидер күши. Ишек шакыйлар. Җавап та көтеп тормастан җил-җил атлап Н а и л керә.

Н а и л. Шафика!

Л а р и с а. Ай! Сез кем?

Н а и л. Күрмисеңмени? Солдат!

Л а р и с а. Сиңа ни кирәк, солдат?

Н а и л. Кара әле, Шафика бит син! Ул!

Л а р и с а. Шафика бик еракта.

Н а и л. Ул еракта түгел. Ул син... Шулкадәр охшагансың... Минем җанкайны — Шафиканы камалыштан алып чыккан кыз синме?

Л а р и с а. Минем Шафикамны? Шафика синекеме?

Н а и л. Ха-ха-ха! Курыкса да куркыр икән кеше! Күрше егете мин. Шафика белән бергә аунап үстем. (*Күрсәтә.*) Менә мондый чактан. Фронтка да бергә чыгып киттек. Менә мин яраланып та өлгердем... Кыска сроклы ялга җибәрделәр. Кул төзәлсә, бүгеннән әзер!

Л а р и с а (*уфылдап*). Лариса мин. Седых.

Н а и л. Мин сине беләм.

Л а р и с а. Каян?

Н а и л. Безнең авыл кешесен фронтта коткару бәләкәй вакыйгамы әллә? Әллә ничә тапкыр хатта яздылар... Кайтып керүгә сеңелкәшләр сайрашырга тотынды.

Л а р и с а. Туйганчы хурлаганнардыр инде?

Н а и л. Бездә кунакны хурлау гадәте юк.

Л а р и с а. Кунакны шулайдыр... Кунак... Син менә кунак!.. Кунак булсам иде мин!.. Чит кешеләр арасында кунаклый алмассың...

Н а и л. Син чит кешеләрдә түгел, бездә. Югары авылда. Син безгә кунактан да кадерлерәк.

Л а р и с а. Аңламыйлар алар мине. Аңлый алмыйлар. Менә син солдат... Дары исе иснәгән. Пуля сызгырганны ишеткән. Кан койган солдат! Кем аңлый сине монда? Яки мине? Мин дә солдат!

Н а и л. Сөйлә, зинһар. Берсен дә, берсен дә калдырма. Шафика ни хәлләрдә анда?

Л а р и с а. Яратасыңмы?

Н а и л. Үземнән дә ныграк... Бик яратам!

Л а р и с а. Ни әйтим синең яраткан йөрәгеңә, солдат?! Без аның белән бик күптән күрештек ич, көзен... Аннан соң күпме вакытлар узды. Язмыймыни сиңа?

Н а и л. Язадыр да, адрес еш алышынды соңгы вакытларда.

Л а р и с а. Яратам диген...

Н а и л. Бик! Яшермим! (*Йөренә.*) Бу өй... Бу тәрәзәләр... Икесе безгә караган... Иртә таңнан ачып җибәрер иде... Кояшның каян чыкканын белмим, чөнки аның нурларын да Шафика каплый иде... Кул сызлый, нәләт... Мәргәннәре гаепле. Снайпер. Полк штабына элемтә суза идек... Әле ярый беләкне генә эләктерде. Сөяк чатнаган...

Л а р и с а. Авыртмасын өчен нишлим сиңа, мескенем?! Беләк өчен көяләнмә шулкадәр. Йөрәккә чыдап булмый монда...

Н а и л. Йөрәк нык безнең.

Л а р и с а. Нык булсын, Наил. Нык. Син яшь, чибәр... Минем йөрәк сызлый... Синең төсле берзаман мин дә үз авылыма кайтып керермен. Ничек булыр ул, кайчан? Йөрәк сызлый!.. Гел-гел яхшы хәбәрләр көтеп торамы анда мине? Әле син менә тып-тыныч авылга кайтып төштең. Фронт еракта. Анда да... Шулай да син бәхетле. Көнләшәм! Ә мин кайтып керсәм?

Н а и л. Авылың кайда соң синең? Туганнарың бармы?

Л а р и с а. Бары немец кулында. Туганнар юк диярлек. Булганнары таралышты. Әни карчык япа-ялгызы. Исәнме ул, юкмы... Ә монда... Сугыш ачысын татыган хатын-кыз йөрәген кем аңлый ала? Сиңа яшерми сөйлим, чөнки син үзең анда булган кеше... Хатын-кыз сугышны күрә икән, ул инде бөтенләй башка зат. Син үзеңнең Шафикаңны аңлый алырмын дип уйлыйсыңмы? Ул бөтенләй, бөтенләй башка кеше. Кешеләр генә түгел, заман да, җир дә башкача булачак...

Н а и л. Ничек башка? Нигә күзләреңне миннән яшерәсең?

Л а р и с а. Нигә яшерим? Сезгә хәзер аңлашу кыен булыр дип кенә әйтүем...

Н а и л. Сөйлә. Берсен дә калдырма.

Л а р и с а. Сөйләмим. Нигә кирәк ул? Вакыты җиткәч, үзең белерсең.

Н а и л. Сөйлә!

Л а р и с а. Турыдан-туры йөрәгеңә барып кадала торган хәбәр сиңа нигә?

Н а и л. Нигә сүз башладың, алайса?

Л а р и с а. Сөйләшүне сагындым. Син мине аңларсың, мин сине.

Н а и л (*тәмәке төрә башлый*). Өйрәнә башлаган идем. Була да иде. Сыңар кул белән җайлы гына төрә дә идем. Төреп бирче, Шафика, зинһар! Төрче, Шафика!.. Әй, юк...

Л а р и с а (*көлеп*). Шафика икән, Шафика! Кайгырма, баш сау булсын.

Н а и л. Хәзер сөйлә. Яшермә.

Л а р и с а. Чын Шафика синең каршыда булса нишләр иде?

Н а и л. Мин белгән, мин сөйгән Шафика бары тик дөресен генә сөйләп бирер иде.

Л а р и с а. Миңа рәнҗемәсме ул?

Н а и л. Дөреслек өчен рәнҗиләрме?

Л а р и с а (*паузадан соң*). Ул башканы сөя, Наил.

Н а и л. Тагын сүнде. Тәмәкесе еш сүнгән солдаттан көләләр иде бездә. Кәләшең чит кеше кулына кергән дип мыскыллыйлар. Ятларны сөя диләр... Ләкин анда тыныч заман кызлары турында сүз бара иде! (*Сикереп тора.*) Солдат күңеленә кагылуның нәрсә икәнен беләсеңме?

Л а р и с а. Чү, чү. Акылыңны җуйма.

Н а и л. Безнең сөйгән ярлар турында гайбәт сатарга сине кем котыртты?

Л а р и с а. Сүз башлавыма үкенәм.

Н а и л. Шафика фронтта кемнедер сөя дисәң, сине авылдан куарлар. Бәлки, син бу хәбәрне таратып та өлгергәнсеңдер? Шуңа яратмыйлар сине! Шуңа!.. Ул бит, ул бит... Май кояшында йомарланган песи... Учка сикергән яшел чикерткә... Үзе йомшак, үзе куркак... Кешегә күз күтәреп карамас, күкләр белән сөйләшкәндә генә күзен күрерсең... Куркак ул... Юаш.

Л а р и с а. Куркак? Юаш? Мөгаен, без икебез ике кеше турында сөйләшәбездер. Мин белгән Шафика юаш та, куркак та түгел. Түгел.

Н а и л. Ничек килеп эләктең син безнең авылга? Кем рөхсәте белән?

Л а р и с а. Син дә табалый башладың.... Җитмәсә, солдат...

Н а и л. Ничек кайтасы иттең?

Л а р и с а. Шафика адрес бирде. Озатып калды.

Н а и л. Ялганлыйсың. Башкаларны ышандыра алсаң да, мине ю-ю-юк! Ялганчы, хәйләкәр, начар кешедер син. Документларың! Тиз-тиз... Күрсәт...

Л а р и с а. Мә. Кара!.. (*Елап.*) Ялганчы янына нигә кердең, алайса? Мин чакырып кертмәдем.

Н а и л. Рәхмәт әйтергә кергән идем... Шафиканы камалыштан алып чыгып, мине бетерергә кайткансың икән!.. Арттан пычак кадарсың дип кем уйлаган?

Л а р и с а. Минем гаебем юк. (*Пауза.*)

Н а и л. Күпме бергә булдыгыз сез?

Л а р и с а. Ике атнадан артык.

Н а и л. Ике атнада Шафиканы белеп буламы?.. Ничә ел яшәп мин белә алмадым аның күңелен!

Л а р и с а. Мине бер кичтә аңлап алдыңмы? Ялганчы дидең, гайбәтче...

Н а и л. Шафика бит ул ачылмаган бөре... Аңа җил тимәгән, яңгыр бөртеге таммаган... Ул мәк чәчәге төсле саф, күбәләк канаты кебек нәфис... Кочаклаганым да булмады минем аны!.. Учымда йөрде...

Л а р и с а. Ялгыш кайткан мин монда, һәм без икебез ике кеше өчен талашабыз. Мин белгән Шафика кырыс, усал, үзсүзле, нык һәм бик көчле... һәм аның сөйгәне бар! Үзе сөйләде! Гомер буе шушы егетне белә идем, аны гына сөям, диде.

Н а и л. Мин аның сөйгән егете! Мин!

Л а р и с а. Син түгел. Мин аны да күрдем...

Н а и л. Юк. Шафика булмаган ул. Түгел. Син нидер бутыйсың. Йә авылны бутагансың, йә районны... Шафикалар азмы әллә дөньяда?

Л а р и с а. Сугыш син танымаслык итеп үзгәрткәндер аны... Менә мин сугыш заманы булмаса, гайбәтче дигәнне тыныч кына тыңлап кала торган кыз идемме?

Н а и л. Белмим. Аңламыйм. Сөйләмәгән булсаңчы боларны.

Л а р и с а. Син үтендең, ә мин, әйткәнемчә, сөйләшүне сагындым... Сине, солдат кешене күргәч, дөнья үзгәрде дә куйды... Мин гаепле түгел. Алдамадым мин сине!

Н а и л. Алдаган булсаңчы!

Л а р и с а. Малайлыгың чыгып бетмәгән димме...

Н а и л. Искә төшермә малай чакларны! Кул сызлый, кул... Йөрәккә төшә. Малай чаклар, малай чаклар... Бар иде шундый чаклар, кесә тулы борчаклар... Саламнан тәртә каерып, чикерткә җиккән чаклар! Нигә сүнә бу тәмәке?! Нигә сүнә?! Чыннан да фронтташ дуслар хаклы идеме әллә? Ярларны ятлар сөяме?..

Л а р и с а. Мә, кабыз. Синең бәхеткә учакта ут сүнмәгән...

Н а и л. Учакта ут сүнмәгән дисең, алайса?.. Ян, учагым! Дөрли-дөрли! Мин куаныйм! Кирәк булса синең белән кушылып яныйм...

Л а р и с а. Шафика шигыре!

Н а и л. Алайса, чыннан да син аның яныннан кайткан...

Л а р и с а. Ә хәзер синең катыңда Шафика басып торса, аның нинди булуын теләр идең син?!

Н а и л. Белмим. Белмим.

Л а р и с а. Шулай да...

Н а и л. Күзләр аны сагынды... Җан! Куллар аны сагынды...

Л а р и с а. Соң, кочакла мине...

Н а и л. Уңайсыз... Берәрсе килеп керсә?

Л а р и с а. Кем йөрсен?.. Ялгызым мин. Төннәрен морҗа улый. Чикерткәләр ярыш уздыралар... Әллә ниләр кыштырдый... Ялгыз мин... Ифрат читен...

Ишек шакыйлар.

Н а и л. Ләмига апа кайтты.

Л а р и с а. Бер айга китте. Әле ике атна гына узды.

Т а в ы ш. Наил абый! Наил абый!

Н а и л. Минем сеңелкәшләр!

Л а р и с а. Кергәләп йөр!

Н а и л. Керермен.

Л а р и с а. Кер дә миңа: «Шафика!» — дип эндәш...

Н а и л. Белмим, белмим.

Л а р и с а. Эх, син! Кая инде сиңа Шафика йөрәген аңлау!.. Минем күңелне дә аңламадың... Шафика ул мин түгел!.. Ул, ул!

Т а в ы ш. Наил абый, Наил абый!

Н а и л. Хуш. Ачуланып калма...

Чыга. Җыр. Урман. Кыш. Л ә м и г а белән Г ө л б а н у. Гөлбану кулында хат.

Г ө л б а н у. Балакаем, Наилем кайткан!

Л ә м и г а. Олы сөенеч, күрше. Озак куанычка булсын. Хатны үзе яза алганмы?

Г ө л б а н у. Кулы ранный бит. Кызлар язган. «Абый кайтты» дигәннәр.

Л ә м и г а. Исән кеше бер кайта. Безгә дә шул көннәрне күрергә насыйп булсын.

Г ө л б а н у. Үзе язаламы соң? Язарлык булса, кайтармаслар да иде.

Л ә м и г а. Шафика белән бергә чыгып киттеләр. Ул турыда сүз-фәлән юктыр?

Г ө л б а н у. Хатлары бик кыска. Юньләп, барын түкмичәчми язып торыгыз дип колакларына кирт кенә кирт-ләмәдем, юк! Ләмига, күңелемә сөенеч-карлыгач белән көенеч-ябалак та керде... Хат та кыска, хатны биргән Мисбах абзыйның да чырае бик караңгы күк тоелды... Төртмәрәк сүзләр дә ычкындырды... Биш-алты балалылар кан койганда, кайта шунда җыен этрәк-әләм дигән күк тә булды... Наилне илгәзәк диде.

Л ә м и г а. Йә, йә... Мисбах абзый төртмә кеше түгел болай...

Г ө л б а н у. Кызлар да әллә ничек... Сәлам-мазар да юк. «Әнкәй, кайт син» дигәннәр. «Тиз кайт» дип тә өстәгәннәр.

Л ә м и г а. Үзең төшенеп җитмәгәндә, мин ни әйтеп куандырыйм сине, күрше?

Г ө л б а н у. Озакка кайтканмы, саумы, бер сүзләре юк.

Л ә м и г а. Кашшаф абый белән сөйләштеңме?

Г ө л б а н у. Кайтармый. План үтәлеп бетмичә шаг та юк, ди. Малаең кайткан, күрергә өлгерерсең. Берәүләрнең әнә яртышар ел хатлары юк, ди.

Л ә м и г а. Аның сүзе дә хак.

Г ө л б а н у. Син аны якларсың инде.

Л ә м и г а. Вагоннар утын көтә. Шул гына...

Г ө л б а н у. Кулыңда нәрсә ул?

Л ә м и г а. Килешли кашлак җирдән уҗымнан бер кәс кубарып алган идем. Беләсем килә, тереме уҗым, үлеме? Анда кар бик аз ята... Әллә вак-төяк чыбык-чабыкларны кар тотарга ташыйбызмы дим?.. Кышы бик салкын.

Г ө л б а н у. Әлләниләр уйлап йөрисең син.

Л ә м и г а. Уем бер генә... Кызым анда!

Г ө л б а н у. Сорамыйча гына кайтып китсәм?

Л ә м и г а. Ярамас. Законнар каты. Аяусыз.

Г ө л б а н у. Ничекләр икегә бүленим икән?

Л ә м и г а. Болай киңәшик: син кайтып кит. Кашшаф абый белән үзем сөйләшермен. Синең өлешне икәү кисәрбез. Икәү тапшырып торырбыз.

Г ө л б а н у. Ләмига, күрше... Бит-кулларың ярылды. Үзең авыру. Билең сызлый. Төннәрен ыңгырашып чыгасың. Үз нурмаңны үтәп бара алсаң да...

Л ә м и г а. Синең улың — минем күршем. Синең улың — минем кызым белән китте. Синең кайгың — минем хәсрәтем... Безнең хәсрәт — ил кайгысы. Эшләрмен.

Г ө л б а н у. Иткән изгелегең өчен гомерең озын булсын, Ләмига.

Чыга. К а ш ш а ф керә.

Л ә м и г а. Ишетеп тордыңмы, Кашшаф абый?

К а ш ш а ф. Ишетеп тордым, Ләмига.

Л ә м и г а. Алайса, ярый.

К а ш ш а ф. Хәзер кайгы да, шатлык та тиз йөриләр. Аяклары җитез.

Л ә м и г а. Синең болай таба килүеңне мин дә күрдем.

К а ш ш а ф. Ул күрмәде. Кар шыгырдый югыйсә.

Л ә м и г а. Аналар кайчак саңгырау һәм сукыр булалар.

К а ш ш а ф. Кайчан?

Л ә м и г а. Балаларына бәла килгәндә!

К а ш ш а ф. Йә, нишлибез? Башкалар төшлектән килгәнче вакыт бар бераз.

Л ә м и г а. Ал балтаны, Кашшаф абый. Мин пычкыны...

К а ш ш а ф. Башта кем өлешен кисәбез?

Л ә м и г а. Аныкын. Аның бурычы бетә торсын. Улы янына тыныч күңеле белән кайтсын. Мөгаен, аны анда тынычсызлык көтәдер?..

К а ш ш а ф. Тотындык.

Л ә м и г а. Тотынабыз, Кашшаф абый.

К а ш ш а ф. Менә без тагын бергә... Янда син булганда көн якты, рәхәт. Армыйм да, талмыйм да...

Л ә м и г а. Миңа да ифрат рәхәт, Кашшаф абый...

Пәрдә төшә. Фронт. Р и н а т белән В а н я.

В а н я. Нигә яннарына ук бармыйбыз соң?

Р и н а т. Сөйләшенгән. Үзләре килерләр.

В а н я. Син мең ел яшәргә җыенган кеше төсле, Ринат. Вакыт кадерле!

Р и н а т. Госпиталь начальнигы туташларның солдатлар белән очрашуын яратып бетерми. Рөхсәт тә итми. Сугыш белән мәхәббәт икесе ике нәрсә, алар бер җиргә сыешмыйлар, ди.

В а н я. Күле кипкән әбидер ул.

Р и н а т. Түгел. Ягымлы гына ханым. Утызларда.

В а н я. Утызда? Әби ич ул!.. Әйдә, күзе шакмак булсын.

Р и н а т. Кызларга кыенга килер.

В а н я. Сине ничек чәйнәп йотмады соң әле моңарчы?

Р и н а т. Мин бит, Ваня, яманлык теләп йөрмим.

В а н я. Әби аны каян белә?

Р и н а т. Анысын үзем беләм. Үзем белгәч кызны да саклыйм. Яман күзләрдән, яман сүзләрдән. Барыннан да...

В а н я. Күңел юатырлык та булмагач нигә мине ияртеп килдең? «Кызлар да кызлар!» имеш... Мин сине тагын, юньле сунарчы күк, кәҗә сукмагына төште бу егет дип йөргән булам.

Р и н а т. Нигәме? Ваня, минем өчен хатын-кыз акыл ирешмәслек хикмәтле зат ул. Шундый хикмәтле зат белән дус та булсаң... Сугыш дип, әллә ни уйлап чыгарма. Мәхәббәт һәр чакта да сафлыкны, чынлыкны, бирелгәнлекне сорый. Кем белгән, бәлки синең мәңгелек язмышың мондадыр, Ваня?.. Сиңа юлдаш кирәк. Хатын-кыз дус кирәк. Менә шуның өчен ияртгем дә мин сине.

В а н я. Болай кисәтеп куйгач, мин аның белән ничек сөйләшермен? Мин бит гап-гади эш дип уйлаган идем... Без киләбез, алар көтә...

Р и н а т. Син гап-гади очрашу дип уйла да! Менә Люся килеп җитте. Шафика кайда?

Л ю с я керә.

Л ю с я (*Ваняга карап*). Хәзер килер.

Р и н а т. Менә минем иптәш егетем Ваня.

Л ю с я. Ваня?.. Орденлы икән бу Ваня.

В а н я. Нигә, ямьсез исемме? Аның каравы минем фамилиям шәп: Жуков! Армиядә без бу фамилияне икәү генә йөртәбез. Ванялар күп.

Р и н а т. Безнең Ваня фронтында бер генә. Разведчикның ниндие әле. Белорус егете ул.

Л ю с я. Ә мин Туладан. Ваня Жуковны кайдадыр ишеткән бар. Газеталарда укыдыммы икән?

Р и н а т. Әйттем бит, аны бөтен Россия белә!

В а н я. Бусы минем файдага түгел. Ринат көлә миннән.

Р и н а т. Шафика кайда диден, Люся?

Л ю с я. Үзе өчен сөйләгәнне яратмый безнең Шафика. Әнә килеп тә җиткән!

В а н я. Әллә гашыйкларны ялгыз калдырабызмы, Люся?

Р и н а т. Тагын бер егетлегең бар икән, Ваня! Тапкыр син.

Л ю с я. Әйдәгез, йөреп килик. Кайда ишеткән идем соң мин сезнең исемне?

Чыгалар. Ш а ф и к а керә.

Р и н а т. Шафика!

Ш а ф и к а. Ринат!

Р и н а т. Сержант Булатов үзе. Бүген тагын да озаграк көттердең...

Ш а ф и к а. Көндәгечә... Син түземсезрәк була барасың.

Р и н а т. Ел көтәргә дә риза. Ун ел!

Ш а ф и к а. Мин Люсяга әллә кайчан бара тор дидем.

Р и н а т. Люся китергән хәбәр генә миңа аз булыр дип уйламадыңмы?

Ш а ф и к а. Бүген үзем турында күбрәк уйладым, Ринат. Бары шул гына.

Р и н а т. Монысы миңа яңалык.

Ш а ф и к а (*паузадан соң*). Мин сиңа әйтми йөрдем, Ринат. Чөнки кайбер нәрсәләр үзем өчен дә ачык түгел иде.

Люсяның кычкырып көлгәне ишетелә.

Р и н а т (*Шафиканы бүлдереп*). Син Люсяга яхшылап аңлаттыңмы? Үз якларыннан ерагайган саен Ваняның күңеле кителә барганны ныгытып төшендердеңме?

Ш а ф и к а. Люся безнең арада иң сизгер кыз.

Р и н а т. Бик кирәкле сүз сөйли башлаган идең бая...

Ш а ф и к а. Безне укыта башладылар, Ринат.

Р и н а т. Нинди уку ул? Нигә аны моңарчы әйтмәдең? Медсестралыккамы?

Ш а ф и к а. Түгел шул. Мин снайперлар курсына йөрим. Җиде кыз язылдык.

Р и н а т. Мәргән буласың киләме?

Ш а ф и к а. Килә дисәм?.. Бүген ун мишеньнән, сигезне алдым. Фашист сурәте төшерелгән аңа. Йөз илле метрдан.

Р и н а т. Мондый теләк каян туды болай?

Ш а ф и к а. Төшенмисеңме?

Р и н а т. Шулай да аңлат.

Ш а ф и к а. Санбатта...

Р и н а т. Кыенмы?.. Мәргәннәр отрядында тагын да читен булачак. Гел-гел алгы сызыкта... Без әлегә һаман чигенәбез...

Ш а ф и к а. Сабырым сынды... Санбатта мин сугышның бер ягын гына күрәм — фашист кылган җинаятьләрне генә. Күз алдымда күпме якты гомерләр киселә. Кул астымда күпме кайнар тәннәргә гүр салкыны дулкын-дулкын йөгерә... Күпме гариплләр кала... Мин сугышның бу ягында торам. Фашистны күрмим. Ә минем сугышның үзәгенә кереп, якага-яка алышып, нәтиҗәсен үзем ясыйсым килә. Сугыш һөнәрләре хатын-кыз өчен чикле. Уйладым-уйладым да, иң хак юл дип снайперлыкны сайладым. Врач та каршы килмәде. Төз атам икән мин! Беренче көннәрне чакмага басканда куркып күзне йома идем, хәзер зарарсыз!

Р и н а т. Сүзләр артык. Төчеләнәсем килми.

Ш а ф и к а. Әнидән бүген хат алдым.

Р и н а т. Ниләр яза?

Ш а ф и к а. Гадәттәгечә... Аягыңны җылыда тот... Салкын алдыра күрмә... Җирдә ятып йоклама, дигән. Посылка салган... Аннары, Наил кайткан. Күрше егете. Яралы.

Р и н а т. Ул да язганмы?

Ш а ф и к а. Кулы яралы дидем бит.

Р и н а т. Әйтеп торып яздыра алмаганмы?

Ш а ф и к а. Ул язар!.. Ларисадан сәлам дип куйганнар.

Р и н а т. Төпләнгән икән!.. Безнең авыл кызыл яр астында... Турыбызда куш өянке... Тиздән яз!.. Мин бүген карга күрдем.

Ш а ф и к а. Календарен бутагандыр ул. Каргаларга иртәрәк.

Р и н а т. Барыбер тиздән яз.

Люся кычкырып көлә.

Ш а ф и к а. Үзең ни хәлләрдә?

Р и н а т. Күргәнеңчә... Төнгә чыгып китәбез.

Ш а ф и к а. Тагын?

Р и н а т. Әйе, Шафика.

Шафика. Кайчан башлана инде?.. Син разведкага йөрисең, бездән күбрәк беләсең... Кайчан һөҗүм башлыйбыз? Кайчан?

Ринат. Анысын белсә Жуков иптәш беләдер.

Шафика. Ванямы?

Ринат. Олырагы. Әзер икәнлегебезне мин дә беләм.

Шафика. Яз исе... Яшисе килә, Ринат... Ой, сәгатеңне күрсәт әле. Кузгалырга вакыт! Дәрес башлана? Люся!

Ринат. Хуш.

Шафика. Барыр юлың да, кайтыр юлың да ак булсын. Мин бүген йокымсыраган кышкы елгага зәңгәр җеп агызырмын! Сиңа, иптәшләреңә, илгә иң яхшы теләкләр теләп!.. Тиздән яз!..

Ринат. Рәхмәт сиңа, гүзәлем...

Сәхнә караңгылана. Ләмигалар өе. Өйдә Лариса белән Наил. Урамда җыр. Егетләр тавышы сыек кына. Хатын-кызлар элекке кебек ишле тавыш белән җырлыйлар.

Егетләр.

Без урамнан үткән чакта,
Күтәрелсен тузаннар!
Дошманны җиңгәч кайтырбыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Хатын-кызлар.

Алмы синең кигәнең,
Гөлме синең кигәнең?
Кайсы фронтларда йөри,
Дустым, синең сөйгәнең?!

Наил. Китәләр... Кай арада үсеп егет булдылар әле алар?!

Лариса. Мин вакытсыз сулган чәчәк идем. Киселгән кыерчык идем мин... Син миңа җан өрдең... Кеше иттең!

Наил. Ишетәсеңме, китәләр!

Лариса. Шомыртлар чәчәк атты... Сездә дә нәкъ бездәге кебек икән аның чем-ак чәчәкләре!.. Авылыгыз кышын үтә ямьсез иде, хәзер китәсе килми...

Наил. Ә алар китәләр!

Лариса. Кулың ничек?

Наил. Беләсең ич инде! Сорама!.. Урамда кәшәкә уйнап йөргән егет-малайлар...

Лариса. Тиздән син дә китәрсең... Төшемдә күрдем... Син дә китсәң, мин нишләрмен? Кая барырмын?.. Син миңа бар дөньяны алыштырдың. Мин Шафика... Син көчле, батыр. Син берәүдән дә курыкмыйсың! Мин синең Шафикаң!..

Н а и л. Син Шафика? (*Мыскыллап көлә.*) Син?.. Мактама мине!

Л а р и с а. Ул мактамас идеме?

Н а и л. Дәшмә. Керәләр.

Л ә м и г а, Г ө л б а н у, К а ш ш а ф керәләр.

К а ш ш а ф. Киттеләр...

Л ә м и г а. Тагын җиде егет...

К а ш ш а ф. Тимер юлга өч кеше сорыйлар... ФЗУга бишәү кирәк.

Г ө л б а н у. Кешеләр кырда, чәчүдә. Авылда җан иясе калмаган. Мәктәп балаларына тиклем шунда.

Л ә м и г а. Нигә озатырга чыкмадыгыз?

Н а и л. Кул сызлаштырып тора...

К а ш ш а ф. Җайсызрак кочаклагансыңдыр!.. Нихәл, чибәр апа, эчеңнән салкының чыгып беттеме инде?

Г ө л б а н у. Ни хикмәт булыр икән алай? Ишеткәнем бар иде, янар таулар бар икән, шулар туктаусыз ут атып тора, ди. Бетмәс ут барын беләидем, бетмәс суык барын ишеткән юк иде, ни гаҗәптер.

Л ә м и г а. Йә, куегыз әле аны!

Л а р и с а. Авыру мин. Каным начар.

Г ө л б а н у. Менә, менә! Үзем дә шулай дим... Яңартырга кирәк синең канны...

К а ш ш а ф. Ләмига, синең сүзне көтәбез.

Л ә м и г а. Лариса, кызым, рәнҗемә туры сүзләргә. Сине авыл белән кабул иттек... Карадык. Син безгә бик кадерле зат булдың. Хәзер дә шулай. Кан яңара торган яз җитте!

Л а р и с а. Ләмига апа, җаным... Син мине куасыңмы?

Л ә м и г а. Куу дип аңлыйсыңмы син бу сүзләрне?.. Кумыйм. Хакым юк... Үзгәртергә тырышып карадым сине... Әйе, хәзер куркаклыгың узды. Төннәрен чыгып китә аласың!.. Соң гына кайтасың... Тик көләгәң дә, салкын җилең дә үзең белән янәшә йөри икән синең. Син әлегә безнең авыл гаиләсендә. Синең өчен без җавап бирәбез.

Л а р и с а. Хәзер сугыш заманы.

Л ә м и г а. Сугыш заманы булганга түзәрем юк та шул!

Г ө л б а н у. Әйт барын да!

Л ә м и г а. Ил-көн алдында көпә-көндез азынуыңа чыдый алмыйм!

Н а и л. Ләмига апа, юкка кимсетәсең аны!

К а ш ш а ф. Ир була бел, дәшмә!

Л а р и с а. Шулай инде, кеше күзендәге кылчык та күренә. Ә үз кызың?! Үз матурың, Шафикаң? Фронтка

барып та кермәгән килеш егет муенына асылынган иде... Мин аны егете белән бергә коткардым бит!

Наил. Кирәкмәс иде, Лариса.

Ләмига. Ачулы тел ни сөйләмәс. Рәнҗемим...

Гөлбану. Бәлки, син әйткән хәбәр дөрестер дә, Лариса. Мәгәр яман хәбәргә куанган кеше мөртәт була.

Лариса. Мин куанаммы? Болай гына әйттем... Көчсезлегемнән әйттем... Гафу ит мине, Ләмига апа.

Наил. Тынычлан, Лариса. Уйламагыз, Лариса әйбәт кыз ул. Әгәр ул булмаса, әгәр ул булмаса... Шафика мине онытты! Ул мине яратмады. Мин, мин...

Кашшаф. Син, син... Их, син, егет, борының җебек!..

Наил. Лариса, әйдә безгә. Әйдә! Әллә кайчан алып кайтырга кирәк булган сине!

Гөлбану. Кем сыйфатында алып кайтасың инде син аны, улым?

Наил. Нигә? Шафиканы коткарган өчен Ләмига апаларда тордымы? Торды. Мине коткардымы? Коткарды. Ул безнең кадерле кунагыбыз.

Лариса. Юк! Кунак буласым килми!

Гөлбану. Кем буласың килә соң синең?

Лариса. Ләмига апа! Бүгеннән эшкә чыгам... Кая кушсалар, кая җибәрсәләр, барам. Әзер!..

Ләмига. Шулай да үзебездә калдыра алмыйм... Кызымны ямьсезләп телгә алып күңелемне каралттың. Бусагам дошманга биек, дуска тәбәнәк минем, Лариса. Ил бусагасы кебек. Ә син, Наил, ялгышма!..

Сәхнә караңгылана. Фронт. Бер-бер артлы шартлау тавышлары. Ринат ялгызы. Ваня керә.

Ваня. Әһә! Күтәр кулыңны!

Ринат. Шаяртма әле, Ваня.

Ваня. Ишетәсеңме, аталар.

Ринат. Тынмыйлар. Кичә без эләктергән «тел» һөҗүм турында бер сүз дә әйтмәгән иде, ә бүген...

Ваня. Тел яшергәнне туплар сөйли бүген, Ринат... Син нишләп ялгызың?

Ринат. Шулай...

Ваня. Разведчик Ванька Жуковтан качып котылырмын дигән идеңме? Барыбер таптым...

Ринат. Яшеренергә уйламадым да... Күңел нигәдер борчыла.

Ваня. Күңел һәрвакыт борчулы бит, Ринат.

Ринат. Бүген аерата күңелсез!

Ваня. Аталар, шуңа ул!.. (*Пауза.*) Ә без нәкъ сугыш беткән көнне Люся белән Белоруссиягә кайтабыз.

Ринат. Кайчан бу турыда договор төзеп өлгердегез әле?

Ваня. Әллә кайчан. Беренче очрашканда ук.

Ринат. Нихәтле таныш булып та минем бу хакта сүз башлый алганым юк.

Ваня. Кара аны, соңга калма! Җиңү көненә юл ерак, беләбез. Әмма ул көнгә якынайгач матур кызларга иялəр артыр... Хәзер, читен чакта килешеп куярга кирәк... Мин, Ринат, партиягә керергә булдым... Хәзер минем Люсям да бар, көчем артты.

Ринат. Котлыйм, дустым. Әйе, синең Люсяң бар.

Ваня. Бар сиңа! Әнә Шафика килә, ә ул юк.

Ринат. Разведчикка ялгышырга ярамый, Ваня!

Ваня. Чыннан да! Люся!

Люся керә.

Ринат. Люся! Шафика кайда?

Люся. Тукта, Ваня. (*Пауза.*) Юк. Шафика кайтмады.

Ринат. Ничек?

Люся. Шулай. Ул НПдан ерак та түгел чаукалыкка урнашкан иде. Кичә ул постта көне буе мин булдым. Кичә тыныч иде. Бүген фашистлар иртә таңнан НП тирәсен ут астына алдылар. НП белән элемтә өзелде. Шафика да юк. Безнекеләр ике-өч мәртәбә узарга талпынып карады, фриц ирек бирми. Төнне көтәбез.

Ринат. Ә без монда...

Ваня. Әйе.

Люся. Ул үзе дә караңгы төшкәнне көтәдер.

Ринат. Яраланган булса?.. Канга батып шунда ятса?..

Люся. Ни уйларга да аптыраган.

Ринат. Ваня!

Ваня. Тыңлыйм, иптәш өлкән сержант.

Ринат. НП безнең маршрутта иде бит ул.

Ваня. Әйе, Ринат, таныш урыннар. Чаукалык та күзгә таныш.

Ринат. Хәзер мин командир янына барам. Әгәр ул рөхсәт итсә, син миңа ияреpсеңме?

Ваня. Сиңамы, иптәш өлкән сержант?! Һе...

Ринат. Дус син, Ваня, чын дус!

Ваня. Башкача булыр дип уйлаган идеңме әллә?

Ринат. Юк, Ваня. Юк, Ванька Жуков.

Люся. Ваня, син...

Ринат. Исән ул, исән. Беләм. Мин командир янына киттем. (*Чыга.*)

Люся. Ваня... Шушы кыска очрашуларда да син бик күп сөйләп җибәрә идең. Күбесенә ышана идем, бик күбе-

сенә ышанып та бетми идем... Ә бүген... бер сүз әйтмәдең, һәм мин башка көннәрдә сөйләгән бөтен сүзләреңә ышандым.

Ваня. Сугышның үз җае бар икән аның, Люся. Гашыйклар да монда башкачарак аңлашалар... Башкачарак сөяләр...

Люся. Риза мин, Ваня! Риза! Синең белән... Гомернең актыккы көненә хәтле бергә... Сиңа малай булэк итәргә дә риза! Зәңгәр күзле булыр ул, нәкъ синең төсле! Барына да риза, барына да... Хәзердән үк риза, бүгеннән үк... Исән йөреп, сау гына кайт...

Ваня. Сау бул, Люся...

Палата. Караватта Ринат ята. Аның янында Шафика утыра. Люся керә. Пауза.

Люся. Үзгәреш юкмы?

Шафика. Үзгәреш дип...

Люся (*паузадан соң*). Син бар, чак кына әл-хәл ал. Мин утырып торыйм.

Шафика. Ял сиңа кирәк. Син снайпер. Без мондагылар...

Люся. Ял да ителми. Әллә ни эшлисе килә! Әллә ни генә!

Шафика. Сабырың җый, дустым.

Люся. Мин аларның авылларын таба алырмынмы?

Шафика. Әгәр бик теләсәң... Әгәр бик тырышсаң, бәлки...

Люся (*Ринатка ишарәләп*). Икебезгә берәү калды... Анысының да чыкмый калган җаны гына бар.

Чыга. Пауза.

Ринат. Көнме, төнме?

Шафика. Көн, бәгырем, көн.

Ринат. Син ничек монда?

Шафика. Монда, җаным, монда.

Ринат. Шафика...

Шафика. Бүген ничәнче көнең...

Ринат. Хәлең ничек?

Шафика. Күрәсең ич, әйбәт! Йөрим! Дүрт саным исән. Шулай диләрме әле? Бәбәй туганда «Дүрт саны исән булсын» диләрме?.. Тиздән мине чыгарырлар да. Колак кына бик шәп ишетеп бетерми.

Ринат. Ә мин?

Шафика. Яныбызда гына мина ярылды. Мине алып чыкканда, Ваня белән икегез арасында мин идем... Ваня юк... Ә син...

Р и н а т. Көн диденңме, Шафика. Көн түгел, төн икән, төн. Ваня юк... Аның өчен үч алыр иде, Ринат та сугышны тәмамлаган.

Ш а ф и к а. Син тынычлан, ярсыма.

Р и н а т. Караватта ярсудан илгә ни файда?!

Ш а ф и к а. Син үз бурычыңны, намус кушканны үтәдең.

Р и н а т. Минем бурыч шулай аз дип беләсеңме син? Заставада безнең егетләрне күрмәдең бит син... Әле алар өчен дә... Ванька Жуковны кая куясың?!

Ш а ф и к а. Өметеңне өзмә генә!..

Р и н а т. Өмет... Зур сүз ул... Кеше иң әүвәл үз көченә таянып өметләнергә тиеш.

Ш а ф и к а. Сине тылга, госпитальгә озаталар иде, менә ничәнче көн яңгыр. Оча торган көн түгел.

Р и н а т. Кошлар оча бит, нигә оча торган көн булмасын?

Ш а ф и к а (*шатланып*). Кошларны күрәсеңме?.. Оча кошлар, оча! Мин кош оя типмәс көнне туганмын. Бәхетсез көнгә юрыйлар аны... Ике тапкыр үлемнән котылдым инде. Икесендә дә син минем янымда булдың...

Р и н а т. Сөйләшмик, зинһар, минем хакта.

Ш а ф и к а. Мин синең хакта гына сөйләшәм дә!

Р и н а т. Кем белән?

Ш а ф и к а. Люся белән... Кошлар белән... Күк белән... Син яткан карават белән... Ул да синең тән авыртуыңны тоядыр бит? Фәкать синең хакта гына! Чөнки син — минем киләчәгем, тормышым, дуслыгым, матурлыгым.

Р и н а т. Син кем турында сөйлисең алай? Кайчангы Ринат турында?.. Әгәр хәзергесе икән, син бернәрсә дә аңламыйсың дигән сүз.

Ш а ф и к а. Аңлыйм, сөеклем, аңлыйм.

Р и н а т. Бөтен тән, күзәнәкләр, җан ут эчендә... Безнең янда шартлаган минаның бөтен уты миңа күчкән икән... Ваняга салкыны, миңа уты...

Ш а ф и к а. Мине моннан озатырга дигәннәр иде, үтенгәч калдырдылар. Начальник булышты. Бик кешелекле апа!

Р и н а т. Китәсең калган, Шафика.

Ш а ф и к а (*рәнҗеп*). Нигә?

Р и н а т (*озак паузадан соң*). Ныклап дәвалан... һәм күрмә мине бу хәлдә...

Ш а ф и к а. Мин синең хакта барын да уйлап куйдым, Ринат.

Р и н а т (*әрнеп*). Шулай ук мәңгелек гарипмени мин? Минем өчен дә уйларга калдымыни сиңа, кадерлем?

Ш а ф и к а. Госпитальдән туп-туры безнең авылга кайтасың. Туп-туры безгә. Үзебезгә.

Р и н а т. Безнең авыл кызыл яр астында... Турыбызда куш өянке. Бу сүзеңнең минем өчен никадәрле авыр икәнен белсәң иде син!

Ш а ф и к а. Яраң авыр. Госпитальдән соң сиңа барыбер ял кирәк булачак. Әни карар сине.

Р и н а т. Ә сугыш?

Ш а ф и к а. Сугыш? Дошман җиңелер.

Р и н а т. Ничек инде мин, егет башым белән, сугыш бетмәгән хәлдә кыз йортына имгәк булып кайтып егылыйм?

Ш а ф и к а. Син — һөнәр иясе. Машина йөртә беләсең. Авылда эшсез итмәсләр. Тик ятмассың. Әнием сине бик яратыр.

Р и н а т. Гайре табигый хәл бит бу, Шафика!

Ш а ф и к а. Сугыш үзе гайре табигый хәл түгелмени, Ринат?! Хәзер элеккечә яшәп булмастыр кебек. Без гапгадиләр идек, ваемсыз идек, беркатлы идек. Сугыш боларны бездән ботарлап тартып алды. Алмашка ниләр биргәндер, әлегә аңлау да, аңлату да кыен. Сугыштан кайткач без элекке төсле була алмабыз инде. Шуның өчен әйтәм, бул тыныч! Безгә кайт, Ринат. Шулай кирәк, бәгырем, шулай.

Р и н а т. Кем син? Изгеме? Фәрештәме? Изгеләрнең шундый тере, кайнар куллары буламыни?..

Авыл. Ләмигалар өе. Ул ялгызы. Таякка таянып Р и н а т керә.

Р и н а т. Дөрес кердем микән?

Л ә м и г а. Әйдүк, әйдүк! Нинди ялгыш керү ди ул. Кунак булырсың. Сәфәрче икәнсең, күрәм. Самавырым да тиз кайный.

Р и н а т. Сез Ләмига апа бит?

Л ә м и г а. Үзең кем буласың син? Бер дә төсмерләмим. Имән урамының читтә йөргән Хәйри зимагур улы дисәм...

Р и н а т (*елмаеп*). Турыгызда куш өянке... Авылыгыз кызыл яр астында.

Л ә м и г а. Күзләр бирешә башлады, улым, гаепләмә.

Р и н а т. Сез мине белмисез, Ләмига апа. Мин кызыгыз Шафика белән бер фронтта булдым. Хәзер госпитальдән кайтып киләм.

Л ә м и г а. Шулаймыни, куанычым?! Кайчанрак күрдең аны? Кузгалма син, утыр. Кай төшең яралы? Үзең кайсы як кешесе? Кая юл тотасың?

Р и н а т. Моннан ике ай элек бергә идек. Госпитальгә килеп тә озатып калды. Сезгә сәлам алып кайттым.

Л ә м и г а. Яхшылыкны онытмагансың, рәхмәт. Ничек керәсе иттең, рәхмәт төшкере.

Р и н а т. Детдомда үскән идем. Әле шуннан килешем... Торырга чакыралар... Эвакуация белән бик күп балалар килгән. Моннан нихәтле ятим өстәлгән. Элек ун бала яшәгән бүлмәләрдә хәзер утызар кеше. Шофер идем мин... Яхшы һөнәр! Автомеханик булып та эшли алам. Машиналары гына юк. Сугышка хәтле берәү бар иде, анысы да ватылып иске чаналар арасында тутыгып ята.

Л ә м и г а. Ятим-ялпы икәнсең...

Р и н а т. Шулайрак идем. Шафика белән бер фронтта сугыштык. Якташлар кадерле анда, таныштык та... Киткәндә менә озатып калды, хат бирде.

Л ә м и г а. Яле, яле. (*Хатны ала.*) Үзеннән байтактан юк иде шул. Яле, үзең генә укып бирче. Күзем, күзләрем...

Р и н а т. Хат сезгә язылган. Сез укыгыз.

Л ә м и г а (*укып*). Йә, ярар алайса. «Сәлам» дигән... «Бу Ринат атлы егет мине коткарып калды» дигәнме?

Р и н а т. Белмим, Ләмига апа. Ни язгандыр.

Л ә м и г а. Тора-тора гаҗәпкә калырсың, әй. Коткарды да коткарды... Тоталар да минем кызны коткаралар! Башка эшләре беткәндер боларның! Үзе ташкурчакмы әллә ул?

Р и н а т. Хатка өстәп бер сүз дә әйтә алмыйм. Тик шунысы бар, курчак түгел Шафика. Снайпер ул, мәргән, иң оста укчы! Немец окоплары авызына керә язып дошманны сагалый... Үзегез чамалагыз шуннан. Берьялгызы немецны сагалый!.. Коткарды дип, анысын ялгыш язган.

Л ә м и г а. «Бездә торсын» дигәнме?

Р и н а т (*көлемсерәп*). Юк, мин сездә калмыйм. Рәхмәт изге сүзенә! Детдомда чакыралар... Ватык машиналары өстенә ватык язмышлары бар. Ярап куярмын. Күпне күрдек, күпне.

Л ә м и г а. Китәм дисәң дә җибәрмим. Кунак итмичә, мунча кертмичә, коймак ашатмыйча. Кызым турында белгәннәреңне сөйләрсең. Чыннан да батырмы ул? Курыкмыймы? Кызым турында сөйлисең килмәсә, сугыш турында сөйлә!

Р и н а т. Хәзер алар икесе дә бер. Сугыш турында сөйләсәң Шафика турында булып чыгар... Аның турында сөйләргә тотынсаң, сугыш турында сөйләргә генә кала!

Л ә м и г а. Мәгънәле сүз әйттең, улым. Ипле бала күренәсең... Мин хәзер әйләнеп кайтам.

Чыга. Л а р и с а керә.

Л а р и с а. Ринат! Мин сине урамнан күреп калдым.

Р и н а т. Лариса апа! Һаман монда икәнсез!..

Л а р и с а. Кайларда булыйм? Кайларга барыйм?! Син

уйлама, мин монда тик ятмыйм. Бер көн тик торганым юк! Колхоз эшенә чыгам, өй арасында тынмыйм!.. Ярарга тырышам.

Ринат. Син канәгатьме, әллә?..

Лариса. Бик канәгать...

Ринат. Әллә бәхетле дәме?

Лариса. Әлеге бәхетле дә!

Ринат. Илгә файда китерәм дип уйлап яшисеңме?

Лариса. Бөтен кеше дә алай уйлап тормыйдыр инде.

Ринат. Бөтен кеше дә! Йә?

Лариса. Анысын ничек әйтә алыйм?

Ринат. Шуңа сорадым... Бәхетле дисең, канәгать дисең, ә үзеңнең күзең ишектә. Кемне сагалыйсың син, кемне куркып көтәсең?

Лариса. Мин бары тик синнән куркам, Ринат.

Ринат. Курыкма, мин сине җылы урыныңнан куып чыгарырга кайтмадым.

Лариса. Мин сиңа аңлатырмын... Алай түгел ул. Ләмига апаларда тормыйм мин хәзер... Мин күршеләрдә.

Ринат. Шафика өендә урын булмадымы? Сыймадыңмы?

Лариса. Минем хакта берәр начар сүз ычкындыра күрмә, ярыймы? Бик тырышам мин хәзер, бик.

Ринат. Нигә шулай дер-дер киләсең?

Лариса. Сугыш бит... Әйбәт кенә үрә башлаган тормышымны син җимереп китсәң, тагын кая барырмын?

Ринат. Алайса, син миңа ялганладың... Бәхетле түгел син.

Лариса. Ничек?

Ринат. Канәгать кенә икәнсең...

Лариса. Бәхетсез башкайларымны ашарга кайткансың икән!

Ринат. Кызык бит! Сугыш икәнен онытмагансың!.. Димәк, елның-көннең нинди икәнен сизенәсең... Безне монда Шафика җибәрде... Безне кайтарды, үзе фронтта! Авылы кызыл яр астында... Турыларында куш өянке... Ә ул канлы сугыш кырларында. Монда без! Син шул куш өянке астыннан узып йөрисең. Кызыл ярдан бәреп чыккан чишмәдән су чөмерәсең... Ә Шафика турында бер сүз сорамыйсың?.. Аның өлешенә керүеңме бу?!

Лариса. Таптама мине. Мин көчсез...

Ринат. Шафика сөйләве буенча син аның әнкәсенә сыенып байтак яшәгәнсең... Ләмига апага сыенып яшәгән кеше көчсез булырга тиеш түгел иде...

Ләмига керә.

Л ә м и г а (*яратмыйча*). Әһә, тагын бер коткаручы килгән икән. Саумы, Лариса.

Л а р и с а. Ләмига апа, суга барып килимме?

Л ә м и г а. Чиләкләрем тулы, чапчакларым мөлдерәмә. Күңелем дә туп-тулы...

Л а р и с а. Әллә мунча ягып җибәримме?

Л ә м и г а. Ничек килеп кердең әле син монда?

Л а р и с а. Мин бу егетне беләм. Сөйләгән идем ич. Бу — ул.

Р и н а т. Ләмига апа! Сез бая мине тыңлап бетермәдегез. Шафика чыннан да мине коткарып калды... Күңелдә мәңгегә уелып калган якты кешеләр бик күп булмыйдыр ул... Шуларның берсе минем өчен кызыгыз Шафика булды. Әгәр мин бүген сезнең җылы түрегездә утыра алам икән — бу аның эше... Әгәр бүген мин сезнең үткер күзегезгә туры карый алам икән — бу аның эше... Әгәр инде сез мин аңа яхшылык эшләп, шуның әҗерен түләтергә кергән дип уйласагыз, хаталанасыз. Тирән хаталанасыз!

Л а р и с а. Син бөтенләйгә монда кайтмадыңмыни?!

Л ә м и г а. Алай уйламадым. Уйламам да. Беләм, яхшы кешеләр күбрәк. Әле начары турында да яхшыны уйлыйсы килә.

Р и н а т. Кайту ягына килгәндә, Лариса апа, мине шушы кара юргага атлангач та (*таягын күрсәтә*) беркая бара алмас дип уйлама!

Л ә м и г а. Мунча ягарга дидеңме әле?

Л а р и с а. Кушсаң, ягам.

Л ә м и г а. Мунчасыз ярамас... Ягарсың... Тик менә бу егеткә, Ринат атлы дидеңме әле, бер соравым гына бар.

Л а р и с а. Мин чыга торыйммы әллә?

Р и н а т. Ашыкма.

Л ә м и г а. Ярар инде, хәерле булсын, сорамыйм.

Н а и л керә. Кызмача.

Н а и л. Солдат кайткан. Солдат!

Р и н а т. Кайтып җиттек, кордаш. Исәнмесез. Нигә кулыңны бирмисең?

Н а и л. Син чыннан да Шафика яныннан кайттыңмы?

Р и н а т. Аның яныннан да.

Н а и л. Фронтта ни хәлләр?

Р и н а т. Фронт хәлләре төрлечә. Әмма җиңәбез фашистны!

Н а и л. Син Шафиканы үз күзләрең белән күрдеңме?

Р и н а т. Бер фронтта сугыштык. Ул снайпер, мин разведкада.

Н а и л. Орденнарны чүпләгән син... Әйтер сүзең шул гынамы?

Р и н а т. Тагын ни кирәк соң сиңа, егет?

Н а и л. Тукта, Лариса. Монда син дә кирәк! Сүзне син башладың. Сүзне син чыгардың... Хәзер мин аннан барын да сорыйм. Яшерә алмас!

Л ә м и г а. Улым, дорфаланма... Югары авыл егете бит син!

Л а р и с а. Ринат... без аның белән якын дуслар. Аңлыйсыңмы?

Р и н а т. Аңлавын аңлыйм да...

Н а и л. Юк! Беренче башлап вәгъдәсен Шафика бозды!

Р и н а т. Минем белүемчә, аның берәүгә дә вәгъдә биргәне юк. Берәүгә дә.

Н а и л. Намуссыз кыз булып чыкты ул!

Л ә м и г а. Тыел, юньсез!

Р и н а т. Син солдат түгел! Түгел! Син болай гына гимнастерка киеп йөрисең.

Г ө л б а н у керә.

Г ө л б а н у. Солдат кайткан икән, төкле аягың белән, егет.

Р и н а т. Исәнмесез, апа.

Г ө л б а н у. Әйдә, улым, кайтыйк.

Л ә м и г а. Чыкмасын! Аның үз сүзенә җавап бирәсе бар.

Г ө л б а н у. Ярсып кереп китте. Военкоматка барган иде... Тагын алмаганнар... Ярсып ни файда?

Р и н а т. Кем соң бу?

Л а р и с а. Минем якын дустым дип әйттем бит.

Л ә м и г а. Наил атлы егет бу. Күршебез.

Р и н а т. Наил? Шушымы Наил?!

Н а и л. Наил шул. Белмәсәң бел. Дөньяда барлыгын да белми йөри идеңме? Әйтмәдеме Шафика?

Р и н а т (*паузадан соң*). Шафика барын да дөрес әйткән икән. Барысын да. Авылы турында да... Әнисе турында да... Тик бер сызыгында ялгышкан, бик каты ялгышкан...

Л ә м и г а. Ни-нәрсәдә инде аның ялгышы, мәсәлән?

Р и н а т. Менә шушы селәгәйне кыю, батыр егет, кече күңелле ярдәмчел дус, ипле-саф егет дигән иде...

Н а и л. Шафика шулай дидеме? Чынлап та шуны әйтә алдымы? Кыю дидеме?.. Их бу баш!

Ут сүнә дә, кабынып, сәхнәнең ике ягында басып торучы Ринат белән Шафиканы гына яктырта.

Шафика. Исән-сау Татарстанга кайтып җитүеңне ишетеп сөендем.

Ринат. Рәхмәт, бәгырем.

Шафика. Шунысын аңламадым: нигә бездә калырга уйламадың?

Ринат. Ярамый иде, Шафика. Сездә калсам, синең намуслы, саф исемеңә тап төшүе бар иде.

Шафика. Әни ничегрәк?

Ринат. Гаҗәеп апа! Гаҗәеп! Үзеңдә ни хәлләр?

Шафика. Картайгандыр инде, борчылгандыр?

Ринат. Җитез. Мөлаем. Күзләре янып тора.

Шафика. Миңа орден тапшырдылар. «Кызыл байрак» ордены.

Ринат. Котлыйм, җаным.

Шафика. Аннары, аннары...

Ринат. Ишетмим, ишетмим...

Шафика. Мине моннан җибәрерләр сыман. Тылга.

Ринат. Кайчан?

Шафика. Тиздән, диләр.

Ринат. Ялгамы?

Шафика. Түгел... Мин монысын хатта яза алмыйм... Укырга җибәрәләр.

Ринат. Синең үзгәрешсез булмас инде...

Шафика. Сөйләргә ярыган хәтлесен очрашкач сөйләрмен. Күп сөйләр дип өметләнмә, ярамый. Аннары белеп тә бетермим әлегә. Шунысы куанычлы: узышлый өйгә кагылып чыгарга мөмкинлек булачак.

Ринат. Серле укуың куркыта бераз... Сизенәм... Без озакламый аерылырбыз төсле. Кайтуың исә шәп булачак! Әниеңә бер машина утын кайтардым... Кашшаф абый белән мунчасын сипләдек... Машинаны ремонтлап бетердем дип язган идемме? Шундый егетләрем бар хәзер!

Шафика. Малайларың да безгә кайттымы?

Ринат. Бергә инде, һәммәсе бергә!

Шафика. Люсядан бик күп сәлам. Ул монда кала...

Ут яктыра. Авыл өе. Ләмига белән Кашшаф.

Ләмига. Шафика кайтканнан бирле ешладың әле, Кашшаф абый.

Кашшаф. Бүген ныклап сөйләшергә дип килдем, Ләмига.

Л ә м и г а. Нигә алай ашыгырга? Менә Шафиканы озатыйк, аннан сөйләшербез.

К а ш ш а ф. Синең белән сөйләшеп эш чыкмады, Ләмига. Мин сүзне Шафика белән башлап карамакчы булам.

Л ә м и г а. Ни әйтерсең инде син аңа?

К а ш ш а ф. Барын да... Яратуымны да, ялгыз тора алмавымны да.

Л ә м и г а. Әй, Кашшаф абый, җаныкачым!.. Синең белән кушылгач Ләмига Ләмига булып кала алырмы соң?! Менә нәрсәдән курка бит ул! Әйдә әле, яшьләр кайтты бугай!..

Чыгалар. Бераздан Р и н а т белән Ш а ф и к а керә.

Р и н а т. Әниең югында тагын бер соравым калды: кая җибәрәләр хәзер сине?

Ш а ф и к а. Анысы сер, Ринат.

Р и н а т. Разведчикка да ярамыймы?

Ш а ф и к а. Аңа ярамый да ярамый инде!.. Тик бөтенләй белми дә калма... Миннән хатлар бик озак килми торса да өметеңне өзмә...

Р и н а т. Син радисткамы, Шафика?

Ш а ф и к а. Сорама дигән идемме?

Р и н а т. Дошман тылына озаталармы сине?

Ш а ф и к а. Белмим. Белмим. Әни керә!

Р и н а т. Сорамыйм. Көтәрмен. Өметемне өзмәм. Мәңгегә!

Чыга. Л ә м и г а керә.

Л ә м и г а. Кайтмаган да кебек булдың, кызым.

Ш а ф и к а. И-и, әни... Кашшаф абыйны озаттыңмы?

Л ә м и г а. Хәзер әйләнеп керер әле.

Ш а ф и к а. Әйбәт кеше ул... Син ялгыз булмассың. (*Гөлбану керә.*) Наил кайда?

Г ө л б а н у. Капка төбегездә тәмәке тарта. Читенсенә.

Ш а ф и к а. Лариса апа минем китәсене беләме?

Г ө л б а н у. Белмәгән кая. Ул да фермадан әле генә чабып кайтты.

Л ә м и г а. Керсен, күрешсен. Үпкәләшүдән кемгә файда?.. Сугышны һәркем үзенчә кабул итә торгандыр инде.

Г ө л б а н у. Корт төшкән итне салкын кар базына куйсаң да барыбер бозыла бирә...

Ш а ф и к а. Наил кайчан китә?

Г ө л б а н у. Дүшәмбедә юлга чыгарга дигәннәр...

Ш а ф и к а. Бүген җомга...

Р и н а т белән Н а и л керәләр.

Р и н а т. Әйдә, әйдә! Чит кешеме син?

Н а и л. Юк ла! Болай гына... Ларисаны чакырыгыз сез. Җылый да җылый.

Л ә м и г а. Керсен, керсен.

Р и н а т. Лариса апа?!

Л а р и с а белән К а ш ш а ф керә.

К а ш ш а ф. Монда мин дә бар әле, егетләр. Арагызга аласызмы?

Р и н а т. Бергә инде хәзер, Кашшаф абый!

Ш а ф и к а. Элек бергә, бер көнне чыгып киткән идек, Наил...

Р и н а т. Ул көннәрне без заставада немец белән сугышып ята идек...

Н а и л. Мин сине куып та җитә алырмын әле...

Ш а ф и к а (*көлемсерәп*). Куышмыйк, Наил...

Р и н а т. Без сине озата барырбыз.

Л ә м и г а. Кызым!

Урамда үсмерләр җырлый.

Ү с м е р л ә р.

Без урамнан үткән чакта,
Дуылдасын тузаннар!
Гитлерның муенын борырбыз,
Сау булыгыз, туганнар!

Ш а ф и к а. Ринат, синең егетләр!

К а ш ш а ф. Бер-икесен монда калдырып булмыймы шуларның, Ринат?

Р и н а т. Икесе фронтка качкан иде, Бөгелмәдән тотып кайтардылар...

Ш а ф и к а. Алар сугышны күрмәсен иде инде.

Л а р и с а. Сугышны күрмәсеннәр иде...

Л ә м и г а. Балам...

Ш а ф и к а. Әни!.. Хәтереңдәме, әни? Беренче тапкыр чыгып киткәндә син: «Сорасаң, калдыралар сине»,— дигән идең... Хәзер мин, бу юлы, сәфәрнең тагын да хәтәррәгенә чыгам. Әгәр син: «Юк!» — дисәң, мин уйлап карармын...

Л ә м и г а. Кызым! Балалар! Яши-яши тагын бер хәл белән очрашасың икән... Үзең аралашып яшәгән кешеләр арасында берзаман син өлкәне яки иң өлкәне булып каласың икән. Менә без монда ничәү? Урамда күпме кеше? Арабызда өлкәнебез Кашшаф абый, аннан кала мин... Сез китаплардан гына укыган байтак вакыйгаларның

шаһиты мин... Бик җаваплы икән әнә шул өлкәнлекне тоюю. Дөнья чатакларын сугышка сылтаучылар да булыр... Әйе, сугыш безне нык үзгәртте. Горурлык хисебезне арттырды. Без халык буларак үзебезне бөтенрәк, хәллерәк тойдык. Шуңа күрә сиңа бер генә сүзем бар, кызым: «Калма! Бар. Кыйна дошманны!»

Шафика. Әнием, әнием!

Лариса. Кичер, Шафика.

Кашшаф. Сүзем бар иде сиңа, кызым, әйләнеп кайткач инде!

Наил. Бәлки, миңа да озата барырга рөхсәттер?!

Шафика. Рөхсәт... Ринат, әйдә... Хушыгыз, авылдашлар! Хушыгыз, дуслар. Әни, хуш!..

Пәрдә.

*1974—1975 еллар,*
*Казан—Займище*

# *Ефәк баулы былбыл кош*

*Драма ике кисәктә*

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең иледә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!

*Кызлы йортка килгән яучылар җырыннан.*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Мияссәр.
Рәшидә.
Әсма.
Рәсим.
Шифан.
Әдһәм.
Хурия.

Вакыйга XX гасырның 80 нче елларында, картлар картаеп авылдан китәргә мәҗбүр булган, яшьләр исә авылда калырга һич тә теләмәгән кискен бер вакытта бара.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Күл буе. Агачлык. Бер якта интернат почмагы да шәйләнә. Мияссәр кармак салып утыра. Мавыккан, яныннан узып баручы Рәсимне күрми. Рәсим дә, ашыкканга күрә, картны күрми. Шунда ук өр-яңа бәби арбасы. Рәсим артыннан Әсма килә.

Әсма. Рәсим улым, Рәсим, дим!

Рәсим туктап тормый, югала, һич көтелмәгән яктан Шифан керә. Әсма аңа каршы бара.

Әсма. Шифан! Ни булды сезгә?

Шифан да тукталып тормый, ишетми дә, кырт борылып чыгып китә.

Әсма. Һич аңламыйм! Ни булды боларга?! (*Чыга.*)

Шифан керә, аның артыннан Рәсим ияргән.

Рәсим. Шифан! Шифан!

Шифан эндәшми, чыгып китә. Рәсим ялгызы. Әсма керә.

Әсма. Берәр нәрсә аңлатасыңмы, юкмы? Нигә качышлы уйныйсың? Анамы мин сиңа, юкмы?!

Рәсим чыгып китә, яр буеннан Мияссәр калкына.

Мияссәр. Күл буенда мондый ыгы-зыгыны байтактан күргән юк иде. Карт-корыга аңа ни? Йөриләр адымнарын санап! Яшьләр шул, яшьләр! Алар бар җирдә хәрәкәте дә бар, тизлеге дә, ашыгыч йомышлары да күп.

Әсма. Мияссәр абзый, коры куаныч, син мондамыни?

Мияссәр. Нишлисең?! Монда шул. (*Сузып.*) Картлар интернат-йортында.

Әсма. Рәсим улым кайтып төште бит.

Мияссәр. Күрәм.

Әсма. Нигәдер көлемсерәдең?

Мияссәр. Нашатыр кыстырып җибәргәннәрме әллә, дим? Кайтканнан бирле юрга тайдай чаба да чаба. Әле Шифанны эзли, әле Шифаннан кача.

Әсма. Бардыр инде, Мияссәр агай.

Мияссәр. Тукта!.. Ә Шифан елый да елый!

Әсма. Елый?

Мияссәр. Гыйльметдингә укол кадарга керде, куллары калтырый.

Әсма. Сизенәм.

Мияссәр. Ни булган? Студент улың күчтәнәчкә күңелсез хәбәрләр алып кайтканмы?! Яшьләрдән чыккан күңелсезлек безне дә бик борчый.

Әсма. Әй, Мияссәр агай, үземнең дә юньләп сөйләшә алганым юк. Улымны алыштырып җибәргәннәр, дияр идем, үзе!

Мияссәр. Шифан кызганыч! Һәйбәт медсестра, бигрәк сылу бала, риясыз.

Әсма. Әле кызганырлык әллә ни юк бит, Мияссәр абзый! Алай ук хафаланма.

Мияссәр. Бүген карыйм, карт-корылар гаҗәп иртә уянганнар да коридорда кыштыр-мыштыр йөриләр. Сөйләшүләр шыпыртланган. Яшьләр хәле картларны борчымый калмый бит.

Әсма. Үз әти-әнисе берни белми, сез, төн ябалаклары, барын белеп, тикшереп торасыз тагын.

Мияссәр. Тукта, алай димә син, Әсма. Ата-ана күп

чакта күрми кала ул. Менә мондагы картларның, карчыкларның фаҗигасе дә шунда: алар үзләре искиткеч әйбәт булганнар, ә менә балаларының кая аяк атлавын күреп бетермәгәннәр.

Әсма. Алай димә, Мияссәр агай!

Мияссәр. Баланы, яшьләрне тәрбия итү, һай, авыр, әкәмәт икән ул! Әле шушы арада гына укыдым, яшь буынны тәрбия итү мәсьәләсендә безнең илдә, беләсеңме ничә галим эшли?

Әсма. Ундыр инде, йә йөздер.

Мияссәр. Ун мең галим эшли! Ун мең!

Әсма. Минем улымның монда ни катнашы бар?

Мияссәр. Кайтты. Шифан елый. Интернат гү-гү-ү килә.

Әсма. Бәйләнчек кеше син, Мияссәр агай!

Мияссәр. Ул гадәтем бар! Үз семьяң булмагач, читләр белән мавыгып, ятлар белән юанып яшисең шунда.

Әсма. Өйләндерик соң үзегезне?!

Мияссәр. Ул сүз белән шаярма, Әсма.

Әсма. Гыйшык тотып йөргән әбиегез дә бар бугай. Йә, йә, шаярып кына әйттем.

Мияссәр. Авыр шаярдың, авырттырып.

Әсма. Үземнең дә авыр көнем, Мияссәр агай.

Чыга. Мияссәр, кармакларын рәтләп, тагын тал арасына кереп чүгәли. Шифан керә, ул Мияссәрне күрми, талга таянып җырлый.

Көлүеңне сөям нурландырып,
Нигә моңланасың бу ара?
Матур күзкәйләрең кырыс карый,
Ник ташлыйсың авыр уйларга?

Сүзләреңнең беләм кайнарлыгын,
Нигә салкын алар бу ара?
Офыклар ак, көннәр, күкләр аяз,
Үпкәң бармы әллә дөньяга?!

Мияссәр. Их, юк бит балыгы, юк! Сиңа бирер идем, Шифан, сиңа.

Шифан (*кинәт борылып карый*). Рәхмәт, Мияссәр агай.

Чыга. Рәшидә узып бара, арба янында туктала, кыштырдый, Мияссәр борылып карый.

Мияссәр. Рәшидә-ү!

Рәшидә (*ни әйтергә белми аптырап*). Утырасыңмы, Мияссәр абзый?

Мияссәр. Урын сиңа да җитәрлек, кил, күңеллерәк булыр.

Рәшидә. Балыгы юк күлгә кармак салып...

Мияссәр. ...утырырга бер тиле баш та җиткән, дисеңме?

Рәшидә. Алай димим дә... (*Уңайсызланып.*) Кеше көлдерәсем дә килми.

Мияссәр. Миннән көләләр, беләм! Бая карыйм, күрәм: картлар йортыннан берәү тәрәзәгә ябырылган. Кучеп утырдым. Монда агачлык, ышыграк.

Рәшидә. Көләләр, дип, Мияссәр абзый... Әллә ничек, алай да! Менә һич кирәкмәгәнгә бәби арбасы сатып алып кайткансың...

Мияссәр. Матурмы?

Рәшидә. Җитмеш-сиксән яшьлек карт-корыларны үртәр өчен алдыңмы моны?

Мияссәр. Акча әрәм итеп, иеме?

Рәшидә. Эш акчада гынамыни? Хәер, акчасы да жәл.

Мияссәр (*арба янына килеп*). Матур шул, матур. Күрдем, кызыктым да алдым. Яшьрәк чагымда тал чыбыгыннан бишек үрә идем мин авылда. Кабыктан бәби арбасы кирәксә дә, миңа киләләр иде. Туйлар миннән башка узмый иде, Рәшидә-ү! Яучы да идем мин. Чалбар балагын чыгарып салыр идем дә, билне чуклы зәңгәр зәр белән буып, кызлы йортка барып керер идем. (*Җырлап сәхнә буйлап йөри, аягы чак кына аксый.*)

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең илеңдә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!

Ишетәсеңме? «Ефәк баулы былбыл кош» дип кәләшне атаганнар безнең борынгы Болгар илендә! Шуннан калган җыр булыр бу! Ә егете «лачын кош» булган. Былбыл кошлар белән лачыннарны бик күп кавыштырдым мин заманында!

Рәшидә. Былбыл кош очкан. Лачын каргага әйләнгән. Булган да уңган. Беткән. Акча әрәм итеп, валлаһи, нигә шушы күз көеген алып кайттың?! Балыксыз күлгә кармак саласың? Билләһи, картлар йортына бер экият булдың.

Мияссәр. Шыр юләр карт, җиңеләйгән, диләрме?

Рәшидә. Алай ук димиләр. Минем алда каты сүз әйтергә базмыйлар!

Мияссәр. Әһә, синең алда каты сүз әйтергә ярамаганын сизәләрме?

Рәшидә. Ни уйлап чыгарасың тагын?

Мияссәр. Һәммәсенә күнегерләр.

Рәшидә. Килгәнеңә ике ел булдымы инде?

Мияссәр. Ике ел да өч ай. Тагын унике көн. Бүген унөченче көнем. Җитмәсә, туган көнем, җитмеш тулды!.. Сугыштан кайтып төшкән көнем. Анысына утыз биш ел тулды... Күнегерләр дигәч тә, сөенмәдем! Күнекмәсеннәр. Бусы начар. Ичмасам, мәзәк итеп сөйләп куансыннар, көлсеннәр. Кырык өч карт-коры... Сирәк көләләр! (*Рәшидә китә башлый.*) Ашыкма инде.

Рәшидә. Туган көнең икәнен беләбез. Кичке чәйдә котлаулар булыр.

Мияссәр. Кирәкми лә!

Рәшидә. Сәрбиҗамалны, бүлмәдәш карчыгымны авылына озатабыз.

Мияссәр. Бер әйткән идең. Мине тәмам хәтерсез дип уйлыйсыңмы, Рәшидә-ү?!

Рәшидә. Машина көтәбез.

Мияссәр (*чак кына мутланып*). Бүлмәңдә берүзең каласың икән.

Рәшидә. Мияссәр абзый, тукталуымның сәбәбе шул, кичә үк әйтермен дигән идем...

Мияссәр. Әйттең инде, әйттең, калдырмадың.

Рәшидә. Бусын әйтмәдем. Сәрбиҗамал киткәч, безнең бүлмәгә кереп йөрмә инде син.

Мияссәр. Нишләп?

Рәшидә. Әллә ни уйлаулары бар. (*Үзе дә сизмәстән, бәби арбасын Мияссәр кулыннан алып тәгәрәтә башлый.*)

Мияссәр (*рәхәтләнеп көлә*). Миңа җитмеш!

Рәшидә. Котлы булсын!

Мияссәр. Син чак кына яшьрәк. Ни сөйләрләр?

Рәшидә. Күп калгандырмы гомер, аздырмы, гел монда яшисе, кеше күзендә. Авыр сүздән бер куркам, гайбәттән ике!

Мияссәр. Тиле-миле карт нишләмәс, дисеңме?

Рәшидә. Берүк мине сүздән арала, читен хәлдә калдыра күрмә.

Мияссәр. Ә-ә-әх, Рәшидә-ү! Хәзер акыллы сүз әйтсәм дә, ышандыра алмам инде. Ә мин, Сәрбиҗамал карчыкның китүен яхшыга юрап, сиңа бер арба сүз әзерләп йөргән булам тагын. Беләм, мине тыңламас өчен аның итәгенә тагылып йөрдең!.. Менә, китте дә барды!

Рәшидә чыга. Мияссәр дә күздән югала. Кармак сапларын шунда агачка гына элә. Рәсим белән Шифан керәләр.

Рәсим. Нигә миннән качасың?

Ш и ф а н. Кем соң син хәзер минем өчен? Кем?! Аңлата аласыңмы шуны?

Р ә с и м. Мин Рәсим.

Ш и ф а н. Беттеме? Өстәп әйтер сүзең юкмы?! Үтенеп, ялварып сорыйм. Эзәрлекләмә. Йөрмә минем арттан. Миңа болай да бик авыр икәнен сизмисеңмени? Син Рәсим генә түгел шул! Рәсим генә булсаң, белер идең, аңлар идең! (*Чыга.*)

М и я с с ә р. Типте бия тәртәгә!..

Р ә с и м. Шифан, Шифан! (*Чыга.*)

Мияссәр бәби арбасын тәгәрәтеп җырлый.

Әлли-бәү, бәлли-бәү!
Нәнекәчем-кошчыгым!
Әлли-бәү, бәлли-бәү,
Йомшак сары томшыгым...
(*Кинәт җыры үзгәрә.*)
Күлем өсләрендә ак томан,
Бу илләрдә күп тормам.
Язын торсам, көзен тормам,
Сагынырсыз, мин булмам.

Елама, әлли-бәү, бәлли-бәү!.. Яшьләр елый икән, монда картларның да гаебе бар.

Чыга. Пауза. Машина килеп туктала. М и я с с ә р, кире кереп, арбаны агач күләгәсенәрәк кертә. Чыгып китә. Сагаеп карана-карана Ә д һ ә м белән Х у р и я керәләр.

Х у р и я (*алданрак килә*). Кил, кил, курыкма!

Ә д һ ә м. Кеше-кара юкмы?

Х у р и я. Шушындамы?

Ә д һ ә м. Элекке килүләремдә шунда иде. Хәзер кая китсен? Кемгә барып сугылсын?

Х у р и я. Кешедән читенсенгән буласың, анаң җәннәттә яши икән әле!

Ә д һ ә м. «Җәннәт» димәгәннәр шул.

Х у р и я. Җәһәннәм дә түгел.

Ә д һ ә м. Әнә, кыегына «Картлар интернат-йорты» дип язганнар. Кара.

Х у р и я (*таякларны күреп*). Балык ашап яталар.

Ә д һ ә м. Иясе мондадыр, кузгатма.

Х у р и я. Үзләренә күрә түгел, бамбук таяклар! Теге җәфа әллә кайчан сорап йөри иде. Синең теләнче төпчегеңне әйтәм.

Ә д һ ә м. Ана кеше үз баласын «җәфа, теләнче» дип йөртә.

Х у р и я. Әй, әй! Берәүләр үз аналары янына килгәннәр икән, кояш батыштан чыгып маташа! Мин китереп тыктыммы әллә әниеңне бу җәннәт-җәһәннәмгә?!

Ә д һ ә м. «Җәһәннәм» дә димәгәннәр. Гап-гади колхозара интернат. Ин-тер-нат!

Х у р и я. Ә улыңны... җәфа димичә соң? Ел саен чалбар алыштыра.

Ә д һ ә м. Алдыра икән, буйга үсә.

Х у р и я. Үсә икән, тамагы тук, әнисе әйбәт карый!

Ә д һ ә м. Анысы, үпкәләштән түгел, Хурия, синең сүзне сүз итеп кенә китердем мин монда әнине. Өч малае бар килеш, чит кулларда ята.

Х у р и я. Күрәсеңме, аста күл, Әдһәм! Сикер, дисәм, сикерәсең. Сикерәсеңме?

Ә д һ ә м. Сикерми кара! Муенга таш бәйләп төртеп төшерерсең!

Х у р и я. Шулай диген, ишәгем.

Ә д һ ә м. Булган шул заманалар, ат белән иргә пачут булган. Хәзер сыер белән хатын-кыз алдынгылыкка чыкты. Закон да алар ягында, сүз дә.

Х у р и я. Ике сөйләшү юк, тәмам. Исерек булып кыланып анаң янына керәсең. Ул сине чеп-чи алкаш дип белә. «Бурычым күп, түләмәсәм, үтерәләр!» — дип тәгәрәп елыйсың. Һәм ике айлык пенсия акчасын каерып торып аласың.

Ә д һ ә м. Бирсә...

Х у р и я. Көтәргә исәбем юк, бирсә дә аласың, бирмәсә дә.

Ә д һ ә м. Бирмәсә, ничек аласың?

Х у р и я. Куркытасың! Өч якта өч малаең барын начальствога әйтәм, дисең. Пенсиясен аласың да аласың. Аның өчен генә мин килеп тә йөрмәс идем, рәхмәт, башка чакларда төгәл кайтарып тапшырдың...

Ә д һ ә м. Тагын ни җитми сиңа, ачкүз? Өч бүлмәле фатирың бар. Өч җанга! Тартма-тартма туннарың. Төргәк-төргәк акчаң.

Х у р и я. Сиңа әйтелгән: онытсаң, тагын кабатлыйм — аның өй саткан акчасы бер биш йөз калган булырга тиеш. Минем исәпләвемчә.

Ә д һ ә м. Биш йөз?!

Х у р и я. Син, онытма! Машина чираты җиткән! Миңа мең сум акча кирәк.

Ә д һ ә м. Мең сум? Узган айда гына «ике йөз җитми» дигән идең.

Х у р и я. Тотынды! Шуны бел: машина алгач, яңа күлмәк кирәкме? Кирәк! Күлмәккәятышлы муенса да

аласы булыр. Муенсага тиң алка! Тукта әле, ни сөйләшәбез? Өйгә кайткач аңлатырмын. Бар!

Әдһәм. Барыбер машинаны сатабыз, дисең ич.

Хурия. Башкалар ике бәягә алганда, нигә сатмаска? Алар безне талый, без дә юләр түгел, талыйк! Берне дә сатарбыз, икене дә... Бел, әгәр янында мин булмасам, син чеп-чи алкаш булып тайга урманында агач ега идең.

Әдһәм. Трамвайда йөрерлек акча бирмисең. Кулга талон тоттырасың... Беләм, ишеткән... Элек, «татар хатыны ниләр күрми» дигәннәр, хәзер — «татар хатыны ниләр күрсәтми»...

Хурия. Бар, ишәгем. Дуңгыз борыным! Бар!

Мияссәр керә.

Мияссәр. Кардәшләр, теге сезнең машинамы?

Хурия. Син автоинспектормы әллә?

Мияссәр. Түгел дә...

Хурия. Алайса, безнеке.

Әдһәм (*кәпәренеп*). Нәрсә булган?

Мияссәр. Сез монда берәрсе янына килдегезме, әллә узып кына барасызмы?

Хурия. Кара әле моны!

Әдһәм. Безне, без...

Хурия. Балык сөзеп карарга исәп.

Мияссәр. Бу күлдә балык юк.

Хурия. Сиңа ни кирәк соң, бабай?

Мияссәр. Бер бик хөрмәтле кешене озатасы бар иде. Безнең интернат ятимен. Станция ягына бармыйсызмы?

Әдһәм (*сискәнеп*). Кемне, кемне? Кая озатасыз?

Мияссәр. Бер әбине.

Әдһәм. Нинди әбине? Нигә безгә бәйләнәсең? Нигә аны безгә тагарга маташасың?

Мияссәр. Сәрбиҗамал китә. Җәйгә авылына кайта.

Хурия. Юк, юк, станция ягына бармыйбыз.

Мияссәр. Кая барасыз соң сез?

Әдһәм. Кайманга катык ашарга!

Мияссәр. Хәзер генә таныдым. Сине кайдадыр күргәнем бар. Ихлас. (*Чыга.*)

Әдһәм. Хәтерли! Картайгач, күз начарлана диләр тагын.

Хурия. Монда казлар да бар икән, Әдһәм.

Әдһәм. Закускага дисеңме?

Хурия. Бар, кер. Күр. Ал!

Әдһәм. Куркам.

Хурия. Башка чакта ничек алып чыга идең?

Әдһәм. Бүтән чакта теләсә нинди машинага уты-

рып килә идем. Әләгеп. Йөз грамм булса да кабып керә идем. Салып бир!

Х у р и я. Син рульдә. Машина кешенеке.

Ә д һ ә м. Керә алмыйм аек баштан! Кылана алмыйм. Мин сиңа артист түгел.

Х у р и я. Машина алыйк. Ике бәһагә сатыйк. Заманалар гына үзгәрмәсен. Күп итеп машина ясап, эшне бозып кына ташламасыннар. Гел җитмәсен ул әйбер-кара. Акыллы кешеләргә рәхәт була. Ике бәягә сатып, тагын берне алгач... Ун көн... юк, атна буе! Түгел лә, өч көн рәттән пиво эчертермен. Үзем!

Ә д һ ә м. Булмас! Ай башында егерме кап сигарет тоттырасың бит! Акча бирмәс өчен!

Х у р и я. Дөнья мәшәкатьләре җилкәңә басса, ата каз булып каңгылдарсың.

Ә д һ ә м. Тфү!

Х у р и я. Яле, осталыгыңны күрсәт. (*Әдһәм исерек булып кылана.*) Фи, моңа сукыр тавык та ышанмый. Менә күр. (*Үзе исерек булып кыланып күрсәтә.*) Җиде ел алкаш булып йөреп... Тфү!

Ә д һ ә м. Хурия, акчаң бүгенге көндә ике машинага җитә. Бәрәңге белән килька — кунак сыең да шул.

Х у р и я. Ике машина алабыз да, икесен дә озатабыз!.. Ах! Акчам күбрәк булсын иде әле!.. Җан рәхәте! Күңел гел сөенеп тора! Акча бар, акча бар, дип җырлый.

Ә д һ ә м. Син машина кибете ачканчы, оят булса да, әни янына керәм.

Х у р и я. Бар, минем ишәгем. Бар, минем акча янчыгым. Кер.

Әдһәм бара башлый, каршысына ак халаттан Ш и ф а н очрый.

Ш и ф а н. Исәнмесез!

Х у р и я (*Әдһәмне бер якка аралап*). Исән, исән. Әлегә аңа врач кирәкми.

Ш и ф а н (*Әдһәмгә*). Мин сезне беләм. Сез Рәшидә әби янына киләсез. Сез аның ерак туганы. Күчтәнәчләр китерәсез. Рәхмәт сезгә.

Х у р и я. Нинди Рәшидә? Без машина юарга гына туктадык. Юлда тузан, тузан! Фу, борын тишекләрең капкара! Бар!

Ш и ф а н. Ялгыштым микәнни?

Ә д һ ә м. Ялгыштың, ялгыштың.

Ш и ф а н. Рәшидә апаның ерак кардәшенә бик охшагансыз. (*Чыга.*)

Х у р и я. Нигә тормозга бастың?

Ә д һ ә м. Әнә бит, «рәхмәт», ди.

Х у р и я. Әйтсә соң?

Ә д һ ә м. Ай, әни үзе монда таба килә!

Х у р и я. Шулмы?

Ә д һ ә м. Килен! Әнине танымый башлаган!

Х у р и я. Күрмәгәнгә дүрт ел. Мин ычкындым. Кара аны, озаклама. Җебемә. Кил әле, түшеңә аз гына аракы тамызыйм. (*Нәни генә шешә чыгарып, түшенә аракы сөртә.*)

Ә д һ ә м. Калганын, калганын йотам!

Х у р и я. ГАИ түгел. Авызыңны иснәп карамас. Чү, бу яктан да кемдер килә.

Ә д һ ә м. Директорлары.

Х у р и я. Ул да сине таныймы?

Ә д һ ә м. Очратканы бар.

Х у р и я. Шылдык. Түшеңнән аракы очып бетәр инде. Иртәрәк тамыздым.

Чыгалар. Икесе ике яктан Р ә ш и д ә белән Ә с м а керәләр.

Ә с м а. Озаттыгызмы әбине?

Р ә ш и д ә. Китте.

Ә с м а. Утырып тор, Рәшидә апа. Таңнан аяк өстендә. (*Утырышалар.*) Монда җиләс. Син безгә килгәнгә дүрт ел булдымы инде?

Р ә ш и д ә. Әллә бер-бер жалу бармы?

Ә с м а. Юк. Нишләп алай сорадың?

Р ә ш и д ә. Сүз җаеннан гына. Дүрт ел тулып узды. Байтак гомер, байтак. Сиңа рәхмәт, Әсма... Син алмасаң...

Ә с м а. Сәрбиҗамал синнән ике ел алдан килгән, алайса?

Р ә ш и д ә. Әйе. Мин килгәндә ул монда иде.

Ә с м а. Тату тормыйсыз, ахры, сез? Әллә бүлмәдәш итеп синең янга башка берәүне кертергәме?

Р ә ш и д ә. Нишләп тату тормыйк ди?! Кем сүзе бу? Кеше сүзеннән, гайбәттән болай да бик куркам!

Ә с м а. Алайса, ике ай саен, ай актыгына таба, син аны нишләп авылына озатырга омтыласың? Кичә дә колагыма чалынып калды, бик нык үгетләдең.

Р ә ш и д ә. Кайтыр кешесе исән чакта авылын күреп калсын. Әйе, дөрес, якын туган-тумачасы юк, ятимә, мәгәр иске күршеләренең балалары бик тә әйбәт җаннар, ди. «Бөтенләйгә кайт, әби!» — дип тә әйтәләр, ди. Үз сүзе.

Ә с м а. Алай да... Ике ай саен шушы хәл кабатлана. Бармаса, үпкәләшәсез.

Р ә ш и д ә. Турысын ач, Әсма, берәр сүз ишеттерделәрме?

Ә с м а. Бүлмәгезгә Мияссәр абзый кереп йөри.

Р ә ш и д ә. Әллә ул сүз чыгардымы?!

Ә с м а. Юк ла! Намуслы карт.

Р ә ш и д ә. Йөремсәк җан бит. Урын таба алмый.

Ә с м а. Әллә Сәрбиҗамал көнләшәме, дип тә уйлап карадым.

Р ә ш и д ә. Син директор, Әсма, теләсә ни уйлый аласың.

Ә с м а. Миңа рәнҗи күрмә. Миңа сезнең тынычлыгыгыз кыйммәт.

Р ә ш и д ә. Яңадан безнең ишек тоткасына кагылып карасын, мин ул исәрне!..

Ә с м а. Исәр түгел ул, Рәшидә апа. Тынгысыз яшәгән, чәчрәп, хәзер дә шуны кумакчы була... Тормыш ул түгел, шартлар башка! Интернат! Ни әйтсәң дә, боегыр кеше боегырлык та!

Р ә ш и д ә. Авыр сүз ишетәсе килми, Әсма. Тормыш болай да нык тукмады безне. Инде җан тынычлыгына ирештек, дигәндә...

Ә с м а. Борчылма. Сөйләштек, гаепләшмәдек! Әйдә, керик. Чәй эчәрбез. Рәхәтләнеп утырырбыз. Тәмле сүз — җан азыгы булсын.

Чыгалар. Ә д һ ә м белән Х у р и я күренә.

Х у р и я. Эш беткән боларның! Җәннәт! Чәй эчәләр. Гәп куерталар!

Ә д һ ә м. Син аларның ни сөйләшкәнен аңладыңмы?

Х у р и я. Әллә... Тыңламадым! Әдһәм, бу арба машина багажнигына сыямы?

Ә д һ ә м. Китер аракыңны!

Х у р и я. ГАИ... Инспектор!

Ә д һ ә м. Мин үзем ГАИ! (*Шешәне талап ала.*) Имән экәләсе хәтле шешә тыккан бит, һу, карун! Саран бака!

М и я с с ә р керә.

М и я с с ә р (*шешәгә ымлап*). Һай-һай-һай! Көпә-көндез. Үзең машинада.

Х у р и я. Тай моннан, карт, тиз бул!

М и я с с ә р (*каранып*). Кармакларым! Ике ел беркем кагылмаган иде.

Ә д һ ә м. Нинди кармак, карт пәри? Монда балык юк, диден ич.

М и я с с ә р. Син алдыңмы, исерекбаш?

Х у р и я. Ник бәйләнәсең аңа? Менә ич кармакларың. (*Бөтенләй башка җирдән алып бирә.*)

М и я с с ә р. Исеректән кармаклар да аякланып кача икән. Машинага таба атлаганнар! Гаҗәп кешеләр булып

чыктыгыз әле сез. Беркая бармыйсыз. Нидер күзәтәсез... Тукта, директорны чакырыйм әле.

Х у р и я. Әдһәм! Өс, өс!

Ә д һ ә м. Карт! Стоп! Нигә бәйләнәсең? Сакалыңнан учлап күлгә салганны көтәсеңме? Нигә мин генә өркеп торырга тиеш? Куркытасым килә! Ыргытам хәзер күлгә!

Х у р и я. Мә, йотып бетер!

М и я с с ә р. Көпә-көндез, ә?!

Ә д һ ә м. Бәйләнә, карт пәри! Үзе! Ух-х! Мин сине!

М и я с с ә р. Кагыласы булма!

Әдһәм аны йолыккалый. Р ә с и м керә.

Р ә с и м. Бу ни хәл?

Ә д һ ә м. Нигә ул минем үртәлгән җанымны үрти?!

М и я с с ә р. Исерек ул, сак бул!

Р ә с и м. Эшне зурга җибәрәсегез килмәсә, хәзер үк моннан китегез.

Ә д һ ә м. Нишләп китим? Син кем?!

Х у р и я. Ну, кешеләр тар күңелле хәзер! Иркенләп машина юарга да бирмиләр!..

Чыгалар.

М и я с с ә р. Нишләде бу халык, ә?!

Р ә с и м. Хулиган!

М и я с с ә р. Син булмасаң, баш беткән иде, Рәсим улым. Бугазга үрелә бит, явыз. Каушап калдым.

Р ә с и м. Узып барам, күрәм... Мин болай гына!

М и я с с ә р. Болай гына түгел. Юк, Рәсим улым, җил исми яфрак селкенми. Карт бабаңны явыздан саклап калыр өчен дә ныгыган син. Явызы бар икән, кодрәтле табигать яклаучысын да әзерләп өлгерткән.

Р ә с и м. Мияссәр бабай, син Шифанны күрмәдеңме? Медсестраны?

М и я с с ә р. Иртәнчәк күргән идем, хәзер генә юк.

Р ә с и м. Табармын!

М и я с с ә р. Кер, сакалыңны кырырмын. Йөрмә болай йонга батып.

Р ә с и м. Сез элек тә парикмахер идегезме?

М и я с с ә р. Яшь чагында мин тимерче идем. Аннан, олыгайгач, колхоз машиналарын көйләүче булып йөрдем. Мастер-наладчик диләр иде.

Р ә с и м. Хәзер чәч кыручы, ә?!

М и я с с ә р. Кая барасың, ничарадан бичара.

Р ә с и м. Дөрес сөйлисең, Мияссәр бабай! Моны минем әни алдында әйтерсең, яме. Непременно! Шифанга да сөйләп күрсәт. «Кая барасың, авылда яшәп!» — диген.

М и я с с ә р. Ялгыз калган карт кая барсын, дидем мин! Ә болай... Менә син! Нинди тормыш күтеп тора сине! Колхоз стипендиаты булып иркәләнеп кенә укыйсың. Җәйләрен — ата йортында. Кунак! Белгеч, зоотехник булып авылга кайтып төшәсең...

Р ә с и м. Юк, боларын кузгатып торма, Мияссәр бабай, кирәкми.

М и я с с ә р. Ә кем көтеп тора! Нинди кыз!..

Р ә с и м. Көтә әнә, качып йөри!

М и я с с ә р. Кыз да шәп! Отличный! Сәгате җиткәч, белдерерсең, яучы булып үзем барам.

Р ә с и м. Мин үзем дә сөйләшә алам.

М и я с с ә р. Алмыйсың шул! Әнә ич, әнигә тегене җиткер, болай дип әйт, дип миннән ярдәм сорадың!

Р ә с и м. Анысы башка мәсьәлә.

М и я с с ә р. О, егет! Карт кешегә дә туктап ял итәр өчен зәңгәр күл буе гына түгел, күңел куаныр өчен кешеләр дә кирәк. Яшьләр — җирне-күкне мирас итеп алып кала торган өметле кешеләр кирәк. Менә Шифанга карыйм да сөенәм. Бетмәс куанычлар көтә бит аны!.. Шәп кыз, валлаһи! Нинди һәйбәт кызлар, егетләр бар авылда дип, көн саен куанып сөйләшәбез. Яшьләрне ярату — гомереңне озайту бит ул. Җан ял итә, сезгә карап! Син кайтып, сөенечебезне икеләттең. Гомерле булыгыз.

Р ә с и м. Мияссәр бабай!

М и я с с ә р. Әллә нигә күңел тулып китә. (*Чыга.*)

**Рәсим ялгызы. Тәмәке кабыза. Бәби арбасы янына һәркем үзенчә килә. Рәсим исә кулы белән буявын сөртеп карый. Кармак сапларын күрә, көлемсери.**

Р ә с и м. Да-а, монда кешеләр үзгәрмиләр. Кызык карт! Бер сүз белән резюме ясаганда — исәр! (*Әсма керә.*) Әни! Әти Чаллыга күчик дигәндә, нигә кузгалмадың? Ничек түздең? Ничек син шушы оешмада директор булып тора аласың? Мин ярты сәгатькә дә чыдамас идем.

Ә с м а. Утыр әле, улым. Иртәдән бирле сөйләшәсем килә.

Р ә с и м. Әйдә, сөйләшик! Дөнья күптән эзгә салынган. Нигә без үз тормышыбызны бутап, баш ватып интегәбез? Һәммәсе дә күптән ап-ачык икән!

Ә с м а. Сүзнең ни турыда икәнен сизәсең.

Р ә с и м. Бөтенесен сизәм! Син мине әрләргә керешәсең. Мин синең белән килешмим. Актыктан барыбер син минем белән ризалашасың!

Ә с м а. Алай да, тыңла!

Р ә с и м. Тыңлау кирәкме икән?

Ә с м а. Гармун алдырдың. Уйнамадың.

Р ә с и м. Шуны искә алып торасыңмы?

Ә с м а. Электрогитараны Казанга барып алдым. Икеөч чирттең дә ташладың! Сүз әйтмәү генә түгел, этиеңә дә әйттермәдем! Унынчыны тәмамлагач, авиационныйда бер ел укыдың. «Сызымнар күп, көне-төне укырга кирәк!» дип, яратмадың. Кайтып бер ел тик яттың... Әйе, китүчеләр бар, авыл шәһәрне азык-төлек белән генә түгел, эш көчләре белән дә туендырып тора. Әмма син авыл хуҗалыгы институтын үзең сайладың. «Минем урыным авылда икәнен аңладым!» — дидең. Этиең урнаштырды. Председатель! Колхоздан акча аласың. Егерме тәңкә түләп фатирда тотабыз.

Р ә с и м. Рәхмәт, әни, рәхмәт.

Ә с м а. Икеле-микеле характерыңны сизсәм дә, моңарчы түздем. Беләсеңме, нигә?

Р ә с и м. Син мине яратасың, әни.

Ә с м а. Ник бер чакта да каршы төшмәдем? Этиеңне тыеп, яклап килдем?! Нигә?!

Р ә с и м. Аналар һәммәсе дә шундыйдыр инде?

Ә с м а. Аналар шундый, хак. Син минем бердәнберем булдың! Врачлар катгый тыйганда, үземне үлем куркынычы астына куеп, мин сине таптым.

Р ә с и м. Боларны әйткәнең юк иде.

Ә с м а. Көне-сәгате җиткәнне көткәнмендер! Тыңла! Дүрт яшьтә чагында син: «Минем алты балам булыр!» — дия идең. Минем баламның берәү генә булуына уфтанганымны ишетеп калгансыңдыр инде! Ә мин читкә борылып үкси-үкси елый идем бит! «Алты улымның алтышар бәбие булыр, минем утыз алты оныгым туачак!» — дип әйттерә идем мин синнән. Санарга син туачак балаларыңны исәпләп өйрәндең. Сигез яшь тутыргач, син һич көтмәгәндә: «Минем өч балам булачак»,— дидең. «Өч баланы карау җиңел булмас, улым»,— дигәч, син: «Мин хатыныма бик нык булышырмын, эшкә соңрак барырмын, иртәрәк кайтырмын»,— дип җавап бирә идең. Синең шул акыллы сүзләреңне әйтеп күрсәтеп, дус-ишләремнең һушын ала торган идем. Ун яшьтә син, кистереп: «Минем бер генә балам булсын, әмма аның бар телләгәне тормышка ашсын»,— дип куйдың. Сине авылыбызның иң чибәр, иң уңган кызы сөйде!.. Һәм менә син аңа кичәгенәк ни дигәнсең?! Телем бармый... «Мин бер чакта да өйләнмим, буйдак булып калам. Минем бай буйдак булып, бик җитеш тормышта гомер сөрәсем килә!» — дигәнсең.

Р ә с и м. Ул шуларны сиңа җиткердеме?

Ә с м а. Көчләп әйттердем... Укол кадый алмый, куллары калтырый... Әйттердем!

Р ә с и м. Ә мин аңа юри әйттем.

Ә с м а. Син байтактан инде юри генә сөйләшмисең.

Р ә с и м. Әни, укып бетергәч, мин авылга кайтмыйм. Стипендия акчасын кайтарып бирергә кирәк. Анысын үзем эшлим.

Ә с м а. Каян аласың?

Р ә с и м. Шабашкага йөрермен. Мебель кибетендә грузчик булырмын. Беләсеңме алар күпме суга?! Ике зоотехникның төшенә кермәгән акча ала алар.

Ә с м а. Каян килде бу акыл?

Р ә с и м. Тормыш үзгәрде. Авыллар бетә, перспективалары юк.

Ә с м а. Бетә?! Юк?! Икмәкне каян алырбыз? Итне-майны?!

Р ә с и м. Үзең шаһит. Күреп торасың. Әнә ич колхоз ветераннары! Безне шул язмыш көтмимени?!

Ә с м а. Шифан нәрсә ди?

Р ә с и м. Шифан? Сорашма, әни!

Ә с м а. Ә без?! Атаң-анаң?!

Р ә с и м. Курыкма, мин сезне дә үз яныма алдырырмын! Болар кебек яшәтмәм.

Ә с м а. Ә җир?! Җирне кемгә калдырырбыз?! Барыбыз да күчә, кача башласак, җирдә кем калыр?! Болар көненә калдырмам, дисең... Әйе, өйләнмичә, юньле тормыш кормыйча, теләсә кайда эт сугарып йөрсәң, безгә алай гына булырмы әле?!

Р ә с и м. Усал сөйлисең бүген, әни.

Ә с м а. Син йомшак сөйләп кара. Йомшарт күңелләребезне.

Р ә с и м (*паузадан соң*). Шифан шәһәргә күчәчәк түгел.

Ә с м а. Әйе, ул монда калачак, җирдә!

Р ә с и м. Нигә ул монда газап чигәргә тиеш?

Ә с м а. Ә кайда тормыш бик җиңел, бик ансат? Тормыш итү әрәмтамакларга һәм имгәкләргә генә җиңел!

Р ә с и м. Быел мәктәбегезгә ничә бала укырга керә?

Ә с м а. Бер бала.

Р ә с и м. Ул да читтән китерелгән инженер малае.

Ә с м а. Шуннан.

Р ә с и м. Ник кайтыйм мин авылга?

Ә с м а. Ә Шифан калага китәргә ризалашса?.. Өйләнәсеңме?

Р ә с и м. Юк.

Ә с м а. Юкмы?

Р ә с и м. Бала-чага карап хәсрәткә батасым килми.

Мин үз рәхәтемдә генә яшәргә телим. (*Әсма китә башлый.*) Килештеңме, әни, минем белән?

Әсма. Бердәнбер баласыннан шул сүзне ишеткән ана... Аяк астында ничек җир убылмый?!

Рәсим. Син бит акыллы хатын. Кирәк чакта этине дә үз җаеңа бора аласың. Тыңла! Нигә миңа сез яшәгән тормыш? Нигә кабатларга тиеш ди мин аны?!

Әсма. Үзеңчә кор. Үзеңчә оештыр. Илне-көнне, җирне без сезгә тапшырасы. Парың бар. Белемең! Син укыган кеше. Нидер ошамый икән, үзгәрт, җайла, көрәш. Бирешмә!

Рәсим. Сез интеккән дә җиткән. Шәһәрдә исә һәммәсе җайга салынган. Артык көч түкмичә генә арага керәсең дә китәсең.

Әсма. Һәм күренмисең! Югаласың, шулаймы?

Рәсим. Күндер этине! Ризалат!

Әсма. Бу юлы үзең ризалатып кара! Әнә, Шифан килә.

Рәсим. Синең янга килә. Йомышы зурдыр! Мин барында килмәс иде югыйсә.

Шифан керә. Тынлык.

Әсма. Син медикаментларга китмәдеңмени?

Шифан. Аларын шофер алып кайтырга булды. Документларны бирдем.

Әсма. Үзеңә барырга иде. Заказлар тагын үтәлми кала.

Шифан. Әллә нигә аягым тартмады.

Әсма. Җебемә! Бер юньсезгә карап дөньяның чите кителмәгән. Кителсә дә, тормыш туктамас!

Шифан. Мин басып торган нәни генә чите кителә шул аның! Мин баскан урын.

Рәсим. Качма, Шифан. Әни барын да белә.

Шифан. Аның белгәнен мин дә беләм. Үзем сөйләдем.

Рәсим. Кирәкмәс иде.

Шифан. Ул синең әниең. Ә минем бергә эшли торган һәм алда да бергә булачак кешем. Белеп торсын!..

Әсма. Улым, уйла! (*Чыга.*)

Рәсим. Барын да белгәч, аңлагач, нигә качасың миннән?

Шифан. Барын да әйтеп бетергәч, нигә эзәрлеклисең син мине?

Рәсим. Нигә курыктың син минем сүзләрдән? Ялган бармы аларда, ялгышмы? Каргышмы? Ни?!

Шифан. Ичмасам, алдар идең! Дөресен әйтмә идең!.. Болай гына, тып-тын гына югал идең!..

Рәсим. Минем сүзләрнең кайсысы ялгыш?! Әйе, бергә

булыйк, дидем. Өйләнешмичә генә, семья богауларын такмыйча гына бәхет табып булмыймыни?! Әйдә, китик без моннан берәр яры! Шушы шомлы йорт теңкәмә тия!

Шифан. Нигә шомлы?

Рәсим (*дәвам итеп*). Өйләнешкәч күпме бәла-каза киләсен белмисең син. Ә мин беләм, күреп торам. Өйләнү — газап, ызгыш, талаш, хәтта сугыш!.. Ә болай... тормыш — тоташ бәйрәм! Беребез алдында да җавап бирәсе юк. Син ирекле кош, мин ирекле кош...

Шифан. Син — «каеш баулы лачын кош», ә мин — «ефәк баулы былбыл кош».

Рәсим. Кем сүзләре бу?

Шифан. Эш кем әйтүендәме?!

Рәсим. Исәр Мияссәр карт сүзләре генә ич болар!

Шифан. Теләгәндә кавышабыз... Җаннар ерак булса да, тәннәр бергә...

Рәсим. Дөрес, теләмәгәндә һәркем үзенчә яши! Үзенә-үзе хуҗа!

Шифан. Ә бала булса? Бала?

Рәсим. Бала булмас. Кирәкми дә. Кем бу дөньяда баладан рәхәт күргән?

Шифан. Әйе, бала — мәшәкать. Семья — мәшәкать.

Рәсим. Интернатта эшләп, син тормышның төп фаҗигасен аңлагансың. Хәзер ничек итеп рәхәт чигәргә мөмкин булуын мин төшендерим.

Шифан. Ә авыл?! Кем эшләр монда?!

Рәсим. Кем булса да калыр әле.

Шифан. Ил сакларга кем барыр?.. Юк, мин монда калам.

Рәсим. Кал! Мин кайтып-кайтып йөрермен. Кышларын йә җәйге ялыңда син минем янга килерсең.

Шифан. Мин андый сүзләргә җавап та бирә алмыйм.

Рәсим. Тормыш үзгәрде, Шифан! Хәзер бәхет төшенчәсе бөтенләй башка!

Шифан. Кеше тормышны үзе үзгәртә. Хак, авылда яшәү ансат түгел. Юллар пычрак. Кышкы төннәр озын. Ә нигә без барыбыз да ансат юл сайларга тиеш?! БАМга китәләр. Җиңелме?! Алтышар ай күктә очалар. Ансатмы?! Караңгы җир астына төшеп, күмер чабалар! Бәйрәмме?! Эссе цехларда смена буе басып торалар. Уенмы?!

Рәсим. Авылның гомере ун-унбиш ел. Качалар авылдан! Качалар!

Шифан. Качмыйлар, китәләр. Ә калганнар кала. Матур кешеләр кала. Акыллы кешеләр кала. Китмим мин моннан!

Рәсим. Шушы бәлтерәгән картлар янындамы?

Шифан. Китсәм дә, авылга гына китәчәкмен! Җәйге ялга кайтып, кәпәренеп йөргән буйдак, бай Рәсимне күрәсем килмәс анысы!.. Хуш!

Рәсим. Шифан! Шифан!

Шифан чыгып китә. Рәсим дә аңа иярә. Хурия белән Әдһәм керәләр.

Хурия. Фу! Башка чакта да шулай болгавыр була идеме монда?

Әдһәм. Әһә, күрдеңме? Белдеңме? Ир башына күпме газап төшкәнен аңладыңмы?

Хурия. Монда кунар хәлем юк, ачты карыным, кер дә эшеңне башкар.

Әдһәм (*тукталып*). Җәнҗал куптарса?

Хурия. Бәяңне арттырырга маташма! Башка чакта дәшмәгәнне, бер бүген генә...

Әдһәм. Бу юлы биш йөзне сорарга куштың!

Хурия. Сорарга түгел! Алырга! Мәнсез баш.

Әдһәм. Теге шайтан таягы тагы килә!

Мияссәр белән Шифан керәләр.

Мияссәр. Кара! Машинаны хәйран озак юган сез?

Хурия. Бәйләнчек тә җан икәнсең син!

Шифан. Мин сезне беләм бит. Сез Рәшидә әбинең туганы. Нигә яшерәсез шуны?

Әдһәм. Юк, диләр ич сиңа! Вәт кырмавык! Минем туганым да, чуртым да юк.

Хурия. Төрле яктан ятим ул! Китик, җанкисәк. (*Чыгалар.*)

Мияссәр. Минем дә күргәнем бар шикелле. Тиккә йөрмиләр. Баягынак та директорга әйтергә теләдем... Нигә чакырдың мине, кызым?

Шифан. Мияссәр агай, мин озакламый моннан китәм.

Мияссәр. Синме? Кая китәсең, балакай?

Шифан. Әлегә белмим.

Мияссәр. Белмәгәч, ничек китәм дип әйтә аласың?

Шифан. Китүемне берәүгә дә әйтмим, беркемгә дә белдермим.

Мияссәр. Миңа да ялгыш кына ычкындыргансың, алайса?

Шифан. Мин сезне бик яратам, Мияссәр агай. Сез миңа гел-гел шәфкатьле, мәрхәмәтле булдыгыз.

Мияссәр. Бәй, тукта әле. Синең яшьтә елыйлар димени?

Шифан. Әйе, китәм. Бөтенләйгә югалам. Әткәйләргә дә белдереп тормыйм. Гел.

Мияссәр. Тынычлан. Сөрт яшьләреңне. Менә шулай. Ул ничек? Ул? Рәсимне әйтәм. Юктыр ла!.. Без ничек? Безгә ни?!

Шифан. Яратмый ул мине.

Мияссәр. Ә-ә, тәмсезләнешкәнсез икән. Була инде ул. Исең китмәсен!

Шифан. Яратмый! Яратмый!

Мияссәр. Болытлы көннәр була, җибәрмә тирәнгә.

Шифан. Авылга кайтмыйм, ди. Хыянәтче ул!

Мияссәр. Рәсим дә кайтмыймы?! Ала-ай... Шулай укмыни? (*Шифан раслап баш кага.*) Ә син? Син? Син дә, китәм, дисең түгелме?

Шифан. Мин аның янына шәһәргә бармыйм.

Мияссәр. Сиңа рәхмәтемнең иң олысы. Ала-ай... Алдагы гомереӊ ничек узса да, бүгенгеӊ өчен рәхмәт. Мин сиңа карап кына юана идем, балакай. Сезгә карап! Өч улым бар иде минем. Өчәү! Икесе Ватан сугышыннан кайтмады. Өченчесе, иң олысы, кырык яра белән кайтып егылды. Өйләнә дә алмады. Өлгермәде. Ун ел урын өстендә тилмереп ятып, үз кулымда җан бирде! Өйләнгән генә булса соң!.. Миңа кара башлы бер бала калдырган булса!.. Үз гомереңне бирәсеңмени?! Хәсрәтләр дәрьясы карчыгымны да алып китте... Югыйсә мин монда ята торган җан идемме?! Авылыбызда тимерче генә түгел идем мин, туйларда түрдә, тәгам атасы да идем. Кызлы йортларда зарыгып көтеп алалар иде мине. Яучысыз өйләнмиләр иде безнең Көмешле Елгада! Яучыны көтәләр, йортташлар капка төбенә чыгып каршылыйлар иде. Ә мин киләм... Мин! Йоланың үз рәте, тәртибе, җырлары бар! (*Җырлый.*)

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең иләңдә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!..

Өч лачын кошымны очырттым. Югыйсә монда килә торган зат идемме мин?! Шуннан сезне күрдем. Йокысыз, тынгысыз төннәр кичеп, зар-интизар булып тилмереп йөргәндә, Рәсим белән син шушы күл буен урадыгыз. Икәү!.. «Ефәк баулы былбыл кош бардыр минем илемдә!» Ишетәсеңме, балакай, «өемдә» түгел, «илемдә!» Яшь кияүле, яшь кәләшле йортны безнең болгар бабалар Ил дип олылаганнар... Син идең бит минем ефәк баулы былбыл кошым. Ни булды сиңа? Нишләттеләр сине? Мин ул Рәсимнеме?! Кешене шулай җәберлиләрмени?! Авылны шулай мыскыл итәләрмени?!

Шифан. Кирәкми, Мияссәр агай. Зур авыллар бар, матур, нык нигезле авыллар күпме?!

Мияссәр. Юк димим, беләм, бар! Авылларның гөрләп утырганнары бар! Ә ничаклы авыллар хәл эчендә?! Ташландык йортлар, такта тәрәзәләр, шыксыз урамнар. Менә бит, ерак барасы да түгел, Чабаклы күлгә кара! Җитмеш икенең җаендә, афәтле корылыкта, аның суын төбенә хәтле суыртып җиргә сипкәннәр. Кирәкмәгәнгә сипмәгәннәр, мәгълүм! Кара балык йөзгән элек монда, табан балык, сазан! Хәзер кәрәкә дә юк! Ике йөз метр арадагы елгадан канау казып, күлгә су тутырдылар. Суы бар, балыгы юк. Күл элекке хәленә кайтсын өчен тагын ярты гасыр вакыт кирәк икән. Әле ул чакта да чын-чын үз мәгънәсенә кайтырмы, юкмы? Авыл да шул күл сымак ич, кирәк чакта эшче кулларны суырып кына алабыз. Китәләр, китәләр. Күл-авыл бушап кала. Авылны да читтән кеше җыеп тутырабыз. Тик ничә елдан үз тәртибенә килер ул? Килерме?! (*Бәби арбасын тартып, гадәттәгедән ныграк аксаклап, чабып диярлек йөри, җырлый.*)

Әлли-бәлли, бәү-бәү!
Нәнекәчем-кошчыгым!
Әлли-бәлли, бәү-бәү!
Йомшак сары томшыгым!

Кисте сугыш безнең гомерне! Балыксыз күл. Бәбәйсез арба. Укучысыз класс... Бу арбаны сезгә бүләккә дип алган идем. Кая ташлыйм мин аны хәзер? Әлли-бәлли көен кемгә җырлыйм?

Шифан. Минем гаебем юк, Мияссәр агай!.. Минем бит Рәсим күзе җитмәслек җиргә генә китеп югаласым килә!

Рәшидә керә.

Мияссәр. Их, Шифан балакай! Рәшидә-әү, кая кабаланасың?

Рәшидә. Ялгыз калдыммы, күзгә әллә ниләр күренә башлый. Әнә тегендә бер әйбер юкмы? Селкенәме?

Шифан. Берни дә юк анда, Рәшидә әби.

Рәшидә. Мөгаен, күземә күренәдер.

Мияссәр. Сиңа сүзем бар.

Рәшидә. Әйт, Мияссәр абзый.

Мияссәр. Син мине аңларга тиеш, син!

Рәшидә. Тырышып багармын.

Мияссәр. Аңларсың да, ышанам.

Шифан. Мин кирәкмимме инде? Китимме?

Мияссәр. Син дә тыңла. Кирәге булыр. Рәшидә-әү!

Минем авылым моннан илле биш чакрымда, Көмешле Елга!

Рәшидә. Сөйләгәнең бар, Мияссәр абзый.

Мияссәр. Алты почмаклы, такта башлы йорт. Йорт алдында өч каен.

Рәшидә. Аларын да хәтерлим.

Мияссәр. Өйне үзем салдым. Мичен дә үзем чыгардым. Үзем үк тәрәзәләренә такта кадаклап чыгып киттем.

Рәшидә. Нишлисең, дөнья! Мин исә, йорт-җиремне тузгытып, сатып чыгып киттем.

Мияссәр. Әйдә, парлашабыз да, безнең авылга кайтып, минем өйдә бергә яши башлыйбыз? Теләсәң, Шифан кызым, сине яучы итеп җибәрәм.

Рәшидә (*көлә*). Шушы арбаны парлашып җитәкләп кайтып керәбезме, Мияссәр абзый?! Их-ха-ха!

Мияссәр. Мине тилегә чыгарасың инде, һични сүземә ышанмыйсың. Авыл бетә бит, авыл! Яшьләр авылны сөйми. Авыл белән моң бетә, моң! Күңел моңы бетә! Әкиятләр бетә, табышмаклар... Яшьләр нигезне ныгытмыйлар, өйләнмиләр. Көмешле Елга бетә. Авылымның җан биргәнен ничек түзем генә карап торыйм? Ә ялгыз яши алмыйм. Ялгызлыктан качып чыгып киттем... Ә хәзер уйладым, уйладым да... Хәл кадәренчә тырышырбыз! Тәндә егәр барда тәвәккәллик!..

Рәшидә. Тукта, Мияссәр абзый, чү!

Шифан. Ни күрдең, Рәшидә әби? Ник алай сискәндең?

Рәшидә. Ялгыз калдыммы, күземә әллә ниләр күренә башлый дисәм, чү, чүегез...

Шифан. Нинди яхшы кеше сез, Мияссәр агай!

Мияссәр. Кемне күрдең? Нигә курыктың? Ә-ә, юлаучылар алар! Баядан бирле машина юалар. Озак юалар мәгәр.

Рәшидә. Беттем!

Мияссәр. Хәзер сөреп җибәрәм мин ул исерекбашны!

Рәшидә. Исерек икәнен дә белеп өлгергән.

Мияссәр. Шешә авызыннан гына чөмереп ята.

Шифан. Ул сезнең туганыгыз бит, Рәшидә әби, иеме?

Рәшидә. Белмисез шул сез, берни генә дә белмисез!

Мияссәр. Белдер соң.

Әдһәм исерек булып ярым кыланып керә дә Рәшидәне кул изәп чакыра.

Әдһәм. Кил монда, кил!

Шифан. Рәшидә апа! Барасы булма!

Мияссәр. Үзең мондарак атла, тәти егет. Ачу кабарган чак!

Әдһәм. Минем болар белән вакланып торырга вакыт чамалы. Минем сиңа йомышым бар.

Мияссәр. Үзең кил, диләр сиңа!

Әдһәм. Әтәчләнмә, карт!

Рәшидә. Кирәкми, Мияссәр абзый. Шифан балам... Икегез дә китеп торыгыз. Нигә өстәмә борчылырга? Юлаучының сүзе бар икән, әйдә, сөйләп карасын.

Мияссәр. Мин иртәдән бирле сине сагалап йөрим! Сүземне әйттем, ниһаять. Нигә җавап бирмисең? Әү, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Алай ордым-бәрдем белән генә җавап бирә торган сүз түгел.

Мияссәр. Әйдә, Шифан! Бер кызган чакта Рәсимне дә табыйк... Мин анымы, мин аны! Дагаламасаммы?! Рәшидә-әү, кирәк икән, без монда гына. Якында, яме?

Рәшидә (*Мияссәр белән Шифанны озатып*). Ярый, ярый. (*Әдһәмгә.*) Килеп җиттеңме, исерек Газраил?! Тагын килдеңме, җәфа?! Килеп төштеңме, кара хәсрәт?! (*Елый.*)

Әдһәм. Килдем, әни. Сиңа бармыйча, кемгә барыйм? Кая? Коткар!

Рәшидә. Нишләтергә сине? Ни кылырга? Ничек котылырга синнән?!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Шул ук урын — күл буе. Шул ук кешеләр — Рәшидә белән Әдһәм кара-каршы басып торалар.

Әдһәм. Әнием, бердәнберем! Ташлама! Коткарсаң, син генә коткара аласың игелексез улыңны. Хәер, аны коткарып та дөньяга ни файда? Беләм, күңелең балавыз, эри дә китә. Беләм, шәфкатең киң. Ә мин?! Олтырак! Беткән кеше.

Рәшидә. Тагын ни булды?

Әдһәм. Сорама. Сорама да. Сорап ни файда? Әйдә бетерсеннәр, бетерсеннәр. Синең баш та котылыр.

Рәшидә. Ике айның берендә дүртенче елыңны йөрисең. Юньле берәр сүзең булырмы, юкмы?

Әдһәм. Әнә, куак артында кемнәр торганын беләсеңме? Ту-ты, белмисең. Сезнең дөнья бит ул... Әнә, әнә! Мине сагалыйлар алар. Йә качыр, йә коткар.

Рәшидә. Бу юлга акчам юк.

Әдһәм (*кинәт айнып*). Пенсияңне китермәделәрме?

Рәшидә. Китерделәр.

Әдһәм. Өстең бөтен. Тамак бушлай. Кая куйдың?

Рәшидә. Бер айныкын барыбыз да Тынычлык фондына бирдек. Бөтенебез бер булып. Калганын Сәрбиҗамалга багышладым. Ул авылына кунакка кайтып китте. Ку-нак-ка! Үзең гаепле. Очрашуыгызны теләмәдем. Узган юлы да идәндә үрмәләп, әллә ниләр мыгырдый башладың. «Әни!» дип ычкындырырсың дип бик курыктым. Ул бит сине ерак кардәшем дип белә.

Әдһәм. Әллә ниләргә акча җәлләми, ә үзенең газиз балакаена, төпчек улына...

Рәшидә. Сиңа бит акча эчәргә генә кирәк. Эчми торсаң да үлмәссең.

Әдһәм. Чыдыйм! Эчмим, әни. Элек эчкәнне түләргә кирәк. Бурычым бар.

Рәшидә. Бурычка кердеңме? Ничәләр әйттем мин сиңа?! Алма кешедән бурыч, дидем. Үлсәң үл, мәгәр алма. Бурыч — адәм баласының муенына тагылган таш ул. Төпкә сөйри, тарта. Харап булгансың...

Әдһәм. Бәхет булмады, әни.

Рәшидә. Хатыннан уңмадым. Шулаймы?

Әдһәм. Үзем дә әллә кем түгел инде. Хатыннан да уңмадым, әти-әнидән дә, туган җирдән дә — берсеннән дә кот кунмады.

Рәшидә. Һай, затсыз! Ничек аларга тел күтәрә аласың? Тел күтәргән дивана кул күтәрүне дә чит итмәс.

Әдһәм. Соң инде, баш белән уйла! Кырык төтенле авылда туганмын. Бәхетме бу?!

Рәшидә. Юк бит акчам, бирер идем дә олактырыр идем. Дөмек иең шунда эчеп.

Әдһәм. Ә мин шәп калада, олы урындагы ашлы-сулы кешенең улы булып туа ала идемме? Ала идем! Кем булып яши идем мин бүген, ә?! Нигә дәшмисең? Ту-ты!

Рәшидә. Шөкер Ходайга, моны башкалар ишетми. Ана йөрәге түзә. Ничек шартламый торгандыр.

Әдһәм. Әни, син төпчек балаңның бәхетсезлеген беләсең. Яман аның хәле, баш китәрлек.

Рәшидә. Күрәм. Ничек йолып алу җаен таба алмыйм. Тол бит мин, ялгыз. Таянырым да, киңәшер кешем дә юк.

Әдһәм. Шушы атна эчендә түләмәсәм, харап итәләр, муенга аркылы чабалар. Тередәй кычкыртып туныйлар.

Рәшидә. Кемнәр соң алар? Әйдә, милициягә тапшырыйк та, котыл син алардан!

Әдһәм. Абыйларга барыр идем, үзләре сволочь. Зариф абыйның ишеген кагып караган идем, пыяла күздән генә чекерәеп карыйлар, ачмыйлар да, дәшмиләр дә! Ә тегесе настаяшний свинҗә! Алар акча бирсә, сиңа килеп йөрми идем, кояштыр. Яз әле үзләренә хат, кече энеләрен рәнҗетмәсеннәр, ныгытып яз.

Рәшидә. Бурычың күпме?

Әдһәм. Алай ук түгел дә...

Рәшидә. Сузма, барыбер әйтәсең бит.

Әдһәм. Биш йөз сум.

Рәшидә. Күпме, күпме дисең?

Әдһәм. Бусы үземнең гадел өлешем. Өй сатудан калган акчадан бирерсең. Тагын бер йөзне үзеңнән өстәрсең. Бирәчәктән котылгач та яшәргә кирәк ич әле миңа.

Рәшидә. Өй саткан? Кайчан иде ул, беләсеңме, тинтәк?!

Әдһәм. Белүемчә, синдә запас калды.

Рәшидә. Өйне саткач, өчегезне дә йөреп чыктым. Өчегез дә, мине чират-чират пропискага кертеп, өчәр бүлмәле фатир алдыгыз. Өчегезгә дә өй котлап байтак акча бирдем. Үз өем кереп китте, колагы да күренмәде. Туйлар узып, хәвеф-хәтәр онытылгач, өчегез дә мине күпсендегез. Әллә мин монда ятар идемме?

Әдһәм. Әни, хәзерге киленнәр каенана белән тынышмый! Аннары син хөкүмәт исәбендә! Фронтовик хатыны! Сине дәүләт карый.

Рәшидә. Совет хөкүмәтеннән өч тапкыр фатир өлеше алдым. Дүртенче урынымны менә моннан бирделәр. Ник миңа тынгылык юк икән һаман?

Әдһәм. Менә мине әйт син, мине! Башкалар балаларына машина калдыралар. Йортлы-җирле итәләр. Эшләтмиләр. Синең аркада гомерем буе чиләнәм, эшлим. Тузан-туфракка манчылып өч ел комбайнда йөрдем. Өч ел! Өй котлап биргән мең сумын санап ята! Берәү булса, аны телгә алырга оялыр иде. Бетердең башкайларымны! Йә, бирәсеңме алты йөз сум? Җиде йөзгә менгәнче биреп кал.

Рәшидә. Беттеме?

Әдһәм. Нәрсә тагын? Нәрсә?

Рәшидә. Болары өйдә хатының биргән акыл. Ул өйрәткән сабак. Хәзер менә мондарак утыр да, сабыр гына, чынлыкны сөйләп бир.

Әдһәм. Чынын сөйләсәм, акча бирәсеңме?

Рәшидә. Карап карарбыз.

Әдһәм. Их, әни! Син, кайда яшәсәң дә, үзеңә үзең хуҗа. Минем бит... Зарплатадан бер тиен күрә алмыйм. «Алкаш!» дип жалу язып, турыдан-туры кассага күчертә.

Кенәгә аның исемендә. Тәмәкене дә парктан шешә җыеп алам.

Рәшидә. Тартма. Ташла.

Әдһәм. Өс-башны кыса. Тамакны әйткән дә юк. Был- тыр гына өч килога кимедем.

Рәшидә. Нигә издерәсең шулкадәр? Әби патша түгел лә, үз хатының.

Әдһәм. Моннан дүрт ел элек, малайлар белән, юләр- ләнеп, контейнердан телевизор урлап саткан идек. Ти- мер юлда.

Рәшидә. Яманның актыккы чигенә барып җиткән- сең икән, балам!

Әдһәм. Ачыгавызланып, шуны ычкындырып таш- лаганмын.

Рәшидә. Акча хатыныңа кирәктер инде.

Әдһәм. Ипләп! Үзе монда. Тыңлый!

Рәшидә. Шулайдыр кебек тоела иде дә! Хурия, Ху- рия, кил!

Хурия керә.

Хурия (*иренә яман карап*). Син нишләп монда сыер тәбикмәге кебек җәелдең? Көн уза! Вакыт кыса. Бурычыңны мин түләр дип көтәсеңме? Минем акчаны әнә ачарбак малаең кимерә.

Рәшидә. Исәнме, килен!

Хурия. Килен? Хи-хи, килен! Килен булып төшеп, синнән ни хөрмәт күргән дә, ни рәхәт татыган?! Башка каенаналар, әнә, киленгә алтын алкалар бирә, көмеш беләзекләр. Борынгы алтын акчалар калдыра.

Рәшидә (*сабыр гына*). Боларын ишеттем.

Хурия. Каян? Кайчан? Дүрт ел күргәнем юк. Килен...

Рәшидә. Ирең, минем тыңлаулы кадерле балакаем, барын да бәйнә-бәйнә сөйләп тапшырды. Түкми-чәчми бар сүзеңне ишеттерде. Сүзеннән бушаганга тик утыра ул.

Хурия. Рәхмәт әйт, әгәр аны мин кулда тотмасам, синең ул исерекбашың койма астында чуар дуңгызлар белән аунап ята иде.

Рәшидә. Рульдә! Аек ул!

Хурия (*Әдһәмгә*). Булдымы?

Әдһәм. Акчам юк, ди.

Хурия. Иртәрәк айныгансың. Шәп! Әле дә ярый үзем килгәнмен. Булды. Гарык! Мин синең йолкышыңа саф килеш кияүгә чыктым. Матурлыгымны жәлләмәдем, яшьлегемне кызганмадым. Барын бүләк иттем. Ни ал- дым мин аннан?! Йә?

Әдһәм. Хурия, дим...

Р ә ш и д ә. Әйтеп куансын. Әллә кабат очрашабыз, әллә юк. Хатыныңның кем икәнен анаң янында күреп кал.

Х у р и я. Кайтам да тиешле кешеләренә тапшырам мин аны. Алсыннар чебен җанын. Мәетең өстенә менә аны чакырам! (*Рәшидәгә күрсәтә.*) Сөекле төпчек улын көн яктысында күреп китсен. Болары гына җитмәсә...

Ә д һ ә м. Туктасана! Ватык самавыр кебек гөжли...

Х у р и я. Гөжләү түгел, шартларсың монда. Күрә торып улын әҗәлгә... (*Еламсырый.*)

Ә д һ ә м. Телеңне авызлыкла азрак.

Р ә ш и д ә. Ә син, килен, бүген олы хата ясадың.

Х у р и я. Нинди хата? Әйт, нинди хата?

Р ә ш и д ә. Хатаңны үзең дә аңлап алдың, зирәклегең юк түгел. Иреңә ияреп акча таларга килгәнсең. Үзе генә чакта гаярь иде, хәзер әнә икеләнә. Әнкәсен этләрдән талатасы килми.

Х у р и я. Мине эт белән тиңлиләр. Әдһәм!.. (*Рәшидәгә.*) Балаңны гөлдәй итеп карап торган намуслы хатынны эт дидеңме?!

Ә д һ ә м. Ярар, дим, шыңшыма, туйган.

Х у р и я. Кайтып керәсеңне онытма! Ачкыч миндә.

Р ә ш и д ә. Шулай, улым, акчам юк.

Х у р и я. Җәһәннәмнең җиденче катыннан эзләп табарсың. Балаңны суйдырасың килмәсә... (*Агачлыкка ымлый.*)

Ә д һ ә м. Йә, дим, Хурия! Дөньяның асты-өскә килмәгән. Тирә-юньдә кешеләр дә йөри.

Х у р и я (*кинәт ялварып*). Теләсә ничек итеп хурла. Эт диген! Хайван диген! Акча гына тап. Улыңны йолып аласы бар! Улыңны!

Ә д һ ә м (*паузадан соң*). Әни, минем хәлне аңладың. Кызган, чын күңелемнән дөресен әйтәм. Көч юк миндә. Тукмар идем, тамырыңны корытыр.

Р ә ш и д ә. Ярый, актык чиккә терәлгәнсез икән, бераз табармын.

Х у р и я (*Әдһәмне арттан йолыккалап*). Тизрәк сорап кал! Күпме бирә? Ела инде.

Р ә ш и д ә. Күпме табачагымны белмим. Безнең монда акчалы халык юк. Алай да, бурычка алып торырмын.

Ә д һ ә м. Бурычка? Бурыч муенга бәйләнгән таш, дидең...

Х у р и я. Дәшмә, юньсез!

Ә д һ ә м. Син яманлама аны! Әнә, бурычка булса да таба.

Р ә ш и д ә (*үртәп, тегеләрдән котылырга теләп*). Безнең картлар бик елгыр, машинагызның тәгәрмәчен чәлдермәсеннәр.

Х у р и я. Ә?!
Ә д һ ә м. Шаярма. Әйдә, китеп торыйк.
Х у р и я. Сузмасын иде инде... Кайтып җитәсе дә бар...

Чыгалар. Рәшидә ялгызы. М и я с с ә р керә.

М и я с с ә р. Киттеләр. Ай-һай, озак гәпләштегез! Күзәтеп тордым. Рәшидә-әү! Нинди котсыз кешеләр. Ни йомышлары бар икән синдә андыйларның?!
Р ә ш и д ә (*кармак сабын тотып ала*). Бу күл тирәнме, Мияссәр абзый?
М и я с с ә р. Шактый, диләр. Үлчәгәнем юк, Рәшидә.
Р ә ш и д ә. Чоңгылдыр. Суы да салкын. Син, Мияссәр абзый, гел күлгә карап утырасың. Нинди уйлар килә башыңа?
М и я с с ә р. Төрле чак булды. Элек уйлар чуалчык иде, хәзер, үзең дә белеп торасың, гел бер тирәдә йөри.
Р ә ш и д ә. Шушы күл төбенә чумып, мәңгегә югаласы килгән вакытлар да булгаладымы?
М и я с с ә р. Ни булды сиңа, Рәшидә? Бер чакта да күз яшеңне күрсәтмәгән идең, хәзер атна буе җаныңа урын таба алмыйсың?! Олы кешегә кинәт җил кагылса, хәтәр!.. Сөйлә!.. Теге юньсез кешеләр ни дип килгәннәр? Белдем, алар машина юган булып, сине көтеп, син чык-канны сагалап торганнар. Сиздем, алар синең ялгыз кал-ган чагыңны көттеләр. Баядан бирле күзәтәм! Ә сине... атна буе гаҗәпләнеп сагаладым! Тиешле сүземне дә ашык-пошык кына әйтергә мәҗбүр булдым.
Р ә ш и д ә. Шулай ук булдымыни?
М и я с с ә р. Сиңа берәр бәла-каза килдеме әллә?
Р ә ш и д ә. Куйчы, Мияссәр абзый. Дөнья белән эшен өзеп, туры юлга чыккан кешене нинди сикәлтә көтсен ди тагын?!
М и я с с ә р. Хәзер эзләрен суытам мин аларның. Хәзер! Көчем җитмәсә, әнә, Рәсимне чакырам. Ул да йөри илереп. Берочтан үзенең арт сабагын да укытасы бар.
Р ә ш и д ә. Тимә аңа. Йөрсен шулай. Теләгәнчә.
М и я с с ә р. Нигә тыныч түгел син? Нигә тыныч түгел без?!
Р ә ш и д ә. Ил тынычмы? Җиркәебез тынычмы?!
М и я с с ә р. Юк, син бүген үзең турында гына сөйлә.
Р ә ш и д ә. Мияссәр абзый, син миңа бераз акча биреп тора аласыңмы?
М и я с с ә р. Акча, диденме?
Р ә ш и д ә. Мин өлешләп, пенсиямнән ваклап-ваклап түләрмен. Ходай кушса, бурычлы булып үлмәм.
М и я с с ә р. Ни хаҗәтең килеп чыкты әле алай? Кичтән

сорамадың, иртән очрашканда да берни әйтмәгән идең. Ни тынычсызлый сине? Хат-мазар алмадың. Налог агенты да күренмәде.

Рәшидә. Миңа акча кирәк. Шул.

Мияссәр. Бары бер шигем — алар! (*Читтәге Әдһәмнәргә күрсәтә.*) Акча сиңа кирәкме? Әллә шул шыксыз йон төргәкләренәме?!

Рәшидә. Барыбер түгелмени? Сиңа мин түлисе.

Мияссәр. Нишләп алай барыбер булсын? Мин сине үземә чакырдым. Көмешле Елгага! Бергә торырга! Ничек мин сиңа «бурыч!» дип акча бирә алыйм?!

Рәшидә. Аларга бирәчәгем калган икән. Түләнеп бетмәгән.

Мияссәр. Ышанмыйм. Ас, кис, тура, син бурыч саклый торган кеше түгел.

Рәшидә. Нишләмәк кирәк соң?

Мияссәр. Ярар. Бераз табармын. Мин ул акчаны синең белән кавышып яши башлауга дип багышлап куйган идем. Җавабың әзерме? Нигә иң кирәген, шул турыда сөйләмисең син?!

Рәшидә. Җанны көйдерәсең, Мияссәр абзый!

Мияссәр (*өзеп*). Күпме бирим?

Рәшидә. Күпме бирә аласың инде?

Мияссәр. Әллә күпкә өметләнәләрме мөртәтләр?!

Рәшидә. Күп кирәк, диләр. Биш йөз.

Мияссәр. Күсе даруы ашаганмы әллә алар? Ятим карчыктан ярты меңне таптыралар. Бик нык юмартлансам да, мин аларга йөз тәңкәдән ары, ну пуч, йөз ярым китсен, бирә алмыйм. Бирәм дә пумала белән куам. Яңадан эз дә бастырмыйм. Әнә Рәсим дә килә. Икәүләп куабыз аларны. Рәсим, тизрәк атла! Тагын бер мәртәбә синнән көчгайрәт кирәк.

Рәсим узып бара.

Рәсим. Вакыт юк, Мияссәр бабай.

Мияссәр. Кая киткән ул вакыт? Сатып эчмәгәнсеңдер бит?

Рәсим. Юк та...

Мияссәр. Шулай булгач?! Әле сине болай да күрәсе бар!

Рәсим. Тагын бәйләнәсезме?

Мияссәр. Бая узып барам, атасы белән пыр да пыр сөйләшеп яталар. Ата белән шулай сөйләшәләрме?

Рәшидә. Син аннан юкка ярдәм сорыйсың, Мияссәр абзый. Аның үзенә ярдәм кирәкмиме икән?!

Рәсим. Сез нигә миңа бәйләнәсез?! Күл буена да чыгарга ярамый башладымы?!

М и я с с ә р. Бәйләнү генә аз! Атаң урынында булсам, мин сине дилбегә белән агачка бәйләп ярыр идем!

Р ә с и м. Кыргыйлык ягында инде сез, алайса? Оят, Мияссәр бабай, газеталар укыйсыз. Кулыгызда гел китап...

М и я с с ә р. Төс сиңа! Шундый кызны рәнҗеттең, шундый ахак кызны!

Р ә ш и д ә. Егәрең булса, дөньяны колачлар идең, Мияссәр абзый.

М и я с с ә р. Әллә җавабың шул?

Р ә ш и д ә. Бер түмгәктән икенчесенә сикерәсең. Түмгәкләр бетмәс җир өстендә!..

М и я с с ә р. Хак! Әй! Рәсим! Тукта, тукта, киту юк. Синең кызган чак, минем кайнаган вакыт, икебез дә коры куык кияү егете, әйдә, теге әтрәк-әләмнәрне интернат тирәсеннән өшкереп җибәрәбез!

Р ә с и м. Мин аларны белмим.

М и я с с ә р. Как так белмисең?! Кешегә хәсрәт китергәч, әйбәт адәмнәр түгел инде.

Р ә с и м. Куып җибәргәч, миңа бәйләнүдән туктыйсыңмы?

Р ә ш и д ә. Туктар ул!

Р ә с и м. Бармыйм. Нигә юкка бер-беребезгә бәйләнергә? Яшәсеннәр үзләренчә генә. Мин аларга тимим, алар миңа кагылмый.

М и я с с ә р. Юлбасарлар алар. Таларга килгәннәр!

Р ә с и м. Алайса, милиция чакыртыгыз.

М и я с с ә р (*Рәсимне әйләнеп чыга*). Карыйм да, парин, исем китә. Кан иртә суынган синең. Алда ничек яшәрсең?! Шифан төс тә түгелдер әле синең ише юеш балакка!

Р ә с и м. Юлбасарлар... Яратасыз инде күперенке сүзләрне! Тормыш тыныч телле кешеләрне өстен күрә. Эшегез беткән, тамак тук, кайгыгыз юк, йөрисез шунда.

М и я с с ә р. Туктал, диләр сиңа! Теге юлбасарны чакырып яллап, тәки үзеңне тукмарбыз.

Р ә ш и д ә. Мияссәр, Мияссәр абзый!

Ш и ф а н керә.

Ш и ф а н. Нигә кычкырышасыз? Тавышыгызга кешеләр җыела. Әнә!

Р ә с и м. Минмени?

Ш и ф а н. Анда әтиең белән талашкансыз...

Р ә с и м. Минем тормышыма бәйләнергә кемнең хакы бар?

М и я с с ә р. Тыел, егет, тукта!

Р ә ш и д ә. Үз ата-анаң белән дә аңлаша алма икән...

Дөньяда моннан да зур газап юк. Балаң белән аңлаша алма!..

Мияссәр. Уйлаган алга килде: каршыбызда кыз бала! Әйт анын үз алдында: ни гаебе бар анын? Нигә кагасың аны?!

Рәсим. Әйдә, Мияссәр бабай, теге юлбасарларны куабыз! Минем бокстан разряд...

Шифан. Мияссәр агай, кан басымыгыз күтәрелмәсен. Керик, үлчәп карыйк. Дарулар бирермен.

Мияссәр. Басым күтәрелде, сизәм. Шуны төшерергә маташам да! Яле, Рәсим, атла алга! Егетлекне күрсәтик. Постой! Ә үзең?! Нигә җавап бирмәдең баягы сорауга? Безнең ишеләрне явызлардан аралыйсы урынга, үзең дә Шифанны кимсеттең түгелме?!

Шифан. Заманы шулайдыр, Мияссәр агай, үзгәргәндер. Без монда, күл буенда яшәп, арттарак калганбыздыр. Әйтмәгез аңа авыр сүз.

Рәшидә. Хак та. Нигә табалыйсың син аны?

Мияссәр. Үзе белә! Синнән-миннән артык укыган. Колхоз акчасына. Белмиме соң?! Их, шулай ук юкка яшәдекмени, Рәшидә-әү! Һәммәсе бушка, тиккә булып чыктымы? Әнә бер яшьрәге көпә-көндез акча талап йөри... Бездән соң бу җирдә сез каласы бит, Рәсим! Син торып каласы!

Рәшидә. Өметсезләнмә бигүк, Мияссәр абзый, монда Шифан бар. Ул кала. Вәгъдә бирер тә өйләнмәү хәсрәтнең олысы, кызым, нишлисең бит, түз. Түз!

Мияссәр. Әллә бу бик азмы? Кеше күңелен рәнҗетүе өчен мактаргамы аны? Беребез вәгъдәсен бозса, икенчебез алдашса, өченчебез урлашса... Якты көнне, якты исемебезне ничек саклап калырбыз соң?!

Рәшидә. Рәсим улым, син Мияссәр бабаңның тузынуына артык игътибар итмә.

Рәсим. Әйдә әле, Шифан.

Рәшидә. Ул бер төрле әйтер, мин икенчерәк... һәркемнең үз үлчәве бар.

Мияссәр. Чыпчыкка үз адымы да зур, димәкче син, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Кеше сүзе кешегә ярамас. Әгәр тыныч яшисең килә икән, миннән сиңа бер генә киңәш: өйләнмә!

Шифан (*бик борчылып*). Рәшидә апа!

Рәшидә. Бәхетле картаясың килсә, син дә кияүгә чыкма. Юләр булырсың.

Мияссәр (*таң калып*). Ни әйттең син, Рәшидә-әү?!

Рәшидә. Күпме яшәп, күпме газапланып ирешкән акылымны әйттем. Ачы тәҗрибә авазын...

Мияссәр. Юлны белеп тә, адашканга кире якны күрсәттең түгелме?!

Р э ш и д э. Үзем белгәнчә әйттем, гаепләмәгез.

М и я с с э р. Ничек әйтә алдың мондый суык сүзләрне?! Шушы сүзләрне әйтерлек үк күңелең каттымыни?!

Р э ш и д э. Беләсең ич. Сорама артыгын.

Р э с и м. Да-а... Ишеттеңме, Шифан?

Ш и ф а н. Син, Рәсим, бар, моннан ераграк йөр. Рәшидә апа, әйдәгез, керик. Ятып торырсыз, ял итегез. Башыгыз авырта булыр, куе чәй эчертермен! Бик кайнарын ясап бирермен.

Р э ш и д э. Рәхмәт, балам, бер төшем дә авыртмый.

Р э с и м. Менә бу киңәш! Акыл! Аңладыңмы, Шифан?

М и я с с э р. Син, егет, чынлап та читтәрәк йөр әле!

Р э с и м. Ачы тәҗрибә авазы! Өйләнеп, бала үстереп кем рәхәт күргән?! Бала чагымнан интернат ятимнәрен күрә киләм!

Р э ш и д э. Син, Шифан кызым, рәнҗемә миңа. Соңыннан, татыгач, барын белгәч, күргәч, миңа рәхмәт кенә укырсың. Читен ул семья хәлләре! Былтыр ничәү идек тә, быел күпмегә арттык? Әниең яңа бина салдырырга йөри, Рәсим улым... Ә болай, гомергә ялгыз калсаң, рәхәт! Кайгың бар икән — берүзең. Сөенечең килә икән — бер башың. Ялгыз кеше дә сөенечен таба ала! Таба!

М и я с с э р. Менә сиңа Рәшидә-әү! Менә сиңа олылар киңәше! Рәсим, Шифан, эндәшүе сезгә түгел аның, ялгыш аңламагыз! Рәшидә апагызның миңа җавап бирүе! Миңа. Шулай бит, Рәшидә-әү!

Р э ш и д э. Сиңа да, үз-үземә дә, балаларга да!

М и я с с э р (*арбаны тартып титаклап йөри*).

Әллә-бәлли, бәү-бәү,
Йокла-йокла, йом күзең.
Төнлә йокың кала да,
Елап үтә көндезең.

Ш и ф а н. Аягың сызлыймы, Мияссәр агай?

М и я с с э р. Бодай бөртеге хәтле генә мина ярчыгы утыра анда. Тез капкачында. Ай-һай, Рәшидә-әү!

Р э ш и д э. Чапма, алайса, тигрәк утыр.

М и я с с э р. Әллә йөрәккә дә мина ярчыгы барып тиде инде, сулкылдый.

Р э с и м. Шифан, әйдә әле.

Ш и ф а н. Рәшидә апа сине коралландырдымы? Ашыгып һөҗүмгә кучәсеңме? (*Кулларын күтәрә.*) Мин бирелэм. Әмма синең белән беркая да бармыйм. Аягымны да атламыйм... Монда яралылар барында, мин, шәфкать туташы... Китә аламмы?!

М и я с с э р. Сакалыңны кырып ыргытыйммы, Рәсим?! Кер! Бушлай!

Р ә ш и д ә. Рәнҗемә егеткә, Шифан... Рәсим турысын әйткән, алдап-юлдап маташмаган. Шуңа куан!..

М и я с с ә р. Ни булды сиңа?

Р ә ш и д ә. Инде чират миңа җитте! Миңа ни булганын күрмисеңмени? Колачы белән дөнья иңли торган җан!

М и я с с ә р (*күрсәтеп*). Тагын бер кат сорыйм, алар гаепләме?!

Р ә ш и д ә. Кем белсен... Төп гаеп, бәлки, миндәдер?

М и я с с ә р. Син изге җанда нинди гаеп-кыек булсын! Үз чордашларымның нинди авыр, данлы юл узуларын беләм. Нинди кыеннарда да намусыбызны сатмадык. Гомерең буе колхозда. Кышын-җәен эш-хезмәттә. Орденың бар! Курорт күргәнең юк, диңгезнең ни икәнен дә белмисең. Тамагың кайчан туйды? Әһә! Ә туган илгә синең кул аша күпме икмәк узган!

Ш и ф а н (*күзәтеп карап*). Бу кеше, Рәшидә апа, сезнең янга элегрәк тә килгәләде. Исемә төште! Шул! Үзе! Ул килүгә, сез каушап каласыз да, китүенә чирли идегез. Басымыгыз уйный.

Р ә ш и д ә. Әйе. Хак.

Р ә с и м. Китәбезме без, Шифан, юкмы? Бәлки, минем дә ярам ачылгандыр.

Ш и ф а н. Синең тәнең корыч, тирең калын. Ачылмас!

М и я с с ә р. Кем ул?!

Р ә ш и д ә (*газапланып, гасабиланып*). Бу котсыз кеше —минем улым.

Һ ә м м ә с е   б е р г ә. Улыгыз?!

М и я с с ә р. Булмаганны! Шаяртма!

Р ә ш и д ә. Әле бусы төпчеге. Тагын икәү бар минем, Мияссәр абзый.

М и я с с ә р. Менә сиңа вак бәлеш! Пешсә дә, авызга сыймый!.. Ә мин аның чак кына ипи шүрлеген җимермәдем.

Р ә ш и д ә. Өчесе дә сау-сәламәт. Ә мин монда ятимнәр арасында ышыкланып ятам. Ишеттеңме, Шифан! Син дә белеп кал, Рәсим улым. Сиңа «өйләнмә!» дигәнмен икән, юкка түгел. Ә сиңа «чыкма кияүгә!» дип үгет биргәнмен икән, кыланып түгел. Тормыш өйрәтте ул шыксыз ымнарга, бары тик шул гына.

М и я с с ә р. Өч улың?! Өчәү!.. Ә Көмешле Елгада безнең өй түрендә өч каен. Утыртма каен агачы, кайгыга батарсың, диде миңа күршеләр... Агачларым зур инде хәзер. Кайгым да бәләкәйдән түгел.

Р ә ш и д ә. Хәйлә белән монда урын алган икән дип рәнҗемәгез миңа. Юк, аңлата китсәң, озак та, авыр да...

Балаларны артык иркәләдек. Яраттык! Бары шул безнең гаебебез. Җилкәдән бик озак төшермәдек, муенга алар үзләре менеп атландылар. Актыккы серемне дә алдыгыз. Ә син: «Бергә булыйк!» — дисең, Мияссәр абзый. Йә, була аламмы мин синең белән?! Була аламмы?! Соңыннан барын да белер идең... Ничек яшәр идем мин калган көннәремне? Кояшка карый алыр идемме?! Авыз тутырып әйткән сүзем һаман бер: өйләнешмәгез, Рәсим! Шифан әйбәт кыз, сүз дә юк... Ә нинди заман килер? Балаларыгыз кем булып үсәр? Шуннан куркыгыз!

Рәсим. Рәхәт булып китте бит әле, әй! Бөтенесе, олысы-кечесе, «өйлән-өйлән», дип туйдырып бетергән иде. Ниһаять! Бер чын сүз! Туры сүз! Рәшидә апа, сез бу сүзне үз тәҗрибәгездән чыгып кына әйтмәгәнсездер, мөгаен?!

Рәшидә. Миндәйләр азмы әллә? Кими барабызмы?

Мияссәр. Ну, кирәген бирәм монысының! Теге улларыңны да эзләп табам. Рәсим, ярдәмең хәзер конкретно кирәк! Разрядың бар икән, давай, теркелдә!

Рәсим. Хәзер барырга да була!

Шифан. Менә хәзер барырга ярамый сиңа. Хакың юк.

Рәсим. Нигә булмасын?!

Шифан. Син дә үз ата-анаңның өметен алдадың!

Рәсим. Мине таш дип беләсеңме?! Бу гыйбрәтләр мине борчымыймы? Уйландырмыймы! Рәшидә апа кызганыч түгелме миңа?!

Мияссәр. Кызганасыңмы?

Рәсим. Теге улларын да эзләшим мин сиңа, Мияссәр бабай!

Мияссәр. Кешегә әверелә башладың, алайса! Йөнтәс маймыл идең, хәзер агачтан төшә башладың! Әгәр теге чучкаларны да аз-маз уйландырып тукмап җибәрә алсак, тәмам кешегә әйләнәсең!

Рәсим. Көлмәгез әле, Мияссәр бабай.

Мияссәр. Елап та булмый.

Шифан. Соңгы сүзем: син дә алар кебек үк кансыз, шәфкатьсез.

Рәсим. Алай каты хөкем итмә, Шифан. Өзмә өметеңне! Әллә ничек булып китте әле. Рәшидә әбинең өч улы исән! Өч! Үз балалары! Күз алдына китереп кара әле! Китереп булмый! Әллә ничек күз аллары яктырып китте, яхшырак күрәм кебек! Күлнең суы куе зәңгәр икән. Тирән җирләре яшькелт! Ә сез яр читендә басып торасыз, Мияссәр бабай. Рәшидә апа да синнән ерак түгел. Һәм бер читтәрәк мин... Әллә нигә күңелгә тирән уйлар агыла...

Шифан. Кыланчык! Маймыл!

М и я с с ә р (*Әдһәмгә кычкырып*). Әй, син, карачкы! Салам-торхан! Кил монда.

Р ә ш и д ә. Нигә чакырасың аларны?

Р ә с и м. Әйдә, үзебез барыйк.

Р ә ш и д ә. Хак юлга төшерермен дип уйлыйсыңмы?

М и я с с ә р. Ятып калганчы, атып кал. Вакыт!

Ә д һ ә м белән Х у р и я керәләр.

Х у р и я. Нигә чакырасыз безне? Абау, чырайлары. Көл ашаганнар.

Ә д һ ә м. Без беркемгә кагылмадык. Әйбер-карага тимәдек.

М и я с с ә р. Килегез, кил. Якынрак. Менә шулай. Йә?!

Ә д һ ә м. Килермен дә, китәрмен дә.

М и я с с ә р. Бернидән дә курыкмыйсың, алайса?!

Р ә с и м. Беркемнән дә?!

Ш и ф а н. Рәсим, катышма! Кеше хөкем итәргә әле синең хакың юк.

Х у р и я. Хөкем? (*Мияссәргә.*) Син, карт пәри, дөньяның баш-аягын бутама. Калдык-постык көчеңне үзең өчен сакла.

М и я с с ә р. Сәгать сукты, чык уртага! Әйт, кем басып тора синең каршыңда?! Яхшы кара, бутама! Таныйсыңмы?

Ә д һ ә м. Мин болай да бик әйбәт күрәм.

М и я с с ә р. Күргәч, әйт безгә. Кем?

Р ә ш и д ә. Йа Ходай!

Р ә с и м. Ну!

Ә д һ ә м. Бумы?

Х у р и я. Балаларын юньле тормыш көтәргә өйрәтә алмыйлар да, менә хатыннары газап чигә аннары! Кемлеген аның үзеннән сорагыз сез! Миннән! Сөйләп бирә алам!

Ш и ф а н. Сез дә сөйләгез.

Х у р и я. Менә, матуркаем, ышанырсыңмы? Авылның күпер төбенә кабык арбадан төшеп калган бер бичарасы иде. Мәхлук! Җәлләп шәһәргә алып киттем. Кеше иттем. Квартиралы! Шунысы яман — эчте. Бурычка батып бетте. Кәрт уйнап акча оттыра! Бүгенгесе көндә мең сум бурычы гына бар аның!

М и я с с ә р. Белүемчә, аның бурычы алай гына түгел.

Х у р и я. Әллә?!

М и я с с ә р. Менә хәзер ачыкларбыз!

Р ә ш и д ә. Чыннан да, эчәсеңме, улым? Элек бер дә капмый торган идең ләбаса. Әйт, бурычың күпме?!

Х у р и я. Улым? Үләм, валлаһи!

Ә д һ ә м. Минме? Минемме?!

Х у р и я. Әчә! Иснәп карагыз! Фу, күпчеп беткән.

Р ә с и м. Сездән сорамадылар, апа.

М и я с с ә р. Яле, яле!

Ш и ф а н. Китик моннан, Рәшидә апа. Авыр монда, читен.

Р ә ш и д ә. Улымның әҗәтенең күпмелеген тәгаен генә беләсем килә.

М и я с с ә р. Аның күпме бурычы барын үзем әйтәм!

Х у р и я. Әллә синнән дә алып торды, мәрхәмәтле карт?!

М и я с с ә р. Әтисенең якты исеме, әнисенең якты күне алдында аның бурычы — мәңге түләп бетерә алмаслык!

Х у р и я. Аны гына әйтсәң, ярый.

Ш и ф а н. Апа!

Х у р и я. Хәзерге балалар ата-ананы карамый. Ата-ана гомере буе бала тәрбияли. Үзебез дә бер имгәк үстереп ятабыз, беләм.

Ш и ф а н. Әйе, кияүгә чыкмыйм мин, Рәшидә апа.

Р ә с и м. Ашыкма, сиңа тәкъдим ясаган кеше дә күренми әле.

Ш и ф а н. Тәкъдимнәре белән соңга калдылар.

М и я с с ә р. Үзем яучы булып килсәм, нибуч, чыгарсың!

Х у р и я. Ярый, акчабызны бирегез дә, без китик. Кеше машинасы. Без бит ярлы-ябагай, ата малы белән калмаган, булганын бөртекләп җыйган.

М и я с с ә р. Бирәбезме акча, Рәшидә-әү?

Х у р и я. Нигә дәшмисең, Әдһәм? (*Шыпырт.*) Өй ачкычы миндә, баскычта кунарсың, чамала!

Ә д һ ә м. Әйе, бу минем әнием.

Ә с м а керә.

Ә с м а. Ник болай җыелдыгыз? Кыяфәтләрегез дә мәзәк. Сугышырга торган кыдрач әтәчләр шикелле. Болары кемнәр? Кем янына килгәннәр?

Ә д һ ә м (*Хуриягә, шыпырт*). Директор!

М и я с с ә р. Кемнең кем икәнен, кемнең кемгә күпме бурычы бар икәнен ачыклыйбыз.

Х у р и я (*кычкырып*). Директормы?

Ә д һ ә м (*качарга ымлап*). Үзе!

Х у р и я. Әһә!

Р ә ш и д ә. Китегез. Барыгыз, юлыгызда булыгыз. Сораганыгызны табып салырмын.

М и я с с ә р. Алай ук димә, Рәшидә. Акча үзебездән дә артмас.

Х у р и я. Кемнең кем икәненә пичәт сугу кирәк. Хөрмәтле иптәш директор бик вакытлы килде. Кайбе-

рәүләрнең, балалары барлыгын яшереп, хөкүмәтне бер яктан, улларын икенче яктан мыштым гына имеп ятканын ачыкларбыз.

Әдһәм. Життеме сиңа, Хурия, юкмы?!

Рәшидә. Зинһар, күземнән генә югалыгыз.

Мияссәр. Чү, телиләр икән, анык белеп китсеннәр! Исемең бармы синең, йә?!

Әдһәм. Әдһәм лә мин!

Мияссәр. Бездә дә бер зур сүз бар иде, Әсма, олы киңәш. Без, Рәшидә белән икәүләп, минем авылга, минем йортка күчеп китәргә мәслихәтләштек. Ягъни синең элеккеге әнкәң белән инде ул, Әдһәм, Хуриянең ире!

Хурия. Әдһәм, анаң кияүгә чыга! Бурычын калдырмасын!

Әдһәм. Тфү! Тел түгел, чалгы янавычы.

Хурия. Бурычың биш йөз! Төп-төгәле! Китсә, тәтемәс!

Әсма. Мияссәр абзый, бу сүз уен түгелдер дип беләм. Гәрчә син шаярткаларга яраткалыйсың.

Мияссәр. Ялгыз яшәүне дошманыма да теләмим. Хәтта менә бу ала күзгә дә! Без татыдык, мәҗбүр идек... Ә берәүләр (*Рәсимгә ымлый.*) ирекле баштан ялгыз яшәргә маташалар!.. Авылны, туган җирләрен ятка калдырып китәләр.

Рәсим. Мияссәр бабай, алай ук димә әле син!

Мияссәр. Әйтергә хакым бар! Җан әрнүем хак!

Рәсим. Мин сезне аңлыйм шикелле.

Рәшидә. Мин риза, Мияссәр абзый. Сине кызганам! Җаның һаман тере ич синең! Тырпылдый торган җан! Бергә булыйк. Гомеребезнең аянычлы азагын бергә уздырыйк. Җиңелрәк булыр.

Мияссәр. Рәхмәт сиңа, Рәшидә-әү! Какмам, рәнҗетмәм. Бергәләп яшәү икебезгә дә җиңелрәк булыр. Кайтам да тәрәзә такталарын каерып ыргытам.

Рәшидә. Мин пыяла тузаннарын юармын!

Мияссәр. Дөрес! Ичмасам, тагын бер авыл йортына нур керсен!

Әсма. Мин дә хуплыйм. Гәрчә монда, бездә, диюем, начар да түгел... Алай да...

Рәшидә. Көч кенә бетеп калды. Юкка сарыф иттек без аны.

Мияссәр (*һаман Рәсим ягына ишарәләп*). Яшьләр оятына көч килсен.

Хурия. Әдһәм!

Әдһәм. Кирәкми миңа акча. Машина да кирәкми.

Хурия. Алайса, барыгыз да белегез! Менә ул, ягъни минем ир җәфам, Рәшидә апа дигәннәренең улы!

Ә с м а. Беләм. Мин Рәшидә апаның өч улы барлыгын әллә кайчаннан бирле беләм.

Р ә ш и д ә. Ничек?

Ә с м а. Безнең арада күп яшәгән, күпне кичергән затлар да бар. Аларның эч серләрен ачып, хәсрәтләрен арттыруның һичнигә хаҗәте юк.

Ә д һ ә м. Сез барын белә торып, аны монда тоттыгызмы?

Ә с м а. Күрәсең ич.

Ә д һ ә м. Хурия, ишеттеңме?

Х у р и я. Сиңа ни кирәк соң?

Ә д һ ә м. Миңа бүгеннән берни дә кирәкми.

М и я с с ә р. Ничек? Алай булмый инде. Менә Рәсим алма кебек ярыннан баш тартты. Димәк, аңа без белмәгән нидер кирәк. «Машина кирәкми»,— дисең. Нидер сиңа да кирәктер инде? (*Шифан елый.*) Елама, дим, түкмә яшеңне.

Х у р и я (*Әдһәмгә сырпаланып*). Аңа мин генә кирәк.

Ә д һ ә м. Син дә кирәкмисең. Әгәр әни рөхсәт итсә, Мияссәр каршы төшмәсә, мин дә алар белән авылга кайтыр идем. Үз авылдашларымнан оялам. Йорт та юк. Көмешле Елгага! Комбайнчы идем. Уч тутырып акчасын ала идем. Почетым бар иде! Кеше идем. Узганда сокланып карап калалар иде. Минем төп урыным авыл булган! Хурия! Өч бүлмәле квартира, ике машиналык акча, кием-салым — һәммәсе сиңа калсын. Шулар бәрабәренә мин синнән котылыйм.

М и я с с ә р. Әй, Рәшидә-әү! Ул бит әле алай карт түгел, өшәнгән генә. Без малайлы булабыз түгелме? Әй, Әдһәм! Кайту белән мин сине өйләндерәм. Безгә касмак башлы бер кара малай алып кайтасыз! Бүләк әзер, тот бәбәй арбасын!

Р ә с и м. Мияссәр бабай, коляска безгә түгелмени?

М и я с с ә р. Базардан бәрәңге ташыргамы?

Ә с м а. Улым, ачыклап сөйлә.

Р ә с и м. Шифан, читтә боегып торма алай.

Ш и ф а н. Нишлим соң? Төшеп биер идем, сәбәбе юк.

Р ә с и м. Сиңа сүзем бар.

Ш и ф а н. Миңа?

Р ә с и м. Яшьлек мәхәббәтем бәрабәренә мин сиңа үземне бүләк итәм. Гомерлеккә! Ризамы? Бирәсеңме кулыңны?!

Ш и ф а н. Рәшидә апа ни әйтер бит әле?!

Ә д һ ә м. Әни, әйт.

Р ә ш и д ә. Бир кулыңны, балам, бергә булыгыз.

Ә с м а. Сөендердең, улым. Тормышыбызны бизәдең. Анда әтиең пыр туза югыйсә.

Р ә с и м. Ул пыр тузганга түгел лә! Үз күңелем, үзем... Мияссәр бабай! Шифаннар йортына миннән яучы булып бар!

Ә д һ ә м. Үзем кияү егете!

Р ә с и м. Ефәк баулы былбыл кошны алып кайтыйк, әни. Рәнҗетмик саф күңелләрне. Шәһәргә китәм икән, бер елдан әйләнеп кайтам.

Ш и ф а н. Чын күңелдәнме, Рәсим?!

Р ә с и м. Ризамы син?

М и я с с ә р. Ризалыкны яучыга гына белдерәләр. Кайгырма, Әдһәм улым. Арбаның менә дигәнен алып бирермен. Үзеңә тиң былбыл синңа да табылыр, ил-йортыбыз буш түгел, шөкер! Бар анда затлы җаннар, бар! Ә хәзер тезелегез! Кыз йортына барабыз, Шифан, йөгер! Киләләр, диген!

Шифан көлә-көлә чыгып китә. Һәммәсе дә тезелешеп җырлап чыгып баралар.

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең илеңдә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!

Арба тәгәри, алар җырлый, башта кыяр-кыймасрак торган Әдһәм дә аларга иярә, Хуриягә бер тапкыр да борылып карамый.

П ә р д ә.

# *Эчтәлек*


Киек Каз Юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Көзге ачы җилләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Җиргә тапшырылган серләр . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Шомырт чәчәк атканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Кара күзле кызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Җиз кыңгырау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
Хәдичәнең кече улы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
Яланаяклы кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 377
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз... . . . . . . . . . . . . . 429
Ефәк баулы былбыл кош . . . . . . . . . . . . . . . . . 489

Литературно-художественное издание

*Гилязов Аяз Мирсаидович*

**Избранные произведения**

в пяти томах

**Том 2**

(*на татарском языке*)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, С.Н.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 23.11.2002.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы-басма табагы 27,72+ф.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 28,04. Нәшер-хисап табагы 28,28+ф.0,36.
Тиражы 3000. Заказ Б-700.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.